ISSN 0206—4189



# КАЗАН УТЛАРЫ

5.1987



# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ

ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ОРГАНЫ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

5

1987

КПССның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ КОМИТЕТЫНЫҢ ГАЗЕТА ҺӘМ ЖУРНАЛЛАР НӘШРИЯТЫ

КАЗАН


## *Бу санда*


Н. АРСЛАНОВ. Сак-Соклар. Поэма . . . . . 3
М. МАЛИКОВА. Басып сайрар талы бар. Роман 8
Р. ГАТАУЛЛИН. Тормыш бизәкләре. Кави Латыйпка — 60 яшь . . . . . 60
К. ЛАТЫЙП. Мәхәббәт һәм нәфрәт. Шигырьләр 61
Ә. ГАФФАР. Йөрәк хәтере. Җәмил Мостафинга — 60 яшь . . . . . 65
Җ. МОСТАФИН. Ике язмыш. Хикәя . . . . . 66
Ф. ЯРУЛЛИН. Җыр башы. Шигырьләр . . . . . 74
Р. ӘБУБАКИРОВА. Картлар нигә туңа. Хикәя 78
К. СИБГАТУЛЛИН. Безнең моңнар. Шигырьләр 83
Р. ЮНЫСОВ. Дәште съезд. Шигырьләр . . . . 86

ОСТАХАНӘ

З. ХӨСНИЯР. Сыңар канат. Хикәя . . . . . 89
М. ХӘСӘНОВ. Читтә калмаска! . . . . . 95
В. ИМАМОВ. Таныш тыкрык. Хикәя . . . . . 97
Г. АХУНОВ. Киләчәк — һәркемнең үз кулында 102

КПССның XXVII СЪЕЗДЫ КАРАРЛАРЫН — ТОРМЫШКА!

М. ХӘСӘНОВ. Урман кайтавазы . . . . . 103
М. ЗАРИПОВ. Сигез сыер асраганчы... . . . . 110

ТАТАРСТАН — ТУГАН ТӨБӘГЕМ

Н. Н. ӘХМӘТҖАНОВ. Илһам чыганагы. *(Актаныш)*. . . . . 125

АЭС — ӘДӘБИ ПОСТ

М. ӘҺЛИУЛЛИН. Көрәш кискенләшә . . . . 129

БЕЗНЕҢ ӘХЛАК

Ф. ЛАТЫЙПОВ. Алдану . . . . . 132

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

М. ВӘЛИЕВ. Учагың сүрелмиме? . . . . . 140

ЯҢА ӘСӘР УКЫГАЧ

Ф. ДУНАЙ. Сөюнең сынаулары бар . . . . . 151

БИБЛИОГРАФИЯ

Л. ЛЕРОН. Йөрәктә ниләр бар? . . . . . 156
Г. ГЫЙЛЬМАНОВ. Шагыйрь сүзе бер була . . 158

ОРЕНБУРГТА КУЛЬТУРАБЫЗ ИСТӘЛЕКЛӘРЕ

Муса Җәлил яшәгән йорт. З. МӨХӘММӘТҖАНОВА рәсеме . . . . . 162
Җ. МИҢНУЛЛИН. Оренбург һәм Җәлил . . . 163

*Баш редактор*
**РЕНАТ ХАРИС**

*Редколлегия*

**МАРСЕЛЬ ГАЛИЕВ**

**ӘХӘТ ГАФФАР**

**МИРКАСЫЙМ ГОСМАНОВ**

**АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ**

**МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВ**

**МӘДИНӘ МАЛИКОВА**

**САЛИХ МАННАПОВ**
*(җаваплы секретарь)*

**ТУФАН МИҢНУЛЛИН**

**ФӘҮН МУСИН**

**РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВ**
*(баш редактор урынбасары)*

**РӘФЫЙК НӘФИКОВ**

**НУРИХАН ФӘТТАХ**

**РИЗВАН ХӘМИД**

**НИЛ ЮЗИЕВ**

**АЗАТ ӘХМӘДУЛЛИН**

Безнең адрес: 420066,
Казань, ул. Декабристов, 2.

Телефоннар:
баш редактор —53-07-60,
баш редактор урынбасары —
53-07-09,
җаваплы секретарь —53-07-09.
*бүлекләр:*
проза, поэзия, очерк —53-07-61,
тәнкыйть, фән, сәнгать,
хатлар —53-07-63.

СӘИД ВАХИДИНЫҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ

М. ГОСМАНОВ. **Игелекле мирас** . . . . . . . . 164

МИРГАЗИЯН ЮНЫСКА — 60 ЯШЬ

Л. САБИРОВА-ХӘЙДӘРОВА. **Яшәү мәгънәсе** . . 169

ӘДӘБИЯТЫБЫЗ ТАРИХЫНА

Р. МОСТАФИН. **Абдулла Алиш белән очрашу** 173
А. АЛИШ. **Очрашу.** Шигырь . . . . . . . . . 178

СӘНГАТЬ

Ж. ИТКИНА. **Рахлин могҗизасы** . . . . . . 180
Т. ӘИДИ. **Заманнарга куелган һәйкәл** . . . . 182

ЮМОР-САТИРА

З. НУРИ. **Китап лотереясы.** Шигырьләр . . . . 189
**Культура тормышы көндәлеге** . . . . . . . . 190
**Тышлыктагы сурәтләр** . . . . . . . . . . . . 192

## В нашем номере

Поэма Н. АРСЛАНОВА, стихи К. ЛАТЫПОВА, Ф. ЯРУЛЛИНА, К. СИБГАТУЛЛИНА, Р. ЮНУСОВА; окончание романа М. МАЛИКОВОЙ «Ивушка плакучая», рассказы: З. МУСТАФИН — «Две судьбы», Р. АБУБАКИРОВА — «Старость — не радость».
В рубрике «Литературная мастерская» рассказ З. ХУСНИЯРА разбирает писатель М. ХАСАНОВ, рассказ В. ИМАМОВА «Знакомый переулок» разбирает писатель Г. АХУНОВ.
Решения XXVII съезда КПСС в жизнь — очерки М. ХАСАНОВА «Лесное эхо», М. ЗАРИПОВА о современных проблемах животноводства.
В рубрике «Татарстан — родной мой край» — выступление первого секретаря Актанышского райкома КПСС Н. АХМЕТЗЯНОВА.
«Литературный пост — АЭС» — статья М. АГЛИУЛЛИНА «Борьба обостряется».
В рубрике «Наша мораль» — очерк Ф. ЛАТЫПОВА «Искушение».
Литературная критика» — статья М. ВАЛЕЕВА «Очаг». Рецензия Ф. ДУНАЯ на новую книгу Ф. Байрамовой.
«Библиография» — рецензии на поэтические сборники Ф. Сафина и Ш. Бабича.
«Памятники татарской культуры в Оренбурге»: дом на улице Ленина, где жил М. Джалиль.

К 100 летию Саид Вахиди — Статья М. УСМАНОВА «Благодатное наследие». Миргазияну Юнысу — 60 лет: статья Л. САБИРОВОЙ-ХАЙДАРОВОЙ «Смысл жизни».

«К истории литературы» — публикация Р. МУСТАФИНА об Абдулле Алише.
В рубрике «Искусство» статьи Ж. ИТКИНОЙ о дирижере Н. Рахлине. Т. АЙДИ об архитекторе М. Булатове.
Стихи З. НУРИ.
Дневник культурной жизни.
На наших обложках — образец татарского ювелирного искусства — хасита и памятник павшим героям в Казани.

Техник редактор *Р. Сөләйманова.* Корректорлар *Т. Сибгатуллина, Г. Салихҗанова.*

Производствога бирелде 27.02.1987 ел. Басарга кул куелды 22.04.1987 ел. ПФ 05140. Офсет ысулы белән басыла.
Кәгазь форматы 70×108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8).
Тираж 67149. Заказ М-101. Бәясе 90 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе,
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1987 ел.

## **Нури Арсланов**

# САК-СОКЛАР

ПОЭМА

*

Кызыл вокзалда пыяла ишек.
Сак белән Сокның бәетен ишет.
Ике баланың язмышы элек
Җырланган диләр, бәеткә кереп.
Каргалып бергә, кош булгач, алар
Гомер-гомергә кавышалмаганнар...
Якынлашсалар, имеш, таң ата,—
Кавышу өметен шундук тарата:
Аерыла икән Сак-Соклар елап.
Китәләр икән каңгырап ерак...

*

Алар язмышы килде безгә дә,
Әкиятләр шулай чынга үзгәрә:
Кызара каннан кояш баешы,
Килә еррактан Сак-Сок тавышы...
Салкын сабырлык өнди түзәргә,—
Ә хәсрәт төсе чыга күзләргә,
Мөлдерәп тора, яшьләргә тулып,
Юылмас зарны юардай булып.
Ватан өстендә кара болытлар...
Коткар иленне, бәладән коткар!
Һәлакәт атлый изге йортыңа,—
Тетри Җир шары, Кояш тотыла.

*

Варислар онытмый шәһитләр васыятен,
Әманәт итәләр тарихлар хасыятен.
Казанның болытлы чаклары булганмы?
Борынгы җимерелгән, таланган Болгарны
Дәвамлап калыккан, караңгы көннәрдә,
Давыллар кичсә дә, тузмаган көлләргә!
Мәйданда батырлар егылган көрәштә...

---

НУРИ АРСЛАНОВ *(1912)— өлкән шагыйребез, татар һәм рус телләрендә утыздан артык китап авторы, ТАССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты. Казанда яши.*

Ә Казан каласы горур да, көләч тә,
Ул тора сызганып, Иделдәй киң сулап,
Мин әзер! дигәндәй, көрәшкә яу сорап.

*

Кызыл вокзал шыгырым тула:
Китәләр... Озаталар...
Берәүләр яшькә буыла,
Берәүләр юаталар:
— И, улым, улым, улым!
Әйбәт иде уегыз,
Ниләр кылыйм!.. Шуңа җылыйм —
Булмый калды туегыз.
И, улым, улым, улым!
Әллә Герман шашканмы?..
Кайда йөрми, ниләр күрми
Газиз солдат башлары.
И, улым, улым, улым!
Бу хәсрәтне күргәнче
Яшәрмен дип белмәдем бит —
Яшьләргә күмелгәнче...
— И, әни, әни, әни,
Күз яшең кем башына?!.
Сугыш туктар, улың Мохтар
Кайтып басар каршыңа.
И, әни, әни, әни,
Җибәргән хатларыма
Юанырсың, куанырсың
Сагынган чакларыңда.

*

Ә Җәүһәр бер читтән генә
Мохтарга карап тора.
Яшьли хәсрәт чиккәненә
Йөрәге канап тора...
Бөркет нигә ау алмасын,
Ауга салсыннар да ди,
Йөрәк нигә кан саумасын,
Бәгырьнең канлы калҗасын
Умырып алсыннар да ди!..

*

Һәркем үз уен уйлый.
Гармун үз моңын уйный.
Күңел тулгач — күзләрдә яшь,
Тыелып булмый, булмый...
Сибә лә гармун, сибә лә,
Моң ага, моң тирбәлә,
Йөрәгенә чыдый алмый
Егет җырлап җибәрә:
«Сандугачның мөшкел хәле —
Канаты каерылган...
Бер без генә түгел әле
Ярыннан аерылган».

*

Менә өч тапкыр чаң сукты,
Йөрәккә чәнчеп алды:
Паровоз сузып кычкыртты,
Пошкырды һәм кузгалды.
Кузгалды кораллы солдат,
Вагоннарга төялеп.
Ә Җәүһәрләр калды карап,
Рәшәткәгә сөялеп.
Китте яшьлек, китте шатлык,
Өметләр китте бергә...
Насыйп булыр микән, кайтып,
Туган илне күрергә?..

*

Әллә кырлардан, әллә урманнан
Ишетелә моңлы Сак-Сок тавышы.
Ак яңгыр сыман, күзләрдә томан,
Хатларда килә солдат сагышы...
Сак-Сок тавышын җилләр тарата,
Сак-Сок бәетен солдат яңарта:
Кырыс язмышка кирәк булдык без,
Бу дөньяларга гыйбрәт булдык без.
Өч почмакланып бөгелгән хатлар,
Күңелдән моңнар түгелгән чаклар!..
Илкәйдән хатлар, әнкәйдән хатлар,
Толлардан хатлар, кызлардан хатлар...
Хатларда моңлы Сак-Соклар өне,
Ишетелә хәзер ул көне-төне.
«Кара карлыгач, сары сандугач,
Әнкәй, жылама, солдат булды баш.
Унтугыз тулгач, «язылды канат»,
Безне озатып калдылар карап:
«Мохтар, исән кайт, җиңүгә ireш!»
Хатлар языла окопта килеш:
Таулар кичтек без, сулар йөздек без,
Сак-Соклар булып дөнья гиздек без.
Аклы күлмәгем туя кимәдем,
Газиз ярымны туя сөймәдем»...
Төннәр дә була, таңнар да туа,
Сак-Сок бәете дөньяга тула.

*

Сак-Сок бәетенә йолдызлар чыңлый,
Сак-Сок бәетенә тол кызлар җырлый.
Элек чәчәктәй нәфис сылулар
Инде саргаеп, гөлдәй сулдылар...

*

Гөрелдәп еракка китсә дә яулар,
Күчсә дә тарихка дәһшәтле даулар,
Халыкның йөрәктә ярасы бетмәгән,
Тешләнгән ирененнән каннарын сөртмәгән,
Күзендә бәллүрдәй яшьләре кипмәгән...

Бугазга тыгылган төердән күп еллар
Арынмас, айнымас ятимнәр һәм толлар,
Күчкәндәй бәетләр телләрдән-телләргә,
Күчәр ул хатирә киләчәк көннәргә!

*

Карлар сугарып торса да,
Сула умырзая да,
Күпме хыяллар корса да,
Үтте гомер заяга...
Үтте еллар өмет куып,
Җуелдылар эзләр дә.
Кайгы кара печать булып
Ятты якты йөзләргә.
Кара печать, кара печать,
Кайттың сугыш кырыннан:
Мохтарларга кердең нишләп,
Узмыйча бер кырыйдан?!.
Җәүһәр кыз килеш тол калды
Мәхәббәттән, рәхәттән...
Кызлар кырык ел сызланды,
Түземнәр ашты хәттән:
Теләкләргә киртә салып,
Язмыш яман уйнады.
Вакыт китәр әле алып
Бөтен хәсрәт-уйларны,
Дип өметләнде тол кызлар,
Юаныч табып эштә.
Тормышта юк шул тылсымнар,—
Сагыш көйрәде эчтә...
Хезмәттә эш уңган белән
Гомер җамы тулмады,
Уртак бәхет булган белән
Тол кызларның — Җәүһәрләрнең
Үз бәхете булмады...

*

Яшьләр инде акмаса да,
Күзләрдә һаман да чык...
Яу, ук төзәп атмаса да,
Чыкмакчы мәйдан ачып.
Сугыш кара яшен төсле
Атмакчы була кабат.
Кемнәр анда, безгә үчле,
Яңадан суга набат?!
Хиросимада «сынаулар»
Үткәрелде бит инде...
Басыгыз сафка, уяулар!
Акыл, хөкем ит инде:
Булмасын дип һәлакәтләр,
Зур бәхәс барган чакта,
Тетри җирләр, мәмләкәтләр!
Хикмәт, син кайсы якта?!

Үзең уйлап тапкан көчне
Үзең үк авызлыкла!
Җәннәт төсле җирнең өсте
Шартлап чыкмасын юкка.
Тол кызлар дигән кушамат
Тагылмасын тагын да.
Чәчәк ат, хаят, чәчәк ат
Гашыйклар кочагында!
Кеше! Яктырсын тормышың
Кояшың белән бергә,
Ал кулыңа Җир язмышын,
Ул әверелмәсен көлгә.
Гөлбакчалар шаулап торсын,
Җиргә кырау кунмасын!
Сак-Сок бәете булса булсын,
Тик Сак-Соклар булмасын!

*

Әрни җан, сыкрый җан Сак-Соклар зарына...
Һаман да моңнары бәгырьгә сарыла,
Һаман да тол кызлар язмышны каргыйлар:
«Ал өстән гарасат дәһшәтен, ал!»— диләр.
Әверелсә түгәрәк Җир кара печатькә,—
Һәлакәт! Котылгы юк аннан нишләп тә.
Тол кызлар шикелле тол калса Җир-Ана,—
Хыяллар зир-зөбәр, яшәү юк дөньяда!
Мәетләр тәненнән өелсә зур таулар,
Сөякләр, көлләрдән ялралса утраулар,
Яралса җиһанда өрәкләр оясы,
Әйләнсә галәмдә җансызлар дөньясы,
Тоташ бер кабергә әверелгән Җиргә без,
Кем белә, кешеләр, яңадан килмәбез...
Сакла син, Кешелек, сеңлесен Кояшның —
Иминлек, мәхәббәт һәм бәхет оясын!

*1986.*

# Мәдинә Маликова

# БАСЫП САЙРАР ТАЛЫ БАР

РОМАН

27



Язмышлар тактасы»на «Кадимбикә»дә уйнаучыларның яңа исемлеге эленде. Кадимбикәгә ике актриса — Исмегөл белән Сафия билгеләнгән иде.

Исемлекне укыганда, Сафия катлаулы хис кичерде. Ул, әлбәттә, сөенде, куанычы, җылы дулкын булып, аяк очларына хәтле барып җитте. Шул ук вакытта көенми дә булдыра алмады. Көенүе Наргизә өчен иде. Бикбау аны Кадимбикәдән бөтенләй читләштергән. Залда, коридорда артистлар туктаусыз йөреп, сөйләшеп-көлешеп торалар иде, әмма барыбер Сафия Наргизәнең аяк тавышларын әллә каян ишетеп алды. Аның якынлашканын тоеп торды, тик борылып карамады, урыныннан кузгалмады. Теге көннән соң алар бер-берсе белән сөйләшмиләр, үпкәләшкән ир белән хатын төсле, кечкенә бүлмәдә бер сүз алышмый яшиләр иде. Менә Наргизә бүлмәдәше янына килеп басты, менә белдерүне күздән кичерде. Сафия моны карамаса да тоеп торды, әйтерсең лә, аның күңеле радиоалгыч кебек, Наргизәнең күңел хисләрен тотарга көйләнгән иде. Менә үзәкне әрнү хисе сызып-сызып узды — Сафия Наргизәнең адымнарын шулай кабул итте, җан ачысы аяк атлауларында ук сизелеп тора иде. Ул коридорга борылгач, Сафия сиздерми генә күзәтеп барды. Наргизә грим бүлмәсен узып китте, баскыч мәйданчыгына чыкты. Аннары, берничә минут эчендә бер гомергә картайгандай, авыр, әкрен атлап, баскычтан төшә башлады. Ул төлке бүреген, киярга онытып, кулына тотып бара иде. Сафиянең күз алдында, әйтерсең лә, җиргә иңә, кечерәя барды. Менә аның иңбашлары күренмәс булды, менә җирән бөдрәләре ялкын теле булып җилпенде дә тәмам күздән югалды.

Ул шул хәлендә хәтергә нык уелып калды, репетиция барганда да әледән-әле Сафиянең күз алдыннан Наргизәнең боек кыяфәттә әкренләп баскычтан төшеп киткәне чагылып узды. «Кайткач, ничек тә көен табарга тырышырмын, янәшә утырып, ачыктан-ачык сөйләшербез, аңлашырбыз»,— дип уйлаган иде ул. Шуңа күрә, репетиция бетүгә, ашыкпошык киенде дә йөгереп өенә чыкты. Әмма Наргизә бөтенләй башкача уйлаган, бүтән хисләр белән янган икән. Сафия ишекне ачканда, ул идән уртасында басып тора иде, башын горур борып, күзләреннән очкын

---

Ахыры. Башы 3, 4 саннарда.

сибеп карады, кулын иреннәренә тигерде һәм колак төбендә сискәндергеч каты сызгыру яңгырады:

— Каравыл! Талыйлар! Дус дусны талый!

Низам бүләк иткән сыбызгы иде бу.

Сафия, артка чигенеп, ишекне япты, бүлмәдән Наргизәнең сулкылдау аша шаркылдап көлгәне ишетелеп калды.

Урамга чыкканда, Сафиянең бөтен тәне калтырый иде. Бераз вакыт ул капка төбендә зиһенен җыя алмый торды. Аннары бүген иртәдән бирле ашамаганын исенә төшерде. Ашханәгә кереп, май таплары белән чуарланган пластик өстәлдә борчак боткасы белән таралып торган кәтлит ашап, алма суы эчкәч, хәл кергәндәй булды.

Кичке спектакльгә хәтле вакыт шактый иде әле, ул Актерлар йортының китапханәсенә юнәлде. Кадимбикә өчен кием тектергәндә, нинди фасон сайларга? Борынгы патшабикәләр, ханбикәләр ничек киенгән? Шуларның рәсемнәрен табып карыйсы килә иде аның.

Исемнәр күп иде. Мәхәббәте, чибәрлеге һәм зирәклеге белән тарихта мәңгелеккә калган Мисыр патшабикәсе Клеопатра. Тумыштан королева булган, ләкин үзенә лаек пар тапмаган, шуның нәтиҗәсендә һәлакәткә дучар булган Шотландия королевасы Мария Стюарт. Ирен үтереп тәхеткә менгән, соңрак зирәк патшабикә буларак бөтен дөньяга танылган Екатерина Икенче... Һәм язмышы беркемгә охшамаган, илен-җирен, Казан каласын афәтләрдән йолып калу хакына үзен һәлакәткә дучар иткән Сөембикә.

Төрле язмышлы патшабикәләр, данлы хатын-кызлар яшәгән бу дөньяда, тик аларның сирәге генә халкының җырларында, бәетләрендә урын алган. Үз язмышын Ватаны язмышы белән аерылгысыз үргән, халкы өстенә килгән афәтне үз җилкәсендә күтәрергә омтылган хатын һәм ана булып, фаҗигале тормыш юлы узган ил кызы булып күз алдына килеп баса Сөембикә җырларда һәм бәетләрдә.

Боларны укыганда, Кадимбикәнең: «Әгәр дә минем канымнан кызыл гөлләр үсә торган булса, һәр тамчысын орлык итеп туган җиремә сибәр идем»,— дигән сүзләре күңелгә килде.

Китаплар Сафияне тарихи язмышлар арасына алып кереп, дускае белән ачуланышуны оныттырганнар иде. Урамга чыгуга, тагын шул искә төшеп, кәеф кырылды: алар бүген «Галиябану»да бергә уйнаячаклар иде. Күрәсем килми дип, бер-берсен әйләнеп уза алмыйлар — грим бүлмәләре үк уртак. Ишектән тын гына керделәр, бер-берсенә аркаларын куеп, икесе ике көзге каршында грим салдылар. Әледән-әле терсәкләре белән бәрелешеп, киенделәр — дәшешмәделәр.

Ләкин сәхнәдә алай кылану мөмкин түгел: алар анда ахирәт дуслар бит. Күзләргә туры карарга, ачык йөз, тәмле тел белән сөйләшергә, серләшергә кирәк. Дөрес, сәхнә артына чыгуга, үпкәләрне искә төшереп, йөзләрне чытарга тырышалар, ләкин эчтәге ачу барыбер элеккечә үк кабармый, шактый шиңгән була инде.

Менә шундый ул — театр дөньясы. Бер-береңә кинә саклап, бүртенеп, озак йөри алмыйсың, сәхнә ирексезләп диярлек, килештерә, яраштыра, үпкә-сапкаларны оныттыра.

Алай да тамам ачылып китәргә мин-минлек ирек бирми әле. Наргизә тиз-тиз киенде дә, ашыгып, алдан чыгып китте. Сафия юри соңгарак калды. Һәм ишек төбендә үзен көтеп торган Әхмәтнуровны күргәч, бер җиңеллек тойды.

## 28

Сафиянең өйгә, Наргизә янына керәсе килми иде. Әхмәтнуров та ашыкмый иде булса кирәк, ничектер шулай, алар сүзгә мавыгып, капкадан читкәрәк киттеләр, аннары аркылы урамга борылдылар. Монда

аеруча аулак, тыныч иде, машина да узмый, җәяүле дә күренми, ераграк барыгыз дигәндәй, аркадан апрель аеның салкынча, дәртләндергеч җиле этәрә, ике якта тезелеп торган борынгы йортлар, без сезне күрмәгәнгә сабышырбыз, серегезне кешегә чәчмәбез дигәндәй, тәрәзәләрендә утларны сүндереп куйганнар иде.

— Мондый чакта Сез нишләр идегез, иптәш Әхмәтнуров?

Сафия моны шаярып сорагандай әйтте, әмма көлемсерәве аша әрнү саркып чыкты.

— Беренчедән, без Сезнең белән җыелышта утырмыйбыз, миңа Нигъмәтҗан дип эндәшсәгез дә була,— диде Әхмәтнуров.— Икенчедән, мин аңламый калдым әле: нинди чакта?

— Әйтик, Сезнең җан дустыгызга бик мөһим бер эш ышанып тапшырдылар ди.

— Роль уйнарга,— диде Әхмәтнуров көлеп.

— Әйдә, Сезнеңчә булсын: бер зур бина төзү эшен җитәкләргә куштылар ди. Безнең өчен бер роль уйнау сезнең бер бина торгызуыгыздан һич тә ким түгел.

— Миражлар төзисез инде, воздушные замки.

— Сез һаман шаяртасыз.

— Бүтән алай итмим, бетте-бетте.— Нигъмәтҗан тун җиңе белән Сафиянең иңбашын сыйпаштыргандай итте.

— Дусыгыз шул эшнең шактый өлешен башкарганнан соң, комиссия килә дә, болай ярамый, бүтәнчә эшләргә кирәк дип, карар чыгара һәм, дустыгызны урыныннан алып, Сезне куя.

— Наргизәдән алып, төп рольне Сезгә бирделәрмени?

— Шулай иттеләр шул.

— Ә сез риза булдыгызмы?

— Мин моны режиссердан үзем сорадым.

Беразга тынлык урнашты. Аяк астында боз нык шытырдый башлагандай булды, караңгылык куера төште, урам чатына җиткәч, биткә ачы җил бәрде.

— Бик үк матур килеп чыкмаган икән шул,— диде ниһаять Нигъмәтҗан.— Әгәр берәү минем урынны үзенә даулап йөри икән, ул нинди дус була инде?

Сафия хәлне дөрес аңлатып җиткермәгәнен төшенде.

— Юк ла, алай түгел, спектакльне худсовет кабул итмәде,— диде һәм вакыйгаларны тәфсилләбрәк аңлатырга кереште.

Әхмәтнуров Сафиягә якынайган кебегрәк булды. Урам аша чыгып, йортлар ышыгына кергәч, җил тагын әкренәйде.

— Алай булгач, дустыгыз Сезгә үпкәли алмый инде,— диде Нигъмәтҗан. Аннары бераз тынып торгач: — Тиеш түгел дип әйтүе генә ансат инде ул,— дип куйды.— Күңел дигән нәрсә бар бит әле. Теге чакта дустыгызның бәргәләнүе минем күз алдында булды бит. Анасы үлгәндәй кыланды. Безнең ише читтән карап торган кешегә мәзәгрәк тә инде үзе. Шул хәтле кыланмасагыз, артистларга театрда роль беткәнме әллә?

— Андый роль сирәк була. Аңлыйсызмы, шундый героик хатын-кыз... Илгә яу килә...

Һәм Сафия, барган җиреннән туктап, Нигъмәтҗанга йөзе белән борылды да Кадимбикә хакында сөйли башлады. Тик үзе, сөйләгән саен ныграк дулкынлана барса да, юлдашының күңелендә нindидер кабул итмәү тойгысы туганны тоеп алды. Әллә ышанып җитми аңа бу егет, әллә сөйләгәнен уенга саный.

Ниһаять, Сафия буталып, каушап туктап калды. Нигъмәтҗан бераз шулай аңлашылмас мөнәсәбәтен саклаган хәлдә тынып торды да уйчан гына итеп:

— Уен ни дисәң дә уен инде ул,— дип куйды.— Тамаша.

— Уен? Тамаша гына? — Ярсудан Сафиянең сулышы капты.— Театр тормышның үзеннән дә чынрак ул әгәр беләсең килсә! Әнә, бездә «Әни килде»не куйгач, күпме кеше әйтте: рәхмәт сезгә, минем гаебемне

күрсәттегез, мин әнине онытып җибәргәнмен икән, бүген кайткач та аңа хат язып салам, посылка җибәрәм, моннан ары мин әниемә игътибарлы булырмын диделәр. Син тамаша дигән нәрсә кешене күтәрә дә ала, бетерә дә ала, беләсең килсә. Үтерә дә ала хәтта!

— Анысын инде арттырып җибәрәсең!

— Арттырып торасы да юк. Революциягә кадәр Дуров үзенең хайваннары белән Одесса шәһәренә тамаша күрсәтергә килгән бервакыт. Ә Одессаның шәһәр башлыгы ул чакта Зеленый фамилияле бер юньсез адәм икән. Дуров манежга үзенең бер дуңгызын яшелгә манып чыгарган. Моны күреп, бөтен халык шаркылдап көләргә тотынган: «Зеленый, карагыз әле, Зеленый!» Шуннан соң теге Зеленый дигән адәм, өенә кайтып, үз-үзенә кул салган.

Нигъмәтҗан тыенкы сызгырып куйды:

— Үләрсең дә алай итсәләр. Куркыныч кешеләр икән әле сез. Мин белми дә йөрим тагын.

— Ә син театрга вакыт уздырыр өчен генә килә идеңме?

— Соң алай егылып үләрлек нәрсә күргән юк иде әле моңарчы театрыгызда.

— Йөрәгең кузгалганы да юкмы?

— Алай зыян күргәнне хәтерләмим. Анда бу рольне фәлән артист урынына төгәне уйнаса әйбәтрәк буласы икән, дип уйлап утырмыйсың. Кызык булса, көләсең, кызганыч булса, җәллисең. Кайчакта кызык та булмый, кызганыч та. Чыгып китәргә кешедән кыен, утырасың шунда иснәштереп.

— Ә Кадимбикәне караганда, берәү дә иснәштереп утырырга тиеш түгел,— диде Сафия.— Минем тамашачым Кадимбикәдән күзен ала алмый, бөтен гамьнәрен, сызлануларын онытып утырырга тиеш. Алай гына да түгел, минем Кадимбикәм аңа спектакльдән соң ияреп китәргә, төн йокысын качырырга тиеш.

Нигъмәтҗан бала-чаганың беркатлылыгыннан көлгәндәй елмайды, аның бу елмаюы караңгыда да бик ачык шәйләнде.

— Нәрсә көләсең? Көлке эшмени?

— Юк, мин болай гына. Бигрәк каты куясың бит мәсьәләне. Берьюлы йөз егетнең йокысын качырырга... Ай-һай зурдан икән өметегез!

— Качсын да шул. Менә син — ир кеше...

— Егет кеше,— дип бүлдерде аның сүзен Нигъмәтҗан.— Мин — егет кеше, Сафия туташ, белеп торыгыз. Минем бер тапкыр да өйләнгәнем юк әле.

— Ну егет булсын... барыбер...

— Юк, барыбер түгел. Һич тә барыбер булырга тиеш түгел бу. Әллә кеше ире белән дә шушылай төнлә йөрер идегезме?

Әхмәтнуровның сүзне кирәкмәгән юнәлешкә алып кереп китүе, җитди сөйләшүдән читләшүе Сафиянең ачуын китерде.

— Ә беләсеңме син ир-егетләрнең, гомумән, кешеләрнең бу заманда иң беренче чиратта нәрсәгә мохтаҗ икәнлеген?

Егет, шаркылдап көлеп җибәрүдән тыелырга тырышып, башын боргалады, күтәрелеп, болытлы күккә карады, перчаткасы белән нягән ышкыгандай итеп, үзләреннән-үзләре җәелгән иреннәрен каплады. Гарьлегеннән нишләргә белмәгән Сафия шактый ук кычкыра төшеп:

— Тугрылыкка мохтаҗ хәзер кешеләр! — дип әйтеп салды.

— Шулайдыр, шулайдыр, ышанам, тик, зинһар, әкренрәк, пожар дип, халык җыелмасын!

Сафия башын иде, кечерәеп киткәндәй булды. Бу кеше белән юкка гына ачылып сөйләшә бугай ла ул, юкка гына... Әмма Нигъмәтҗан җитдиләнгән иде инде. Сафия моны тоеп алды, эрнү аша:

— Бәхәссез хакыйкать бу, билгеле,— дип куйды.— Ләкин без моны кайчакта онытып җибәрәбез шикелле. Күптән мәгълүм хакыйкатьләрне дә вакыт-вакыт искә төшереп торырга кирәк бит. Әйтик, менә сәнгать

әсәрләрендә мәхәббәт һәм тугрылык хакында нәрсә сөйлибез без? Яшьлектә бераүне яраткан, ә хәзер икенчегә гашыйк булган. Чөнки беренчесенең килешмәгән ягы табылган. Яки артыгын яхшы булган. Шулай итеп, мәхәббәт кагыйдәләргә буйсынмый торган йөгәнсез, ышанычсыз, үзгәрүчән хискә әверелә. Ә Кадимбикә — боларга капма-каршы. Ул иренә яратам дип тә әйтми. Аның өчен ире — ата яисә ана кебек үк, алыштырып булмый торган кеше. Бердәнбер. Ул — тугры кеше, шуның белән ирен дә, илен дә коткара. Безнең тормышка турыдан-туры килеп тоташа бит бу. Әгәр сугыш вакытында әниләребез әтиләргә шулай ук тугрылык сакламаса, дошманны җиңә алыр идекме? Ә бәлки, безнең буынны да бик авыр сынаулар көтәдер! Хәер, тыныч тормышта да бер-берең ышанычсыз яшәп булмый. Спектакль шуны искә төшерергә тиеш.

Алар, шулай сөйләшә-сөйләшә, әкрен генә кайту ягына борылганнар иде. Нигъмәтҗан, уйга калып, шактый вакыт дәшми барды. Аннары әкрен генә:

— Син, ата бер генә була дидең. Ә ана? Ана ике була аламы? — дип сорап куйды. Аның тавышында бу юлы көлемсерәү дә, баласыту да юк, шул ук вакытта әчке бер мәгънә ята иде. Бу тагын миннән көләргә берәр җай эзләмиме икән дип шикләнеп куйды Сафия.

— Их, көләсез генә шул сез. Бер кешене ышандыра алмыйм, меңне ничек ышандырырмын соң мин?

— Юк, мин көлеп түгел, җитди сорыйм.— Нигъмәтҗан тагын бераз дәшмәде. Аннары: — Син ул пьесаны миңа укырга биреп тора алмассыңмы? — диде.

— Пьесаны? Сезгә? — Сафия моны һич көтмәгән иде. Алай да эченә җылы керде: пьесаны укыйсы килә, димәк, егет чынлап торып кызыксына башлады.— Ә нигә, була ул! — диде Сафия.— Иртәгә театрга алып керермен.

— Бүген булмыймы?

— Бүген дә мөмкин. Хәзер үк алып чыгарга була.

Алар ишегалдына керделәр. Сафия, башын күтәреп, тәрәзәгә карады — аннан зәңгәрсу пәрдә аша тоныкк кына яктылык сибелә иде. Наргизә өстәл лампасын гына кабызган — әллә укып ята, әллә йокыга киткән дә утны бүлмәдәше өчен калдырган.

Юк, йокламаган икән әле, ишектән кергән Сафиягә, юрган астыннан башын суза төшеп, текәлеп карады. Абажур күләгәсендә аның күзләре йолдызлар кебек елтырый, аларда кинаяле көлемсерәү аша кызыксыну ярылып ята иде: Сафиянең кайда болай озаклап йөргәнен беләсе килә иде аның, тик сорашырга горурлыгы ирек бирми. Сумкасын актарганда да, ишектән кире чыгып киткәндә дә аның бу карашын тоеп торды Сафия, һәм, кире урамга чыккач, иркен сулап куйды:

— Менә, рәхим итегез. Тик озакка түгел, бер-ике көнгә генә.

Ул төргәкне Нигъмәтҗанга сузды.

— Озын, түгелдер бит? Һи, моны бер кичтә укып чыгам мин.

Нигъмәтҗан, тун җиңен кайтарып, сәгатенә карады:

— О-о, бик соң икән инде. Тулай торакның ишеген ачмый азапларлар микән!

— Сез... тулай торакта яшисезмени?

— Буйдак егет кайда яшәсен тагын?

— Гафу итегез,— диде Сафия рәсми тавыш белән.— Мин Сезне озаграк тоттым бугай, артыграк мавыгып киттем.

— Зарар юк, хәзергә Сез минем белән мавыкмаган бит әле, театрда уйныйсы роль белән генә мавыккан.

Алар ашыгып саубуллаштылар. Очраклы кешегә болай ачылып китүенә Сафия үкенә иде инде. Хәер, күңеле тулы иде шул аның, уйларынмоңнарын урамда очраган баганага сөйләргә әзер иде, күзгә-күз терәшеп, рәхәтләнеп сөйләшер кешесе юк иде бит.

Наргизә йоклый иде инде, алай да утны сүндермәгән. Сафия бая

күз салмаган икән — җәймә ятакның япмасы өстендә бизәкле конверт ята. Сафия пальтосын салып элде дә карават читенә утырып уйга калды. Кулындагы конверт хакында ул онытты иде, чөнки һаман Нигъмәтҗан белән бәхәсләшә, аңа әйтә алмаган, бергә чакта башына килмәгән сүзләрне — иң ачык дәлилләрне, иң тапкыр чагыштыруларны күңеленнән үткәрә иде.



## 29

Хаким. Димәк, иреңнең йөрәген син дөньядагы иң зур хәзинәгә саныйсың инде алайса, ә?

Кадимбикә. Һәрнәрсәнең чын кыйммәте күрә белгән кешегә генә ачыла. Әйтик, юлда бер кантар ята ди. Берәү аңа абынып, тиргәнеп узып китә, икенче берәү күтәреп ала, кантар алтын булып чыга. Хакимнәргә тажлар ясый торган алтын.

Хаким. Ирен китерегез бире! Ярый, тикшереп карыйк алайса. Иреңнең йөрәген кулга алып карыйк. Чыннан да син әйткәнчә үк зиннәтле микән?

— Ирең килеп керүгә, син урыныңнан кузгаласың,— диде Бикбау Сафиягә.— Һәр хәрәкәтең салмак, мәгънәле булырга тиеш. Әкрен торасың, әкрен атлап, тәхеттән төшәсең. Иреңнең каршына киләсең. Хаким тарафына керфек тә сирпемисең, ләкин аны игътибардан ычкындырмый күзәтеп барасың, тамашачы моны сизеп торырга тиеш. Хаким кыланмышларыңны ничек кабул итә — бу синең өчен бик мөһим. Син ирең каршына тезләнәсең. Бик нәфис, матур итеп.

Бикбау сәхнәдә әрле-бирле йөгереп йөри, Сафиянең кайда ничек басарга, борылырга тиешлеген күрсәтә, ә артистлар — уңда баскан Җиһангир, аның артында, күләгәдәнрәк Зыятдин һәм алгы пландагы Тәүфикъ-Нариман күзәтеп торалар иде.

Үзгәреш нык сизелә иде яшь режиссерда. Кысан араннан ирекка чыгарылган тай кебек кылана иде ул, иркенлек, ышаныч белән сөйли иде. Башкаларны да дәртләндерә, җилкендерә, шунлыктан эшләү дә күңеллерәк булып китте. Әмма Сафиянең йөзендә канәгатьсезлек чагыла иде: артыграк өстән йөгертә түгелме бу Бикбау, тирәнгәрәк үтеп керү турында уйламый түгелме?

Сафия тәхеттән торып басты, ике баскыч атлап, идәнгә төште, ләкин шунда туктап калды һәм:

— Юк, мин идәнгә тезләнмим,— диде.

— Ничек инде тезләнмисең? — Рәмзи өчен бу көтелмәгән кирелек иде, ул, бөтен гәүдәсе белән борылып, Сафиягә соң дәрәҗәдә гаҗәпләнеп текәлде.

— Тезләнмим, табигатем каршы,— диде Сафия, аның күзләренә туры карап.

Рәмзи, чабып барган җиреннән кинәт арканлап туктатылган тай кебек, баскан урынында әйләнгәләп, тыпырчынып алды, аннары бөтен сабырлыгын җыеп, мөмкин кадәр тыныч сөйләшергә тырышып:

— Нәрсә ди әле Кадимбикә? Минем өчен иремнән өстен хаким юк диме? Менә хәзер шул сүзеңне исбатларга мөмкинлек ачылды. Син Хаким каршында башыңны имәгән идең, ирең каршында тезләнәсең. Логикага туры киләме бу? Килә! — дип, пичәт басып куйгандай итте ул үзенең сүзләренә. Һәм ак водолазка җиңе нечкәртеп күрсәткән озын беләге белән һавада кискен хәрәкәт ясады.

— Кем логикасына туры килә торгандыр, әмма Кадимбикә логикасына туры килми. Тормыш катлаулы, күп нәрсәләрне истә тотарга туры килә.

— Ярый, тормыш вакыйгалары белән таңгал китереп карыйк алайса,— диде Рәмзи, тыныч булырга тырышып.— Декабристларны каторгага хөкем иткәннән соң, хатыннары алар артыннан Себергә киткәнне исеңә төшер! Волконская үзенең язмаларында ире белән ничек очрашуы

турында яза бит әле? Ире янына җир астына, рудникка төшә ул. Язмаларында шундый сүзләр бар: «Тезләнеп, зыңҗырларын үптем мин аның». Тетрәндергеч күренеш: кадер-хөрмәттә яшәгән, затлы киенгән аксөяк хатын, кыйналган, кимсетелгән, өс-башы тетелеп беткән богаулы тоткынның аягына баш ора. Менә шулай хәл итәргә кирәк бу күренешне! Бөтен спектакльнең үзәге, орлыгы бу!

Сафия яңагына ук төшеп, чигәләрен каплап торган, ялтыравык тәнкәләр белән бизәлгән хикмәтле башлыгын башыннан сыдырып алды.

— Киемнәрем уңайсыз минем, аксөяк декабрист хатыннары болай җайсыз киенмәгән,— диде.

Чыннан да, ука белән тоташ чигелгән, итәге җирдән сөйрәлгән күлмәк, аның өстеннән иңгә салынган олы тун һәм бу башлык — барысы да элекке спектакльне әзерләгәндә, Наргизәгә үлчәп тегелгәннәр һәм аңа килешеп торалар, аларны кигәч, Наргизә, алтын кысага куелган асылташ кебек тагын да балкыбрак китә иде. Әмма буй-сынга аннан шактый кайтыш, каш-күзләре дә тыйнаграк Сафияне бу киемнәр басып китә, алар арасыннан кызның борын очы гына тырпаеп тора иде.

Башлыгын салгач, ул иркен сулыш алды һәм Рәмзигә түгел, караңгыланып торган залга карады. Анда икәү шәйләнә — берсе Исмегөл, ул Сафиянең дублеры бит, бөтен нәрсәне энә күзеннән үткәреп күзәтеп утыра, сәхнәдәге Сафиянең һәр уңышын күңеленә сеңдереп бара, һәр җитмәгән ягын, моны мин башкача эшләргә тиеш дип, хәтеренә уеп куя. Аның белән янәшә Наргизә басып тора, анысы инде эче пошканнан кергән. Репетиция барышында һәр көйсезлектән кызык табуы бик ачык күренмәсә дә, шәйләнә: Сафиянең җайсыз кием эчендә ятмәгә эләккән балык кебек тыпырчынуыннан авыз ерып көлә.

Сафия чәченә тоташтырып үрелгән ясалма толымнарны суырып алды да тәхет култыксасына салды, алар анда кара елан кабыгы булып аркылы яттылар.

— Кара, үсеп киткәндәй булдың, үз бөдрәләрең мең яхшырак икән,— диде күләгәдән Зыятдин кычкырып.

Сафия иңнәреннән тунны шудырып төшерде.

— Миңа киемнәрне бөтенләй башкача тегәргә кирәк,— диде.— Бүтән фасон белән.

— Художник фасоннарны пьесадагы образга яраштырып ясаганны беләсең! — диде Рәмзи.

— Ләкин образ актер рәвешендә туа бит!

— Сафиягә киемнәрне, әлбәттә, яңадан тегәргә кирәк,— диде Җиһангир нык итеп.

Бикбау аны ишетмәмешкә салышты:

— Соңыннан,— диде Сафиягә карап.— Барыгыз да урыннарыгызга! — ул кулын чәбәкләде.— Нариман керә, Кадимбикә аның аягына егыла...

— Егылмыйм,— диде Сафия.

— Сөйләштек, килештек бит инде! — Рәмзи аның кирелегенә хәйран калган иде.

— Ә мин синең белән килешә алмыйм. Волконская мисалы — ул бөтенләй икенче. Алар анда, рудникта, икәүдән-икәү генә булганнар.

— Ә сакчылар?

— Сакчы адәммени ул? Монда — Хаким,— Сафия кулы белән киң итеп Җиһангирга таба ишарә ясады,— хыянәтче Газизҗан. Нишләр икән бу дип, миңа текәлеп карап торалар. Алар күз алдында минем горур башым иелмәс, тезем чүгелмәс.

— Син алар каршында түгел, ирең каршында баш иясең! Аңа тугрылыгыңны, ихтирамыңны бәян итәсең! Син — ир хатыны!

— Юк,— диде Сафия.

— Ничек «юк»? Нәрсә «юк»?

— Бу очракта мин беренче чиратта хатын түгел, ә кеше, шәхес.

— Шәхес? Аңла: әсәрдә беренче чиратта хатынның иренә тугрылык саклавы хакында сүз бара,— диде Рәмзи аңа якын килеп һәм, томанага аңлаткандай, һәр сүзен өзеп әйтте. Һәр әйткәненә кулы белән төйгәндәй хәрәкәт ясады хәтта.

— Тугрылык хисе ир-ат өчен аерым, хатын-кыз өчен аерым була алмый, минемчә,— диде Сафия сүзендә нык торып.— Без спектакльне хатын-кызларга сабак бирер өчен генә куймыйбыздыр бит? Сүз, гомумән, кешенең биргән антына, туган иленә тугры булу хакында барырга тиеш. Монда Нариман белән Кадимбикә — иң беренче чиратта — ватандашлар! Ир белән хатын гына түгел!

— Әлбәттә, шулай,— дип, тыныч, әмма көр тавыш белән аның сүзен җөпләп куйды Җиһангир.

Сүз Рәмзи бөтенләй теләмәгән якка кереп бара иде. Көчәнмичә, иплән кенә, җай гына эшлисе урында, кая тарталар бу артистлар режиссерны?

— Ярый, җитте, сүз көрәштермик,— диде Рәмзи һәм чәчен артка сыпырып куйды.— Я без уртак фикердә булып, бергә эшлибез, яисә юлларыбыз аерыла. Минем фикергә кушылмыйсыз, таләпләремә каршы киләсез икән, ул чакта без бергә эшли алмаячакбыз.

— Үз табигатемә, күңелемә каршы килеп, җанлы курчак кебек, режиссер кушканны үтиммени? — дип сорады Сафия.

— Сүз бергә эшләү турында бара, аңлыйсызмы?

— Юк, бу спектакльдә,— Сафия, басым ясап, тагын бер тапкыр кабатлады,— бу спектакльдә, Кадимбикә ролендә мин үз күңелем кабул итмәгән бер генә ишарә дә ясамаячакмын. Бу — минем иҗат принцибым! — Сафия башын тагын да югарырак күтәрде.

— Принцип? — Рәмзи аңа аркасы белән борылды.— Алайса принципларыгыз туры килгән режиссер белән эшләрсез. Иптәш Солтанбаева! — дип дәште ул рампа кырыена барып.— Менегез әле монда!

— Рәмзи, тукта әле, алай кызмыйк,— дип, аны тынычландырырга омтылып карады Җиһангир.

— Туктап торырга вакытым юк минем. Киенегез! — диде ул сәхнәгә очып кына менгән Исмегөлгә.

Солтанбаевага бер әйткән сүзне кабатлап торасы юк. Сафия салган күлмәкне «ә» дигәнче киеп тә куйды, толымнарын да беркетте, тунын да иңенә салды. Чын патшабикәгә әйләнде дә куйды — толымнарга җан кергән кебек, ак муены тирәсенә иркәләп уралдылар.

— Башлыйбыз! Нариман! Нариман кая!

Тәуфикъ сәхнә артына чыккан икән. Ул сәхнәдә күренүгә, Исмегөл урыныннан торды, йөрәкләрнең очына баскандай, матур адымнар белән аңа таба юнәлде һәм, зифа сынын җилдә тибрәлгән талчыбыгыдай бөгеп, егетнең керле, ертык киндер штан балагына маңгаен терәде. Әйе, чыннан да тетрәндерерлек күренеш иде бу.

— Менә шушы кирәк тә инде безгә,— диде Бикбау бик шапырынмый гына, шул ук вакытта залга, анда төшеп утырган Сафиягә ишетелерлек итеп.— Дәвам итәбез. Беренче составны синең белән эшләячәкбез моннан ары, әзерләнеп тор.

Сафиягә түзеп булмаслык эссе булып китте. Димәк, рольне Исмегөл өчен куячаклар, бөтен хәрәкәтләр аның кыяфәтенә, образны аңлавына яраштырып эшләнәчәк. Сафия дублер булып кына кала; ә дублерлар белән режиссер гадәттә ныклап эшләргә җитешә алмый — алар беренче составның репетицияләрен күзәтеп, шуннан өйрәнеп кенә утырырга мәҗбүр булалар.

Ачы иде Бикбауның бу сүзе Сафия өчен, ай-һай ачы иде, ләкин бусы — тозы гына икән, борычны бер тыннан соң сипте режиссер.

— Бу рольгә дублер, бәлки, бөтенләй кирәк тә булмас әле,— дип тәмамлады ул сүзен.

Сафия, үзе дә аңышмастан, урыныннан сикереп торды, тәне аның

ихтыярыннан башка, сәхнәгә омтылды, бәгырь түреннән: «Туктагыз, мин риза, ни кушсагыз да тыңлыйм!» — дигән сүзләр ургылды. Ләкин ачылган иреннәре сулышыннан күеп китте, тавышы чыкмады. Янәшәдә басып торган Наргизә бер аңа, бер сәхнәдәге Исмегөлгә карады да:

— Чистый чехарда ясадылар бу Кадимбикә белән! — диде.

Һәм бу мәтәвекләрдән үзенең читтә торуына бик тә канәгать кыяфәттә, сәхнәдәге ыгы-зыгыдан барыбер рәт чыкмаячагына иманы камил икәнлеген белдереп, эре адымнар белән чыгу ягына юнәлде.

Ә Сафия калды, алай гына түгел, кире урынына утырды. Рольдән читләштерүләре ни авыр булса да, ул бу очракта режиссер белән дә, Исмегөл белән дә килешә алмаячагын аңлый иде. Әйе, бу — истә кала торган күренеш, әйе, ул дулкынландыра. Ләкин шул ук вакытта анда Кадимбикәне кимсетә, аның дәрәҗәсен төшерә торган нәрсә бар. Ул бит сәхнәдә бердәнбер хатын-кыз, аңа төрле яктан ирләр карап тора. Аягөсте басып, башларын туры тотып. Һәм шулар арасында бер Кадимбикә генә идәндә тәгәрәп ята. Шәхес буларак аның ирләрдән кимлеген күрсәтмимени бу?

Нишләргә? Ничек моны Бикбауга аңлатырга?

Әгәр дә шушы минутта Кадимбикәне Исмегөлдән дә мәһабәтрәк, тирәнрәк итеп уйнап булса, ул чакта, бәлки... Ләкин моның чарасын таба алганы юк бит әле Сафиянең. Хәер, таба алса да, ул инде аны куллана алмаячак, чөнки Бикбау аңа мөмкинлек бирмәячәк!

Сафия үзен маңгае белән таш кыяга килеп бәрелгәндәй тоя иде.

## 30

Сафия кием цехына керде дә ишек янында туктап калды. Аның каршында рәт-рәт тезелеп киткән элгечләргә тыгызлап кием-салым эленгән иде. Ука белән чигелгән, энҗе-мәрҗән белән чуарланган затлы хәлләләр, итәге җир себереп йөри торган атлас күлмәкләр, төрле халыкның төрле заман гаскәриләре кигән мундирлар, чапаннар, сюртуклар, казакилар, балаитәкле ситсы күлмәкләр... Дистәләрчә спектакльләр өчен булдырылган хәзинә. Сафия бу байлыкны йөгерек караш белән күзеннән кичерде дә кире чыгарга борылды: биредә күңеленә ятышлы кием табылмаячак иде.

Ул тегү цехына керде. Анда, бер якны биләп торган, зур гәүдәле кеше аунарлык иркен өстәл янында, тегүче Насибә нәрсәдер җөйләп азаплана иде. Күзлек пыялаларын ялтыратып, астан башын борып, Сафиягә бер карап кына алды да кире эшенә иелде. Сафия ишек янәшәсендәге киштәдә яткан көмешсу ефәк төргәгенә кулын куйды.

— Кадимбикәгә күлмәкне шушыннан тек, Насибә апа. Хаким әйтә бит әле: минем янымда утырырлык итеп киендерегез бу хатынны дип. Менә фасоны,— дип, сумкасыннан рәсем алып, Насибәгә таба сузды ул.— Башлык фасоны да бар монда. Яңак-чигәләрне капламыйча, маңгайның яртысына гына куна торган.

Тегү эшен дөньяда иң җаваплы һөнәр дип санаучы, һәр җөен уйлап-нечкәләп ясый торган Насибә өстәле янында тураеп басты, энәсен чәнчеп куйды, ләкин бик уалып төшәргә ашыкмады, тулы гәүдәсен бормыйча, күмәчтәй ак чыраенда уйчанлык саклап, озаклап рәсемгә карап торды, шуннан соң гына артисткага борылып, аны беренче күргәндәй, буй-сынын карашы белән үлчәде, гүяки рәсемдәге киемнәрне аңа кигезеп карады.

— Килешергә тиеш бу сиңа,— дип куйды аннары.— Җиренә җиткереп тегәргә генә кирәк. Тегә алсак, теләсә нинди егетне гашыйк итәргә була.

— Миңа теләсә ниндие кирәкми, Бикбау карарлык булсын,— диде Сафия.

— Бикбаумы? — Насибә, бу эшнең гадәттән тыш авыр икәнен аңлатырга теләгәндәй, шома маңгаена җыерчык чыгарып, уйга калгандай итте.— Белмим шул, белмим. Кем генә тегә алыр икән соң ул хәтле оста итеп?

Сафия бу сорауның бөтенләй урынсыз икәнен белдереп:

— Синнән башка кеше андый эшне булдырамы соң,— диде.— Бөтен өмет синдә!

— Эш бик күп бит, баш күтәреп, билне язар ара бирмиләр. Тегү дигәч тә, безнең эш тә уен-муен түгел, аңа да баш кирәк, йөрәк кирәк,— диде Насибә.— Менә килешсез кием киеп чыгып карагыз әле сәхнәгә!

— Шул шул! — дип җөпләде аның сүзен Сафия.— Наргизәгә теккән кием баса бит мине, изә, юк итә!

Насибә тегү эшеннән башын күтәрми, энә-җептән башканы күрми, артистларга да киемнәрен кигезеп үлчәгәндә һәм спектакль вакытында гына карый сыман, әмма үзе театрда кемнең ни сөйләгәнен генә түгел, ничек сулаганына хәтле белеп тора. Шунлыктан аңа хәлне озаклап аңлатасы булмады. Тик тегүченең үзен генә кабындырып җибәрергә кирәк иде, ә бусы бик ансат эшләнде: ул теккән киемнәрнең ярамавы, гәрчә алар башка берәүгә үлчәп тегелгән булса да, Насибәнең мин-минлегенә тиеп, күңелен кузгатып җибәрде.

— Нишләп кешегә теккән күлмәкне киясез? Үзегез гаепле,— диде ул.— Алпут бияседәй Наргизә бит ул, аның янында син йөгән күрмәгән тай кебек!

Насибәнең Наргизәгә үпкәсе бик зур иде: нинди әйбәт киемнәр тегеп бирелде бит аңа, ә ул, шуларны киеп тә, ролен тиешенчә башкарып чыга алмады!

— Бу фасонны каян алдың? — дип сорады Насибә.

Сафиянең музейда булып, андагы киемнәрне караганын, китаплардан эзләнгәнен ишеткәч, сөйләгәннән генә канәгать булмыйча, китапны үзенә китереп күрсәтергә кушты. Аннары:

— Бикбауны да сындыра алмасак, безгә монда эшләп йөрисе дә түгел,— диде.— Тик икәүләп тотынырга кирәк. Теккән киемне кия белеп кисәң генә бит аны. Чын иясе булсаң гына...

Сүз шактый озакка сузылды. Сафия грим бүлмәсенә кайтканда, сәхнәдә репетиция тәмамланган, Җиһангир өс-башын алыштырырга кереп бара иде.

— Ни эш кырып йөрү? — дип сорады ул.

— Һаман шул эш белән инде, аны кулдан ычкындырырга исәп юк әле минем,— диде Сафия үҗәтләнеп. Ләкин бик батыр сөйләшергә тырышса да, иреннәре калтыравын тыеп ук бетерә алмады.

— Безнең дип сөйләш,— диде Җиһангир.— Мин синең партнерың лабаса!

Һәм күкрәген киерә төшеп, башын артка ташлап басты, нәкъ менә Хаким кыяфәтенә керде.

— Мине партнерлардан мәхрүм иттеләр бит,— диде Сафия.

— Партнерың үзе синнән баш тартмаса, беркем сине мәхрүм итә алмый. Режиссер монда бердәнбер хаким түгел,— диде Җиһангир катгый итеп.— Син коллектив барын, минем партоешма секретаре икәнемне онытма. Иртәгә әзерләнеп кил: икедән соң репетиция ясаячакбыз.

— Ничек? Икебезме?

— Башта — икебез. Аннары башкаларны да чакырырбыз. Тәуфикъны. Зыятдинны.

— Тәуфикъны? — Сафия икеләнә калды. Исмегөлнең сөйгән егете, эштән соң калып, Сафия белән репетицияләр ясарга риза булырмы? Җиһангир кызның икеләнүен үзенчә аңлады.

— Нәрсә, куркасыңмы әллә? — дип сорады.— Көрәштән баш тартасыңмы?

— Әгәр андый куркак булсам, мин баштан ук бу рольгә алынмас

идем,— диде Сафия.— Димәк, иртәгә сәгать икедән башлыйбыз?
— Әйе,— диде Җиһангир.— Өр-яңадан.

## 31

Репетицияләргә ныклап керешкәч кенә, Сафия үз алдына нинди зур бурыч куйганын күзаллый башлады. Аңа бу образда ихтыяр көчен, акыл зирәклеген, зур шәхес кодрәтен хатын-кыз нәфислеге, гүзәллеге белән берләштерергә кирәк иде. Шулай һәркем күңеленә якынаерга, кешеләрдә, әйе, мин дә шундый була алам, шундый булырга тиеш, дигән фикер тудырырга, гадәти яшәештә дә сафлыкка, зурлыкка өндәргә тиеш иде.

Ә бу — сәхнәдәге һәр хәрәкәт, һәр сүзнең нәкъ тиешенчә әйтелеше белән генә булдырыла ала.

Хаким каршына кереп басуга, беренче хәрәкәт үк сискәндереп җибәрергә тиеш. Әмма моңа ирешеп булмый, чак-чак кына нидер җитенкерәми иде. Барысы да бар, тик күңелне кузгатырлык ниндидер нечкә кыл гына чыңламый. Сәнгатьнең бөтен хикмәте менә шул «чак-чак»та да шул инде! Җитмәсә — сәнгать булмый да!

Җиһангир аны һаман үсендереп торса да, Сафия үзе теләгән ноктага җитеп бетмәгәнен аңлый иде. Шуңа күрә репетициядән күңеле төшеп чыкты ул.

Кичен Наргизә Илнурны үзе белән театрга алып кереп китте, Сафия өйдә ялгызы ямансулап калды. Ишек шакыганны ишеткәч тә, күңеле кузгалмады, Нигъмәтҗанны күргәч тә йөзе ачылмады.

— Ә мин сине театрдан эзләп йөрдем,— диде егет.

— Кирәк идеммени?

— Киңәшәсе бар иде.

Сафия моңсу гына көлемсерәде:

— Артистлардан киңәш сорар кеше дә булыр икән. Югыйсә гомер буе безнең үзебезне өйрәтәләр: тегендә бас та монда тор, тегеләй итмә, болай ит... Гомер буе кеше сүзен сөйлибез бит без.

— Тыңлаучан халык, димәк, сез?

— Тыңламый кая барасың? Режиссер сүзен үтәми кара!

— Бер генә кичкә режиссер булып алсаң иде, ә?

— Ә кем сине тыя?

— Алайса, туташ, бүген мин Сезнең режиссерыгыз булам. Хәзер үк киенегез дә минем белән барыгыз!

Урамга чыккач, алдан сүз куешкандай, икесе берьюлы уңга борылдылар. Яз һавасы, күкрәккә тулып, сулышны иркенәйтеп җибәрде. Аяк асты югандай чиста, күк йөзе юка болыт пәрдәсе белән өртелеп, тулган ай тирәли нурлы ырмау сызылган, әйтерсең, көмеш җамаякны алтын читле ак тәлинкәгә куйганнар иде.

Алар түбәнәя барган урам буйлап бераз төштеләр дә, чатта тукталып, эчтән балкып торган трамвайларның кара-каршы килеп узганын көтеп тордылар. Аннары җитәкләшеп урам аша чыктылар һәм ихтыярсыздан уңга карап, икесе берьюлы туктап калдылар. Анда, шәрә ботаклы биек сирень куаклары, зур фонтан чынаягы артында ак бина калкып тора иде. Ул ничектер җиргә иркенәеп, рәхәт итеп, шул ук вакытта артык авырлык та салмыйча утырган шикелле иде. Күккә дә якын үзе, ай нурыннан яктырган болыт кисәкләре аның түбәсенә кунып ял итәдер сыман. Калада нинди генә биек корылмалар торгызылып, күккә үрләмәсен, бу бина аларның һәммәсеннән югарырак һәм мәһабәтрәк булып калачак, чөнки анда үзенә бер илаһилык, җир белән күкне тоташтыра торган тылсым көче бар.

Театр. Ул — зур каланың зиннәтле таҗындагы иң кыйммәтле асылташ. Әмма бина нинди генә гүзәл һәм мәһабәт булмасын, әгәр дә эчендә

иҗат дәрте кайнамаса, чын артистлар, режиссерлар һәм сәхнәдә үзенә бер мохит булдыра торган күп төрле һөнәр ияләре илһамланып эшләмәсә, ул театр булмый әле. Театрны нәкъ менә алар бар итә, чын итә.

Театр — ул матурлык символы гына түгел, үз-үзеңне аямый хезмәт итү билгесе дә. Сафия музыкантларның, биючеләрнең, җырчыларның һәркөнне күп сәгатьләргә сузыла торган ялыктыргыч репетицияләрен күз алдына китерде. Репетиция вакытында балет артистларының кулларындагы сөлгеләр тирдән манма чыланган була. Әйе, алны-ялны белмәс хезмәт кайный гүзәл бина эчендә. Һәм ул хезмәтнең күп өлешен тамашачыларга бөтенләй күренми торган кешеләр башкара.

Алар ачык капкадан Ленин бакчасына керделәр. Зур түгел бу бакча, минут эчендә аркылы чыгасың, ләкин ул — Казан халкына бик мәгълүм һәм күпләр өчен истәлекле урын. Җәен аның уртасындагы фонтан тирәсендә кызыл гөлләр чәчәк ата, эскәмияләрдә онykларын күзәтеп картлар-карчыклар утыра. Куак астындагы өстәлләрдә ирләр шахмат-шашка уйный, капка янында студентлар очрашырга вәгъдә бирешә.

Ә хәзергә бакчада үтеп-сүтеп йөрүчеләр генә, фонтандагы бронза малайлар әлегә йокыдан уянмаганнар. Тик агачларда гына күзгә күренмәс, ләкин йөрәккә тәэсир итә торган үзгәреш сизелә. Алар ялангач әле, ботаклары ай нурында кара челтәр ясаган, ләкин алардан сизелер-сизелмәс әчкелтем исле сулыш бөркелә сыман. Әйтерсең лә алар иң якты, иң тәмле төшләрен күрәләр, менә-менә уянып китәрләр дә, елмаешып, керфекләрен күтәрерләр. Әле уянмаган, ләкин битенә төшкән кояш нурыннан зиһене сизгерләнә башлаган Илнурга охшатты аларны Сафия.

Кыйгач юл бакчаның икенче ягындагы киң капка янына китерде. Каршыда, машина юлы аша гына — тагын капка, анысы элекке Черек күлнең иң түбән өлешенә — балалар паркына алып керә. Капкасы гади капка түгел, үзенең сере, хәтта ырымы бар. Аның ике ягындагы ак баганалар, өстә түгәрәк ясап, бергә кушылган. Баганаларның да, түбәнең дә эчендә уем бар. Күзгә-күз карашып мәхәббәтен аңлатырга кыюлыгы җитмәгән гашыйклар шушы капка янына килеп аңлашалар имеш. Әйтүләренә караганда, Казан каласының әллә ничә буын яшьләре шушы йоланы үтәп килә икән инде.

Моны исенә төшереп, Сафия ничектер каушап китте. Нигъмәтҗан да шул хакта уйлаган икән:

— Синең бу капка төбендә берәрсе белән сөйләшкәнең булдымы? — дип сорап куйды.

— Андый эшләргә уңганлыгым юк шул.— Моны әйткәндә, Сафиянең тавышы ирексездән калтырап куйды.

— Икебезнең уңмаганлыкны бергә кушсак, уңганлык булып чыкмас микән?

Нигъмәтҗан Сафияне багана янына бастырды да үзе капканың икенче кырына китте. Сафия уентыга йөзе белән борылды, салкын аклыктан аңа эссе бөркелгәндәй тоелды. Болай баскан кеше йоланы үтәргә — пышылдап кына эч серен әйтергә тиеш. Аның сүзләре уем буйлап югарыга — капка түбәсенә күтәрелә, аннары теге кырыйда торган кешенең колагына барып ирешә. Йола буенча әйтелергә тиешле сүзләре дә һәркемгә мәгълүм: «Мин сине яратам...»

Юк-юк, Сафия үзе мондый сүзләрне әйтә алмый, ул хәтта аларның үз колагына килеп ирешүеннән дә куркып калды. Курыкты, тик нишләптер читләшә алмады. Менә аңа чыннан да әкрен тавыш ишетелде:

— Сафия...

Бу аваз сулышны кисте.

— Сафия, ишетәсеңме?

Хәзер, хәзер йола үтәлер, теге өч сүз Сафиягә ишетелер! Ләкин, кирәкми! Ярамый әле аларга! Аларны ишетергә дә, әйтергә дә әзер түгел әле Сафия!

Ул кинәт борылды да Нигъмәтҗанга таба атлады:
— Әйдәле, балачакны искә төшереп, атынгычта атыныйк!
Атынгычлар, карусельләр, бакчаның аргы башында. Капкадан ул тарафка өч юл китә. Юл читләренә аю, куяннар, лампаларның сыек яктысында бик үк танып булмый торган җанвар сурәтләре ясап куелган.
— Кайсы юлдан китәбез? — дип сорады Нигъмәтҗан.
— Уңга китсәң, атыңны җуярсың, сулга китсәң, башыңны җуярсың дип сөйләнә бит әкиятләрдә.
— Атларны җуйыйк микән, башларны җуйыйк микән?
Нигъмәтҗан Сафиянең кулыннан каты итеп кысып тотты. Кызның кулы туңган иде ахрысы, егетнең бармаклары пешерерлек кайнар тоелды.
— Сафия, синең бу эшең бармый бит, әйеме? Рольңне әйтәм...
Ул моны авыруның хәлен белешкәндәй итеп сорады.
— Нишләп син миңа авыр сүз әйтәсең? Артист кешегә, эшең бармый дию, беләсеңме, ни дигән сүз ул?
— Бурычын яшергән бөлгән, чирен яшергән үлгән диләр, Сафия.
— Чир?
— Әйе, чир. Бу роль синең чиреңә әверелә башлаган инде.
— Бер миннән генә калмаган. Гомумән, актерлык — ул һөнәр түгел, чир исеме, диләр бит.
— Чирләүчесе син беренче булмагач, дәвасы да бардыр. Гел эш, иҗат турында гына уйлап йөрсәң, акылдан шашарсың. Онытып торырга кирәк эшне, башка да, йөрәккә дә бераз ял бирергә. Җаныңа ял булсын дисәң, минем хакта уйлап ал.
Нигъмәтҗан аңа якын ук килеп басты.

## 32

Ниһаять, ул көн килде, Сафиянең күңеленә илһам, канатлану иңде. Репетиция башланып, өске каттагы кечкенә залның уртасына кереп басуга, ул үзендә шундый җиңеллек тойды ки, мондый халәтне очкычның бетон юлдан йөгереп узып, һавага күтәрелгән чагы белән чагыштырырга мөмкиндер. Җиһангир Биктаһиров Сафиядәге бу үзгәрешне минутында күреп алды һәм киеренке дикъкать белән аңа текәлде, гүяки башкаларны: «Карагыз, күрми калмагыз!» — дип кисәтте. Иң кирәкле минутында тамашачының дикъкатен партнерына юнәлтә белә шул ул. Сафия уң кулын кош канаты кебек җиңел, нәфис хәрәкәт белән өскә күтәрде, бармаклары чак кына баш очында туктап калдылар, аннары йөнтәс бүрекне тотып салдырдылар. Ул моны шундый итеп эшләде, карап торган кеше мехның йомшаклыгын, җылылыгын, кулларның назын үзендә тойгандай булды.
— Молодец! — дигән тавыш ишетелде ишек тарафыннан. Анда репетиция барышын Тәүфикъ күзәтеп тора икән.— Тукта, бүгенгә моны бүтән кабатлама! Ашыкма! Югалта күрмә бу хәрәкәтеңне, оныта күрмә!
Әйе, кайчак шулай да була: репетициядә бик уңышлы табылган бер хәрәкәт, күз карашы, тавыш аһәңе шундук онытыла, ни тырышсаң да, икенче тапкыр аны кабатлый алмыйсың. Тик монда куркасы юк: очраклы табыш түгел, күп тырышлык белән булдырылган күнекмә иде бу. Зур булмаса да, җиңү иде. Сафия, куанычыннан нишләргә белмичә, алай да тыелырга тырышып, әле Җиһангирга, әле Тәүфикъка карады. Фәкать шунда гына егетнең ялгыз түгеллеген, аның артында бик үк күзгә чалынмыйча Исмегөл басып торганын күреп алды. «Миннән гаеп эзлидер, тапкандыр да инде»,— дигән уй куаныч учагына су сипкәндәй итте, Сафиянең ерылган иреннәре җыела төште.
Аның кичерешләрен китап укыгандай күреп торган Тәүфикъ бөдрә башын Исмегөлгә таба борды:

— Сафиянең бу хәрәкәте Кадимбикәне җанга якын, ягымлы итеп җибәрә, әйе бит? — диде.— Югыйсә ничектер кырысрак ул, катырак дип әйтимме. Андый хатын-кызларны без, егет кеше син дип мактыйбыз. Андыйлар белән разведкага барып була, шулай бит?

Ни уйлады, ничек кабул итте сөйгәненең бу сүзләрен Исмегөл? Шулай ук бер генә дә көнчелек очкыны кабынмады микәнни аның күңелендә? Кабынгандыр, чын артист мондый чакта һич тә битараф кала алмый. Әмма Исмегөлнең чибәр йөзен көнләшү дигән ямьсез хиснең чаткысы бозмады, киресенчә ул, көндәшенең уңышына үзеннән нык куангандай, нурланып елмаюдан балкыды.

— Бу ни дигән сүз? — диде үзе Тәүфикъка.— Минем Кадимбикә белән разведкага барып булмыймы әллә?

— Синең Кадимбикә — сөйдерә. Тик шунысы: разведкага сөйгән ярларны ияртеп йөрмиләр.

Исмегөл үпкәләп вакланмады.

— Икебезнең ике төрле булуыбыз бигрәк әйбәт,— диде.— Бер-беребезне кабатламабыз. Тик менә син нишләрсең икән, дублерың юк бит. Сафия белән ирле-хатынлы буласы урынга, бертуган көрәшчеләр булып күренмәссезме?

Әһә, бөтенләй үк тешсез дә түгел үзе, ничек авырттырып каптырып алды! Һәм агулы да түгел тешләве, көндәше файдасына.

— Миңа да гел бертөрле булырга ярамый,— дип кабынып китте Тәүфикъ.— Икегезгә ике төрле мөнәсәбәт булырга тиеш. Сиңа — кызгану һәм ничек тә булса бәла-казадан коткарырга тырышу, аңа — таләпчәнлек һәм таяну. Иртәгәдән мин дә сезнең белән эшкә керешәм! — диде ул Җиһангирга карап.

Артка борылып караучы булмады, шунлыктан бу бәхәсне тагын берәү — режиссер Бикбау тыңлап торганын һичкем күрмәде. Партоешма секретарена йомышы булып, репетициядән соң Биктаһиров белән сөйләшмәкче иде ул. Әмма сәхнәдән чыгуга, Җиһангир ничектер бик тиз күздән югалды. Кече залга аны эзләп килүе иде Рәмзинең. Артистларның кызып-кызып бәхәсләшкәнен ишетеп, туктап калды ул.

Бикбау барысын да белеп тора иде, әлбәттә. Сафиянең яңа кием тектергәнен дә, өске катта репетицияләр барганын да һәм анда сәхнәдәгегә бөтенләй охшамаган — бүгенге көннең эшлекле хатыннарына охшаш, ирләр кебек гайрәтле, зирәк акыллы Кадимбикәнең ныгып килгәнен дә. Барын да белә иде яшь режиссер, тик белмәмешкә генә салыша иде. Сәхнәдә барган репетицияләрдә спектакль әйбәт кенә оешып килә, Исмегөл һәрвакыттагыча тамашачыларга ошаячак. Артыгына җан көйдереп, ми черетеп азапланасы килми иде Рәмзинең. Шулай булмый ни, ул биредә вакыт узсынга гына йөри ләбаса. Эльвираның диплом алганын гына көтә һәм, беркемгә сиздерми генә, тирә-як шәһәрләрнең берәр театрында режиссер урыны буш түгелме дип белешкәли.

Шулай да артистларның сәхнәдә дә, монда да буталып йөрүләре аны һич тә рухландырмады. Бөтен көчләрен режиссер белән эшләгәндә бирсеннәр!

Ул каты-каты басып, ишеккә юнәлде. Артистлар сискәнеп сүзләрен өзделәр, дәррәү борылып карадылар. Бикбау, мыегын тешләштереп, сүзсез генә бүлмә эченә — Җиһангир янына узды.

Исмегөл белән Тәүфикъ баскыч төбендә пышылдашып калдылар, Сафия әкрен генә атлап, аска, икенче катка, грим бүлмәсенә юнәлде.

«Нинди тәкәббер кыланган була!» — дип уйлады ул Бикбау турында һәм үзалдына, аны үртәп, аскы иренен бүлтәйтеп, өске иренен тешләштергәндәй итте. «Мыегыңны чәйнәп йотсаң да, туктатмыйбыз инде хәзер без бу эшне!» — дип уйлады елмаеп. Үзалдына шулай шаярып, ул бу халәрне бер кызыкка сабыштырырга тырышты. Ләкин җаны тыныч түгел иде, ай-һай бер генә дә тыныч түгел иде!

Сәхнә артында аулак почмаклар, караңгы борылышлар, күзне адаш-

тыра торган күләгәләр җитәрлек. Ләкин ни сәбәптәндер монда сер сакланмый, кемнең кайда төчкергәненә хәтле бөтен театр белеп тора. Бу юлы да шундый хәл булды. Баскычның аскы мәйданчыгында кемнәрдер сөйләшеп тора иде, Сафия, кинәт үз исемен ишетеп, туктап калды.

— Кара, син сәхнә артына да сукмак салгансың икән инде,— диде Револ тавышы. Ул моны ничектер үчекләгәндәй көлемсерәп әйтте.

— Йомыш бар иде.

Сафия тын алмас булды — бусы Нигъмәтҗан иде. Гаҗәп: ничек килеп чыккан әле ул монда?

— Йомышың бик ашыгычмыни? — Бу юлы Револның үртәгәне тагын да ныграк сизелде.— Туйга әзерләнеп йөрүегез түгелдер бит?

— Ихтимал.

Нигъмәтҗан шушы бер сүзе белән сөйләшергә теләмәгәнен сиздерде. Бу исә Револны отыры котыртты гына бугай.

— Юк артыннан йөрисең! — диде ул.— Әле булса башыңа барып җитмәдемени соң: сине аның белән юри генә таныштырдым бит. Бер шаяру гына иде ул. Саф кыз, имеш! Артистканың сафлыгына кем ышансын! Аларның һәркайсының күңеленнән җиде давыл узган инде, беләсең килсә!

— Анысын үзебез карарбыз, сабый түгел,— диде Нигъмәтҗан нык итеп. Тавышы бик салкын иде. Револ исә күтәренке итеп, шаярып сөйли:

— Аны-моны аңлап өлгергәнче, соңарып куймагаең! Ул квартир дигәнен кара тагын. Квартирлы кыз дип шаярттым гына ич мин!

Нигъмәтҗан дәшмәде. Бераз тынып тордылар, ләкин бу тынлыкта, давыл артыннан була торган бөркүлектәге кебек, ниндидер дәһшәт бар иде.

Менә шап иткән шомлы бер аваз сискәндереп җибәрде. Бераздан гына Сафия моның хикмәтен аңлады: Револ Нигъмәтҗанның иңенә сукты ахрысы. Ай-һай ла авыр булып төшкәндер аның кулы!

— Әй син, малай, бирешмә! — Револның бу сүзендә ясалма дәрт яңгырады.— Борыныңны салындырма. Сине башлы-күзле итмәсәм, исемем Револ булмасын. Менә дигән кәләш табам сиңа. Музыкант! Пианист! Быел консерватория бетерә. Тамчы да хилафлык юк монысында — кул тимәгән саф кыз. Өч бүлмәле квартиры ике кешегә — анасы да үзе. Син өченче булырсың. Бирәм дигән колына чыгарып куяр юлына!

Сафиянең аяк астында баскыч чайкала башлагандай булды. Мәсьәләнең асылы аның зиһененә әле генә барып иреште. Саф кыз кирәк диләр... квартирлы... Теге чакта Револ Нигъмәтҗанны Сафияләргә, көлке ясап, мәзәк өчен генә алып кергән, димәк? Үч алыр өчен? Ә Нигъмәтҗаны соң, анысын әйт тагын! Базарда мал сайлаган кебек, өйләнергә кыз эзләп йөри икән!

Оят, гарьлек эш өстендә тотылгандай булды Сафия, бит очлары уттай кызышты.

Астан Нигъмәтҗанның:

— Алай бик яхшы булгач, ул музыкант кызны миңа әрәм итмәссең инде, үзеңә булсын,— дигәне ишетелде, ләкин Сафиянең зиһененә барып җитмәде.

— Әллә чынлап торып мавыгып киткән идеңме? — дип сорады Револ тагын көлемсерәп.— Анысы булыр. Бер син генә түгел, дөньяны шактый күргән абзыйларның да пеләш башын әйләндерде инде ул. Гостиницаларда күргән булгалады! Ну син ул абзыйлар белән ярыша алмыйсың. Кая инде, малай, безгә! Ни кесәдә көмеш юк, ни бармакта алтын юк...

Сафия, кычкырып җибәрмәс өчен, авырттырып, иренен тешләде дә, йөгереп, грим бүлмәсенә кереп китте, аның аяк тавышлары коридорлар буйлап яңгырап калды.

Ничек өстен алыштырганын, чәч тараганын тоймады. Ишек шакыган тавышка өне китеп, кулындагы грим савытын төшереп җибәрде, буяулар идәнгә чәчелде.

Ләкин ишекне ачканда, тыныч булырга, үзен кулга алырга тырышты. Нигъмәтҗанның күзләренә туп-туры карап, һәр сүзен аермачык салмак итеп әйтте:

— Кыз кирәк дисез инде алайса, квартирлыны эзлисез. Андыйны театрдан табып булмый шул, ун бармагыңны прожектор итеп эзләсәң дә. Алла сакласын, безгә ышанып, өч бүлмәле музыкант кызны ычкындыра күрмәгез!

Нигъмәтҗан нидер әйтмәкче иде, туктатырга теләп, беләгеннән тоткан иде, ләкин Сафия тыңларга теләмәде, пальто җиңен аның кулыннан тартып алды да баскычтан атылып төшеп китте.

## 33

«Син, мөгаен, миңа үпкәлисеңдер, соңгы вакытта хатларыңа вакытында җавап яза алмадым. Ә язар сүз күп, яңалыклар булгалап торды. Арада куанычлысы да бар: ниһаять, мин дә хуплау сүзләре ишеткәли башладым. Нәзеремне үтәргә — сезнең якларга барып, бу рольне синең өчен генә уйнап күрсәтергә туры килмәгәе дип торам.

Бу арада мин синең хакта еш уйланам. Бергә булган чаклар һаман искә төшә. Хәтерлисең микән: бер көнне, диңгез буенда йөргәндә, яр кырында үскән пальмалар турында әкият сөйләгән идең: «Бу пальмалар миңа агач булып түгел, чәчләре диңгез җилендә тузгыган малайлар булып тоела,— дигән идең.— Алар монда йөгерешеп килгәннәр дә, офыкта кораб күренмәсме дип, еракка текәлгәннәр. Әтиләре диңгезче аларның, шуларны көтәләр. Офыктан монда ак кораб килеп туктамыйча һәм әтиләре ярга чыкмыйча торып, малайлар моннан китмәячәк».

Мин сине хәйран калып тыңладым, чыннан да, ак кораб күренмәсме дип, озак-озак офыкка карап тордым. Иң гаҗәпкә калдырганы диңгез түгел, син идең: мин дә шул диңгезгә карап торам югыйсә, ә күңелемдә бернинди әкият тә тумады. Гомумән, син кешеләрнең дә, табигатьнең дә мин күрә белмәгән якларын күрә идең. Синең белән бергә күргәзмәдә булганыбыз хәтердә. Хатын-кыз рәссамның картиналары куелган иде анда. Ул гомере буе чәчкә рәсемнәре ясаган. Аларның бакчада балкып утырганын, җиргә өзелеп төшкәнен, җыеп, вазаларга куелганын. Сиреньнәрне, канәферләрне, гөлчәчәкләрне, акчәчәкләрне... Баштарак күргәзмә миңа ошап җитмәде, төсләр артык җете, буягыч тупас күренде. Мин сиңа шулай дип әйттем дә. Ә син картиналарның берсенә озаклап, онытылып карап тордың да тыенкы моңсулык белән: «Ә миңа ошый,— дидең.— Бу рәссам күңелсез, ямансу мохитта үзе өчен ямьле, җанны җылыта торган бер почмак булдырган». Шунда кинәт минем дә күзләрем ачылып киткәндәй булды: картинаны бөтенләй башкача күрә башладым. Анда көзге бакча тасвирланган иде: яфраклары саргаеп коелган, кара ботаклары төрле якка тырпаешкан шәрә агачлар арасында, гади эскәмиядәге балчык чүлмәккә кемдер кашкарыйлар җыеп утырткан. Бер карадым агачларга, икенче — чәчкәләргә. Һәм, чыннан да, ак, кызыл, шәмәхә чәчкәләрнең тере, дәртле бәбәкләреннән җанга яктылык сирпелгәнен тойдым. Чәчкәләрнең матурлыгын гына түгел, кеше кулының гайрәтен дә тасвирлаган иде рәссам. Дөрес, кеше бу рәсемгә кермәгән, ул картинаның кысасыннан читтә калган, ләкин аның хезмәте, кайгыртучанлыгы, матурлыкны саклый белүе шушы чәчкәләрдән күренеп тора иде. Әгәр дә уңган, оста бакчачы булмаса, болай балкый алыр идемени алар?

Елның ямьсез фасылын да матур итеп тасвирлый алган, гөлләр гүзәллеге аша кеше хезмәтенә дан җырлый белгән бу рәссам һәм син — әйе, син! — сез икегез дә яшәешнең матур якларын күрә беләсез, моны күрәсең, гомерегезнең авыр чакларында да онытмыйсыздыр.

Ә мин сезгә охшамаган, башка камырдан ясалганмын ахрысы. Һәр

очракта да дөньяны матур итеп, кешеләрне яхшы итеп күрергә өйрәнмәгәнмен. Кай көннәремдә күз алларым томаланып, башларым әйләнә, таяныч табалмас булам. Теге чакта карусельдә әйләнгән шикелле.

Исеңдә микән: җилле, ямьсез бер кичтә паркка барган идек. Анда халык аз, атынгычлар буш, тамаша тәгәрмәче туктап калган иде. Карусель янында бер хатын күшегеп тора, әллә инде шуның ятим кыяфәтен күреп, кызганганга, ичмасам бер хәрәкәт булсын моңа дип, билет алдык та, агач атларга менеп атландык. Калган атлар буш иде, каруселне икебез өчен генә әйләндереп җибәрделәр. Йөге җиңел булгангамы, ул баштан ук хәйран кызулап китте. Җиргә төн карасы иңгән иде инде, якындагы әйберләрне лампалар тигезле-тигезсез яктырта, бәлки шуңадыр, карусель үзе түгел, ә аның тирә-юнендәге агачлар, баганалар, күктәге йолдызлар — безне урап алган мохит әйләнә шикелле тоелды. Баштарак бу кызык һәм рәхәт сыман иде, ләкин тиз арада читен була башлады, нык җиргә басасы, агачларны, йолдызларны аерым-аерым күрәсе килде. Карусель исә тагын да кызурак әйләнә иде. Мин түзә алган хәтле түздем, ахырда, тәкатем калмагач, синең якка авып төштем. Хәлемне аңлап алдың, иңнәремнән тоттың да бар көчеңә: «Туктатыгыз! Туктатыгыз!» — дип кычкыра башладың. Тик сине тиз генә ишетүче булмады; теге күшеккән хатын әллә берәр кая киткән, әллә сүзгә мавыгып, безне оныткан иде.

Син мине, күтәреп диярлек, эскәмиягә илтеп утырттың. Аннан соң да әле шактый вакыт бөтен дөнья күз алдымда әйләнеп, тибрәлеп торды.

Ул чакта янымда син бар идең. Хәзер андый кешем юк, ә дөньям андагыдан яман әйләнә-тулгана. Кем хәлемне аңлар, кем кул сузар? Беренче карашка гадәти тоелган күренешләрнең мәгънәсен, чын асылын күрергә, кешеләрнең кемлеген таный белергә кем ярдәм итәр? Юк бит андый дус янымда. Ялгыз икәнмен бит, бөтенләй япа-ялгыз, беркемгә дә кирәгем юк икән. «Сакла, Сафия, сафлыгыңны, күңел чисталыгың халкыңның дәрәҗәсен күтәрә, кешеләр өчен кирәк ул»,— дигән идең. Ялгышкансың, күңелемнең ниндилегендә беркемнең хәбәре юк. Көләләр генә миннән. Әйе, шулай, кеше көлдерергә генә ярый шушы көнгәчә саф булып яшәвем. Аһ, дустым, күңел тәрәзәләремне ачкан идем, салкын җилләр бәрде миңа! Ачы җилләр бәреп, җанымны өшетте! Юанычлар кайдан табарга?

Сине уйлап, синнән отып калган җырны көйләп юанырга тырышам. Ул җырларны үз ана телемә тәрҗемә итеп, шул шөгыль белән онытылып торам. Сиңа да язып җибәрәм, авазлар ничек яңгыравын укып кара:

Чегән кызлары өйрәттеләрме
Яшь йөрәкләргә ут салырга.
Көннәрем кара син юк чакларда,
Төннәрем якты син барында.

Бу хатны алгач, исеңә төшер әле: апрельнең егермесендә, төнге сәгать унберде нишләгән идең? Мөгаен, җырлагансыңдыр, мине исеңә төшереп моңайгансыңдыр. Сафиянең ямансулаганын шуннан торып сизгәнсеңдер, сизми калмагансыңдыр...»

## 34

Шәһәргә яз үзенчә, ашкынулы, җитез килә. Кояш елмая башлауга, асфальт өстендәге бозланып каткан кантарлар эреп юкка чыга, юл кырыеннан йөгерек гөрләвекләр агып үтә, йортларның көньякка караган биек стеналары янында үлән борын төртә, үги ана яфрагының чәчкәләре алтын башын калкыта. Ул арада бөреләр шартлап ярыла, тупыллар бал исе аңкыта, шомырт агачлары ак тәлгәшләрен суза.

Шәфика иртәләрен кошлар тавышына уяна, көндезләрен кечкенә

бакча сукмагы буйлап йөргәндә, ак каусәле каеннарның нәфис яфракларына, койма кырыендагы әрекмәннәргә, аяк астында ыгы-зыгы килгән вак кырмыскаларга һәм беренче чәчкәләрдән үк бал жыярга керешкән бал кортларына карап, хәйран калып, үзалдына сөйләнә иде:

— Карале, башка елларны да язлар шушылай килә идеме икән соң? Нишләп моны бер дә күрмәдем икән?

Шулай дип, ул сукмак кырыендагы куе яшелләнеп, бөдрәләнеп үскән кычытканны сыйпап узды. Уч төбенең, бармакларының кычытып ачытуына көлде:

— Үзең матур, үзең шифалы бит син,— диде яфракка карап.— Каян килә сиңа мондый зәһәрлек, ә?

Аннары чирәмне чуарлап, балкып утырган эре тузганак чәчәкләренең берсен өзеп алып, учына салды. Аны әйләндерә-әйләндерә, җентекләп карады, иснәде. Аның гомерендә дә тузганак чәчкәсен иснәгәне булмаган икән, югыйсә аннан бал исе килүгә бу хәтле гаҗәпләнмәс иде. Нәрсә белән чагыштырырга җете сары, катлы-катлы нәфис таҗ яфраклы чәчкәне? Алтын беләнме? Ул чәнти бармагыннан алтын балдагын салып, чәчкә белән янәшә куйды һәм аларны чагыштыруның никадәр мәгънәсез икәнлеген аңлады, көлеп җибәрде. Нәфис, тере, йомшак, җылы тереклек иясен, салкын, каты, җансыз тимер кисәге белән ничек тиңләмәк кирәк? Ә шулай да, нәрсә белән тиңләргә була соң тузганак чәчкәсен?

Гаҗәп, моңарчы ул беркайчан да тирә-ягына бу кадәр текәлеп, җентекләп карамаган икән. Никадәр гүзәллекне күрми яшәгән!

Аның күзләрен ачкандай итте бу яз. Хикмәт табигатьтә генә түгел, хикмәт Шәфиканың үзендә дә иде: бу айларда ул да үзгәрә, яңара, моңарчы кичерелмәгән хисләр кочагында тирбәлә иде.

Ана булырга әзерләнә иде Шәфика. Ә бу яңа халәт аның бөтен йөреш-торышын, тышкы кыяфәтен, хәтта холкын да үзгәртеп җибәрде. Элек аның эчендәге тышында, уйлаганы телендә була торган иде. Хәзер исә бик зур сере барлыкка килде: бу хәлен ул беркемгә, хәтта иренә, энисенә дә белгертмәскә тырыша иде. Әйтермен дә, бер-бер хәл булыр, өметләрем өзелеп куяр дип шикләнә иде ул. Аныңча, бәхет әле бөредә генә, башкаларга әйтү өчен аның чәчкә булып ачылганын көтәргә кирәк иде.

Һәм Шәфика сабыр булырга тырышты. Кышын врачларга дәваланырга йөргәнен сиздермәде, апрель аенда больницага кереп ятканда, Рәмзигә: «Болай гына, бераз дәваланып, ныгып чыгарга кушалар»,— дип кенә аңлатты.

Больницага йөген сакларга яткач, Шәфика ай буе ыгы-зыгылы хезмәтеннән, өеннән, иреннән аерылып торды. Тәрәзә аша һәм больница каршындагы агачлыкка йөрергә чыккан араларда булса да, яз алып килгән үзгәрешләрне ашыкмый, нечкәләп күзәтергә, тереклек ияләренең яралуы, тууы, яшәү тантанасын кичерүе хакында уйланырга мөмкинлеге булды.

Яз күренешләре һәм үзенең халәте бөтен уй-хисләрен биләп алган иде, шунлыктан Рәмзинең ул теләгәненнән сирәгрәк килүенә дә, килгән чакта да күзгә бик туры карамый гына сөйләшүенә һәм эшем бар дип ашыгуына да карамастан, артыгын кыйналмады. Әйе, ике арада әле һаман калын пыяла торгандай иде, ләкин озакламый Шәфиканың кулында аннан котылу чарасы булачак иде: әз генә сабыр итсә һәм ышанычы ныклы булса, ул чакта аның бер сүзе ике арадагы пыяланы яз кояшы астына эләккән боз кыйпылчыгы сыман эретеп юкка чыгарачак иде.

Әлбәттә инде, Шәфиканың күңелендә дә көнләшү уты кабынган чаклар булмады түгел, Эльвира да әледән-әле хәтергә килеп тора иде, ләкин күңелдәге өмет яктысы шомлы уйларны, яз кояшы иртәнге кырауны кугандай, тиз арада куалар иде. Ул, тузганак чәчкәсен учында биетеп

йөргән сәгатьләрдә, башка берәүнең Рәмзи йөрәген үз учына торган саен ныграк йомарлый бару ихтималы хакында уйламаска тырышты.

Ниһаять, авыр эштән һәм борчулы кичерешләрдән сакланырга кирәклеге, режимны нык тоту зарурлыгы турында озын-озын киңәшләр биргәннән соң, аны больницадан чыгардылар. Ул өенә кайтып, әнисе белән кара-каршы утырып чәйләр эчкән арада сәгать өченче китте. Рәмзи кайтмады, Шәфика җанына урын тапмады, соң булса да, театрга кереп чыгарга ниятләде.

Репетиция күптән тәмамланган, зал буш иде инде. Ул өченче катка менде. Кече залның ишеге төбендә, тулган айдай яктырып, сары күлмәк кигән Наргизә белән ак күлмәкле Исмегөл эчкә карап торалар иде. Алар, борылып, Шәфикага елмайдылар, тавышланырга ярамаганын белдереп, пышылдап кына исәнләштеләр, кулын кыстылар һәм янә залга таба борылдылар.

Шәфика алар арасында тукталып калды. Иң беренче чиратта аны эчтә басып торган Сафиянең күлмәге гаҗәпләндерде.

— Каян алган ул мондый фасонны? — дип пышылдап сорады Наргизәнең колагына үрелеп.— Кара, ничек үсеп киткән! Кадимбикә булырга да ярый бу күлмәк, бүген киеп кичәләргә дә барырлык. Оста-а!

— Үзе тапкан фасон,— дип җавап бирде Наргизә һәм мәгънәле генә елмаеп куйды. Өчесе дә тынып, эчтә барган репетицияне — Кадимбикәнең Хаким белән һәм хыянәтче Газизҗан белән канга-кан, үлемгә-үлем чигендә барган көрәшен күзәтеп тордылар.

Наргизә бик уйчан күренә иде. Исмегөл алданрак китеп барды, бераздан Наргизә дә баскыч тарафына юнәлде. Шәфика аңа иярде.

— Үсте дисез инде алайса? — дип көлемсерәп сорады аннан Наргизә.

— Кемне әйтәсең?

— Шуны инде, Сафияне.

Шәфика тиз генә җавап таба алмады. «Үсеп киткән»,— дигәндә, ул Сафиянең килешле, дәрәҗәне күтәреп җибәрә торган көмешсу күлмәген күздә тоткан иде. Наргизә исә аны башкачарак, тирәнрәк мәгънәдә аңлаган булып чыкты.

— Ә беләсегез килсә, гомер буе миңа астан өскә карап ияреп йөргән кыз бит ул,— диде Наргизә.— Мәктәпкә ияртеп алып бардым мин аны, училищега җитәкләп алып килдем.

— Гел шулай синең арттан гына йөрер дип уйлаган идең дә, кинәт узып киттеме?

Шәфика сукмак буенда берничә көн эчендә баш калкытып күкрәп үсеп чыккан кычытканнарны исенә төшерде, Сафияне шуларга тиңләде. Нык, тере алар, чәнечкеле, каты тамырлы. Ә менә Наргизә тузганакка охшабрак тора кебек: балкып торган сары чәчкә, бераздан исә тотрыксыз ак мамык...

— Бу рольне баштук аңа гына бирәселәре калган,— диде Шәфика,— Рәмзи аны күрмәгән генә.

— Ни генә күрә соң ул? — Наргизә моны шундый итеп, үзәгеннән суырып әйтте, Шәфика ирексездән тукталып калды.— Хәер, ул гынамыни! — дип кулын селтәде Наргизә.— Чын дөресен күрә белмибез, дөрес итеп яши белмибез. Тамырсызлар без!

Шунда ул Шәфиканың, күзләрен зур ачып, гаҗәпләнеп карап торганын күрде дә, чигәләре турыннан чәч бөдрәләрен бармаклары белән өскә таба аралап, зиһенен туплагандай итте.

— Хәер, без дип дөрес әйтмимдер, мөгаен. Сезнең хакта болай әйтергә ни хокукым бар минем? Үзем турында әйтүем. Канат җилпеп очарга талпынып яшим, ләкин җирдән күтәрелә алмыйм. Әле бер канатым каерыла, әле икенчесе. Бер канатым — сәхнә, иҗат, икенчесе гаиләм иде. Икесенә бертигез таяну миңа насыйп булмады шул. Ә сыңар канатлы кош оча алмый. Әнә, Сафия тасвирлаган пар канатлылар гына биеккә күтәрелә...

Наргизә, Шәфиканы уйда калдырып, баскычтан төшеп китте.

Икенче көнне «Кадимбикә»не яңадан сәнгать советы карады. Бу юлы Шәфика баштан ук ире белән янәшә утырды, ләкин иңе белән аңа елыша алмады. Рәмзи үзен шулкадәр ышанычлы тота, бернинди тәрәккә мохтаҗ түгеллеге бөтен кыяфәтенә чыккан, аның туры сыны, югары чөелгән башы бернинди якынаюга юл куймый, ирексездән үзеннән читтәрәк торырга мәҗбүр итә иде. Һәм Шәфика урындык култыксасының икенче ягынарак авышып утырды. Борчылырга сәбәп юк, спектакль үзенә күрә җиңел генә тамаша булып оешкан, чибәр, сөйкемле Исмегөл, шиксез, егетләрнең иң асылларын үзенә каратырлык иде. Дөрес, кече залда барган репетициядәге кебек, бер карауда күңелне кузгатып, бәгырьне сызландыра торган, уйландыра торган тирәнлек юк иде бу Кадимбикәдә. Ләкин Рәмзи ул тирәнлеккә омтылмый да ахрысы, бик канәгать күренә иде.

Спектакль тәмамланып, утлар кабынуга, Шәфика арткы рәттән күтәрелгән Эльвираны күреп алды. Кыз нечкә гәүдәсен тимер казыктай нык тота, йөзендә, карашында масаюлы тантана. Нәрсәгә шул кадәр борын чөя соң әле ул, кемне җиңү тантанасын кичерә? Ай-яй үзгәрде кызый! Бар иде бу кызыкайның минем күзләремә ялварып, мөлдерәп карап торган чаклары дисәң, адәм ышанмас! Әйе, килбәтсез үрдәк бәбкәсе канат ярды, тик аның нинди кошка әверелгәнен Шәфика һаман аңлап бетерми иде әле. Ул, Эльвираның йөзеннән бөркелгән бозлы җилдән бәгырен сакларга теләгәндәй, иңендәге ак шарфның очлары белән күкрәген каплады. Күпкә чыдаган азга сабыр итәргә кирәк дип уйлады. Спектакльне бүген шиксез кабул итәчәкләр, җәйгә Рәмзи шул спектакль белән авылларга гастрольгә китеп барачак. Ә бу кызый Казанда кала. Гастрольләр тәмамланганчы, күп нәрсәләр үзгәрәчәк әле дип уйлады Шәфика.

## 35

Револ театрга соңарып, худсовет членнары һәм артистлар үз урыннарына утыргач һәм утлар сүнгәч кенә килгән иде, беркемгә сиздерми генә кереп, иң арттагы буш рәткә утырды. Театр тирәсендә күп чуалган кеше буларак, ул артистлар уенының житешмәгән якларын гадәттә бик тиз тотып ала, кимчелекләрне күп күрә, шунлыктан спектакльдән тәм табып, рәхәтләнеп караган минутлары да сирәгрәк була иде. Бу юлы исә ул сәхнәдәге вакыйгалар алмашын беркайчан булмаганча дулкынланып күзәтте. Әйтерсең лә, узган гомерләр аның күңеленә карлар салып киткән, хәзер исә сәхнәдән аңа җылы нур төшеп, ул катламнар әкрен-әкрен генә эри башлаган иде. Кышын бакчада Сафия белән сөйләшеп утырганы исенә төште. Ничек дигән иде әле ул: «Кар астында җылы җир, гөл орлыклары»,— димеме? Револ да менә йомшап төште түгелме? Әллә чыннан да аның күңел түрендә нинди орлыклар шыта башлады инде!

Тагын Сафиянең музейда тезләнеп җырлаганы хәтергә килде: «Йокла, бәбкәм, йом күзеңне, борчылма һич тә...» Гел әни җыры төсле...

Спектакль тәмамланганда, күңеле нечкәреп киткән иде аның, үзе хакында, эчтән генә өнәмичә көлемсерәп: «Тәмам җебеп төштем түгелме мин? Карт кыз кебек...» — дип уйлап куйды. Гадәттәге гамьсез һәм бераз дорфарак кыяфәткә керер өчен, залдан чыгып килгән халык күзенә чалынып тормады, ишегалды аркылы әйләнеп, артистларның грим бүлмәләре ягына узды.

Ул икенче катка менгәндә, «Язмышлар тактасы» янында Наргизә басып тора иде. Аңа күз ташлау белән, Револ бу хатынның да үзгәреп, йомшап киткәнен сизеп алды. Ул гадәттәгечә тәкәббер күренми, уйчан, ямансу, башын кая куярга белми залда тулганган улы Илнурны

да онытып, зиһене чуалган кыяфәттә иде.

— Кемнәрдер гастрольгә минем туган якка бара дип ишеткән идем,— диде аңа Револ.

— Әйе, Түбән Камага без барабыз,— диде Наргизә.— «Галиябану» белән. Менә.

Ул пыяла астындагы кәгазьләрнең берсенә бармагы белән төртте.

— Кемнәр бара?

— Сиңа кем кирәк? Мин барам дидем бит инде.

— Тагын берәрсе күренмәдеме шунда? Сезнең белән баручыларны әйтәм.

— Сиңа ни кирәк соң?

— Йомыш бар иде. Әти-әнигә тапшырасы әманәт.

— Әманәт тапшырырга мин ярамыйммы?

Наргизә, борылып, аның йөзенә текәлеп, сынап карады. Шөгыльсезлектән җәфа чиккән Илнур да алар янына килеп басты, авызын ачып, Револга текәлде.

— Әманәтем четереклерәк шул,— диде Револ. Ул ник сүз башлаганына үкенә иде инде.

— Кәнфит җибәрәсеңдер инде. Миңа бирсәң, юлда ашап бетерер дип куркасыңдыр.

— Әй, малай, ярлы да инде бу артистларның фантазиясе! Тамактан ары китә алмый! — Револ башын чайкап куйды.— Бер бичара җан иясен кайгыртып йөрим әле монда.

Наргизә, берни аңламаганын белдереп, иңбашын сикертте.

— Эт баласы җибәрәсе бар минем авылга, бик беләсең килсә, көчек!

«Көчек» сүзен ишетеп, Илнур Револның янтыгына ук килеп терәлде, үзенә игътибар итүләрен теләп, шыңшый ук башлады:

— Әни-и, көчек ал, көчек кирә-әк!..

— Әй, үзәгемә үтмәсәнә! — дип кул селтәде Наргизә. Аннары Револга:— Таптың син дә сүз! — диде.— Болай да көннең-көнендә эт ал да эт ал дип үзәккә үтә, шул гына җитмәгән иде.

— Әни-и, алы-ыйк! — дип, аның итәгенә ябышты Илнур.

— Махсус сатып алдыңмы инде син аны? — дип сорады Наргизә Револдан.

Башка чакта Револ аның белән озаклап сөйләшеп тормас иде. Ләкин бүген әлеге дә баягы шул күңелнең нечкәрүе комачаулады — бер төртмә сүзне ишетүгә борылып китәргә ирек бирмәде. Наргизәнең кичерешләрен аермачык күргәндәй булды ул. Каты бәгырьле булганнан түгел бит хатынның кыланмышлары, ялгызлыгыннан, үз язмышын таба алмавыннан гына. Шушы минутта Револ аның белән сөйләшмичә кырт кына борылып китеп барса, тәмам сөмсере коелачак, алай гына да түгел, күңеле җәберләнәчәк. Егетнең йөрәк түрендә кызгану хисе уянды. Һәм ул сабыр гына аңлатуны кирәк тапты:

— Күрше малае каяндыр алып кайткан иде дә, анасы өйләренә кертмәде. Ишек төбенә чыгарып ташлаганнар. Аяк астында чинаштырып ята, бәләкәй әле, өрә дә белми. Аркылы атлап үтәргә намусым кушмады.— Револ көрсенүен яшерә алмады. Барысын да бу хатынга сөйләп бетереп булмый: мөлдерәп карап яткан маэмай аңа үзенең чирле туып, сабый килеш үлеп киткән кызын хәтерләткән иде.— Алып кердем инде өйгә, нишләтәсең. Шуны авылга җибәрергә иде. Эт асрау минем кулымнан килми, өйдә сирәк булына. Ул анда берүзе бөтен дөньяны пычратып ята, миңа өрергә өйрәнде инде. Рәтләп карамагач, яратмый да. Авылда ишегалдында йөрер иде әле шунда.

— Әни-и, ди-им! Алы-ыйк!

— Абыең бирми бит әнә, безгә ышанмый!

Илнур, күзләрен мөлдерәтеп, башын артка ташлап, Револның йөзенә текәлде. Шулкадәр өзелеп ялвару ярылып ята иде аның яшькелт күзләрендә!

— Ышанмый дип, син нәрсә мине ул хәтле... Үзеңә мәшәкать кенә булыр дигән идем...

Алар шулай, маэмайны ничек кулдан-кулга бирү, кайда очрашу турында сөйләшә-сөйләшә, баскыч ягына киттеләр. Маэмайны кулга алачагын уйлау шатлыгыннан нишләргә белмәгән, тәмам үсеп киткән Илнур Револ белән янәшә теркелди. Наргизә алданрак бара иде. Кинәт кенә малайның колагына Револ ягыннан зең-зеңләп матур бер көй чыңлавы килеп ирешә.

— Ни җырлый ул?

— Нәрсә?

— Ти-ти-ти-и итә,— дип карашын Револның костюмына күчерде Илнур.

— Ә, аны әйтәсеңме. Җырлый торган сәгать ул шундый. Японский.— Ул сул җиңен кайтарып, сәгатенә карады.— Ике тулган инде. Эштә дә күренеп чыгасы бар бит әле.— Ул театрларның эшенә җитәкчелек итә торган бер оешмада эшли иде.

— Кары-ыйм әле! — дип, аның сәгатенә сузылды малай.

Баскычтан төшә башлаган Наргизә туктап борылды да көлеп:

— Тоттырган ди сиңа шундый сәгатьне! — диде. Аның тагын кирелек җене кузгалган иде.— Абыең андый әйбер өчен кан калтырап тора ул, ватылмагае дип коты оча!

Бу сүзләрдән Револның чырае каралып чыкты:

— Нәрсә син мине һаман чәнчеп торасың әле? Кайчан саранланганым бар? Мә, пажалыста!

Ул сәгатен салды да малайга сузды. Һәм үзе, моны бернигә санамагандай, Наргизә артыннан төшә башлады. Малай исә өлкәннәрнең әйткәләшкәненә игътибар бирмәде, ул сәгать белән мавыккан, әйләндерә-әйләндерә аны карый, көе каян чыкканын белергә тырыша иде.

— Әйдә инде! — дип кычкырды аңа Наргизә.

Малай сәгатькә караган килеш баскычка атлады, абынды һәм сөрлегеп китте...

— Аһ!..

Наргизә һушыннан язды бугай. Ул аңына килгәндә, Илнур Револның кочагына сеңгән, ә сәгать баскычның аскы мәйданчыгында ялтырап ята иде. Егет, киек җәнлек сизгерлеге белән малайның егыла башлаганын сизеп алды, күз ачып йомганчы борылды да, бер аягын өске басмага куеп, авып килгән малайны тотып калды.

Малай исә куркырга өлгермәгән иде. Револның кочагыннан чыкканда, аның карашы аска, елтырап яткан сәгатькә текәлгән иде. Револ да шунда карады, һәм аның йөзе каралып чыкты. Танышлары аркылы шактый озак эзләтеп, зур гына хакка сатып алган сәгать иде ул. Менә ул, күтәрелеп, малайга карады һәм тетрәнеп китте: Илнурның күзләрендә коты очып курку, гаҗизлек ярылып ята, гүяки ул хәзер үзенә үтереплек итеп китереп сугуларын көтә, моннан котылу чарасын белми иде. Аның ап-ак йөзендә моңарчы сизелмәгән сипкелләр чәчрәп килеп чыккан иде. Аһ, авырдыр ла ул мондый минутларда таудай биегәеп торган көчле, гайрәтле кеше каршында шушындый йолып булмастай гаепле хәлдә кан калтырап басып торулары! Чарасыз булып, үзеңне яклау өчен берни эшли алмыйча! Револ чигенебрәк, бер баскыч аскарак төште, болай иткәч, аларның йөзе бер биеклектә калды. Егет алга авышыбрак, йомшак кына итеп:

— Син нәрсә, егет башың белән куян кебек калтыранасың? — диде.

— Мин алырмын... алырмын... Алып бирермен...— дип сөйләнде малай күгәргән иреннәре белән.

«Бу беренче генә куркуы түгел бит моның, әлектән коты алынган чаклары булган!» — дигән уй узды Револның башыннан. Ул бик сакланып кына, йомшак хәрәкәт белән сузылып, авырлыгын салмаска тырышып, җиңел итеп, аның иңбашына кулын куйды:

— Ә син нык бул, калтырап төшмә.— диде.— Бу дөньяда ватылганжимерелгәнне күп күрерсең әле. Егет булып кала бел. Сәгатьне төзәтеп була бит аны.

Малайның йөзенә төс керә башлады, ул уйларлык хәлгә килде, күзләрендә өмет кабынды:

— Буламы? — дип сорады, аның бу сүзне тагын бер тапкыр ишетәсе килә иде.

— Була, тимерне төзәтәләр. Кеше жаны бозылса гына төзәтеп булмый.

— Ә нишләп булмый?

И сабый, бер жылы караш, бер юату сүзе житте үзенә, бөтен куркулары онытылды, янә гамьсез балага әйләнеп, Револга нәни кулын бирде. Егет тә үзенең үсеп киткәнен, көче артканын тойды шикелле. Кечкенә, көчсез, гажизләнгән адәм баласына бер карашың, бер сүзең белән жан тынычлыгы кайтарып бирү — чын егетлек түгелмени?

— Ә маэмайны алып киләсеңме соң? — дип, алай да шикләнеп сорады Илнур.

— Анысын сорама инде, улым, болай булгач, алып килмәс шул инде абыең,— диде Наргизә. Ул сәгатьне алып әйләндергәләп карады да, егеткә сузды һәм күзләрен тутырып, аның йөзенә әйтеп бетереп булмаслык рәхмәт хисе белән карады. Хисләре шундый зур иде, аларны белгертерлек сүзләр таба алмады, аннары бик ачылып китәргә кыюлыгы житмәде. Бу минутта ул фәкать аның күкрәгенә капланып елый гына ала иде, тик моны ярамас дип санады, яшьләрен тыярга тырышты. Револ аңа гажәпләнеп, керфеген какмый, озаклап карап торды: бу хатынның болай өздереп, тирән итеп караганын күргәне дә, мондый йомшак, йөрәккә май булып ятышлы итеп эндәшкәнен дә ишеткәне юк иде әле аның моңарчы.

— Син нәрсә, малаеңны кыйныйсыңмы әллә? — дип сорады ул.

— Кайчакта төшергәлим инде, беребез дә ансыз үсмәгән.

— Икәүләшеп дөмбәслисезме әллә?

— Кемне әйтәсең?

— Атасын.

— Балага азрак кирәк ул дип исәпли иде атасы да.

— Их сез, сабый белән сугышырга ничек кулыгыз бара... Кадерен белмисез икән...

Ә Илнур аның итәк чабуыннан тарткалый иде:

— Абый, кайчан алып киләсең маэмайны! Кайчан?

## 36

Кече залдагы репетицияләр белән мавыгып яшәгән Сафия гастрольләргә чыга торган труппаларның берсенә дә кертелми калганын башкалар таралып беткәч кенә аңлады. Алай да төшенкелеккә бирелмәскә, артык нечкәләп уйламаска тырышты, көзгә хәтле вакытын эч пошуларсыз гына үткәрү жаен карый башлады. Профсоюздан кая да булса берәр турпоходка путевка сорарга ниятләде, аны көткән арада авылга кайтып килергә булды. Балачак сукмакларыннан узарга, эти-әнисенең каберен барлап, тәртипкә китерергә. Бу мәшәкатьләргә керешкәнче, әйбер-карасын юып-жыеп куярга кирәк тапты.

Ярый әле, орды-бәрде ашыгып чыгып китмәгән икән. Ике көн дә үтмәде, һич көтмәгәндә, аны эзләп, режиссер Бикбау килеп керде. Ул «Кадимбикә» белән Куйбышев районына киткән иде, иртән генә кире кайткан. Ник дисәң, анда Исмегөл салкын тигезеп, тамагын шештергән, тавышы беткән, ә Сабира ролен башкаручы Фагыйлә Батталовага санаторийга «яна торган» путевка биргәннәр. Шул ике артисткага алмаш эзләп кайткан режиссер. Бикбау күп сөйләшеп тормады, иртәгесен ир-

түк елга портына төшеп, «Метеор» белән Болгарга барырга кушты да ашыгып чыгып та китте.

Бу шулкадәр көтелмәгәндә булды ки, ул чыгып киткәч, Сафия бераз вакыт хәл җыеп утырып торды, фәкать шуннан соң гына күңеле куаныч белән тула башлады. Төнне йокысыз уздырды, иртәне көчкә көтеп алды ул.

Талпынып, буталып, әйбер-карасын зур сумкага тутырды, урамга, троллейбус тукталышына чыкканда, йөгерүдән чак тыелды.

Троллейбуста барганда, Сафия хихылдашкан тавышка борылып карады. Өч-дүрт яшь егет, студентлар булса кирәк, нидәндер кызык табып, көлешәләр иде. Сафия янындагы кешеләрнең җилкәләре аша үрелеп, алар караган тарафка күз салды — анда Шәфика басып тора иде. Кыска җиңле зәңгәр күлмәктән, ак сумка тоткан, эре дулкынлы алтынсу чәчен килешле итеп тараган. Йөзе уйчан, бармак төртеп көләр җире юк.

Сафия, халыкны ерып, якынрак узды. Ә-ә, хикмәт менә нәрсәдә: Шәфика, гадәттәгечә зиһене таралып, бер егет кулындагы озын таякның очына тотынган икән — троллейбус тотынгычы дип уйлаган. Кеше көлдергәнен сизми үзе, моңаеп алгы якка караган.

— Исәнмесез, Шәфика апа!

Сафия йомшак кына итеп аның бармакларын таяктан куптарып алды. Шәфика шунда гына хатасын аңлады, ләкин моңа бер дә исе китмәде, уйлары башкада иде.

— Бикбау иптәш кайда соң әле, алданрак киттеме? — дип сорады аннан Сафия.

Шәфика ияге белән шофер кабинасына таба ымлады. Анда Рәмзи басып тора иде, билет ала икән. Менә ул хатыны янына юнәлде. Чырае шактый ук караңгы күренә, ак чесуча костюм фонында бу аеруча нык сизелә иде. Ул килеп үк тә җитмәде, арада бер-ике кеше калдырып, туктап калды. Шәфика Сафиянең кыска җиңе астыннан беләген авырттырып кысты.

— Әбәү, Шәфика апа, тотмагыз әле шул хәтле, күгәртерсез.

— Ник син болай сәер карыйсың?

— Кая?

— Рәмзигә дим.

Сафия, кыенсынып, беләген сыпыргалады.

— Аптырарсың сезнең белән. Бикбауга күз тияр дип курыктыгызмы әллә?

Ул бераз зиһенен җыеп торды, аннары сүзне борырга кирәк тапты:

— Үз уйларымның очын югалттым әле, Шәфика апа. Менә Сезнең якын кешегез бар. Озатасыз, пароход кузгалганда, ярдан кул болгап каласыз, кайтканын көтәрсез. Озату — бер бәхет, озатучың булу — икенче бәхет бит ул. Ә мин менә китсәм — ялгыз, кайтсам — ялгыз, һаман берүзем.

— Ә кая соң теге чокыр иякле егет? Эшеннән җибәрмәделәрмени?

— Юк инде ул, Шәфика апа, бетте.

Сафия, Шәфиканың аны тыңламаганын, гәүдәсе белән Рәмзигә таба авышканын, бөтен игътибарын аңа юнәлткәнен күреп, тынып калды. Рәмзи аңа мыек аша мыгырдап кына сәлам бирде дә, түшәм астыннан сузылган тоткага нык кулы белән ябышып, яны белән борылды. Сафия тәрәзәдән урамга, иртәнге якта аеруча чиста, төзек, мәһабәт күренгән яңа биек йортларга, аларның кояш нурларын чагылдырган тәрәзәләренә, ачык яшеллеккә төренгән өрәңге-тупылларга карап барды.

Җәй башы — табигатьнең дә, артистлар күңеленең дә яшәргән, талпынган вакыты. Бар табигать терелә, кояшка үрелә, яшеллеккә төренә, чәчәк ата, ә артистлар шул табигать кочагына, яңа урыннар күрергә, яңа кешеләр белән очрашырга, яңа кичерешләр белән сафланырга, иске гамьнәрне онытып торырга омтыла. Яшәсен җәй, яшәсен гастрольләр!

Шундый уйлар, өметләр белән бара иде Сафия Болгарга.

Җәйге иртә-кичләрдә елга порты тирәсендә шушы рәвешле күңеле кузгалган, каядыр ашкынган халык күп тулгана. Кыш буе тыныч кына өйләрендә утырган кешеләр дә, көн җылынгач, урыннарыннан кубып, бер җилләнеп кайтырга монда чыга, күбесе, эреле-ваклы теплоходларга, ракеталарга, су трамвайларына утырып, бакчаларына, урманга, авылдагы туганнарына һәм туристик сәяхәтләргә юнәлә.

Сафия елга портының пыяла белән бетоннан салынган зур-якты бинасын, киң мәйдан уртасындагы агачларны күздән кичерде, троллейбустан төшеп, Идел буе һавасын йотылып сулады. Яр читендәге пароходларга таба халык агыла иде. Шунда ул трамвай тукталышыннан таныш кеше килгәнен күреп алды. Кара күн пинжәгенең төймәләрен ычкындырып, түшен ачып җибәргән Гыйззәт Бикашин юан гына бер апайның беләгенә тотынып, аның салмак, үрчемсез адымнарына ярашырга тырышып, теркелдәп бара иде. Пеләшен каплаган, күзләрен күләгәләгән ак эшләпәсе астыннан уңга-сулга күз салмыйча аяк астына карап атлый, абыну-сөртенүдән курка иде ахрысы, Сафияне күрмәде. Алар шулай бик матур гына парлашып яр буенда биегәеп торган ак пароходларга таба киттеләр. «Йөрәге бу минутта ничә тибә икән, һаман алтмыш микән әле? — дип уйлап куйды Сафия аның сүзләрен исенә төшереп.— Егетләрдән нык әле мин, дип мактанган иде, бичара. Юк шул инде, Гыйззәт абзый, кара сакалың, кая барсаң да, артыңнан калмый. Алтмыш яшегез тулысы белән үзегездә. Тотынып йөрер кешегез булганга куанып туймаслык».

Бер кулына кара дипломат, икенчесенә сары маэмай күтәргән ак костюмлы Револ елга портының троллейбус тукталышында әрле-бирле йөренә иде. Бала белән болганып, Наргизә бераз соңарган иде. Троллейбус ишеге ачылуга, ул иң беренче итеп Револны түгел, арырак, яр буендарак йөренгән Низамны күреп алды. Култык астына зур гына уенчык — алсу пластмассадан ясалган танк кыстырган, мөгаен, хатыны белән улын көтә иде ул. Наргизә алдан үзе төшеп, борылып, улына кул бирде, ул арада яннарына килеп баскан Револны күреп, бераз каушап китте. Болай ике ут арасында калачагын белмәгән иде, инде хәзер нишләргә? Алай да гадәттәге кыюлыгы, турылыгы бу юлы да коткарды — төшә-төшүгә Револга таба талпынган Илнурның кулыннан тотып алды да:

— Әнә, улым, этиең килгән; бар башта этиең янына бар,— диде. Әлбәттә, башка вакытта ул болай димәс, улына Низамны күрсәтеп тормас иде, ләкин соңгы көннәрдә нидер үзгәргән иде аның күңелендә, холкында, үз-үзен тотышында. Малай, маэмайга карап, дөньясын оныткан, аның кара йомшак, дымлы борынына, очлы колакларына, ак тәпиләренә һәм кара тырнакларына карап хәйран калган иде, ул гына да түгел, Револдан аны ала башлаган иде инде.

— Бар, этиең белән саубуллашып кил,— дип, аңа төртте Наргизә.— Маэмайны аннан алырсың.

Малай аптырап калды: аның этисе янына да барасы килә, маэмайны да ычкындырасы килми иде. Көчек ике кул арасында калып, җиргә төште, Илнур белән Револ икәүләшеп аны алырга иелделәр. Халык кайнаган җирдә кеше баласы белән әвәрә килү килешми иде, бу — Револның мин-минлегенә тиде. Торып басты да көчекне күтәреп:

— Бар, бар, сине көтәләр бит,— диде. Малай, артына карый-карый, теләр-теләмәс кенә китеп баргач, Наргизәгә коры гына:

— Ярый, сез монда үз эшегезне үзегез карагыз,— диде.— Мин «Метеор» янына киттем. Берәрсе очрар әле.

Ул шактый ерагайган, «Метеор» янына барып җитә язган иде инде: «Револ абый! Револ абый!» — дип кычкырганны ишетеп, борылып карарга мәҗбүр булды. Аның артыннан җан-фәрман Илнур чаба иде. Кулындагы зур алсу танк нык комачаулый иде бугай, уенчык кулыннан төшеп калгач, малай аны алырга иелмәде, сулуына кабып йөгерүендә булды.

— Революл абый! Тукта-а!

Ул йөгереп килде дә, капыл гына тукталып кала алмыйча, егетнең янтыгына йөзе белән капланды. Ак костюм итәгендә карасуланып дым таплары калды.

— Син кая? Маэмайны бир!

— Мин тегендәрәк кенә барып тормакчы идем,— диде аңа Револ.— Маэмай синеке инде ул, синеке, вәгъдә бирдем бит.

— Ә үзең безнең белән барасыңмы?

— Юк, мин монда калам.

Малайның йөзе моңсуланып киткәнен күреп, Револ үзе дә сизмәстән:

— Мин бераздан кайтам авылга,— дип өстәде.— Сезне анда очратырмын әле.

Алар янына, чемоданын күтәреп, ашыгып, Наргизә килә иде. Юл өстендә аунап яткан уенчык танк янынннан узганда, аңа күз дә салмады.

— Әни! Револ абый да авылга кайта! — дип каршы алды аны Илнур куанып. Наргизәнең сораулы карашына Револ:

— Миңа да бер кайтып килергә кирәк инде,— дип җавап бирде.— Әти-әнинең хәлен белергә. Анда очрашырбыз әле без, авыл халкы каршында ничек уйнаганыгызны күрербез.

...Причалда, ишәйгәннән-ишәя барган халык төркеме уртасында, су өстендә назлы тирбәлеп торган ак «Метеор» белән янәшә баскан Шәфика иренә якынрак елышты, башын артка ташлап, аның күперенке мыегына, куе керфекләренә карады һәм Рәмзи белән икесе арасында беренче тапкыр уртак хис яралган кичне, күзләргә карашып кына аңлашкан минутларны хәтеренә китерде. Ул чакта Рәмзи артист булып кына йөри иде әле. Премьерадан соң артистлар гадәттәгечә кечкенә генә бәйрәм оештырып алдылар. Табигый ки, бөтен игътибар Шәфикада иде, барча мактау аңа эләкте, һәммә чәчәкләр аның кочагына тулды. Шәфиканың исә бар кешене дә бәхетле итеп күрәсе килә иде. Шул ук спектакльдә кечкенә генә роль уйнаган Рәмзинең читтәрәк кыенсынып басып торганын күреп, Шәфика аның янына барды һәм, чәчәкләрен өстәлгә куеп, кулларын аның җилкәсенә салды да, аяк очларына күтәрелеп, үрелеп, егетне мыегыннан үбеп алды:

— Премьера белән! Партнерым шушындый булганга уңышка ирештем бүген!

Болай гына арттырып җибәрү мондый көнне табигый иде. Ә артистның күңеле йомшак, тамагы мактау сүзенең татлы балына һәрчак сусап тора. Рәмзи зур куллары белән аның терсәкләреннән тотып алды да үзенәрәк тартты һәм, ватарга курыккандай, сак кына күтәрә төште дә, чиктән тыш гаҗәпләнеп:

— Кара, Сез нинди кечкенә икәнсез бит! — диде. Танылган остазы аңа моңарчы үзеннән дә зур бәдәнле булып күренгән ахрысы. Шәфиканы үз кочагына алгач кына, ул аның җыйнак буй-сынлы, хисле хатын икәнлеген, ә үзенең гайрәтле ир-егет булганлыгын аңлап алды. Шунда алар бер-берсенең күзләренә беренче тапкыр хатын-кыз һәм ир-егет буларак карашканнар иде.

Китәргә әзер торган «Метеор» янында, ыгы-зыгы килгән халык арасында, аяк очларына басып, иренең көчле иңнәренә учларын куйгач, Шәфика үзен янә бик кечкенә, ярдәмгә мохтаҗ җан ияседәй хис итте, шул ук вакытта зур гәүдәле, гайрәтле иренең үзенеке икәнлеген тою аның күңелен куаныч белән тутырды. Ул Рәмзинең урман күле төсле күзләренә томырылып карады, аларның төбендә шәйләнгән күләгәләрне куарга теләде, иренең теге чактагыча гаҗәпләнү һәм соклану белән: «Кара, син бик кечкенә икәнсең бит!» — дигәнен көтте.

Рәмзинең дә күңеле кузгалды бугай, күзләре җылынгандай булды, йөзе тетрәнеп куйды, ул, иелеп, хатынының бит очыннан үбеп алды. Кешедән оялгандай, ашыгып, бик сак үпте ул. Яннарыннан, күрмәмешкә салышып, Сафия узып китте — алар моны сизмәделәр.

Китәсе халык «Метеор»га кереп беткән, причалда озатучылар гына калган иде. Күпне күргән адәмдәй кырыс, эре кыяфәт белән уң аягын алгарак куеп баскан яшь кенә матрос трапны алырга әзерләнгән иде инде.

— Хуш,— диде Рәмзи һәм эчкә керде. Ләкин трапның аргы башына җиттем дигәч кенә, кинәт борылып, атылып кире чыкты, Шәфиканың терсәкләреннән тотып, үзенә таба тартты:

— Ни диден син миңа?

Шәфика берни әйтмәгән иде, аптырап китте.

— Исән йөреп, сау кайт,— диде.

— Юк, син нидер әйттең бит.

— Болай гына... Мин сиңа хат язармын. Маршрутыгыз билгеле бит. Әйтелми калганның барын язып җибәрермен.

— Утырасызмы, юкмы? — диде трапның теге башыннан матрос калын тавыш белән.— Әллә Сездән башка гына китеп барыйкмы?

Бәлки, шунда Рәмзине җибәрмәскә, тотып калырга мөмкин булгандыр?

Әмма аның урынына Шәфика ирен үзеннән читкәрәк этәрде.

— Бар инде, бар, трапны ала бит хәзер.

Рәмзи йөгереп үтүгә, трапны алдылар. Теплоходның ак янтыгы күксел бетоннан әкренләп ерагая башлады, аның белән яр арасында соргылт су кайнады. Кинәт, сискәндереп, теплоход динамикларыннан җыр ургылып чыкты:

Барыр юлым иркен басу-кырлар аша үтә,
Алда мине янар учак булып өмет көтә...

Аерылышу турында булса да, бу җыр дәртле, кызу, тыпырдап биергә җайлы булып яңгырый иде. Шәфика, палубада култыксага таянып басып торган Рәмзигә нидер әйтергә теләгәндәй, аяк очларына басып, аңа таба сузылды. Тик теге җыр аша берни ишетерлек түгел иде. Теплоход аларның арасын ерагайтып, тизлеген арттырды, борыны белән аргы якка борылды. Рәмзи, Шәфикага караган килеш, кулын култыкса буйлап шудырып, койрыкка таба атлады. Әллә ничек бик моңсу иде аның кыяфәте. Инде теплоход: «Китте-е-ем!» — дигәндәй, кинәнүле аваз белән көмеш тәңкәле су өстеннән еракларга хәбәр салганнан соң, Рәмзинең ак сыны койрыкка җитеп туктап калгач, Шәфика халык арасында таныш бер кешене күреп алды. Вак бизәкле ак күлмәк кигән нечкә билле ул кызны ерактан булса да таныды ул, күзләре белән түгел, йөрәк сулкылдавы аша таныды: бу Эльвира иде. Рәмзи белән бер теплоходта китеп бара иде ул.

Теплоходтан яңгыраган җыр ярга әле һаман аермачык ишетелә иде:

Юллар көтә мине, җырлар көтә, шуңа китәм,
Аерылу синнән бигрәк авыр, авыр икән...

## 37

Кичке спектакль булачак клубка барып кергәч, Сафиянең күңелендә, уйларында бу яңару хисе, гадәти яшәештән күчеп, бөтенләй яңа бер мохиткә күчү тойгысы тагын да көчәйде. Биредә авыл клубларында көндезләрен була торган бушлык, серлелек хөкем сөрә иде.

Моңарчы таныш булмаган сәхнәне бөтенләйгә үз дөньяңа әйләндерү, анда табигый хәрәкәтләнү өчен, алдан аны бик ныклап өйрәнергә, үзләштерергә, күп таптанырга кирәк. Сафия анда ялгызы да озак айкалды, аннары, Җиһангир белән Зыятдин килгәч, аларның башын катырып бетерде: «Мин моннанрак чыксам, ничек булыр икән?» — «Син биредәрәк торсаң, уңайлырак булмасмы?» — «Яктылык ничегрәк төшәр икән?»

Ахырда Зыятдинның сабыры төкәнде:

— Син теләсәң каян кер дә теләсә кая чык,— диде ул.— Ә мин үзем, саф һавага чыгып, изге Чулман елгасында рәхәтләнеп су керим әле. Безгә дә бер фарыздыр!

Алардан соң Сафиягә Эльвира белән ныклап торып эшләргә кирәк булды әле. Әйе-әйе, Эльвира белән, чөнки кабаланып санаторийга китеп барган Фагыйлә Батталова урынына, Сабира ролена Бикбау аны кертте. Ярый әле, кыз рольнең сүзләрен ятлап өлгергән икән, мизансценаларны режиссер үзе куйды.

Кичен спектакль Сафия өчен канат кагып очу кебек үтте. Моны ничек тасвирларга? Алдына зур бер изге максат куеп, ниһаять, шуңа ирешкән кешеләр болай да аңлар, ә инде яхшылык өчен көрәшмәгәннәр һәм җиңүне татымаганнар өчен сөйләп торуның да мәгънәсе юк, аңламаслар.

Сафия сизеп-тоеп уйнады: залдагылар аның белән бергә яна-көя, һәлакәт чигенә барып баса һәм җиңү куанычын кичерә иде. Ул залдагы йөзләгән халыкның үз гамьнәрен оныттырды, сәхнәдәге вакыйгалар арасында яшәргә мәҗбүр итте. Гүяки аларның барысының йөрәгенә берьюлы орынды.

Кайсыдыр бер минутта, караңгыдагы арткы рәтләрнең берсендә аңа таныш йөз чалымнары чагылып узгандай булды. Ул хәтта озынча ак йөзне, төз борынны, уемлы иякне күргәндәй иде. Тик ул: «Монда каян   килсен ул? — дип уйлады.— Охшаган гынадыр». Һәм карашын якындарак, алтынчы рәт уртасында, тамашачылар арасында утырган режиссер Бикбауга күчерергә ашыкты. Рәмзинең күзләре зур ачылган, йөзе башкаларныкы кебек үк агарынган иде. Сафия, ниһаять, аны да яулап алган иде.

...Әйе, гадәти мохиттан аерылып, яңа урынга, яңа кешеләр арасына килеп эләгү режиссер Бикбауның да күңелен үзгәртеп җибәргән иде. Таныш булмаган залда, чит-ят кешеләр арасында утырганда, ул сәхнәгә дә яңача, берни белән исәпләшмичә, янәшәсендәге тамашачылар кебек үк эчкерсез карады һәм Сафияне дә өр-яңадан күргәндәй булды. Әйтерсең лә, күңел түрен каплап торган пәрдә салмак кына ачылып китте. Баксаң, мондый Кадимбикә — Рәмзинең дә хыялы, идеалы икән бит. Ул моңарчы үз-үзен аңлап кына бетермәгән: спектакльне нәкъ менә шушындый образ тирәсенә туплап хәл кылырга кирәк икән...

Дөрес, режиссерның очлы күзе тамашачыларга сизелми генә үтеп киткән төгәлсезлекләрне, эшләнеп җитмәгән урыннарны тотып ала иде. Бу урында мондыйрак хәрәкәт ясарга, тыныбрак торырга, бу сүзне ачыграк итеп әйтергә, менә бу урында басым ясарга... Режиссер кулы житенкерәмәү сизелә иде монда, шактый нык сизелә иде! Һәм Бикбауның, сикереп торып, спектакльне туктатырга, аерым күренешләрне икенче төрлерәк итеп кабатлатырга омтылган чаклары шактый булды. Ныклап шомартканда, чынлап та, театр тарихына керерлек спектакль чыгачак иде моннан, һәм Рәмзинең шундук эшкә керешергә кулы да, теле дә кычыта башлаган иде инде.

Бу сәгатьтә ул үзенең бөтен үпкәләрен, шәхси тормышында килеп чыккан көйсезлекләрне, Эльвираны, Шәфиканы оныткан иде.

Спектакльдән соң иң беренче булып сәхнә артына Исмегөл очып килеп керде:

— Котлыйм! Җиңдең! Бөтенесен аяк астыңа егып салдың!

Ә тавышы яңгырап тора! Ләкин Сафия бу хакта әйтергә өлгермәде, ачык ишектә Нигъмәтҗанны күреп, телсез калды...

Гостиницага кайткач, төн уртасында, Исмегөл бу хәлләрнең хикмәтен Сафиягә көлә-көлә сөйләде:

— Нигъмәтҗан абый килеп төште дә, Тәүфикъны чакырып чыгарып, бик озак сөйләште. Ни сере бар боларның дисәм, сине монда чакыртырга план корулары икән.

Бик соң яткан булсалар да, артистлар иртә уяндылар. Алар чәй эчеп чыкканда, сәгать тугызынчы гына иде әле.

Сафия белән Исмегөл Рабига күленә киттеләр. Ул авыл читендә генә икән, биек тупыллар ышыгыннан гына барасы. Әнә ул — агачлык уртасында зур түгәрәк көзге төсле, кояшта ялтырап ята. Әйтерсең лә, аны күктән бер илаһи көч ташлаган, урман як-якка чигенеп, җир уелып кергән. Тирә-як калкулыклардагы чыршы-наратлар аңа ерактан карап торалар, аргы ярдагы дүрт бертуган өянке генә, бер-берсенә сыенышып, батыраеп, якын ук килеп, суга караганнар да, үзләренең нечкә тармактолымнарына хәйран булып, тынып калганнар. Күл өсте тыныч, якты, керфекләреңне кыса төшеп, хыялга бирелсәң, аны җирнең мөлдерәгән күзе белән дә чагыштырырга була.

Сафия белән Исмегөл, җиңел туфлиләрен салып, ярга якын килделәр, салкынча, йомшак ләмдә аларның яланаяк эзләре уелып калды. Кызлар, учларына су алып, битләрен, иреннәрен сөрттеләр.

Бераз тынып торгач, чирәмле сукмактан кире өскә менгәндә, наратлар арасыннан каршыга кыска җиңле күлмәк кигән, озын буйлы бер ир кеше килеп чыкты. Бу — Нигъмәтҗан иде.

— Саумысыз, кызлар,— диде ул берни булмагандай.

— Исәнмесез,— диде Исмегөл туктап. Ә Сафия атлавында булды, йөрәге кинәт каты дөпелдәгәнен, каушаганын сиздермәскә тырышты. Нигъмәтҗан аның юлына аркылы басты:

— Гөнаһлы булмагыз, Сафия туташ, бу изге урында күңелдә кинә йөртергә ярамый. Монда кешеләрне генә түгел, кош-кортларны рәнҗетү дә зур гөнаһ санала.

— Башка гөнаһ кылырга язмасын,— диде Сафия маңгай астыннан гына карап.

— Алай димә! Син беләсеңме бу күл янында Рабига исемле күзгә күренмәс кыз яшәгәнен, аның бар нәрсәне күреп, ишетеп торганын?

Сафия дәшмәде, керфекләре генә тетрәнеп куйды.

— Рабига күле риваятен ишеткәнегез юкмы әллә сезнең? — дип сорады Нигъмәтҗан бу юлы Исмегөлгә борылып. Исмегөл Сафия белән Нигъмәтҗан арасындагы киеренкелекне киметеп, аклы күлмәге белән каеннарга тиң яктырып, елмаеп тора иде.

— Юк, Нигъмәтҗан абый, ул яктан надан бит без. Әллә Сез беләсезме?

— Беләм. Монда килүем дә махсус сезгә шуны сөйләр өчен генә.

— Сөйләгез әле, Нигъмәтҗан абый,— дип, балаларча наз белән сузды Исмегөл.

— Борын-борын заманда, кәҗә команда, саескан сотник, үрдәк урәтник булган заманда бу күл тирәсендә калын кара урман булган ди. Күлдә аккошлар оя корган, тирә-юнендә бихисап җәнлек үрчегән ди. Болгар каласының сунарчылары монда ауга йөргәннәр. Шул сунарчыларның берсе Булат Мәргән исемле булган ди, аның Рабига исемле кызы булган ди. Рабига аккошларны бик ярата икән, аларны кызгана икән. Ул атасына: «Әтием, син бүтән аккошларны атма!» — дип ялварган. Булат Мәргән кызына бүтән монда ауга йөрмәскә ант биргән. Берзаман Болгар ханлыгына читтән олы кунаклар килергә тиеш булган. Хан барча аучыларын чакырып китергән дә иртәгесен аккошлар тотып китерергә боерган. Булат Мәргән дә аның әмеренә буйсынырга тиеш булган. Төнлә, кызы татлы йокыга талгач, ул ук-җәясен алып, күлгә киткән. Әмма кыз моны сизеп алган. Ак яулыгын бөркәнеп, ул да күлгә йөгергән, тик аучылар сукмагыннан түгел, туры юлдан киткән ул. Яр буена басып, яулыгын күтәреп җилпегән дә: «Әтием, атма аккошларга, атма!» — дип кычкыра башлаган. Әмма урман шавы аның тавышын басып киткән. Булат Мәргән аның җилпенгән ак яулыгын аккош дип

белеп, угын төзәп атып җибәргән. Аның угы Рабиганың йөрәгенә барып кадалган.

— Ай аллам, үз кызын үзе һәлак иткәнмени шулай? — диде күзләрен зур ачып Исмегөл.

— Бичара кыз яраланган аккош кебек үзәк өзгеч өн белән кычкырып җибәргән дә күлгә егылган ди. Булат Мәргән бу юлы кызының тавышын танып алган, йөгереп килсә, ни күрсен, су өстендә ак яулык кына чайкала икән. Аучы аңа үрелгән икән, яулык ак канатка әверелгән, ул җилпенә башлаган һәм судан аккош калкып чыккан. Ул, Мәргәнне күреп, читкә тайпылган, сызланып кычкырган да, авыр гына күтәрелеп, башка аккошлар тарафына очып киткән.

— Рабига... шулай аккошка әверелгәнмени? — Исмегөл тынычланып киткәндәй булды.

— Әйе, нәкъ шулай. Хәзер дә исән ди әле ул. Таң аткан сәгатьләрдә күл тирәсендәге һәммә җан иясенең иминлеген саклый ди. Көндез күзгә күренми икән, тик барысын белеп тора ди, әгәр берәр җан иясе кыерсытылса, үзәк өзгеч итеп кычкырып җибәрә ди.

— Шулай укмыни? — дип көлемсерәде Сафия.

— Шулай, шулай. Карагыз аны, мине рәнҗетмәгез, Рабига хәзер кычкырачак үзегезгә.

Кызлар, дәррәү борылып, шикләнеп, суга карадылар. Аннары үзләренең беркатлылыгыннан үзләре үк көлеп җибәрделәр.

— Ә мин, Рабига күленең кыйссасы мәхәббәт белән бәйле дип уйлаган идем,— диде Исмегөл.

— Мәхәббәт ул, беләсегез килсә, мәрхәмәттән башлана. Рабигадай нечкә күңелле, сизгер, саф, миһербанлы йөрәкләр генә риваятьләргә кереп калырлык итеп ярата ала. Таш бәгырьле кешенең башка берәүне чынлап сөюе мөмкин эшмени?

Нигъмәтҗан моны Сафиягә карап әйтте, тегесе ни сәбәптәндер кызарынып чыкты.

Күл чыннан да тылсымлы иде ахрысы, кай арададыр Исмегөлнең ак сыны наратлар арасындагы ялгыз каен кебек чагылып узды да юкка чыкты, аңа ияреп китәргә дип талпынган Сафиянең аяклары чирәмгә ябышкандай булды, кымшанмады. Йөрәктән җылы дулкын күтәрелеп, әйтергә дип әзерләп куелган чәнечкеле сүзләрне эретеп юкка чыгарды, йөздә елмаю балкытты.

Тылсым яр буенда гына түгел, шактый еракка таралган булса кирәк — ул Сафияне, Нигъмәтҗанга ияртеп, урам әйләндерде, ә кичкә таба, көннең эссесе сүрелә төшкәч, икесен янәшә борынгы Болгар җиренә алып чыгып китте.

Алар эссеdә тынып калган киң урам буйлап, нык капкалы ихаталар, кәрнизләре челтәрле йортлар, сиртмәле кое, биек тупыллар яныннан, йомшак тузанлы юлдан китеп, поселок читенә чыктылар, аз гына арырак калкып торган дүрт почмаклы ике таш багана арасыннан үттеләр. Баганалар борынгы Болгарның капкасы урынына куелган икән — аларның берсенә беркетелгән тимер тактадан шул мәгълүм булды. Капкадан ике тарафка чирәм баскан зур буразналар, сузылып, еракка китә — монысы каланың ишелгән дивары һәм янындагы тирән су чокырыннан калган уем икән. Алда, кала үзе булган урында, киң чирәмлек җәйрәп ята, еракта ак манара калкып тора, аннан читтәрәк бер авыл күренә иде.

Сафия белән Нигъмәтҗан аяк киемнәрен салдылар, йомшак, җылы тузанга баскан саен рәхәтлек тоеп, манарага таба киттеләр.

Авыл янындарак бер урынга кызыл бозау бәйләп куйганнар иде. Ул үзенә якынлашып килгән кешеләргә зур күзләре белән иренеп кенә карап алды да яткан килеш күшәвен дәвам итте. Аннан ерак та түгел дүртпочмаклап казылган киң чокыр күренде. Аның бер читенә балчыкка буялган чүлмәк ватыклары, икенче почмагына сөяк-санак өеп куелган иде.

Археологлар казыган чокыр, аларның табышлары иде бу. Кызыл

балчыкка, чүлмәк ватыкларына, сөякләргә текәлеп карагач, Сафиянең йөрәге жу итте. Шаулап-гөрләп торган каладан, меңнәрчә кешеләрдән фәкать шулар гына калганмы? Ул, башын күтәреп, тирә-юнендәге такыр кырны күздән кичерде. Чыннан да биредә мәшһүр кала булды микәнни? Чыннан да анда меңләгән халык гомер сөрде микәнни? Кайда аларның йортлары, урамнары, гүзәл сарайлары? Кайда куанычлары, көенечләре, сөюе, нәфрәте, җыры-моңы? Барсы да менә шушында, Сафия басып торган чирәмлек астына иңеп юкка чыкты микәнни?

— Археологлар, шушындай казылмалардан чыгып, Болгарның планын төзегәннәр инде,— дип сөйли иде Нигъмәтҗан.— Без басып торган төштә чүлмәкчеләр урамы булган, арырак тимерчеләр яшәгән. Гаҗәп оста төзүчеләр, дан тоткан мәдрәсәләр, затлы сарайлар, көтепханәләр булган монда. Йортлар идән аша җылытылган...

Чыннан да шулай булды микән? Ә бәлки, аларның барысын да галимнәр үзләре уйлап чыгаргандыр?

Ләкин әнә бит, ерак та түгел, чирәмлек уртасында ак манара калкып тора, аның янында йомры башлы төрбә. Әйтерсең лә алар бүгенге кешеләргә еракларда калган каладан хәбәр китергәннәр.

Димәк, шәһәр дә, осталар да, галимнәр дә булган. Алар заманында да кояш шушылай нурын сипкәндер, акчәчәкләр ак башларын җилдә чайкагандыр, кызыл бозаулар да шушылай гамьсез күшәп яткандыр. Вакыт үзенең агышын дәвам итә, күпмедер җәйләр-кышлар узганнан соң, хәзер җирдә яшәгәннәр дә шушы рәвешле юк булырлар. Нигъмәтҗан да, Сафия дә... Алардан да шушындый ватык-сыныклар гына калырмы?

Сафиягә куркыныч булып китте, ул чокырдан читкә чигенде.

Манара тирәсендә иркен мәйданны койма белән әйләндереп алганнар да турникет куйганнар — монысы да галимнәр эше, мал-туар таптамасын дигәннәр. Әчтә урта яшьләрдәге бер ир кеше, башын иеп, нидер эзләнеп йөри. Сафия белән Нигъмәтҗанны күреп, ул үз итеп елмайды. Мондый урыннарда кешеләр тиз таныша, уртак хис күңелләрне якынайта.

Ир кеше йөзеннән акыл һәм күңел ачыклыгы бөркелде.

— Истәлеккә борынгы таш эзләвем иде,— диде ул.— Әти сорый. Болгардан миңа истәлеккә бер таш булса да җибәрче, дип яза. Минем әти Болгариядә яши, үзе килә алмый. Болгарлар бит без. Берәр тамгалы таш очрамасмы дигән идем.

— Казылган җирдән эзләп карарга кирәк аны,— диде Нигъмәтҗан.

— Шулай итәрмен инде. Безнең әти әйтә, Идел буе болгарлары белән без бертуган ди.

Алар халыкларның катлаулы язмышы, туганлыгы, дуслыгы турында сөйләшеп киттеләр.

Нигъмәтҗан, башын артка каерып, манарага карады да:

— Ул заманда мондый корылмаларны ничек күтәргәннәрдер — башка сыймый,— дип куйды.— Хәзер генә ул, кранны китереп куясың да кирпечләрне «ә» дигәнче астан биреп кенә торасың. Шуңа карамастан, кайбер йортларыбыз үз гомеребез эчендә җимерелеп куя әле. Гасырларга чыдарлык шундый бер корылма торгызсаң, үлсәң дә үкенмәс идең.

— Гаҗәп...— диде Сафия.— Гаҗәп. Зур каладан нибары бер манара торып калган. «Кадимбикә»дә Хаким әйтә: бу каланың халкы миңа баш июгә караганда һәлак булуны артыграк күрде, ди. Каласын да, баласын да, үзен дә кызганмады, капкаларны миңа ачмады ди. Каланы яклап, күпме җаннар кыелган! Ә ул барыбер юкка чыккан.

— Хикмәт каланың таш биналарында гына түгел бит,— диде Нигъмәтҗан уйланып.— Хикмәт яхшылыкны, изгелекне явызлыктан, золымнан яклауда. Уйлап кара: әгәр дә бу халык шул чакта золым каршында баш игән булса, буйсынса, бүген без кем булыр идек? Алар һәлак бул-

ганнар, ләкин безгә бу манараны гына түгел, Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф»ын, телебезне, җырларыбызны, яхшылыкка омтылган рухыбызны саклап калганнар. Әгәр алар шул чакта золымга буйсынган булса, без бу җирдә яши алыр идек микән әле?

Тагын тынып тордылар.

— Кайчакта миңа, бу җирдә минем беренче генә яшәвем түгелдер сыман тоела,— диде Нигъмәтҗан.— Бу манараны салганда, ул биегәя барган саен, сулышның иркенәйгәнен, җанның куанганын шул хәтле ачык итеп күз алдына китерәм, нәкъ үзем кичергән шикелле. Биналар торгызу — гаҗәп бит ул, җирне күккә, кояшка якынайтасың сыман. Үзең кошларга тиңләшәсең кебек.

Сафия очлаеп килгән манара түбәсенә керфеген дә какмый озаклап карап торды. Әнә аның түбәсе турыннан ак болыт йомарламы узып бара, ул беразга тукталып та калды шикелле. Әллә ул болыт түгел, җирдәгеләрнең хәтерен яңартырга җибәрелгән хәбәрме?

Чыннан да, Сафиянең хәтере яңара түгелме? Ул да бик ачык күз алдына китерә: менә шушылай күзне кысыбрак караганда, манараның әле төзелеп бетмәгән, очлаеп кына килгән чагын күрәсең. Аннан, югарыдан Сафиягә куанычтан балкыган берәүнең йөз нуры түгелә, йөрәге талпынып типкәненә хәтле ишетелә бугай...

Әйе, кайчандыр кичерделәр алар бу хисләрне, югыйсә шушы хәтле аермачык булып күз алдына килеп басар идемени ул күренеш, уртак хистән күңел шушы рәвешле җилкенер идемени?

Алар борынгы төрбә эченә керделәр. Салкынча, дымлы һаваны күкрәк тутырып сулагач, Нигъмәтҗан:

— Җырла әле, Сафия,— диде.— Тавыш яңгырашы ничек икән.

Сафия тирән итеп сулыш алды да, әкрен генә, сак кына сузып җибәрде:

> Исмә җил, сызгырма, тукта,
> Монда әнкәм күмелгән.
> Монда ятим, яшь сабыйның
> Кайнар яше түгелгән.

Тавыш тора-тора көчәйде, киңәйде, әйтерсең лә таш диварлар да кызга кушылып моңлана, сагышлана иде. Нигъмәтҗан да җырчы тавышыннан бигрәк аларны тыңлады булса кирәк.

Сафия соңгы авазны сузып туктаганнан соң да әле диварлар моңны дәвам итеп тордылар, иң ахырдан да җыр тынмады, ә бәлки, ташка сеңеп, ишетелмәскә әверелде.

Алар ташларга иңгән моңны таратудан саклангандай, әкрен генә басып, кояшлы чирәмлеккә чыктылар.

— Менә хәзер мин ышандым,— диде Нигъмәтҗан.

— Нәрсәгә?

— Кадимбикәгә.

Ул Сафиянең аңлап җитмәгәнен тоеп, сүзләрен сайлап кына сөйләргә кереште:

— Тарих бүгенге көндә хәтер бөреләре рәвешендә саклана. Археологлар, галимнәр ул бөреләрнең рәвешен, төсен ачыклый. Әмма, ул бөреләр җанлансын өчен, бу гына җитми. Аларны җыр, җанлы сүз, тасвир — кыскасы, сәнгать кенә җанландыра ала. Сәнгать — безнең хәтеребезнең кояшы һәм яңгыры ул. Әйтик, менә сез борынгы шәһәрне, анда кайчандыр яшәгән кешеләрне чын итеп, теп-тере итеп минем күз алдыма китереп бастыра аласыз. Фәкать сез генә, башка беркем моны булдыра алмый.

— Әйе, шулай,— диде Сафия. Ул бу туфракка күптән иңгән Кадимбикәгә яңадан җан өрә ала, аның бөтен язмышын кешеләр алдында ачып бирә ала. Менә нинди эш килә гади артистның кулыннан!

— Ә аларны җанлы итеп күрү безгә кирәк, бик кирәк, ансыз тормышның мәгънәсе югала,— дип дәвам итте Нигъмәтҗан.— Кем без шушы туфрактан, ата-бабаларыбыздан аерып алып карасаң? Кем ул

Сафия Бикташева? Нигъмәтҗан Әхмәтнуров кем? Бу исем-фамилияләр болай әйткәндә буш аваз булып кына яңгырый. Әмма инде бу ике кеше турында, алар шундый-шундый ил-җирдән, менә шушындый халыкның балалары дип аңлатып әйтсәң, ул чакта алар бөтен кешелек каршына зур бер халыкның вәкилләре булып килеп басалар, галәм чиксезлегендә очып йөргән тузан бөртеге булып калмыйча, үзләренең нык нигезле җирлеген табалар. Менә кем булабыз без ул чакта!

Сафия рәшәгә төренгән ерак урманга, якындагы авылга карады. Әйе, чыннан да, кайчандыр бу якларда көн көткән кешеләр, кала салган, китаплар язган, җырлар чыгарган кешеләр күптән җир куенында инде. Ләкин алар юкка чыкмаганнар, юк, аларның рухы безнең җаннарда, җисеме безнең тәннәрдә саклана. Без — җирдә безгәчә яшәгәннәрнең мирасы, алар хезмәтенең, намусының, әхлагының нәтиҗәсе һәм дәвамчысы. Менә без кем!

— Кайчан да булса бу урынга бөтенләй бүтән кешеләр килер,— дип дәвам итте Нигъмәтҗан.— Ул чакта инде без дә тарихка әверелеп калган булырбыз. Безнең хакта да: борын-борын заманда, кәҗә команда...

— ...яшәгән ди Нигъмәтҗан исемле бер егет дип сөйләрләрме? — дип аның сүзен дәвам итте Сафия.

— Сөйләрләр, сөйләргә тиешләр.

— Тик ничек булыр икән соң ул кыйссаның дәвамы?

— Кылганнарыбызга лаек булыр.

— Моның өчен безнең кылганнарыбыз әкият итеп сөйләрлек булырга тиеш шул.

Нигъмәтҗан аның кулын учына алып, сак кына кысты, шуның белән уйлары уртаклыгын белдерде.

## 39

Әстерханга киткәнче, Сафиянең Казанда берничә буш көне булды. Алар Нигъмәтҗан белән паркка чыктылар. Яшь чакта, аннан да бигрәк парлы чакта, парк-бакчалар ифрат ямьле була бит ул. Бүген дә алар килүгә әйтерсең лә һәр төшне юып-җыеп, тузанын сөртеп, гөлләрен чәчәк аттырып, эскәмияләрен буяп, хәтта күк йөзен дә шомартып ялтыратып куйганнар иде. Алар тамаша тәгәрмәченә утырып, кала урамнарына һәм елга аръягына биектән карап төштеләр, түгәрәк мәрмәр өстәл янына басып, туңдырма ашадылар, эсселек әлсерәткәч, фонтан читенә иелеп, су чәчрәтештеләр.

Аннары агачлар күләгәсенә керделәр. Куе куаклар үскән текә ярлы чокыр төбендә йөргән зәңгәр күлмәкле, сары чәчле бер хатын-кызның кыяфәте Сафияне сискәндереп җибәрде — бүгенге якты, матур көнгә шул хәтле ятышмый иде ул. Хатынның иелгән башыннан, салмак адымыннан, кулларын тигезле-тигезсез болгавыннан хәсрәт бөркелә иде — «Жизель» дигән балетта биючеләр аңын югалткан яшь кызны шундыйрак итеп тасвирлыйлар: ул да шулай кулларын өнсез буташтыра, өнсез атлый.

— Карале,— диде Сафия,— безнең Шәфика апа түгелме соң бу? Нишләп анда нәүмизләнеп йөри икән?

Ул, үр кырына ак туфлиләре белән кырын басып, куакларга тотынып аска төшеп китте.

— Шәфика апа, нишләп йөрисез монда?

Шәфика апа әле генә йокысыннан уянгандай, күк йөзедәй күзләре белән аңламыйчарак карады.

— Ә нәрсә?

— Әллә берәр әйберегезне югалттыгызмы дим?

— Югалттым шул, Сафия, югалттым.

— Шушында төштемени? Ни төслерәк соң ул? И, бу үлән арасыннан табарсың инде, бар. Әйдәгез, бергәләп эзлик.

— Булмас шул,— дип аның белән килеште Шәфика.— Табылмас. Син табарлык кына булса, мин аны югалтып та тормас идем.

— Алайса, әлсерәп йөрмик монда, өскә меник, бик бөркү бит.

Чыннан да, өскә менеп, карт тирәк төбендәге агач утыргычка утыргач, сулыш җиңеләеп китте. Нигъмәтҗан шешә белән су китереп бирде. Барча гамь-ваемнар агач ябалдашлары арасында адашып, кояш нурында эреп юкка чыккандай, бу рәхәт дөньяда Шәфиканың да борчуларын таратасы, аның да күзләрендә гадәттәге яктылыкны балкытасы килә иде Сафиянең. Тик моның чарасын гына белеп булмый иде.

— Син каян килеп чыктың соң әле? — дип сорады Шәфика бераз зиһенен җыйгач.

— Әстерханга киткәнче бер ял итеп аласы килде.

— Тагын Идел буйлап китәсез инде, ә?

— Иделдә рәхәт бит, Шәфика апа. Шундый матур. Сез дә бер чыгып керегез. Күңелегез ачылыр.

— Миңа Иделдә йөрергә ярамый шул.

— Нишләп?

— Яратмый ул мине. Мин анда бер батып үлә яздым инде.

— И, Шәфика апа, аннан бер дә куркып тормагыз Сез.

— Бер карасаң, бигрәк кызык уйный бу язмыш адәм балалары белән, әйеме,— диде Шәфика.— Берәүләрне тормыш юлыннан, абынмасын-сөртенмәсен дип саклап кына алып бара, юлларыннан бөтен кантарларны алып куйгандай итә. Ә безнең ишеләргә көйсезлек өстенә көйсезлекне өеп кенә тора. Нидә икән моның хикмәте?

Сафия — «язмыш» дигәндә, Шәфиканың кемне күз алдында тотканын бик яхшы белә иде. Ул Рәмзине күз алдына китерде: аның Әстерханга киткәндә артистлар белән ничек кыенсынып, оялып хушлашканын... Аннан да элегрәк, авылларда спектакльләр белән йөргәндә, бигрәк тә беренче тапкыр Сафияне сәхнәдә күргәч, ничек мавыкканын, дөньясын онытып караганын... Аннары көндезләрен клубларның сәхнәләрендә озак-озак репетицияләр ясаганын. Ничек мавыгып эшләгәннәр иде бит алар! Көз җиткәч, театр сәхнәсендә премьераны ничек зурлап үткәрергә планнар корганнар иде! Шулай ук теге чандыр кызыкай бу хыялларның бөтенесен онытуыра алыр микәнни? Әгәр алай икән, димәк, режиссер Бикбау чын иҗат кешесе түгел, аның мавыгулары да ясалма гына булган дигән сүз.

Сафиянең моңа ышанасы килми иде. Шулай да ул бу хакта Шәфикага ачылып, ышанычлы итеп сөйләп бирә алмады. Фәкать, үзалдына уйланып утырганнан соң:

— Әгәр Идел чыннан да Сезгә үчле булса, теге чагында ук ычкындырмас иде,— диде.— Бу юлы да үтә торган хәсрәт кенә килгән Сезгә.

Шәфика аңа зәңгәр күзләре белән мөлдерәп, ышанырга теләп карады:

— Үтәр дисеңме?

— Менә, әйткән иде шушы кыз диярсез.

— Ләкин...— Шәфика читкә карап уйланды.— Ник соң ул сездән аерылып китте, бер көнгә булса да кайтмады? Аның туган көне бит бүген. Ә мин аңа бүләк алып куйган идем... Буй-буй йөнтәс кытай халаты. Күптән хыялланып йөри иде. Хәзер кирәге дә калмады бугай инде,— дип, яшь аралаш көлемсерәргә тырышты Шәфика.

— Нишләп кирәк булмасын? Үлмәгән ләбаса ул. Бирегез Сез аны миңа! Әстерханга баруга, тапшырырмын. Менә күрерсез, кайта ул. Мин үз кулларым белән кайтарып тапшырам аны сезгә!

— Ничек итеп?

— Чарасын беләм. Соңыннан әйтермен.

Сафия белән Нигъмәтҗан икәүләшеп Шәфиканы өенә чаклы озатып куйдылар, әманәтен алдылар. Халат кесәсенә Шәфика кыска гына сә-

лам хат та тыкты, анда Рәмзинең көзгә эти булачагын да белгерткән иде.

Әманәткә рәхмәт һәм хатка җавап көткән көннәр Шәфика өчен бик озын булып тоелдылар. Ниһаять, Рәмзидән җавап килеп төште.

Хат кыска иде: «Бүләгең өчен рәхмәт яусын. Мәшәкатьләнергә кирәк түгел иде. Ә яңалыгыңа килгәндә, турысын әйтәм: хәзерге көндә безнең араларны бәйләп торган өченче берәүнең булмавы хәерлерәк түгел микән? Ныклабрак уйлап кара әле...»

Хатны укыганда, Шәфика Рәмзинең тавышын ишеткәндәй булды. Тавыш ялгызы гына яңгырамый, аңа тагын кемдер кушыла иде кебек. Мөгаен, кәгазьгә төшкән һәр сүзне ят күзләр күзәтеп торгандыр. Рәмзинең җилкәсе аша үрелеп...

Шәфика елый алмады. Аның күңеле ничектер катып киткәндәй иде. Юкка тырышкан дип уйлады ул көндәше хакында. Бу дөньяда Шәфика бик үк дөрес яшәп бетерә алмагандыр, ләкин ул беркайчан да үзенең дошманнары теләгәнчә, алар кушканча яшәмәде. Бу юлы да алар теләгәнчә булмаячак.

## 40

Рәмзи Бикбауны Казанга алып кайту Сафия уйлаганча ансат булып чыкмады. Гастрольләр тәмамланып, артистлар ялга тарала башлагач кына, Сафия Рәмзинең Казанга түгел, Кара диңгез буена билет алганын белде. Үзе генә түгел, тагын шул Эльвира белән бергәләп...

Казанга кайтуга, Сафия Шәфика янына үзе барды. Шәфиканың кыяфәте генә түгел, холкы да нык үзгәргәне сизелде. Ул эч серен үзендә сакларга тырышты:

— Минем Рәмзи диңгезгә китте бит инде, беләсең,— диде.— Үзебез шулай килештек. Миңа бу хәлемдә көньякка барырга врачлар рөхсәт итми. Ул ял итсен дидем инде.

Әгәр дә зарланса-сыкранса, Сафиягә читен булачак иде. Ә болай көрешеп-сөйләшү икесе өчен дә җиңелрәк узды.

Өстәвенә Сафиянең үз мәшәкатьләре дә җитәрлек иде. Һич уйламаганда дигәндәй, Сафиягә үзенең кайчандыр әйтеп куйган нәзерен үтәргә җай килеп чыкты. Профсоюз оешмасы бер көнгә Киев каласына экскурсия оештыра икән. Иртәнге алтыда самолет Казаннан оча, төнге дүрттә кире монда кайтып төшә. Ничек шулай бөтенесен бик җайлы гына туры китереп куйды соң әле бу язмыш? Вәгъдәсен җиңел генә биреп ташлаган иде, үтәү ягына килгәндә, кыюлыгың җитәрме дип, юри сыный иде микән әллә ул Сафияне? Килгән хатлар да шактыйдан җавапсыз ята иде, моны уйлап, Сафия үзалдына кыенсынып куйды.

Кыенсынырга тагын да бер сәбәп бар иде: аның кем беләндер хат алышканын да, нәзер әйткәнен дә Нигъмәтҗан моңарчы белми килде. Андый серләрне кешегә ачуның үз вакыты бар бит ул. Ашыгу яхшы түгел, егет кешенең кыз турында, нишләп бу хәтле кылана әле бу, әллә миндә берәр өмете бармы дип уйлавы мөмкин. Киная дип кабул итүе бар. Соңарсаң да уңайсыз, эчле булып күренәсең.

Ә Сафия бу эштә соңарып барганын абайламыйрак калган иде бугай.

Алар паркта кечкенә якта очраштылар. Казан елгасының биек ярына басып, аргы якка озак кына карап тордылар. Анда, баеп барган кояшның алсу-саргылт нурларына коенып, иркен болыннар, камышлы сазлыклар, әрәмәлекләр җәйрәп ята, алар артында яңа районның ак биналары тезелеп баскан иде. Колакта зур каланың һич тынмый торган гөрелтесе шаулый, сыек зәңгәр күктә ак тасма сузып, көмеш лачын — самолет узып бара, болын-әрәмәләрне кисеп узган киң юлдан уенчык хәтле генә булып трамвай барганы күренә, юл өстендә зәңгәрсу төтен эленгән. Ә әрәмәлек өстендә оеш-оеш булып та, сибелеп тә кара нок-

талар бөтерелә — куаклар арасында кыр үрдәкләре бала чыгарган, хәзер шуларны зур юлларга әзерлиләр, чыныктыралар. Күпме афәт алар тирәсендә, күпме куркыныч яный, җәйләрен әрәмәлекләрдә мылтык тавышлары да гөрселдәп куя бит әле — браконьерлар бернинди законнар белән исәпләшми — шуңа да карамастан, тормыш дәвам итә, үрдәкләр һәр яз саен туган җирләренә кайтып оя кора, һәр җәй саен шул куаклар өстендә балаларын канат ярдыралар...

Аларга карагач, ямансу да, рәхәт тә булып китте.

— Сафия, озакламый көз җитә, туйлар вакыты...

Нигъмәтҗанның тавышында да ямансулау, олы юлга чыгар алдыннан була торган алгысу, дулкынлану сизелде.

— Көзләр житте, Сафия, безгә дә ныклап уйларга вакыттыр...

Сафиянең күңелендә аның сүзләренә каршылык туды. Бик зур сүз башлый түгелме бу егет? Иртәрәк бит әле, вакыты җитмәгән, аңа җавап бирергә әзер түгел әле Сафия!

— Син квартирлы кыз эзлисең бит,— диде ул һич кирәкмәгәнгә Револны искә төшереп. Үзе шундук бу сүзләренең урынсызлыгын аңлады, кызарынды, кыенсынганын сиздермәс өчен, йөзен читкә борды да елга өстеннән Иделгә таба йөзеп барган су трамваена текәлгән булып кыланды. Трамвай ак иде, кичке кояш нурларыннан чак кына алсуланып, балкып, көмешләнгән су өстеннән тантаналы бер хәрәкәт белән килә иде. Шундый чиста иде ул, әйтерсең, аңа бер генә кер бөртегенең дә кунуы мөмкин түгел иде.

— Ә нигә,— диде Нигъмәтҗан,— өйләнер алдыннан квартир ягын чамалау гаеп эшме әллә? Загстан парлашып кая да булса кайтып керергә кирәк бит.

Ул моны бик тыныч, бик гади итеп әйтте. Аның сабырлыгы һәм җавабының шушы хәтле гадәти булуы тагын Сафиянең кәефен бозды.

— Алайса булачак кәләшнең нәсел-нәсәбен, туган-тумачасын да тикшерергә кирәк инде. Ат алгандагы кебек, авызын ачтырып, тешләрен дә карарга...

— Анысы да артык булмас, анысын да карыйбыз,— диде Нигъмәтҗан уйчан гына. Ул тамчы да үртәлмәде.— Кәләшнең тешләре бик таза, үткен күренә, аллага шөкер. Тешләп өзмәкче. Анысы әйбәт. Балаларның теше сызламас...

Шуннан соң Сафия бу шаяруны кабул итеп, көлеп җибәрергә тиеш иде. Ләкин ул көлмәде, аның күңеле кинәт тынычланып китте, ул борылды да, Нигъмәтҗанның кояшта каралмый торган ак йөзенә, чокырлы иягенә, аның эчкерсез, якты күзләренә карады.

— Шулай да гаҗәп...— диде Сафия.— Сиңа мин түгел, Сафия дигән кеше түгел, квартирлы кыз кирәк сыман. Мин шул шартларга туры килгәнгә генә, хәзер син бу сүзне башлагансың кебек. Әгәр минем торыр урыным булмаса, әгәр мин бәхетсезлеккә юлыгып, ирдән аерылган хатын булсам?

— Булмаганны нигә сөйләшеп торырга? — диде Нигъмәтҗан. Ул иягең тагын да ныграк күтәреп, Сафиягә керфекләре арасыннан сынап карады.

— Ә шулай да... Андый очракта да... мин мин булып калыр идем бит инде.— Сафиянең сулышы кайнарланып, иреннәрен пешергәндәй итте.

Нигъмәтҗан аны беләгеннән тотып читкәрәк, агачлар ышыгына әйдәде.

— Беләсеңме, Сафия, дөресен әйтим, ул чакта миндә мең сорау туган булыр иде. Берәүгә үз теләге белән барып та, аның белән тормышын җайга сала алмаган кеше минем белән бәхетле яши алырмы? Һәм башкалар. Минем бу хакта баш ватасым килми. Сиңа ата-анаң саф дип исем кушканнар икән, син моны аклагансың, бик рәхмәт.

Сафия иренен тешләде.

— Утыздан узган карт кыз... Бәлки, миңа кеше карамагандыр.

— Миңа теләсә кем карый торган кыз кирәкми. Моңарчы мине көтеп алгансың икән, димәк, мин сиңа киләчәгемне ышанып тапшыра алам. Әйдә, без юкны уйлап баш катырмыйк, туй алдыннан мәшәкатьләр болай да җитәрлек булыр әле.

Сафиянең бу киреле-мырлы сөйләшүләрен ул ризалык дип кабул иткән иде инде. Менә бит ничек, Сафия нәзерен үтәү турында әйтергә дип килгән иде, ә Нигъмәтҗанның уе бөтенләй башкада булган икән! Сафия тәмам югалып калды. Кая китте аның кыюлыгы, кая китте сәхнә техникасы! Әйтергә теләгәнне сәхнә уенындагы кебек итеп тә әйтеп булмый, җитди әйтү аннан да читенрәк иде. Ул инде катылан-ган, нәфислегән җуйган тупыл яфрагын өзеп алды да, аның бөтен сырларын хәтеренә сеңдерергә теләгәндәй, бик җентекләп карарга кереште.

— Ә шулай да син минем хакта барысын да белмисең бит әле,— диде әкрен генә.— Минем... башка берәүгә биргән вәгъдәм бар. Сиңа җавап биргәнче, мин шул вәгъдәмне үтәргә тиешмен.

Тынлык урнашты. Сафия Нигъмәтҗанга борылып карарга оялды. Аның йөрәге шашып тибә, ул аваз Нигъмәтҗанга да ишетеләдер кебек тоела иде. Ниһаять, аның әкрен, бик әкрен, бераз калтыранган тавышы ишетелде:

— Ә бәлки, яңа вәгъдә бирер алдыннан искесеннән баш тартырга гына кирәктер? Син миңа... аның кемгә бирелгәнен һәм ни хакында икәнен әйтә алмыйсыңмы?

— Вәгъдә дип... Нәзер иде ул. Нәзер әйткән идем мин...

Сафия Нигъмәтҗанның, өстеннән авыр йөк төшкәндәй, җиңел сулап куйганын ишетте.

— Ә-ә, нәзерменн... Шулай дияргә кирәк аны. Югыйсә артык зур итеп тотындың.

— Юк, бу зур нәрсә... Мин бер кешегә, әгәр Кадимбикәне миңа бирсәләр, мин аны синең яныңа барып, берүзең өчен уйнап күрсәтермен, дип сүз биргән идем.

— Алай... Әгәр ул кеше янына без икебез бергә барып кайтсак?

— Син миңа ышанам дигән идең. Әгәр ышануың шуның хәтле генә булса...

— Кем соң ул?

— Ул еракта...

— Бу балалык,— диде Нигъмәтҗан.— Аңа, хәлне аңлатып, хат кына язып булмыймы соң?

Сафия хәзер менә анда барып кайтырга бик җайлы форсат табылганын аңлатты.

— Баруын барырсың да, кайтуын ничек кайтырсың икән соң? — дип сорады Нигъмәтҗан.

— Шул ук самолет белән...

Сафиянең бу нәзере ничектер араларны ерагайтып җибәргәндәй булды. Хәзер инде киләчәккә зур планнар корып, туй хакында да сөйләшеп булмый, арада өченче берәүнең шәүләсе тора иде сыман.

Эңгер-меңгердә алар капка төбендә кул бирешеп кенә хушлаштылар.

— Ярый, синеңчә булсын...— диде Нигъмәтҗан.— Мин сине берсекөнгә кич белән Черек күл капкасы төбендә көтәрмен.

Инде хушлашып, Сафия ишеккә юнәлгән иде, инде ишек тоткасына тотынган иде, кинәт нәрсәгәдер сискәнеп борылып карады. Капка яныннан аңа таба ашыгып Нигъмәтҗан килә иде:

— Сафия, бу көлке! Театр уены бу, тормышта алай булмый! Тормыш законнары башка, үзенә бер! Сәхнәдә генә шулай була ул! Кем инде үзенең кәләшен башка берәү янына җибәрсен!

— Әгәр ышанасың икән, ахыргача ышан инде,— диде аңа Сафия.— Тормышның да без аңлап бетермәгән законнары күп бит әле. Әгәр үз сүземне үзем аяк астына салсам, күңелемә күләгә төшәр сыман. Безнең бүлмәдә портрет тора бит әле. Шул портретны язган кеше ул...

Ә бәлки, ул өйдә туры килмәс, я очрашырга вакыты булмас, яисә телефоны эшләмәс дип уйлаган иде Сафия. Җайсызлык гел килеп чыгып кына тора бит ул.

Ләкин «Борисполь» аэропортына килеп төшеп, беренче автомат-телефоннан шалтырату белән, аның тавышын ишетте:

— Тыңлыйм.

Ишетте һәм таныды. Ә ул Сафияне тавышыннан танымады. Көтми иде, Сафиянең Киевка килгәнен белми иде, аның белән телефоннан сөйләшкәне юк иде, шуңа танымады. Ләкин Сафия дулкынланудан калтыранган тавыш белән үзенең кемлеген әйткәннән соң да, аның каушап төшкәне сизелмәде. Тыныч, эшлекле итеп сөйләште.

Алар көндезге сәгать икедә тимер юл вокзалы янындагы метро станциясендә очрашырга килештеләр.

Сафия, күп халык арасында бер-беребезне тиз генә таба алмабыз, читен булыр, ә бәлки, ул мине танымас та әле дип курыккан иде. Тимер юл станциясенә алдан ук килде, борынгы чатырларга охшатып, тимердән челтәрләп эшләнгән вокзал бинасының эченә кереп, аның залларын, стеналардагы төсле фрескаларны карап йөрде...

...Ул киң мәйдан аша үзенә таба килгән Сафияне ерактан ук күреп алды, йомры башын иеп, зәңгәр күзләре белән сөзебрәк карады, елмайды, ләкин каршысына ашыкмады. Сафиянең һәр адымын йотылып күзәткән хәлдә, аны шушылай хәтеренә гомерлеккә сеңдереп калырга теләгәндәй, кузгалмыйча көтеп алды. Кыяфәтендә беркатлылык, чисталык. Бер дә үзгәрмәгән, һаман шулай «сакаллы сабый» икән әле.

Озак күрешми торганнан соң очрашкач, сөйләшергә сүз табу баштарак кыен була. Әйтәсе килгәннәр күп, бик күп, кайсыннан башларга белми аптырыйсың. Алар шулай тынып, кара-каршы басып торганда, машина гөҗләве аркылы кинәт кенә вокзал ягыннан берничә тавышка җыр сузып җибәрделәр. Икесе дә ирексездән шул якка борылдылар. Вокзал янында берничә хатын посылка тартмалары, төеннәре бушаталар икән. Шулар эштән туктаганнар да, өемнәр өстенә утырышып, җырлап ял итәләр:

Зәңгәр күккә карыйм, йолдызларны саныйм,
Моңлы уйларымның очын таба алмыйм;
Ник мин бер кош түгел, ник юк канатларым,
Очар идем җирдән, ташлап моңым-зарым...

Җыр моңлы иде, хатыннарның берничә тавышка — Сафия санап бетермәде, һәрхәлдә өчтән дә ким түгел иде тавышлары — сузган көе дәртле дә иде шул ук вакытта. Бу җырчы хатыннар үзләре дә белмичә, метро станциясенең гөмбәзе астында, ак таш багана янында очрашкан ике кешегә зиһеннәрен җыярга, уй-хисләре агышын бер көйгә җайларга ярдәм иттеләр, очрашуның беренче минутларында туган кыенсыну-ятсынуны җыр агышы белән юып алып киттеләр. Алар бер-берсенең күзенә туры карады. «Игнат, Игнат»,— дип аның исемен кабатлады күңеленнән Сафия. Гаҗәп, аңа бу исемне кычкырып әйтү сәерләнгән икән, чөнки бик озак вакытлар әйтелми торганга күрә тел бизгән, ятсыну башланган...

Игнат та шундыйрак хисләр кичерә иде булса кирәк, ул да Сафиягә исеме белән дәшәргә ашыкмады. Әле бүген иртән генә күрешкән кебек, гади генә:

— Синең ашыйсың киләдер? — дип сорады.

— Мин нәзеремне үтәргә килдем... Игнат. Хәтерлисеңме?

Игнатның зәңгәр күзләре томанланып киткәндәй булды, ул бераз уйланып алгандай итте.

— Хәтерлисеңме,— диде Сафия,— мин сиңа, бер пьесадагы төп

рольне миңа бирсәләр, аны янына килеп, үзең өчен генә уйнап күрсәтермен дип вәгъдә биреп хат язган идем...

— Ә-ә, әйе! Аны әйтәсеңмени! — Игнатның йөзендә, әллә ни мөһим нәрсә онытылмаган икән әле дигән сыман бер җиңеләю белән елмаю балкыды.— Мин гел әйтеп килдем бит: син менә дигән рольләр уйнаячаксың әле!

Игнатның күз карашында тагын борчылу чагылды. Ул таркау, нигәдер тынгысыз күренә, гүяки каядыр ашыга иде.

— Синең вакыт ягы ничегрәк соң? — дип сорады Сафия.

— Юк-юк, мин эштән әйтеп киттем...

— Ә шулай да...

— Әйтсәм, үпкәләмәссең микән? — Игнат бик кыенсынып елмайды.

— Әллә башка берәү белән очрашырга сүз куешкан идеңме? — Моны Сафия җиңеләеп, чын күңелдән сөенеп әйтте. Әй, Игнат та үзенә пар булырлык берәр кеше тапса, бигрәк яхшы буласы иде лә.

— Шулайрак шул,— диде Игнат аска карап.— Кайтып житәргә тиеш мин... әни янына. Ике генә сәгатькә дип киткән идем. Озакка дип сорасам, елый башлый, җибәрәсе килми. Авырый. Гел миңа гына карап тора.

— Янында башка кеше юкмыни соң? — Сафия бердән житдиләнде.

— Икебез генә яшибез бит без.

— Хәзер үк поездга утырсаң, әйткән вакытыңа кайтып җитәсеңме соң?

— Мин сине болай калдырып китә алмыйм бит инде!

Игнатның түгәрәк йөзендә Сафия белән бик тә, бик тә сөйләшәсе килгәне, китәсе килмәгәне сизелеп тора иде.

— Мин бит сиңа язган нәзеремдә, ролемне янына барып уйнармын дигән идем. Монда сине чакырып китереп түгел.

Игнат аңа ышанып җитмәгәндәй, күзләрен түгәрәкләндереп карады.

— Ә син... ул сүзеңдә торасыңмы соң?

— Шуңа дип килдем дә бит инде. Авылыңны төшләремдә күрә идем...

Электропоезд аларның ашыкканын, анда бер авыру карчыкның моңаеп, баласын көтеп ятканын беләә иде микән әллә, бигрәк ашкынып, бигрәк зур тизлек белән барды. Ак шәһәрчекләр, урманнар, кояшлы аланнар, инде туңга сөрелгән, каралып яткан басулар, мине күр дә мине күр, дигәндәй, йөгерешеп яннан узып тордылар. Монда йортлар аграк, агачлар — бездә дә үсә торган нарат-чыршы, каен-имәннәр тагын да зуррак, биегрәк, мәһабәтрәк булып үсә икән. Тормышның тынычлыгы, муллыгы һәркайдан сизелеп тора. Бу дөньяда кемнең дә булса авырып, сыкранып, зарыгып ятуына күңелнең ышанасы килми иде.

Поездан төшкәч, халык белән тыгызланып, кечкенә, калтырча автобуска утырырга туры килде. Автобус Болгарда пристань белән шәһәр арасында йөри торган кебек үк «Уазик» иде. Ул урман юлыннан һәм саргаеп утырган кукуруз басуы, ак йортлы авыллар кырыннан шактый барды. Менә, ниһаять, көчәнеп, тавышланып, урманлы үрдән менеп, туктап калды. Сулда — биек наратлар, уңда авыл урамы башлана иде. Әйтерсең лә, урман үзенең баһадир агачларын кешеләрнең иминлеген сакларга чыгарып бастырган. Игнат, авыл очындагы иркен ихатага, биек алмагачлар, груша агачлары ышыгында утырган ак өйгә таба ымлады.

Капка капканы ачты. Сафия эчкә атлап керде. Алмагачлар, грушаларның төбе эре җимешләре белән чуарланган, өй янында гладиолуслар җете төсләре белән күзләрне җәлеп итә. Арада иркенәеп утырган, күркәп үскән яшь чыршы каралып тора иде. Сафия аның сукмакка сузылган ботагын сыйпап узды.

— Бу чыршыны кызым тугач утырткан идем,— диде Игнат.— Баштарак нишләптер бик әкрен үсте. Оксананың аны очыннан тотып төшкән фоторәсеме дә бар әле. Аннары кинәт мантып китте, хәзер кызымның

буе житәрлек түгел инде... Ә бу алмагачның алмасы нишләптер чамасыз күп коела. Бик әйбәт сорт үзе. Ышанасыңмы, юкмы — былтыргы алманың соңгысын без быел июль уртасында әни белән икебезгә бүлеп ашадык.

Әни белән бер алманы бүлешеп ашадык... Ничектер сәер яңгырады бу сүз олыгаеп килгән ир кеше авызыннан. Алманы гадәттә гомерлек ярлар белән бүлеп ашыйлар...

— Тик менә коелып әрәм була. Ник икән, белмисеңме?

Чыннан да, агачның төбе алмадан чуп-чуар иде. Сафия бер тәгәрәп яткан эре, яшел, сусыл алмаларга, бер Игнатка карады. Кызык! Бу алмаларның ботагыннан ник вакытсыз аерылып төшкәнен артист кеше кайдан белсен? Шулай да дәшми калмады:

— Ә син аңа су сибәсеңме соң? — дип сорады.

— Үзенә кирәк дымны җирдән ала бит ул. Тамырлары җитәрлек тирән китә.

— Ә бәлки, аның суны өске тамырлары белән дә эчәсе килә торгандыр? Сусаганда үкчәне күлдәвеккә тыгып кына сусын басылмый бит, авыз белән эчәсе килә.

Игнат, көлемсерәп, башын чайкады.

— Үтемле әйтәсең. Су сибәргә була анысы, аның берние юк. Шлангыны сузып саласың да, агып ята ул шунда.

Сафия күкрәп утырган иркен бакчаны, әле генә акшарлангандай, пөхтә-чиста зур йортны күздән кичерде. Бөтенесен карарга, тәртиптә тотарга кирәк. Больницада авыруларны карау һәрчакта да эш сәгатьләре белән генә чикләнми. Хаста карчык та бар бит әле. Ние бар аның дип әйтүе генә җиңел. Һәрнәрсә күз сорый, кул сорый...

— Ә кызың... кайда соң?

— Әнисе белән... Монда килгәли... Еш түгел, әлбәттә.

Игнат болдырның ике басмалы баскычыннан күтәрелеп, өй ишеген ачты.

— Рәхим ит,— диде ул пышылдап диярлек. Аның сак хәрәкәтләреннән, тавышын әкренәйтүеннән, Сафия авыру карчыкны борчырга ярамаганын аңлады һәм аяк очларына гына басып, эчкә атлады. Өйалдына уңнан ике ишек, каршыдан бер ишек чыга иде. Уңдагы ишекләрнең берсеннән сыкрангандай нечкә тавыш ишетелде. Тавыш, зарланып, көйләп, нидер сөйләде, сүзләре аңлашылып бетмәде.

— Бу мин, мамо, кайттым. Син тыныч кына ят, борчылма.

Игнат каршы ишекне ачты. Бу — аның эш бүлмәсе булып чыкты. Каршы стена тоташ киштәләрдән тора, анда китаплар, агачтан, балчыктан, ботаклардан ясалган төрле сыннар, вазалар, чынаяклар тезелгән, уртада буйдан-буйга киң өстәл сузылып, өсте кәгазь-катыргы, буяулар, буягычлар белән тулган иде. Сафия аны әйләнеп узды да, киштә янына барып, балчык ташбакага орынды, ташбака, аны сәламләгәндәй, кечкенә башын уңга-сулга боргалый башлады.

— Кызык...— диде Сафия.

— Минем бер дус егет шөгыльләнә аның ише белән. Шул бүләк иткән иде. Ә мин... үзең дә чамалыйсыңдыр, агачка, көйдереп, бизәкләр ясау белән мавыгам.

Шунда гына Сафия бу бүлмәдә иң күзгә ташлана торган, иң мөһим нәрсәне игътибарсыз калдырганын аңлады: түшәмнең сап-сары нарат матчасы, тәрәзә кашагалары, ишек яңаклары кара бизәк белән тоташ чуарланган, ә киштәләрдә агач әйберләр балчык сыннардан чагыштыргысыз күбрәк иде.

Хатлар язган чакларда, күз алларына китереп күңелдән серләшкәндә-киңәшкәндә, очрашканнарны искә төшергәндә, Игнат Сафиягә бик якын, бик үз, бик таныш булып тоела иде. Ләкин ул күз алдына китергән ир-егет бөтенләй башка, хыял җимеше генә булган, чын Игнат исә катлаулырак та, гадирәк тә, читрәк тә икән, һәм аның Сафия күз алдына да китермәгән борчулары, моңнары, хәтта мавыгу-шөгыльләре дә бар икән...

Игнат аны тагын бер бүлмәгә алып керде — монысы кунак бүлмәсе яки зал иде. Тәрәзәләрдән челтәрле пәрдәләр аша кичке кояшның ямансу нурлары саркый, кырый өстәлдәге читлектә кечкенә сары кош, хуҗасы кайтканга сөенгән кебек, сикергәли иде.

— Сагындыңмы? — диде аңа Игнат. Аннары Сафиягә борылмый гына, учын читлеккә терәгән килеш, әйтеп куйды: — Менә без шушылай өч ялгызак бер-беребезгә сыенып, бер-беребезне сагынышып яшибез инде.

Кинәт кенә бу ят йортта Сафиянең күңеленә бик таныш, бик якын бер моң яңгырап узгандай булды. Ул, сулга борылып карады — стенадагы гади генә рамнан йөрәккә килеп тоташа икән ул моң. Таныш төсләр, таныш зәңгәрсу-алсу рәшә, шул рәшәне бер ноктада гына яктыртып үткән иртәнге кояш нуры... Тик монда, чәчәккә күмелгән азалия куаклары урынына — төз наратлар, Сафия әле генә күреп узган куәтле наратлар, ә эскәмиядә уйланып утырган кыз торып киткән, эскәмия дә алынган, кояш нуры биегәеп торган ак обелискны яктырта...

Әле шушы юлны узганда гына да мондый һәйкәлләр шактый күзгә чалынып узды — сугыш булган җирләрдә күп шул алар... Бу һәйкәл әйтерсең лә шушы күкрәп утырган табигать фонында, дәртле, куанычлы, тантана белән сибелгән кояш нуры яктысында, үткәннәрнең, безгә кадәр яшәгәннәрнең һәм шушы яшәеш тантанасы өчен үзен корбан иткәннәрнең бер кисәтүе, васыяте, йөрәк авазы иде. Сафия портретындагы кебек үк төсләр, шул ук рәшә, шул ук нур, ләкин тавыш икенче, көч бөтенләй башка. Һәйкәлнең нигезе дә, очы да рәшә белән тоташкан, ул, әйтерсең, әкрен генә җирдән күккә күтәрелә, җирне болытлар белән тоташтыра иде. Кайсы ягы беләндер ул яшел калкулыкта күк гөмбәзенә таба омтылып утырган Болгар манарасын хәтерләтте. Ничек дигән иде әле Нигъмәтҗан аның янында? Әйе, алар һәлак булганнар, алар, золымга каршы чыкканда, үз-үзләрен аямаганнар... Әгәр дә алар үз гомерләрен саклау хакында уйласалар, золым каршында баш июне үлемнән яхшырак дип санасалар, ул чакта җир мондый булмас иде... Ул чакта җирдә менә без дә булмас идек инде...

Сафия, борылып, кашларын җыерып торган Игнатка карады. Әйе, бу кеше Сафиягә элек уйлаганнан да якынрак, аларның уртаклыгы ул белгәннән зуррак икән...

Алар кире ишегалдына чыкканда, ябык ишек артыннан нечкә тавыш тагын нидер әйтеп зарланып калды.

— Мин монда, мамо... Син борчылма, мин беркая да китмим...

Бакча эчендә үрмәле гөлләр белән уратылган өстәл-эскәмияләр бар икән, шунда чыгып, кара-каршы утырдылар да бер-берсенең күзләренә туры карадылар.

— Монда килербез дип уйламаган идем,— диде Игнат.— Сый да әзерләмәгәнмен.

— Монда сый-хөрмәт җитәрлек,— диде Сафия җирдә чәчелеп яткан җимешләргә ишарәләп.

Игнат тиз генә чәй кайнатып алып чыкты, помидор турады. Ә үзе кичкә таба кузгалган черкигә, помидорның тәме юклыкка сукранды. Аның болай чын картларча үзалдына мыжлап йөрү гадәте дә Сафиягә таныш түгел иде.

— Игнат, черки кузгалмаса, помидорның тәмлесе эләксә, син бу минутта нәрсәгә сукраныр идең икән?

Игнат көлеп җибәрде:

— Табылыр иде әле.

— Игнат, авылың төшемнән матуррак, бакчаң — оҗмахтан ямьлерәк. Оҗмахта кеше бәхетле булырга тиеш бит инде. Син...— Сафия, әйтергәме-юкмы дигәндәй, икеләнеп торды.— Син... һаман шушылай яшәрсең микәнни?

Игнат аны аңлады.

— Якын киләчәктә тормышымда тамырдан үзгәреш күренми әле,—

диде.— Беләсеңме, Сафия, мине бик авыр сайлау алдына куйдылар. «Я әниең, я мин»,— диделәр. «Мин» дигәне хатыным белән кызым иде.

Ул тынып калды.

— Ә син... сайларга мәҗбүр булдыңмы?

— Юк, мин сайлый алмадым. Ничек сайлыйсың? Мин фәкать әнине ташлап чыгып китә генә алмадым. Ничек? Сугыш аны тәмам аяктан еккан чакта, ничек ташлап китәсең?

— Сугыш?

— Әйе, сугыш. Аның элек кичергәннәре менә хәзер килеп чыкты. Быел инфаркт булды, әллә каян шикәр чире килеп бәйләнде. Ялгызын калдырып булмый. Бу дөньяда ир белән хатын арасындагы мәхәббәттән өстенрәк нәрсәләр дә бар.

— Ә бәлки, хатының хәзер бөтенесен аңлагандыр, үкенәдер?

— Үкенүдән эш узды инде хәзер. Ул күптәннән кияүдә.

— Бәхетлеме?

— Ничек дип әйтим... Аның ире начар кеше түгел. Аек чакларында. Тик менә аек чагы гына сирәк була. Кайчакларда кызымның әнисе мине үзләренә чакыра, ярдәм ит ди, ире кыйный башласа, аерып ал, ди. Алар моннан ерак түгел.

— Син барасыңмы?

— Мин врач, ярдәм сораган кеше янына барырга тиешмен. Барам. Ирен үгетлим, эчмә, дим, ипле яшәгез, дим.

Сафия тамагына төелгән әче төенне кайнар чәй белән йотарга тырышты. Зәңгәрсу эңгергә төренә башлаган бакчага, наратларның очын алсулыкка манган шәфәкъ нурларына карады. Дөнья шундый тыныч, шундый иркен, табигать кешеләргә мул итеп җимешләрен бирә, арган тәннәре ял итсен дип, кичке җиләслекне җибәрә, күңелләре хушлансын дип, гөлләрнең, агачларның хуш исен бөрки, өметләре сүнмәсен дип, йолдызларны балкыта. Нәрсә җитми безгә бәхетле булырга, ник бер-беребезне газаплыйбыз шулай?

Табигать көйсез диючеләр бар, дөнья җайсыз диючеләр бар. Ләкин бу дөньяның, бу табигатьнең безне беркайчан да алдамый, хыянәт итми торган ныклы, ышанычлы тәртипләре бар бит. Иң караңгы, шомлы төннәрдән соң да, яктырып, кояш чыга. Иң каты салкыннардан, иң ачы җилләрдән соң да, балкып, язлар килә. Без үз вакытында кояш чыгасына, йолдызлар кабынасына, чәчәкләрнең керфекләре ачыласына беркайчан да шикләнмибез. Ә безнең үзебездә бармы соң шундый ныклы ышаныч, тайпылышсыз законнар? Бер-беребезне өзелеп сөйгәндә, мәңге тугрылыклы булырга антлар биргәндә, тайпылышсыз булырга кирәклекне ахырынача аңлыйбызмы һәм сөюебезгә, вәгъдәләребезгә тугрылыклы булып кала алабызмы?

Бар бит ул кешеләрдә дә андый ныклык һәм тайпылышсыз ышаныч, бар. Тик сирәк очрый торгандыр ул, бәлки? Оҗмах кебек дөньяда бер-берсен бәхетсез иткән кешеләр бу йортта гынамыни?

— Әйт әле, Игнат, син ни өчен бер генә тапкыр да миңа үзеңнең тормыш хәлләреңне язмадың?

— Зарланудан ни файда?

— Мин зарланып яза идем бит әле.

— Ул зарларың үтә торган көйсезлектән генә бит, Сафия. Синең өчен бер эч бушату гына. Ә минем... Хатлар язып, эч бушатканнан гына үтә торган ваем түгел. Язсам, фәкать бер генә сүз яза ала идем сиңа: кил. Бөтенесен ташла да кил яныма! Шулай гына яза ала идем сиңа.

— Ә ник соң язмадың?

— Гөлне туфрагыннан аерырга ярамаганын беләм, шуңа язмадым.

Эскәмияне ураган яфраклар аша, куе, кара чыршы төбендәге эңгерләргә уралып, әйтерсең лә Нигъмәтҗан шәүләсе килеп басты. Шушы укфикерне, тик бүтәнчә сүзләр белән, дөньяның башка бер почмагында, төсмерләре бөтенләй башка, әмма үзенчә гүзәл бер төштә Сафиягә ул әйткән иде түгелме?

— Игнат, мин нәзеремне үтәргә тиеш, сиңа роль уйнап күрсәтергә тиеш. Димәк, болай: ул хатынның халкы җиңелгән, иле таланган, ире әсирлеккә төшкән... Ул үзе залим патша янына килә...

— Әйе, хәзер исемә төште инде, язган идең. Хатларың миндә бөтенесе бергә саклана, теләсәң, алып чыгып күрсәтәм...

— Кирәкми... Алар синеке инде... Кадимбикә патшага әйтә: ирем синең зинданыңда сыкранып ята, мин аның сызлануын тоеп торам, ди...

— Шул кадими заманда гына булгандыр да инде андый хатыннар.

— Ул әйтә: мин патшалардан, синнән баерак, чөнки сызлануларымны уртак кичерә торган кешем бар, ди. Ә синең гамеңне берәү дә йөрәге белән тоймый, ди.

— Чыннан да, ялгызлыкны бернинди алтыннар белән дә бетереп булмый шул...

— Ә беләсеңме, миңа берәү болай диде: әгәр дә Кадимбикә кебекләр булмаса, җирдә яшәеш калмас иде. Андыйлар хәзер дә күп, тик без аларның шундый икәнен белмибез, алар гадәти тормыш белән яшиләр. Әгәр берәр төрле сынау килсә, алар үзләренең ныклыгын, фидакарьлеген күрсәтәчәкләр...

— Мәхәббәтләренең көчен димәкче инде син?

— Юк, монда мәхәббәттә, сөюдә генә түгел хикмәт. Кадимбикә, ирен яратам дип, бер тапкыр да әйтми. Аннары шунысы: патша аны үзенә хатынлыкка алмакчы, патшабикә итмәкче була бит. Ә Кадимбикә аның тәкъдименнән баш тарта. Кодрәтле, көчле, акыллы, чибәр һәм мәһабәт патшадан имгәнгән әсирне артыграк күреп ярату өчен, ул минутта Кадимбикә йөрәгенең аерым бер сыйфатлары таләп ителгәндер. Ул сыйфатлар тугрылык, вөҗдан сафлыгы дип аталадыр, мөгаен.

Сафия, урыныннан торып, әңгер-меңгердә караеп, зураеп һәм, әйтерсең лә, сагаеп торган чыршы янынарак килде.

— Бер әсирне үзеннән өстен күргәнгә патша бик гарьләнә, билгеле, ул Кадимбикәне дә, ирен дә үтерергә әмер бирмәкче була. Аңа каршы Кадимбикә болай ди:

К а д и м б и к ә. Мин сине кызганам, Хаким!

Х а к и м. Син үзеңне кызган! Хәзер башыңны кисәчәкләр. Синең дә, иреңнең дә!

К а д и м б и к ә. Мин сине кызганам, чөнки күңелеңне курку баскан. Котың очып куркасың!

Х а к и м. Минме? Минме? Мин бу җирдә иң кодрәтле хаким!

К а д и м б и к ә. Куркасың. Миннән куркасың! Иремнән котың оча!

Х а к и м. Җитәр, ахмак хатын!

К а д и м б и к ә. Курыкмасаң, безне үтермәс идең. Патшалар үзләре өчен куркыныч кешеләрне генә үтерәләр, шулай бит? Бераз гомерләр узганнан соң очрашсак, үзеңнең җиңелгәнеңне күрер идең, минем хаклы булганымны аңлар идең. Синең үз сүзеңне аста калдырасың килми. Шуңа безне үтерәсең.

Х а к и м. Юк, ялгышасың. Ялгышасың! Мин синнән дә, киләчәктән дә курыкмыйм.

К а д и м б и к ә. Син моны миңа берничек тә исбат итә алмыйсың. Безне һәлак итеп, курыкканыңны гына раслыйсың.

Х а к и м. Юк, мин киресен дә раслый алам. Раслыйм! Әй, кем бар анда! Керегез әле бире! Бу хатынны далага чыгарып ташлагыз. Ире белән бергә. Миңа, чын Хаким булыр өчен, коллар кирәк. Буш җирдә мин Хаким була алмыйм. Коллар булып көн итсеннәр, минем хакимлегемне раслап гомер кичерсеннәр. Чыгарып җибәрегез аларны!

К а д и м б и к ә. Безнең бәхәсне киләчәк хәл кылыр, Хаким.

Урам яктан автобус тавышы ишетелде. Ике персонажның да сүзләрен саф татарча сөйләп торган Сафия дә, аның каршында тын калып басып торган Игнат та кинәт айнып киткәндәй булдылар.

— Бу — соңгы автобусмы? — дип сорады Сафия.

— Соңгысы...— Моны Игнат теләр-теләмәс кенә әйтте.

— Ничә минуттан китә ул?

— Тагын бер тукталыш кына бара да борылып килә... Инде монда кадәр килеп җиткәч... Тагын бер генә сәгать торудан берни дә үзгәрмәс

ич...— Игнатның тавышында Сафия беренче тапкыр ялвару ишетте.
— Миңа самолетка соңга калырга һич ярамый. Анда мине берәү көтә.
— Һәм син аның йөрәге сыкранганын даими тоеп торасың,— дип, башын иеп, чак ишетелерлек итеп әйтте Игнат.— Аның йөрәк хисләрен мең чакрымнан сизәсең.
Сүз кинәт өзелде, хушлашу ничектер ашык-пошык килеп чыкты. Икесе дә мәңгелеккә аерылышканнарын, күп сүзләрнең әйтелми калганын, әйтелгәннәренең дә күңелләргә сагыш кына өстәячәген аңлыйлар иде. Әйтерсең лә алар үзләре генә түгел, сүзләре, уйлары да аерыла, әйтерсең лә әйтәсе килгәннәр тылсымлы канат яра да, төркем-төркем очкан кечке кошларга ияреп, каядыр кояш баешына китеп югала иде. Киләчәге юк иде сүзләрнең, шунлыктан алар икесе дә тын калганнар иде.
Вакытның агышы үзгәрде, аңлашылмас булды. Сүзсез тын калып, юл кырында көтеп тору озакка сузылды сыман, шул ук вакытта секундлар йөрәккә бәреп, чигәләргә сугып, гадәттән тыш тизлек белән узалар кебек иде.
Юк, алар кайбер киноларда күрсәтелгәнчә, бер-берсенең күзләренә өздереп карап, кулларын кысышып, озаклап хушлаша алмадылар. Вакытның шушылай ике яссылыкта, бик озак та һәм бик кызу да узуы зиһенне таратып җибәргән иде. Автобус кинәт килгәндәй тоелды, аның ишеге һич көтелмәгәндә ачылды. Сафия, Игнатның да үзенә ияреп, әчкә атлавын күргәч, аны учы белән кире этәрде:
— Әниең соң... Әниең... Ул сине югалтыр бит.
— Электричкага кадәр генә...
— Ярамый... Минем монда килүем башка берәүгә борчу китермәсен.
Шунда кинәт караңгы тынлыкны ярып, кайдадыр ике тавышка кызлар җырлап җибәрде.

Әй матур, матур мин, яр сайлыйм үземә...

Автобус ишеге аларның сузылган кулларын аерды. Мотор шавына кушылып, Сафиянең күңелендә таныш җыр дәвам итте:

Егетләр өздереп карый, егетләр тилмереп карый,
Өзелеп карыйлар баскан эзләремә...

Җиңел җырлана торган, шаян җыр... Ләкин нигә соң ул Сафия күңелендә шул хәтле моңлы, шул хәтле сагышлы булып, бәгырьне өзеп яңгырады икән?

## 42

Очрашуның бөтен шартын туры китерергә уйлаган иде Сафия. Нигъмәтҗанга күренми генә килергә, түгәрәк капканың сул ягына басарга һәм шыпырт кына:
— Мин килдем...— дип дәшәргә.
Әнә бит, Нигъмәтҗан да, шулай бөтен шарты туры килсен диптер, бәлки, уң баганага иңбашы белән сөялеп, юлга аркасы белән борылган да бакча эченә карап тора. Белмәгән кеше, ашыгыч эше юк ахры бу егетнең, барган җиреннән тукталып уйга калган дип уйлар, мөгаен. Кая барырга белми торгандыр ул: өч юлның кайсын сайлыйм икән дип уйлыйдыр: уңга борылыргамы, сулга юнәлергәме? Атны җуяргамы, башны җуяргамы? Ияген чөя төшеп, тын калып, шуны хәл итә кебек иде ул.
Ләкин юк, алай түгел, урамдагы машиналар шавы, үткән-сүткән халыкның аяк тавышлары аша Сафиянең сак адымын әллә кайдан ишетеп торган икән, ул якынаюга, кисәк борылды, аның капка янына килеп җиткәнен, багана уемына сүз әйткәнен көтеп тормады. Сафия аның каршына барып басты, үрелеп, күзләренә туры карап:

— Мин кайтып җиттем,— диде.
— Әйдә, алайса, киттек.
— Кая... киттек? — Нигъмәтҗанның катгый тавышы Сафияне сагайтып җибәрде.
— Абыеңнарга. Мин сине сорарга тиештер бит инде. Әтиең урынына калган кешедән сорарга.
— Алдан әйтеп куярга иде! Өйдә туры килмәсләр, я җайсыз вакытларында барып керербез.
— Әйдә, язмышны сынап карыйбыз. Өйдә булсалар, әйбәт каршы алсалар, язмыш икебезгә уртак елмая дигән сүз булыр. Килештекме?
Сынар өчен генә диярлек ризалашты моңа Сафия. Соңгы ике көн эчендә кичергән тойгылар әле һаман күңелдә кайный, шунлыктан ул Нигъмәтҗан әйткән сүзләрнең җитдилеген, зурлыгын аңлап, бәяләп тә җиткерә алмады. Юлда фәкать: «Өйдәләрме икән? Ничегрәк каршы алырлар икән?» — дип кенә уйлады, ә нилләр сөйләшәсен күз алдына китермәде.
Абыйсы Гамир белән җиңгәсе өйдә иделәр. Алай гына да түгел, Гамир галстук таккан, костюм кигән, өйгә бәлеш исе таралган иде, Сафия белән Нигъмәтҗан бусагадан атлауга, каршыларына кухня яктан бит очлары алланган, балкып елмайган Заһидә килеп чыкты:
— Әйдүк-әйдүк, хуш киләсез! Баядан бирле көтәбез инде!
Ничек инде ул «көтәбез»? Сафия аптырап китте. Каян белгән әле абыйсы белән җиңгәсе бүген аларның киләсен?
Ул минутта Сафия бу хикмәтнең серенә төшенеп бетә алмады, соңыннан гына белде: ул югында Нигъмәтҗан инде монда бер килеп сөйләшеп утырган һәм абый белән җиңгәгә бик тә ошап калган икән.
Табын янында Гамир, чишелеп китеп, гармунын алды. Сафиягә моңлы гына карап, җырлап җибәрде:

Үрмәле гөлләр үрмәли сәгать чылбырларына,
Сенлем, сине охшатамын сахра былбылларына.

Сафия аның гармун күрәгенә наз белән иелгән йөзенә, маңгай өстендә бераз сирәгәйгән, тузгыган, әле чал әсәре кермәгән кара чәчләренә, бераз гына киңәйгән, кызарынып киткән йөзенә текәлеп карап утырды. Әйе, хәзер дә чибәр, хәзер дә сөйкемле әле аның абыйсы, яшь чакларында кызларның өзелеп сөюе бер дә гаҗәп түгел. Ләкин аның күңелне иң җәлеп итә торган ягы — моң, җыр. Әнә ничек итеп, әкрен бәрхет тавыш белән, үзәкләрне айкап, көйнең һәр борылышына иркенләп кереп җырлый бит ул.
Менә ул гармунын үзенә якынрак тартты, кочаклап, күкрәгенә кысты һәм иң йөрәк түрендәге серне әйткәндәй:
— Рәхмәт сиңа, сеңел, шушындый көнне безгә килүеңә, безне зурлавыңа рәхмәт,— диде.— Әйбәт үстең, матур яшәдең, җиңгәң белән безнең күзгә чүп төшермәдең. Шуның өчен мең рәхмәт сиңа. Алып килгән кешең дә болай карап торуга ошамаслык түгел. Бер-берегезнең хәленә кереп яшәгез, миннән сезгә иң зур теләк шул.
Гади генә бу сүзләр Сафиянең йөрәген кузгатып җибәрде. Абыйсы аңа рәхмәт әйтә... Абыйсы, тәрбияләп үстергән, Сафия хакына яшьлек мәхәббәтеннән ваз кичкән абыйсы! Сафия рәхмәт әйтәсе урында!
Сафия нидер әйтергә теләде, ләкин тавышы чыкмады. Ул урыныннан кузгалды да, ашыгып, кухняга чыкты, кран астында йөзен чылатты, алай да тынычлана алмыйча, артсыз урындыкка утырып, майлы клеенкага, өстәлгә капланды. Үксегәнен ишеттермәскә тырышып, тавышсыз гына елады ул.
Күпме вакыт узгандыр, бүлмәдә тагын гармун уйнап җибәрде, Сафия кухня ишеге ачылганын, кемнеңдер кергәнен ишетте. Йомшак кул сак кына аның иңбашына килеп ятты. Сафия башын күтәреп карады — янында җиңгәсе Заһидә басып тора иде.

Ул тын гына өстәлнең икенче башына узды, савыт-сабаны җыйды, клеенканы сөртеп алды. Аннары зәңгәр бөрчекле ак күлмәген төзәткәләп, алъяпкычын салды, бөдрәләнеп торган аксыл-сары, карап торуга ук йомшак чәчен учы белән сыйпап куйды. Яшьрәк чакта Заһидәнең чәче сарырак иде, хәзер аксыл-сары төскә кереп бара. Ләкин чаларганы сизелми, әйтерсең кояштан гына бераз уңа. Сафия, беренче тапкыр бугай, җиңгәсенә текәлеп, сынап карады. Яшьрәк чакта ул бик гадәти, күзгә ташланмый торган, гади булып күренә иде. Чибәр түгел иде ул. Ләкин нәкъ менә шушындый күзгә ташланмый торган, тыйнак басынкы кызлардан мөлаем хатыннар чыга, олыгайган саен, алар сөйкемлерәк була баралар.

Заһидә каенсеңлесенә тутырып карады да, моңсу гына елмайды. Аннары клеенка шакмакларына текәлеп:

— Кияүгә чыгар алдыннан мин дә бик елаган идем,— диде.

Сафия аларның өйләнешү тарихын кешеләрдән ишетеп белә, ләкин бу хакта абыйсыннан да, җиңгәсеннән дә аны-моны ишеткәне юк иде. Заһидәне Гамиргә димләп биргәннәр, холкы йомшак, каенсеңлесен җәберләмәс, дигәннәр. Ә бит Гамирнең сөйгәне башка булган... Гади генә, җиңел генә узмагандыр туй хәлләре.

Заһидә бүлмәгә кереп, аннан кулына бер кечерәк кенә калын дәфтәр алып чыкты.

— Әни кеше кызына мондый көнне бик кирәкле, бик изге сүзләр әйтергә тиештер инде,— диде Заһидә дәфтәрнең тышын кулы белән сыпыргалап.— Мин сиңа бәхет теләүдән башка сүз әйтә алмыйм. Менә миндә бер аманәт бар. Әниеңнең дәфтәре.

Сафиянең йөрәге сулкылдап куйды. Ул әнисенең дәфтәре барлыгын белми иде.

— Мин аны моңарчы яшеребрәк сакладым,— диде Заһидә.— Бик кадерле әйбер бит... Шушындыйрак бер көнне әниеңнең истәлеге итеп сиңа тапшырырмын дип саклаган идем. Теге чакта барактагы бүлмәбез янып киткәндә, чак коткарып калдым аны...

Ә Сафия ул уттан ике мендәр белән юрган гына чыкты дип белә иде. Алай гына түгел икән: җиңгәсе аңа әнисенең изге истәлеген саклап калу турында да уйлаган икән. Ут эчендә дә онытмаган икән ул моны...

...Төнлә, түгәрәк лампа яктысында бер ялгызы калганнан соң, Сафия дәфтәрнең эсседән көйгән калын, каты тышын ачты. Анда, шәмәхә карандаш белән, һәр хәрефе җиренә җиткереп, йомры, түгәрәк итеп язылган сүзләрдән гүяки әнисенең тавышы ишетелде.

Дәфтәргә җырлар, бәетләр теркәлгән иде. «Сагыну», «Рәйхан», «Су буйлап»... Сугыш вакытында һәм сугыштан соң киң таралган моңлы җырлар... Ахырга таба аеруча сагышлылары...

> Китсәң, мине дә алып кит,
> Я булмаса салкын дәрья суларына салып кит...

Аннары һич көтмәгәндә генә «Янмый калган кыз кыйссасы»... «Тимерләң патша Болгар шәһәренә һөҗүм белән килеп, аны яулап ала, каланы җимерә. Болгар ханы үзенең гаиләсе белән таш пулатка кереп бикләнә. Дошманнар пулатны ут төртеп яндыралар, анын эчендәге бөтен кеше һәлак була, фәкать ханның акыллы, гадел һәм чибәр кызы гына исән кала. Килеп керсәләр,— ул ак тула өстендә утырып тора икән...»

Бары шул гына, аннары тагын җыр язылган:

> Агыйделне иңләп-буйлап йөзәрсең әле, үрдәк,
> Хәсрәт кургәннәрең бардыр, түзәрсең әле, йөрәк...

Нигә уйлап күчереп язды икән бу кыйссаны Сафиянең әнисе? Нигә үзеннән берничә генә сүз булса да өстәп куймады икән?

Өстәмәгән, уйларын язмаган, уйланырга, төшенергә кызына калдырган иде ана.

Телеграмма бик кыска иде: «Премьера 15 нче сентябрьгә билгеләнде нкт София». Ләкин Рәмзи аны һич укып бетерә алмагандай, бик озак карап торды. Шулкадәр онытылып, йотылып басып торды, әйтерсең, шушы гади сүзләр астына катлаулы шифр белән яшерелгән тирән мәгънәне аңларга тырышты. Сул кулбашын нидер баса, эсселәтә, фикерне тупларга комачаулый иде, ул бу авыр нәрсәдән котылырга теләп, уңгарак авышты. Шул хәрәкәт белән ул Эльвирадан читләшкәнен үзе тоймады. Бу минутта аның өчен Эльвира да, якында гына ак күбекле дулкыннарын чаптырып шаулаган диңгез дә, яр буена тезелеп баскан кипарислар да юк иде, бу минутта Бикбау утлар яктысында балкыган сәхнәне күз алдына китерде. «Премьерага кадәр бер ныклап эшләп аласы бар бит әле,— дип уйлады.— Сәхнәнең үзендә эшлисе. Берәр атна вакыт кирәк булачак».

Диңгез буенда ике атна бергә ял иткән чор эчендә иркәлеккә өйрәнгән Эльвираның ирене турсайган иде, Рәмзи моны сизмәде. Әйтерсең, араларына диңгез дулкыны бәреп, аларны бер-берсеннән ерагайта башлаган иде.

— Нәрсәгә исең китте шул кадәр! — диде Эльвира. Һәм телеграмманы егет кулыннан йолкып алды да, туп-туры аның күзләренә караган килеш, башта икегә, аннары дүрткә бөкләде, әкрен хәрәкәт белән ерткалады, тәмам теткәләп, ваклап бетерде. Аннары читкәрәк китеп, зәңгәрсу кәгазь вагын зур чүп савытына салды, җирәнгәндәй итеп, сөякчел кулларын каккалап, сыпыргалап куйды.

Егет аны беренче тапкыр күргәндәй текәлеп күзәтеп торды. Моңа кадәр әле берәүнең дә Рәмзи кулындагы әйберне болай сансыз тартып алганы һәм юкка чыгарганы юк иде. Кай арада бу арык кыз аның өстеннән власть алды соң әле? Монда килгәннән бирле Эльвираның бер генә теләге дә үтәлми калганы юк бит, шуңа күнегеп өлгергән, димәк!

Менә ул кире әйләнеп килде, Рәмзи каршына басып, текәлеп карады, егетнең йөзе-карашы үзгәргәнен күрде. Эшне зурга җибәрмәү чарасын эзли башлады.

— Анда әллә нинди премьера булса да, безгә кагылмый инде хәзер, әйе бит,— диде. Ике куллап Рәмзинең сул беләген тотып алып сыйпаштыргалады.

— Ләкин сүз минем премьера хакында бара,— диде ул салкын гына.

— Нишләп синеке булсын?

Эльвира бер генә минутка югалып торды. Шундук хәйләсен тапты:

— Монда сүз вообще премьера хакында бармый, минемчә,— диде.— Бикташева эшемени ул режиссерны кайгырту? Каян килгән начальник! Котырткannar аны, мөгаен. Теге карчыгың котыртып язгандыр әле. Я үзе үк почтага барып салган София исеменнән! Мөгаен, шулай! Нинди генә хәйләләр тапмый, ә! То бала табарга әзерләнә янәсе, то премьерага чакыра. Бала! — Эльвира борын аша мышкылдап куйды.— Егерме ел буе бала тапмаган да, ире ташлап киткәч кенә, бүртә башлаган имеш. Көлке бит бу, адәм көлкесе! Син шуңа ышанасыңмы?

Рәмзи дәшмәде, кызның тыкылдавы аңа еракtan килеп ирешкән кебек кенә иде. Шулай ук бөтенләй тәэсир дә итми калмады, әлбәттә. Чыннан да, бәлки, Шәфика ялганлыйдыр, бу телеграмманы да ул биргәндер?

Рәмзи хатынын күз алдына китерде дә көлемсерәде. Кая инде ул беркатлы бичарага хәйләли белү! Аннары телеграммасы да аның кулы белән язылганга охшамаган. Шәфика булса, «режиссер көтә»,— дипме, я булмаса, «кайтып җит»,— дипме, берәр артык сүз кыстырмый калмас иде. Болай кыска итеп фәкать София гына яза ала. Шәфика бу хакта белми дә калгандыр. Ләкин хикмәт анда түгел. Хикмәт шунда: Рәмзи премьераны үзе үткәрергә тиеш, әгәр шулай эшләмәсә, иманына хыянәт

иткән булачак. Шушы спектакль белән халыкка житкерергә тырышкан идеалларны үзе үк аяк астына салып таптаячак.

Ә Эльвира һаман сөйләнә иде әле. Менә ул туктап калды, кечкенә сумкасыннан калын гына кесә дәфтәре тартып чыгарды да, аны пляж кырыендагы тәбәнәк таш стенага салып актарырга кереште. Дәфтәр битләренә төрле театрларның адреслары һәм баш режиссерларның исем-фамилияләре теркәлгән иде. Кайсы театрга урнашу әйбәтрәк, кайсы шәһәрдә яшәү җиңелрәк. Ләкин Рәмзи аны тыңламады, ак күбеккә баткан дулкыннарга карап торды да, кызны ярты сүздә бүлеп:

— Мин киттем,— диде.

— Кая?

— Билет кассасына. Казанга билетлар күптән сатылып беткән диләр диюен, ләкин бик тырышып эзләсәң, берне генә табып булыр әле.

...Аның кайтып төшүе һич кенә дә Шәфика күз алдына китергәнчә булмады. Алар трамвай тукталышында очраштылар. Дөресрәге, Рәмзи аны трамвай тәрәзәсеннән күреп алды. Шәфика, кулына озын сабаклы эре гладиолуслар бәйләме тотып, тукталышта басып тора иде. Нык үзгәргән үзе, тәмам тулышкан гәүдәсенә килешле, түштән бөрмәле ачык көрәнсу йон күлмәк кигән, аягында тәбәнәк үкчәле ак туфлиләр. Аның кыяфәте дә, күлмәге дә Рәмзи өчен яңа иде, шул ук вакытта узып барган трамвай тәрәзәсеннән башын сузган ирен күрми үткәреп җибәрүе һәм җилдә тузгыган алтынсу бөдрәләре җанга газиз иде.

Рәмзи алгы ишектән сикереп төште дә, йөгереп барып, арткы ишек янына баскан хатынын терсәгеннән тотып алды:

— Ә Сез, ханым, кая барасыз?

Шәфика башта аны танымады да кебек, йөзендә фәкать гаҗәпләнү генә чагылды. Трамвай зырлап китеп баргач, бушап калган урам уртасында алар бераз вакыт берни дәшми, бер-берсенә карап басып тордылар. Хатынына караган саен, Рәмзи күңеленең тынычлана, җылына барганын тойды, ул гүяки озак вакытлар чит җирләрдә йөргәннән соң, туган йорт бусагасын атлап кергән иде.

— Кая җыендың болай мутланып? — дип сорады ул.

— Исмегөл белән Тәүфикъның туе бүген.

— Мине чакырмадылармыни?

— Син юк идең бит,— диде Шәфика балаларча беркатлы итеп.

— Бик тиз югалткансыз икән мине. Ә мин исән әле, яшим. Әйдә!

— Кая?

— Өйгә керик, өсне алмаштырыйм. Югыйсә бу кыяфәттә туйга барсам, аптырарлар, хатыны бистә бикәсе, ире киндер көлтәсе икән боларның, диярләр.

Урам аркылы чыкканда, ул хатынын узгынчы машиналардан саклап, биленнән кочып алды. Шәфиканың аннан нык тәбәнәк икәнлеге сизелде. «Кара, син бик кечкенә икәнсең бит!» Бу сүзләр аның уенда гына чагылып узды, әмма Шәфика аларны аңлады бугай, иренә ныграк сыенды. Рәмзинең учына йомшак кына итеп нидер бәреп-бәреп куйды. Бу — ана карынында тыпырчынган баланың үзе хакында хәбәр бирүе иде.

Өйгә кергәч, Рәмзи ваннадан юынып чыкканда, Шәфика диван аркасына капланып елый иде. Рәмзи аның янына утырды да, йөзен үзенә таба борып, күкрәгенә кысты.

— Син бер дә борчылма,— диде.— Бергә чакта безнең икебезгә дә һичнәрсә куркыныч түгел, шулай бит? — диде. Аннары аз гына тынып торды да: — Өчебезгә дә,— дип сүзен төзәтеп куйды.

Ул хатыны үз хәлен авыр кабул итәдер, киләчәге өчен борчыладыр дип уйлады.

Шәфика үзе исә нидән елаганын да белми, фәкать аның йөрәк түрендә күптәннән оешкан, кайчан да булса таралырына өмет тә сүнгән зур бер төен чишелә башлап, күзләрдән кайнар һәм татлы яшь бөртекләре булып коела иде.

## 44

Исмегөл белән Тәүфикъның туе бик мул чакка туры килде. Сафия базардан гладиолусларның иң эреләрен, иң җетеләрен сайлап алган иде. Бусагадан атлауга, җитез апаларның берсе аның кулындагы чәчәкләрне алды да зур пычак белән озын сабакларын чыжт итеп кисеп ташлады һәм кулында калган өлешен өч литрлы банкага илтеп тыкты.

Өстәлләрдә аннан башка да чәчәкләр күп иде шул. Өч литрлы банкага кереп, читтәге шкаф өстенә менеп утыргач, Сафиянең гладиолуслары башка чәчәкләр янында кечерәеп, мескенләнеп калдылар, шаулап торган күңелле мәҗлестә бердәнбер ямансу, моңлы рәвешкә керделәр...

Матурлыкны менә шулай минут эчендә кимсетеп, кадерен җибәреп була. Ак, кызыл гладиолусларның бичара хәле Сафиянең хәтеренә әледән-әле килеп торды.

Нигъмәтҗан белән туй көнен билгели башлагач та ул:

— Туем чәчәкләрнең кадерле чагында булсын иде,— диде.— Кыйбат булсыннар, һәркайсына игътибар бирелсен иде.

Моның сәбәбен ныклап сорашкач, Нигъмәтҗан:

— Ә без һәр чәчәкне үз урынына куярбыз, моны үзем карап торырмын,— дип вәгъдә бирде.

Һәм шулай эшләде дә. Артистлар туй мәҗлесенә соңлап кына, спектакльдән соң шаулап килеп керделәр. Чәчәкләр бәйләм-бәйләм генә түгел, кәрзин-кәрзин иде. Һәр кунакка лаеклы урын табылган кебек, кашкарыйлар, гладиолуслар, розалар да игътибарсыз калмады.

Чәчәкләр күп иде, мәҗлеснең вакыты аз булды. Бер-ике сәгать утырып, җырлап-биеп алгач, театрда уйналган спектакль күренешләре, борынгы йолалар хакында сүз китте, кияү өенең тулай торакта әзерләнгәнен белгәч, барысында да дәрт кузгалды:

— Әйдәгез, барып карыйк әле!

— Кем әзерли?

— Рәтен beləләрме икән?

— Ә кем рәтен белә кияү келәте әзерләүнең? — дип сорады Зыятдин. Бөтенесе тынып калдылар. Арада туй үткәргән кешеләр күп, ә менә кияү өенең дә, кияү кабул итүнең дә рәтен белгән кеше юк икән. Гаҗәп! Барысында да күз күрмәгән бу нәрсәне күреп калу теләге кабынды.

Заһидәнең ай-ваена карамыйча, дәррәү кузгалдылар, «Анда бер бәйрәм итәрбез»,— дип, өстәлдән тегене-моны алдылар да, урамга чыгып, машина ауларга керештеләр.

Сафия белән Нигъмәтҗан кайтып кергәндә, бүлмә чыннан да танымаслык булып үзгәргән иде. Карават өстенә чыбылдык ясаганнар, өстәлгә самавыр куйганнар, пәрдәләр алышынган, ишеккә яңа чаршау корылган, идәнгә палас җәелгән. Ә күпереп торган караватта, ак мендәрдә нәни генә озынча төргәк ята. Өстәл янында чынаякларны матурлап тезеп азапланган Мөкәррәмә, боларга борылды да:

— Бәй, кайттыгыз дамыни? — дип сорады. Кая соң, самавыр әзер түгел, ишек бавын тотарга күрше малаен чакырырмын дигән идем, уятып кертергә сөйләшкән идек...

Ул арада мендәрдә яткан төргәк кычкырып аваз салды,— ул Шәфиканың әле бер генә атна элек туган нәни кызы икән. Сафияләр шаулап кергәнгә исе китмәгән иде, сабые тавышын ишетүгә, күрше бүлмәдән Шәфика үзе атылып килеп керде:

— Анда бавырсак пешерергә дигән идек...

Аңа ияргән Илнурны күргәч, Мөкәррәмә:

— Менә-менә, нәкъ син генә кирәк идең,— дип кычкырып җибәрде.— Кил әле, улым, монда, чишен әле!

Һәм шарф очларын җилкәсенә ташлады да малайның аякларыннан ботинкаларын салдырырга кереште. Сафия белән Нигъмәтҗан моның хикмәтен аңлап өлгергәнче, Илнур инде чишендерелгән иде, Мөкәррәмә

аны шырык-шырык көлдерә-көлдерә караватта, ак җәймәләр өстендә тәгәрәтә иде.

— Син кирәк идең монда, син булмагач, үзебезнең сабыйны тәгәрәткән идек. Әйдә, мул булсын, ул да булсын, кыз да булсын, барысы да сәламәт-таза булсын, ата-ана канаты астында үссен...— дип тәкрарлады Мөкәррәмә. Ә Шәфика ислемай шешәсен ачып, мендәрләргә сөртә иде.

— Ә сез монда гына калыгыз,— диде Сафия белән Нигъмәтҗанга Мөкәррәмә.— Исегез китмәсен, элекке заманда кияү белән кәләш туй мәҗлесендә утырмаган.

Ишек шакыдылар.

— Кем йөри инде тагын! Ярамый, ярамый! — диде Мөкәррәмә ризасызланып. Бусы Револ икән. Ишектән башын сузып, гөрелдек тавыш белән:

— Ят малайлар адашып йөрмиме189 сездә? — дип сорады. Һәм, өлкәннәр ыгы-зыгысыннан файдаланып, өстәлдәге чәкчәкне бармагы белән каезлап азапланган Илнурга кул изәде:

— Әй, малай актыгы, нишлисең анда! Кил әле!

Малай йөгереп барды да, Револның муенына асылынып, аяклары белән биленнән кочып алды.

— Тайыйк моннан тизрәк! Боларның әле үз малайлары юк, сине үзләштереп куймасыннар тагын! — диде Револ.

— Муеныңа күптән бала асып куясы булган икән,— диде аңа Нигъмәтҗан.— Бу кызлар моңарчы ни карап йөргәндер. Наргизә кайда соң әле, күренми?

Бу сорауга Мөкәррәмә җавап бирде:

— Мондый җирдә бик урала алмый әле Наргизә,— диде киная белән.— Ризык исенә чыдамый торган чагы, ятыбрак тора.

— Ә-ә, имәндә икән чикләвек! — Нигъмәтҗан шап итеп Револның иңбашына сугып куйды.— Чыда, муен! Икәүләп асылыначаклар икән әле!

— Муеннан зарланырлык түгел, бишне күтәрерлек чамабыз бар,— диде Револ.

— Туйга чакырмадыгыз, ә!

— Туй гомердә бер генә була ул,— диде Револ.— Без шул бернең кадерен белми үткәреп җибәргән идек шул инде. Аннары авылда гына язылыштык бит, мәҗлесе дә тыйнак булды. Сез генә ул бөтен шартын китердегез. Бәхетегез уңмасын, гомерегезгә житсен! — дип өстәде ул чыгып киткәндә.

Баласын кочагына алып чыгып киткәндә, Шәфика бүлмәне күздән кичерде дә:

— Көнләшәм,— диде.— Белсәгез иде, мин сездән шул хәтле көнләшәм!

— Әллә миңа гашыйк булдыгызмы? — дип сорады Нигъмәтҗан шаярып.

— Мин сезнең шушылай матур итеп тормышыгызны башлап җибәрүегездән көнләшәм. Их, мин ике тапкыр башлап җибәрдем тормышымны, берсендә дә кешеләр көнләштерерлек итә алмадым! Сезгә бик матур сүзләр әйтәсе килә, аның мондый көндә әйтергә тиешле сүзләре дә бардыр инде, борынгы ата-бабалардан калган сүзләр... Без аларны белмибез шул. Әллә җырлап бирәсе инде...— Ул тамагын кыргалап куйды.— Ярар инде, тавышым теләгәнчә матур чыкмый. Бәби алып кайткач, тавыш нечкәрде бит әле минем, Сафия. Бөтенләй җегәрен югалтты. Сизәсеңме, бала-чага тавышы килә миннән. Әй икегез, икегез, икегезнең битегез...

— Яшәрдегез сез, Шәфика апа, шуңа ул.

— Тавыш яшәрү генә житми бит әле. Хәзер инде Әнвәрбәков миңа бөтенләй роль таба алмас...

Ул кулын селтәде дә:

— Теләк шул инде сезгә: чиста яшәгез, арагызга ямьсезлек, кер заты кермәсен...— диде.

Ул, күзләренә тулган яшьләрне тыярга тырышып, тизрәк чыгу ягына юнәлде. Коридорда аны ире Рәмзи көтеп тора иде.

...Иртәнге кояш нуры, ябылып җитмәгән пәрдә арасыннан кереп, һичкем күрергә тиеш булмаган күренешне күреп алды: Нигъмәтҗан Сафиянең күпереп торган кара бөдрәләрен сак кына сыйпап:

— Сафиякәй, саф җаным, саф намуслы язмышым,— дип пышылдый иде.— Тормышыбызны керсез башладык, керсез гомер итсәк иде...

## 45

Театрда премьера бара иде. Тәнәфес вакытында фойеда таныш-белеш, агай-эне Даян Ризвановны уратып алды.

— Гаҗәп әйбер язгансың син бу юлы,— дип, кулын бер-бер артлы кысалар иде аның.— Өр-яңа сүз бу! Заманнарны берләштерә торган, кирәкле әсәр.

— Күптән шушындый әсәр кирәк иде. Сискәндерә торган әйбер! Сафлык, тугрылык турында шушылай үтемле итеп халыкка, бигрәк тә яшьләргә әйтергә күптән вакыт.

Даян мыек астыннан кыенсынып елмая, кулын кыскан кешеләргә баш иеп рәхмәт әйтә:

— Рәхмәт инде яхшы сүзегезгә,— ди.— Тик мин үзем мондый әйбер язмаган идем. Пьесасы мондый түгел иде аның!

— Шулай бик нык үзгәрткәнмени соң Бикбау? Юк ла, булмас, драматургка өстәп язмый ул.

— Сүзләре шул инде аның... Тик мин болай ук булыр дип уйламаган идем...

Залда утлар сүнеп, халык икенче пәрдәне карарга кереп утырганда, ул һаман үзалдына сөйләнә иде әле:

— Мин яздым микәнни соң моны? Мин шундый әйбер яздым микәнни?

Сүзләр бар да таныш, барысы йөрәктән кайнап чыккан, ләкин сәхнәдән яңгыраш бөтәнчә — киңрәк, зуррак, масштаблырак иде. Һәм иң мөһиме — йөрәкләргә үтеп кереп тетрәндерә, озак хәтергә сеңеп кала торган иде.

Вакыт үткәне сизелмәде, ике пәрдә ике тын алуда үтте шикелле. Менә эпилог та башланды.

Беренче пәрдәдән соң егерме ел үткән. Ярлы чатыр эчендә казан янында Кадимбикә утыра. Яшь бер егет керә.

Е г е т. Әни, залим патшаның гаскәре тар-мар ителде. Хаким үзе кулга алынды. Хәзер безнең яннан алып китеп баралар. Син аны бер күреп сөйләшермен диган идең. Теләсәң, бирегә алып кererләр.

К а д и м б и к ә. Әйе, мин аны күреп сөйләшергә теләр идем. Бик теләр идем.

*(Хакимне алып керәләр. Ишек янында өч егет тезелеп басып кала.)*

К а д и м б и к ә. Хуш киләсең, Хаким. Сине дә үз чатырымда күрер көн килде менә. Заманында син мине үзеңә тиң күреп сөйләшкән идең. Бүген мин дә сиңа мөмкин булган сый-хөрмәтне күрсәтергә әзермен.

Х а к и м. Ләкин минем мондый чатырларда яшәүчеләр белән эш йөрткәнем булмады. Мин — зур дәүләтнең Хакиме! Мине үз тиңең итеп сөйләшергә кем хокук бирде сиңа? Кем син?

К а д и м б и к ә. Син мине үзеңнең затлы чатырыңда кабул иткән идең. *(Пауза.)* Мин — Кадимбикә, синнән үз ирен йолып алган хатын булам.

Х а к и м. Син — Кадимбикә? Иренең йөрәген зур хәзинәгә исәпләгән хатын — синмени ул? Иренең сызлануларын әллә каян тоеп торган хатынмы син?

К а д и м б и к ә. Әйе, мин.

Х а к и м. Картайгансың, йончыгансың, танымаслык булгансың.

К а д и м б и к ә. Гомер итүләре бик авыр булды шул. Синең әмерең белән

безне коры далага чыгарып ташладылар. Ләкин анда да тыныч кына яшәргә мөмкинлек булмады. Әледән-әле ялчыларың килеп, бар булдырган малыбызны, хезмәт белән, тир белән тапкан милкебезне талап алып бетерә тордылар. Безнең бар тапканыбыз, бар кул көчебез хәзинәләреңне арттыруга китеп барды.

Хаким. Ул хәзинәләр хәзер берсе дә минеке түгел инде. Баш күтәргән халык аларны миннән тартып алды.

Кадимбикә. Кайда соң гаскәрләрең, якыннарың, ярдәмчеләрең?

Хаким. Ярдәмчеләрем, якыннарым афәт килгән көндә мине ташлап качтылар, бердәнбер улым аумакай һәм куркак булып чыкты, дошманнарым ягына авышты.

Кадимбикә. Син бик фәкыйрь идең шул, бичара!

Хаким. Миндәй бай хаким дөньяда юк иде!

Кадимбикә. Ләкин син фәкыйрьләрнең дә фәкыйре идең. Берәү дә сиңа йөрәген бирмәгән, берәү дә күңел сызлауларыңны ерактан ук тоеп тормый иде.

Хаким. И мәҗнүн хатын! Әле һаман да шул буш хыяллар белән юанып яшисеңмени? Кайда соң зур хәзинәң, ирең кайда? Ул нык имгәнгән иде, әллә кайчан үлгәндер, син алтыннан кыйбат дип йөргән йөрәге дә, череп, туфрак булгандыр.

Кадимбикә. Ялгышасың, Хаким! Алтын череми, чын хәзинә югалмый, гомерләр узган саен, арта гына бара.

Хаким. Кайда соң әле үзе?

Кадимбикә. Борылып кара, Хаким.

Хаким. Ләкин бу егетләр арасында ул юк.

Кадимбикә. Болар — безнең улларыбыз. Аларда иремнең һәм минем йөрәк тибешләребез дәвам итә. Сиңа каршы күтәрелгән яуда алар да катнашты, тәхетеңне алар да җимереште.

Хаким. Аларны миңа каршы итеп үстердеңме?

Кадимбикә. Мин аларны явызлыкка, золымга каршы торырга, яхшылыкны, гаделлекне яклап сугышырга өйрәттем.

Хаким. Шушы далада, шушы чатырда, имгәнгән ир белән яшәп торганда, миңа каршы күтәрелерлек уллар үстерә алдыңмы?

Кадимбикә. Үзең күреп торасың, Хаким.

Хаким. Ләкин... бу хәзинә... мондый уллар үстерү һәркем кулыннан килә бит! Аның өчен зур беләмәләр дә, власть та кирәкми.

Кадимбикә. Бу балаларны үстергәндә, саф вөҗданыбыздан гайре башка хәзинәбез юк иде.

Хаким. Вөҗдан нәрсә ул? Аны беркемнән дә тартып аласы юк лабаса! Ул — һәркемнең үзендә! Минем тәхетемне, байлыгымны тартып алдылар, властьтан мәхрүм иттеләр, ләкин әле мин исән, мин яшим, мин дә уллар булдыра алыр идем! Әйе, мин дә далага китәргә телим! Җибәрсеннәр мине, иреккә чыгарсыннар!

Кадимбикә. Ярый, мин халык алдында баш иеп, теләгеңне үтәүләрен үтенермен. Заманында мине иреккә чыгарып җибәргән идең. Мин дә сине иреккә җибәрү өчен тырышырмын.

Өлкән егет. Кол булып калсын ул! Кол итәргә кирәк аны!

Кадимбикә. Патша булып туган кол булып яши алмый, улым... *(Сәхнә караңгылана. Моңлы көй яңгырый. Бераздан сәхнә яктыра. Шул ук чатыр. Кадимбикә казан янында утыра. Өлкән егет керә.)*

Егет. Әни, хәбәр китерделәр. Далада Хакимнең үле гәүдәсен табып алганнар.

Кадимбикә. Халыкның хөкеменә каршы килеп, кем аңа кул күтәргән?

Егет. Аны Хакимнең элекке ялчылары явызлык белән һәлак иткәннәр.

Шунда тамаша залыннан тавыш ишетелә: «Туктагыз! Сабыр!»

Тамашачы *(залдан сәхнәгә сикереп менә).* Туктагыз, ашыкмагыз! Димәк, Хаким үтерелде? Ни әйтмәкче сез моның белән? Явызлык җиңелде, золым бетерелде, димәкчеме? Ю-ук, дөрес түгел! *(Тамаша залына.)* Ышанмагыз мондый сүзгә! Дөньяда бүген дә залимнәр яши бирә, золым кылына тора. Беләсезме сез шушы минутта җирдә күпме кан-яшь түгелгәнен? Күпме гөнаһсыз сабыйларның җаны кыелганын беләсезме? Саф җаннар иңри, йөрәкләр әрни, күңелләр сызлый. Кадимбикәләр, сизәсезме? Ишетәсезме, Кадимбикәләр? Кайда сез, Кадимбикәләр?

*1981—1984.*

# ТОРМЫШ БИЗӘКЛӘРЕ

## КАВИ ЛАТЫЙПКА — 60 ЯШЬ



Каләмдәшебез, СССР Язучылар союзы әгъзасы, Бөек Ватан сугышында катнашкан шагыйрь, КПСС члены Кави Латыйпка 60 яшь тулды.

Кави Таһир улы Латыйпов 1927 елның 1 маенда Чувашстанның Батыр районы Кызыл Чишмә авылында ярлы крестьян гаиләсендә туган. Урта мәктәпне тәмамлагач, Татар Тимәше авылында балалар укыта. 1944 елда Совет Армиясе сафларына алына, 1955 елга кадәр ул — хәрби хезмәттә; Бөек Ватан сугышында солдат, соңыннан хәрби-политик училище тәмамлаганнан соң, офицер-политработник... Демобилизацияләнгәч, ВЛКСМның Татарстан өлкә комитетында, Мәгариф министрлыгында, Казан телестудиясендә, күп тиражлы газетада, СССР Педагогия Фәннәре Академиясенең профтехпедагогика фәнни-тикшеренү институтында эшли. Читтән торып М. Горький исемендәге әдәбият институтын тәмамлый. Хәзерге вакытта ул — профессиональ язучы.

Кави Латыйпның беренче китабы — «Солдат эзләре» исемле шигырьләр җыентыгы, шагыйрь Әнвәр Давыдов фатихасы белән, 1960 елда басылып чыга. Аннары төрле елларда аның «Шигырьләр», «Умырзая», «Ак карлар», «Тормыш бизәкләре» исемле китаплары дөнья күрә. Бер үк вакытта шагыйрь тәрҗемә өлкәсендә дә көчен сыный: Иванов, Сеспель кебек чуваш поэзиясе классикларының әсәрләрен татарча яңгыратуга ирешә. Бу чорда Кави Латыйп проза әсәрләре дә яза: аның «Бәләкәй Чапай», «Йолдыз тапкан егет» (якташы, космонавт Андриан Николаев турында) повестьлары татар һәм чуваш телләрендә басылды. Ул — шулай ук «Бәхетле язмыш» исемле очерклар китабы авторы да...

Шагыйрьнең «Тормыш бизәкләре» дип аталган шигырьләр китабы Мәскәүдә «Советский писатель» нәшриятында рус телендә дөнья күрде. Бу китаплар, тәнкыйть билгеләп узганча, аның зур әдәбият юлындагы «тәҗрибәләре, эзләнүләре» булдылар. Соңгы елларда басылган «Вакыт канатында» (1983) һәм «Күңел йомгагы» (1986) китаплары инде Кави Латыйпны үзенчәлекле, үз шигъри дөньясы, кызыклы, оригиналь күзаллавы белән аерылып торган шагыйрь итеп танытты...

Аның «Күңел йомгагы» китабына язган кереш сүзендә тәнкыйтьче Рафаэль Мостафин бу үзенчәлекне менә ничек билгели: «...К. Латыйп үзенең сөйләм ысулын, поэтик интонациясен тапты. Аның шигырьләрендә ниндидер эчке драмага, бик тирән ямьсезләнгән трагедиягә ишарә бар. Аның һәр шигыренең нигезендә фикер ята, ләкин коры риторика түгел — хисле фикер...» Шагыйрь Зөлфәт исә К. Латыйпның ирекле шигырьдәге уңышларын, үзенчәлекле ритмикасы китергән яңалыкны билгеләп, болай язды: «Тормышның үзенчәлекле мозаикасы, панорамасы күз алдына килә... Берләштерүче көч — шагыйрьнең шәхес буларак мөнәсәбәте — дөньяга, кешеләргә мөнәсәбәте, дөньяның трагик һәм комик күренешләренә мөнәсәбәте...» Күренә ки, бирedә ике әдипнең дә фикере тәңгәл килә.

Гражданлык хисләре биографиясенә тыгыз бәйләнгән, әтисе һәм абыйсы Бөек Җиңү хакына сугыш кырларында ятып калган солдат-шагыйрь яу каһарманнарының васыятьләрен онытмыйча, гүя алар өчен яши, янып иҗат итә. Ул II дәрәҗә Бөек Ватан сугышы ордены һәм медальләр белән бүләкләнгән.

Шагыйрьнең янә бер күркәм сыйфатын әйтеп үтәсе килә: бу — аның шигырьдә ихласлыгы... Бу ихласлык, садәлек, хәтта беркатлылык — кешеләргә яхшылык теләү, бөтен дөньяны матур итеп күрергә омтылу белән бәйләнгән.

Әйе, кырыс тормыш, чынбарлык аша бөек Матурлыкның җиңүенә ышаныч хас Кави Латыйпка. Шул ышаныч шагыйрьнең үзен дә, иҗатын да тынгысыз, яшь итә кебек.

Алтмыш яшен дә шагыйрь әнә шулай, яшьләрчә каршылый.

**Рәдиф ГАТАУЛЛИН**

## Кави Латыйп

### Мәхәббәт һәм нәфрәт

... Икесе дә кирәк,
икесе дә
йөрәккә терәк.

Берсе яраттырып көч өсти.
Икенчесе —
кулдагы кылыч төсле.

Яшиләр бер күңелдә икесе дә...
Ә хуҗалары бер өйдә,
кием-салымнары бер чөйдә.

### Моң

Һава ярып уйнатасы иде быргылар.
Ишетерләр иде, бәлки, борынгылар?..

Быргыларда яңгыратып,
борынгыларны уятырлык
нинди икән моң бар?..

Табасы иде.

... Моң булып
борынгылар ташына тамасы иде.

*

«Мин үлдем!»
Сөенегез!

Мин яшим.
Көенегез!

Сынап карыйсым килә
дусларны,
дошманнарны:
яшәргә,
үләргә кушканнарны.

Кайсылары өстенлек алыр?

Әмма белсеннәр,
Җирдә
көенечләрем дә,
сөенечләрем дә
калыр.

# Аваз

Күпме генә кычкырсам да,
бөтен дөнья ишетмәс.
Кычкырмасам,
йөрәгем гафу итмәс.

Үлгәннең авазы юк,
үлгәннең — газабы юк.

Исән генә авазлы,
исән генә газаплы.

Газаплы авазлардан
тере дөнья азатмы?..

❁

Кошлар, кошлар,
бармы күктә көтелмәгән борылышлар?
Хәвефле түгелме очышлар?..

Канатлылар белмидер бәлки
җәяүлеләрнең хәлен?..

Куркынычлы борылышлар
Җирдә дә бихисап.
Җирне исән-имин яшәтү —
беренче максат!
Аннары гына җыр...

Килде әйтеп тә, язып та
бетермәслек кырыс чор!

❁

Серле моңнарны,
керсез моңнарны
ничек чишәсе?

Кайда чишмәсе?..

Беләдер моны
ихлас күңелле җырчы.

Ә син, океан,
шауламый торчы.

Керсез моңнарны
килә ишетәсе.

Кайда серләр чишмәсе?..
Ничек телен чишәсе?..

❁

Бакчам минем — яшел бүлмәм.
Бер китсәм,
кире килмәм.
Алма өзмәм,
тәмен белмәм,
кошларга да сәлам бирмәм.

Агачтай сыгылмам,
бөгелмәм,
җиләккә иелмәм,
чыктай түгелмәм.

Минем бакчам — яшел бүлмәм.
Юрганым — яшел үлән.

Бакчада тын.
Күкрәп яңгыр яуды әле генә.
Үзенә иш эзли йөрәгем,
көтә яңадан күк күкрәвен.

Күкрәүләрсез,
тетрәүләрсез

йөрәгем
һич кенә дә яши алмый.

Кеше аңламаса,
яшен аңлый...

Саф, намуслы кешеләр,
исән чакта
хакыйкатьне әйтеп калыгыз,
үзегез белән алып китмәгез!

...Дөреслектә —
исәннәр тереклеге,
береклеге.

Атылган җан белән
сатылган җан —
Җир белән күк арасы.

Атылган — адәм баласы...

Сатылган — эт баласы...
Көчле булып каласы,
кургаш пуля аласы...

Кеше булып каласы!..

Чәчәкләр сибелсә дә,
серләрең сибелмәсен.
Сер — күңел хәзинәсе.

Югалтсаң,
янарсың-көярсең.
«Җуләрмен!»— диярсең.

Чәчәкләр сибелсә дә,
серләрең сибелмәсен.

Дөньяга таралса,
җыеп алалмассың.

Булыр соң!

## Бишектәгеләр

Йолдызлар йоклый,
уяна-уяна...

Галәм бишегендәгеләрне,
Адәм бишегендәгеләрне сана!..

## Бөртек

Арышның бер бөртеге
Җир шарын тарта үзенә.
Шулай түгел икән,
Җир белән кеше арасында
элемтә бетә, өзелә.

Бер бөртек арышта
Кояш көче сизелә.
Санаулы планеталардай
бөртекләр гәрәбә теземдә...

Арышның бер бөртеге
Галәмне тарта үзенә.

## Йомыклар

Канатсыз кешеләргә
канатлы сүзләр сөйләмә.
Бушка!

Андый йомыкларга
канатлы сүзләр
йомычка булып оча.

❁

Йөрәктә таш саклау
саңгыраулыкка илтә.
Гафу итә белгән йөрәк

бөтен җиһан яхшылыгын ишетә.
...Үземне диңгезләр киңлегендә,
йолдызлар биеклегендә хис итәм...

## Максат

Максатка ирешер өчен,
кызганмаска кирәк көчең.
Шуның өчендер бу йөрәк,
шуның өчен теләк...

Ә максатсыз...

Максатсыз кеше сансыз.

Максат!..
Кеше яши алмый,
кеше кеше була алмый ансыз.

❁

Сөйлә,
сөйләмә,—
Сүзгә Сүз гашыйк булса гына,
Сүзгә Сүз өйләнә.

...Сүзне Сүз каратса гына,
мәңгегә яратса гына,
Ул Сүзнең баласы була.

...Безгә —
исем табасы була!

❁

Миллионнар тату яшәгәндә,
ике кеше дөньяга сыймаска мөмкин.

Ул икенең берсе — син,
берсе — мин.

Җиһан — миллионнар өчен генә киң...

# ЙӨРӘК ХӘТЕРЕ

## ҖӘМИЛ МОСТАФИНГА — 60 ЯШЬ

Мәскәү язучысы Җәмил Мостафин иҗаты турында сүз башлар алдыннан Ленин премиясе лауреаты Мариэтта Шагинянның сүзләрен телгә аласы килә: «Җәмил Мостафин — авыр тормыш мәктәбе үткән кеше. 1927 елда Башкортстанда крестьян гаиләсендә дөньяга килеп, ул тимерче, слесарь, токарь булып эшләгән. Эшче халкы аның хикәяләрендә гаҗәеп төгәллек белән һәм чиста тасвирлана. Укып чыкканнан соң, аның әсәрләрен озак оныта алмыйсың, ә иң мөһиме — алар язучының кешеләрне нинди дер нәфис һәм күркәм ратуы белән яктырып торалар». Ул Җ. Мостафинның табигать һәм җәнлекләр турында бик тасвирлы, шигъри язуын да билгеләп үтте. Хикәяләрендә булсын, повестьларында, романнарында булсын, Җ. Мостафин «йөрәк хәтере» белән яза, һәм бу хәтер аның әсәрләрендә халык хәтере сыйфатында чагыла.

Алай да Җәмил Мостафин иҗатының төп асылын нәрсә тәшкил итә соң? Минемчә, иң әүвәл — халыктагы бердәмлек хисе. Аның әсәрләрен аерым-аерым алып тикшерсәң дә, тулаем күз алдына китерсәң дә, бер үзенчәлек хакында уйланасың. Ул да булса — язучының илебездәге төрле милләт вәкилләре холык-табигатен тирәнтен белеп чагылдыруы, аларга хас рух бөтенлеген, омтылышлар биеклеген, максат чисталыгын төгәл гәүдәләндереп, гомуми мәгънә дәрәҗәсенә җиткерүе. Аның БАМ төзүчеләре турындагы «Күпер» дигән повестен укыйсыңмы яисә Себердәге мәһабәт үзгәрешләрне эпик киңлектә сурәтләгән «Юл» романынмы — күңелне бер хис били: Җ. Мостафин, кайсы гына милләт вәкилләренең тормышын сурәтләсә дә, соңгы нәүбәттә киләчәкне төзүчеләрнең шәхес буларак үзкыйммәтен, кабатланмас икәнлеген раслый. Ахыр килеп, бу раслауда какшамас бер принципиальлек, ягъни кешелеклелек тантанасын, уртак бәхетне дәгъвалау ярылып ята. Бу әсәрләрдәге геройлар — безнең заман кешеләре, заманча кешеләр, язмышлары үтә гыйбрәтле. «Юл» романында геройларның язмышлары психологик тирәнлектә ачыла, эчтәлеге публицистик кайнарлыкка, биләп алырдай катлаулы вакыйгаларга бай, гражданлык күтәренкелеге, фәлсәфи уй-фикерләр белән тулып тора. Язучы үз геройларын һәрчак көрәшче итеп тасвирлый. Прораб Петр Новгородов, бетончы Иван Шпак, юл монтеры Клава Варфоломеева, Себердә утызынчы елларда төпләнеп калган татар хатыны Рабига — һәркайсында язучы кешеләрнең эштәге, тормыштагы үзара катлаулы мөнәсәбәтләрен синтезлап күрсәтә. Рабига түти, мәсәлән, сугышта ирен, ике улын югалтып, ялгыз калса да, ныклыгын, сабырлыгын, чит кеше кайгыларын җаны-тәне белән үзенеке итеп кабул итүен бөтен гомере буена инанган байрагы төсендә дәвам иттерә. Бу образ Г. Бәширов, Ә. Еники, А. Гыйләҗев, М. Мәһдиев кебек әдипләр иҗат иткән татар хатын-кызлары галереясында лаеклы урын тота.

Интернациональ рухлы язучы Җ. Мостафин — СССР Язучылар союзының кыргыз әдәбияты советы члены, Мәскәүдәге Ворошилов район Советы депутаты, РСФСР әдәби фондының президиум члены. Ул бик күп милли язучыларның әсәрләрен русчага тәрҗемә итеп, үзәк газета-журналларда, нәшриятларда чыгарды. Алар арасында татар язучыларының әсәрләре аеруча күп. Татар әдәбияты, Татарстан белән даими элемтәдә тора. Әлмәт нефтьчеләре янына ул әледән-әле кайта, тормышлары белән кызыксына, китап укучылар конференцияләре үткәрә.

Тормыштан алып язган геройлары язмышында Җ. Мостафинның үз язмышын да чамаларга була. Ул — зур тормыш мәктәбен, авыр сынаулар үткән кеше. Җ. Мостафин — язучы буларак, чын мәгънәсендә көрәшче кеше. Дөреслек өчен көрәшүче. Аның язган әсәрләренең һәркайсы ышандыра, алар уйлап чыгарылмаган, алар автобиографик рух белән сугарылган. Язучының «йөрәк хәтере» — менә шунда инде.

Бу хәтернең озын җепләре Җ. Мостафин иҗатын башка халыкларның рухи дөньясы белән дә тоташтыра. Аның әсәрләре СССР халыкларының күп телләренә тәрҗемә ителгән. Кайбер әсәрләре поляк, югослав, вьетнам, монгол, немец, инглиз, испан телләрендә чыкты.

Бу елның май аенда язучы Җәмил Мостафа улы Мостафинга 60 яшь тула. Шушы нисбәттән аңа сәламәтлек, рухи ныклык, иҗат офыгының һәрчак шулай ачык булуын, укучыларны чакырып торган учак төсле үз йөрәге хәтере тирәсенә җыюын телисе килә.

Әдипнең бер хикәясен, рус теленнән тәрҗемә итеп, укучылар игътибарына тәкъдим итәм.

**Әхәт ГАФФАР.**

## Җәмил Мостафин

# ИКЕ ЯЗМЫШ

хикәя



Колыннар бер үк көнне, бер үк вакытта диярлек, урман куелыгыннан аерылып чыгуларына шатлангандай торган яшь каеннар һәм чыршылар кочагындагы уйсу бер болынлыкта дөньяга килделәр.

Россия киңлекләрендә мондый матур урыннар күп ул.

Юеш колыннар яшел чирәмлектә кыймылдамыйча гына яталар, әйтерсең лә таныш булмаган чуар дөнья тавышларын сагаеп тыңлыйлар. Бияләр тынгысыз башларын игәннәр дә аналарга гына хас гаҗәеп түземле төстә аларны, сөлге белән сөрткәндәй, телләре белән ялап киптерәләр иде.

Читтәрәк бүтән атлар йөри һәм һични күрмәмешкә салышалар, табигатьнең бөек күренеше — тере җан ияләре дөньяга килгәнгә игътибар итмәгәндәй булалар. Кырыкмыш тайлар да тыныч кына читтә йөриләр, нишләргә белмичә, әле тибенәләр, әле сын шикелле катып калалар. Ә картрак атлар кайда парлашып, кайда өчәүләп, бер-берсенең аркаларына башларын салган көйгә, сагаеп кына җилгә колак салалар, йомылыр-йомылмас торган зәйтүн күзләре белән беренче тайларын сизгер борыннары белән иснәштергәләгән һәм аларны һаман да иркәләүдән туктамаган яшь ана атлар ягына карангалап алалар. Яшь бияләр һәр төкләре белән ат карауччы карт Хәнәфи агайның үзләрен борчылып күзәткәнен тоеп тордылар. Ул агачка сөялгән дә, вакыт һәм тәмәке каралткан төрепкәсенең күптән сүнгәнен дә сизмичә, аны яңаклары батып кергәнче суыруын белә.

Кинәт күк гөмбәзен чакыру авазы белән тулган, шул ук вакытта шатлыктан ташып торган, әле ныгып җитмәгән кешнәү тавышы ертып җибәргәндәй була. Яшь урманны шундук кошлар чыркылдавы басып китә. Болындагы атлар сагаештылар, йөренергә керештеләр. Колыннар яллары чак сизелерлек тотнаксыз муеннарындагы тупыйк борынлы башларын күтәреп, дөньяга гаҗәпсенүле карашларын юнәлттеләр. Аларга җавап итеп, бияләр кабарынкы койрыкларын тыйнак төстә селеккәләделәр һәм колакларын шаңкәйттеләр. Кешнәү авазы колыннарны җирдән күтәреп бастыргандай итте; һәм алар калтырап торган, нечкә аякларын киң җәеп, аналарының корсаклары астына борыннарын төрткәләделәр. Ниһаять, тыгыз иреннәре белән кара имчәк башларын эләктереп алдылар да шәфкатьсез төстә тарткалый башладылар. Сөт башта аларның телләренә төште, аннары, татлы агым булып, тамакларына агып керде.

Авырттырса да, бияләр түзде һәм колыннарның бәхетле уйнаклаган кыска койрыкларына шатланган сыман карап тордылар. Хәнәфи агай канәгать төстә аларга якынрак килде, төбәлеп диярлек, тайларга караш ташлады. Ул шундук малларның килеш-килбәте яхшы икәнен абайлады: кузна сөякләре югары, койрык өсләре таманча түгәрәк, күкрәкләре киң.

— Яхшы мал булыр бу! — диде ул һәм турының дымсу муенын каккалап алды.

Бия пошкырып куйды да бәрхет иреннәрен картка таба сузды. Ат карауччы сырмасының кесәсеннән тәмәке исе сеңгән ипи кыерчыгы чыгарды. Туры ипине гадәтләнгәнчә киң, бияләйгә охшаган тешләре белән эләктереп алды.

Ат караучы кола атның да тир каралткан муенына суккалады, анысына да учында ипи сузды.

— Яхшы мал булыр бу! — дип кабатлады ул.

Хәнәфи агай барлык атларны да бердәй ярата иде. Әмма аеруча тыныч һәм эшчәннәрен һәрчак үз яклавы астына ала: аларны ипи белән сыйлый, утлыкларына бер-ике уч солыны артыграк сипкәли, дирбияләрен тәртиптә тота. Һәрбер ат камытының бушлыгын, шлеянең тәнен яки ботларын кыруын шундук тоеп житкерми бит. Инде дуга да чит, ят икән, эш бөтенләй харап — тәртә арасында, ат дагалау станындагы шикелле, кая бәрелергә белми торасың. Эшкә чит дирбия белән жиксәләр, тагын да начаррак. Камытның жилкә калкымын чи иткәчә кырганын эштән соң гына күреп аласың.

Зоотехник Рәхим Садриев, картның бу йомшаклыгын белеп:

— Хәнәфи агай, синең үтә яраткан атларың бар дип сөйлиләр, дөресме? — дип шаяртکалый иде.

— Андый нәрсә юк югын, агайне. Юк,— дип мыгырдана Хәнәфи агай.— Үтә ярату кешеләр арасында гына була ул. Ә атларның барчасы эшчән бит. Ялкаулары да бар, әлбәттә. Тик алар — барыбер ат. Аларның бер ишләрен генә яратып, икенчеләрен кагу эшмени ул? Һәркайсы — ат көче. Уйлап та чыгаралар соң: машиналарның көчен дә ат белән үлчиләр!

Шулай да Хәнәфи агай кайбер атларны башкаларыннан өстен куйгалый иде. Моның өчен аны гаепләп булмый торгандыр, мөгаен. Атлар аның яратуын ялагайланып, икейөзлеләнеп түгел, ә эшләре белән казана иделәр.

Менә хәзер, яңа гына дөньяга килгән һәм һәр йотым сөт саен үзләрен ышанычлырак тоткан колыннарга карап торганда да холкы белән уйга бирелүчән Хәнәфи агай аларның киләчәк язмышларын күз алдына китерергә тырыша иде. Ни өчендер ул аларны жиңел тарантаска жигелгән көйгә авыл урамнары буенча жилдерер өчен яратылган чибәркәйләр итеп күрергә теләде... Картның киң яңаклары төссезләнеп китте, көрән күзе кысылып, ул гына күрә алырдай ерак-еракларга төбәлде... Буш төрепкәсен күнитегенең балтырына каккаларга кереште. Күңеле белән ул атларның шундый язмышына күнләшеп алды. Ничек көнләшмисең ди? Эше тупас түгел, ризыклары да шәптән булыр. Эш атларына болын печәне житенкерәмәсә дә, жиңел тарантас тәртәсенә кергәннәрнең алдыннан өзелмәс әле.

Кеше утыртып кына йөртергә язган атларны сөйми түгел Хәнәфи, ләкин андый тигезсезлекне йөрәге белән кабул итеп тө бетерми. Бөтен атларга шундый язмыш эләгү начар түгел анысы... Мәгәр дөнья бит бу, алай гына булалмый.

Хәнәфи үз уена уфтанып куйды: ул чагында кырда, фермада кайсысы эшләр соң? Анысы машина белән хәзер бөтен дөнья тулган, тик ат көчен дә санга сугарга кирәк әле...

Сүз куешканнар диярсең: колыннар бер үк вакытта имүләрен ташладылар да аналары тирәли беренче тапкыр йөренә башладылар. Биләрне әйләнеп чыккач, алар бер-берсен күреп алдылар да кара-каршы якынайдылар. Бер-берсен иснәштергәләгәч, гажәпсенделәр: һәркайсыннан сөт исе килә икән бит! Кола ат белән туры ат, алардан күзләрен алмыйча, тын гына, шат төстә кешнәп куйдылар. Бәхетле аналар янына башка атлар да тартылды. Колыннар башта алардан куркынып читкә янтайдылар. Аяк асларындагы жир каядыр шуыша кебек иде, койрыклары үрә торды. Ят атлар, курыкмагыз дигәндәй пошкырынып, башларын чайкадылар. Гүя үзләренең колын чаклары белән очрашулары. Алар да дөньяга беренче мәртәбә шулай гажәпсенү катыш курку белән караганнар иде бит. Аларның да шундый уйган мәрмәр сымак тояклы озын аяклары бар иде; ирениәре дә, шәлперәйгәнче кайнатылган пилмән шикелле, асылынып тормый иде. Ул чагында ат караучы да, башын

казык итеп боргалый-боргалый һәм: «Җитәр, җитәр, малкайлар!» дип сөйләнә-сөйләнә, үз муенын кытыкларга рөхсәт итә иде. Хәзер инде, әүвәлгечә киң күңелле булса да, ул алар белән уйнап тормый. Бәлки, алар эшкә яраксыз калганнардыр инде? Ә бәлки Хәнәфи агай үзе дә картайгандыр? Вакыт ага да ага бит ул. Әнә, корсак тирәсен тәртә һәм дирбияләр ничек кырган, койрыклары шундый сирәкләнгән — туйдырып бетерүче бөгәлчәннәрнең дә әллә ни исләре китми. Таушалган, белен шикелле җәелеп калган тояклар хакында уйлап та торасы юк — аларга дагалар көчкә эләгеп тора. Ул тоякларның рәхәтләнеп боз ваткан чаклары да бар иде ләбаса, дагаларның кирәге дә юк иде.

И гомер, гомер! Атларны ни генә кыландырмый ул!

...Шаулап яуган яңгыр астында ат көтүенең бергә укмашып, күк күкрәгән саен пошаманга калуына карамастан, яшеннәрнең камчы шикелле селтәнүен бар дип тә белмичә, тай-тулак бөтен болынны бетереп тузына, рәхәтләнеп тибешә иде. Яшьләре арткан саен, аларга сабырлык иңә башлады, аналары алар өчен артык кайгырмас, бүтән атлар кыерсыткан чагында да борчылмас булдылар. Тай булып җитлеккәндә, кола белән турының буйсыннары өлкән атлар белән тиңләшсә дә, көч ягыннан калыша иделәр әле. Бер заманны алар, бурлы бия белән шаярып алгач, йөрәк тибешен тыңлаган кебек, башларын аның биленә салган көйгә талгын бер хозурлык хисе кичереп торалар иде. Көтмәгәндә яннарына алмачуар айгыр томырылып килде дә кола тайның сыртын карт, ләкин нык тешләре белән каптырып алды. Кола тайның авыртудан һәм хәтере калудан кешнәп җибәрүе урман киңлегенә таралды. Каршысында көтүдәге иң мәртәбәле, иң хөрмәтле айгыр торуына да карамастан, кола тай үзенең кыерсытучысына ташланды. Әмма күкрәгенә көчле тояклар килеп төшкәч, ул янга тайпылды, шәм сыман үрә басты. Алмачуар да үрә торды һәм, алгы аяклары белән тукмый-тукмый, аны муенынннан эләктермәкче булды. Үз дигәненә ирешә дигәндә генә, кола тайга ярдәмгә туры тай килеп җитте. Алмачуар көндәшләренең өстенлеген бик тиз таныды. Шушы кыюлык һәм, иң мөһиме, кумәк каршылык күрсәтү өч яшьлек тайларны үзләрен яклый алырлык өлгергән малларга әйләндерде. Кола тай белән туры тай алмачуарның муенын түбән каерып төшерделәр, теге, ычкынып, урманга качарга мәҗбүр булды. Тавышка, ыгы-зыгыга йөгереп килгән ат карауч, алышу зәһәрлегеннән сүрелеп өлгермәгән тайларның үзара пошкырынуын күрде дә, көрәшнең ахырына канәгать калып:

— Яхшы маллар булып җитештеләр, яхшы маллар булып,— диде.

Кемдер җиңел кулдан кола тайга Орлик дип, ә аның иптәше туры атка гади генә — Туры дигән кушамат бирде. Күпләрнең гаҗәпләнүенә каршы, Орлик белән Туры җигемгә тиз күнектеләр һәм теләсә нинди йөкне рәхәтләнеп тарталар иде. Иңләшенмәгән бу эштә алар үзенә күрә рәхәтлек таптылар. Гадәттә, тиреләре астында тыгыз туплар кебек теләр-теләмәс кенә кыймылдаган мускуллары киерелгәндә, аларның яшь тәннәре җылына, йөрәк тибешләре кызулана, каннары күз аллары тоныкланганчы кайнарлана иде...

Ат карауч карт аларга мактау сүзен кызганмады, шул ук вакытта яшертен генә аларга яхшы язмыш теләде. Тупас дирбия арасында да сыгылмалы йөреш саклауларын күреп:

— Әх, ат заводына җибәрәсе иде сезне, малкайлар,— дип уфтангалый иде.

Атларның язмышына хәтере калу, кызгану аны торган саен ныграк били барды. Ихтимал, моңа Орлик белән Турының эш сөюе, кешеләрне үз итүләре дә сәбәпчедер. Ә бәлки мондый матур, җигүгә тиз иңләшкән атларның утарда тулып ятмавы да булгандыр. Хәнәфи агай киез эчле камытларның тора-бара атларны ни дәрәҗәдә таушалтуын яхшы белә иде шул. Шуңа күрә Орлик белән Турыны җигүче йөкче Тимофей Передеринга ул еш кына:

— Син инде, Тимоша, арттырып җибәрә күрмә,— дия иде.— Беләм мин сине, аю: ат кына түгел, арба еларлык итеп төйисең. Онытма: атлар яшь әле, буыннары утырып җитмәгән, өзлегүләре бар.

Андый чакларда Передерин ни өчендер уңайсызлана иде.

— Кыерсытмам, Хәнәфи агай. Беләсең ич инде, аттан да яхшырак җан ияләре минем өчен юк бит ул. Аларны үзе ялкау кеше генә аңламый. Әнә, мин аларны икмәк белән дә сыйлыйм,— ди йөкче, солы капчыгына ишарәләп.— Ашханәдә әрәм-шәрәм итәләр, ә мин — атларга.

Ничектер бер заманны Хәнәфи агай янына зоотехник Садриев килеп керде дә урап-урап сүз башлады:

— Безнең фермалар кайсы-кайда чәчелеп ята, Хәнәфи агай. Әйләнеп килгәнче, ни гомер вакыт уза... Миңа тарантаска җигә торган ат кирәк. Аякка җиңел булсын, килеш-килбәте дә ким-хур булмасын. Әлбәттә, дирбиясе дә кеше күзенә чүп булып кермәсен.

Карт, зоотехникның дилбегәне кая борганын чамалап:

— Машинаңа ни булган? — дип сорады.

— Машина җансыз бит ул. Ат белән — дөнья рәхәте.

— Ат җигеп йөрсәң, кеше көлмәсме соң? Заманы ул түгел бит.

— Әх, заман, заман!.. Гомер-гомергә ат белән игенче икесе бер җан булган. Шуннан көләр көнгә калдыкмыни? Менә шул, Хәнәфи агай. Миңа, таушалмас борын, Орликны бигеләп куй әле син. Камытның атларны ничек үтүкләгәнен үзең беләсең. Рессорлы тарантаска куябыз, сбруен да җиңелне юнәтергә кирәк. Ике тәгәрмәчле арба кулайрак булыр. Минем андыйларны Мөслим районының «Урожай» колхозы ипподромында күргәнем бар. Оча гына атлар, тояк асларыннан кара буран туз-гып кала... Безнең Орлик кай ягы белән ким? Ризамы? Синең малыңа нинди язмыш елмаясын белдеңме инде? Тора-бара, бәлки, Турыны да жылы урынга урнаштырырбыз.

Карт, төрепкәсен сызгыртып, бер суырды да дәшми торгач:

— Ниятең изге, олан. Тик Турыга иптәшсез кыенга килер инде. Алар бергә үсте ич. Тимоша да һәр икесен ярата. Яхшы, тырыш атлар, ди, аларны ипи белән сыйлый. Кызгана ул аларны,— диде.

— Орликны чабышкылар рационы белән ашатырга кирәк. Биш кило солы, кишер, чөгендер, ә печән — күпме кирәк, кызганма, алдыннан өзелмәсен.

— Кайвакытны атларга бер уч солы да тәтеми. Ә монда берүзенә биш кило. Тел төбеңә төшенмим әле, энем.

— Корчаңгы атта йөри алмыйм ич инде мин? Халык күреп сөенсен, халык! Бигрәк тә балаларны ат җанлы итәргә вакыт. Моның нәрсәсенә төшенмисең?

Ул чагында Орлик белән Туры фермага салам, силос ташый иде. Алар үз азыкларын намуслы эш белән табалар. Көпчәкләре берәр канауга туры килсә, Тимоша аларны сак кына каулый; андый чакларда ул аз сүзле, кырыс кешедән тел бистәсенә әверелә, атларның бер алдына, бер артына төшә. Төкемсә йөкченең татлы теленә гаҗәпләнәсе генә кала. Кешеләргә түгел, атларга бит!

...Бер караганда, Орликның язмышына шөкер кылсаң да ярарлык. Ул рессорлы тарантаста зоотехникны җилдертеп кенә йөртә, аның конторасы төбендә сәгатьләр буена тик тора. Күнегү кыен түгел, җиңел тормышка бигрәк тә. Ул Хәнәфи агайның үзен салкын каршылый башлавын шундук тойды. Инде менә күпме тапкыр ул, әүвәлгечә, картның колакчын бүреген тешләп салдырмакчы булып кыланды. Ат караучы:

— Җитәрсәнә! Симерүдән көчеңне кая куярга белмисең,— дип кенә җибәрде.

Кайчандыр киң күңелле булган бу карт аңа тәмәке исе сеңгән тозлы ипи кыерчыгы да тәртми, яратып кына: «Аргансың да соң, малкай...

Ярый, хәзер ял итәрсең. Безнең эш җиңелдән түгел бит ул»,— дия-дия, муенына да суккаламый инде.

Шунысы сәер: барысыннан да бигрәк Орликка элеккеге хуҗасы Тимошадан эләккәләде. Йөкче зоотехник атын күрмәмешкә салыну гына түгел, җаен китереп, усал калын тавыш белән:

— Әх син, җилбәзәк! Бушка ашап, бүксәң киерелеп беткән! Сугымга әзерлиләрмени, тьфу! — дип, тубал кадәрле йодрыгы белән аның сыртын төеп алудан да тайчынмый иде.— Кара инде моны — кабыргаларының кайдалыгын да белерлек түгел!

Орликны куркудан хәтта очкылык тота башлый. Мондый эше өчен Хәнәфи агай Тимошаны тиргәп тә ташлады.

— Нигә тик торган малны кыерсытасың әле син? Башың белән уйла әле: ходай аякларын нәфис уйган да матур күзләр куйган икән — моңа ат гаеплемени?

— Төкерәм мин аның нәфис аягы белән матур күзенә! Минем Турым, салам ташыса да, тирес түксә дә, аннан тамчы да кайтыш түгел.

— Мал хәленә кермәү барыбер әйбәт түгел,— дип, Хәнәфи агай Орликны аратага бикләп куя.

Кешеләр генәме соң — Орликка карата Турының да мөнәсәбәте үзгәрде. Ул үзенә бүтән иптәш — корсагы шәлперәеп торган, балалар бакчасына су ташуга куелган карт алмачуарны сайлап алды.

Ә Орлик белән Турының, башларын бер-берсенең муеннарына куеп, тиздән аерыласыларын сизгән шикелле, сәгатьләр буена басып торганнары бар иде бит.

Орлик та, Туры да үз аналарын хәтерләмиләр иде инде — алар, төштәге сыман, сиздермичә генә башка атлар арасында югалып калдылар. Бервакыт, алар әле колын гына чакта, кола бия белән туры бияләрнең яңа колыннары дөньяга килде. Болында уйнап йөргән Орлик белән Туры аларның кыңгырау тавышын хәтерләткән беренче йомшак кешнәүләрен ишеттеләр. Әле онытылмаган тәмле исне тоеп, аналар йөрәге кебек җылы, татлы сөт авыз итү нияте белән тайлар шул тарафка элдерделәр. Аларның бу ашкынуында ярату, иркәләнәсе килү, ышаныч ташып тора иде. Ул аларны сукырайткан шикелле итте. Шуңа күрә аналарының тешләрен ыржайтып, колакларын яткырып, әллә ниткән нәфрәт белән тулы күзләрен акайтып каршылауларын башта күрми дә калдылар. Аналары куркыныч кыяфәтле, аңардан рәхим-шәфкать көтәрлек түгел иде. Яңа гаиләләренең изгелегенә үрелгән теләсә кем белән үлгәнче сугышырга әзерләр. Орлик алданрак аңга килде. Чабып килгән уңайга ул юлын үзгәртте, шулай да анасы аның бер уч ялын йолкып алырга өлгерде. Күбрәк ышанучан Туры, анасының ыржайган тешләренә илтифат итмәстән, башын сузды, һәм шул ук мәлдә аның иңбашы каты авырту белән тулды, күзеннән яшь бәреп чыкты. Башка атларның дулкынлануы һәм кешнәп куюы биянең хаклылыгын аңлата иде. Шуңа күрә авырту тиз сүрелде, ләкин эзсез югалмады.

Орлик үткәннәрне онытыр да иде бәлки. Шулай булмый хәле юк иде аның. Ул инде барлык атлар да, үзе кебек, җиңел тарантас кына тартып йөрүләре ихтималлыгы белән килешкән иде. Ләкин, тормышта еш кына булгалаганча, көтелмәгән бер хәл килеп чыкты.

Ноябрь урталары иде. Җиргә кар ятты. Беренче кар күренгәнгә кырык көннәр узган иде инде. Карның бөтенләйгә ятканына ышанган авыл кешеләре мал суя башлады, каз өмәләре китте. Кинәт бәргән салкыннар җирне яргаларга да кереште. Егетләр, шаулап-гөрләп, армия сафларына китеп баралар, кайтып төшкәннәренең кайсылары туйлап та өлгерде.

Зоотехник Рәхим Садриевның сөйгән кызы — Кама аръягында. Беркөнне ул Орликны җиңел чанага җигеп алды, мәктәптән сорап торып, дугага көмешле кыңгырау такты, кызыл башлы сөлге урады һәм, бөтен авыл урамына бәйрәм төсе биреп, сөйгән кызын алмага чыгып китте.

Янында — иңенә кызыл башлы сөлге салган, кулында баян уйнаткан кияү егете. Шулай, артларында кар бураны уйнатып, кызарып чыккан кояшка каршы җилдереп киттеләр. Орлик кызлар шикелле биеп бара, бөтен җаны кайный, аякларын гаярь салып барышында — дәрт-дәрман, борыныннан, бөтерелеп, пар чыга, авызлык кигезелгәнгә күрә ирен читләре күбекле,— менә-менә күккә ашып очар кебек.

Кама туңган иде инде. Алай да ике паром кара-каршы йөри әле. Аларның юллары кар яткан боз аклыгында каралып тора. Ике ярга да машиналар чираты тезелгән. Сарыч тавы ягындагы шоферлар җылынырга, чәйләп алырга совхоз ашханәсенә кереп чыккалый, каршы яктагылар учак ягып җылына ахрысы, ул турыда кара төтен баганасы күренә — иске покрышка ягалар булса кирәк. Паромнарның икесе дә теге як ярда. Шоферлар тынгысызлана, кичүне менә-менә ябулары, паромнарның кышкы затонга китеп барулары бик ихтимал иде.

Бозга җәяүле сукмак салынган иде инде. Шуңа күрә Рәхим Садриев паромны көтеп тормыйча, елгага кереп, бозның ныклыгын карап чыкты, халыктан сорашты. Кайсысы кермәскә киңәш итте, кайсысы иңбашын җыерды. Кайсысы, җиңел гәүдәле атка, җиңел чанага сынап, аларны капшап карагач, тәвәккәл төстә кул изәде:

— Егет кешегә диңгез тубыктан! Өйләнәм дигәнгә киртә бармыни ул!

Боз өстен тутырып, малай-шалай хоккей уйный иде. Садриев соңгы киңәшне алардан сорарга уйлады — аларның белмәгәне бармыни!

— Егетләр,— диде ул,— боз ныкмы соң?

— Таш шикелле! — диделәр.— Без ике атна уйныйбыз инде. Иртә белән Савва дәдәй, ат җигеп, Алексеевскийга чыгып китте инде. Әнкәсе авырган, шуны апкайта.

— Аның аты трактор хәтле. Ничава, узды.

— Ә минем ат кош шикелле!

— Күз ачып йомганчы чыга ул! — диеште малайлар, аны куәтләп.

Зоотехник пальто төймәләрен чишеп җибәрде дә, гайрәтләнеп, кошевкасына менеп утырды.

— Син шушында көтеп тор,— диде ул иптәш егетенә.

— Мин кемнән ким? — диде кияү егете, риза булмыйча.

— Юк-юк, үпкәләмә. Сакланганны алла саклаган. Кызы миңа гына кирәк, ә баянчы — туйга.

Кияү егете, сыкы сарган мыек очын чәйнәп, ризасыз төстә:

— Ярый. Мин арттан чыгам,— диде.

Атның дагалы тояклары бозга чакма таш шикелле чакылдап төшә, таеп-таеп киткәндә, ат пошкырып куя, күзен уйната иде. Боз ярчыклары, шрапнель шикелле, атның корсагына чәчри, зыңгылдап, кошевканың алгы такталарына бәрә. Орликның аяклары тыгыз боздан резин туп сыман сикергәләп бара кебек.

Ярдан ерак та китмәделәр, бозның буеннан-буена гайрәтле зың йөгереп узды. Шуннан куркып, ат бер генә мизгелгә туктады да чәбәләнеп таптанып алды, уңлы-суллы каерылды, арткы аяклары алга шуып, тыпырчынып торды, арткы саны бозга тия язып чүкте. Кырпак кар белән капланган боз кинәт зәңгәрләнеп аска иңеп килде.

— Орлик! Но-о-о! Алга, әйдә, алга! — дип кычкырды Садриев һәм, дилбегәне кулыннан ычкындырмыйча, янга сикереп төште. Боз тагын да ныграк сыгылды, ат калтыранып һәм тотнаксыз төстә алга тартылды. Ләкин аның арт аяклары таянычын югалткан иде инде... Боз өстенә кара-кучкыл су бәреп чыкты да ашъяулык булып җәелә башлады.

— Атны җибәр! — дип кычкырды кияү егете һәм, йөгереп килеп, кошевканы янга бора башлады. Хәлне аңлаган ат та кире борылды, ләкин өлгерми калды: аның аяк астындагы боз убылып китте, ул тәртәләргә генә эләгеп тора иде инде. Боз өстендә алгы саны гына калкып калды. Ул кабалана, алгы аяклары бозны төя, корсагын үткер боз кыра иде, куркудан күзе томаланды.

Боз өстенә шоферлар йөгерешеп төште. Кайсысы такта, кайсысы бау әләктереп өлгергән. Ат баткан урынга якын килмәскә тырышып, алар кошевканы арканладылар, ат тыпырчынган саен, чананы аның җаена боргаладылар.

Садриев атны тугарырга, камыт бавын, аркалыкларны, түшлекләрне кисәргә кирәклеген аңлап алды һәм, күп уйлап тормастан, пәке чыгарды да, пальтосын салып, тәртәгә таяна-таяна суга керде. Салкын су, корыч кыршау булып, муенын китереп кысты, бер генә мизгелгә йөрәге тибүдән тукталгандай тоелды.

«Әле дә ярый яр чите,— дип уйлады ул.— Юкса су суырыр да алыр иде». Ул, Орликның аяк астына туры килүдән булдыра алганча качып, атны тынычландырырга тырышып, дирбияләрне кискәләп чыкты. Кешеләрнең ыгы-зыгысы Орликны ярсыта иде. Ул елга өстен тутырып кешнәп җибәрде һәм, азатлык сизеп, бар гайрәте белән алга ыргылды.

Рәхим Садриевка куе чәй эчертеп, тәнен аракы белән уа башлагач, ул яткан урынында балык кебек үрсәләнде һәм йорт хуҗасыннан Орликны берәр җылы җәймә белән каплавын, алдына ашарга салуын үтенде. Хуҗа моны ошатып җиткермичә:

— Үзеңнең хәлеңне уйла башта. Бу коенуыңның нәрсәгә төшәсе билгесез әле. Ә синдә — ат кайгысы,— дип мыгырданды.— Ат — ат инде ул, егет.— Аннары, бөркәнеп яткан зоотехникның урыныннан калкуын күреп: — Яхшы, син дигәнчә булыр,— диде.

Аны көтеп тормастан, кияү егет ат янына чыгып китте.

Тик барыбер җиренә җиткерә алмаганнар ахрысы. Өч ай уздымы, юкмы — Орлик аксый башлады. Ветеринар да аның янында байтак кайнашты, әмма тегенең соңгы сүзе хәерле булмады:

— Аяк тамырлары шешенгән. Дәваларлык түгел, чире гомерлек.

Шулай итеп, Орликның язмышы тагын үзгәрде, дөресрәге, элеккегә кайтып калды. Зоотехник аны җикми инде: өйләнгәч, ат кайгысымы соң? Орликны Хәнәфи агай тагын Туры белән бергә яба башлады. Ә Туры үзенең элеккеге дустыннан читләшкән икән инде, ятсынды, исе китмәде. Аларның уртак утлыгында солы — хәзер бик сирәк сый, ашаганнары салам да печән, эчкәннәре бозлы су. Орликны яңадан Тимоша җигә иде инде. Ул Орликның үзенә әйләнеп кайтуына әллә ни шатлык белдермәде. Аксак атны җиккән вакытта еш кына:

— Кинәндерделәр! Боздылар да кире төрттеләр имеш! Хәзер нәрсәгә ярый инде бу малкай? Матурлыгына чиркәү саласыңмыни аның? — дип сөйләнә иде.

Ул аны әүвәлгечә һәм кызганусыз җигә, һәрчак авызлык кидерә — әйтерсең ат тыеп булмастай шайтанга әверелгән. Авызлыкны чәйни-чәйни, Орликның иреннәре авыртып бетә иде, гүя кызган тимер белән каезлыйлар.

Бервакыт, ат чанасына Тимошаның чамасыз төстә фураж төягәнен күреп, Хәнәфи агай түзмәде.

— Син нәрсә, шаштыңмы әллә? — диде ул ярсып.— Йөрәгең таш икән, валлаһи! Аягы нишләгәнен оныттыңмыни, мәлгунь? Өзлексен, тәмам эштән чыксын, итлеккә китсен дисеңмени?!

Карт кесәсеннән ипи кыерчыгы чыгарды да Орликка сузды. Ат, зәйтүндәй күзләрен зур ачып, гаҗәпләнгәндәй, озак итеп карап торды, алыргамы-алмаскамы дип уй кордымыни. Хәнәфи карт аның боек карашын күтәрә алмады, читкә борылды һәм ишетелер-ишетелмәстәй генә әйтте:

— Күрәсеңме, Тимоша, атларда да акыл бар, әйеме?

Орлик, ниһаять, ипине тешләре белән кыяр-кыймас кына әләктереп алды һәм, нидер уйлаган кебек, туктап-туктап чәйнәргә кереште.

Кичен, һәрвакыттагыча, Хәнәфи агай утарга килеп керде. Сүрән ут яктысында ул Орликның аякларын карап чыкты, канәгать калды.

— Без әле җигүдә, җанкай,— диде ул, аның ялын бармаклары белән аралап.

Килешкән шикелле. Орлик башын чайкап куйды, күптән булмаганча, сак кына аның муенына үрелде. Карт янтаймады, киресенчә, атның сөякчел яңагына башын терәп торды.

— Әй, гомер... Су белән бер: ага да китә икән, әйеме? — диде ул атка, кешегә эндәшкән кебек.

Кайтып киткәнче, ул шулай араталарга кереп-кереп чыкты; йокы алдыннан балаларын юаткан ана шикелле, атларның һәркайсын барлады, әйтәсе сүзен калдырмады, утлыклардан курпыларны алып-алып атты, асларындагы пычкы чүбен тараткалады, мал тозларын җайлап-җайлап куйды...

Кышкы гадәти тыныч һәм серле кич җитеп килә иде. Кыршылган тимер акчага охшаган айның йөзе яктырган, аның нуры түбәдәге шифер читләреннән сузылып төшкән беренче нечкә боз сөңгеләрен зәңгәрләтеп тора. Хәнәфи агай авыр эштән соң йоклаган атларның тирән сулышларын тойды, пошкыруларыннан кайсысын ни борчыганын билгеләргә тырышты. Ул Орликны күз алдына китерде. Туры, тәгаен, башын аның муенына салгандыр һәм алар шул көйгә бер-берсен тыннары белән тынычландырып, тигез, тирән сулыш алалардыр...

..................

# Фәнис Яруллин

## Җыр башы

Яшел кара белән
Шигырь язды шагыйрь,
Һәр сүзендә аның наз иде.
Йотылып укыды бу шигырьне һәркем...
Ә шагыйрьнең исеме — Яз иде.

Нота язды яшен бу шигырьгә,
Һәм яфраклар аны җырлады.
Дәртле җилләр дирижерлык итте,
Башын иеп, дөнья тыңлады.

Күңелләрдә ярсу елга булып,
Әллә нинди якты нур акты.
Кошлар кауриеннан моңнар тамды,
Ак болытлар булып, җыр акты.

Шушы җырда, гади генә җырда
Күпме көч бар, күпме ашкыну!
Кырда иген булып шаулаячак
Җәйге симфония башы бу.

## Рәнҗемәсен

Тезелешеп очкан кыр казлары
Чагылып китсә әгәр офыкта,
Кемдер карый, кулын кашына куеп,
Кемдер — бармак салып курокка.

Кош-кортларга кемдер җимнәр куя
Һәм ышыклый зәһәр суыктан.
Ә кемнәрдер читлек элеп куя
Үреп каты тимерчыбыктан.

Кемдер чишмәләрнең юлын ача,
Ә кемнәрдер китә томалап.—
Дөнья бит бу, ә дөньяда инде
Төрле хәлләр тора булгалап...

Табигать ул үзен яклый алмый,
Үч тә ала алмый кешедән.
Ул бары тик рәнҗи генә ала,
Куркыйк шушы рәнҗеш төшүдән.

Рәнҗемәсен безгә очар кошлар,
Рәнҗемәсен күлләр, урманнар.
Рәнҗемәсен Кояш, Җир һәм күкләр,
Рәнҗемәсен безгә ал таңнар...

Рәнҗемәсен, үзенең яклаучысы
Кеше икәнлеген белсен ул.
Яңгырлары белән еласын да
Кояшлары белән көлсен ул.

---

ФӘНИС ЯРУЛЛИН *(1938) — шагыйрь, «Мин тормышка гашыйк», «Аерылмас дустым», «Табыну» һ. б. шигырь китаплары авторы. Проза һәм драматургия өлкәсендә дә эшли. Татарстан АССРның М. Җәлил исемендәге комсомол премиясе лауреаты. Казанда яши.*

## Күмелеп калмасын

Улым да юк минем, кызым да юк,
Җимешсез шул нәсел агачым.
Белеп торам, нәсел агачымның
Озакламый җиргә авасын.

Тик мин, җирдән мәңге киткән чакта,
Теләп эчтән соңгы теләкне,
Дусларымның хәтер учагына
Күмеп калдырырмын йөрәкне.

Кирәк кеше аннан ут алыр да
Үз учагын куяр тергезеп.
Йөрермен мин җаннан-җанга күчеп,
Йөрермен гел шулай җир гизеп.

Шушы булыр минем улым-кызым,
Шушы булыр минем дәвамым.
Дусларымның хәтерен көл басмаса,
Гел янармын, күмелеп калмамын.

## Килә калса атом кышы

Тимерләр сынган салкында
Чыдаса да әле кеше —
Чыдый алмас, өшер-туңар
Килә калса атом кышы.

Талпыныр да егылып төшәр
Күкнең җаны — очар кошы —
Дөньяны көл белән каплап
Килә калса атом кышы.

Ургып-ургып, сулар акмас;
Ыргып-ыргып, тайлар чапмас.
Галәмгә очкан кораблар,
Төшәр өчен, Җирне тапмас.

Кояш нурын кұралмыйча
Гөлләр үләр сабагында.
Күз яшьләре катып калыр
Җирнең ике яңагында.

Һәм бу яшьләр мәңге эремәс.
Соңгы нәфрәт булыр шушы —
Кояш суыныр, Җир әйләнмәс
Килә калса атом кышы.
Исеңдә тот шуны, Кеше!

●

— Кая ашыгасың, кеше?
— Берәүгә илтәм шатлык.
— Алайса, берүк, туктама,
Ашык, дускаем, ашык.

— Нигә бик әкрен барасың,
Ни булды, әйтче, кеше?
— Адымнарым шуңар әкрен,—
Мин — кайгы хәбәрчесе.

— Миссияң авыр икән дә,
Тик син барыбер ашык.
Билгесезлектә яшәүдән
Ачы хакыйкать яхшы.

●

Кайгы килсә — чигенер,
Уңышсызлык — җиңелер.
Сагыш басса — таралыр,
Шатлыклар бер яңарыр.

Оят кына килмәсен,
Хурлык кына килмәсен.
Кайгыдан иелсә дә, баш
Хурлыктан иелмәсен.

## Автобиография

Уйнадым — уйладым,
Еладым — сынадым,
Абындым — егылдым,
Кагылдым — сугылдым,
Моңайдым — елмайдым,
Ашкындым — шашындым,
Кабындым — табындым,
Ышандым — бушандым,

Таныштым — кавыштым,
Айкалдым — чайкалдым,
Дауладым — яуладым,
Чәелдем — чигендем,
Сөендем — көендем,
Карыштым — тартыштым,
Алыштым — ябыштым,
Атылдым — ватылдым,
Ирештем — бирештем...

## Сөенәм

Кичә генә яткан идем
Тартышып мин үлем белән.
Бүген менә бер сәбәпсез
Елмаям, сөенәм, көләм.

Сөенәм кошлар сайравына,
Сөенәм яфрак шаулавына,

Сөенәм — якты яз кояшы
Тәрәзәмнән каравына.

Сөенәм бала-чагаларның
Чыр-чу килеп чабуына.
Сөенәм хәтта... үземнең мин
Шулай сөенә алуыма.

❁

Кем өчендер Җир түгәрәк,
Кем өчендер ул — яссы.
Бәхәс чыкса, үзен генә
Хаклы саный һәркайсы.

Ә хакыйкать, үзен яклап,
Сүз әйтми — тыныч тора.
Чын һәм ялган арасында
Кынысыз кылыч тора.

❁

Тауга менеп таш кубарды кеше,
Салыр өчен аны нигезгә.
Таш астында елан ята иде
Бөгәрләнеп җиде-сигезгә.

Гаҗәпләнеп карап торды елан,
Оясыннан чыгып качмады.
Шушы көннән бары тел очында
Агу саклап йөртә башлады.

## Китеп барам

Гомер агачымның яфраклары
Коелып бетеп бара — мин беләм.
Калганнары өзеләм-өзеләм диеп
Тартышалар әнә җил белән.

Тик шулай да җанда үкенү юк,
Анда бары якты моң гына.
Китеп барам офыкларга таба
Сиздермичә генә, тын гына.

Сыкранулар, уфтанулар нигә? —
Яшәләсе инде яшәлгән.
Гомер агачымның яфраклары
Туып-үскән җиргә төшәлгән.

Шуннан артык нәрсә кирәк безгә?
Шул бит инде яшәү максаты.
Соңгы яфракларым тибри җилдә,
Ә күңелдә, никтер, яп-якты...

●

Теткәләнә, туза бик тиз —
Мишень бит безнең йөрәк.
Тузмас иде, бер-беребезгә
Булсак мәрхәмәтлерәк.

Елмайсак, куллар кысышсак,
Йөрешсәк әгәр күбрәк,
Булыр иде бу дөньялар
Тагы да мәхәббәтлерәк...

Җирдә күпме кешеләргә
Кирәк таяныч, терәк.
Мәрхәмәтебез белән без
Булыйк мәһабәтерәк.

●

Син миңа елмая күрмә
Шаяртып та, ялгыш та.
Очармын синең артыңнан
Әверелеп бер кошка.

Калмамын кая барсаң да
Көнен дә, төннәрен дә.
Ял иттерми калалмассың
Үзеңнең иңнәреңдә.

Ә иңнәреңә бер кунсам,
Төшәсем килмәс мәнге.
Син миңа, берүк, елмаеп
Карама инде, яме.

●

Син килдең, юк, син килмәдең —
Яшьлегемнән хәбәр килде,
Шау чәчәкле язлар килде,
Назлы йомшак җәйләр килде.

Син килдең, юк, син килмәдең —
Гөлбакчама кошлар килде:
Әллә кайчан онытылган
Татлы, матур төшләр килде.

Син килдең, юк, син килмәдең —
Тып-тын күлгә давыл килде;
Ярсыды күл, кайнады күл,
Дулкыннары авыр иде.

Син килдең, юк, син килмәдең —
Учагыма бер ут төште.
Җылыныйм дип, кулым суздым —
Тәнем пеште, җаным пеште.

●

Кемнәр килеп, кемнәр китми җиргә,
Җир ул — биографияләр китабы.
Язмышымны мин дә яздым шунда,
Халкым куяр соңгы ноктаны.

**Рәисә Әбүбакирова**

# КАРТЛАР НИГӘ ТУҢА

хикәя



Зарифа карчык мич башында ята. Вакыт дип аталган иксез-чиксез бушлыкта мич әкрен генә йөзә, һәм Зарифаның баш өстендә эленеп торган түшәм бер якка җиңелчә генә авышып киткәндәй була. Монда ярым караңгы, тыныч, бары чуар чаршау гына ара-тирә селкенгәләп куя. Иләнгән сарык тиресе һәм киез итек исләре аңкый.


— Син, әбекәем, капитан күперчегендә шикелләрәк,— дип ягымлы эндәшә торган иде оныгы Габделфаяз, аңарга баскычлы күперчәдән аска төшәргә булышканда.

Кайчандыр Зарифа бу баскычлардан үзе генә дә бик иркенләп төшә, комган тотып ишегалдына чыга һәм намазлыкта дога кылып алганнан соң, тавыш-тынсыз гына мич башына үрмәли иде. Хәзер тәнендә җегәр кимеде, һәм ул, туганнары тарафыннан очраклы рәвештә онытылган кунактай, үз дөньясында салмак кына яшәп ята. Мич сәндерәсендә ятып тәмам өшәнгән карчыкны, аның көйсезлегенә зарлану белдереп, кече оныгы Марат чәйгә алып төшкәли. Яшь, кайнар Марат шуны аңламый: Зарифага бик тә салкын, өстенә әллә ничә кат тун бөркәсәләр дә җылы сеңми аңа. Менә ничәнче көн һәм төн инде Зарифа карчык, иң вакытлы чакта ходайдан чакыру килмәвенә эчтән генә офтанып, каядыр чаршау артында гына барган ерак-ерактагы тормышы белән төшләнә.

Кемдер ишек ачып керде булса кирәк, чаршау селкенеп куйды. Салмак, тупас, ирләрчә адымнар. Габделфаяз кайтып керсен иде. Ул әбисен беркайчан да онытмады, янәшәдә яшәгән чакта һәр кичне йөгереп керер иде. Үзенең гаиләсе белән шәһәргә күченеп китте шул. Бөтенләйгә. Зарифаны да үзләренә алдырды. Оныгының җәмәгате бик әйбәт хатын, карчыкны беркайчан да кыерсытмады, әмма зур бәла килде үзләренә: армия хезмәтендә Габделфаязга озак вакыт салкын су эчендә торырга туры килә, өенә дә, матрос киеме өстеннән ялтырап торган муенса тагып, вакытыннан элек әйләнеп кайтты,— авыру ул, ә өйләре тулы балачага. Менә шуннан соң Зарифа, күпме генә үгетләмәсеннәр, улы Дәүләт янына кайтып сыенды.

---

РӘИСӘ ӘБҮБАКИРОВА — *яшь язучыларның VIII Бөтенсоюз киңәшмәсендә катнашкан автор. Омск шәһәрендә яши һәм төзүче булып эшли.*



А. Тимергалина рәсеме

Сөенеп туя алмый Зарифа: Габделфаяз әйбәт кеше булып үсте. Аның кадерле булуы моның өчен генә түгел, әлбәттә. Әле малай чакта ук өстенә текәлә дә телсез кала иде Зарифа: сугышта ятып калган олы улына коеп куйгандай бу кадәр дә охшаса охшар икән оныгы! Зарифаның олы улы тимер танк эчендә янып үлде. Габделфаяз армиядән кайту белән, ул аңардан бары бер нәрсәне сорады:

— Улым, танкны үз күзләрең белән күрдеңме?

— Күрдем, әбекәем,— дип елмайды оныгы,— һәй, күп күрдем мин аларны!

Зарифа исә елмаймады. Габделфаяз әбисенә текәлеп карады, аның көрән кыйгач күзләрендә ниндидер очкын җемелдәп алды. Бер атнадан ул Зарифаны үзе белән киногa барырга ризалатты. Карчык баштарак курыкты; ирләр җыелган урында күренеп йөрү гөнаһ иде, ләкин каһәр төшкән танкларны да бик күрәсе килә иде аның. Керде, клубтагы сөйләшкән авазлар шундук тынып калды, кемдер гаҗәпләнеп тел шартлатты, әмма үзенә хөрмәтләп кенә урын бирә белделәр.

Һәм ул үз гомерендә беренче тапкыр озын борынлы, килбәтсез кара ящикларны күрде; алар туп-туры Зарифа өстенә киләләр, төтен эчендә маңгайга-маңгай чәкәшәләр дә тузгып-үкереп яналар. Зарифа түзмәде, чырыйлап кычкырып җибәрде: шуларның берсендә аның улы да янган ич...

Чаршау ачылып китте, караңгылы-яктылыда тоныкшәүлә пәйда булды, аннары Маратның күк күкрәгәнгә тиң тупас тавышы яңгырады:

— Исән? Күрәм, син безнең мәңгелек җан икәнсең. Нәрсә кирәк?

Зарифа бик начар күрә, ә Марат, сөйләшми торганда, Габделфаяз абыйсына охшаган, әмма ите-сөяге белән генә охшаган шул.

— Бичара Габделфаяз,— дип пышылдый карчык.

Баш югала, пәрдә артыннан:

— Әби саеккан, сөйләнә, мине танымады,— дигән сүзләр ишетелә.

— Вакыт инде,— дип, Маратның әтисе Дәүләт күңелсез генә әйтеп куя.— Тиздән йөзне тутырачак. Аллядан һаман да гомер сорап ялварамы әллә ул?

Улына рәнҗеми Зарифа. Үпкәләгән чаклары булды булуын, мич башына хәсрәтле уйларын төяп менә дә, газизләре өчен борчылу һәм кешеләргә тартылу гаменә йотылгач, мич җылысында рәнҗүләре йомшап китә иде. Дөньяда күпне кичерде ул; суынып килгән күкрәгендә юк-барга тавышланып, ызгышып бер-берсен җәфалаган ыгы-зыгылы балаларына карата гына күпмедер кызгану хисе җылынып тора. Карт булса да, Зарифа барын да ишетеп ята. Чаршау артында ниләр эшләнә: бала еламыймы, шулпа ташымыймы,— боларның һәммәсенә дә колак сала карчык; оныклары тәгәрәп үсте, шулпаны килене — Дәүләтнең хатыны карый, ә менә дөньяга күз-колак булу гадәте һаман да канында калды аның.

Зарифаның колагы үтә сизгер. Кыз чагында ук инде ул бүтәннәр ишетмәстәй йомшак авазларны бик тиз сиземли, шуларны үз тавышы белән кабатларга тырыша иде. Бер хәллерәк адәм Зарифаның җырлавына мөкиббән китә һәм аны — кухня тирәсендә хезмәт итүче кызны — байдан хатынлыкка сатып ала. Төнге күңел ачулардан соң ире нибары ике сүз белән боера торган иде:

— Җырла, сандугач!

Тыңламый хәле юк, ире җикеренә күрмәсен дип, Зарифа калтыраулы тавыш белән җырлый башлый. Җыр тегене уйга сала, үзенең көчәя барган тавышына ияреп, Зарифа урыныннан кузгала, нечкә билләрен дәртле хәрәкәтләндереп, ялангач аяклары белән идән өсләтеп йөзә...

Менә шушы чамадан тыш тәвәккәл биюгә кушылып, мич тагын да ныграк әйләнә-бөтерелә башлый. Кинәт кенә мизгел эчендә кызыл йөзле, чуалчык чәчле, симез ире күз алдына килеп баса: ул шундый еракта һәм шундый кечкенә-көлке булып күренә ки...

Карчык, сыңар теш кенә тырпаеп калган казналарын шәрәләндереп, үзалдына тавышсыз гына елмаеп куя.

— Менә шайтан! Җырлый бит теге карга. Әти, ул гауга чыгармас микән? — Маратның хәвефле тавышы төш дигән дөньялыкка бәреп керә.

— Чыгармас,— дип җавап кайтара Дәүләт.— Көче юк бит аның.

...Әйе, ире икенче хатын алып кайткач, каргага әверелгән иде ул. Зарифа балалары белән чоланга күченде, ире исә, аны очрату белән ямьсез итеп сукрана торган булды:

— Аяк астында буталып йөрисең шунда, карга!

Әнә шундый очраклы очрашуларның берсеннән соң төпчек баласы — Дәүләт дөньяга килде. Күрәсең, ураза аенда аракы эчеп, ире аны яшь хатын белән бутады булса кирәк.

Ходайның ачуын китергәндер шул: яшь-усал хатыннан урлап, бер вакыт балаларына коймак ашатты, аннары менә кино дигән зәхмәтне карады. Ходай үз рухына чакырмый икән, димәк, әнә шуларны гафу итми ул. Ни өчен чакырмаганын да яхшы белә карчык: әгәр яшәүне өр-яңадан кабатлыйсы булса, ул барыбер теге чактагы коймакларны тагын әләктерер, улы дөрләп янган тимер ящикны күрергә ашкыныр иде — ходай шушы яшерен уйларын сизгән ахрысы.

Сөйкемсез ирен, кулак дигән җисеме-ние белән, Себер дип аталган исеменнән үк якты салкынлык бөркелеп торган ерак җиргә сөрделәр. Икенче хатын суга чумгандай юкка чыкты. Йортны мәктәпкә дип алдылар. Зарифага исә тәрәзәләре кадакланган, уртасында миче булган бер буш йортны бүлеп бирделәр. Өлкән улы мич киңлеге итеп такталардан бүлем ясагач, кухняга тоташкан кечерәк ике бүлмә барлыкка килде. Авылга нишләптер күңеле ятмады беренче малаеның, гаиләсен алды да мануфактура эшенә китте. Зарифаның улы әйбәт иде. Нигә иң яхшы балалар гына әниләреннән читкә китә икән? Эшендә бик хөрмәтләделәр үзен, матур-матур ситсы төргәкләре белән бүләкләделәр, ул аларны әнисенә җибәрә торды. Улы өчен горурланып, аларны күршесенә күрсәткән иде, теге исә авыл советына барып «тишкән». Килделәр, улының халәл бүләкләрен кайтарып алдылар, кулак иренең байлыгын яшереп яткыра дигән сылтау белән Зарифаны да ире артыннан җибәрделәр. Күпме генә еламасын, ялвармасын — бай хатыны имеш!..

Һәм менә мич тагын чайкала, әллә кайдагы билгесез Себергә барып чыга. Таш ятак кинәт җилкәләрне туңдыра, карчыкка салкын булып китә. Бер чынаяк чәй булсын иде хәзер, юкса тәмам эченә суык йөгергән. Ә аяклар бөтенләй берни сизми, гүя алар Себернең үзендә торып калган. Өлкән улы Себердә чакта да ташламады: Мәскәүдәге зур-зур гына йортларга тикле барып җитте, бер елдан әнисен кайтартты. Ул елларда Зарифа күпне күрде, күп кешеләрне очратты, күп нәрсәгә төшенде: шул кадәрле халык арасыннан бер гап-гади татар хатынын кем генә хәтерләп торыр икән! Ләкин мәсьәләнең төбенә төштеләр, Зарифаны кайтарып җибәрделәр. Югарыдагы зур кешеләргә рәхмәт инде, ходай шикелле, аны онытып бетермәгәннәр. Көн уртасында Зарифа үр башына күтәрелде, тирә-якка күз ташлады һәм таң калды: әнә, каршында Идел буе даласы җәйрәп ята! Күкрәген тутырып һава сулады да әрем исе аңкып торган бәхетеннән елап җибәрде ул.

Кызының гаиләсе якты каршылады, ә Дәүләт акылга сыймаслык булып үзгәрде, тупасланды, әнисе өчен оялган булып кыланды. Өлкән улы хәлен белергә еш кына килеп йөрде, элеккеләренә карый да матуррак күлмәкләкләр бүләк итте. Аны соңгы тапкыр күрүе икәнен Зарифа башына да китермәде ул чакта. Сугыш чыгып, озак та үтмәгәндер, өлкән улының кара хәбәре килде. Зарифа үзенең кайгысын мич артына яшерде, инде кече улын саклый күрсен дип, иртә-кич аллага ялварды...

Мич башына, мышный-мышный, Маратның биш яшьлек кызы үрмәләп менде, ялтырап торган күзләре белән озаклап әбисенә карап торды.

— Дәү әнием, чәй эчәсеңме?

Чәйне гомердә теләмәгәнчә эчәсе килгән чагы, әлбәттә! Мич инде җылытмый, күрәсең, аңа начар ягалар; тамагы кипкән, иреннәреннән бер

генә сүз дә шуып чыгарлык түгел. Карчык зур кыенлык белән булса да авырайган кулын күтәрде, елмая төшеп, кәкре бармаклары белән куркуны белми торган оныгының башыннан сыйпады һәм кинәттән ни өчен балаларга караганда оныкларның кадерлерәк булуын аңлады. Беренче онык туу бөтенесен каплап китә икән: алар бер-бер артлы ишәя торалар, асларына саласы киезләре дә күзгә күренеп ишәя, озыная. Дәүләттән генә дә карчыкның ун оныгы бар, кызының һәм фабрикада эшләгән өлкән улының балалары тагын күпме диген, инде оныкларының балалары да байтакка җыйнала бит. Зарифаның нәсел-нәсәбе зур, таза, дөньяга аның күпме дәвамы сибелгән, шуларның һәркайсында Зарифадан нәрсә дә булса саклана лабаса! Бу урында карчык горур бер коркылдау белән хәтта елмаеп та куйды.

Мич тагын бер тапкыр зур һәм салмак әйләнеш ясап алды, түшәм кинәт юкка чыкты, Зарифа биек-биеккә күтәрелде һәм үзенең каршында дарчин төсендәге буш, соры җирне күрде, көтелмәгәнчә якты, үткер хәтере белән аны шундук танып алды: миллион еллар элек үз кайнарлыгында әвәләнгән җир инде туң катламга әверелгән иде. Җир яшәрсен өчен, Зарифа нишләргә тиеш соң?.. Ул хәлсез кулларын тәне тирәсенәрәк елыштыра, гәүдәсенең авырайганын сизгәннән соң аска — төпсез упкынга таштай томырыла. Ул инде нишләргә кирәген яхшы белә. Аңа вак кисәкләргә уалырга, шушы кырыс җиргә вак орлыклар булып чәчелү өчен челпәрәмә ватылырга кирәк; аның зирәк орлыкларыннан җирдә ап-ак авыллар үсеп чыгачак һәм алар, Зарифа токымының дәвамы булып, һаман саен артып торачак. Чылбырдай тезелгән ак авыллар — Җирнең мәңгелек җыры.

Русчадан **Рашат НИЗАМИЕВ** тәрҗемәсе

# Кадыйр Сибгатуллин

## Безнең моңнар

Моңлы дөнья,
моңлы тормышыбыз...
Безнең ишеләрне моң баса.
Моңлы җаннар Җирдә булмас иде,
моңлы дөнья әгәр булмаса.
Үзе уйный,
үзе җырлый күңел.
Моңнар белән тулган ул күңел.
Лачын итеп күккә алып менә,
безнең моңнар — мескен моң түгел.
Кирәк чакта иңә алар безгә,
әкрен генә иңә,
сиздерми.
Гел чистартып тора җаныбызны,
дөньялардан безне биздерми.
Яшел бөре булып агыла моң,
яшел яфрак булып ярала.
Сары яфрак булып җиргә ята,
кар бөртеге булып тарала.
Әкрен генә аткан таңнар моңлы.
Кояш моңлы.
Моңлы иртәләр.
Җилләр булып кына исәләр дә,
моңнар безне кеше итәләр.
Иркә генә,
йомшак кына алар,
гүя сөйгән кызлар карашы.
Шушы моңнар ялап алды инде
йөрәкләрнең күпме ярасын!
Кырлар моңлы.
Моңлы авыл, шәһәр...
Моңлы сулар,
моңлы һавалар...
Сөйгән ярлар моңлы,
моңлы бала,
моңлы безнең ата-аналар.

Моңлыларга башны иеп үтәм.
Моңсызны да булды күргәнем.
Беркайчан да мин күрмәсәм иде
дөньяларның моңсыз көннәрен!

---

КАДЫЙР СИБГАТУЛЛИН *(1942) — шагыйрь, «Әманәт», «Гамь», «Авазлар» һ. б. шигырь китаплары авторы. Брежнев каласында яши.*

## Глобус

Алып кайтып куйдым өстәлемә.
Кирәкме ул миңа,
түгелме?
Чын Җир шары түгел икәненә
ышандыра алмыйм күңелне.
Һәр көн саен аңа күзем төшә.
Карап чыгам,
барлыйм,
тикшерәм...
Һәр шәһәрнең кайсы параллельдә
торганлыгын яттан мин беләм.
Елгаларын карыйм,
диңгезләрен,
йөреп чыгам кат-кат тауларын.
Сәяхәттә минем кичләр була,
сәяхәттә ата таңнарым.
Җир шарымны һаман әйләндерәм.
Һәр ноктасын аның барлыйм мин.
Һәр көн саен,
Җиргә соңгы тапкыр
караган күк әрнеп карыйм мин.
Әйтерсең мин бер авыру саклыйм.
Үзем белмим:
исән калырмы? —
Җибәрергә Җирнең тамырына
сорарлар күк әле канымны.
Инде үзем авыру мин хәзер.
Бу тәннәр дә бүген чирдәдер...
Авыруым бәлки бетәр иде,
вируслары аның Җирдәдер.

## Карлар

Көтмәгәндә
(әллә көткәндәме?),
бер болытсыз ява карларым.
Дөньяларга бүген тагын бер кат
ап-ак карлар аша карадым.
Рәхмәт әйттем мин күкләргә карап,
рәхмәт әйттем ап-ак карларга.
Мин кулымны куйдым тагын бер кат
«Яшәү матур!» дигән карарга.
Кемнәргәдәр бәлки гади кардыр,
минем өчен гади кар түгел.
Ясын әйдә сезнең иңнәргә дә,
минем күңел алай тар түгел.
Кар яуганын бик күп күргәнем бар,
көткәнем бар карлар яуганын.
Бу тормышта минем иңнәремә
чиста карлар гына яумады...
Барысын да юды шушы карлар,
пычрак тормый минем өстемдә.
Рәхмәт сезгә,
минем ак карларым,
күңел сафлыкларым өчен дә...
Рәхмәт сезгә
яуган өчен,
миңа
шатлык, юанулар китереп.
Кар бөртеге очып йөри күктә
безне уйлы-моңлы иттереп.
Бик сөенеп күккә карап торам,
рухым бүген түгел ялангач,
бу дөньяның шушы карлары да,
куандырып, мине ява алгач!

## Шул бер ишек

Кайткаларга кайчак туры килә
авылларга —
туган бишегеңә.
Яшәсәк тә күптән шәһәрләрдә,
без өйрәнгән авыл ишегенә.
Шыгырдаса бераз шыгырдасын.
Дерматин да аңа кагылмасын.
Тупасрак була булсын бераз,
жеге-жеккә килеп ябылмасын.
Ачып керү шуны күңеллерәк,
күңеллерәк шуны ябып керү.
Күңеллерәк үзең белән бергә
берәр кочак суык алып керү.
Бусагадан аяк атлаганчы,
минем күңел инде кереп китә.
Бераз гына туңган булса, йөрәк
каз мае күк кинәт эреп китә.
Алып керә килен сөт исләрен,
энекәш кайта арыш исе белән.
Бер ачылып,
бер ябылып тора
шул бер ишек авыл хисе белән.
Кичләр җитсә,
урамнардан җанны
тирбәтерлек моңнар, көйләр керә.
Шәһәремә кайтсам, өч көн тоташ

төшләремә шушы өйләр керә.
Ачык калган авыл ишегеннән
шаулый урман,
шаулый чишмә,
инеш...
Бер кечкенә шушы ишек аша
киенмәгән,
төренмәгән килеш
тормыш үзе,
яшәү үзе көн дә
кереп, чыгып тора,
йөреп тора.
Мөлдерәгән моңлы күзе белән
минем күңел шуны күреп тора.
Без өйрәнгән:
авыл ишекләрен
Ачып-ябып үскән малайлар шул —
инде хәзер дерматинлы ишек
ачып керә торган агайлар шул.
Суыгы да керми...
җылысы да...
Бөтенесе тышта кала хәзер.
Агайлар без, дим дә,
без,— мөгаен,
балалыгын җуйган бала хәзер.
Күңелләр бай әле.
Әле ярый
шул ишекләр ачык безгә һаман.
Мин авылга барып кайткан саен
күңелемә нидер алып салам.
Бар хәзинәм шунда ята минем,
мин кисәкләп аны алып кайтам.
Ничә кабат ярлы килеш китеп,
ничә кабат шуннан баеп кайтам!
...Күп нәрсәләр җитми безгә бүген,
авылда да җитми — үзем беләм.
Гомер буе җитми шул бер ишек,
алып кайтып булмый үзең белән!

## Мәгънә киңәйгәндә

Көтмәгәндә
шундый бер көн килде,
язмыш аңа:
— Гомерең бетте! — диде.
Белә иде.
Ул бу көнне көтте.
Иң авыры
инде баштан үтте.
Кырда үскән
чәчәк сорап алды.
Язмыш белән
бер ялгызы калды.
Бу чәчәккә
карап туймады ул.
Исе китеп,
шуны уйлады ул:
«Бу чәчәкне
күпме күргәнем бар.
Бу чәчәкне
таптап йөргәнем бар...
Ант итә алам,
шунысы да хактыр —
күрәм аны
мин беренче тапкыр».
Елады ул:
— Рәхмәт сиңа, үлем!
Синең аша
матурлыкны күрдем
мин бары тик
әле бүген генә...
Язмышымдыр...
риза үлемемә.

Кинәт кенә
каян килде кодрәт?
Кинәт кенә
еш-еш типте йөрәк...

Әйтте язмыш:
— Тагын ялгышканмын,
күзгә карап
алдадылар тагын.
Кырда үскән
кыргый бер чәчәк тә
тыгыла бит
минем киләчәккә!

# Рәфикъ Юнысов

## Дәште съезд

— Кыю җаннар кирәк, фидакарьләр!
Бу — дәвамы каты көрәшнең! —
Шулай дәште съезд.
Сорады ул
Координатын минем йөрәкнең.

Йөрәк әле интим орбитада.
Түбән әле аның очышы.
Кыю сүзне, әрнеп, ярып салам
Тик хатынга —
Шуңа эч поша!

Бер солдаты аның санал да син,
Партияңнән, имеш, тел яшер!
Минсезләндерелгән сыек «без»дә
Уй-теләкләр ничек берләшер?

Күпме була качып үз «мин»еңнән,
Болай да бик кыска гомердә?!
Икеләнми, әнә, яңгыр коя...
Менә болыт уза дөбердәп...

Кояш чыкты балкып:
Үзе килеш
Үти безнең уртак теләкне.
Кояш — үрнәк:
Актив орбитага
Күчерергә кирәк йөрәкне!

## Синең кулың

*Абыема*

Бакчага да әле йөрми идем,—
Колагымда чыңлый шул чактан —
Туганнармы, әллә күршеләрме
Әйтте:
— Мәсгуть кулын югалткан!

---

РӘФИКЪ ЮНЫСОВ *(1943).— «Вакыт чылбыры», «Җирдә яшим» исемле шигырь китаплары авторы. Казанда яши.*

Интеккәнем шунда аңламыйча:
Ни сөйлиләр — чынмы, ялганмы?
Ничек югалган ул? Атакага
Барган чакта төшеп калганмы?

Ун кул күтәрмәсне күтәрә алды
Шушы уң кул, шушы уңган кул.
Мең төрле эш белде.
Ә сул кулың...
Инде аңлыйм, югалмаган ул.

Уйлыйбызмы: нигә тыныч дөнья?
Безгә нәрсә — уйна-көл генә...
Кулың фашизмны бугазыннан
Буып тора. Кырык ел менә!

## Теләк

Аста — бит-бит — усал тарих.
Аста сугыш — мең катлам:
Күпме ачу, үч һәм ярсу
Җирдә күмелеп калган.

Һаман әле тынышмыйлар —
Анда да орыш бара:
Канлы-ташлы бу катламнар
Сугышалар үзара.

Урын даулый, кысрыклый,
Бер-берсен ватып тора.
Шуңа бит ул җир тетри,
Вулканнар атып тора...

Өстә — Кояш, янда — гөлләр,
Әй, яшәп калыйк әле!
Беренче тыныч катламны
Менә без салыйк әле!

❁

Йокылы пыяла аша
Карыйм төнге дөньяга.
Бернинди дә хәрәкәт юк,
Тик бары вакыт ага.

Ага вакыт Идел булып,
Урамнарны тутырып.
Алып китә үткәннәрне
Чуп-чар төсле юдырып.

Агыза ул кораб итеп
Хәзер безнең өйне дә...
Билгесезлек чоңгылында
Батырыр ул мине дә.

Бар да бата. Кала бары
Биек бер илаһи яр:
Балкый анда гомер бакый
Йолдызлар һәм даһилар...

❁

Арттан килеп, җан турына
Бата йөзе балтаның.
Кан йота гаярь имәннәр,
Пакь каеннар ватаны.

Тимер күптән агач нәслен
Корытырга кызыга.

(Тик... хыянәт кулы гына
Шулай белеп сузыла.)

Кычкыра күгәрек тавыш
Металл телдә: «Әйдә, чап!»
Агач телен, имеш, күптән
Оныткан ул, өрәңге сап!

## И, каләм

И, каләм, ник төртеләсең,
Юртасың да чак кына?
Кәгазь — ап-ак, үзең — алтын,
Юкса чап та чап кына!

Шәмем якты, күзем үткен,
Кул да әле нык, шөкер.
Йөрәк тә сау. Бумый ютәл.
Тамагым да тук, шөкер.

Ник тукталдың, үтәлмыйсың
Кайсы текә тауларны?
Син гаепсез. Җанда бугай
Куркаклык тышаулары.

❁

Әкиятләр һәм ялгызлык сөйгән
Уйчан күзле бала идем мин.
Матурлыклар тоеп, күңелемә
Өмет белән бага идем мин.

Җылы яңгыр көткән бөре кебек,
Үзгә язмыш һаман көттем мин.
Юл читендә үскән гөл күк, майлы
Тузаннарга батып беттем мин.

Су буеннан искән саф җил булып
Нидер сөйли һаман киләчәк.
Мин һаман да әле бөредә күк,
Атармын күк бер көн ал чәчәк.

## Йолдызга

Менә бит бүген дә
Син минем күгемдә
Янасың. Ә үзең —
Чиксезлек чигендә,
Төпсезлек төбендә.

Хәлең ни? Бәгъреңдә
Утың күп калдымы?
Ни хәбәр нурларың —
Шатлыкмы, кайгымы?

Очасың сызгырып
Киләчәк көннәргә.
Ниләргә юлдаш син,
Кояш син кемнәргә?

Кемнәр чәч киптерә,
Тезелеп, яныңда?—
Әллә син учакмы
Исемсез болында?

Янасың — талпыну,
Дөрләүләр — әрәмгә —
Бер бизәк булып тик
Минем тын тәрәзгә?

## Зиннур Хөснияр

# СЫҢАР КАНАТ

хикәя



Сабирулла карт бәрәңге бакчасындагы тирәккә өр-яңа нарат такталарыннан сыерчык оясы ясап куйды. Аннары читкә, лапас янына ук китеп, үз эшенә сокланып карап торды. Мондый ләззәтне аның инде күптән татыганы юк иде.

Бу уй аның башына карчыгы Мәһитап гүр иясе булгач, узган көз үк килгән иде. Дөнья мәшәкатьләре белән шушы көнгә чаклы кулы җитмәде. Моннан бер ай элек, авырып, түшәк өстенә егылгач, әйткән нәзерем тота ахры дип, күңеленә шик керде. Менә бүген, алҗыган гәүдәсендә бераз көч сизүгә, таңнан ук торып, утын әрдәнәсе өстендә яткан такталардан оя әмәлләде.

Кичә төш вакытларында бәрәңге бакчасы артындагы инешнең бозлары шартлап ярылырга кереште. Тәрәзәдән, мүге череп, тузанга әйләнә башлаган бүрәнә араларыннан үтеп, яз өйгә тереклек сулышы өрде. Картның гәүдәсе җиңеләеп, сөякләре җылынып китте. Нәзере җиренә җиткерелгәч, күңеле тынычланып калды.

Аннары, тәненә җыела башлаган көчен сынап карарга теләгәндәй, сул беләгенә шыгырдап торган каен утыны төяде дә өйалды бусагасына чаклы түшәлгән таш сукмак буенча атлады. Бусагага күтәрелгәнче, тупылның җыерчыклы каралҗым кәүсәсен яктыртып торган сыерчык оясына тагын бер мәртәбә күз салды. Авырудан яңа гына айныган хәлсез гәүдәгә утын күтәрү ярамадымы, кинәт, башы әйләнеп, сыерчык оясы ике булып һәм утлы нокталарга әверелеп, сикерешә, биешә башлады. Сабирулла, кочагындагы утыннары белән бергә дөбердәп, өйалды бусагасына ауды. Язгы карның юеш салкыны, суга әйләнеп, тәненә үтеп керә башлагач кына, исенә килде ул һәм, як-якка чәчелгән утыннарны җыеп, ухылдый-ухылдый, мич алдындагы ләгәнгә кертеп ташлады. Тизрәк өен җылытып, киемнәрен алмаштырмаса, хәленең мөшкел булачагын аңлады Сабирулла. Калтыранган куллары белән мичтәге утыннарны тергезеп җибәргәнче, шактый гомер үтте. Аннары ул бишмәтен ишек катындагы чөйгә элде дә сөякләренә кадәр туңган гәүдәсен мич авызына ук китереп җылынырга кереште. Шарт-шорт янган коры утынның утлы күмере сакалына чәчрәп, борынына көйгән ис бәрелгәч кенә, мич яныннан китеп, чишенми-нитми, түшәгенә ауды.

Ярты сәгатьләп ятканнан соң, картка эссе булып китте, пинжәген салып, идәнгә ташлады.

Бераздан уң колагы шауларга тотынды. «Тагын килде»,— дип уйлады карт. Сыңар канатлы фәрештә янә Сабирулланың иңбашына кунды. Карчыгы үлгәннән бирле азаплый инде Сабирулланы. Моңарчы төнлә генә килгәли иде. Бүген менә иртәдән үк борчырга кереште.

Фәрештәләр турында кечкенә вакытта әнисе сөйли торган иде. Имеш, бөтен кешенең дә ике иңбашында ике фәрештә утыра. Сул яктагысы кешенең кылган начарлыкларын, уңдагысы изге эшләрне язып бара икән. Теге дөньяда кешене менә шул язылганнар буенча хөкем итәләр ди.

Балачакта бу сүзләрне авызын ачып тыңлаганын әле дә хәтерли Сабирулла. Фәрештәләрне тотып карарга теләгәндәй, иңбашларын сыпырып та куйгалый иде. Үсә төшкәч, ул, моның матур әкият кенә булганлыгын аңлап, үзеннән-үзе көлә торган иде.

Карчыгы үлгәннән соң, әллә Сабируллага балачагының беркатлы акылы яңадан кайттымы, әллә авыл кырыендагы зиратта кычкырышкан козгыннар тавышына ешрак колак сала башладымы — анысын тәгаен генә әйтә алмый, әмма балачак хатирәсе аны тагын шомландырды. Бәлки, артына әйләнеп, узган гомерен исенә төшергәч шөбһәләнәдер күңеле? Ләкин аз-маз сизенә дә шикелле: фәрештәләрнең уң як иңбашындагысын кыерсытты бугай. Ул фәрештә аның күз алдына сыңар канатлы булып килә.

Бу гөнаһлы тормышта кылган изгелекләрен теркәп баручы фәрештәнең сыңар канатлы икәнен сизгәч, Сабирулланың башына икенче кайгы да килеп ояланы. Гомере буе җыйган байлыгы кем кулына калыр? Бу уй хәтта үлемнең үзеннән дә куркынычрак, шомлырак иде.

Якты дөньяда алтмышка кадәр яшәп, хатыны гүр иясе булгач, Сабирулла беренче мәртәбә балалары булмавына үзәге өзелеп үкенде.

Шуннан бирле үз-үзе белән бәхәсләшеп яшәде ул. Кайчак үзен язмыштан өстенрәк, көчлерәк итеп тә хис итте. Андый вакытларда күңеле дә, нидер өмет иткән төсле, талпынып куйгалый.

Кыш буе май күрмәгән ишеге чыелдап ачылды. Бусагада бишмәт өстеннән зәңгәр халат кигән күрше хатыны Алтынбикә күренде. Яше кырыктан узган бу тол хатын, көн саен килеп, Маһитабы үлгән Сабирулланың ашарына пешерә иде.

Алтынбикә, кәҗә мамыгыннан бәйләнгән калын шәлен баш артынарак шудырды да, түшәм ярыкларын санап яткан Сабирулла янына килеп, хәлен сорашты. Аннары ашарга әзерләргә кереште.

— Мичтә бәрәңге тәгәрәтеп ал әле, Алтынбикә,— диде Сабирулла.

Алтынбикә, кәстрүл тотып, идән астына төшеп киткәч, Сабирулла беренче мәртәбә: «Баскычта аягы тая күрмәсен тагы»,— дип, күршесе өчен борчылып куйды. Ул керер алдыннан гына уянган өмете, күкрәк читлеген җимерердәй булып, тыпырчына башлады. Идән асты авызыннан Алтынбикәнең яшел яулыгы күренгәч кенә, Сабирулланың хәлсез йөрәгенә көч кереп киткәндәй булды. «Егылмаган икән...»

Хатын, мичне томалап, бәрәңгеләрне тәгәрәтте дә идән себерергә тотынды. Сабирулла да башын юрган астыннан чыгарды. «Хәзер әйтәм! — дип уйлады ул.— Сузарга ярамый, әйтәм».

Маһитап үлеп, бер ай узганнан соң, авылдашлары Сабируллага берничә тол хатынны димләп карады. Бигрәк тә шушы арада гына өченче иреннән аерылып кайткан мут күзле Җәүһәрия өметләнеп йөрде. Авылда яшәргә йорты булмаганлыктан, ул апасына кайтып сыенган иде. Ләкин Сабирулла аңа кулын гына селтәде. Тик менә сыңар канатлы фәрештә бик борчый башлагач, ялгыз гына яшәүләре, ай-һай, кыен икән, бигрәк тә төннәрен шомландыра. Ә Алтынбикә аның өчен менә дигән! Карт димәсә инде.

— Алтынбикә, кил әле монда.

Хатын, тагын нәрсә инде, дигәндәй, башын күтәрде, Сабирулланың үзенә төбәлгән карашын күргәч, канатын идән уртасында өелгән чүп өстенә ташлады да караватт янына килде.

Сабирулла янәшәдәге урындыкка күрсәтте.

— Утыр әле.

Алтынбикә, Сабирулланың гадәти булмаган карашыннан берәр нәрсә укырга теләгәндәй, аннан күзен алмыйча, күлмәк итәкләрен җыя төшеп, урындыкны үз янына тартты.

— Җә?

Сабирулла елмайгандай итте. Аннары кинәт җитдиләнеп:

— Син, Алтынбикә, минем тормышның тазалыгын беләсең инде,— диде.

Авыл халкы Сабирулланың череп баеган карун икәнен күптәннән сөйләсә дә, Алтынбикә «беләм» диярга яхшысынмады, бары иңбашларын гына сикертеп куйды.

— Хисабын әйтсәм, байлыкның дим, күзләрең маңгаеңа менәчәк. Минә шул байлыгым ятка кала. Мин алай озак яшәмәм, үләрмен инде.

Хатын аны авыру кешене юата торган гадәти сүзләр белән юатырга керешкән иде, Сабирулла кул гына селтәде.

— Син минем балаларым юк икәнне дә беләсең. Байлыгым әрәм калачак. Әйдә, Алтынбикә, күченеп кер минем йортка!

Иртәгә ахырзаман дисәләр, Алтынбикә, бәлки, бу хәтле үк гаҗәпләнмәс тә иде. Ни кычкырып көләргә, ни еларга белми, сүзсез калды. Бераз башы да әйләнеп киткән кебек булды. Шулай да беравыктан ирен читләренә саран елмаю эленде. Аннары инде, көлеп җибәрмәс өчен, авызына яулык кырыен китереп:

— Соң үзең «озак яшәмәм» дисең бит? — диде.

— Күп дигәндә ике-өч ел.
— Соң?
— Син миңа бер бала табып бир. Үзем үлгәч, бөтен акчаларым, байлыгым сезгә калыр.
Алтынбикә урыныннан капылт сикереп торды да карават башыннан бишмәтен йолкып алды һәм:
— Өйләнер исәпләрең дә булгач, авыруың ялган икән, картлач. Тамагыңны үзең туйдырырсың,— дип, пыр тузынып чыгып китте.
Гаҗәп хәл: Алтынбикә керер алдыннан гына газраил көтеп яткан карт, әлеге сөйләшүдән соң, яшәреп киткәндәй булды. Таш белән бастыргандай изеп, кысып торган авыру, мәче баласы кебек йомарланып, гәүдәсенең кай төшендәдер йокыга талды. Кайчак, кискен хәрәкәтләнгәндә, мәче баласының үткен тырнаклары тәненә тиеп-тиеп ала иде.
Алтынбикә куеп киткән бәрәңгеләр пешеп, өйгә тәмле ис таралды. Сабируллаfamның ашыйсы килә башлады. «Карчыгым исән булса!» — дип уйлады ул, көрсенеп. Мәһитап хәзер мичтәге бәрәңгеләрне кисәү агачы белән табакка тәгәрәтер, пешкәнлеген белү өчен, һәркайсына кулын тигезеп алыр, аннары, табак өстенә ак тастымал каплап, өстәлгә китереп утыртыр иде. Оеп яткан картына, болдырдагы газ плитәсендә кайнап утырган чәйнекне алып керергә киткәндә:
— Тор, бәрәңге суына,— дияр иде.
Карчыгы юк шул инде. Ә берәр кызы яки килене булса?! Юк бит. Балалары юк аның. Шулай хыялланып, үз-үзен кимсетә, рәнҗетә ул.
Балалары булып та, аталарына ярдәм кирәк чакта, әллә кайда йөрсәләр? Алар үзләре дә үлеп яткан аналарының авызына бер кашык су да сала алмадылар бит!..
Биш бала үстеләр. Әтиләре сугышта үлеп калды. Өч апасы өч якка кияүгә китте. Сугыштан кайткан абыйсы, акча эшләргә дип, Себер якларына юл тотты.
Балаларының бишесе дә үз янында чакта Суфия карчык еш кына: «Соңгы сәгатьләремдә авызыма су салсагыз, миңа шул җиткән»,— дия иде.
Сабирулла ана җанлы булды. Әмма еллар авыр вакытта, бераз акча төшерү нияте белән, анасының хәер-фатыйхасын алып, ул да күмер чыга торган якларга китте. Берәр ел эшләгәч, кире кайтып, картайган әнисенә ярдәмче булу иде исәбе.
Ел ярымнан күршеләре аны телеграмма белән чакыртып алдылар. Әнисе вафат булган иде. Кайтып, туган-тумачалары, күрше-күлән белән бергәләшеп, аны җирләделәр. Шуннан соң туып-үскән нигез генә түгел, авыл үзе дә буш, күңелсез кебек тоелды аңа.
Әнисенең кабер туфрагына ятып, үкси-үкси елады Сабирулла шул чакта. Үлгәндә, иреннәрен су белән чылатучы кеше дә булмаган бит мәрхүмәнең. Аннары Сабирулла, шыксызланып, нәүмизләнеп калган өйдә өч көн дөньяга чыкмыйча ятты да тагын авылдан китеп барды.

* * *

Мичтәге бәрәңгеләрне табакка җыеп, Сабирулла карт авызын пешерә-пешерә ашарга кереште. Шул чак капка шыгырдап ачылды. Кулындагы бәрәңгесен авызына кабарга да онытып, карт ишеккә төбәлде. Анда каененесе Шәрәф күренгәч кенә, бәрәңгесен тоз суына манып, авызына озатты. Шәрәф, гадәттәгечә, кычкырып сәлам бирде, ак чүсинкаләрен бер-берсенә шап-шоп бәрә-бәрә, ишек катында маташты, аннары пәке белән кырылган шома башындагы бүреген сыпырып төшерде дә түргә узды.
— Нихәл, җизни, тереләсеңме?
Сабирулла баш кагып кына җавап бирде:
— Әйдә, уз, бәрәңге ашыйбыз.
Шәрәф, бишмәтен салып, урындык артына ташлады.
— Сыерчык оясы ясагансың икән, җизни.
Җизнәсе, аның сүзләрен җөпләп, баш кагып куйды. Аннары:
— Кирәк бит,— дип өстәде.
— Минем онык та, сыерчык оясы ясыйм дип, әйбәт такталарны тураклап бетергән. Тотып ярдым үзен.
Шәрәф, бер бәрәңге алып, учында әвәләде-әвәләде дә кире өстәлгә куйды. Күзе идән уртасында җыелып яткан чүпкә төште. Бая Алтынбикә идәнне себереп бетермәгән иде.
— Кызны җибәрермен, җизни, өеңне җыештырып китәр,— диде Шәрәф.
Сабирулла дәшмәде. Шәрәф аңа күз салды. Әле үткән җәйдә генә егетләр кебек йөргән җизнәсе шактый бирешкән иде. Әллә авыру шулай иткәнме, йөзе

зәңгәрләнә башлаган, пәке белән тигезләп кырылган башына җыерчыклар кунган. Бары кечкенә зәңгәр күзләре генә элеккечә һаман шул: аларга карап, җизнәсенең ачулымы, каефлеме икәнен белеп булмый, аларга мәңгелек томан иңгәндәр сыман.

— Их, җизни, балаларыгыз юк шул. Ичмасам, картайган көнеңдә ярдәмчеләрең булыр иде.

Караватта оеп утырган Сабирулла башын күтәрде, күзләрендәге зәңгәр томан сыеклана төште.

— Синеке дүртәү бит, ярдәм итәләрме соң?

— Һы, дүртәү шул. Тик аларның ярдәме кирәкми әлегә.

— Ике малаеңның берсе төп нигездә калдымы соң?

— Укыган бит алар, авылда нишләп ятсыннар? Син ишетмәгәнсеңдер, олы улым Исрафилга орден бирделәр. Бик кирәкле машина уйлап тапкан. Кичә зур начальникләреннән карчык белән минем исемгә рәхмәт хаты да килде.

Шәрәф, үзе дә сизмичә, күкрәгенә сугып алды. Гүя орденны аның түшенә такканнар иде.

Сабирулла дәшмәде. Шәрәф тә бераз сүрелә төште. Аннары, капылт кына кузгалып, бишмәтен киде дә бүреген кулында әүмәкли-әүмәкли:

— Ни, җизни, күрше авылда берәү бура сата икән, шуны белешеп кайтып килә идем әле. Исрафил дача салам ди. Тик минем акча җитеп бетми. Ярдәм итеп тормассыңмы икән? Малай шимбә көнне кайта, китереп бирер,— диде.

Сабирулла, беренче тапкыр күргәндәй, каенəнесенә озак карап торды.

— Миндә андый акча юк.

Җизнәсенең холкын Шәрәф яхшы белә иде. Шуңа күрә артык сүз көрәштереп тормады, ишеккә юнәлде.

Шәрәфнең акча соравы Сабирулланың күңелен күтәреп җибәрде. «Дүрт бала үстереп, минем янга теләнергә килгән. Балалар, балалар дип, тормышның рәхәтен дә татымый кала. Малайлары хәйләкәр, һаман аталарын суыра. Ә минем, телим икән, бүгеннән ун малай үстерерлек рәтем бар. Акча бөтенесенә дә баш шул»,— дип уйлады ул. «Ун малай. Хәзер кайдан аласың инде аларны, элегрәк булса иде ул...»

* * *

Әнисе вафат булганнан соң, яңа йорт-җир җиткерсә дә, өйләнергә ашыкмады Сабирулла. Туйга җитәрлек акчасы калды калуын. Әмма бер тәмен сизгәч, тагын да ишәйтәсе килде аны. Чәер исе аңкып торган нарат өйнең ишек-тәрәзәсенә иске такталар кадаклады да, күрше-күләннән йортка күз-колак булуны үтенеп, яңа сәфәргә юл тотты.

Кабат авылына кайтып төшкәндә, Сабирулланың яше утыз белән бара иде инде.

Егетнең башына өйләнү уе керде. Мал кадерен белгән, йорт җанлы кыз эзләде. Шулай йөри торгач янә өч ел үтте. Әмма бер көнен дә бушка уздырмады ул. Акча бик аз төшә торган колхоз эшеннән ничек кирәк алай тайпылып, ике-өч иптәше белән балта эшенә кереште. Байлыгы арткан саен, Сабирулланың күзе кыза гына барды. Югыйсә, элек акча аңа йорт салып, әнисен кадер-хөрмәттә яшәтү өчен генә кирәк иде. Шул исенә төшкән вакытларда, ул үзенең комсызлыгына үзе дә шаккаткалый иде. Тора-бара, малы ишәйгән, акчасы күбәйгән саен, аптырау-гаҗәпләнүләр онытылып бетте.

Өйләнүенең икенче көнендә үк Сабирулла хатынын йорт-җире белән таныштырды да: «Малны арттырмасаң, үзе артмый ул. Бүгеннән башлап бу эшкә икәүләп керешәбез»,— дип, колагына киртләп куйды.

Моңарчы апасыннан калган киемнәрдән башканы күрмәгән Маһитап, Сабирулланың байлыгына телен шартлатты да, җиң сызганып, бу байлыкны тагын да үрчетү эшенә тотынды.

Ул башта өч ел буе балага уза алмый йөрде. Хатынына, шәһәргә барып, зур врачларга күренергә, дәваланырга киңәш итсәләр дә, Сабирулланың бу эшкә акча түгәсе килмәде. Бары өч ел узгач кына, Маһитап үзенең күкрәк астында күптән көтелгән җан иясенең тыпырчынуын сизде. Иренә: «Сыерчыклар безгә бәхет алып килә»,— дип сөйләнде.

Балалары булмаганга моңаеп, кимсенеп йөрсә дә, хатынының яз башында шундый хәбәр әйтүе Сабирулланы артык шатландырмады. Чөнки алда эшнең нәкъ кайнаган чагы. Печән җыясы бар, утынын әзерләргә кирәк. Кыр эшләре беткәч, мунча салырга да уйлаганнар иде. Бурасы череп утыра. Мондый эшләрдә Маһитап — иренең төп ярдәмчесе, уң кулы.

Печәнен дә җыйдылар, күп итеп утын да әзерләделәр, июль аенда ук мунчасы да салынды. Күз кергәндә, Маһитапның билләре шактый түгәрәкләнгән иде инде. Ләкин ире аның өйдә генә ятуын өнәмәде. «Әниләр авырлы килеш урак та урганнар әле, бернәрсә булмаган»,— дип уйлады.

Бер көнне бәрәңге салынган капчыкны күтәргәч, Маһитапның эчендә нәрсәдер шартлап өзелгән кебек булды: дөньяга үле бала китерде.

Бу хәлләрдән соң хатынының күкрәк астына бүтән берниндин җан иясе дә оялмады.

Инде менә Маһитап та юк, бала таба алмавына гаҗиз булып яшәде-яшәде дә каен астына кереп ятты. Күздән бирле Сабирулла ялгызы гына гомер итә һәм төннәрен теге сыңар канатлы фәрештәне төшендә күреп сискәнеп уяна башлады.

* * *

Ачык тәрәзәдән килеп кергән күбәләк стеналарга, түшәмнәргә куна-куна фырылдап очып йөрде дә, әңгер-меңгер иңә башлагач, кире тышка атылды, әмма пыялага туры килеп, бусагага шуып төште.

Сабирулла караватында ята иде. Күбәләкне күргәч, күңелен биләп алган шатлык, картның авырудан алҗыган гәүдәсен җиңеләйтеп, савыктырып җибәргәндәй булды. Караватт тимере шыгырдаган тавыштан күбәләк өркемәсен дигәндәй, ул акрын гына торды да, бер аягында оекбашы юклыкны да онытып, тәрәзәгә таба атлады. «Килдеңме, газизкәем. Карчыгымның җаны булып килдеңме?» Карт, шулай сөйләнә-сөйләнә, рам читенә борыны белән кадалган күбәләккә үрелде. Әмма күбәләк, фырылдый-фырылдый, тәрәзә пыяласы буенча шуып йөрде дә, юл табып, урамга очты.

«Үпкәләгән. Сөйләшәсе дә килмәде»,— дип пышылдады Сабирулла. Һәм авыр сулап, кире караватка барып утырды.

* * *

Беркөнне, үзе ясаган ояга сыерчыклар килгәнне күреп, балаларча шатланып йөргән иде ул. Күрше-күләндә дә күренми әле сыерчыклар. Сабирулла оясына иң беренче булып килгәннәр! Шуннан соң ул мунча түбәсенә дә оя ясап куйды. Әмма бу оясы буш калды. Анда ара-тирә чыпчыклар гына кереп-чыккалыйлар иде.

Үз оясына таба күршеләренеке янында сайрашкан кошларны да куып карады. Тик сыерчыклар аны тыңламады. Сабирулланың моңа аллә ни кәефе кырылмады кырылуын. «Мунча түбәсенә соңрак куйдым, инде урнашып беткән булганнардыр»,— дип уйлады.

Сабирулланың иңбашына бу төнне сыңар канатлы фәрештә яңадан әйләнеп кайтты һәм телгә килде. Моңарчы фәрештәнең үз хуҗасы белән беркайчан да сөйләшкәне юк иде әле. Бүген сыңар канатын кагып алды да: «Язганнарымны укып күрсәтимме?» — дип, Сабирулланың колагына кайнар сулыш өрде. Сабирулланың бөтен гәүдәсе кызыша башлады. «Куркасыңмы? — диде сыңар канат.— Курыкма, моннан соң мин синең яныңа көн дә килермен. Хәзер якын инде, мунча түбәсендәге сыерчык оясында гына яшим. Синең иңбашыңда миңа эш юк, бик күңелсез. Шулай да киләм. Мин синең яннан китәргә дә тиеш түгел. Эш булмагач, нишлим соң? Ә язганнарымны укымыйм. Укырлык берни дә юк. Әнә, бик теләсәң, сул иңбашыңдагы фәрештә укысын. Кара дәфтәре бик калын. Минем сиңа бер сорау гына бирәсем килә: Үзең үлгәндә байлыгыңны кемгә васыять итәргә җыенасың? Кирәкми, җавап бирмә. Син аны үзең дә белмисең бит! Шуны онытма, мине син гарип калдырдың»... Үзендә фәрештәгә каршы сүз әйтерлек көч сизепме, Сабирулланың да теле ачылды: «Гарип, имеш... Син гарип булсаң, мин япа-ялгыз әле монда! Менә бер үзем, бер башым ятам! Беләсең килсә, минем ялгызлык каршында синең бер канатың юклыгы чүп кенә ул!»

...Сабирулла шабыр тиргә батып уянды. Таң беленеп килә иде инде. Ул беркавым селкенмичә ятты. Күзгә күренми торган сыңар канатлы фәрештә төш белән бергә эреп юкка чыккан. Әмма уң колагы ут кебек кызыша.

Сабирулла киенеп тышка чыкты һәм мунча түбәсендәге сыерчык оясын колга белән җиргә бәреп төшерде. «Өйләнергә кирәк! — дип уйлады ул, ояның такталарын сүтә-сүтә.— Бүген үк Җәүһәрия янына барам!»

Җәүһәрия аллә ни карышмады: шул көнне үк, төенчеген күтәреп, Сабирулла

йортына килде. Әмма Җәүһәриянең ирдән бәхете булмаган икән. Сабируллада ике-өч көн яшәде дә, өченчесендә җиде төн уртасында сикереп торып, үзе белән күтәреп килгән төенчеген җыйнаганнан соң, стенага таба борылып яткан хуҗаны уятты:

— Китәм, Сабирулла абзый. Хәтта сандык тулы алтының булса да, кызыгып яшәр хәлем юк. Кияүнең менә дигәнен табам әле мин. Ә арканны җылытыр өчен генә син башка кеше эзлә инде. Карт-коры бетмәгән,— дип чыгып китте.

...Аягы туңа башлагач кына, сыңар оекбашы юк икәнен искәрде Сабирулла. «Тәмам аңгырайдым ахрысы»,— дип сукранды ул. Инде савыгып кына киләм дигәндә, йөрәгенең тагын хәле юк. Моның сәбәбен үзен хур иткән Җәүһәриядән генә күреп, ул хатынның тетмәсен тетте. «Бар, гомереӊ буе дүдәк каз шикелле ялгыз йөр шунда, төенчегең белән генә әллә кая китә алмассың әле. Сандык тулы алтының да кирәкми имеш. Тәтесә, алай димәс идең әле. Миңа димәгәе...»

Сабирулла лып итеп караватына утырды. «Сандык, дидеме?! Нинди сандык? Каян белә? Әллә?..» Ул хәлсез икәнен дә онытып, җәһәт кенә оекбашын киде дә сөртенә-сөртенә, ишеккә таба йөгерде. «Тапкан! Чормадан сандыкны тапкан. Кичә көндез югалып та торган иде, денсез хатын! Чормада мәче йөриме дип уйласам...»

Сабирулла егетләрчә җитез хәрәкәтләр белән ике-өч баскычны бер итеп чормага үрмәләде. Туфраксага күмелгән кечкенә тимер сандыкта гүя аның бу гөнаһлы дөньяда дәрт-дәрман бирерлек бердәнбер иманы, соңгы куанычы һәм газап белән яшәгән гомере бикләнгәнмени, әй ашыкты-кабаланды. Чормага менеп җитүгә ул, бәреләсугыла, ата каз муены шикелле тырпаеп утырган морҗа янына китте.

Сандык күмелгән туфракса өстендә ят эзләр, шикле билгеләр күренмәде. Сабирулла карт үпкәсе бугазына килеп тыгылдымыни, бер мәлгә урынында тынсыз калды. Сандык урынында иде. Сабирулланың йөзенә алсулык йөгерде. Ул, тынычлынып, сандык янына чүмәште.

Җәүһәрия кыек атып туры тидерде: чыннан да, сандыкта картның алтыннары бар иде. Акчага гына ышанып ятмады ул. Акча кәгазь генә бит, аны күсе дә кимерә ала. Алтын балдаклар, алкалар, беләзекләр яхшы саклана алар...

Түбә ярыкларыннан, тәрәзәгә эленгән пәрдә кырыеннан чормага утлы сызыклар сузылган. Маһитаптан калган кер бавында хатын-кыз кирәк-ярагы эленеп тора иде. Сабирулла, шуларны күргәч кенә, Җәүһәриянең чормада нишләп йөргәнен аңлады. «Ишегалдына чыгарга уңайсызлангандыр инде, яшь килен булып төшкән иде бит».

Ул сандыкны ачты да алтыннарын берәм-берәм санап чыкты. Һәммәсе дә урынында, югалмаган, төп-төгәл унөч. Сабирулла аларның исәбен биш бармагы кебек белә. Дөресрәге, авызындагы унөч теше кебек...

Авызында исән-имин нәкъ унөч теше бар. Сандыкта өч балдак, алты беләзек, ике брошка, бер медальон, бер йөзек.

Сабирулла алтыннарын учларына алып, йөзенә якын китерде. Түбә ярыгыннан сузылган яктыда ялт-йолт итәләр. Матурлар, авырлар, салкыннар...

Һәм җансызлар... Карт аларны сандыкка кире салды да элекке урынына күмеп куйды. Сандыкны күрү шатлыгыннан туган ләззәтле хис тоныклангандай, авырайгандай кебек булды. «Байлыгыңны кемгә калдырасың? Кемгә?! Кемгә?!» Картның кәефе кырылды. Ул, аякларын өстерәп, чорма баскычына таба юнәлде. «Байлыкларың белән нишләргә уйлыйсың, нишләргә?!»

Сабирулла баскычтан көч белән генә төште дә өй ишеген ачты. Аннары, нидер исенә төшеп, ишекне япты да болдырдагы тимер карават астыннан балта алып килде һәм чорма баскычының уртадагы аркылы басмасын сугып сындырды. Аннары шуны яңадан урынына утыртты. Хәзер ул, тотынуга, ычкынып китәчәк иде.

Алҗыган гәүдәсе, түшәккә яткач, таралып китте. Урамнан узган трактор тавышына уянып, күзләрен ачканда, төш вакыты авышкан, кояш хәзер ишегалды ягына караган тәрәзәдән күренә иде. «Тәрәзәне юарга кирәк икән,— дип уйлады ул.— Алтынбикә дә күренми. Башка кермәс тә инде». Ләкин, шулай уйласа да, карт Алтынбикәнең керүен хәзер үзе үк теләми иде. Күңеле кайтты. Сәер кеше. Мә, ал, дип торганда бушка килгән байлыктан баш тарталармыни инде!.. Алтынбикә шулай кыланса кылансын, әмма Сабирулла аңа барыбер ышанмый. Исе китмәгәнгә генә салына ул. Күрүен күрсә, күзләре тонар иде... Бәлкем, ул Сабирулланың сандыгын урларга план корып йөридер әле!

Бу уйлары картны бераз шүрләтсә дә, Алтынбикәнең үз чормасында мүкәлимүкәли сандык эзләп йөрүен күз алдына китерү аның күңеленә рәхәтлек бирә иде. Менә әле кайчан гына картның байлыгыннан йөз чөергән, баш тарткан булып кыланган күрше хатыны сандыкны тапты ди. Үзе курка, як-якка карана, хәтта чорма тәрәзәсенә кунган күбәләктән дә шикләнеп, дерт итеп куя, ә үзенең сандыкны шун-

дук ачып, эченә күз саласы килә, тартып-каерып карый. Тик сандык капкачы селкенми дә. Ә Сабирулла аны читтән генә күзәтеп тора. Хатын, капкачны ача алмагач, нишләргә дә белмичә аптырап тора. Аннары итәк эченә яшерә. Шулчак моржа артыннан Сабирулла пәйда була. Куркуыннан дәшми-нитми дерелдәп торган хатын янына килә дә күлмәк итәген күтәрә! Башка чак булса, Алтынбикә аны төртеп җибәрер иде җибәрүен, әмма хәзер кыл да кыймылдатмый. Сабирулла аңа: «Нәрсә, аллә алтын кирәк булдымы, күрше?» — диячәк. Андый чакта Алтынбикә ни дисен инде, авызын да ача алмас, сандыкны да бирәсе килмәс үзенең. Тарткалашыр, тырнашыр... Моны сыңар канатлы фәрештә дә күрми калмас, әлбәттә. Уң иңбашында утырам ди бит. Шуннан соң әйтер аңа Сабирулла, авызын томалар: «Күрдеңме? Кешеләрнең һәммәсе дә комсыз! Ә син миңа канығасың»,— дияр.

Өйалдында нәрсәдер, дөбердәп, идәнгә төшкән тавыш мизгел эчендә Сабирулланы айнытып җибәрде. Башыннан шомлы да, ләззәтле дә бер уй узды: «Алтынбикә! Чормада! Эзли!..»

Алтынбикәдән ни рәвешле көләчәген уйлап, хыялланып, өйалдына чыккан Сабирулла, чорма баскычыннан төшеп килгән Җәүһәрияне күреп, өнсез калды. Хатынның кулында эчке күлмәккә төрелгән керләр иде. Сабирулла җиңел сулыш алды.

— Минием әле бу. Менә онытып калдырганмын. Өеңә кереп, сине борчырга кыймаганием.

Сабирулла аңа каршы ни дип әйтергә дә белмәде. Җәүһәрия чыгып киткәч, өйалды ишеген шартлатып бикләде дә, чайкала-чайкала, өйгә керде. Аннары, бәрәңге бакчасындагы тирәктә кошлар чыр-чуын ишетеп, тәрәзәгә капланды. Әгәр дә рамы булмаса, аның авырлыгыннан пыяла шартлап ватылачак иде. Егылып китмәс өчен, карт, соңгы көчен җыеп, тәрәзә бусагасына таянды. Кошлар тавышы сыерчык оясы яныннан килә иде. Оядан ерак түгел генә юан ботакта йоннары туздырган соры тилгән кунган. Ә эчтә, куркыныч сизепме, сыерчык балалары чырылдаша. Сабирулла ачудан кулын йомарлады һәм шунда гына ул үзенең чынлап та хәлсез икәнлеген сизде, чөнки бармаклары оешып каткан кебек — бик авырлык белән генә аның ихтыярына буйсындылар. «Көш-ш-ш!..» — дип тәрәзә аша тилгәнне кумакчы булды ул, әмма аның бу пышылдавыннан пыяла буенча безелдәп йөргән чебен дә өрекмәде. Карт, моңа үчекләнеп, тәрәзә кагарга теләде, үзе хәлсез булса да, йодрыгы хәйран саллы төште ахрысы — пыяла шартлап ярылды. Аны тигезләп куяр өчен тырыша торгач, бөтенләй үк чәлпәрәмә килде.

Шулчак каяндыр ояның хуҗалары — ике сыерчык пәйда булды. Алар тирәк яныннан йөрәк өзгеч тавыш белән бер-ике әйләнделәр дә, бу гына тәэсир итмәгәч, кошларның берсе, уктай атылып, тупыл ботагына кунган тилгәннең яныннан ук очып узды. Соры тилгән, канатларын иренеп кенә җилпи-җилпи, очып китте.

Офыкка якынлашып бара торган кояш Сабирулланың күз алдында әллә ничәү булып сикерешә башлады. Аяк буыннары йомшарды. Карт, хәлсезләнеп, караватка егылды.

Уң иңбашындагы фәрештә сыңар канаты белән, шапылдатып, колагына китереп сукты. Каяндыр пәйда булган кызыл канатлы күбәләк өй эченнән фырылдап бер әйләнде дә, ватык тәрәзә аша урамга очып чыгып китте.

Түбә кыегындагы чыпчыклар чыр-чуын инде тынычланган һәм бәрәңге бакчасындагы тирәктә сузып-сузып сайраган сыерчыклар тавышы күмеп китте...

# ЧИТТӘ КАЛМАСКА!

Зиннур Хөснияр — минем өчен яңа автор. Бәлки шуңадыр, хикәяне зур кызыксыну, яшерен бер өмет белән кулыма алдым. Яле, яшь дустым, нәрсә алып килләсең икән? Әсәрең белән нәрсә әйтергә телисең? Яңа сүзең бармы? Сәнгати сиземләвең ни дәрәҗәдә?..

Башта ук шуны әйтәсе килә: хикәя беренче юлларыннан ук мавыктырып алып кереп китә. Димәк, укучыны тота. Яшь язучы өчен бу инде бик мөһим нәрсә.

Хикәянең игътибарны җәлеп итә торган тагын бер уңай ягы бар: әсәрдә чагылдырылган вакыйганың эчталегенә, сурәтләнгән материалына туры килә торган дөрес ритм табылган. Авторның теле дә, әсәрнең эчталеге таләп иткәнчә, тигез агышлы, салмак-саллы, сурәт-

ләү чаралары да, буяу-интонацияләре дә, хикәя тукымасына туры килеп, ятышып торалар.

Хикәяне укуымны дәвам итәм. Шунда үзем өчен тагын бер ачыш ясыйм. Монысы да яшь автор файдасына. Әсәрдә алынган персонажларның эчке дөньялары, кичерешләре психологик яктан шактый ук акланганнар. Бу инде язучы осталыгын чагылдыра торган бик әһәмиятле казаныш. Шулар янына тагын яшь авторның бары тик үзенә генә хас язу алымы, стиле, хикәяләү манерасы да бар сыман. Димәк, автор эзләнә, үз тавышын табарга тырыша.

Зиннур үзенең хикәясенә исемне дә дөрес сайлый белгән. Карчыгы дөнья куйганнан соң, япа-ялгыз калган Сабирулла карт үлем түшәге өстендә ята. Әмма аны бер уй изә, газаплый, кешелектән чыгара: «Гомере буе җыйган байлыгы кем кулына калыр? Бу уй хәтта үлемнең үзеннән дә куркынычрак, шомлырак иде». Шунда хикәягә тагын бер хикмәтле деталь килеп өстәлә. Сабирулланың сыңар канат булуы — бер хәл, аның уң як иңбашына кунаклап, тормышта кылган саваплы эшләрен, изгелекләрен теркәп-язып баручы фәрештә дә сыңар канатлы гарип-гораба икән ич! Фани дөньяда фәкать үзе өчен генә яшәгән, яман комсыз, кешелексез Сабирулла җилкәсендә аңа эш юк, вакытын, хуҗасы яныннан очып китеп, мунча кыегына куелган буш сыерчык оясында үткәрә...

Күргәнебезчә, яшь автор хикәясенең эчтәлеген тагын да катлауландырган, символикага мөрәҗәгать иткән. Бик һәйбәт! Фантазиягә бай кешенең максат-омтылышлары да эрерәк һәм кызыграк була...

Хуш! Зур өметләр баглап, әсәрне укуымны дәвам итәм. Нинди хикмәтләр, яше алтмышка җиткән Сабирулла гомерендә беренче мәртәбә балалары булмаганга үкенә. Бу бәладән котылу юлы да әллә ни еракта йөрми икән ләбаса. Шулчак ишектә, көн саен кереп Сабирулланың ашарына әзерләп, өен җыештырып, кырык яшьләрдәге ялгыз хатын Алтынбикә пәйда була. Шунда ялгыз карт әлеге күрше хатынына тәкъдим ясарга уйлый. Хәер, Сабирулланың запаста тагын «шушы арада гына өченче иреннән аерылып кайткан мут күзле Җәүһәрия» дә бар...

Ни хикмәттер, шушы тирәләргә җиткәч, хикәя шактый ук сузыла, сыеклана, кызыгын югалта башлый. Тәэсир итү көче кими. Әсәрдә сурәтләнгән вакыйгаларның да ышандыру, дәлилләү көче житенкерәми башлый. Әгәр дә алынган вакыйга — хикәянең йөрәге булса, мотивлаштыру — аның җаны...

Хәзер әсәрдәге мотивлаштыру ягъни «хикәянең җаны» җитенкерәмәүгә берничә мисал китерик. Алтынбикәнең «урыныннан капылт кына сикереп торып... пыр тузынып чыгып китүен» мин, мәсәлән, берничек тә аңлый алмадым. Беренче мәртәбә ялгыз ирнең бусагасын атлап кергән көнне үк инде авылдашлары: «Әллә кияүгә чыгасыңмы?» — дип колагын тондырып бетергән булганнардыр. Һәрхәлдә, Сабирулланың тәкъдим ясавы Алтынбикә өчен көтелмәгән хәл булырга тиеш түгел иде. Шулай ук «яшәргә өе дә булмаган» Җәүһәриянең дә: «Арка җылытыр өчен генә син башка кеше эзлә инде. Карт-коры бетмәгән»,— дип, төенчеген күтәреп чыгып китүе дә хакыйкатькә туры килмидер. Боларны автор бары тик Сабирулланы ялгыз калдыру өчен генә эшләгән, шунлыктан ябыштырып җиткермәгән дигән фикер кала.

Каенесе Шәрәфнең, ярты кыстырып, җизнәсеннән бурычка акча сорарга килүе дә ышандырмый. Гомерләрен бергә кичергән бу ике кеше бер-берсенең кемлеген белмиләр микәнни дигән тәэсир кала.

Аннары мал-мөлкәт, байлык тутырылган сандык белән булган маҗаралар да берьюлы мең төрле сорау тудыра. Сандыкмы ул, әллә кечкенә генә калай тартмамы? Сандык икән, аны күмеп куярлык туфрак чормага каян килсен икән? Ул кадәр туфракны өй матчалары ничек күтәреп торсын ди?

Менә хәтердә калырлык җанлы детальләр белән сурәтләнгән бер күренеш. Сабирулла чормада байлыгын — алтын әйберләрен барлый. «Һәммәсе дә үз урынында, югалмаган, тәп-төгәл унөч. Сабирулла аларның исәбен биш бармагы кебек белән. Дөресрәге, авызындагы унөч теше кебек...» У н ө ч — хәтәр, һәлакәтле сан! Һәрхәлдә, тикмәгә кертелмәгәндер бу яман сан дип, берәр төрле хикмәтле могҗиза көтәсең. Әмма яшь авторның хикәясендәге «Унөч» саны «уйнамый», үз вазифасын үтәми кала. Хикәя ифрат та нәзберек, бик тә «мәрхәмәтсез» жанр, ул артык детальне түгел, хәтта артык сүзне дә күтәрә алмый.

Кызганыч ки, акланмаган, мотивлаштырылмаган, ышандырмый торган нәрсәләр хикәядә шактый. Ә бит әдәбият чынбарлыкка караганда да дөресрәк булырга тиеш!

Лирик чигенүләрнең берсендә Сабирулла узган гомере турында уйланып ята. «Еллар авыр вакытта ул, әнисенең хәер-фатихасын алып, бераз акча юнәтү нияте белән, күмер казый торган якларга чыгып китә. Ел ярымнан соң, әниең вафат дип, күршеләре телеграмма суга. Кайта, туган-тумачалары җыелып, әниләрен җирлиләр...» Янә бер-бер артлы сораулар туа. Кайсы елларда була бу хәлләр? Ничек итеп җәһәннәм читеннән көнендә кайтып җитә алган ул? Әсәрдән әлеге сорауларга җавап эзлим. Чыннан да, кайсы еллар соң болар? «Әнисе вафат булганнан соң, яңа йортҗир җиткерә. Бер акча тәмен татыган Сабирулла чәер исе аңкып торган нарат өйнең ишекләренә иске такталар кадаклады да янә сәфәргә чыгып китте. Кабат авылына кайтып төшкәндә, Сабирулланың яше утыз белән бара иде инде».

Менә шундый очы-очка ялганмаган нәрсәләр хикәя турында тискәре фикер уята, кәефне боза, чак кына игътибарлы булганда, шул ук телеграмманы: «Әниең авыр хәлдә»,— дип бирергә дә мөмкиндер бит?!.

Яшь язучыларның шактый өлешенә хас булган уртак бер җитди кимчелек турында әйтеп үтәргә уйлыйм. Белмим, ни өчендер яшьләребезнең бер өлеше үзләре тирәнтен белмәгән, тормышыбызның икенче сафында торган, бүгенге әдәбиятыбыз өчен әһәмияте аз яки бөтенләй ят нәрсәләр турында язарга алыналар. Ә бит бернинди олы художник та үз заманы омтылышларыннан, үз чоры проблемаларыннан читтә кала алмаган, һәрчак социаль көрәшнең үзәгендә булырга тырышкан. Шуның нәтиҗәсендә генә җәмгыять белән бер адымнан атлаган, үз заманына авазлаш яңгыраган әсәрләр безнең көннәргә кадәр килеп җитә алганнар. Чөнки андый әсәрләр, кагыйдә буларак, мәңгелек яшәү проблемаларына, кешене олылауга, аның бөеклегенә дан җырлауга багышланган булганнар.

Әдәбиятыбыз алдына куелган ифрат та зур, бик тә җаваплы бурычлар турында сүзне озакка сузмыйча, бары тик шуны әйтә алам. Бүгенге көннең, бүгенге дөньяның иң актуаль мәсьәләләре — тынычлык-иминлек өчен көрәш, ил язмышы, аның узганы, бүгенгесе турында тирәнтен уйлану. Халык тормышының бөтен катлаулылыгын, драматик вакыйгаларын читләтеп узмыйча, аларны кыю рәвештә әсәрләргә кертеп, бөтен бер буынны, хәтта киләчәк буыннарны тәрбияләрлек, сәнгатьчә камил, үзенчәлекле, күп планлы, колачлы әсәрләрне яшьләр иҗат итми кем иҗат итсен соң?! Бу хәл, кемгә ничектер, әмма мине бик нык хафаландыра, пошаманга төшерә.

Язучыларның соңгы форумнарында: үз язмышын әдәбият белән бәйләгән кешенең хәзер ярым-йорты егәрлегенә генә эшләргә хакы юк, дип басым ясап искәртелүе безнең барыбызга да бер үк дәрәҗәдә кагыла, минемчә.

**Мәхмүт ХӘСӘНОВ.**

## Вахит Имамов

# ТАНЫШ ТЫКРЫК

ХИКӘЯ



Бер аягына нык кына аксаган хәрби киемдәге кеше, басу капкасын үтеп, авыл урамына керүгә үк, әле бер, әле икенче капка өстендә яулыклы, бүрекле башлар пәйда булды. Авылның бала-чагасы, тартынып-нитеп тормастан, читән, киртә өсләренә кунаклап, хәрби киемлене күзәтте. Өлкәннәр дә тартыну-кыенсынуны оныттылар. Күршеләр, читән аша гына сүз алышып, төрлечә гөман кылырга кереште.

— Бакчы, сугыш беткәнгә инде ике ел бит. Бу бичара кайда югалып йөрде икән?

— Гуспиталдә чиләнгәндер дияр иең, анда да ике ел тотмыйлар.

— Дәрәҗәсе капитан бугай. Җибәрми асраганнардыр, мужыт.

— Кайтып, берәүне бәхетле итә инде бу, тучны. Беләсе ие, кем кочагына кайта икән?

— Бер дә безнең Чиялек кешесенә охшамаган бу. Мөгаен дә, Чишмә авылыннандыр.

Хәрби киемдәге кунак ялгыз яшәп яткан Мирхәйдәр карт йортына таба борылгач кына, гөманлаучылар маңгайларына суккалап, дәррәү хәтергә килделәр.

— И, сантыйлар! Мирхәйдәр бабайның теге каладан җәй саен кунакка кайтып йөргән оныгы бит бу. Исеме кем соң әле, тфү! Тел очында гына тора.

— Шул инде, шул. Теге Әсма кызы Гөлзада белән дә йөргән ие бит әле. Нумер ясап китте. Исеме ничек соң, шайтан алгыры?!

— Минә исемә төште — Мөҗәһит.

— Әйе лә, Мөҗәһит, нәкъ үзе!

... Мирхәйдәр бабасының йорты инде шактый кыйшайган булса да, аның бусагасыннан Мөҗәһит һаман элеккечә дәртләнеп, әсәренеп килеп керде. Күзләре, кичекмәстән, таныш эзләр, билгеле тамгалар эзләде. Болдыр сайгаклары һаман элеккечә шыгырдый, ишектән керүгә, уң якта шул ук агач эскәмия тора икән. Өстендәге яртылаш су тулы чиләк белән аның колагына элгән калай кружкага кадәр үзгәрешсез, гел элеккечә. Өй матчасындагы бишек бөҗрасына асылган уникеле лампага да, әйтерсең, кул тимәгән. Әллә соң бу йорт бусагасын атлап чыгуга җиде ел узмаган да, ул аяусыз сугышлар, кан, үлем, яралану, госпитальләр — төштә генә булдымы?

Мирхәйдәр бабай элек тә күп сүзле кеше түгел иде. Гомер буе бергә чөкердәшкән карчыгын да җирләгәч, хәзер бөтенләй үз эченә бикләнгән. Оныгы белән күрешмәүгә җиде ел үтсә дә, ул өстәл артындагы чәй вакытында Мөҗәһит сорауларына әле йокымсырап, әле яртылаш кына җавап кайтарып утырды. Сизелеп тора, карт дөнья белән алыш-бирешен инде ныклап өзгән. Әллә шуны аңлаудан, әллә кыенсынудан Мөҗәһит бабасына Гөлзада турында бер сүз дә катмады. Чынаякларны әйләндереп каплагач кына, Мөҗәһит урыныннан кузгалды. Озак торудан зәңгәрләнә башлаган тәрәзә пыялаларына карап, каешын, фуражкасын төзәткәләп киде. Ишек тарафына атлагач, ярым борылып бабасына эндәште.

— Авылны бер әйләнеп керәм әле. Калмыя буена төшәм. Бергә үскән иптәшләрне дә күрергә исәп. Исән кайтканнары да бардыр, мөгаен.

Бабасы нык көттереп кенә: «Бар, бар»,— диде. Бу аның урамга чыгуын хуплау идеме, әллә соравына җавап идеме — Мөҗәһит аңламады. Баш түбәсен нәкъ җиде ел элеккеге кебек ишек ниргәсенә орып, ул тышка атлады.

Үзгәргән Чиялек. Элек һәр йортны диярлек каплап торган дәү ябалдашлы тупыллар, ямь-яшел зирек, каен, өянкеләр сугыш елларында юкка чыккан. Белоруссия авылларын гына юк итмәгән икән бу сугыш, ерак тылдагы Чиялекләрне дә өтеп алган икән.

Гөлзадасы янына ашкынудан йөрәге атылып чыгардай булып уйнакласа да, сагынылган йорт каршына урам яклап килергә яхшысынмыйча, Мөҗәһит тыкрыкка атлады. Ялан буйлап сукмак озын, алда көткән кавышу рәхәтен сузарга мөмкинлек бар әле.

Сөекле Гөлзадасы бу минутта нишли икән? Көтәме ул Мөҗәһитне, әллә башкалар яры булганмы? Җиде ел буена Мөҗәһит аңа хат та салмады бит. Беренче атнасыннан ук сугыш эченә кереп китте дә, җиңү залплары яңгырамый торып, чыкмады. Кем белә, бәлки, Мөҗәһиттән өметен өзеп, Гөлзада үз язмышын башка берәү белән бәйләгәндер. Гел тормышка чыкмаган булса да, ничек каршылар әле ул Мөҗәһитне? Яшьлектәге теге тилелек өчен гафу итәрме?

Язмышның ничек ачы итеп мәсхәрәләвен кара инде син, ә? Кирәк бит, шул каһәр суккан кырык беренче елның 21 июнендә Мөҗәһит тилелек эшләп ташлады. Яшьләр Калмыя буендагы өянке янына җыелган ул кичтә кызлар арасында Гөлзада юк иде. Гөлзаданың үзенә ике су тамчысы кебек охшаган сеңелесе Гөлҗиһан, Мөҗәһитнең боек йөзен күреп, үзе килде. «Әткәй белән күрше районга сыер сатарга киттеләр, иртәгә базар көне бит»,— дип, сәбәбен шунда ук аңлатты. Моны ишеткәч, Мөҗәһиткә кичке уеннан кайтып кына китәргә кирәккән, югыйсә. Ә ул нишләптер торып калды. Ут борчасы кебек хәрәкәтчән, һәр тарафта өлгер булган өчен яшьләр арасында «Чытлы» кушаматы алган Хәлимәнең чакыруларына түзмичә, тора-бара уеннарга, биюләргә катнашып китте. Чытлы Хәлимәнең үз каршында бөтерелүен күрү аңлашылмас канәгатьләнү, хәтта кәпрәю хисләре китерде аңа. Яшьлек тилелеге үзенекен итте, шаштырды бугай. Муенчак белән бәйләнгән бозау төсле, Мөҗәһит ул кичтә Хәлимәне озата ук китте. «Бер кичкә ни булган, Гөлзада белмәс әле»,— дип, үзен юаткан иде. Тик базардан кайтып төшкән таңда ук Гөлзада сеңелесеннән ишеткән ул хәлне. Ә көндезен инде авыл өстенә «сугыш» дигән кара болыт таралган иде. Шул кичтә үк хәрби комиссариатка юл алган Мөҗәһитне озатырга Гөлзада килмәде. Мөҗәһит кат-кат сеңелесе Гөлҗиһан аша да дәштереп карады, тыңламады Гөлзада. Күрәсең, үпкәләү-

сызлануы җитди иде. Чөнки кавышырга исәп тотып йөргән чаклары, Гөлзаданыкыларның туй хәстәрен күрә башлаган көннәре иде бит. Өстәвенә Гөлзада соңгы вакытта серле рәвештә һаман бер үк сүзләрне кабатлап йөрде:

— Бер яңалык әйтәсем бар әле сиңа... бар әле.

Их, яшьлек, тилелек диген! Терсәк якын да бит, тешләп булмый.

Тукта, ул кадәр җебеп төшмә әле, капитан! Ничәмә-ничә айлар, еллар Белоруссиянең салкын урманнарында, сазлыкларында ятуың, окопларда җәфалануың белән син соң шушында калдырып киткән сөеклеңнең назлы каршылавына, кайнар кочагына лаек түгелмени? Коелган каның, алган яраларың, егерме җиде яшьтә яртылаш чаларган чәчең, күкрәк тулы орденнарың белән яуладың түгелме соң син ул хокукны? Син бит аның азатлыгы өчен, аны яклап, аны сагынып сугыштың. Кыюрак атла!

Мөҗәһит Гөлзадалар йортына бакча яклап якынлашты. Менә ул таныш тыкрык, сагынылган сукмак. Шулар аша Гөлзадасын күпме озатты да, күпме каршылады ул? Мөҗәһит шушы тыкрык башына килдеме, күңеле сизгән төсле, Гөлзада һәрчак, елмаеп, каршы чыга, үзе оялудан яулык башын иреннәренә тидереп, узып китешли генә пышылдый иде:

— Әти-әни күргәнче, әйдә, тизрәк бакча артына!

Их, хәзер дә шулай капкадан Гөлзада йөгереп чыксын да үзе белән дәшсен иде!

Менә бәбкә үләне белән капланган таныш ишегалды. Әнә, Гөлзада атлап килгән тар сукмаклар.

Болдыр ишеге шыгырдап ачылуга, Мөҗәһит сискәнеп китте. Ямьмыш! Хәтфә үлән өстеннән, йөгереп, киләткә таба баручы бу таныш кыз еллар буена төшләргә кереп юксындырган Гөлзада түгелме соң?

— Гөлзада! — дип кычкыруын Мөҗәһит сизми дә калды. Аягы авыртканны да тоймыйча, ул атлый-йөгерә капкага юнәлде. Кыз, җансыз сындай, селкенмичә, аны ихата уртасында көтә иде.

— Гөлзада, Гөлзадам!

Мөҗәһит аягына эләгеп, ниндидер тагарак һәм бүкәннәр чирәмдә тәгәрәшеп калды. Аларны шәйләп тормастан, Мөҗәһит йөгереп килешкә кызны кочагына алырга теләде. Тик ни өчен артына чигенә ул? Ни өчен аның йөзе һәм күз карашлары шул хәтле куркулы?

— Танымыйсыңмы әллә, Гөлзадам? Бу мин бит, мин исән!

Кызның кулларын күкрәгенә кыскан килеш һаман саен артка чигенүен күреп, Мөҗәһит тә тукталырга мәҗбүр булды. Аптырау һәм сагыну тулы карашлар белән кызга текәлде. Нәрсә булган, нинди үзгәреш бар бу йөздә? Шул ук дулкынланып, иңнәргә таралган коңгырт чәчләр, элеккечә урталары чокырланып торган бит алмалары. Тик бу кашлар, бу карашлар нишләп болай сәер? Әллә Гөлзада инде башканың ярымы?

Мөҗәһит үзгәрешне аңларга өлгергәнче, кыз үзе телгә килде:

— Сез ялгыштыгыз, Мөҗәһит абый. Мин Гөлзада түгел, Гөлҗиһан.

Мөҗәһит шунда гына кылт итеп Гөлҗиһанны искә төшерде, югалып калды.

— Ә Гөлзада кайда, Гөлзада? — дип ашыгып сорады ул.

Гөлҗиһан йөзендәге курку һәм аптырау төсмерләре үзгәрмәгән иде әле. Шулай да ул үзен кулга алып, уйчан төскә кереп җавап бирде.

— Гөлзада апа юк инде, аны эзләмәгез.

— Ничек юк? Ул кайда?

Мөҗәһитнең сораулары капылт, кисәк килеп чыкса да, күрәсең, кыз аларга әзер иде. Ул, алъяпкычын кулларында углап, аз гына сүзсез торды. Мөҗәһит аша үрелеп, йорт болдырына күз ташлады. Аннан, кисәк борылып, Мөҗәһиткә дәште:

— Әйдәгез, минем арттан, Мөҗәһит абый. Бакча артында мин сезгә барын да аңлатырмын.

Мөҗәһит ихтыярсыз рәвештә аңа иярде. Ян капка аша тыкрыкка чыгып, алар яланлыкка атладылар. Баш капкачына нидер дыңгычлап тутырылган төсле, бернәрсә уйлый алмыйча, аягына акрын басып, Мөҗәһит арттан сөйрәлде.

Бакча артында тезелешеп яткан бүкәннәрнең берсенә утыргач, сүзне Гөлҗиһан башлады.

— Сез дә утырыгыз, Мөҗәһит абый. Сизеп торам, аягыгыз авырта.

Мөҗәһит бүкәннәр өстенә урнашуга, Гөлҗиһанның йөзе караңгыланып китте.

— Сез Гөлзада апаны эзләп килгәнсез инде, Мөҗәһит абый, әйеме?

Лəкин бик соң искə төшергəнсез түгелме соң? Сез китүгə инде җиде ел үтте бит. Үзегез турында иртəрəк белгертергə мөмкин түгел идемени?

— Мин бит сугышның беренче аеннан алып партизаннар отрядында...— дип. Мөҗəһит авыз гына ачкан иде дə, Гөлҗиһан кул селтəп туктатты:

— Ə күпме көтте ул сездəн хатларны, күпме тилмереп йөрде? Дүрт ел эчендə кайсы төнен генə ул сезне телгə алмыйча үткəрде икəн дə, кайсы көнне хат ташучыны көтми калды икəн? Шул дүрт ел эчендə нинди əкиятлəр генə сөйлəп бетермəде ул үзенең...

Гөлҗиһан, тотлыгып, ярты юлда туктап калды. Мөҗəһитнең, нидер əйтергə телəп, авыз ачуы аны тагын да ярсытты гына, күрəсең. Ул, əле елаудан кырыслануга, əле усаллыктан кабат елауга күчеп, сөйлəвен дəвам иттерде:

— Ə хəзер кайткансыз менə. Исəнсез, сагынгансыз, имеш. Тик сезнең кайту хəзер кемгə кирəк? Гөлзада апа үзе инде юк бит. Əйе, юк. Өч ел инде аны югалтканга. Барып еларга кабере дə юк мескенемнең.

Мөҗəһит капылт урыныннан сикереп торды. Авыр ыңгырашып, маңгаена ябышты, җиргə тезлəнде. Канлы сугыш кырларында явыз үлемнəрне күп күрде ул, күп кичерде. Əмма монысы...

Гөлҗиһан Мөҗəһит сызлануларын көтеп җиткерə алмады, елый-елый, тагын сөйлəп китте.

— Язгы боз асларына кереп харап булды, җаныкаем. Аны трактор белəн Аю урманыннан агач алырга җибəргəннəр иде. Кайткан юлда Ык өстендə тракторы белəн боз астына төшеп югалды. Тракторын да, агачларын да алдылар соңыннан. Ə апаның, мескен, гəүдəсен дə тапмадылар. Бар иде, юк булды кеше. Кабере дə калмады. Ярый əле үзеннəн... Хəер, сезгə ул ник кирəк? Сез исəн, шул җиткəн. Апа, мескен, көтеп җиткерə алмады. Ə ничек көткəн иде ул, ничек көткəн иде! Кем белə, бəлки, апа шул сездəн өметен өзгəнгə боз асларыннан чыкмый калгандыр.

Мөҗəһит Гөлҗиһанның сүзлəрен ишетте дə, ишетмəде дə. Сугышта тагын бер авыр контузия алгандай, ул, җиргə тезлəнеп, хəрəкəтсез утырды. Гөлҗиһанның тавышы əле якынайды, əле ерагайды. Мөҗəһитнең тамагына төер дə утырмады, күзлəренə яшь тə килмəде. Күңеле катып калды. Əмма эчтə, нəкъ күкрəк турысында, нинди дер көч, бик тилереп, кисəклəргə телə, талый, газаплый, өзгəли иде аны.

Гөлҗиһанның соңгы сүзлəре аңа томан аша гына ишетелде:

— Сөйлəдем, белдегез, Мөҗəһит абый, инде китсəм дə ярый. Лəкин ялварып сорыйм сездəн, китегез авылдан. Тизрəк китегез! Зинһарлар өчен тизрəк!

Гөлҗиһан китте. Мөҗəһит исерек кеше төсле, əвеш-тəвеш килеп, Калмыя буена төште дə, яшьлəр кичке уенга җыела торган өянке төбен табып, үлəнгə капланды...

Икенче таңда, Колмагыр тавы артыннан кояш калыкканда гына, аягына күтəрелде ул. Күтəрелде дə, кыйнап ташланган кешедəй авыр атлап, Мирхəйдəр карт йортына кайтты. Авылда инде һичбер гаме юк, аның өчен күктə кояш сүнгəн иде.

Мирхəйдəр карт, оныгының юл капчыгын җыйный башлавын күреп, əллə ни гаҗəплəнмəде.

— Китəргə ниятлəдең, димəк, улым? — дип элеккечə салмак эндəште.

— Əйе, бабай, китəм.

— Кирəкле бер кешеңне дə тапмадыңмы?

— Тапмадым.

— Шулай микəн?..

Бабасының соңгы соравы сəер булып ишетелсə дə, Мөҗəһит аны аңламый калды. Бу минутта ул аягүрə басып, фуражкасын киеп азаплана иде. Əмма бабасының алдагы сүзлəре аны урынында тараташтай итте:

— Ə улыңны нишлəтəсең? Ул синең белəн китəме?

Мөҗəһит, акрын чүгеп, ишек катындагы эскəмиягə иңде.

— Нинди... улым? — диде ул, ниһаять, тик бераздан гына һəм нык сакауланып.

Бабасының җавабы каты, усал чыкты.

— Үзең белмисең дəмени? Ə Гөлзададан туган улыңны нишлəтəсең? Тормышка да чыкмаган, гөнаһсыз Гөлҗиһан синең балаң белəн тагын күпме чилəнергə тиеш?

Хəбəр Мөҗəһитне корт чаккандай итте. Кинəт колагында айлы кичлəрдə Гөлзада пышылдаган серле сүзлəр кабат яңгырады.

«Бер яңалык әйтәсем бар әле сиңа... бар әле».

Гөлзаданың яшерен сере шул булды микәнни? Димәк, шул. Аның улы бар!

Мөҗәһит, үз бәхетенә үзе ышанмыйча, йөзен күтәреп, тагын бабасына дәште.

— Минем улым бармыни, бабай?

— Бар, улым, бар,— дип бабасы баш изәгәндә, Мөҗәһит инде урамда иде...

Бәйгедән кайткан ат кебек авыр мышнап, Гөлҗиһаннар ихатасына килеп җиткәндә, Мөҗәһит, мичкә кыршавын тәгәрәтеп, үзенә каршы килгән алтыҗиде яшьләрдәге малай белән бәрелешә язды. Каршында әллә кайдан гына килеп чыккан хәрби киемдәге кешене күреп, малай туктап калды. Кул аркасы белән әле борынын, әле төбе тезенә җиткән трусигын тарткалады. Мөҗәһит, килеп, аның каршына чүгәләде, чәчләрен тузгытып шаярткан булды. Дулкынланып торган коңгырт чәчләр, почык борын, таныш күзләр. Әллә соң шул инде?

— Исемең ничек, егет? — дип, Мөҗәһит елмаеп эндәште.

Дустанә мөгамәлә малай күңеленә хуш килде ахры, ул авызын ерып җибәрде.

— Мин җегет түгел лә, малай гына.

— Нинди малай ди инде син? Валлаһи, егет. Кара син бу беләкләрне.

Мөҗәһитнең, шаяртып, куллар кыскалавы малайны тәмам батырайтты.

— Ә мин беләм, абый, син командир.— Ул Мөҗәһитнең погонындагы йолдызларны боргаларга ук кереште.— Минем дә эти командир. Тик ул әле сугышта.

— Сугыш бетте бит инде, туганкай.

— Юк әле, абый, бутама. Минем эти кайтмады, шулай булгач, сугыш та бетмәгән. Менә ул кайтты исә, сугыш бетә. Ә син аны сугышта күрмәдеңме?

Мөҗәһит үз авызыннан атылып чыккан сорауны шәйләми дә калды.

— Ә исеме ничек аның?

— Мө-җә-һит,— дип, малайның тырышып-тырышып үз исемен вакткалавын ишетүгә, Мөҗәһит тыела алмады. Ярсып, малайны кочагына кысты, онытылып-шашып үбәргә тотынды. Үзе үбә, ә үзе күз алдын томалаган ачы яшьләр аша берни күрми иде. Мөҗәһитнең аңа: «Улым, улым, мин синең әтиең»,— дип эндәшәсе килде, теле әйләнмәде. Улының муенын, яңакларын күз яшьләренә чылата-чылата, һаман үпте, һаман үпте.

Кинәт улын аның кочагыннан суырып алдылар. Баш очында гына Гөлҗиһанның елау катыш ачулы тавышы ишетелде.

— Апам серен җиткергәннәр, димәк. Ләкин өметләнмә, мин Мирзанурны бирмим, Мөҗәһит абый. Гөлзада апаның бөтен хатирәсе шушы. Бирмим, бел шуны. Кит лутчы авылдан. Телгәләмә сабый йөрәген.

Гөлҗиһан җитәкләгән килеш артына борылып карый-карый атлаган малайны Мөҗәһит җиргә тезләнгән көенчә озатып калды...

Кичкә таба инде ныклы карарга килеп, тагын таныш ихатага кергәч, әйтерсең лә, Мөҗәһит утка пеште. Ихатада һичбер хәрәкәт юк, болдыр келәсе бөтенләй йозакта иде. «Әллә мин килүдән куркып, Гөлҗиһан Мирзанур белән авылдан ук чыгып качканмы?» — дигән уй Мөҗәһитне янә өтеп алды. Манма тиргә батып ул авыл урамнарын әйләнде, кабат йортка кайтты. Ишектә һаман йозак күргәч, ярсып, елга буена йөгерде. Калмыя буендагы ташлык ягыннан ниндидер авазлар ишетелгәндәй тоелгач, шунда таба йөгерде. Кичке эңгер-меңгер аша су өстендә томанлы шәүләләр пәйда булды. Елга уртасында, комлыкка батып, кул арбасы туктап калган. Арбага биек итеп төялгән коры-сары өстендә ботакларга нык тотынып Мирзанур утыра. Ә итәкләрен ботларына кадәр сызганган Гөлҗиһан арба тәртәләре арасына кереп баскан да бар куәтенә аны әле артка этә, әле алга сөйри. Сөйри, тик арбаны комнан чыгара алмый.

Яр өстендә ни эшләргә белми югалып калган Мөҗәһитне күреп, Гөлҗиһан түзмичә, авыр ыңгырашып, аңа эндәште:

— Ярдәм ит инде, Мөҗәһит. Берүземә генә дөнья көтүләр, ай, авыр бит.

# КИЛӘЧӘК — ҺӘРКЕМНЕҢ ҮЗ КУЛЫНДА

1986 елның февраль аенда Татарстан Язучылар союзының яшьләр комиссиясе һәм яшь авторлар белән эшләү бүлеге үткәргән конференциядә безне шатландырган күңелле бер хәл булды: татар әдәбиятына сәләтле һәм белемле берничә прозаик килгәне күренде. Шулар арасында Вахит Имамов та бар иде. Без аның ике йөз битле кулъязмасын укып чыктык. Анда «Акъял ялгыз түгел» исемле повесть һәм ун хикәя тупланган иде.

«Акъял ялгыз түгел» дигән повестенда ул Акъял исемле ат язмышы аша бүгенге яшьләр тормышын сәнгать чаралары белән укучыны мавыктырырлык итеп ачып бирә алган. Сюжеты төзек, теле үткен, халыкчан. Хикәяләре дә тормышны белеп, яратып, уйланып язылган. Табигать белән кеше мөнәсәбәте, хайваннар дөньясы, авыл кешеләренең тормышы, күңел тибрәнешләре хикәяләрдә күңелгә ятышлы итеп бирелә. Иң мөһиме — Вахит Имамов әсәрләрендә кеше язмышлары, характерлар бар. Вахитның әдәби иҗат эшенә җаваплы каравы семинар алып баручыларга ошады.

Вахит 1954 елны Актаныш районында туган. Казан университетын тәмамлаган. Журналист. Беркадәр вакыт район газетасында эшләгән. Хәзер — КамАЗда инженер. «Ләйсән» әдәби берләшмәсе утырышларында актив катнаша.

«Казан утлары» журналы үзенең укучыларына бу санда Вахит Имамовның «Таныш тыкрык» дигән хикәясен тәкъдим итә. Ул хикәя дә, конференциядә тикшерелеп, уңай бәя алган иде.

Укучылар сизгәндер: хикәя кыска һәм шактый ук тыгыз язылган. Сугыш беткәннән соң ике елдан соң гына авылга кайткан капитан Мөҗәһитнең игътибар казанырлык кеше икәнен яшь автор хикәянең башында, койма өсләренә кунган бала-чага сөйләше, аннары өлкәннәр диалогы аша үтемле итеп яза.

Гөлзада, Гөлҗиһан образлары хәтергә уелып кала. Авыр сугыш елларында тракторы боз астына киткән Гөлзада, аның Мөҗәһит югында туган баласы, капитанның улы белән тәүге мәртәбә очрашуы, Гөлҗиһанның, апасы һәлак булгач, кияүгә чыкмыйча аның ятим улын үстерүе — болар барысы сугыш заманының фаҗигале хакыйкатен ачып бирәләр.

Вахит Имамовка мин, үз нәүбәтемдә, хәерле юл телим. Халык тормышыннан аерылмаса, телне өйрәнүен туктатмаса, ирешкәннәреннән канәгать булып, масаеп йөрмәсә, озын сүзнең кыскасы — үз-үзенә таләпчәнлеген арттыра барса, киләчәктә аңардан зур колачлы, җитди язучы чыгуы мөмкин. Мин моның шулай булуын бик тә телим.

**Гариф АХУНОВ.**

## Мәхмүт Хәсәнов

# УРМАН КАЙТАВАЗЫ

*«Табигатьне саклау — Ватанны саклау ул».*

М. Пришвин

Кеше гомеренең иң гүзәл сәхифәләре, җуелмас тирән эз калдырган истәлекле мизгелләре табигать белән бәйле. Тәүге адымнардан ук без кояшлы якты көнгә, хәтфәдәй яшел чирәмгә омтылабыз. Күп тә үтми, ныгый төшкән тәпиләрең сине аллы-гөлле чәчәкләр белән бизәлгән яшел болынлыкка, каз-үрдәкләр йөзеп йөргән агымсу буйларына алып төшә. Анда исә — мәһабәт таулар тезмәсе, бөтен офыкны иңләгән, иге-чиге күренмәгән кара урманнар... Җир-ана үз баласына торган саен күбрәк серләрен ача, гүзәллеге белән сихерли, әсир итә.

Табигатьнең һәр нәрсәсе газиз, кадерле безгә.

Хәер, башкача булуы мөмкин дә түгел. Чөнки кешенең үзен табигать барлыкка китергән. Табигать — безнең яшел бишегебез. Бала ана карынына кендеге белән бəреккән кебек, кеше күп төрле физик, биологик, психологик элементләр белән табигатькә бәйле. Аларны өзү — үз-үзеңне һәлакәткә дучар итү дигән сүз.

Сүзебез табигать күрке — урман турында. Урман! Ирексездән Тукаебызның данлы «Шүрәле»сендәге юллар искә төшә: «...Бик хозур! Рәт-рәт тора гаскәр кеби, чыршы, нарат, төпләрендә ятканым бар, хәл җыеп күккә карап...»

Урман һәрчак үзенчә матур. Киң яфалдашлы меңьяшәр имәннәр, озын толымлы каен кызлары, серләшеп туймас усак егетләре, бөдрә зирекләр кемнең генә күңелен тыныч калдыра алыр икән! Ирексездән, үзен табигать баласына санаган тагын бер сөекле шагыйребез Һади Такташ сүзләре искә төшә:

Мин җир өстен артык сөйдем бугай,
Артык сөйдем аның гөлләрен,
Һәрбер буйга җиткән каен кызын
Усак егетеннән көнләдем...

Урман борын-борыннан кешенең тугры юлдашы булган. Урман турында әкиятләр сөйләнгән, риваятьләр, җырлар чыгарылган, аңа мадхия укылган. Гаҗәп тә түгел. Чөнки урман кешене киендергән, ашаткан-эчерткән, җылыткан, кирәк чагында яу-дошманнан саклаган.

Күп кенә илләрдә урман, агач хәзер дә изгегә санала. Андый агачларны төрлечә бизиләр, аларны кисмиләр, башына үрмәләмиләр, җимешләрен бары тик сырхау кешеләргә им итеп бирәләр. Вьетнамлылар, мәсәлән, агачларны үлгән кешегә саныйлар, «безнең үлгән якыннарыбыз» дип атыйлар. Ә Ливанда эрбет агачы — хәзер дә «оҗмах агачы», агачларның патшасы булып санала. Белгәнебезчә, Ливанның дәүләт флагын эрбет агачы бизи.

Безнең илебездә дә тере һәйкәл булып саналган истәлекле агачлар бик күп. Алар — дәүләт байлыгы, берни белән дә алыштыргысыз хәзинә. Гадәттә андый агачлар олы шәхесләр — бөек әдипләр, композиторлар, рәссамнар исеме белән бәйле. Мәсәлән, Спасскида Тургенев тарафыннан утыртылган имән үсә. Иван Сергеевич, чит илдә каты авырып ятканда, шагыйрь Я. Полонскийга язган хатында болай ди: «Спасскида булганда, минем өемә, бакчама, яшь имәнемә, туган ягыма баш иегез...» Хәзер инде ул имәнгә дә 150 яшь тулып узды.

Михайловскида, Ясная Полянада, Кырлайда, Тарханда да бар андый кадерле агачлар.

Табигатьнең кешедә матур әхлак, завык тәрбияләү ягыннан тәэсир итү көче берни белән дә чагыштыргысыз. Бу хакта бөек педагог Ушинский язмалары аеруча гыйбрәтле. Атаклы язучыбыз, «Рус урманы» романының авторы Леонид Леонов: «Табигатьне танып-белгән, аның белән якыннан аралашкан кеше саф күңелле, кешелеклерәк һәм намуслырак була, чөнки ул табигать куенында «күңел университетын узган»,— дигән фикер әйтә. Лев Толстой да, көннәренең берендә, иң яраткан урыннарыннан, урман буйларыннан әйләнеп кайтканнан соң, көндәлегенә: «Гүзәл табигать куенында булганнан соң, кешедә ачу тоту, үч алу яки үзе кебек үк башка берәүне юк итү кебек хис уяна алырмы икән! Табигать белән, шундый илаһи гүзәллек белән якынайганнан соң кеше күңелендә булган барлык әшәкелек, яман уйлар юкка чыгарга тиеш бит ,— дигән сүзләрне язып куя.

Күргәнебезчә, урманга без материаль байлык, шәхси хуҗалыгыңны ныгыту чыганагы, төзү, ягулык материалы, кәгазь, җиһаз, тагын 30 меңгә якын төрле әйберләр эшләп чыгару чималы итеп кенә түгел, ә рухи хәзинә, халкыбызның табигый дәвалаучысы, күңелгә ял бирү, илһам һәм көч туплау урыны итеп тә карарга тиешбез икән әле. Көндәлек тормышыбызда урман тарафыннан безгә бирелгән «бүләкләр» санап бетергесез. Ул безнең сулыкларыбызны саклый, климатны тотрыклы итә, басу-кырларыбызны эрозиядән саклый, санитария-гигиена ягыннан әһәмияте турында әйтеп торасы да юк. Кыскасы, урман — җирдәге барлык тереклекнең яшәве, үсеше өчен кирәк булган барлык шартларны тудыручы ул. Әгәр дә без мәгърур иманнәр, зифа наратлар, сипкелле-сөйкемле каеннарыбызның һәрчак туган җиребезне бизәп торуын телибез икән, табигатьне күз карасыдай сакларга тиешбез.

Хәзер, ифрат кызу темпларда үскән индустрия, фән-техника революциясе шартларында табигатькә дөрес мөнәсәбәт тәэмин итү — кешелек алдында торучы иң җитди, глобаль мәсьәләләрнең берсенә әверелде.

«Җир бер генә ул...» Тирә-юнь мохитны саклау буенча Халыкара хезмәттәшлекнең девизы шундый. Туфрагы, урман-суы, һавасы, җир асты байлыклары — барысы да шунда. Кешелек дөньясының киләчәге шул хәзинәләрнең ни дәрәҗәдә дөрес саклап тотылуына бәйле.

...Дөнья галимнәре урманны: планетабызның «үпкәсе» дип атыйлар (бер олы агач һәр тәүлек саен уртача 180 литр кислород «җитештерә»). Әмма шунда ук, авыл-шәһәрләребезне кислород белән тәэмин итеп, өзлексез сафландырып торучы урманнарыбызга яман чир яный дип кисәтергә дә онытмыйлар. Шул ук галимнәр, политик эшлекләр, чиркәү әһелләре яки сихерчеләрнең күрәзәлек итүләренә караганда, бик тиздән, атом-төш сугышыннан башка да, безнең планетабызда биологик катастрофа булырга тиеш. Җир йөзе ай ландшафтына охшап калачак. Кая карама, кешеләр чыгарып ташлаган чүп-чар өеме, көлсу-сары туфрак, шәрә калкулыклар, коры ярлар... Ә тереклек дөньясы күселәрдән, тычканнардан һәм кеше өчен яман да куркынычлы бактерияләрдән генә торачак...

Бу яман күрәзәчелектә күпмедер хаклык бармы соң? Нишләп соң әле тирә-юнь мохитны саклау мәсьәләсе соңгы вакытта бөтен кискенлеге белән көн тәртибенә килеп басты? Җир-анабызның хәле, чыннан да, шулкадәрле үк аяныч, шул кадәрле үк куркынычмыни? Бәлки бу берни белән дә акланмаган уйдырма, берни белән дә нигезләнмәгән куркыту гынадыр? «Правда» газетасының «Историческая миссия рабочего класса: новые аспекты» дигән мәкаләсендә мондыйрак сүзләргә юлыктым: Эшчеләр сыйныфының дөньякүләм тарихи бурычына бүген аеруча мөһим тагын ике мәсьәлә өстәлә. Берсе — планетабызның барлык кешеләрен коткару булса, икенчесе — табигатьне саклау, чөнки монысы кешелекнең яшәвен яки һәлакәтен хәл итүдә төп рольне уйный.

Юрий Гагарин космоска очканнан бирле, кешелек дөньясы Җир шарының «бер бәләкәй, гүзәл зәңгәр шар» икәнлеген ап-ачык белде. Шулай ук эчәр суыбызның, сулар һавабызның, туклану өчен уңдырышлы җирләребезнең бик чикләнгән булуы да мәгълүм. Шуңа өстәп, Җир шарындагы халыкның гаять зур тизлек белән артуын, инде 5 миллиардка җитүебезне дә әйтик. Ә бары тик соңгы ярты гасыр эчендә генә дә 120 төрле җәнлек-җанварларның, 150 тәрдән артыграк кош-кортның, йөзләрчә исемдәге үсемлекләрнең бетүгә йөз тотуы, кайберенең бөтенләй юк ителүен дә яхшы беләбез. Галимнәр, әгәр дә без табигатькә карата бүгенгедәй рәхимсез булсак, табигать законнарын санга сукмасак, рәхим-шәфкать көтәргә хакыбыз юклыкны, киләчәктә зур фаҗига туасын һаман тәкрарлап, исбатлап, раслап торалар.

Шул ук планета «үпкәсе» булып саналган урманнарга гына игътибар итик. Космостан төшереп алынган фотолардан күренгәнчә, Африка, Америка, Австралия өстендә төтен-ялкын пәрдәсе — урманнар яна.

Африка аеруча авыр хәлдә. Бүгенге көндә анда 150 миллионнан артык халык ачлык-ялангачлыктан интегә. Мисалга Африканың бер генә илен — Эфиопияне генә алыйк. Беренче һәм иң төп сәбәп шул: феодал-монархия режимы вакытында урман ресурслары ерткычларча таланган булган. Шәрә басуларны корылык көндерә.

Көньяк-көнчыгыш Азия илләрендәге урманнар да мәрхәмәтсез рәвештә киселәләр, корытылалар, комсыз монополистлар тарафыннан вәхшиләрчә талананалар. Газеталар хәбәр итүенчә, һәрбер минут саен җир шарында 40 гектардан артыграк тропик урманнар юк ителә. Урманнар бүгенге темплар белән киселсә, 10-15 елдан үсемлеккә бай булуы белән дан тоткан архипелагның урманнары тулысынча кырылып бетәчәк. Әлеге комсызлыкның нәтиҗәләре хәзер үк инде үзен бик нык сиздерә. Шри Ланкада, мәсәлән, илнең төп байлык чыганагы булып саналган чәй уңышы ел да 4,5—5 процентка кими башлаган. Сәбәбе бер — урманнар күп киселү аркасында, тирә-юньгә төзәтеп булмаслык зыян җиткән.

Көнбатышның алга киткән индустриаль илләрендә дә урманнарның язмышы торган саен аянычрак төс ала. Мәсәлән, «урман чумасы» дип телгә кергән агачлар авыруыннан бары тик бер Австрия генә дә елына 3 миллиард шиллингка зыян күрә. Агачлар кору, сирәгәю нәтиҗәсендә сөзәк тау битләрендә яман эрозияләр башланган, таукыялар ишелү куркынычы арткан. Кайчандыр илнең иң матур саналган Альп болынлыкларында яшәүчеләр, башка урыннарга күчеп китә башлаганнар. Шулай итеп, мәйданының 45 процентын урманнар билап торган Австрия, белгечләрнең әйтүенә караганда, ташлы чүлгә әверелү куркынычы алдында тора икән.

Австрия чигенең икенче ягында — Альп тауларының Германия Федератив Республикасы территориясендәге урманнарның язмышы тагын да яманрак. Тау битләренең уңдырышлы катламы тулысынча юылып беткән. Ил галимнәре, бу бәладән котылу юлын күрсәтеп, проект тәкъдим иткәннәр: таулыкларга, вертолетлар ярдәмендә черемә ташып, яшь агачлар утырту. Экономистларның исәпләвенчә, әлеге ысул белән утыртылган һәрбер төп агач 1 миллион маркага төшәчәк.

Иң яманы — әлбәттә, кешенең табигатькә карата усал ният белән, җинаять эшләве. Моннан берничә ел элек, Америка илбасарлары Вьетнам җирендә хәрби промышленность комплексы тарафыннан хәзерләнгән «кызгылт-сары яңгыр» дип аталган яңа төр химикат белән «тәҗрибә» үткәрде. Нәтиҗәдә халык һәлак булу белән бергә, меңнәрчә һәм меңнәрчә гектар урманнар корып чыкты.

Менә тагын җан тетрәндергеч хәбәр. Америка империалистлары Бразилиядә, Амазонка елгасы бассейнында, яңадан геноцидлык адымы ясадылар. Төзелә торган ГЭС сусаклагычы булачак урынны урманнардан чистарту сылтавы белән, тереклек өчен тагын да яманрак, «Ак пудра» дип аталган яңа төр химикат сынап карады. Нәтиҗәдә ике мең ярым квадрат километр мәйданында уникаль урман, 7 мең кеше, шул исәптән индеецларның ике кабиләсе тулысынча юк ителде. «Бразилия фаҗигасе» дип аталган бу вәхшилек бөтен дөнья халкын тетрәндерде.

Күргәнебезчә: «Бүген — табигать харап булса, иртәгә — без»,— диярлек сәбәпләр җитәрлек. Үзеннән-үзе: «Бу бәладән котылу юлы, тирә-юнь мохитны саклап калу мөмкинлеге бармы соң?» — дигән сорау тууы мөмкин. Бар, әлбәттә. Моның өчен беренче чиратта, алга киткән индустриаль илләрнең кичекмәстән котырынып кораллануын авызлыкларга, бушаган мөмкинлекләрне тирә-юнь мохитны саклауга, торгызуга юнәлдерергә кирәк. Кеше көчле. Хәзер планетаның язмышы тулысынча аның кулында. Табигатьне үзенә буйсындырган, хезмәт итәргә мәҗбүр иткән кебек үк, табигый байлыкларны сакларга да күп төрле чараларны тормышка ашыра ала ул. Яшел бишегебезне һәлакәткә илтергә юл куярга һич ярамый.

...Табигать — бер бөтен: ул социалистик яки капиталистик була алмый. Сүз бары тик тирә-юнь мохиткә карата мөнәсәбәт турында гына баруы мөмкин. Табигатьне саклау, аерым алганда, урманнарга мөнәсәбәт бездә ничегрәк соң? Башта ук шуны әйтәсе килә: бездә — бөтен байлык халыкныкы булган илдә — дәүләт экономикасы планлы төстә алып барыла торган илдә, тирә-юнь мохитны саклау, аның ресурсларыннан рациональ файдалану мәсьәләсе һәрвакыт игътибар үзәгендә торды һәм тора. Совет властенең беренче елларында ук, В. И. Ленин табигатькә һәм аның ресурсларына социалистик мөнәсәбәт таләп итте. Аның васыятьләрен үти барып, без табигатькә мөнәсәбәтне яхшырту өчен күп төрле чараларны тормышка ашырабыз.

Урманга бай булуыбыз ягыннан без дөньяда беренче урында торабыз. СССРда планетадагы бөтен урманнарның дүрттән бере урнашкан. Шулай ук урман кисү, агач хәзерләү темплары һәм күләме буенча да безнең ил беренче урында: елга миллион кубометрдан да артыграк файдаланабыз. Әгәр дә агачның бик акрын үсүен, аңардан бары тик 50—60 елдан соң гына файдаланырга мөмкин икәнлеген исәпкә алсак, нинди генә байлыкның да әллә ни озакка бармаячагын аңлау кыен булмастыр.

Әмма безнең мондый халгә әллә ни исебез китми, моңа без табигый бер күренеш итеп карыйбыз. Чөнки без, белгечләрнең исәплап чыгаруыннан күренгәнчә, илебез территориясендә бер елда үскән урманнарның бары тик яртысын гына алабыз икән.

Табигать, күргәнебезчә, бик бай һәм иффрат юмарт. Акыл белән эш иткәндә, аның байлыгын тагын да күбәйтергә, юмартлыгын тагын да арттырырга мөмкин. Безнең галимнәребез урманнарны тизрәк һәм сыйфатлырак үстерү чаралары эзлиләр. Бу хакта без игенче, бакчачы уңыш турында кайгырткан кебек үк уйланып эш итәргә тиешбез.

Тырышлыкның нәтиҗәсе дә күз алдында: тәҗрибә урманнарында үстерелгән 25 яшьлек наратлар, табигый шартларда үскән 50 яшьлек агачларны озынлыкка да, юанлыкка да узып киткән.

Әмма бездә урман байлыгы һәркайда да хуҗаларча файдаланылмый. Урман хәзерләү, агач кисү ысуллары заман таләпләренә җавап бирми. Агачны әрәм-шәрәм итмичә эшләү, калдыксыз технология алымнары практикага гаять акрын кертелә. Менә бер мисал. Урман һәм агач эшкәртү институты директоры академик А. С. Исаев, «Комсомольская правда» газетасы хәбәрчесенә биргән җавапларында: бары тик Игарка һәм Лесосибирск агач эшкәртү флагманнарында гына да, агачның 40 һәм аннан да артыграк проценты әрәм-шәрәм ителә... Япониядә, мәсәлән, бездән сатып алынган шул агачның кайры-кабыгы, төбе-тамыры да файдаланыла икән.

Димәк, урманнарыбызны сакчыл тоту, урман ресурсларыбыздан рациональ файдалану өлкәсендә өйрәнәселәребез бихисап.

1978 елда илебездә «Урман законы кодексы» кабул ителде. Бу турыда җирле оешмалар, әлбәттә, яхшы беләләр. Әмма агачны төрлечә әрәм-шәрәм итүләр әле һаман чикләнми, һаман дәвам итә. Мәсәлән, күп кенә очракларда киселгән урман урынына, тиешле дәрәҗәдә чистартылып, «Урман законы кодексы»нда күрсәтелгәнчә, яшь үсентеләр утырту чаралары күрелми. Бу бит һәр урман хуҗалыгының төп эше, законда каралган бурычы. Киселгән агачларның еллар буена урманда калдырылып, муртаеп, тәмам эштән чыгарылуы, утынга да ярамас хәлгә килүе шулай ук еш очрый.

Урман утырту, үстерү һәм бигрәк тә саклаудагы кыенлыкларның исәбе-хисабы юк. Бер мисалга гына тукталыйк. Яңа ел җиттеме, ничәмә-ничә миллион төп чыршы белән нарат агачы киселә. Шулай итеп, балаларыбызның иң куанычлы бәйрәмнәре, яшел дустыбыз — урман өчен, бәлагә, фаҗигагә әверелә.

Бу өлкәдә, «Таш иле» булып саналган Әрмәнстанның тәҗрибәсе, чын мәгънәсендә, хуплауга лаек. Анда Яңа ел алдыннан чыршы кисү закон нигезендә тыелган. Шуның нәтиҗәсе буларак республикада ел да ярты миллионнан артыграк ылыслы агачлар сакланып кала. Аңа карап, чыршы бәйрәменең яме китми, түр башларына, бик матур иттереп ясалган, хәтта ылыс исе бөркелә торган синтетик чыршылар куела. Хәзерге вакытта, җиңел промышленность Министрлыгы предприятиеләре тарафыннан ел да миллионлаган ясалма чыршылар чыгарыла.

Яшел дустыбызның тагын бер бик дәһшәтле дошманы бар: урман янгыннары. Урманда булган һәр янгын, нинди генә күләмдә булмасын, һәрчак хәвефле. Кечкенә янгын вакытында да күпме яшь агач, никадәрле кош оясы, җәнлекләр һәлак була.

Янгыннарның 95 проценты диярлек кеше гаебе белән чыга. Аларның күбесе янгынга каршы көрәш чараларын үтәмәүдән килә: сүндерелми калдырылган учаклар, шырпы яки тәмәке төпчеге ташлау, урман чистартканда саксызлык күрсәтү һ. б.

Боларга табигатьнең үзеннән чыккан янгыннар да өстәлә. Андый хәлләр гадәттә, яшен сугудан яки корылыктан башланып китә. Андый янгыннар, үч иткәндәй, кеше аяк басмаслык урыннарда чыгалар, шунлыктан аларны сүндерү шактый озакка сузыла һәм бик кыйммәткә төшә.

Янгын чыгуның беренче минутларында аны бер кеше дә бастыра ала. Бер сәгатьтән соң инде янгынны сүндерү өчен яхшы коралланган тулы бер команда кирәк. Бер тәүлектән соң исә районда яшәүче бөтен халыкны аякка бастыру да ярдәм итә алмаска мөмкин.

...Татарстанда урманнар 1 миллион 113 мең гектар мәйданны били. Алар республиканың 16,4 процентын тәшкил итә. Азмы бу, күпме? Моны ачыклау өчен, янә саннарга мөрәҗәгать итик. Республикабызда кеше башына 0,36 гектар урман туры килә. Әгәр дә күршеләребез Башкортстанда — 1,59, Киров өлкәсендә — 3,5, ил буенча 3 гектар туры килүен исәпкә алсак, республикабызда урманнарны ишәйтергә кирәклеге турында исбат итеп торуның кирәге юктыр.

Алда әйтеп үткән урман мәйданнары елдан-ел кими, торган саен сирәгәя. Борынборыннан, Лашман заманнарыннан бирле безнең төбәкнең горурлыгы булып саналган иманнәр, соңгы ярты гасыр эчендә генә дә ике тапкыр корыды. Аның беренчесе кырыгынчы елларда, ә икенчесе 1978—1979 елгы кышкы салкыннар нәтиҗәсендә булды.

Шулай да безнең республика урманлы регионнардан санала. ТАССР урман хуҗалыгы министрлыгының 22 хуҗалыгы, 8 предприятие һәм техникумы бар. Республикабызда ел саен 2,8 миллион кубометр чамасы агач хәзерләнә. Бу — Татарстанның агач материалларга ихтыяҗының 60 процентын гына тәшкил итә. Шунлыктан киләчәккә булган планнарны тормышка ашыруда урман индустриясенең һәр предприятиесе үзен җаваплы тоя һәм, халык куллану товарларын күбрәк җитештерү өчен, эчке мөмкинлекләрне тулырак эшкә җигү чараларын күрә. Шуның нәтиҗәсе буларак, Татарстан урманчылары һәр елны 20 миллион сумнан артыграк продукция җитештерә.

Партиянең XXVII съезды карарларын һәм КПСС Үзәк Комитетының аннан соңгы күрсәтмәләрен истә тотып, безнең урманчылар производствода калдыксыз технологияне мөмкин кадәр тулырак файдалану юлларын эзлиләр, киң куллану товарлары-

ның шактый гына төрләрен элек ташланып барыла торган калдык-постыклардан ясыйлар.

Республикабыз урман промышленносте предприятиеләре арасында барган социалистик ярышта Хезмәт Кызыл Байрагы орденлы Кама урман хуҗалыгы алдынгылыкны үзендә тота. Бөтенсоюз социалистик ярышында да җиңүче дип табылды. СССР Халык Хуҗалыгы казанышлары күргәзмәсендәге Бөтенсоюз Мактау тактасына кертелде.

Монда «калдыктан байлык» ясау тәҗрибәсе тупланды. Мәсәлән, фанера цехында махсус агрегатлар аша үткән каен агачы тасмаларының түбән сыйфатлылары элегрәк мичкә ягыла иде. Хәзер исә ул калдыкларны файдалану әмәлен тапканнар, алардан мебель фабрикасы өчен бик кирәкле чимал алына.

Биредә агач ылысын витаминлы онга әверелдерү буенча да күп эш башкарыла. Кискәндә, тураганда чыккан йомычкалар, ботаклар, агач очлары, халык куллану товарлары җитештерүгә тотыла. Имән калдыкларыннан гади һәм бизәкле паркетлар, панельләр, эрҗәләр, көрәкләр ясала. Халык куллануы товарларының төре хәзер утызга җитте. Соңгы вакытта монда ипи тартмалары ясый башладылар.

Республикабызда иң күп чәер җыючылар да — шушы хуҗалыкта. Чәердән, билгеле булганча, канифоль һәм скипидар ясала. Чәер тамчылап җыела. Һәр эшче елга 5 тонна чәер тапшырырга тиеш. Тик бу норманы арттырып үтәүчеләр дә бар. Коммунист Габделәхәт Сибгатуллин, мәсәлән, бер елның 7 аенда гына да 15 тонна чәер җыеп тапшырды.

Менә шундый алдынгы урманчыларның тырышлыгы белән бу бердәм коллектив 7 айда гына да ярты миллион сумлап саф табыш алды.

Хөрмәтле укучы, әгәр дә сезгә Кама урман хуҗалыгында булырга туры килсә, контора юлының ике ягында утыртылган көмешсыман чыршыларга игътибар итүегезне сорар идем. Аларның һәркайсы янына язулы такта куелган. Монда шундый гадәт — һәрбер истәлекле вакыйга агач утырту белән билгеләнеп үтелә.

Бөек Октябрьнең 50 еллыгы хөрмәтенә җәелдерелгән социалистик ярышта коллектив күркәм уңышларга ирешә. Шул уңайдан аңа КПСС өлкә комитеты, ТАССР Верховный Советы Президиумы, Татарстан Министрлар Советы һәм профсоюзлар өлкә Советының Истәлек байрагы мәңге саклауга тапшырыла. Беренче чыршы шул вакыйга хөрмәтенә утыртылган.

Бөек юлбашчыбыз В. И. Ленинның тууына 100 ел тулу уңаеннан коллектив Юбилей Почет грамотасына, социалистик ярышта җиңгән өчен КПСС Үзәк Комитеты, СССР Министрлар Советы, ВЦСПС һәм ВЛКСМ Үзәк Комитетының күчмә Кызыл байрагына лаек булган. Алар истәлегенә дә чыршылар утыртылган. КПССның XXVII съезды, ВЦСПС һәм ВЛКСМның соңгы съездлары ачылу хөрмәтенә утыртылган чыршылар да бар. Хәзер анда һәр зур җиңү, һәр мөһим вакыйга хөрмәтенә багышлап утыртылган агачлар, үзләре тулы бер аллея тәшкил итә.

Орденлы Кама урман хуҗалыгы турында сүз чыккач, бу хуҗалыкка 40 ел гомерен биргән, шуның 20 елын директор булып эшләүче Иван Захарович Иванов турында да бер-ике авыз сүз әйтеп узмыйча ярамас. Ул — коллективның акыллы җитәкчесе, табигый хәзинәбезне арттыруга бөтен көчен, сәләтен биргән кеше. Унберенче бишьеллыкта ирешкән фидакарь хезмәтләре өчен аңа Социалистик Хезмәт Герое дигән мактаулы исем бирелде.

— Минем омтылышым — җирдә яңа урманнар үстерү,— дип сөйли ул.— Мәһабәт нарат һәм чыршы урманнары өстендәге зәңгәр күктә һәрвакыт кояш елмаеп торсын, дөньялар имин булсын — теләгем шундый.

Иван Захаровичның тагын бер күркәм сыйфаты турында әйтеп үтмичә мөмкин түгел: ул яңа буын урманчылар хәзерләүгә, яшьләрдә табигатькә карата мәхәббәт тәрбияләүгә зур көч куя. Хуҗалыкта укучылар бригадасы оештырылган.

Республикадагы Кайбыч урман хуҗалыгы яшь урман үстерү буенча мактала. Бүгенге көндә республикабыз урман индустриясе тармагы хезмәтчәннәре ел саен 10.000 гектардан күбрәк мәйданда төрле агач орлыгы чәчәләр һәм яшь үсентеләр утырталар. Бу мактаулы эшләрнең күпчелек өлеше Кайбыч урманчыларына бәйле.

Берсендә «Социалистик Татарстан» газетасы редакциясенә Кайбыч урман хуҗалыгы директоры Илгиз Хаффазов шалтырата.

— 35 ел буе урманга хезмәт күрсәткән Хаҗи ага Сәлаховны пенсиягә озатырга җыенабыз. Рәхмәт йөзеннән, аның турында газетада да сөйлисе иде!

Озак та үтми, газетада М. Рәфиковның «Имәннәр иллеДә балигъ була» дигән мәкаләсе басыла. «Аның чандыр һәм нык гәүдәсен имән кебек тәз тотып атлавын күзәттем,— дип яза автор.— Ягымлылык, ихласлык, сихри көч бар иде бу кешедә. Тагын сокландырганы шул булды: Сәлаховның 300 гектар урман утыртуын, түйраларның 95 проценты үсеп китүен бөтен залга хәбәр иттеләр. Кеше, гомерендә бер генә агач утыртса да, үзенә һәйкәл куя диләр. Монда йөзләгән гектар, меңләгән тәп: имәннәр, карагайлар, нарат-каеннар...»

Хаҗи ага Сәлахов ялда инде. Ләкин ул үзе утырткан яшел дәрьясыннан аерыла алмый. Ул — аның сүз белән әйтеп аңлатып булмаслык зур куанычы да, бәхете дә. Шулай булмыйни! Буш урында үз кулларың белән утыртылган урманның күтәрелүен,

күкләргә ашып үскән агачларның бөреләре ачылуын күрү — зур шатлык түгелмени? Без аңа үзе утырткан иманнарнең шаулап чәчәк атуын күрергә язсын дип телик! Иманнар илледә генә балигъ булалар, ягъни илле яшькә җиткәч кенә чәчәк аталар.

Кайбыч урманнары элек-электән илдә иң таза, сыйфатлы урманнар исәбенә керә. Мондагы урманчылар орлыкчылык белән шөгыльләнә. Кайбыч урманыннан илебезнең төрле якларына тонна-тонна төрле агач орлыклары озатыла.

Партия һәм хөкүмәтебезнең: «Урман чималы ресурсларын файдалануны яхшыртырга!» — дигән күрсәтмәләрен истә тотып, республикабызның урман промышленносте предприятиеләре халыкның ихтыяҗларын тагын да тулырак канәгатьләндерү өчен тырышалар. Азнакай урман хуҗалыгы уңганнары җитештерә торган продукциянең, мәсәлән, 40 процентттан артыграгы — халык куллану товарлары. Авыллар өчен стандарт йорт бураллары, чаналар да ясыйлар алар. Әрҗәләр, мичкәләр, урам һәм мунча себеркеләре, йөзләрчә тонна ылыс оны һәм башкалар. Шулар янына тагын ел да хәзерләнә торган җиләк-җимеш, гөмбә, бал, дару үләннәре һәм башка төрле урман хәзинәләрен өстәргә кирәк.

Һәрбер урман предприятиесенең үзенә генә хас продукциясе дә бар. Саба урманчыларының Мишәбаштагы ярдәмче хуҗалыгы турында бер-ике сүз әйтеп узасы килә. Монда умартачылык шактый табыш бирә. Узган җәйнең шактый ук четерекле килүенә дә карамастан, 95 центнер бал алынган. Чит өлкәләргә, алдан килешү буенча, 150 корт семьясы сатылган.

Әмма республикабызның барлык урман хуҗалыкларында да эшләр шулай ал да гөл икән дигән фикер туа күрмәсен. Еш кына очракларда планнар үтәлсә дә, тармак хуҗалыкларында җитештерелә торган халык куллануы товарларының сыйфаты һәркемне дә канәгатьләндерә дип булмый әле.

«Социалистик Татарстан» газетасының «Халык контроле» битендә Ф. Хуҗинның: «Агач тырма өчен... Горькийга» дигән мәкаләсе басылган иде. Анда Минзәлә районының агач тырмаларны Горький өлкәсеннән, куна тактаны Мари АССРдан, балта, көрәк һәм чүкеч саплары, уклау, орчык, тукмак кебек әйберләрнең дә башка яклардан кайтарылуы турында языла. Ә бит кайчандыр Минзәләнең үзендә, даны тирә-юньгә мәгълүм булган «Кызыл агач» артеле эшләгән. Ул үз районын гына түгел, хәтта башка районнарны да бөтен кирәк-ярак белән тәэмин итеп торган.

Кызганычка каршы, утыртылган яшь урманнарны, үсентеләрне саклау мәсьәләсендә дә кимчелекләребез зур. Яңа ел алдыннан яшь урманнарыбызның корткычларча талануы турында әйтеп тормастан, бер мисалга тукталыйк. Соңгы ун ел эчендә генә дә безнең республикада 23 мең гектар урман һәлак булган. Шуларның 17 меңе — пошилар «эше». Билгеле булганча, бигрәк тә кышкы айларда, яшь нарат, чыршы агачы үсентеләре, пошиларның төп туклану ризыгы булып китә.

Урманнарга пошилар һәм кабан дуңгызлары салган зыянның күләме торган саен арта бара. Бу бәлане киметү буенча тиешле чаралар да күрелә. ТАССР Министрлар Советы каршындагы дәүләт аучылык инспекциясе хәбәренә караганда, аучылар ел саен 2000-2500 башка кадәр пошины аулыйлар.

Әмма яшь үсентеләргә колхоз-совхоз һәм хуҗалык мал-туарлары да зур зыян китерә. Шуңа күрә урман хуҗалыклары агач утыртылган мәйданнарны киртәләп алырга тиешләр. Тирә-юнь мохитны күз карасыдай саклау буенча дөньякүләм көрәш барганда, кулдан килерлек шундый гади эшне җиренә җиткереп башкармау башка сыймый.

...Республикабыз урманнары, аларның бүгенгесе, киләчәге турында уйлаганда, күз алдына Кама буе урманнары киләләр дә басалар. Моның үзенә күрә сере, хикмәте дә бар, чөнки ул төбәк урманнары, күпмедер дәрәҗәдә, минем иҗатыма бәйле. Моннан 35 еллап элек, «Совет Татарстаны» (хәзерге «Социалистик Татарстан») газетасында эшләгәндә, мине 2-3 айга Кама һәм Лубян урманчылыгына командировкага җибәргәннәр иде. Анда мин урман хәзерләүчеләрнең фидакарь хезмәтен чагылдыручы күп тиражлы газета чыгарырга тиеш идем. Киткәндә, журналист дуслар: «Урманчылар турында повесть та язып кайт!» — дип, хәерле юл теләп калганнар иде.

Кама һәм Лубян урманчылары турында (Саба һәм Котлы Бөкәш район типографияләрендә) егерме саннан артыграк газета чыгардым. Каләмдәшләремнең теләкләрен дә үтәдем —«Урман шаулый» дигән повесть төгәлләдем.

Еллар үтә торды. Йокымсырап яткан Кама-Чулман ярлары искәрмәстән генә тетрәнеп уянгандай булды: КамАЗ уятты аны. Миңа яңадан ул төбәкне аркылыга да буйга айкарга туры килде. Шунда мин «Кама таңнары» дигән роман-дилогиямне иҗат иттем. Шуңа күрә миңа ул яклар бигрәк тә якын, кадерле.

Инде 35 ел элек мин белгән урманнарны бүгенгесе белән чагыштырам: чыннан да, булды микәнни бу тирәләрнең шундый чаклары дип хәйран калып уйланам.

Ак томаннарга уралган язгы урманнар күз алдыма килә. Урман андый чакта аерата зәңгәрләнеп китә, язгы суда коенып чыккандай саф-пакь тоела. Тирә-юньдәге төсләр дә күзгә күренеп үзгәреп торалар.

һай-й, ул язгы көннәр! Үзең дә яшәреп киткәндәй буласың, үтелгән гомерне кар сулары гүя юып ала, күңелләрне нечкәртә.

Кама буе урманнарының адәм аягы басмаган төшләренә кергәләгәнем бар. Күңелемдә искәрмәстән генә шик-шом сыман нәрсә туа. Җил булмаса да, агач яфраклары шыбырдаша. Иртәнге дымлы-күләгәле һава бераздан үзгәрә, кояш нурында җылынган һавадан хуш ис бөркелә.

Зиһенеңнең ачылып китүен тоясың, тәнеңдә сихәт арткандай була. Агачларның серле көйләренә мең төрле кошларның сайравы кушыла. Күңел түрендә җанга рәхәт өстәүче җыр тугандай була...

Нарат урманында да могҗиза. Рәт-рәт тезелгән, төз агачлар, ишетелер-ишетелмәс кенә иттереп, моңлы көй сузалар сыман. Һаваның сафлыгы башны әйләндерә. Мондый да татлы һаваны тагын кайда суламак кирәк! Җан тантана итә...

Ул көннәр хәтердә таң алдыннан күргән могҗизалы төш кебек калган. Мин хәзер дә, җае чыккан саен, җанга газиз ул төбәкне әйләнеп кайту ягын карыйм. Әмма соңгы елларда ул якның күренешләре мине чынлап торып пошаманга төшерә. Гүзәллеге белән республикабызда гына түгел, бөтен илгә даны таралган, мәшһүр рәссамнарның илһамына җим биргән Кама-Чулман буе урманнарын танырлык түгел. Кайчандыр адәм аяк басарга кыймаган ярым кыргый, сихри урманнар юк инде. Ул тирәләрдә бүген — туристик базалар, кепинглар, кунак өйләре, палатка шәһәрләре, автопансионатлар...

Кайберәүләр табигатьне саклауны аңа тимәү, аны «кыерсытмау» дип кенә аңлыйлар. Бу һич тә дөрес түгел. Көнчыгыш халыкларында — бер кеше үзса — эз кала, йөз кеше үзса — сукмак төшә, мең кеше үзса — җир такыраеп кала диган гыйбрәтле сүз бар. Бүгенге белгечләребезнең әйтүенә караганда, илебезнең бары тик Европа өлешендә генә дә, җәй көннәрендә, 80.000.000 кеше ял итәргә урманга чыга. Галимнәр күзәтүеннән күренгәнчә, бер гектар урман өч кеше йөрүне җиңел кичерә. Ә инде йөрүчеләр саны унга җитсә, аларның кире тәэсире сизелә башлый. Ә инде бер гектар мәйданда 15-20 кеше ял итсә, туфрагы тыгызлану сәбәпле, андагы агач-куаклар корый башлый. Андый урманда җәнлек калмый, кошлар оямый...

...Табигать — халык байлыгы. Димәк, илдә әйләнә-тирә мохитны саклау, аның байлыкларыннан дөрес файдалану да — бөтен халык бурычы.

Республика табигатьне саклау җәмгыятендә бүгенге көндә 100 меңнән артык кеше член булып тора. Анда җәмәгать тәртибендә эшләүче 6,5 мең инспектор бар, җәмгыятьтә күп кенә секцияләр оештырылган. Аларның эшчәнлеге Татарстан АССР Верховный Советы Президиумында, Татарстан АССР Верховный Советының табигатьне саклау һәм табигый ресурслардан рациональ файдалану даими комиссиясе утырышларында әледән-әле тикшерелеп тора.

Табигатьне саклау максаты өчен акча бирү елдан-ел арта бара. Унынчы бишьеллыкта, мәсәлән, ул ил күләмендә 11 миллиард сум, шул исәптән, РСФСРга — 7 миллиард сум бирелде. Унберенче бишьеллыкта исә бу чыгым бер ярымга диярлек артты. Яңа бишьеллыкта исә 20 миллиард сумлап акча тоту планлаштырылган.

Табигатьне саклау — гасыр проблемасы.

Борынгыларда: «Үзенең урман байлыгын саклый алмаган халыкның киләчәге юк»,— диган сүз яшәгән. Әмма мин төбәгебезнең төп бизәге, иксез-чиксез байлыгы — урманнарыбызның сакланып кына калмыйча, тагын да ишәя төшүенә ышанам. Бер агач кистеңме, икене утырт диган принциптан чыгып эш итүебез моның ныклы нигезе дип, язмамны оптимистик рухта тәмамларга булдым.

**Марсель Зарипов**

# СИГЕЗ СЫЕР АСРАГАНЧЫ...

*Сыерларда — безнең куәтебез, сыерларда — безнең ризыгыбыз, сыерларда — безнең киемебез, сыерларда безнең җиңүебез.*

Борынгы фарсы китабы «Зенд-Авеста»дан.

Шушы эпиграфны язып куйдым да халык риваятьләренең зирәклегенә, борынгылар сүзенең тирән мәгънәсенә сокланып куйдым. Әйе, дөньядагы бер генә җан иясенең дә бу кадәр рәхмәтләргә, мактауларга лаек булганы юк.

Ни өчен шулай мактыйбыз соң аны? Бер карасаң, сере бик гади кебек. Табындагы итнең җитмеш процентын сыер бирә. Диета белгечләре әйтүенчә, сарык ите — авыр, дуңгыз ите — майлы, ат ите — каты, куян һәм кош ите — диетик туклану өчен генә әйбәт, ә менә сыер, тана яки бозау ите тәмле тамакларга да бата, туклыклы ризык яратучыларны да канәгатьләндерә.

Шушы ук мәхлук кешегә өс-баш һәм аяк киеме дә бирә: аның тиресеннән куртка, пальто, күн итек һәм ботинка тегәләр. Хикмәтле химиклар никадәр генә тырышмасын, ни генә уйлап чыгармасын, күнче осталар барыбер табигый чимал белән эш итәргә ярата.

Болар өстенә басу-болыннар сыердан җир сые — тирес ала. Туфракның көчен кире үзенә кайтарып бирә бармасаң, игенчелек эшен дәвам иттерә алыр идеңме икән?

Ниһаять, сыер — үзенә бер төрле җылылык чыганагы булып хезмәт итә ала. Җир астындагы торф, ташкүмер, нефть, газ ятмалары безне күпмедер дәрәҗәдә гамьсезләндереп җибәрде булса кирәк. Әмма табигать сандыкларындагы запас та мәңгелек түгел. Балаларыбызга, оныкларыбызга аларны ни хәлдә калдырабыз? Запас беләнме, әллә таланып беткән хәлдәме? Кызганыч, фермалардан, җылылык чыганагы буларак, һаман файдалана алмыйбыз. Кайбер илләрдә тиресткән биогаз, ягъни биологик ягулык алу башларына килгән: шуның белән өй җылыталар, аш пешерәләр. Икеләтә отыш! Газы — баллоннарга, тиресе — кырларга. Бер сыер ел әйләнәсендә ярты мең кубометр метан газы бирә, ул җиде кешеле гаиләгә ел буе аш пешерергә җитә. Биш йөз кубометр метан өч йөз дә илле литр бензинны алыштыра! Күпме җылылык алырга, күпме утын, ташкүмер, мазут, солярканы янга калдырырга мөмкин булыр иде! Бу терлек фермаларында илебез ел саен утыз биш миллион тонна ягулык житештерә ала дигән сүз. Адәм баласы терлек үрчетүне туктатмаса, кимеми, саекмый торган чыганак ул.

Әмма, чынында, кешеләр сыерны «табигать» әзерләгән гаҗәеп ризык — сөт өчен асрыйлар. Сөттә организм өчен бик кирәкле йөздән артык файдалы компонент барлыгы билгеле: аксым, майлар, углеводлар, минераль тозлар, витаминнар...

Сөт элек-электән дәвалау чарасы буларак та кулланыла. Әчетелгән сөт, катык, кефир, кымыз һ. б. ашказаны-эчәк авырулары, туберкулез белән интегүче кешеләр өчен шифалы ризык та ул.

Яшьрәк чакта кеше ризык талымламый. Әмма гомер узган саен, адәм баласы табигать үзе биргән азыкка ныграк тартыла бара. Чәйнең инде куе-карасы түгел, ә бәлки, каймак яки сөт салынганы җанга ятышлырак, андый чәй хуш исле һәм тәмле генә түгел, туклыклы да, хәл дә кертә. Иртәнге ашка да кыздырылган ит түгел, май ягылган сыр кисәге, эремчек, каймак әйбәтрәк. Врачлар да күбрәк кефир, әйрән, варенец, ряженка, катык ашарга киңәш итә. Моңа өстәп халкыбызның яраткан ризыгы корт турында да күпме мактау сүзләре әйтеп булыр иде.

Фермадан яки җәйләүдән килгән ак цистернаны заводта иң беренче булып таләпчән лаборант каршы ала. Нинди сөт китергәннәр, сыйфаты нинди? Табигый ки, иң элек ул аның майлылыгы белән кызыксына. Бу — үзәк мәсьәлә. Кабул ителгән сөткә, шуннан чыгып, акча түләнә. Аннары тәмен, исен, төсен тикшерәләр. Шушы сыйфатларга карап, аның сортын билгелиләр.

Шулай да әлеге үзенчәлекләр генә сөтнең барлык серләрен ачып бетермиләр. Ул күкрәк баласына да, картларга да, сәламәтлеген югалткан сырхауга да, гомере буе чирнең ни икәнен белмәгән пәһлеван-баһадирга да бердәй файдалы.

Врачлар, авыруга беренче дәва дару түгел, ә дөрес туклану, диета саклау диләр. «Әчетелгән сөт эчсәгез, теләгән кадәр яшәрсез», дип киңәш бирә сыерны изге

хайван дип санаучы һинд йоглары. Борынгы мисырлылар төрле чирләрдән ишәк сөте эчеп дәвалана торган булганнар. Шәрыкның бөек табибы Әбугалисина үзенең «Кануннар»ында сөт белән сабый балаларны да, гомерләре инде узып барган кешеләрне дә бер үк дәрәҗәдә уңышлы дәвалыйлар, дип яза. Инглиз врачы Синдхэм нерв системасы бозылганда сөттән файдалану кагыйдәләре җыелмасы эшләде. Г. Буханның моннан ике йөз ел элек Мәскәүдә басылып чыккан «Өй шифаханәсе китабы»нда зәңгеләгә каршы сөт һәм яшелчә файдаланырга тәкъдим ителә. Доктор С. Б. Боткин сөтне, «йөрәк һәм бөерне дәвалаганда кыйммәтле дару», дип бәяләп, аны углекислый газ белән баетырга киңәш бирә. Туберкулез врачлар һәм пациентларның ихтыяры, ныклыгы алдында чигенә икән, күренекле рус врачы Г. А. Захарьинга рәхмәт әйтик: ул әлеге аяусыз чирне кымыз белән дәвалау кагыйдәләрен уйлап тапкан. Бу ысулны «рус ысулы» дип атыйлар. Танылган рус язучысы Аксаков кымыз белән дәвалауны болай тасвирлый: «...күкрәк баласыннан алып, хәлсез картка кадәр һәркайсы бу шифалы эчемлекне туйганчы эчә, кышкы хәлсезлек һәм хәтта картлык чир-зәхмәтләре кул белән алып ташлагандай юкка чыга: бетәшкән, эчкә баткан яңакларга сәламәт алсулык йөгерә...»

Бөек рус физиологы Мечников, озын гомерле кешеләр хакында уйланганнан соң, йөзгә җиткән гадәти хәл булган, озак яшәп тә, картлыкны белмәгән кешеләр турында күп кенә мәгълүмат туплагач, бер ачыш ясый: шәһәр һәм авыллардан еракта, тау көтүлекләрендә яшәүчеләр гади һәм файдалы ризык — сөт, сыр, брынза, әчегән сөт белән тукланалар икән. Галим үзе дә озак яшәү элексирын — «Мечников катыгын» тәкъдим итә. СССР Сәламәтлек саклау министрлыгының шифаханәләрдә ныклы туклану нормасы кертүе юкка түгел. Аның буенча һәм авыруга көненә өч йөз дә алтмыш биш грамм сөт, унҗиде грамм эремчек, унбер грамм каймак, кырык грамм терлек мае, бер грамм сыр бирелергә тиеш.

Әйе, сыер — гаҗәеп җан иясе. Гадәти үлән һәм үсемлек сокларын үзе аша үткәреп, ул аларны искиткеч күп төрле матдәләргә әверелдерә. Аларның күпчелеге чиста хәлендә табигатьтә очрамый. Иң әүвәл кислоталарны алыйк: май, лаурин, меристин, пальмитин, капрон, каприл кислоталары. Аннары лейцин, пролин, валин, лизин, тирозин, аргинин, гистидин, триптофан, алеанин, серин, глицин, метионин, цистин, треонин, изолейцин, гидроксипролин, фенилаланин кебек сирәк очрый торган аминокислоталар белән баетылган казеин, альбумин, глобулин аксымнарын искә төшереп үтәргә кирәк. Чимал сыйфатында гадәти җир байлыкларын файдаланучы җанлы биологик реактор сөтне диастаза, липаза, фосфотаза, пероксидаза, редуктаза, каталаза кебек ферментлар белән баета: алар исә кеше организмына башка төр туклану ризыкларын да яхшырак үзләштерергә ярдәм итәләр. Әгәр сөтнең составына калий, натрий, кальций, магний, цинк, алюминий, бакыр, тимер, марганец, йод, кремнезем кебек минераль катнашмалар, кире электр корылмалы махсус анионнар кермәсә, ул шулкадәр тәмле булыр идемени?

Россиядә терлекне хәзергегә караганда шактый аз асраган дәвердә Владимир Ильич Ленин, ил һәм халыкның киләчәк көннәре хакында уйланып, һәр балага көн саен бер шешә сөт бирәсе иде! дип хыялланган. Хәзер исә җир шарындагы дүрт миллиард халык өчен ел саен дүрт йөз илле миллион тоннадан артыграк сөт җитештерелә, шуның һәр бишенчесе — совет иленеке. Совет кешеләре дөнья халкының унбиштән бер өлешен тәшкил итә. Димәк, табыннарыбызда шифалы сөт башкаларныкына караганда күбрәк. Илебездәге һәр кеше үзенең уртача җитмеш яшьлек гомерендә егерме ике мең литр, ягъни егермешәр чиләк сыешлы кырык мичкә сөт эчә.

Инде уйлап карыйк: кеше һәр көнне сау-сәламәт яшәрлек сөт һәм сөт ризыклары куллана алсын өчен күпме терлек үрчетергә, күпме май, каймак, брынза, кефир, эремчек, катык, варенец, мороженое, ряженка, простокваша, әйрән, сыр ясарга кирәк?

• • •

Россиядә XX гасыр башында шәһәрдә яшәүче һәр кешегә тугыз крестьян туры килгән. Аграр ил булса да, һәр хуҗалыкта сыер тоту зур байлык, ата-бабаларыбыз әйтмешли, дәүләт саналган. Хуҗалык итүнең нәрсә икәнен яхшы белгән галим һәм публицист А. П. Энгельгардт, мәсәлән, заманасында Казан губернасының кайбер авылларында йорт саен ат тота алмыйлар, ә хуҗалыкларның яртысы диярлек сыерсыз яшәүдән интегә дип язып калдырган.

Күптәнге мәгълүматларны барлап, төрле саннар белән танышкач сөтчелекнең әүвәлге хәле аермачык булып күз алдыма килеп басты. Революция алдыннан Россиядә 60 миллион чамасы мөгезле эре терлек була, шуларның яртысы чамасы — сыер, алар ел саен утыз миллион тоннадан артык сөт алырга мөмкинлек бирә. Бер сыерга

мең килограмм, бер кешегә — йөз литр чамасы туры килә. Җитәр-җитмәс кенә бу!

Сугыш алдыннан, кырыгынчы елдагы мәгълүматлар инде башкачарак. Илебез Днепрогэс һәм Магнитканы кора, Комсомольск-на-Амуре шәһәрен сала, Кузбасс шахталарын төзи, индустрияләштерү фронтындагы кебек үк тырышлык һәм ныклык белән көтүләрне арттырырга омтыла. Чоры шундый була. Алга карап яшиләр, зур һәм кыю планнар коралар, әмма... сугыш башланып китә. Озакка сузылган, кан коюлы, кайгы-хәсрәтле, санап бетергесез югалтулар белән тулы сугыштан соң безгә элек үтелгән юлны кабаттан узарга туры килде. Бары тик җитмешенче елны гына сугыш алдыннан ирешелгән дәрәҗәгә җитә алдык, илебездә һәр кешегә уртача өч йөз килограммнан артык сөт җитештерелде.

Әлеге арифметикада ике хәлне билгеләп үтәргә кирәк. Беренчесе — авыл халкының шәһәргә күпләп күчүенә карамастан, илебездә көтүләр артты. Җитмешенче елларны ук инде шәһәр халкы авылда яшәүчеләргә караганда күбрәк булып чыкты. Ләкин мондый миграция артык борчымый иде әле, бу факторда табигый сәбәпләр күп. Икенче бер хәл борчылу тудыра — авылда яшәүчеләр үз хуҗалыкларында мал-туар асрамыйча, колхоз фермасында, совхоз кырында акчага эшләүне, сөтне сатып алуны артыграк күрә башлады. Әллә инде мохтаҗлык беткән, әллә ялкаулык баскан, әллә шәхси автомобильләр алу, кичнең кич буе «зәңгәр экран» каршында бөкшәеп утыру крестьян тормышы традицияләреннән өстенрәк була башлаган. Илебездә утыз биш миллион шәхси хуҗалык бар, шуларның егерме өч миллионы гына мөгезле эре терлек асрый. Күп булса егерме-егерме биш ел эчендә шәхси сектордагы сыер көтүләре җиде миллион алты йөз уналты мең башка, дуңгызлар — биш миллионга, сарык һәм кәҗәләр ундүрт миллионга кимеде. Гадирәк итеп әйткәндә, ике йортка бер сыер торып калды. Колхоз һәм совхозлардагы зур фермаларга, терлек комплексларына әлеге югалтуларны да тутырырга туры килә, шуңа күрә көтүләрнең гомуми санында югалту юк, ул арта бара. Сугыш алдыннан һәр сыер елына бер мең дә бер йөз сиксән биш килограмм сөт биргән булса, 1970 елда продуктылык ике мең дә бер йөз ун килограммга җитте. Безнең илдә бер кешегә уртача еллык сөт куллану өч йөз килограммнан арта.

Андый көтүләрне үрчетүгә күпме вакыт һәм көч киткәнлеген, шулхәтле сөт алу өчен никадәр борчылу-мәшәкатьләр таләп ителүен онытырга ярамый. Колхоз һәм совхоз маллары фермада һәм комплексларда тотыла, алардагы төп эш коралы сәнәк белән чиләк түгел, ә куәтле электр көче. Азыкны техника тарата, тиресне машина җыя, сыерларны электр сава, сөтне автоцистерналар ташый яисә ул торбалар буйлап турыдан-туры заводның үзенә кудырыла.

Терлекчелектә ныклы азык базасын булдыруга илебез күпме көч куя? Элеккеге печәнлекләр, көтүлек һәм болыннар гына инде аз, миллионнарча гектарга җәелгән көтүлекләргә өстәмә рәвештә тагын алтмыш җиде миллион гектар сөрүлек җирне өстәп бирергә туры килә, ә кырыгынчы елдагыга караганда өч тапкырдан да күбрәк. Иген кырлары бу чор эчендә әллә ни артмады, бөртекле культуралар мәйданы нибары егерме биш миллион гектарга гына киңәйде.

ВАСХНИЛ составында егерме өч селекция үзәге булган Бөтенсоюз терлекчелек институты төзелде, илебезнең төрле зоналарында специальләшкән алтмыш фәнни-тикшерену учреждениесе бар.

Кырык өч миллион сыерлы көтүдә һәр сыердан елына ике мең дә ике йөз — ике мең дә өч йөз килограмм сөт алына.— Бу моннан алтмыш ел элеккеге хәлгә караганда ике тапкырдан күбрәк. Әмма ерак юлда үтелгән чакрымнарга карап соклանмыйлар, узасы араны саныйлар.

Чыннан да, илебездәге сыерлар санын һәм сөтнең күләмен исәпләп карасаң, бездә бер сыер җиде кешене туендыра булып чыга. Шуннан соң мин шушы ук саннарны үзем өчен дә көтелмәгәнчә, бөтенләй башкача санап карадым һәм минә нәрсә ачыкладым: бер сөтләчне асрау өчен дә бездә җиде кеше көчен һәм тырышлыгын сарыф итәргә кирәк икән.

• • •

Димәк, бер сыерның җиде кешене туйдыруы — һич тә мактанырлык хәл түгел. Чагыштырып әйткәндә, куәтле КамАЗ машинасында бер уч ашлык йөртү белән бер. Бу хакта практиклар да, галимнәр дә, кыскасы, терлекчелек белән таныш булган һәркем уйлана. Мисал өчен еракка барып тормыйм, Татарстанның өч хуҗалыгын — «Бөреле», «Коңак», «Восточный» совхозларын алам, чөнки аларны күптәннән беләм. Беренче икесе чыдамлы төньяк терлекләре — «холмогорка»лар үрчетә, һәр сыердан биш мең килограмм диярлек сөт савып ала, теләсә кайсы елны, теләсә нинди шартларда шундый нәтиҗәгә ирешә, ә «Восточный» совхозына Идел буе тирәләрендә сирәк булган Айршир токымлы сыерлар кайтардылар.

Кощак сыер савучылары үзләренең бүгенге үрләренә ике талпынуда ирештеләр. Район һәм республика горурлыгы булган беренче көтүне, сыерларны саклап калырга күпме генә тырышмасыннар, бетерергә туры килде, афәт кешеләрдән көчлерәк булып чыкты. Икенче көтүне ит комбинатына суярга китерелгән сыерлар арасыннан сайлап алдылар, сөткә хәтта исәп тә тотмаганнар иде, өметләре бер генә — бозаулар алып үстерү иде. Бозау — бала белән бер, ничек тәрбияләсәң, шулай үсә: элекке терлекләр белән килеп чыккан баладан соң тугыз ел узгач, Кощак терлекчеләре үз сыерларыннан кабат дүрт мең ярым килограмм сөт сава башладылар! «Восточный»да — алты мең¸әр килограмм.

Дөрес, «Бөреле», «Кощак», «Восточный» совхозлары — җәнлек асраучы хуҗалыклар, савым көтүләре дә зур түгел, ике йөзәр баш сыердан артмый. Зур көтүләр, бәлки, югары савым белән куандыра алмый торгандыр. Тагын бер мисалны карыйк.

Моннан унҗиде ел элек Максим Степанович Новиков тәвәккәлли дә, Сочидагы трест управляющие урынын калдырып, Ленинградтан ерак түгел урнашкан таркалып килүче «Петровское» хуҗалыгын кабул итә. Иң элек ул коллектив алдына шундый бурыч куя: терлекчелектәге уңышны сыер саныннан түгел, ә савып алган сөттән чыгып бәяләргә! 1983 елда инде бер мең дә бер йөз сыерның һәркайсы алты мең өч йөз алтмышар килограмм сөт бирә. Андый сыерның сөте инде җиде кешегә генә түгел, ә егерме кешегә җитәрлек. Сөтчелек энтузиастларының мондый җиңүләре хакында фикер йөрткәндә бер нәрсә гаҗәпләндерә. Төрлесе төрле җирдә эшли; бер-берләрен белмиләр дә, ә эшләре, ирешкән нәтиҗәләре бер-берсенә охшаш. Андый кешеләргә табигать аерым бер сәләт бирә микәнни соң? Терлекләренә алар нинди акыллы, ягымлы сүзләр әйтәләр икән, улакларына нәрсә салалар? Ни өчен соң бүтәннәр алай эшли алмый, нәкъ шундый ук терлекләр аларга күңелсезлек һәм көенечтән башка берни дә китерми?

* * *

Буйволны кулга ияләштереп, аны тәүге тапкыр сауган көннән бирле, хуҗаның төп кайгыртуы көтүдәге сыерлар турында. Алар нинди, яхшымы, әллә начармы?

Сыерның ниндилеге кешенең бу тармакта ни дәрәҗәдә дөрес шөгыльләнүенә бәйле. Сөтнең күп яки аз булуын төрле кеше төрлечә аңлата. Берәүләр: «Сыерның сөте — телендә, хикмәт — азыкта, бөтен эш — агрономнарга, механизаторларга бәйле» — ди. Икенчеләр: «Сыер — савучының кулында»,— дип әйтергә ярата. Биредә дә хаклык юк түгел. Механикалаштырылган фермалар заманында да саву аппараты белән савымчы эшли. Өченчеләр: «Председательнең башында»,— дип раслый. Мин үзем әлеге кешеләр исәбенә район, өлкә, республика, ил күләмендә сөт өчен башлары белән җавап бирүче кешеләрне дә кертер идем.

Алда әйтелгән акыллы һәм зирәк фикерләрнең асылына төшенер өчен кайларда гына булырга туры килмәде!

Тула өлкәсендә мул сөт алучы Ленин исемендәге колхоз барын белә идем. Бер җае чыккач, шул якка киттем.

...Стародубцев үзе һөнәре буенча шахтер. Башта шахтада эшләгән, аннары авыл хуҗалыгы институтын тәмамлаган. Ул иске традицияләргә ябышып ятмый, хуҗалыкны киң колач белән алып бара. Колхозның горурлыгы — уникаль сөтчелек комплексы. Малларга да, савымчыларга да уңайлы анда. Бу корылма СССР Дәүләт премиясенә лаек булган. Әмма иң мөһиме — биредә мул сөт, арзан сөт савалар, аның центнеры уналты сумга гына төшә. Мондый хуҗалыкны бүтән очратканым юк минем.

Шулай бервакыт ниндидер җитди киңәшмәдә Стародубцев бишәр мең килограмм сөт бирә торган сыерлары турында горурланып сөйли. Аның сүзләрендә кемнәрдер масаю күрәләр.

Стародубцев бер дә артыгын әйтми югыйсә. Ленин исемендәге колхозда, чыннан да, Авыл хуҗалыгы министрлыгының алдынгы тәҗрибә мәктәбе эшли. Бөтенләй көтмәгәндә, Уралдан булса кирәк, бер хуҗалык җитәкчесе каршы чыга моңа. Имеш, аның колхозы гади фермада да һәр сыердан алтышар мең литр сөт сава. Стародубцев та шундый нәтиҗәгә ирешеп карасын, шул чакта ул аның комплексына өйрәнергә барыр, ә хәзергә — кыстамагыз да, чакырмагыз да, янәсе. Стародубцев бәхәскә кереп тормый, ләкин бу чакыру аның күңеленә нык кына тия күрәсең. Уйларлык урын бар шул. Чыннан да, гап-гади бер ферма, ә савымы белән фабриканы да узып киткән.

Ленин исемендәге колхозга килеп төшкәч, мин Стародубцевтан иң әүвәл шул бәхәс турында сораштым. Стародубцев артык җәелеп китмәде, иплән кенә: «Савымны биш мең дә дүрт йөз килограммга җиткердек, киләчәктә нәрсә булыр — анысын

вакыт күрсәтер».— дип куйды. Һәрхәлдә, ике як та ихтирамга лаек, икесенең дә үз эш кагыйдәләре, үзләренчә хуҗалык итү принциплары бар.

Күп тапкырлар Мәскәү тирәсе хуҗалыкларында булганым, игенчелектә, бакчачылыкта дан тоткан, әмма терлекчелектә югары нәтиҗәләргә ирешә алмаган Кубань буйларына барганым бар. Йөрсәң, карасаң, гыйбрәт алыр хәлләр күп.

КамАЗның аграр зонасында аеруча еш булырга туры килә. Тормышның ашкынулы адымнарыннан калышмаска тырышып, биредәге авыллар автогигант белән бергә үсә, үзгәрә бара. Ун ел эчендә, 1972 елдан алып 1982 елга кадәр, Тукай районы хуҗалыклары сөт җитештерүне ике ярым тапкырга, итне — өч тапкырга диярлек арттырдылар, яшелчә һәм бәрәңге хәзерл..үне утыз дүрт мәртәбәгә күбәйттеләр. Элек бөтенләй башка да килмәгән кошчылык фабрикалары ел саен егерме дүртәр миллион данә йомырка, дүртәр мең тонна ит бирә башладылар.

Индустрияләштерү чорында сирәк очрый торган тагын бер хәлне әйтергә кирәк. Халык саны ярты миллионнан артып киткән Брежнев һәм Түбән Кама шәһәрләре зонасында 1980 елда җан башына өч йөз дә алтмыш сигез килограмм сөт, туксан җиде килограмм ит, өч йөз дә туксан алты данә йомырка, җитмеш килограмм яшелчә, йөз дә утыз килограмм бәрәңге хәзерләнде. Авыл шәһәрдән калышмый үсә.

Шундый күп төрле экономик, социаль, көндәлек тормыш проблемаларын бер карауда аңлап бетерүе дә кыен, әмма беренче танышуда ук сөт терлекчелеге белән һәркемнең үзенчә, кайвакыт бөтенләй капма-каршы принциплардан чыгып эш итүе күзгә ташлана.

Терлекчелек, фермалар, савым турында фикер йөрткәндә, иң элек һәркемгә күренеп торган нәрсәләрне уйлый башлыйсың. Әйтик, сыерлар саны кемдә күпме? Боларны чагыштыру өчен Мәскәү өлкәсенең Одинцово һәм Кубаньдагы Брюховец районнары фермалары эшчәнлеге белән танышып чыгарга туры килде. Бу күзлектән караганда, Одинцово районын шелтәләп тә алырга мөмкин булыр иде — сыерларның иң азы шушында, кара-чуар токымлы унбер мең дә илле алты баш. Тукай районы терлекчеләренең хәле бераз яхшырак: аларның фермаларында мал саны мең башка артыграк, районда Швиц токымлы универсал ит-сөт терлекләрен үрчетәләр. Ә беренче урынны Брюховец хуҗалыкларына бирергә туры килә, савым сыерлар көтүенең иң зурысы шушында — кызыл дала токымлы ундүрт мең баш.

Күрәсез, аерма зур. Маллар санын сводкалар белән чагыштыручы Дәүләт статистика идарәсе инспекторлары күзлегеннән караганда, Брюховец терлекчеләренә тел-теш тидерерлек түгел! Өч мең баш сыер тотарга күпме көч, күпме тырышлык кирәк. Ләкин кыенлыклардан куркып калмаганнар, үрчеткәннәр. Мактау рапортының икенче юлында, минемчә, Тукай районы. Ул алтын урталыкта тора. Одинцово фермалары ахырда булачак.

Сүз дә юк, сыер көтүләре дә, сарык көтүләре дә, ат көтүләре дә — хуҗалык итә белүнең төп күрсәткечләре, әмма дөрес оештырылган терлекчелектә мал-туарны күп үрчеткән түгел, терлекне оста карап, ит һәм сөтне артыграк ала белгән мактала.

Шундый формула төзеп, мин әлеге дә баягы шул ук фермаларга башка яктан карадым. Гомуми күренеш үзгәрмәде дә кебек, әмма характеристикалар бөтенләй капма-каршы булып чыкты. Бактың исә, Одинцово савымчылары егет икән ләбаса. Тукай районында уртача савым ике мең дә җиде йөз илле килограмм, Брюховец районы фермаларында ике мең дә алты йөз егерме җиде килограмм. Одинцово хуҗалыкларында сыерлар һәммәсенә караганда да кимрәк, әмма һәр сөтләч дүрт мең ярым килограмм продукция бирә. Егетлек түгелме бу?!

Бер сыерның башка хуҗалыклардагы ике сыер хәтле сөт бирүен белергә теләп, Одинцовога килгәч, шәһәр партия комитетының беренче секретаре Валентина Яковлевна Чистякова терлек асрау турында крестьяннарча фикер йөртә белүен раслаган матур бер чагыштыру китерде:

— Көтүгә бүген бер сыер китереп кушасың икән, иртәгәсен өстәмә цистерна китереп куй, дисезме. Алай түгел шул! Сыерлар санын арттырырга телисең икән, мәсьәләне җиде кат түгел, мең кат үлчәргә туры килә. Иң әүвәл — нәрсә ашатырга? Аннары — кайда асрарга? Савымчыларны, терлек карауччыларны, механизаторларны каян алырга?

Һәркайсы дүрт мең ярым килограмм сөт бирүче унбер мең сыерлы көтүгә Валентина Яковлевна чирек гасыр диярлек гомерен багышлаган. 1960 елда, коммунистлар Одинцово шәһәр комитетының беренче секретаре итеп сайлаганда, фермаларда җиде мең өч йөз туксан биш сыер була, һәркайсыннан өч мең килограмм чамасы сөт савыла. Үткән чорда көтү бер ярым тапкырга үсә, сөт сату биш мәртәбә диярлек арта.

Саннар бүгенге хәлне ачык күрсәтә, әмма аңа ничек ирешкәнне аңлатып бетер-

миләр. Хикмәт эшнең нәтиҗәсендә генә түгел, хикмәт — нинди принциплар белән эшләвеңдә, гасырлар буена тупланган тәҗрибәдә һәм аны бүгенге белән бәйли белүдә. Сигез сыер асраганчы, симез сыер асра дигән борынгылар. Ач сыер сөт бирми, җәфа гына китерә!

Одинцово терлекчеләре мондый үрне җиңел генә яулаганнар дип уйлау ялгыш булыр иде. Бик кыен хәлләргә тарыган чаклары булды. Игеп кырларын, көтүлекләрне корылык көйдерде, һәр кочак печәнне, һәр чиләк фуражны саклап тотарга туры килде, нәфес коткысына бирелеп, зуррак мәгълүматлар алу өчен көтүгә бернична артык сыерны кушып җибәрергә дә була иде. Ләкин «терлекчелек белән игенчелек арасында тиешле пропорция сакларга» дигән зирәк кагыйдә бу коткыны җиңәргә мәҗбүр итте. Иң элек көтүлекләрнең уңышын күтәрергә, тамыразыклар, печән, силос, сенажны күбрәк әзерләргә тырыштылар, шуңа бәйле рәвештә генә сыерлар санын арттыра башладылар!

1981 елны Валентина Яковлевна Чистякованың егерме ел буена күңелендә йөрткән теләге тормышка ашты — районда алты меңче савымчылар клубы оештырдылар. Бер елда алты меңле үрне егермеләп кеше яулады, ә Немчиновка фермасыннан Прасковья Кулемина Россиядә беренче булып группасындагы сыерлардан җидешәр мең литр сөт савып алу мөмкинлеген исбатлады. Көтү үзенең генетик потенциалын расласын, аны узып китсен, яхшы кулларда терлекнең мөмкинлекләре белән практик нәтиҗәләре арасындагы аерманы бөтенләй бетерә алсын өчен, кызурак темптагы яңа вакыт исәбе башланды.

Икенче елны инде бөтен Немчиновка фермасы буенча һәр сыердан җиде мең литр сөт саудылар. Прасковья Федоровна тагын да ераграк китте, аның группасындагы сөтләчбикәләр җиде мең биш йөзәр килограмм сөт бирде.

Беренче карашка, Кулемина рекорды озак сакланыр шикелле иде. Әмма тагын бер елдан Зоя Георгиевна Загороднева дустын узып китте, сигез мең килограммлы үргә иреште. Данлыклы эшчән хатынның казанышын илебез Алтын Йолдыз белән билгеләде. Бу — аңа лаеклы бүләк!

* * *

Кубань җире матур: иркен далалар, бәләкәйрәк шәһәр кадәрле станицалар. Әмма, күркәмлек, минемчә, табигать күренешләрендә генә түгел. Төп мактаныч — хуҗалыкларның нинди нәтиҗәләргә ирешүендә.

Партиянең Брюховец район комитетында беренче секретарь Юрий Иосифович Гаркуша белән сөтне нәрсә хисабына күбрәк алу турында бәхәсләшеп киттек. Зур көтү асрапмы, әллә югары савым беләнме?

Мин Мәскәү өлкәсендә күргәннәремне, анда ике юнәлешне дә игътибардан читтә калдырмауларын, әмма күбрәк икенче ысулга таянуларын сөйләдем. Брюховец хуҗалыкларында бер сыердан ике мең дә алты йөз егерме җиде килограмм сөт савалар, Одинцово хуҗалыкларында — дүрт мең ярым. Аерма җир белән күк арасы кебек.

Сүзем, бәлки, кискенрәк тә булгандыр, әмма үзем уйлаганны туп-туры әйтеп бирдем.

— Баш саны сездә күбрәк, ә алар сөт белән алдыра.

— Өч мең башны алып ташласак, бездә дә савым текә күтәреләчәк,— диде Гаркуша.

— Соң, нигә алып ташламыйсыз?

— Аңа кем рөхсәт бирә?

— Шулхәтле көтү асрап, илле мең тонна сөт сату тыеламы?

— Тыелуын тыелмый ул. Барып чыкмый.

Теләсә нинди хокукны, бигрәк тә терлек санын мөстәкыйль хәл итү кебек җитди хокукны, ялварып алып булмый. Кирәкле саннарны исәпләп чыгаралар да аяк терәп исбатлыйлар. Тик Брюховец районы терлекчеләренең һәр сыердан бишәр-алтышар мең литр сөт алуга гарантия бирүләре шикле, чөнки продукция өчен түгел, ә баш саны өчен эшләргә гадәтләнгән алар.

Брюховец район авыл хуҗалыгы идарәсенең баш зоотехнигы Валерий Понаетович Попов белән бергә Суворов исемендәге колхозга чыгып киттек.

Фермада һәммә нәрсә тәртиптә. Капка төбенә кадәр асфальт, ишек төбендә кырыс вахтер. Абзарларда автоэчергечләр, транспортерлар. Ә бүлемнәрдә... мескен сыерлар мөгрәшеп тора...

Мин башта ук күреп, үзем өчен бер нәрсәне билгеләп үттем. Одинцово фермалары яхшы лабораториягә охшаш. Саву графиклары, төрле-төрле исәп-хисаплар,

схемалар, таблицалар, нормалар. Бозауларның кайчан туа башлаулары да билгеле. Алар, дөресен әйткәндә, терлекчеләргә юлдан тайпылмаска, үз вакытында төгәл маршрутны табарга ярдәм итәләр.

Кубаньдагы хәлләр белән дә шул күзлектән чыгып кызыксына башладым.

Фермада барлык эш картотекасын алып баручы учетчы Людмила Ивановна Бирюкова белән бәяләрне карыйбыз, кайсы иң мөһиме, кайсы икенче дәрәҗәле икәнен ачыклыйбыз. Нормалар, күрсәткечләр буа буарлык. Терлек карауда кыш өчен — аерым, җәй өчен — аерым. Сөт өчен түләү, бозау өчен кызыксындыру һ. б., һ. б. Ә «савымны арттыру» сүзе хәтта искә дә алынмаган!

Сыер савучы Валентина Васильевна Верховодкина фермада егерме ел чамасы эшли. Тырыш, пөхтә, тәҗрибәле, ә казанышлары юк. Боларны белгәч, ирексездән, сыерларны әллә эшкә яңа килгән кеше карый микән дип уйлый башлыйсың. Ике мең дә җиде йөз кырык литр. Шул да булдымы савым! Гомереңне фермада үткәр дә, ичмасам, бер генә тапкыр да чиләгеңне мөлдерәтеп сөт саума инде!

Мин Верховодкинаның хәленә керергә тырышып:

— Булдырып булмыймыни соң? — дидем.

— Ничек итеп булсын?! — Аның ачуы чыкты, кайдадыр бишәр мең литр сөт савалар, орденнар, Алтын Йолдызлар алалар, аның исә медале дә юк.— Егерме сыер савам, ә сөтләрен егерме алтыга бүләм. Алтысы — исәп өчен генә асрала,— диде ул.

— Сөт бирмиләрмени?

— «Сирень» дүрт литр бирә, «Фиалка» — ике, «Груша» бөтенләй юк.

Ферманы күрсәтеп бетергәч, колхозның баш зоотехнигы Владимир Степанович Кочаков белән сөйләштек.

— Нишләп бракка чыгармыйсыз? Таналар юкмыни?

— Әллә минем ихтыярда дип беләсезме? — Кочаков миңа ачуланып карады.— Өч йөзләбен иртәгә үк фермадан озатыр идем, азык әрәм итеп кенә яталар, тик баш санына зоотехник хуҗа түгел.

Чыннан да, ферма технологының көтү белән идарә итмәвен, ә бары тик ашатуэчертү кебек агымдагы эшләрне генә башкаруын очратканым юк иде әле. Белгечкә үзбаш эшләргә ирек бирмәгәч, ничек инде аңардан эш — ит белән сөт таләп итәргә?

Сүзсез-телсез җан иясе — сыер тирәсенә шул хәтле күп киртә куелган ки, колхоз һәм совхозларның баш санын хәл итү хокуклары да юк, терлекне базарга чыгару да тыела. Бу план үтәлгәч, анда да бөтен өлкә планы үтәлгәч кенә мөмкин.

Кубаньда, мәсәлән, сыерны ферма чутыннан чыгару өчен, зоотехник алты нөсхәдә кәгазь тутырырга тиеш. Башта актларны район җитәкчеләренә — ветеринария врачына, баш зоотехникка, РАПО советы председателенә күрсәтәләр. Алар әлеге кәгазьләрне карагач, кирәк дип тапсалар, кул куялар. Хәзер инде актлар Краснодарга, крайның авыл хуҗалыгы идарәсенә, баш зоотехникка китә. Иң соңыннан ул уйлап-үлчәп карый: баш исәбе кимемиме, көтүләр санына зыян килмиме?

Краснодар краеның җәмәгать секторында сыерлар саны биш йөз туксан мең; һәр елны көтүнең егерме-егерме биш процентын, ягъни йөз егерме мең баш сыерны бракка чыгарырга туры килә. Әгәр һәр актка икешәр минут вакыт тотсаң, край авыл хуҗалыгы идарәсенең баш зоотехнигына ике йөз кырык мең минут вакыт кирәк. Бер эш көнендә дүрт йөз сиксән минут. Димәк, көтүнең баш дирижеры, эш сөючән контора клеркы шикелле, директив язулар өстендә елына... биш йөз көн (?!) башын да күтәрмичә утырырга тиеш булып чыга.

Кубаньда шуның өстенә, малларның баш саны артуга карамастан, азык культуралары мәйданын кыскартуга таба киткәннәр, менә дигән люцерна басуларын сөреп ташлаганнар, терлекләргә күбрәк бөртекле ашлык ашата башлаганнар, рационда бөртекле фураж кырык биш процентка кадәр күтәрелгән.

Гаҗәп хәл! Азык базасын кыскартып, баш санын да үстерергә, көтүнең продуктлылыгын да күтәрергә мөмкин дигән ялгыш караш буш җирлектә тумаган, ул — экстенсив алымнар белән хуҗалык итү гадәтеннән, уңышны осталык белән түгел, сан белән алдырырга маташудан килеп чыккан нәрсә *.

• • •

Малны яхшы ашатсаң — файда, ашатмасаң — җәфа. Бу әйтемне халыкның мазалы еллар тәҗрибәсе тудырган, әмма әле хәзерге индустриаль-аграр шартларда да

* Бу очерк язылганнан соң күп тә үтмәде, Кубаньнан сөенечле хәбәрләр дә килеп җитте. Унынчы бишьеллыкта край хуҗалыкларында 600 мең баш сыер булып, алардан бер миллион дүрт йөз ике мең тонна сөт савылса, унберенче бишьеллыкта мөгезбикәләр саны утыз меңгә кимеде, ә сөт җитештерү, киресенчә, артты — бер миллион җиде йөз сиксән өч мең тоннага җитте. Һәр сыердан уртача савым 3013 килограмм булды. Терлекчелекне интенсивлаштыру юлында үрнәк алырлык эш бит: сыерлар саны утыз меңгә ким, ә сөт алу дүрт йөз мең тоннага диярлек күбрәк!

күпме кеше «крестьян университетларын» яңадан үтә — көтүләр терлек азыгына караганда зуррак к и л е п ч ы г а. Практика исә «терлекчелек белән игенчелек арасында тиешле пропорция сакларга» куша.

Унынчы бишьеллыкның һәр елында Татарстанда ике миллион йөз кырык меңәр тонна, тугызынчы бишьеллыктагыга караганда җиде процентка артыграк терлек азыгы әзерләнеп килде. Көтүләр исә унөч процентка үсте. Шунлыктан ферма утлыклары элеккечә үк, яртылаш кына тулып килде. Улак ничек тулса, сөте дә шулай гына булды. Республикада иң мул савым — һәр сыердан ике мең сигез йөз егерме килограмм — 1986 елда булды.

Унынчы бишьеллыкта Россия Федерациясе хуҗалыклары сөт җитештерүне сигез процентка арттырдылар. Моны мактарга да булыр иде, әмма бер үк вакытта сыерлар саны да шулкадәр үк арткан. Тула өлкәсендә продуктлылыкны нибары ике процентка күтәрделәр, ә бу нәкъ менә яңа сыер көтүләре биргән сөткә тигез. Калинин өлкәсе фермаларында баш саны үсте, ә савым мең ярым килограммга кимеде.

1871 елда, крестьян хуҗалыклары мал-туарны үз мөмкинлекләренә карап кына тоткан заманда, Санкт-Петербургта белешмә бастырып чыгаралар. Анда менә мондый акыллы сүзләр язылган: «...ач терлек файдага караганда зыянны күбрәк китерә». Һәм хәзер дә техникумнарда, институтларда, илебездә дан тоткан Авыл хуҗалыгы академиясе «Тимирязевка» укытучылары студентларны мәкерле бер сорау биреп «яндыралар». «Ике хуҗа унар тонна азык әзерли. Аларның берсе ике, ә икенчесе сигез сыер асрый. Кайсысының сөте күбрәк була?»

Мәсьәлә, беренче карашка, бик җиңел шикелле, әмма, дөрес җавап бирү өчен, арифметиканы гына түгел, табигать законнарын да белергә кирәк. Студентларның берсе, мәсәлән, юньләп уйлап та тормыйча, азык запасларын ике сыерга бүлә дә, «сөт икенче хуҗаныкында күбрәк була» дип шартлатып җавап бирә һәм ...икеле ала. Ә бит сыер, һәр җан иясе кебек, азыкны, барыннан да элек, үзенә тота, сөткә исә ашказанына кергән азыкның «артыгы» гына китә. Менә дигән ике сыер тотучы акыллы хуҗа ун тонна азыктан ун тонна сөт ала, ә шул ук азыкка бөтен бер көтүне җибәргән икенчесе буш кул белән утырып кала.

Эш азыкта гына да түгел. Азыкны мул әзерләп куйсаң, иртәгәсен үк сөт елгасы ага башлый, дип беркатлы фикер йөртүчеләр шактый. Әмма ачлы-туклы сыер, туйганчы ашатуга күчерелгәч тә, рекорд белән куандырмаячак, чөнки тере организмның яңадан тулы утлыкка, югары технологик нормаларга җайлашуын көтәргә кирәк. Сыер гомеренең моңа җитүе дә шикле.

«Гигант» совхозының тернәкләнеп, үсә баруын инде ун ел буе күзәтеп киләм. Көчле, нык хуҗалык. Совхозның директоры — Социалистик Хезмәт Герое Нәҗип Зиятдинов — дәртләнеп эшләүче гайрәтле кеше генә түгел, ул кыю фикерле, тәвәккәл, сүзен сүз итә алучы да. Әлеге хуҗалыкка автомобиль гиганты КамАЗ, яңа шәһәр күтәрелгәндә, тирә-як гөрләп-күкрәп торган чакта җитәкчелек итә башлады.

Авыл «Гиганты» да булдыклы булып чыкты, янәшәсендәге автогиганттан калышмады.

Кайберәүләр уңышны болыттан көтә. Зиятдинов исә кырларында яңгыр яудыру машиналары булдырды. Башка директорлар, председательләр автомобиль гиганты мәйданнарыннан скреперлар кырып алган кара туфракны, бушлай килгән байлыкны кая куярга белми чигәләрен кашыганда, Зиятдинов аны үз кырларына ташыды да куйды. Бүтәннәр гектардан унбишәр центнер бөртек ала, «Гигант»та утызаркырыгар. 1986 елны «Гигант»та, беренче карашка, мөмкин булмаганга ирештеләр бугай — бөртеклеләрнең гектарыннан алтмыш бишәр, терлек азыгы культураларыннан — туксан центнер чамасы уңыш алдылар. Әнә кая китте эшләр!

Җир йөзендә әле бер генә шәһәрнең дә автомобиль төзүчеләр каласы кебек шулай тиз үсеп киткәне булмады. Үз чиратында ул азык-төлек белән тәэмин итүче инфраструктураны да ашыктырды. Мондый хәлдә Зиятдиновка нишләргә иде соң? Ул бу эштә дә үзен ничек тотарга икәнен белде. Бүтәннәр, стандарт буенча, дүрт йөз — сигез йөз башка исәпләнгән абзарлар корса, курку-суркуны белми торган директор, ике мең баш терлек сыярдай комплекска тотынды.

Төзү-коруы Түбән Кама ГЭСын, КамАЗны төзегән, атом станциясенә тотынган «Камгэсэнергострой» идарәсе төзүчеләренә авыр эш булмады. Биш миллион сумлык сыер абзарлары бер сызыкка тезелгәндәй, калкып чыктылар. Сенаж башняларының гөмбәзләре кояшта ялтырап утыра. Аларга менә дигән юллар сузылган. Малларының кертеп ял та сөт елгаларын агыза башла!

Комплексны традиция буенча үзләштерә башладылар: башта көтүне җыйдылар, аннары продуктлылыкны күтәрә башладылар. Өч мең килограмм — Татарстандагы бүтән теләсә кайсы сөт фабрикасындагыга караганда күбрәк, тик бу хәл — түземсез Зиятдинов өчен соңгы чик түгел икән әле, эшләгән эшеңә әйләнеп карау өчен

сәбәп кенә. Дөрес эшләнелгәнме, кайда да булса хата китмәгәнме? Нәҗип Зиятдинович саннарны тиз әләктереп ала. Ел саен җитештерелә торган алтмыш мең центнер сөтне совхоз азрак санлы көтүдән дә ала алган булыр иде. Тик моңа ничек ирешергә?

Мин аның теңкәсенә тиеп, Одинцово савымчылары турында мисаллар китерәм, сиздермәстән генә Тула ягы председателе Стародубцевны да исенә төшерәм.

— Стародубцев күпме эшли? — ди Зиятдинов, бераз уйлап торганнан соң.

— Унҗиде ел...

— Әнә бит, күпме гомер үткән. Зур көтүдән өчәр мең литр савумы, әллә кечкенәсеннән бишәр мең саву әйбәтрәкме. Уйлап карарга кирәк.

— Тулай җитештерү бер чама сезнең. Алтмышар мең центнер. Сездә аны ике мең, ә Ленин исемендәге колхозда мең дә бер йөз сыер бирә.

— Килер бер көн, азык кытлыгы бетәр. Без дә бу чикне узып китәрбез әле.

1982 елда Зиятдинов көткән көн җитте, шундый уңыш алдылар ки — Кубань көнләшерлек!

Ләкин гектарыннан илле центнердан артык ашлык алуларына карамастан, «Гигант»ка фураж белән артык җәелеп китәргә ирек бирмәделәр, район, республика запаслары белән тигезләштерделәр. Әмма алар печәнне, сенажны, силосны, тамыразыкларны, саламны тау-тау әзерләделәр — һәр терлеккә утыз җидешәр центнер! Кабул ителгән норма — егерме бер центнер. Әгәр инде «Гигант»ның кышка запасларына яшел конвейердан кергән азыкны, фуражны да өстәсәк, нәкъ фән кушкан норма килеп чыга — бер сыерга алты тонна! Алты тонна азык — алты тонна сөт, практикада мең тапкыр расланган төп-төгәл арифметика!

Ел буе «Гигант»ның хәлләрен белешеп тордым. Ике мең башлык олы көтүнең күпме сөт бирә алачагын исәпләп чыгардым. Артым сизелерлек булырга тиеш иде, әмма һәр сыердан өч мең дә ике йөз туксан өч килограмм гына сөт саудылар. Әгәр йомшаграк хуҗалыклар белән чагыштырсаң, сүз дә юк, әйбәт, ә инде көчлерәкләргә килсәк, мактанырлык түгел. Алты тонна юк бит! Ни өчен сыерларга биргән мул азык сөт дәрьясы булып кайтмаган? Ничәмә-ничә еллар ачлы-туклы асралган сыерлар, әйбәт тәрбияли башлау белән үк, сөтләрен арттырмадылар. Аналары шикелле мул рационда яшәячәк яңа буын бозауларның үсеп җиткәнен көтәргә калды.

* * *

Бүген инде фермаларны азык белән тулысынча тәэмин итәрдәй колхозлар һәм совхозлар саны арткannan-арта, хәзер бурыч — сыерларның нәселен яхшырту.

Татарстанның Балык Бистәсе районын алыйк. Менә «Кама» колхозының заманча итеп корылган терлек комплексы. Мең баш сыер. Борчу һәм мәшәкать. Колхозда терлек үстерү белән нык шөгыльләнәләр. Азыкны күктән көтеп ятмыйлар, үзләренең яңгыр яудыру машиналарына исәп тоталар: 500 гектарлап җирдә — кукуруз, үлән, тамыразык кырларында ясалма яңгыр гел явып тора. Сугарулы һәр гектардан 60-70 центнер азык бирәмлеге җыела. Кышка азыкны һәр терлеккә 40-45 центнер әзерләп куялар. Җәй көне яшел болыннардан ашатылган 12-13 центнер азыкны да өстәсәк, һәр сыерга илле центнердан артык ризык туры килә. Бер литр сөт алу өчен бер килограмм азык бирәмлеге кирәк. Димәк, ферма сыерларының мөмкинлеге биш ярым тонна. Ә малкайлар өч мең литрдан уздыра алмыйлар. «Сыерның сөте телендә» дигән сүз, болай булгач, дөрескә чыкмый бит.

Узган бишьеллыкта колхозның савымы 600 килограммга арткан, әмма өмет зуррак булган. Менә дигән абзарлар, сенаж башнялары, азык цехы, сугарулы җирләр, миллионнарча сум ссуда һәм бурычлар — боларның бөтенесе сөтне күп алу өчен эшләнә. Әмма савымны арттыру велосипедта узышу түгел ул. Велосипед ярышында бит бөтен трассаның буеннан-буена лидер артында ышыкланып барырга да финишта кинәт алга ыргылып чыгарга мөмкин. Фермада исә яхшы нәтиҗәгә ирешү өчен бер мәртәбә ыргылу гына җитми, педальләрне бөтен дистанция буена, гомер буена әйләндерергә кирәк. Ничә буын сыерның тамагы туеп җитмәгән икән, бүгенге сыерлар, әлбәттә, сөтне күп итеп бирергә әзер түгел. Бик кыйммәткә төшкән комплекста өч мең литр сөт саву, әллә ни куаныч китерми. Һәр сыердан бишәр-алтышар тонна сөт алына торган яхшы көтүләрдә бер терлек мең сум табыш бирсә, «Кама» колхозының сыерлары зыян гына китерәләр. Бүтәннәрнең сыеры — туендыручы, «Кама»-ныкы — бөлдерүче. Колхозның тугыз миллион сум бурычы бар.

Безнең әңгәмә нәкъ шул хакта: сөтле сыерлар һәм сөтсез сыерлар турында. Идарәдә колхоз председателе Х. Кәримуллин, комплексның начальнигы К. Закиров, баш зоотехник И. Хәсәнов. Кайда икән ул сөт? Менә шуны бергәләп «эзлибез».

Табигатьнең гаҗәеп ышанучан, юмарт җан иясен хәйләкәрлектә гаепләп булмый. Ашаткан азыкны санап караганда, биш тонна сөт саварга кирәк, ә колхозда нибары өчне савалар. Башваткыч, кроссворд! Төгәл җавапны ничек табарга? Кайчакта булмаган запасны да сыерга «сылыйлар», азык хәзерләү кампаниясе чорындагы арттырып язулар очрый. Отчетларда тау-тау азык, ә улакларга калдык-постык кына эләгә.

— Бездә алай булмый,— дип бәхәсләшә башладылар хуҗалар.— Терлек азыгын саклау урыннарына да, фермаларга да үлчәп кенә ташыйбыз, исәп-хисапларда алдашу-ялгышу юк. Йөз дә илле сыер шушы рационда да бишәр тонна сөт бирә. Калган сигез йөзе алай бирә алмый. Алмаштырасы иде аларны. Биш мең литр сөт бирә торган сыерларга заказны кемгә бирергә?

— Заказны биргәч-биргәч, җиде мең литр саудыра торган сыерларга бирергә кирәк. Сөтегез шундук икеләтә артыр.

— Их, хыял зур ла ул...

— Ә районлагы «Корноухово» нәсел совхозы нәрсә карый?

— Әллә сыерлар анда сөтлерәк дип уйлыйсызмы? Юк! Алардагы нәсел бозауларының бәяләре генә бер ярымга артык.

— Ә таналар үстерүче спецхоз? Анда бит ике мең баш яшь тана бар...

— Андагы яшь терлекләр тәүлегенә биш йөз грамм артым бирә, сөтләре — барыбер шул ук өч мең килограмм. Барын да үзебездә үрчетергә кала. Димәк, унунбиш ел кирәк булачак.

Нинди мәгънәсезлек бу? Гади хуҗалык нәселле бозаулардан баш тарта, специальләштерелгән совхозның сыерлары гадәттәге терлекләрдән берниндн өстенлеге белән дә аерылмый.

Чыннан да, колхоз һәм совхозларның нәсел фермалары, специальләшкән дәүләт нәсел заводлары ни өчен зур нәтиҗәләргә ирешмиләр? «Корноухово» совхозы инде алтмыш еллап нәсел хуҗалыклары рәтендә, ул — илебездә сөт терлекчелеге селекциясенең нигезләрен салган хуҗалыкларның берсе. Нәсел эше катлаулы, кыен, аңа вакыт күп кирәк. Токымның генофондын күтәрә, рекордлы сөт бирә торган терлекләр көтүен, классик селекция һәм генетика кагыйдәләрен саклап, бик озак җыйлар. Табигать кануннары белән исәпләшмичә булмый. «Корноухово» совхозының селекционер-зоотехниклары, үз алларына шундый югары максатлар куеп, лидерлар рәтенә дә чыга алган булырлар иде, тик менә хуҗалыкны башка проблемалар йөдәтә. Бөртекле ашлык, бәрәңге, сөт һәм итне ничек итеп күбрәк сатарга? Узган елда совхоз бөртекле ашлык сату планын ике тапкырдан күбрәккә арттырып үтәде. Әгәр нәсел совхозы үзе фураж сата икән, димәк, терлек азыкларына кытлык юк дигән сүз. Җиргә рәхмәт — байлыкны мул бирә. Ә шулай да совхозның төп товары — нәселле терлекне ничек булдырырга? Өчәр мең литр сөт бирә торган сыерлар көтүеннән совхоз елына 450 тана ала. Сөтне уртача дәрәҗәдән күбрәк бирүче, иң яхшы сыерлардан туган бозауларны үзендә калдыра, ә сөтләре 2500 литр тирәсе булганнарының,начарракларының нәселен башкаларга сата. Сату бәяләре зурдан. Бүтәннәрдә таналар, әйтик бер мең сум тора, нәсел совхозының тамгасы сугылганнар — мең ярым.

Соңгы ун елда «Корноухово» совхозы читкә мең ярым баш бозау саткан: аларны нәселле дип шартлы рәвештә генә әйтеп була. Димәк, хуҗалык ким дигәндә бер миллион сум артык акча ала, монысы инде шартлы сумнар түгел; ә реаль акча. Иң аянычлысы шул: алтын бәясенә төшкән нәсел бозаулары хуҗаларына бервакытта да куаныч китермәячәк, аларны мул савымнар белән шатландырмаячак.

Кызганычка каршы, нәсел фермаларының сыерлары гади терлекләрдән югары продуктлылык сыйфатлары белән түгел, ә бәлки алтын бәясенә төшүләре белән генә аерылып тора. Моның сәбәпләре күп. Экономик стимуллар һәм идарә итү алымнары бозыла. Еш кына нәсел өчен чын селекционер-зоотехниклар түгел, ә бәлки сводка энтузиастлары, бүгенге белән генә яшәүчеләр эшли терлекчелектә. Хикмәт шунда: осләренә җаваплылык йөкләнгән кешеләр шул җаваплылыкны тоя белмиләр, үз алларына югары максатлар куеп эшләмиләр, ирешкәннәр белән канәгать булып калалар. Ике мең килограмм савым ала торган гадәти фермалар өчен «Корноухово» совхозы бозаулары, сүз дә юк, әйбәт, алардан көтүгә зыян килми. Ә менә биш-алты мең килограмм савымга исәп тотучылар нәсел бозауларын каян алсын?

1919 елны, яшь Совет дәүләтенең тәүге адымнарында ук, В. И. Ленин нәселле терлекләрне «милли байлык» дип атады. Әлеге бәянең тормышчанлыгын еллар раслады. Күпме боерык, күрсәтмә, директива, лозунг һәм плакатлар илебез терлекчеләренең яшәү һәм эшләү кагыйдәсен теркәп килде: «дәүләт нәсел заводларының, колхоз һәм совхозлардагы нәсел фермаларының производство эшчәнлеген төп бурычы хәл итүгә буйсындырырга — югары кыйммәтле терлекләр үстерергә һәм сатарга». Ачык, төгәл, аңлаешлы.

Терлекләрең нинди — ферман шундый. Муллыкны, табыннарыбыз ямен, ачлы-туклы көн итүче илләр һәм халыклар кичергәннәрне кичермичә, яшәвебезне беренче чиратта көтүләрнең куәте хәл итә. Шушы бөтенхалык программасын тормышка ашыру өчен, илебездә гомумдәүләт нәсел службасы оештырылды, аны фәнни яктан ныклы тәэмин итү каралды. ВАСХНИЛ системасында гына да 117 фәнни-тикшеренү институты исәпләнелә, алар штатында 18 мең кеше эшли, шул исәптән — академиклар, фән докторлары, фән кандидатлары.

Илдә нәсел фермалары күп, биш меңнән артык. Кайберәүләр үзләреирешкәннән канәгать түгел. Бу әле беренче адым гына дип карыйлар. Башкалары исә өч мең литрлы савымны да зур казаныш итеп күрсәтергә тырышалар. Көндәлек мәшәкатьләргә күмелеп, перспективаны онытккан РАПО җитәкчеләре һәм гади зоотехниклар гына түгел, нәсел эшен, терлек селекцияләүнең яңа алымнарын яхшы белгән, ул алымнарны практикада кулланырга тиеш булган кешеләр дә аздан канәгать булып яшиләр. Мәсәлән, «Корноухово» совхозы дәрәҗәсендә эшләүне нәсел совхозлары производство берләшмәсе начальнигы Закирҗанов менә ничек бәяли: «Нәсел хуҗалыкларындагы терлекләрнең продуктлылыгы гадәти колхоз һәм совхозлардагыдан югарырак. Һәр сыердан еллык уртача савым 3000 килограммга кадәр артты».

Бу бит республика буенча уртача күрсәткечләрдән чак кына артык. Ә «нәселле» таналарны сатып алучылар кыйммәткә төшкән мондый малларның көтүне яхшыртмавыннан зарланалар; нәсел эше белән шөгыльләнүче белгечләр исә барабан кагалар, шау-шу куптаралар, моны казаныш итеп күрсәтергә азапланалар.

Яхшы терлек үрчетү — күп хезмәт куюны сорый торган кыен эш. Зоотехник-селекционерларга, профессиональ белемнәрдән, табигать каршылыкларын җиңү өчен кирәкле ихтыяр көченнән һәм ныклыктан тыш, төрле шартларга, төрле хәлләргә каршы тора белү дә кирәк. Кыенлыкның иң зурысы — шапырыну гадәтен ташлау, эшеңне югары профессиональ һәм гражданлык критерийларыннан чыгып бәяләү. Халык хуҗалыгының барлык тармакларында тизләнеш темплары булдырылды. Терлекчелек тә читтә калмады. Сөтсез сыерларны сөтле сыерларга алмаштыру — интенсивлаштыруның төп чыганакларыннан берсе. Яхшы терлеккә мохтаҗлык зур, ә шул мохтаҗлыкны бетерү өчен куелган белгечләр «казанышлар» белән мактаналар. «Животноводство» журналының былтыргы саннарыннан берсендә СССР Авыл хуҗалыгы министрлыгының терлекчелек главкасы начальнигы П. Корнеев һәм нәсел эше буенча Бөтенсоюз фән-производство берләшмәсе генеральный директоры Б. Багрий хәлне менә нинди әйбәт итеп күрсәтәләр: «Нәсел хуҗалыклары челтәре ел саен бер миллион баш нәселле таналар үстерергә мөмкинлек бирә. Соңгы дүрт ел эчендә генә дә нәсел хуҗалыкларыннан 4,16 миллион баш терлек сатылды... Илебездә таналар үстерү буенча специальләштерелән хуҗалыклар челтәре төзелде... аларда бер үк вакытта бер миллионнан артык терлек үстерәләр...»

Күрәсез, һәммәсе ал да гөл!

Ә бит илдәге сыер көтүләрен ел саен 20-25 процентка яңартып торырга туры килә, колхоз һәм совхозларга гына да сигез миллион тана кирәк, ә нәселле терлекләрнең калган миллионнарча башына булган заказларны кем канәгатьләндерер?

Унберенче бишьеллыкның дүртенче елында Россия Федерациясенең дәүләт нәсел заводларында көтүләрнең уртача продуктлылыгы 3831 килограмм, нәсел совхозларында — 3269 килограмм иде, ә колхоз нәсел фермаларындагы нәтиҗәләр тагын да түбәнрәк булды. Иң яхшы таналарны үзләрендә калдыралар, начаракларын саталар. Димәк, нәселле көтүләр үзләре өчен генә эшли, хуҗалыкларның көтүләрен исә беркайчан да өч мең литр сөт бирмәгән сыерлардан туган бозаулар хисабына ишәйтәләр. Нәсел көтүләренең стандарт продукциясе нинди булырга тиеш? Кемне ни өчен мактарга, ни өчен шелтәләргә кирәген беләсем килде. Белеп бетерә алмадым. Берәүләр җиде мең литрны, икенчеләре — биш, кайберәүләре — өч меңне югары нокта дип атады. Заводларда, фабрикаларда эшче урыннарны яңадан аттестацияләү яхшы нәтиҗә бирде. Нәсел фермаларында әледән-әле имтихан үткәрер чак җитмәдеме икән? Көтүләр саны күп, нәселле терлек юк. Әгәр нәсел хуҗалыгы гадәти хуҗалыкларга стандарт булмаган вак үлчәүле терлекләр сата икән, мондый маниловчылык, ягъни буш куыклык, «нәсел хуҗалыгы» дигән битлек белән яшәү кемгә кирәк? Ленинград өлкәсендә, мәсәлән, дәүләт нәсел заводларының эш нәтиҗәләре уртача савымнарны мең килограммга диярлек узып китә, ә кыйммәткә төшкән көтүләрнең сөтне гади фермалардагыдан да кимрәк бирә торган төбәкләре күпме?! Сүз бит күмер яки тимер турында түгел, ә табигатьнең тере затлары хакында бара: аларның бит, төрле шартларга, хәлләргә карап игелекле туендыручы да, явыз бөлдерүче дә булуы мөмкин. Моңа сыерлар түгел, без үзебез гаепле!

Көтүне яңарту иң әүвәл дәүләт нәсел берләшмәләре кулында, аларның үз эшләрен ничек башкаруларында, кагыйдәләрдән читкә тайпылмауларында. Ә нәселле көтүләр башка хуҗалыкларның уңышын хәл итәләр. Алар сөт терлекчелегенең ниге-

зен салалар — нәселле үгезләр үстерәләр. Авылда борын-борыннан: яхшы үгез — крестьян көтүенең яртысы, диләр.

Туладагы дәүләт нәсел берләшмәсенең үзәк станциясендә лаборатория мөдире Тамара Петровна Дужак болай дип зарланды:

— Үгезләр бернигә яраксыз, бер елдан артыкка чыдамыйлар. Зур акчалар тотып «чит-атларны» кайтарабыз, ә үзебезнекеләрне тәрбияләп үстерә белмибез.

Көтү белән профессиональ эш итүнең нечкәлеге шунда — ун-унбиш сыердан токымлы бер үгез алырга мөмкин; барлык контроль экспертизалардан соң андыйларның яхшыларын Кызыл нәсел китабына кертәләр. Безнең фермаларда нәселгә бер мең сыердан өч үгез аттестацияләнә, шуңа күрә дә нәсел үгезләре дефицит, аларны әледән-әле чит илләрдән кайтартып торалар. Бездә дүрт үгезнең фәкать берсе нәселен яхшырта, калганнары исә, селекционер-зоотехниклар теле белән әйткәндә, нейтраль булып чыгалар, яки көтүне бөтенләй бозалар. 1947 елны ВАСХНИЛ академигы Милованов лабораториясендә үрчеткеч-үгезләрнең гаметаларын саклау ысулын таптылар, практиклар сыер көтүләрендә бары тик яхшырткыч үгезләрдән генә файдалануның сирәк була торган мөмкинлеген алдылар. Конкурс үтмәгән үгезгә көтүгә юл ябык!

Конкурс катлаулы, кыен, сайлап алу биш ел буена сузыла. Бу процедура мәҗбүри, югыйсә иң уңай күрсәткечләр булганда да, селекционер-зоотехникларның эше кире нәтиҗәләр бирүе мөмкин.

Кырык ел, бер кеше гомере хәтле вакыт узды. Хәлләр ничегрәк тора, сыер көтүләрендә нинди үгезләр — нәселне яхшыртучылармы, әллә бозучылармы? Тула өлкәсендә узган бишьеллыкта бозауларның 15 процентын гына яхшырткыч үгезләр бирде. Ил буенча әлеге процент аз гына югарырак, әмма сокланырга иртәрәк. Россия Федерациясе фермаларының яртысында диярлек сыерлар сөтне дүрт мең килограммнан кимрәк бирә. Нәсел яхшырткыч үгезләр булган фермаларның биштән икесендә шул хәл. Яңалыкны беренче ачучылар бул да, шулкадәр артка кал имеш!

Кичәге дәрәҗә белән чагыштырганда, сыерларның генетик потенциалы үсте, әлбәттә. Сугыш алдыннан илдә уртача савым 1124 килограмм тәшкил итә иде. Хәзер сыерларның сөт бирүе икеләтә артты. Ләкин бит мөмкинлекләр дә күбәйде, ихтыяҗлар да үсте. Бүгенге йөз миллион тонна сөт — ул әле яңа үрләргә бару юлында бер баскыч кына. Терлек асрауны бүгенге дәрәҗәдә алып барсаң, яңа көтүләр үрчетергә, өстәмә гектарлар биләргә, болай да дефицит хезмәт ресурсларын терлекчелеккә күчерергә туры киләчәк. Илдә чәчү мәйданнары чикле — бөтенесе сөрелгән, чәчелгән. Артык эшче көчләр юк. Шуңа күрә совхозларда көтүләрне яңарту, начар сыерларны мул сөтлегә алыштыру теләге бик зур. Теләк әйбәт, ләкин аны ничек гамәлгә ашырырга — менә хикмәт нәрсәдә. Россия колхозлары һәм совхозларында 5-7 мең килограмм сөт бирә торган сыерлар саны 89 мең, шулар арасында рекордчы сыерлар тагын да азрак — 5 мең. Ә майлылыкны да исәпкә алсак, 4 процент майлы, 4-5 мең литр савымлы сыерлар нибары 37 мең, җиде меңче сыерлар фәкать сигез йөз. Уйландыра, кичектергесез эшләргә чакыра бу арифметика!

Ә мул сөтле сыерларга мохтаҗлык менә нинди: Россия фермаларында ел саен уналты миллионлы көтүне яңартырга кирәк, димәк, нәсел таналарына ихтыяҗ 4 миллион баш. Сирәк булган рекордчы сыерлардан ничек итеп шулкадәр бозау алырга соң? Яхшы мал санын тизрәк арттырырга кирәк. Бу җиңел эш түгел. Кызганычка каршы, гади хуҗалыклар да, махсус дәүләт нәсел заводлары да аны әлегә башкарып чыга алмыйлар, чөнки моның өчен күп вакыт таләп ителә. Я булмаса савым көтүләрен иң сөтле сыерлардан туган таналар белән тулыландыру юлларын табарга, моның өчен һәр терлектән хәзергечә бер-ике түгел, ә ун, йөз, мең бозау алырга! Әле күптән түгел бу хакта вакыйгаларны алдан күрүче фантастлар гына яза иде, бүген исә әлеге проблема заман елъязмачылары-журналистларны уйландыра, фәнни лабораторияләрдә, колхоз һәм совхоз көтүләрендә эшләүче селекционер-зоотехникларның ишекләрен кага.

Сыерны микроскоптан караганыгыз бармы сезнең? Юктыр, мөгаен, чөнки андый хайванны линзаларына эләктердәй микроскоп биш катлы йорт кадәр булырга тиештер. Ә сезгә тагын портатив контейнерда, җиңел автомашина кузовында мең баш сыердан торган көтүне алып кайтырга туры килгәне бармы?

Турысын әйтим: миңа йөк йөртү мәшәкатьләре белән шөгыльләнергә туры килмәде, шундый зур терлек көтүен өлкәләр һәм республикалар, ил чикләре һәм таможнялар аша ташуда да катнашканым юк. Әмма, ышанасызмы-юкмы, сыерны микроскоптан караганым бар.

Тула өлкәсенең «Новая жизнь» колхозында баш зоотехник Таисия Никифоровна Мирушкина безне комплекска алып китте. Бәләкәй генә лабораториядә ветеринария врачы Полина Станиславовна Воронцова безгә могҗизаның үзен — тере эмбрионны

күрсәтте; дөньяга килгән һәр бозауга селекционерлар анкета тутыра, нәсел-нәсәбен яза. Бирердә ул да язылган иде.

Комплексга әле генә гадәти булмаган операцияне төгәлләгәннәр — Лебедка кушаматлы донор-сыерның тере эмбрионнарын бер үк вакытта ике яшь танага күчергәннәр. Лебедка — гадәттәге кара-чуар токымлы сыер, иң югары савымы — 5528 килограмм. Нәселе дә әйбәт, атасы ягыннан савым — 6365, анасы ягыннан — 7820 килограмм, сөтенең майлылыгы — 4,31 процент.

Лебедкадан шундый нәселле бер көтү бозау алсаң, нинди шәп булыр иде. Тик менә нишләргә? Сыер бит кыска гына гомерендә биш, алты, күп дигәндә ун бозау бирә ала. Лебедка дүрт бозаулауда хуҗаларына ике нәни тана һәм өч үгез бүләк итте. Аны мактыйсы гына иде инде моның өчен, ләкин крестьян тәҗрибәсе башкачарак эшләргә, сыерга үзеннән соң мөмкин кадәр күбрәк нәселен калдыруда ярдәм итәргә куша; шулай итеп кара-чуар Лебедка сайлап алынган донорлар рәтенә эләгә. Техник яктан әлеге операция гади генә, һәрхәлдә аны ветеринария эшен белгән, инструментлар һәм приборлар белән коралланган осталар җиңел башкара ала. Лебедкага алтынчы тапкыр ана булыр чак җиткәч, аңа график буенча биш мәртәбә биологик гормоннар бирәләр, процедураны минутын-секундын санап һәр унике сәгать саен эшлиләр, аннары Персик кушаматлы саф токымлы үгез белән «каплаталар». Җиде көн узганнан соң Лебедка инде ата-аналарының бөтен нәсел үзенчәлекләрен алган өч тере яралгы бирә, шуларның икесен яраклы дип табалар. Фермада инде чит яралгыны үстерергә көне-көнгә, сәгате-сәгатькә бер үк вакытта хәзерләнгән ике яшь тана-реципиент әзер тора. Артык затлы булмаган кара-чуар таналар чит яралгыларны кабул итә, аннары алар менә дигән сын — сыйфатлы бозау үстерәчәкләр. Бу бозаулар исә яралгы иялӘренең сыйфатларын алачак.

Колхозның ветеринария шифаханәсендә башкарылган операцияләрнең беренчесе түгел инде бу. Хуҗалыкта мул сөтле сыер-донорлар сайлап куелган, алар гадәттәге бозаулар тудырмыйлар, ә яралгы гына бирәләр. Полочка кушаматлысы елына 6491 литр, Ханна — 5794, Мина — 5393, Грустинка — 6662, Двойка — 6697 литр сөт бирүче сыерлар.

Яхшы хайваннарның эмбрионнарын үзләре берни белән дә аерылып тормаган тәрбияче-сыерларга күчерү әле кичә генә мөмкин булмаган, сирәк очрый торган эш иде. Ә менә «Новая жизнь»дагы зоотехник-селекционерлар өчен бу инде күнегелгән эш икән. Башка тугыз йөз сыердан туган яшьтәшләре арасында ясалма юл белән дөньяга китерелгән шаян бозаулар йөгерешеп йөри, аларны кызыл муенчаклар гына аерып тора. Зоотехникларны башка мәшәкатьләр борчый — бер сыердан күпме бозау алырга була? Уннымы, йөзнеме, хәтта әйтүе дә куркыныч — әллә меңне үкме?

Двойка дигән сыер, мәсәлән, гомумән сирәк очрый торган зат булып чыккан: ул, әйтерсең лә, кешеләргә мөмкин кадәр күбрәк файда китерү өчен генә дөньяда яши. Бишенче бозаудан соң аның кинәт кенә сөте бетеп китә; мондый малны югалту — бәхетсезлек. Двойканы донорлыкка күчерәләр һәм ул хуҗаларына берьюлы унсигез тере эмбрион бүләк итә. Фантастик хәл! Нинди перспективалар ачылуын күз алдына китерәсезме: бер анадан бер көтү бозау алырга мөмкин! Эмбрионнарны трансплантацияләү — практик биологиянең яңа тармагы. Ул терлекләрне ясалма орлыкландыру методыннан башланды. Ул чактан бирле илле елдан артык вакыт үтте. Чиратта икенче адым — терлекләрне үз көтүләрендә түгел, ә лабораторияләрдә, конвейерда үрчетү.

Сораулар күп, җаваплары азрак. Әмма, өйрәнелгән нәрсәләрнең теоретик өлеше инде тормышка ашырылган. Әлеге проблема буенча Бөтенсоюз авыл хуҗалыгы терлекләр генетикасы һәм аларны үрчетү фәнни-тикшеренү институты, Мәскәү янындагы Подольск шәһәренең Бөтенсоюз терлекчелек институты, Калуга өлкәсе Боровск шәһәрендәге Бөтенсоюз авыл хуҗалыгы терлекләр физиологиясе, биохимиясе һәм аларны ашату фәнни-тикшеренү институты, Украина ССРның Урман-дала һәм Полесье терлекчелеге фәнни-тикшеренү институты кебек эре фән үзәкләрендә, Идел буе, Балтик буе фән учреждениеләрендә эш алып баралар...

1983 елның 24 январенда булган бу вакыйга да, башка «гасыр ачышлары» кебек үк максималь төгәллек белән теркәп куелды — 7 сәгать 45 минутта Бөтенсоюз авыл хуҗалыгы терлек үстерү һәм генетика фәнни-тикшеренү институты фермасында бер үгез бозау дөньяга килә, аңа «Первенец» («Беренче») дип исем кушалар. Сенсация ясарлык нинди факт соң бу? Эш шунда ки, дөньяда беренче тапкыр «Первенец» кушаматлы үгез чын мәгънәсендә пробиркадан килеп чыга: яралгы ана карынында түгел, ә ясалма «тере су» тирәлегендә үсә, аннары аны реципиент-сыер «күтәрә». Шулай итеп, тикшеренүчеләр табигатьнең тагын бер биологик серен чишүгә ирештеләр. Бу исә фермада сирәк була торган рекордчы сыердан барлы-юклы йөз үгез яки йөз тана бозау гына алып калмыйча, көтүне тулыландыру өчен һәр ананың күкәй

кузәнәкләрен (ә сыер организмында алар илле меңгә кадәр була) файдаланырга мөмкинлек бирә.

Эмбрионнарны трансплантацияләү, нәселләрне «ин витро», ягъни ана организмыннан читтә, берәмләп кенә түгел, ә дистәләп, йөзләп, меңләп үстерү — искитмәле хәл, гадәти булмаган хәл. Дөресен генә әйткәндә, ул әле катлаулылыгы белән генә түгел, ә булган мөмкинлекләрнең масштаблары белән дә куркытып, сагайтып тора. Автомобиль һәм самолет, таркатылган атом һәм атом-төш коралы, спутниклар һәм космик сәяхәтләр кебек хәзер инде гадәткә кереп киткән чынбарлыклар белән дә заманасында шулай булды бит. Фәндә, димәк, кеше өчен, аерым дәүләтләр, кешеләр җәмгыяте өчен мөмкин булмаган нәрсәләр юк, эш вакытта гына, галим-экспериментаторларга мөмкин булган нәрсәләрне практикларның да эшләргә өйрәнүләрендә. Бар нәрсә тырышлыгыбызга бәйле.

«Ин витро» ысулы әлегә пробиркада, бу идеяне практикларга тәкъдим итү иртәрәктер дә, бәлки. Алда — зур фәнни тикшеренүләр, эзләнүләр. Ә тере эмбрионнарны конвейерга күчерергә бик вакыт. Венгриядә, көтүләрен яңартуга керешеп, сөт терлекләренең голштино-фриз токымын үрчетүгә күчә башлагач, фермаларга, нәселле таналардан тыш, меңнән артык рекордчы сыер эмбрионнары кайтартканнар. 12 ел эчендә һәр сыердан уртача савым 1734 килограммга арткан. Интенсивлаштыруның, терлек үрчетүне кискен тизләтүнең әйбәт күрсәткече бу. Безнең көтүләрдә уртача үсеш соңгы илле елда егерме килограмм гына! Сөт терлекчелеген интенсивлаштыру алымнарын эзләүгә багышланган ике дистә ел эчендә (эмбрионнарны трансплантацияләүдәге беренче тәҗрибәләр дә шул вакытка туры килә) авылны үстерүгә 550 миллиард сумнан артык акча җибәрелде. Унынчы бишьеллыкта гына да агропромышленность комплексын үстерүгә аннан алдагы барлык бишьеллыкларда тотылган кадәр байлык китте. Фәннең партнерлары, әлеге очракта Госплан, Авыл хуҗалыгы министрлыгы сөтчелек көтүләрен селекцияләүнең традицион алымнарына күбрәк исәп тоттылар. Алар исә, кызганычка каршы, терлекләрне яңартуның бирелгән темпларын тәэмин итә алмады, галимнәр алдына практикада файда бирердәй катгый сроклар куелмады.

Россия Федерациясе Госагропромның Бөтенсоюз нәсел эше производство берләшмәсе генеральный директоры В. Чистяков безгә бер уникаль фоторәсем күрсәтте. Анда тере эмбрионнардан алынган, начар гына «паспортсыз» реципиентлар «күтәргән» өч буын терлек төшерелгән. Әбисенең иң югары продуктлылыгы 16 мең литр, кызынныкы — 14 мең, ә оныгы беренче елында ук 10 мең литр сөт биргән. Чыннан да, кешеләр табигатьне кысмаганда, ә үз эшләрен аның кагыйдәләре һәм кануннары белән килештереп алып барганда, мөмкинлекләр нинди зур, кеше һәм табигать дуслыгы никадәр нәтиҗәле, уңышлы була ала. Тик шунысы кызганыч: әлеге уникаль фоторәсем чит ил болыннарында төшерелгән иде.

Вакыт уза. Узган вакытны кире кайтарып булмый. Тырышлык теоретик эшләнмәләрне дә тизләтергә (эшнең бит әле башы гына) һәм экспериментлардан масса төсендәге практикага кадәрге араны тизрәк үтәргә ярдәм итәчәк. Моңа кайчан ирешелер?

— Хәзер эшләр кызулана төште,— ди бүгенге хәлләр турында Бөтенсоюз терлекчелек институты директоры, авыл хуҗалыгы фәннәре кандидаты Николай Иванович Стрекозов.— Илебездә эмбрионнар трансплантацияләү буенча дүрт станция эшли, егерме алты хуҗалыкта селекционерларның терәк пунктлары оештырылды. Аларда югары савымлы донорлардан мул сөт кенә түгел, ә бәлки күпсанлы нәсел дә алырга тырышалар. Быел шундый юл белән өч мең бозау алу планлаштырылган. Боз кузгалды, димәк. Шуны әйтеп китик: АКШ фермерлары рекордчы-сыерларыннан йөз мең бозау алып үстерделәр инде.

• • •

Иртәгәге түгел, ә инде бүгенге савым көтүләрендәге супер-сыерлар турындагы сүзне матур итеп тәмамлыйсы килә дә бит. Ак кәгазь битенә ышаныч, өмет сүзләре ятарга тора: көтүләрне тулыландыруда инде бернинди проблема да юк... Заявка җибәрәсең дә, ампулалар белән менә дигән рекордчы сыерлар кайтып төшә. Тик бу исәп-хисапларда, күңел сизеп тора, чынбарлыкка караганда хыял күбрәк. Институт лабораторияләрендә дә, колхоз һәм совхозлардагы терәк база пунктларында да практиклар моңарчы уйга да килмәгән эшләр эшлиләр. Тик алар әле чит ил кәгазьләре ябыштырылган аппаратлардан һәм дарулардан файдаланалар. Лазер техникасы да, космик техника да түгел югыйсә, гап-гади җайланмалар, баксаң-күрсәң, барысы да диярлек читтән кайтартылган, сатып алынган. Биологик гормоннар юк, тере яралгыларны кирәкле срокка кадәр сакларга мөмкинлек бирә торган аппаратларны сатып алу да бик кыен. Вәгъдәләр күп, буа буарлык, ә кул астында берни дә юк.

— Техник яктан проблемалар гади генә, алар эш тәртибендә генә хәл ителә торганнардан,— ди Бөтенсоюз авыл хуҗалыгы терлекләр физиологиясе, биохимиясе һәм аларны ашату фәнни-тикшеренү институтының трансплантацияләү лабораториясе мөдире, биология фәннәре кандидаты Владимир Павлович Рябых.— Коралларның инде бөтен комплексы эшләнде, катетерлар, мәсәлән, Болгариядә, Германия Демократик Республикасында патентланды, биологик гормоннарның составы табылды, тик конвейерга барып чыга алганыбыз юк әле, бөтенесе бюрократик килешүләрнең контора чытырманлыкларына күмелде.

* * *

— Әйтегез әле, нәрсәдән башларга, безгә дә трансплантация ысулларын үзләштерүдә ярдәм итсеннәр өчен кем ишегән шакырга? — дип, миннән үзенең уй-планнарына яклау һәм булышлык эзләүдән башлады сүзен Татарстанның «Пугачевский» совхозы директоры Александр Петрович Малыхин.— Иртәгәдән үк тотыныр идек.

Мин башта аңа бу эшнең кыенлыкларын әйттем.

— Кыйммәткә төшә торган эш, катлаулы, хуплап җиткермәүләре дә ихтимал. Сезнең аргументларыгыз нindирәк соң?

— Көтү саф токымлы «айршир»лардан тора. Савым 6133 килограмм, сөтләренең майлылыгы 4,2 процент. Азыкларны инде «теләгәнчә» бирәбез, безгә сигез мең литр саварга кирәк. Соңгы вакытта савым һәр елны алтмышар литрга артып килде. Болай барса, сыерларны алыштыру өчен 30 ел кирәк булачак. Көтүне яхшырту иң сөтле нәселләр хисабына барса (46 сыерыбыз алты ярым тоннадан артык сөт бирә, 18 сыерның сөтендә май биш проценттан артыграк), вакытны отачакбыз.

Аргументлары бик нигезле!

Шундый ук югары савымлы, тик инде саф токымлы голштино-фризлардан гына торган икенче көтү Татарстанда — Балтач районының Тукай исемендәге колхозында туплана. Моңа кадәр хуҗалык үзебезнең холмогорларны үрчеткән, уртача савым 3500 килограмм. Сүз дә юк, андый фермага зур акчалар тотып чит илдән кителгән, сатып алынган супер терлекләрне ышанып тапшырырга мөмкин: бу, барыннан да элек, ышаныч күрсәтү белән зурлау. Әмма колхозда малның генофондын саклау өчен генә түгел, ә бәлки аның өстенлекләрен арттыру өчен дә җаваплылыкларын яхшы аңлыйлар. Читтән кайтартылган терлекләрне махсус диетага куялар, бозаулату уңышлы үтә, фермада хәзер 39 тана бозау һәм 39 үгез бозау. Тәүлеклек үсешләре берәр килограмм. Лактация әле тәмамланмаган, әмма инде сигез ай эчендә үк 4500 әр килограмм сөт биреп өлгергән тана сыерлар бар.

Колхозда инде дәртләнеп киткәннәр, сыерларның бөтенесен дә алыштырырга уйлыйлар. Көтүне алтышар мең литр сөт биргән супер сыерлар белән тулыландыру өчен, алдан азык базасын арттырырга кирәк. Кушкәт елгасы буйлап җирләрне сугару өчен, алты буа буачаклар: һәр сыерга икешәр гектар «яңгырлы» мәйдан булачак. Сенаж башнялары куелачак, печән саклагыч, тамыразыклар складлы, азык хәзерләү цехы төзиячәкләр.

— Көтүне алыштыру — ул, барыннан да элек, хезмәт, зур көч түгү һәм күп акча тоту,— дип, үзенең планнары белән уртаклашты колхозның председателе Камил Бәдретдинович Нәҗмиев. Көтү яхшырту хисабына сөт җитештерүне һич югында ике тапкырга арттырырга исәплибез. Барлыгы ике миллион ярым акча тотарга кирәк.

— Холмогоркаларны голштино-фризлар белән алыштырып бетерүгә күпме вакыт кирәк булачак?

— Безнең «аристократларыбыз» беренче егерме бозауны ике елдан бирәчәк. Сыерларны бөтенләе белән алыштырып бетерү өчен, унбиш ел кирәк булыр дип уйлыйбыз.

Гасырлар буе терлек асраучылар сыердан елына бер бозау алуларына канәгать булганнар. Хәзер исә көтүләрне тулыландыру, сыерларның бары тик бөтен яктан да аеруча кыйммәтле нәселләрен — рекордчыларны гына сайлау, алардан унарлап түгел, ә йөзәрләп, меңәрләп бозау алу мөмкинлекләре ачыла.

Әйдәгез, бераз хыялланып алыйк, иртәгәсе көнебезгә кыюрак күз салыйк. Илебез фермаларында ике меңгә якын рекордчы сыер бар. Алар елына җидешәр мең литр һәм аннан да күбрәк сөт бирәләр, сөтләренең майлылыгы дүрт процент, аннан да югарырак. Һәркайсыннан меңәр бозау (биш йөз үгез һәм биш йөз тана бозау) алсак, ел саен шактый көтүне яңартырга җитәчәк бит. Фикер сафлыгыннан, эшкә янача якын килүдән курыкмаска кирәк: әгәр дә инде андый нәселне икеләтә арттырырга көчебездән килә икән, хәзер яхшы терлекләрне чит ил фермаларыннан кайтарта торган булсак, киләчәктә андый малны инде үзебез сатарбыз.



**Н. Н. Әхмәтҗанов,**
КПССның Актаныш район комитетының
беренче секретаре.

# ИЛҺАМ ЧЫГАНАГЫ

Мәгърур Урал таулары итәгеннән ургылып чыккан Агыйдел, гүзәлләгеп, илһамын һәм назын сеңдереп калдырырга теләгәндәй, безнең якларга җиткәч, тагын да җәелебрәк, иркенәебрәк ага. Гасырлар, мең еллар шулай. Аның бөдрә талларга уралып утырган ярлары тугандаш татар, мари, башкорт, удмурт, чуваш һәм башка милләт халыкларының үткәненә, азатлык көрәше сәхифәләренә һәм хәзерге көннәр героикасына шаһит. Агыйделгә җырлы-моңлы Сөн килеп кушылган урында игенчелек һәм сунарчылык белән шөгыльләнүче борынгы бабаларыбызның тарихи эзләре саклана. Районыбыз халкының үткәне һәм бүгенгесе — гомумхалык тарихының аерылгысыз бер өлеше ул.

Актаныш төбәге уңдырышлы туфрагы, мул сулы елгалары, күлләре, җәелеп яткан болыннары, шаулап утырган урманнары булуга карамастан, элекке Уфа губернасының иң ярлы почмакларыннан саналган. 1850 елда, мәсәлән, губернаның күпчелек өязләрендә һәр ир кешегә өч-дүрт ат туры килсә, бездә ул берәр генә булган. Башка өязләрдә батраклар елына 40 сум хезмәт хакы алса, безнең төбәктә 15 сум гына түләгәннәр. Ир-атка тигән имана җире дә башка өязләрдәгедән дүрт тапкыр чамасы ким булуы мәгълүм.

Җир өчен, ирек өчен гасырлар буе дәвам иткән көрәштә безнең бабаларыбызның да өлешләре бар. XVII-XVIII гасырлардагы крестьян сугышларында аларның актив катнашуы билгеле. Мәсәлән, 1645, 1661-1665 нче еллардагы татар-башкорт восстаниеләрендә катнашучылар сафында хәзерге Актаныш районында яшәүчеләр дә байтак булган. Минзәлә төбәге озак еллар тынычлана алмый; патша гаскәрләренең җәзалары да, аяусыз эзәрлекләүләр дә халыкның хөрриятькә, ирекккә омтылышын сүндермәгән. Бу турыда «Татарстан АССР тарихы»нда (Казан, 1970) тәфсилләп бәян ителә.

Патша самодержавиесенең колониаль политикасы һәр җирдә үзен нык сиздергән. Рус чиновниклары А. Сергеев, М. Дохов, А. Жихарев өстеннән сенатка җибәрелгән шикаятьләрдә крестьяннарның моң-зарлары ачык чагыла.

Җәбер-золым, социаль гаделсезлек, җирсезлек Актаныш крестьяннарын Пугачев җитәкчелегендәге крестьяннар хәрәкәтенә кушылырга этәргән. Язучы һәм галим Мөхәммәт Гали, Пучы авылына килгәч, халыкның Пугачевка мәхәббәтен чагылдырган бер бәет язып алган:

Пугачев патша бар диләр,
Постау бишмәтләре тар диләр,
Җаек та буе яу җирләрен
Айкап та йөри шул диләр.
Пугачев патшаны күрсә идең,
Алларыннан буй бөгеп узса идең,
Аргамак менеп, дан тотып,
Җаек яуларында йөрсә идең.

1773 елның көзендә восстание Кама аръягына, Олы Тиганәле, Илбәк, Иске Сакчы һәм башка урыннарга җәелә. Хәрәкәтнең үзәге Минзәлә төбәгендә була. 50-300 кешелек татар отрядлары алпавыт утарларына һәм сакчылык пунктларына һөҗүм итә. Восстание Актаныш төбәген дә чолгап ала. Крестьяннар армиясе Сарсак-Омга, Аккүз, Сукман һәм башка авылларны үтеп, Алабугага киткән. Тарихчы С. Алишев «Каһарман бабайлар» дигән хезмәтендә бу хәрәкәтне киң яктырта. Актаныш ягы крестьяннары Пугачев явында аеруча күп катнаша.

Кыргыз волостеның Иске һәм Яңа Әлем авылларыннан восстаниедә утыз ике яшьлы татар катнаша. Гәрәй волостеның старшина Әтнәгул Тимеров җитәкләгән отрядта Такталачыктан — кырык бер, старшина Табыш Абдуллин командалык иткән отрядта Куян авылыннан — кырык өч, Чишмәдән — илле, старшина Үмәткул Тәфкилев отрядында Ахуннан — тугыз, Колыннан — унике, Пучыдан — йөз ундүрт, Әнәктән утыз җиде яшьлы татар булган. Балтач, Мерәс, Әҗәкүл, Богады, Әтәс, Адай, Суыксу, Ахун, Байсар, Уразай, Уръяды, Актаныш, Аккүз һәм башка авыл крестьяннары да баш күтәрүчеләр сафына кушыла.

Хаклык, азатлык өчен көрәш Октябрь революциясе һәм гражданнар сугышы елларынача дәвам иткән. Агыйдел буе, безнең як авыллары акгвардиячеләргә һәм эчке контрреволюция көчләренә каршы аяусыз көрәш мәйданына әверелә. Халык бәхете өчен көрәштә башларын салган Гыймран Мәрдәмшин, Муллаяр Назаров, Илекбай Миңнебаев, Газиз Шамматов, Рабига Фәйзуллина һәм башка бик күп якташларыбызның якты истәлеген без кадерләп саклыйбыз.

Актанышлылар күңелендә Бөек Ватан сугышының авыр яралары тирән уелып калган. Ил өчен көрәштән җиде меңнән артык ир-егет, дөнья бәһасе торырлык сылу кызларыбыз кайтмый калуын әле һаман авыр кичерәбез, аларны сагынабыз. Бөек Җиңүнең 40 еллыгын бәйрәм итү чорында авылларыбыздагы һәйкәлләрне яңарту, Актанышның биш каһарманы — Советлар Союзы Геройлары Баян Дәүләтов, Гатаулла Минаев, Хәсән Заманов, Сергей Фадеев һәм Гомәр Һадимөхәммәтовлар истәлеген мәңгеләштерү буенча күләмле эш башланды. Шундый истәлекле чорда «Гигант» колхозы эшчәннәренең Бөек Ватан сугышы елларында тылда күрсәткән героик хезмәтләре өчен Ватаныбызның югары бүләге — Беренче дәрәҗә Бөек Ватан сугышы ордены белән бүләкләнүен уртак шатлык, уртак горурлык белән кичердек. Батырлык эстафетасы бүген дә дәвам итә. 1985 ел нәтиҗәләре буенча гигантлылар Бөтенсоюз социалистик ярышында җиңеп, КПСС Үзәк Комитеты, СССР Министрлар Советы, ВЦСПС һәм ВЛКСМ Үзәк Комитетының күчмә Кызыл Байрагына лаек булдылар.

Районның 19 колхозы һәм 3 совхозы карамагында 121 377 гектар җир бар. Районда яшәүче утыз биш мең ярымнан артык кешенең уртак хәзинәсе бу. Шунысы куанычлы: җиребездән алына торган байлык елдан-ел арта бара.

Уникенче бишьеллыкка да ышанычлы аяк бастык. 1986 елда район тарихында беренче тапкыр уртача һәр гектардан егерме алтышар центнер уңыш алдык, дәүләт алдындагы изге бурычны 61 мең тонна итеп үтәдек. Шәймәрдәнов исемендәге колхоз игенчеләре һәр гектардан 31,5 центнер уңыш җыйнап, район хуҗалыклары арасында җиңүче булдылар.

Икмәк фронты батырлары: Киров исемендәге совхоз комбайнчысы Таһир Вәлиев, «Айман» совхозыннан Рафаис Замановлар республика күләмендә танылдылар. Таһир сезон дәвамында ун мең унсигез центнер ашлык суктырып алды. Бу — районда гына түгел, бөтен республикада иң югары күрсәткеч.

Район игенчеләре бәрәңге үстерү һәм дәүләткә сату буенча сизелерлек уңышларга ирештеләр. Әйтик, 1985 елда аның уртача уңышы гектардан 41 центнер булса, 1986 елда ул 142 центнер тәшкил итте. Ничә еллар буе үти алмаган бәрәңге сату планын 125 процентка үтәп чыктык, дәүләткә 6000 тонна урынына 7528 тонна яхшы сыйфатлы бәрәңге озаттык. Әлбәттә, игенчелек өчен һава шартларының башка еллардагыдан уңайрак килүен инкарь итеп булмый. Шулай да, уңышның нигезе дөрес технологиядә, тиешенчә ашлауда, һәм иң мөһиме — кешеләрнең эшкә мөнәсәбәте үзгәрүдә дип карарга кирәк.

Без игенчелектә башлангыч уңышларыбыз белән мактанудан ерак торабыз, ләкин тизләнешнең киләчәктә тагын да куанычлырак нәтиҗәләргә китерәчәгенә ышанабыз. Максатыбыз — тайпылышсыз алга бару.

Терлекчелектәге уңай үзгәрешләрне барлаган чакта бу тармакның нәтиҗәлелегенә ирешүдә иң зәлекле эшләгән коллектив — Киров исемендәге совхоз хезмәтчәннәрен аерым хөрмәт белән искә аласы килә. Кировлылар 1986 ел планын сентябрь уртасына ук барлык төр терлекчелек продуктлары сату буенча үтәп чыктылар.

«Таулар» колхозыннан Хәсинә Сафина, Рәкыя Нуретдинова, «Чишмә»дән Рәзимә Вәлиева, «Үзәк» колхозыннан Зәһинә Гәрәева, Зифа Хуҗиналар ярышның алгы сафында. Алар һәр сыердан 3500-3200әр килограмм сөт савалар. Урта мәктәптән соң өченче генә елын эшләүче оялчан, мөләем кыз Хәсинә инде шактый тәҗрибә туплаган, заманында дүрт мең килограмм чиген ясылаган, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнгән Рәкыя апасының үкчәсенә басып килә. Хәсинә кебек ялкын йөрәкле яшьләр бездә аз түгел. Нәкъ менә аларның хезмәт энтузиазмы — район буенча өч мең килограммлы дәрәҗәгә ирешү өчен төп этәргеч.

Вакыт үткән саен, өметләрнең акланачагына ышаныч арта. Башка яклардан аермалы буларак, бездә туган туфракка тугры җанлы кешеләр күбрәк кебек. Кая ташламак кирәк бу изге нигезне? Биш Советлар Союзы Героен биргән Актаныш туфрагы, дүрт Социалистик Хезмәт Героеның да (А. Сальников, С. Гыйльманов, Г. Латыйпов, З. Иманов), егермедән артык Ленин ордены кавалерларының да, фидакарь хез-

мәтләре өчен башка орден-медальләр белән бүләкләнгән йөзләрчә райондашларыбызның да туган-үскән, шөһрәт казанган газиз җире бит бу!

«Үрнәк» колхозыннан Ленин орденлы Салих Гайнуллин, «Авангард» колхозыннан шундый ук бүләккә лаек булган Әбүзәр Фазлыев кебек өлкән механизаторларыбыз үзләренә алмашка килүче яшьләргә олы ышаныч баглыйлар. Ленин ордены кавалерлары, КПСС райкомы членнары «Октябрьның 12 еллыгы» колхозыннан Хәлимә Хәнипова, Киров исемендәге совхоздан Зөлфирә Кагирова, «Коммунизмга» колхозыннан Тәхия Кашфразиева, Октябрь Революциясе һәм Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары кавалеры «Гигант» колхозы ферма мөдире Камил Латыйпов, елның-елына районда ал бирмәүче, II һәм III дәрәҗә Хезмәт Даны ордены кавалеры Антонида Пугачева, Хезмәт Кызыл Байрагы орденлы Әминә Гарипова һәм башка ветераннарыбыз яшь алмашны үз итәләр, якыннан булышалар. Туган туфракка мәхәббәт шулай тәрбияләнә. Ләкин яшьләрнең авылны үз итүе өчен барысы да эшләнгән дисәк, һич тә дөрес булмас.

Район масштабында авылны социаль үзгәртү проблемасы әле тулысынча хәл ителмәгән. Беренче чиратта авыл хуҗалыгында авыр кул хезмәтен машиналар җилкәсенә салу темпы канәгатьләнерлек түгел. Бу игенчелектә дә, терлекчелектә дә шулай. Әйтик, бәрәңге комбайннары бездә әлегә киң кулланыш тапмый. Югыйсә «Таң» колхозыннан Варис Әмирҗанов җитәкчелегендәге звено аның өстенлеген практикада раслады: 40 гектарга якын мәйданның һәр гектарыннан 200 центнердан артык уңыш алынды. Чөгендер эшләрен техника җилкәсенә салу да хәл ителеп бетмәгән. Терлекчелек фермаларын механикалаштыруны «Җиңүнең 40 еллыгы» һәм «Таң» колхозлары шәп көйләде, бу эш системалы тормышка ашырылачак.

Районның кайбер хуҗалыкларында механизаторлар өчен эш шартларын яхшырту хәл ителмәгән. Кыш көне ачык һавада машина кабызуның яки төзәтеп азаплануның авырлыгын авыл кешесе генә түгел, шәһәр кешесе дә бик яхшы күзаллый. Менә шуңа күрә дә район партия комитеты бу эшләрне уңай хәл итүне үзенең төп бурычы итеп карый.

Квартиралар төзелә тора, культура йорты, балалар комбинаты, ашханә, техник хезмәт күрсәтү объектлары — барысы да заманча. Балалар өчен йөзү бассейнын да эченә алган зур спорт комплексы төзелә. Ярдәмче хуҗалыкның «ярдәме» предприятие эшчеләре өчен генә түгел, район үзәгендәге, хәтта үзәктән читтәге авылларда яшәүчеләр өчен дә сизелә: кырлач суыгы бетәр-бетмәстә үк туй, юбилей табыннарын, ашханә, ресторан өстәлләрен яшел суган, кыяр кебек яшел ризыклар бизи, олы калалардан юллыйсы юк.

Партиябезнең XXVII съезды куйган тизләнеш бурычы кеше факторына турыдан-туры бәйләнгән. Кеше турында кайгырту җәмгыятьнең ни дәрәҗәдә алга баруын билгели. Без, моны шулай аңлаган хәлдә, бу бишьеллык дәвамында һәм 2000 елга кадәр чорда торак мәсьәләсен уңай хәл итеп бетерүне максат итеп куйдык. Авыл халкының культуралы ялын оештыру өчен, беренче карашка, бөтен мөмкинлекләр бар: һәр колхоз-совхоз үзәгендә заманча корылган культура сарайлары, кечкенә авылларның барысында да диярлек клублар төзелгән. Бүген безне шул зиннәтле культура сарайларының (бер дә арттырып әйтү түгел) күбрәк вакыт буш торуы борчый. Яныппешеп гармун уйнаучыны кыстый-кыстый, идәндәге тузанны басар өчен, су сибә-сибә, җырлы-биюле кичәләр үткәргән чорны сагынып искә алырга түгел, бәлки ул вакытлардагыдан да кызыклырак, мавыктыргычрак, сыйфатлырак чаралар табарга кирәк. Актанышның культура, сәнгать йөзен бик матур оештырылган концерт ярышлары, «Агыйдел» халык җыр һәм бию ансамбле уңышлары шактый ачык күрсәтә. Әмма, һәвәскәр сәнгатьтә тагын да күмәгрәк чыгышларга ирешү өчен, күп тырышырга кирәк әле. Даими эшләүче түгәрәкләр, кызыклы шөгыль клублары әле бармак белән генә санарлык. Халыкның ихтыяҗын өйрәнеп, без клубларда, мәктәпләрдә иҗат һәм техника түгәрәкләре оештыруны максат итеп куйдык. Йөзү бассейны, балалар өчен спорт мәктәпләре, лагерьлар төзүне якын арада хәл итәргә исәплибез.

Актаныш төбәгендә туып-үскән данлы кешеләр, талант ияләре хакында күп языла. Вакытында республика хөкүмәте башлыгы булып эшләгән Ш. Шәймәрдәновны, Ленин комсомолының Үзәк аппаратында хезмәт иткән Тимер Кручевны да актанышлылар горурланып искә алалар.

1890 елда Иске Байсар авылында туган Шәйгәрдән Шәймәрдәнов 1924 елның апреленнән Татарстан Үзәк башкарма комитеты председателе урынбасары, бер елдан соң председатель хезмәтләрен үти, 1927 елда республика Халык Комиссарлары Советына җитәкчелек итә. 1928 елдан 1930 елга кадәр — ВКП(б) Үзәк Комитетында инструктор, 1930—1933 елларда РСФСР Халык Комиссарлары Советының финанс коллегиясе члены булып эшли. Чит илләр белән сәүдә итү академиясендә укый. 1933 елны ул Тува халык республикасына илче итеп җибәрелә, анда 1938 елга кадәр эшли. Аннан соң СССРның чит илләр белән сәүдә эшләре оештыру органнарында хезмәт итә. Ш. Шәймәрдәнов — партиянең XI—XVI съездлары делегаты.

Актаныш ягы биргән талант ияләрен санап та бетереп булмый торгандыр. Бер-бер авылы гына да берничә хезмәт батырына, талант иясенә тормыш биргән. Трибун ша-

гыйрь Һади Такташның эзләрен саклаган Такталачык авылыннан татарның беренче профессиональ артистларыннан саналган трагик Мохтар Мутин, бүгенге поэзиябезнең иң җор телле шагыйре, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Гамил Афзал тормышка юл алганнар. Иске Кормаш авылы — Ардуан батырның да (Мирсәет Ардуанов), РСФСРның атказанган, ТАССРның халык художнигы скульптор Васил Маликовның да, Украина ССРның атказанган сәнгать эшлеклесе рәссам Әсгать Сәфәргалиннның да уртак туган җире. Байсар авылы — Шәйгәрдән Шәймәрдәнов, Г. Латыйповның туган туфрагы. Аның күршесендәге Наратлы авылы музыка профессоры Мансур Солтановка тормыш биргән.

Мансур Солтанов 1875 елда Наратлы авылында морза гаиләсендә туа. Мәскәү консерваториясен Зур көмеш медаль белән тәмамлый. Мәскәүнең Зур Академия театры оркестрында, соңрак Ялта шәһәренең симфоник оркестрында эшли, 1912 елдан Саратов консерваториясе профессоры дәрәҗәсенә күтәрелә. Ул гомере буе халкына хезмәт итә, туган туфрагы белән элемтәсен өзми.

Революциягә кадәрге чорда мәгариф үсеше турында сүз чыккан икән, Актаныш авылларында мәктәпләрнең шактый булганлыгын әйтергә кирәк. Наратлы һәм Пучы авылларында мәдрәсәләрдән тыш рус класслары булуы да мәгълүм, Яңа Әлемдә, Такталачык һәм башка кайбер авылларда да мәктәпләр эшләгән. Бөек Октябрьдән соң яңа этәлек алган шул ук мәктәпләр совет кешесен формалаштыру буенча зур эш башкарганнар, элекке чор мәгърифәтчеләренә алмашка килгән Илекбай Миңлебаев, Газиз Шамматов, Рабига Файзуллина кебек яңалык өчен башларын салган мөгаллимнәрнең күңел орлыклары бүген гаҗәеп мул уңыш бирәләр.

Исеме китапларга кереп калган Ардуан батыр турында, бүгенге көн геройлары Сәгыйрь Гыйльманов (ул Казанда бетончылар бригадиры булып эшли), Зөфәр Иманов турында (КамАЗда эшли), СССР Верховный Советы депутаты Рәис Хаҗиәхмәтов (Устиновта яши һәм эшли), күрше Мөслим һәм Минзәлә районнарында колхоз председательләре булып эшләүче РСФСР Верховный Советы депутаты М. Сәләхов, Социалистик Хезмәт Герое Г. Латыйпов турында, «Правда» газетасының баш редакторы, академик В. Афанасьев турында искә алу безнең күңелләрне тагын да яктырта.

Пучы, Әнәк, Айман яклары язучылар Н. Баян, Р. Ишморат, З. Мәҗитов, Р. Хисмәтуллин, Н. Гыйззәтуллин, Р. Хәлиуллина, күренекле галимнәр Г. Әхәтов, Ф. Зыятдинов һәм башка якташлары белән горурланалар. Ямалы төбәгендә яшәүче райондашларыбыз филология фәннәре докторы Леонид Арслановның һәр уңышына сөенәләр. Татар телен, аның әдәбиятын өйрәнүгә гомерен багышлаган мари егетен бездә һәркем үз итә, аның белән горурлана.

Үз туган туфрагы Актаныш турында Әлфия Афзалова кебек өздереп, күңелләрнең иң нечкә кылларын тибрәндерерлек итеп җырлаучы әлегә юк дисәм, башкалар үпкәләмәсен. «Агыйдел» буеның хәтфә болыннарында моң җыйган, бүгенге җыр сәнгатендә популярлык казанып килүче яшь җырчыбыз Газинур Фарукшин да туган төбәге моңын башкаларга юмарт өләшер дип өмет итәбез, аңа иҗади уңышлар телибез.

Дистәләрчә фән докторлары, фән кандидатлары илебезнең төрле почмакларында мәгърифәт нуры өләшәләр, сәхнә күрке саналган артистларыбыз, җырчыларыбыз әле тагын бик күпләр, Актаныш биргән илһам чыганагы бетәрлек түгел.

Әрәмәлекләр арасыннан җәелеп, Агыйдел тын гына ага да ага... Аның агышы мәңгелек булган кебек, ярларында яшәүче тынгы белмәс халкының да шөгыле мәңгелек: ул иген игә, уллар-кызлар үстерә, дөньяны төзи, үзгәртә — алга атлый.

Казан утлары
АЭС
әдәби пост

## Мөнир Әһлиуллин

# КӨРӘШ КИСКЕНЛӘШӘ

Кама Аланына килеп төшкәч тә, иң беренче эш итеп, Татарстан атом электр станциясен төзү идарәсенең баш инженеры Анатолий Дмитриевич Прохоренко ишеген шакыйм. Уртача буйлы, ябык йөзле, җитез хәрәкәтле бу кеше әдипләрне дә, журналистларны да һәрчак якты чырай белән каршы ала, кырыкмаса кырык эшен калдырып, төзелештәге яңалыклар турында дәртләнеп сөйли башлый.

Бу юлы без аның белән төнге сәгать ун тулганда гына очраша алдык. Яңарак кына бетон заводында икенче сменаның эше ничек оештырылуын тикшереп кайткан икән.

— Әйдәгез, түрдән узыгыз,— дип каршылады ул.— Күптән күрешкәнебез юк.

— Әйе, бер еллап була инде...

— Бер ел, бер ел... Уһу, ул вакыттан бирле әллә никадәр үзгәрешләр булды бит бездә!

Анатолий Дмитриевич бармакларын бөгә-бөгә санап китте.

— Хәтерегездәме, теге вакытта бетон җитмәү турында зарланган идек. Ниһаять, бетон заводы өлгерде. Металл конструкцияләр базасының беренче чираты эшли башлады. Төп корпус цехлары күтәрелә. Ә иң мөһиме — беренче энергоблокның нигезе салынды...

Аннары ул мине кабинет стенасына эленгән фоторәсемнәр янына алып килде. Япан кыр уртасында җир казучы ялгыз экскаваторны сурәтләгәненең астына «Бирегә ТатАЭСның беренче энергоблогы булачак. 1986 ел, 19 март» дигән сүзләр язылган. Энергоблокка нигез салу шулай башланган. Дүрт айдан соң рәсемгә зур стадионны хәтерләтүче нигез тирәсендә әллә ничә төрле экскаваторлар, бульдозерлар эшләве төшерелгән. Беренче блок белән машина бүлеге нигезенең озынлыгы — 200 метр, киңлеге 140 метр булачак, тирәнлеге 9 метрдан артып китә. Нигез казыганда, 500 мең кубометр туфрак чыгарылган.

— Шул кадәр туфрак алгач, бу нигез ничек су белән тулмады соң? — дип кызыксынам.

— Урынлы сорау,— дип елмайды Анатолий Дмитриевич.— Нигез казырга керешкәнче үткәрелгән тикшерү, чыннан да, җир асты суларының якын булуын күрсәтте. Шуңа да, әлеге урында берничә артезиан коесы казып, көчле насослар ярдәмендә җир асты суларын суыртып алдык.

Әйе, энергоблок урнашачак нигезне казу катлаулы да, шактый хикмәтле дә икән. Аның төбенә башта чуерташ, аның өстенә 20-30 сантиметр калынлыкта бетон җәелә. Әлеге бетон өстенә ике метр калынлыкта яңадан чуерташ салына. Чуерташ өстенә тагын бетон, ә бетон су үткәрми торган махсус полиэтилен элпә белән ябыла. Шуннан соң тагын бетон катламнары китә...

— Нәрсә мин болар турында сөйләп торам соң әле,— диде баш инженер.— Әйдәгез, шул яклардан урап кайтыйк. Ун тапкыр ишеткәнче, бер тапкыр күрүең яхшырак, диләр бит. Анда төүлек буе эш туктамый.

Без килеп җиткәндә, төнге сәгать уникеләр тула иде инде. Мәйданны көчле прожекторлар яктырта. Бер-бер артлы куәтле КамАЗлар, БелАЗлар агыла. Чуерташны 25 чакрым ераклыктагы елга портыннан ташыйлар.

— Гадәттә, сменага алты рейс ясыйбыз,— диде шофер Владимир Боблик.— Бүген, сигезәр рейс ясап, чуерташ җәюне тәгәлләргә булдык. Югыйсә, әнә арттан бетончы егетләр куа килә.

Янәшәдә генә Рәшит Кәримуллин җитәкчелегендәге бетончы егетләр эшли. Туктаусыз агым булып килгән бетонны кай арада җәеп, тигезләп өлгерәләр! Аларның җитезлегенә сокланмый мөмкин түгел. Бригада үзенә Чернобыль АЭСындагы аварияне бетерү өчен көрәшкәндә һәлак булган Советлар Союзы Герое Владимир Правикны почетлы бетончы итеп алган. Көн саен аның өчен дә норма үтиләр.

Нигезгә түшәлгән бетон өстендә калкып-калкып чыккан торбалар бар.

— Бу торбалар машина бүлекчәсендә махсус аппаратларга тоташтырыла,— дип аңлатты Анатолий Дмитриевич.— Алар нигезнең «үз-үзен тотышын» хәбәр итеп торачаклар. Атом электр станцияләре төзелешендәге яңалык бу. Энергоблок урнашачак нигезнең нык булуын тәэмин итүче бик мөһим чара.

Яшерен-батырын түгел, Чернобыльдәге авария кебек хәлләр Татарстан АЭСында килеп чыкмасмы, дигән сүзләрне ишеткәләргә туры килә. Баш инженерга шул турыда әйткән идем.

— Борчылырга һич тә урын юк,— диде ул.— Чернобыльдәге аварияне̦ң төп сәбәбе кайбер кешеләрнең чиктән тыш, хәтта җинаятьчел җавапсызлыгы дияр идем мин.

Чернобыльдәге фаҗигане Кама Аланы төзүчеләре йөрәкләренә аеруча якын кабул иттеләр. Зыян күрүчеләргә ярдәм фондына ун меңнәрчә сум акча күчерелде. Ә инде Украинадан сигез гаилә килеп төшкәч, аларны ачык йөз белән каршы алдылар, бөтен мөлкәте кечкенә бер чемоданга сыйган бу гаиләләргә менә дигән квартиралар, мебель, төсле телевизорлар бирелде. Хәзер алар Татарстан атом электр станциясен коручылар белән иңгә-иң торып эшлиләр.

Мәгълүм булганча, Кама Аланындагы төзелеш ике юнәлештә бара. Беренчесе — поселоктан шактый ераклыктагы АЭС корылмалары. Икенчесе — энергетиклар яшәячәк шәһәр. Урал һәм Идел буендагы эре промышленность комплексларына хезмәт күрсәтәчәк бу станциянең куәте 6 миллион киловатт-сәгать булачак. Дөньяда әлегә андый куәтле станцияләр юк. Татарстан атом электр станциясе һәр яктан уникаль һәм камилләштерелгән беренче станция булачак. Беренче энергоблок 1989 елда файдалануга тапшырылырга тиеш. Ләкин төзүчеләр тагын да ераккарак карап эшлиләр. КамАЗ корпусларын коруда чыныгу үткән, ике тапкыр Ленин ордены белән бүләкләнгән Умат Наурбиев җитәкчелегендәге бригада инде икенче, өченче, дүртенче энергоблокларның нигезен әзерли.

Яңа шәһәр исә дүрт микрорайоннан тора. Промышленность зонасы белән шәһәр арасында троллейбус йөриячәк. Заманча җиһазландырылган шифаханә, 800 урынга исәпләнгән ике заллы кинотеатр, ябык йөзү бассейны, 5 мең урынлы стадион һәм спорт комплексы төзеләчәк. Зур парк булдыру күздә тотыла. Ерак та түгел су спорты комплексы һәм елга порты үсеп чыгачак.

Кама Аланына һәр килүдә нинди дә булса яңалыкка тап буласың. Әле кайчан гына балалар ике катлы кысан бинада укып йөри иде. Үткән ел исә мең ярым укучыга исәпләнгән менә дигән мәктәп үсеп чыкты. Өч балалар бакчасы, кибетләр, ашханәләр өлгерде. Хәтта мунчасы турында да онытмадылар төзүчеләр.

Шулай да поселокны төзүдә бар да ал да гөл дип әйтеп булмый әле. Үткән бишьеллыкта 111,9 мең квадрат метр торак файдалануга тапшырылырга тиеш иде. Аның нибары 87,5 мең метры сафка басты. Сәүдә йорты, больница, кинотеатр кору да әлегә бик сүлпән бара. «Казан утлары» журналының әдәби посты члены буларак, шул хәлләр белән кызыксынуны да зарур санадым. Сәүдә үзәге бинасы төзелешенә иртәнге сәгать уннарда килдек. Безне сәер тынлык каршылады. Манаралы кран туктап калган, кирпеч өемнәре янында бер генә җан иясе дә күренми.

— Ташчылар вагонда булса кирәк. Күренеп тора, эшкә керешмәгәннәр дә әле,— диде юлдашым, төзүче инженер А. Михайлов.

Вагон ишеген ачабыз. Чыннан да, бер төркем ир-ат җылы вагонда тәмәке көйрәтә. Танышабыз. Брежневтагы 52 нче төзү-монтаж идарәсе ташчылары икән. Атналап эшлиләр. Бер атнадан соң Брежневка кайталар. Барысы да югары разрядлы. Тик еш кына кул кушырып утырырга мәҗбүрләр. Звено җитәкчесе Сергей Свиридов күңеленә күптәннән җыелганны әйтеп салды:

— Без монда гаиләләребездән аерылып, эшләргә, төзергә дип киләбез. Алып киләләр, кайтарып куялар, командировка өчен акча түлиләр. Һәр көн диярлек шулай эшсез утырырга туры килә. Смена башланганга өч сәгать үтте инде, әле һаман измә китереп җиткерә алганнары юк.

Поселокта яшәүчеләргә сәүдә үзәге бик кирәк. Шушы бинада ук кичке кафе, көнкүреш йорты, кунакханә дә булачак. Үткән ел аны файдалануга тапшырырга тиешләр иде. Әлегә беренче каты да күтәрелмәгән. Кызганычка каршы, шундый «сакаллы төзелешләр» яшь поселокта инде күбәеп бара.

Торак, социаль-культура объектлары төзүдә нигә шулай артта кала башладылар соң әле Кама Аланында? Югыйсә, биредә торак төзүне куәтле оешма — Брежнев

шәһәрендәге йортлар төзү комбинаты алып бара. Шул турыда комбинат директоры М. Ш. Бибишев белән сөйләшәбез.

— Билгеләнгән планнарны материаль ресурслар белән тәэмин итү начар барды,— диде ул.— Менә үткән ел Кама Аланында 38 мең квадрат метр торак йорт төзү планлаштырылган иде. Соңыннан исә материаль ресурслар белән тәэмин итүне искә алмыйча гына, бу санны, 62 мең квадрат метрга җиткерделәр. Бер елда гына 70 мең кубометр деталь биреп җиткерелмәде. Шуңа да беренчел планны үтәү белән чикләндек.

Төзүчеләр белән сөйләшкәндә, гаять каршылыклы бер мәсьәлә ачылды: Кама Аланына материаллар Брежнев шәһәрендәге тимер-бетон әйберләр заводыннан китерелә. Төзүчеләр үзләре дә — Брежневтан. Шул ук әйберләрне Түбән Камадагы «Татэнергострой» берләшмәсендә дә ясыйлар. Андагы завод Кама Аланына ике тапкыр якынрак. Димәк, материалларны Түбән Камадан алу шактый арзанга төшә. Ләкин бу мәсьәләне хәл итүдә ике зур оешма бер-берсе белән килешә алмый. «Кама Аланын без төзибез икән, димәк, материаллары да безнеке булырга тиеш»,— диләр «Камгэсэнергострой» җитәкчеләре. Шулай итеп, көн саен уннарча КамАЗлар, БелАЗлар, тимер-бетон әйберләр төяп, Түбән Кама заводы капкасы янында Кама Аланына агыла тора. Шул ук вакытта Түбән Камадагы заводтан Брежнев аша кире якка — Менделеевскига һәм башка төзелешләргә шундый ук материаллар озатыла. Һәрхәлдә бу мәсьәләне партия, совет һәм хуҗалык органнарына уртага салып сөйләшергә, бер үк төрдәге тимер-бетон әйберләрне кара-каршы ташуга чик куярга кирәк иде.

Булачак энергетиклар шәһәренең архитектурасын да камил дип әйтеп булмый әле. Ул хәзер поселок тибында төзелә. Балалар мәйданчыклары, балалар бакчалары өчен урыннар юк диярлек. ТатАЭС директоры белән әңгәмәбез шәһәрнең бүгенге йөзенә, киләчәгенә барып тоташты.

— Шәһәрнең архитектурасы безне дә тулысынча канәгатьләндерми,— диде ул.— Күптән түгел проект мәсьәләләре буенча Мәскәүнең Тимирязев район партия комитетына мөрәҗәгать иттек. Анда проектлау институты вәкилләре катнашында киңәшмә үткәрелде. Моңарчы да алар белән хатлар язышкан идек. Нәтиҗәсе уңай булыр дип уйлыйбыз. Һәрхәлдә озакламый институт вәкилләре Кама Аланына киләчәк һәм алар белән бергәләп шәһәрнең проектын камилләштерү мәсьәләләрен тикшерәчәкбез.

Әйе, энергетикларның үзләре яшисе шәһәрне заманча, матур һәм уңайлы итеп күрәселәре килә. АЭС дирекциясенә алардан күп кенә хатлар да килеп тора. Балта остасы А. А. Поляков Кама Аланы капкасына кую өчен берничә макет ясаган. Инженер И. Х. Хафизов шәһәрдә алкогольсез эчемлекләр заводы салуның кирәклеген исбатлый. «Завод якын-тирәдәге шәһәрләрне һәм авылларны төрле сулар һәм соклар белән тәэмин итәр, хатын-кызларга эш урыны булдыруда ярдәм итәр иде»,— дип саный.

Поселок Советы башкарма комитеты председателе Р. Г. Рәхимовны борчый торган мәсьәләләр дә күп. Халыкка сәүдә, көнкүреш, медицина хезмәте күрсәтү мәсьәләләре белән беррәттән, аларның культуралы ялын оештыру, рухи азык бирүне яхшырту турында да уйлана:

— Моннан ике ел элек республиканың культура министрлыгы АЭС төзүчеләргә культура хезмәте күрсәтү планы төзегән иде. Ләкин аннан соң берниндн үзгәреш булмады.

Әлеге дәгъваны без ТАССР культура министры М. М. Таишевка җиткердек.

— Әйе, без бүген Кама Аланында яшәүчеләрнең культура ихтыяҗларын тулысынча канәгатьләндерә алмыйбыз әле,— диде ул.— Моның төп сәбәбе — тиешле мәйдан юк. Киләчәктә, концерт залы булган кинотеатр файдалануга тапшырылгач, АЭС төзүчеләренә культура хезмәте күрсәтүне яхшыртырга мөмкинлек туачак. Художниклар, язучылар һәм башка иҗат союзлары белән дә шефлык элемтәләре урнаштырылачак.

Юк, бу аңлатма белән килешеп үк бетәсе килми. Әлбәттә, төзелеш мәйданнарында ясалган гади сәхнәләргә караганда зур культура сарайларында спектакльләр, төрле ансамбльләр чыгышын карау күңеллерәк. Ләкин республика сәхнә осталарының эшчеләр һәм төзүчеләр, нефтьчеләр белән иҗади дуслык элемтәләренең бай традицияләре бар бит. Без язучыларның, сәхнә осталарының КамАЗ төзелешендәге җылы очрашуларын яхшы хәтерлибез. Нигә бу тәҗрибәне ТатАЭС төзелешендә дә кулланмаска?!

Кыскасы, төзелеш үсә барган саен, аңа комачаулаучы четерекле мәсьәләләр тагын да калкурак булып күренә. Әмма чигенер урын юк. Алар кичекмәстән тикшерелергә, бетерелергә тиеш. Төзүчеләрнең дә, энергетикларның да теләге шундый.

## Флүс Латыйпов

# АЛДАНУ

Уйларыннан аны телефон чыңлавы бүлде.

— Өлкән тикшерүче Закиров тыңлый.

— «Өлкән прокурор»ың шылтырата әле...

Телефоннан хатыны Равиянең шаярып эндәшкәне ишетелде.

— Кайтасыңмы инде, юкмы,— дип дәвам итте ул.— Әнә Илдус та, «әттә, әттә» дип, трубкага үрелә.

Телефоннан дүрт яшьлек улының яңгыравык тавышын ишеткәч, дөньядагы бөтен мәшәкатьләрне онытып җибәрде әти кеше.

— Әттә, кайт!

— Хәзер, хәзер, улым! Инде киенә башладым,— диде Сәлим Закиров. Ашыгып, өстәлдәге кәгазьләрне җыеп, сейфка бикләде, сәгатькә күз төшерде.— Оһо, инде сигез тулып килә икән ләбаса.

Урамга чыкты да трамвай тукталышына таба китеп барды. Күңелендә исә бүгенге очрашу, сөйләшү яңарды. Әйе, ничек кенә борсаң да, кайсы ягыннан карасаң да, әхлак һәм хокук тәртибен әйләнеп узарга маташу яхшылыкка илтми. Ләкин, кызганычка каршы, әле һаман да шуны аңламаучылар белән эш итәргә туры килә. Аларча барысы да җиңел, үтә гади: барлык льготаларга һәм ташламаларга, дәрәҗәгә һәм байлыкка ирешеп була, тик моның өчен дус-иш, таныш-белеш, кода-кодагыйлар гына кирәк... Кемгәдер итәк астыннан акча төртергә дә, законсыз юл белән үз эшләрен җайларга да тайчанып тормыйлар. һәм еш кына әнә шундыйлар беренче очраган ришвәтче, алдакчы яки мошенникның корбанына әйләнәләр. Баксаң, акчаларыннан да, намусларыннан да колак какканнар икән. Менә шул вакытта инде закон, гадел хөкем органнары, милиция, прокуратура искә төшә. Суд юлларын таптау башлана.

Бүгенге эштә дә шундый ситуация түгелмени? Эчтән генә Валентина Андреева белән Мария Григорьеваларны кызганып куйды ул. Беркатлылыклары, теләсә кемгә җиңел ышанулары аркасында нинди аферистканың корбанына әйләнгәннәр! Бер карасаң, үзләре гаепле. Үзләре юллап тапкан каза. Икенче яктан карасаң, бернәрсәдән тайчанмый торган бу кешенең тагын әллә кемнәрне үз кармагына эләктерүе мөмкин. Эшне никадәр кызу тотсаң, алданучылар да шул кадәр кими төшәр.

Өенә кайтып җиткәнче, шул вакыйганы яңадан күз алдыннан кичерде Сәлим. Мәктәп дәфтәреннән ертып алынган кәгазь битенә вак хәрефләр белән тигезле-тигезсез язылган ике гаризаны кабат күргәндәй булды.

«Казан шәһәренең Ленин районы эчке эшләр бүлеге начальнигына гражданка Валентина Александровна Андреевадан гариза.

Сездән Таня исемле кызны эзләп табуыгызны һәм җинаять җаваплылыгына тартуыгызны үтенәм. 1985 елның июненнән сентябренә кадәр алдау юлы белән ул миннән мең бер йөз алтмыш биш сум акча һәм алтын балдагымны алды».

Икенче гариза Валентинаның әнисе Мария Григорьевадан. Әлеге кыз алардан да ике мең алты йөз егерме сум акча алган.

Җинаятьчене каян табарга? Казандамы ул, әллә, акча җыеп, башка якларга ук чыгып китәргә өлгергәнме? Барлык версияләрне дә берәм-берәм тикшерергә, эзләүгә участок инспекторларын һәм җәмәгатьчелек вәкилләрен дә тартырга кирәк булыр. Күңеленә шуларны беркетеп куйды.

Өметләре өзелгән ана белән кызның сөйләүләреннән аңлашылганча, эш болай тора...

* * *

Күзләрен зур ачып, врачка текәлгән кызына караган саен, Валентинаның йөрәге сулкылдап-сулкылдап куйгандай була. Их, үз сәламәтлекләреңне биреп терелтеп булсын

иде! Юк шул! Юк. Андый мөмкинлек бирелмәгән. Бөтен өмет, ышаныч менә шушы ак халатлы кешеләрдә. Нинди сүзләр, нинди ялварулар белән аларны игътибарлырак булырга, кулларыннан килгәннең бөтенесен дә эшләргә мәҗбүр итәргә?! Врачлар нәрсәнедер яшерәләр, нәрсәнедер әйтеп җиткермиләр кебек тоела Валентинага.

Доктор авыру тарихына тагын бер-ике юл язып куйды да янында гасабиланып утырган анага карады. Басынкы тавыш белән:

— Кызың чыгып торсын. Ял итсен,— диде.

Кызчык чыгып киткәч, бераз тын гына утырды. Сүзен башлап җибәрергә кыенсына шикелле иде ул. Күзлеген салып, кулъяулыгы белән күз кырыйларын сөртте һәм салмак кына сөйләп китте.

— Бәлки мин ялгыша да торганмындыр, Валентина Александровна. Өздереп әйтүе кыен... Белгечләргә күрсәтеп карагыз әле. Анда бик яхшы врачлар эшли. Кулларыннан килгән бөтен ярдәмне күрсәтерләр. Тик өметегезне генә өзмәгез.

— Нинди белгечләргә, кая алып барырга?..

— Мин монда кәгазьгә яздым аны. Шәһәр онкология диспансерына күренергә кирәк булыр...

Валентинаның эчендә нидер өзелеп киткәндәй булды. Битен каплап, тавышсыз гына еларга кереште.

— Шулай ук анда барырга кирәкмени? Терелтеп булмас микәнни?!

Врач — ананың хәлен яхшы аңлый иде. Әйе, мондый вакытта кешене юату, тынычландыру авыр. Ләкин ни хәл итмәк кирәк? Кызганыч булса да, чын дөреслекне әйтми мөмкин түгел.

— Сез артык борчылмагыз,— дип юатырга кереште ул. Хәзер медицина көчле, яңа дарулар күп. Аннан соң бит әле минем ялгышуым да ихтимал...

Барысы да шуннан башланды бугай. Кремль янындагы таш җәелгән юлдан үтеп, онкология диспансерына керүе дә, кызын врачларның ничек караулары да — барысы да яман төш кебек кенә хәтерендә калган. Больницадан чыккач та ул үз-үзен кая куярга белмичә, кая барганын аңламыйча, борынгы урамнардан атлады. Күңелен һаман шик корты кимерә. Врачлар нигәдер кызчыгына салкынрак караган кебек тоела. Әллә нинди анализлар дип, уйларга, тикшерергә дип җанын кыйныйлар. Өздереп кенә әйтеп булмый микәнни соң? «Терeләчәк. Моның өчен фәлән-фәлән нәрсәләр кирәк»,— дисеннәр иде. Аларны җир тишегеннән булса да табарга тырышыр иде Валентина. Ә болай күпме көтәсе, күпме өзгәләнәсе... Анализлары нинди була бит әле...

Үз-үзен белештермичә, күп йөрде ул. Телестудия тукталышы янына килеп чыгуын да абайламый калган икән. Урамда ниндидер таныш йөзне күргәч кенә аңына килгәндәй булды.

«Тукта, тукта! Шул диспансерның поликлиникасында утырган кыз түгелме соң бу? Регистратурада кәгазьләрне кабул итеп алды, кайсы бүлмәләргә керергә кирәклеген аңлатты.»

Валентина тиз генә бер карарга килеп, таныш кызга таба атлады. Туп-туры үзенә юнәлгән ханымны күреп, анысы да туктап калды.

— Гафу итегез, ялгышмасам, сез онкология диспансерында эшлисез бугай. Әйеме?

Куе чәчләрен каштан төсенә буяткан, каш-керфекләрен каралткан кыз, сәерсенеп, таныр-танымас тоелган бу ханымга текәлде.

— Тыңлыйм.

— Минем кызымны сезгә салдылар.

— Ә, әйе, әйе, хәтерлим. Бүген килгән идегез бугай.

Валентина еларга җитешеп дәвам итте.

— Берәр чарасы бардыр ич аның? Мәскәүдә бик авыр хасталарны да терелтәләр дип ишеткән идем. Әйтегез әле, зинһар, шул дөресме? Бер нәрсәмне дә кызганмас идем. Исемегезне дә белмим, ичмасам...

Кыз Валентинага кызыксынып карап алды, шактый озак уйланып торды.

— Таня мин. Ә Мәскәүдә терелтүләре хак. Тик...

— Ни булса да, зинһар, әйтегез. Мин барысына да риза.

Таняның эскәкләп нечкәртелгән кара кашлары, дугаланып, өскә күтәрелде. Зур бер сер әйткәндәй, Валентинага таба иелеп, ярым пышылдап сөйли башлады.

— Була, моны эшләп була. Ләкин болай гына түгел. Аңлыйсызмы, әшнәсез генә ерып чыга торган нәрсә түгел. Акча да шактый кирәк... Андагы чиратны шунсыз үтеп булмый... Әйе, зур акча!

— Таня, бәгырькәем, соң Сезнең берәр шундый танышыгыз юкмы? Әйтәм ич, бернәрсә дә җәлләмәячәкмен.

— Бәхетегез бар. Берничә көн элек кенә Мәскәүдән бер олы белгеч килгән иде. Ул хәзер дә Казанда әле. Сөйләшеп карармын. Әйдәгез, болай итик: Сез иртәгә кичкә минем квартирага килерсез. Мәскәү кешесен дә шул чакка чакырырмын. Минем бик яхшы танышым ул, дустым диярга да була.

Валяны тагын башыннан аягына кадәр карап алды да Таня бәяне атады.

— Үзегез белән бер мең сум алып килерсез. Алар күбрәк тә ала әле. Мин инде, Сезне кызганып кына, шулай кимрәккә дә ризалаштырырга тырышырмын. Килештекме? Хәер, бөтенесен дә үзегез сөйләшерсез...

Валентинаның өстеннән тау төште диярсең. Бу кадәр акчаны каян табачагын әле башына китермәсә дә, берсүзсез риза булды.

— Ай, ничек кенә рәхмәт әйтергә дә белмим инде. Әлбәттә килермен. Бары тик терелсен генә иде,— дип кабатлады ул Таняның кулын кыса-кыса.

Ашыга-ашыга, яңа танышының адресын язып алды. Җилкәсенә канатлар үсеп чыккандай җиңеллек белән өенә йөгерде.

Җир астыннан булса да иртәгесе кичкә кадәр бер мең сум акча җыярга кирәк. Әле тормышларын корып кына килә торган яшь гаилә бу хәтле акчаны каян алсын?

Валентина вак-төяккә тотарга дип куелган өчлек-бишлекләрне сумкасына сыпырып төшерде, саклык кенәгәсеннән соңгы акчаларын алды. Нибарысы дүрт йөз сум җыелды. Инде нишләргә? Әнисе бар бит әле аның. Онытты өчен җанын ярып бирергә әзер булган әби кеше ярдәм итми калырмыни?! Валя, ике дә уйлап тормый, автовокзалга йөгерде.

Эчтән генә врачларның шундый сумма соравына әрнеп, үртәлеп тә куйды үзе. Кеше фаҗигасыннан, аларның чарасызлыгыннан файда эзләүләренә эче пошты. Димәк, шунсыз булмый торгандыр инде. Әнә бит Таня да сезнең хакка гына мең сумга ризалашырга тырышырмын дип тора. Башкалардан әле күбрәк тә каера торганнардыр.

Лаеш районындагы авылларның берсендә яшәүче әнисе Мария Ивановна кызының ашыга-кабалана сөйләгән сүзләреннән бер нәрсәне генә ачык аңлады — яраткан онытына куркыныч яный.

Сөйләшү-аңлашу озакка бармады. Мария Ивановна өйдә булган барлык акчаларны җыеп, яулыкка төйнәде.

Икенче көнне иртән үк Казанга юл тоттылар.

Никадәр генә ашыкмасыннар, билгеләнгән сәгатькә килеп өлгерә алмадылар. Ибраһимов проспектындагы күп катлы йорт янына килеп җиткәндә, инде кичке җиделәр тирәсе иде. Кесәсендәге кәгазьдән квартира номерын карап, түземсезлек белән ишек катына килеп бастылар. Аларны Таня үзе каршы алды.

— Соңлабрак килдегез,— дип каршы алды ул аларны.— Мәскәү кешесе китеп утырдыутырды да китте. Андый кешеләрнең һәр сәгате исәптә.

— Хәзер нишлик инде? — дип, нәүмизләнеп сорады Валя.

— Акча алып килдегезме соң?

— Әйе, әйе,— дияргә ашыкты Валя, сумкасыннан газета кәгазенә яхшылап төйнәлгән төргәкне чыгара-чыгара.

— Алай булгач, барысы да җайланыр.

Таня кунакларны кухняга чакырды. Плитәгә чәйнек куеп җибәрде, өстәлгә чынаяклар тезә башлады.

— Безнең акча мең сумга ук тулмады әле,— дип, кыенсынып, өзелгән әңгәмәне ялгап җибәрде Валя.— Менә монда сигез йөз сум. Җитмәгәненә бәлки бу ярар...

Ул сул кулының атсыз бармагыннан якут кашлы калын алтын йөзекне салып Таняга сузды.

— Ике йөз илле тәңкәлек!..

Таня, йөзекне алып, аның ташын яктыга тотып берничә мәртәбә әйләндереп карады, бармагына киде. Йөзенә йөгергән алсулыктан, күзләрендә кабынган балкыштан аңа йөзекнең бик ошаганы күренеп тора иде. Салып, акчалар янына төргәккә куйгач, хуҗабикә квартираны күрсәтә башлады. Өсте ябулы урындыклар, диваннарга ымлап куйды.

— Чит кеше өендәге шикелле йөргәнгә гаҗәпләнмәгез. Хәзер монда юньләп торырга да туры килми. Кияүгә чыгам бит. Мәшәкатьле вакыт, күбрәк ирем янында булам. Бу квартираны калдыру кызганыч булса да, кемгәдер сатарга туры киләчәк,— дип көрсенде ул.

Ана белән кыз бер-берсенә карашып алдылар. Нинди бәхетле көн бу! Моңа кадәр ут йотып йөргән бөтен кайгы-мәшәкатьләрне бер селтәнүдә юкка чыгарабызмы соң инде әллә. Таня кухняга кереп китүгә, икесе дә бер үк сүзне әйтүләрен сизми дә калдылар.

— Күпмегә сата икән?

— Күпмегә булса да, безнең Викторга ярап куяр иде бу. Ничәнче ел инде тулай торакта изалана бит,— дип куйды әнисе, улын күздә тотып.

— Мин дә шул турыда уйлаган идем,— дип җөпләде Валя.— Кылын тартып карыйк әле. Бәлки ул сораган сумманы ничек тә җыя алырбыз. Аннан соң мондый җай кайчан чыга әле ул...

Чәй янында барысы да ачыкланды. Ике мең биш йөз тәңкәгә кул суктылар. Моның өчен башта Викторның гаиләсен пропискага кертергә кирәк икән. Аннан соң, Таня күчеп киткәч, квартирага законлы төстә алар хуҗа булып калачак.

Икенче көнне Таня инде үзе Андреевaларга килде. Әнисенең гомер буе берәр сумлап, үз авызыннан өзеп җыйган акчалары, шуңа өстәп малае Викторныкы — җәмгысы ике мең таңкә тагын Таня сумкасына күчте.

Бу юлы да үзенең киң күңеллелеге белән «шаккатырды» аларны Таня.

Мария Ивановна биргән акчалардан дүрт йөз сумны санап алып, Валяга сузды.

— Кызыгыз өчен дип биргәндә, яртысын кешедән алып тордым дип зарланган идегез. Шул бурычыгызны түләрсез...

— Ә Мәскәү кешесенә?..— дип кенә сорый алды Валя.

— Анысы өчен борчылмагыз. Үз кешеләр бит. Ничек тә аңлашырбыз әле,— дип елмайды Таня.

— Прописка артыннан кем йөрер икән,— дип сүзгә кушылган Мария Ивановнага да җавап тиз табылды.

— Анысы авыр эш түгел аның. Тәртибен дә белеп бетермәссез, паспортларын, документларын миңа бирсәгез, шул җитеп торыр...

Боларны күз алдыннан кичергәч, Сәлим кешеләрнең шул кадәр дә ышанучан булуына көлемсерәү катыш уфтанып куйды. Таняның астыртын оятсызлыгы да, аналы-кызлы Андреева белән Григорьеваның җиңел акыллылыгы да бернинди киртәгә, аек акыл белән уйлап хәл итеп торган эшкә охшамаган иде. Әйе, теләсә кемне алдарлык әрсез мошенниклар да, үзләрен алдатырга һәм алданырга юл куя торган, кем әйтмешли, беркатлы кешеләр дә очрый шул. Нәрсә бу? Кешеләрдә юридик белем җитмәүме, әллә, ришвәт биреп, кемгәдер акча төртеп, барысын да җайлап була дигән ышанумы?!

Төрле коллективлардагы очрашуларда катнашканы бар аның. Гадәттә ничек була?... Юристның чыгышын ярым-йорты кызыксыну белән тыңлыйлар да тизрәк китү ягын карыйлар. Әллә кешеләрне кызыксындырырлык итеп сөйли белмибезме, әллә инде көндәлек мәшәкать, агымдагы эш белән закон һәм хокук, әхлак һәм тәртип, җинаять һәм җаваплылык турында пропаганданы онытып җибәргәнбезме? Һәрхәлдә кешеләрдәге ваемсызлыкны, битарафлыкны бетерү юлларын эзләргә кирәк. Әгәр кешеләр закон белән яхшырак танышса, мондый алданулар да кимрәк булыр иде. Алдарга теләүчеләр дә ул кадәр узынмас иде.

Берьюлы диярлек өч мең сумлап акча һәм алтын йөзек калдырып та, ул кызның ни фамилиясен белмиләр, ни кулларында расписка-фәлән дә юк. Җитмәсә, документларын да биреп җибәргәннәр.

Аптырап, башын чайкап куйды Сәлим. Вакыйгаларның алга таба үсеше дә, мавыгулы кинофильмнардагыча, бер караганда, үтә гади, икенче караганда, буталчык һәм аңлаешсыз иде.

...Көннәр артыннан көннәр үтә торды. Әллә нинди бәхет вәгъдә иткән, менә-менә ниндидер үзгәрешләр булыр сыман тоелган исерткеч мизгелләр иде алар Валентина белән Мария Ивановна өчен. Кояшлы җәйнең ямен дә, җылы көннәрнең тәмен дә сизми калдылар алар. Бөтен уй-фикерләре, максат-мәсләкләре бер генә нәрсәгә — ничек кенә булса да тизрәк Мәскәүгә баруга, акчаларны түләп бетереп, квартирлы булуга юнәлгән иде. Аларга изгелек арты изгелек кылып торган Таня гына нишләптер ашыкмады. Юкса, инде акчаларны тулысынча түләнеп тә бетте. Вәгъдә ителгән эшләр генә үтәлми. Сылтау арты сылтау табылып тора. Я Мәскәүдәге таныш кандыр командировкага киткән, я үзенең барырга вакыты юк. Пропискага кертергә, «самолетка билет алырга» дип, паспортларны кулдан-кулга тапшырганга да күпме вакыт үтте.

Ишектә кыңгырау шылтырауга кәтә-кәтә көтек булып беткән Валентина дерт итеп куя. Таня килгәндер кебек тоела. Әмма юк. Я күршеләрдән кем дә булса берәү, я әнисе килеп җиткән була.

Озакка сузылган билгесезлек көннән-көн ныграк изә, баса башлады. Киеренкелектән, бу чарасызлыктан котылу юлы бер генә — тизрәк Таняны күрергә дә аңлашырга!

Бүтән түзәр чарасы калмагач, Валентина Андреева бөтен бер көнен Таня белән очрашуга багышларга булды. Үзе эшли торган тегү фабрикасыннан ял сорап алды, авылдан әнисен чакыртты. Тәгаен туры китерү өчен, иртән үк Таняның хезмәт урынына — онкология диспансерының поликлиникасына киттеләр.

«Регистратура» дип язылган пыяла барьер артында бөтенләй башка, таныш булмаган хатын утыра иде.

— Әллә Таня бүген ял итәме? — дип сүз кушты Валя.

— Нинди Таня?

— Монда, регистратурада эшли...

— Андый кешене белмим. Күрәсез ич, мин эшлим,— дип җавап кайтарды әлеге ханым, кәгазьләреннән башын да күтәрмичә.

— Без документларны аңа тапшырган идек...

— Кайчан?

— Июнь азакларында булыр.

— Алай булса табарбыз. Фамилиягез ничек?

— Сез аңлап житкермәдегез бугай. Безгә документ түгел, Таня үзе кирәк иде.

— Июльдән бирле эшлим инде. Таняны күргәнем юк,— дип, ниһаять, күтәрелеп карады ханым.— Ялгышмасам, ул миңа кадәр эшләгән булырга тиеш.

Валя белән Мария Ивановна бер-берсенә карашып алдылар.

— Аны кайдан табып була соң?

Регистратор, «бернәрсә дә белмим» дигәнне аңлатып, иңсәсен генә җыерып куйды. Артта, чиратта торучылар шаулаша башлады. Валя белән Мария Ивановна, танышларының инде монда эшләмәвен ачыклаудан башка берни дә белә алмыйча, чыгып китәргә мәҗбүр булдылар.

Ибраһимов проспектындагы йортка бару да өметне акламады. Бикле ишекләр, ябык квартира. Хәер, яңа гына кияүгә чыккан кешенең өйдә тормавы да гаҗәп түгел. Яңа гаилә, яңа шартлар... Барысы да син теләгәнчә генә бармыйдыр. Хәлне шулай үзләренчә аңладылар Валя белән Мария Ивановна. Бәхетләренә, ир булачак кешенең төгәл адресын ук белмәсәләр дә, Таня элеккеге сөйләшүләренең берсендә аның кай тирәдәрәк торганын әйткән иде. Һич югы шул тирәдә йөреп торырбыз. Җан биргәнгә юнь биргән ди бит. Бәлкем әле үзе дә очрап куяр дигән ышаныч белән эзләүләрен шул якта дәвам иттерергә булдылар.

Иртәдән бирле аяусыз кыздырган кояш астында ничә сәгать йөргәннәрдер, анысы хәтерләрендә калмаган. Инде булмады дип, өметләрен өзәргә торганда, бәхетләре басты. Урам чатындагы киоскыны ничәнче кат әйләнеп узулары булгандыр, каршыларына Таня үзе килеп чыкты.

— Һай, күптән күрешкән юк! Эш артыннан эш чыгып кына тора. Инде, эзләп, үзем барырга җыенып тора идем,— дип, аларны очратуына сөенгәндәй сөйләнеп китте ул.

— Бигрәк озакка сузылды бит. Ни отпускыга китә алмыйбыз, ни фатирны хәл итеп бетермәгән. Галяны Мәскәү больницасына салабыз дидең, анысы да юк,— дип, үртәлеп, ачынып сөйли башлаган ананы бик тиз туктатты Таня.

— Мондый мәшәкатьне бер көндә генә ерып чыгып буламыни? — дип сорауга сорау белән җавап кайтарды ул.— Боларның берсе дә шәхсән миңа кирәкми ләбаса. Үзегез сорап килдегез, ялынып, артымнан йөрдегез.

Тавышсыз-тынсыз калган ана белән кызның гаҗәпләнү катыш сәерсенеп карауларыннан, үзенең тиешле тонны дөрес сайлап алуын аңлады бугай, тагын да ярсый төшеп дәвам итте.

— Әллә мине берәр аферистка дип беләсезме? Миңа калса, акчагызны кире кайтарам да бирәм. Җаным тыныч булыр, артымнан эзләп йөрүче калмас, ичмасам.

— Соң без аптыраганнан бит, Танечка,— дип, уңайсыз хәлдән чыгарга ашыкты Мария Ивановна.— Шул балага караган саен, йөрәгем парә-парә телгәләнә. Син гафу ит... инде... Безгә акчасы да түгел, баланың терелүе кирәк бит. Ярдәмеңнән ташлама инде...

— Ярый алайса,— дип йомшады Таня.— Үзегез әйтмешли, шул бала хакына гына. Мин бүген үк Мәскәү поездына билет алам. Сез иртәгә кич нәкъ сигезгә тимер юл вокзалына җыенып төшәрсез. Килештекме!

— Килештек!

— Тик минем кесә такыррак чак. Туй чыгымы, тегесе-бусы... Билетка, юлга... йөз егерме сумлап кирәк булыр...

Көне буе тинтерәп йөргән, аптыраудан тәмам гаҗиз булган Мария Ивановна калтыранган куллары белән кульяулыкка чияләп бәйләгән төенчеген чишә алмый азапланды.

— Ярый, хәере белән булсын!

Кичен вокзалга төшкән Андреевлар гаиләсе, түземсезләнеп, Таняны көтте. Билет кассалары, белешмәләр бюросы янынан кат-кат уздылар. Трамвай-троллейбус тукталышларын урадылар. Әмма Таня күренмәде. Тымызык кичтә моңсу гудогын яңгыратып, «Татарстан» поезды Казан белән хушлашты. Ә көткән кеше юк. Әле һаман да күңелләрендә: «Бәлки билетны үтеп баручы Себер поездларының берәрсенә алгандыр»,— дигән яшерен өмет пыскый иде.

Вокзал ыгы-зыгысы кими төште. Ерак офыктагы болытлар арасына кереп баручы кояш нурларында күләгәләр дә иләсләнеп, озынаеп калдылар. Шәһәр өстенә кичке караңгылык иңде. Себердән килеп, Казанда берничә минутка гына туктаучы поезд үзе белән соңгы ышанычны да алып китте. Өмет сүнде, шик учагы дөрләп яна башлады: «Алдаганнар!»

Шушы шик, үзләренең иң изге хисләрендә, авыру бала хакына кылган гамәлләрендә алданган Андреевларга төн йокысы бирмәде. Икенче көнне тагын Таняны эзләргә керештеләр. Ләкин ул суга төшкәндәй юкка чыккан иде.

Ибраһимов проспектындагы, үзләренә сатылган йортта ишек ачкан хатын гына әче таңнан килеп кергән һәм бу квартирага дәгъва кылган Валя белән Мария Ивановнага бернәрсә дә аңлый алмый, сәерсенеп карап торды.

— Шаштыгызмы әллә? — диде ул.— Монда унөч ел торам инде. Сатарга җыену гына түгел, уйлаганым да юк. Башыгызга тай типмәгәндер лә...

* * *

Сәлим Закировка әлегә менә шушылар мәгълүм. Теләсә нинди ялганга, аферага әзер булган бу хатын-кызның кайда яшәве дә, хәтта фамилиясе дә билгеле түгел. Хәер, анысын ачыклау өчен, әллә ни озак вакыт кирәкмәде. Онкология диспансеры поликлиникасыннан 1985 елның сентябренә кадәр регистратурада эшләгән кызның Татьяна Куликова икәнлеген әйттеләр. Ләкин, ни гаҗәп, аны эшкә алганда, тору урынын әллә сорарга, әллә язып куярга онытканнар, анда төгәл адресы юк иде.

Капитан Закиров эшне иң элек шуларны ачыклаудан башларга уйлады да. Андреева белән Григорьева үзләре белгән йортларны әйттеләр; адреслар бюросыннан аның торак урыны буенча кайда теркәлгәнен белеште. Туганнарын барлады, онкология диспансерында кемнәр белән аралашуын, дус-ишләрен ачыклады. Хәзер инде бәрәм-берәм шушы адреслар буенча йөреп чыгарга, югалтырга тырышкан эзнең очын табарга кирәк иде. Беренче карашка бик гади һәм җиңел тоелган шушы мәсьәләне хәл итүгә әллә ничә көн үтте дә китте. Вакыт дигәнең — бик үзенчәлекле төшенчә бит ул. Һәр узган көн җинаятьчегә яңа мөмкинлекләр бирсә, тикшерүченең мөмкинлекләрен, киресенчә, чикли бара. Эзләүне ашыкмый гына, бөтен шартын китереп, эш көнендә каралганча, фәлән сәгатьтән фәлән сәгатькә кадәр дип кенә дә алып барырга мөмкин иде. Ләкин җәзасыз калган җинаять башка кешеләрне алдауга, бүтән махинацияләргә китермәс дип кем гарантия бирә ала?! Вакытында туктатмасаң, ахыры ни белән бетәсен күз алдына китерү кыен. Менә шулар борчый Сәлимне. Ял көне дип, эш сәгате бетте дип тормыйча, Таняның танышларын, дус-ишләрен, туганнарын эзләвен дәвам иттерде. Берсендә булмаса — икенчесендә, икенчесендә булмаса — өченчесендә нindидер мәгълүмат табылырга, эшкә азмы-күпме яктылык өстәргә мөмкин иде.

Милиция киемендәге кешеләрне күргәч, Ибраһимов проспектындагы квартира хуҗасы Габдуллина бөтенләй коелып төште. Нәрсә соң бу? Башта нindидер кешеләр килеп, квартира даулый, инде хәзер милиция хезмәткәрләре.

Аның югалып калуын үзенчә аңлады Сәлим. Хуҗаның шушы каушавыннан файдаланып калырга кирәк иде. Исәнләшеп, рәсми рәвештә танышкач, икеле-микеле сорауларга урын калдырмыйча сүзне турыдан ярырга булды.

— Таня Куликова кайда?

— Белмим... Аны күптән күргәнем юк инде...

— Ә сезнең квартира ачкычы аңа ничек килеп эләккән?

Хуҗа хатын җиңел сулап куйды.

— Аны әйтәсез икән! Ялга киткәндә, йортка күз-колак булырсың дип, үзем калдырып киткән идем. Китереп бирде инде ул аны. Бер-бер хәл бармы әллә?

Сәлим үзенең чак кына ялгыш юлдан кереп китми калуын шунда гына абайлап алды. Тикшерүче эше шуның белән катлаулы да. Беркемне дә, тәгаен белми торып, шик астына алырга ярамый.

— Юк, берни дә юк. Аны күрәсе бар иде,— дип куйды ул.— Ачкычыгызны кайчан китерде?

— Август ахырларында булыр...

— Аннан соң күргәнегез бармы?

— Юк шул. Үзем дә, ул күренмәгәч, шиккә калган идем инде. Беләсезме, әле күптән түгел генә ике аферистка килеп керде. Имеш Таня аларга бу квартираны саткан... Бар бит оятсыз кешеләр... Әллә шуларны кулга алдыгызмы?

Сәлим: «Аларның кайсысы аферисткадыр әле»,— дип уйлап көлемсерәп куйды. Алга таба сөйләшүдән файда булмаячагы аңлашылган иде инде.

— Сезгә бер үтенечем бар. Алай-болай Таня килеп чыкса, безгә хәбәр итегез әле.

Закиров телефон номерын язып бирде, әле һаман да ни булганын аңламый торган хатынны аптырашта калдырып, чыгып китте.

Ләкин шулай да кайбер нәрсәләр ачыклана башлады. Таня белән законлы никахта тормаса да, аңа ир булып яшәгән Гали Сафиуллиннан, аларның күршесе Шаландинадан сорау алганнан соң Таняның хәзер Казанда түгеллеген аңлады Сәлим. Аның фоторәсеме, төс-битен һәм кыяфәтен, аерым билгеләрен тасвирлаган язмалар илнең барлык милиция бүлекләренә җибәрелде — мошенниклыкта гаепләнүче Татьяна Куликовага Бөтенсоюз эзләве игълан ителде.

Берниндн нәтиҗәсез берничә ай вакыт узып китте. Тотыныр җебе булмаганлыктан, тикшерү шактый озакка сузылды. Бер яктан, прокуратура ашыктыра, икенче яктан, бүлек начальнигы тыкырдата.

— Бер мошенникны ничә ай эзләргә мөмкин?!.

Әмма берни эшләр хәл юк. Бөтенсоюз эзләве дә әлегә көткән нәтиҗәне бирми. Сәлим шаһитлар белән тагын бер кат җентекләп сөйләшеп чыгарга карар бирде.

...Өстәл янында Гали Сафиуллин утыра. Сорау арты сорау бирелә, әмма кирәкле җавап юк. Егетнең кәефе начармы, әллә кабат чакырганга эче пошканмы — аңламассың. Иреннәре кысылган, күзен яшереп, туры карамый гына сөйли. Беренче карашка, барысы да үз урынында кебек. Җаваплары да дөрескә охшаган. Тик дөресен сөйләгән кеше карашын яшерәмени?!

Эчке бер сиземләү, интуиция белән шуларны тоемлый Сәлим. Ләкин ничек итеп аңардан дөресен сөйләтергә?

Кеше үзенең эчке дөньясына, рухына тупас кагылганны яратмый. Кем белә, бәлки бу егет әле һаман да Татьянаны ярата торгандыр. Мәхәббәтне чит карашлардан саклау — начар сыйфат түгел үзе... Әңгәмәдә, аның хисләренә, тойгыларына, горурлыгына зыян китермичә, итәгатьле дә, таләпчән дә булырга кирәк. Сәлим гадәттә нәкъ шулай сөйләшергә тырыша. Ә монда бу рамкаларга гына сыймый торган киртәләр булса кирәк. Тикшерү башланган чорда гына анә эшеннән чыгарга гариза да биргән.

— Димәк, Сез хәзер Таня Куликованың кайда икәнен белмисез?

— Әйтә алмыйм.

— Әйтә алмыйсызмы, әллә белмисезме?

Егет тикшерүчегә карамый гына үҗәтлек белән кабатлады.

— Ну, белмим. Белмим. Тагын ничә кат әйтергә була.

— Ярый алайса. Сез бераз уйлый торыгыз. Мин хәзер керәм...

Сәлим күрше бүлмәгә ашыкты.

— Күңелем нидер сизенә, Таня Казанда булырга тиеш,— диде ул үзенә күтәрелеп караган хезмәттәшенә.

— Мин әле монда сөйләшә торам, шушы адреслар буенча дежур группа урап кайтсын әле.

Кабинетка кергәч, сүзне бөтенләй икенче яктан башлады капитан.

— Әйтегез әле, Гали. Сез инде Татьяна белән берничә ел бергә торгансыз. Ә үзегез һаман язылышмаган. Үткән юлы сорарга оныткانмын, үзең теләмисеңме, әллә Танямы?..

— Аның баласы булмый дип уйлаган идем.

— Ә хәзер буламы? — дип сораганын сизми дә калды Сәлим.

— Безнең балабыз бар бит.

— Менә сиңа иске авыздан яңа сүз. Кайда соң ул? Ничек инде син балаңның кайда икәнен белмисең?

— Минеке булганына шикләнәм, иптәш капитан. Әллә ничек кенә булды ул...

Моңа кадәр төртмәле җаваплар биреп утырган Галинең авырткан җиренә кагылдымы, әллә уртаклашасы килгән шиге тынгы бирми идеме, ул кинәт ачылып китеп сөйли башлады. Аның бер фикердән икенчесенә күчеп, ашыгып сөйләгәннәреннән шуны аңлады Сәлим: монда кеше язмышының катлаулы җепләре килеп чуалган. Мондый хәлләрне, юри уйлап утырсаң да, эзләп табарлык түгел. Кыскасы, туганнарына китеп торган Таня бер-ике айдан күкрәк баласы күтәреп кайта. Әмма, сөте булмаганлыктан, аны кибеттән алган төрле катнашмалар белән туйдыра. Ләкин күңелен иң биздергәне — ана мәхәббәте җитеп бетмәгәнен тоя Гали. Тагын күпмедер вакыттан баласы белән яңадан туганнарына китеп бара. Хәзер инде ул баласыз гына кайткан.

Ерылып киткән буа үзе белән бар чүп-чарны агызган шикелле, Галинең сөйләгәннәре дә әле моңа кадәр әйтелмәгән бик күп детальләрне ияртеп китерде. Таня Казанда! Моны өздереп әйтмәсә дә, тел төбеннән шуны төшенергә мөмкин иде.

Әле аңлашып та бетмәгәннәр иде, Сәлимне күрше бүлмәгә чакырдылар.

— Дөрес сизенгәнсең икән,— дип, аның аркасыннан кагып алды бүлек начальнигы Тәлгат Бикмуллин.— Егетләр Куликованы алып кайттылар. Бу эшкә нокта куярга вакыт җитте...

Кулга алынган Таня баштарак барысын да кире кагып маташты. Ләкин бу озакка бармады. Алданган Валя Андреева белән Мария Григорьева, шаһитлар Габдуллина, Шаландина, Сафиуллин һәм башкалар белән күзгә-күз очраштыру аның кирелеген дә, тикшерүчене алдарга маташуларын да кул белән алып ташлагандай итте. Галине дә үзе белән алып китәр өчен кайткан булып чыкты ул. Монысы соңыннан, тикшерү барышында ачыкланды.

— Үз гаебеңне чын күңелдән тану гына хәлеңне җиңеләйтә алыр. Шуны истән чыгармавыгызны сорыйм.

Гаепләнүчеләргә карата әйтелә торган шушы гыйбарәне берничә мәртәбә кабатларга туры килде Закировка. Әмма Таня Куликова барыбер бөтенесен дә сөйләп бетермәгән икән әле... Медицина комиссиясе Танянын беркайчан да бала тапмаганлыгын билгеләде.

Ә алып кайтып, Галигә күрсәткән бала кайдан килгән? Кемнеке ул? Үз акылында булган ата-ана ике айлык сабыйны кеше кулына тоттырып җибәрерме? Сәгать саен, минут саен ана назына, карауга, мәхәббәткә мохтаҗ бала Таня кулына каян килеп эләккән? — Закировны шушы сораулар борчый, күңеленә тынгылык бирми. Дөрес, ул инде үзенә тапшырылган эшне ахырына илтеп җиткерде: мошенниклыкта гаепләнүче Куликованың алдау юлы белән дүрт мең сумнан артык акча алуы да, үзенеке булмаган квартираны сатып җибәрүе дә — барысы да исбат ителгән. Эшне бары тик судка тапшырасы гына калган. Кергән гариза буенча да шул таләп ителә. Артык сузарга да ярамый. Ләкин бу бала мәсьәләсенә ачыклык кертми калсаң, гомер буе үзеңне гаепле хис итәчәксең. Бала югалту турында беркайдан да гариза яки үтенеч кермәгән керүен. Ләкин...

Таняның туган-тумачалары кай якларда яшәгәнлеге билгеле иде инде. Тотты да шул якларга хатлар җибәрде. 1985 ел азакларында бу шәһәрләрдә күкрәк баласы югалу очраклары булмаганмы? Җавап озак көттермәде. Свердловск шәһәре эчке эшләр идарәсеннән иде ул. Әйе, нәкъ менә шул чорда Свердловскида подъезд янына куелган арбадан ике айлык сабый юкка чыккан.

Сәлимнең йөрәге жу итеп китте. Кайда булыр икән хәзер ул нарасый? Балаларын югалткан ата-ананың ни кичергәнен күз алдына китерүгә, тәне чымырдап куйды. Дустыңа түгел, дошманыңа да күрсәтмәсен мондый хәлне.

Хәрефләрне йотардай булып, рәсми кәгазьгә машинкада басылган текстның икенче ягын әйләндергәч, йөрәген басып торган таш төшеп китте диярсең. «Тагын берничә айдан ул баланы подъездга кире китереп ташлаганнар»,— дип язылган иде анда. Җинаять эшләүче турында үзләренә билгеле булган кайбер мәгълүматларны да өстәгәннәр.

Казан шәһәренең Ленин районы халык суды Татьяна Куликованы мошенниклык өчен дүрт елга ирегеннән мәхрүм итәргә диган карар чыгарды. Шуның өстенә бала урлау турындагы эше буенча ул Свердловск өлкәсенең тикшерү органнарына тапшырылды. Анда да җинаятьче тиешле җәзасын алган.

• • •

Күбәләк-күбәләк кар ява. Шәһәр урамнарында кичке тынлык. Милиция капитаны Сәлим Закиров бүген өенә тыныч күңел, яхшы кәеф белән кайта. Тормышыбызның ямен, яшәвебезнең тәмен җибәрүче тагын бер җинаять эшенә чик куелды.

Трамвай тукталышына килеп җиткәнен сизми дә калган икән. Ул да көтеп торучылар төркеменә кушылды. Өйдәге нәни улын, ишектән килеп кергәч тә аның үзен ничек кочаклап алачагын күз алдына китереп, рәхәт бер ачыклык белән елмаеп куйды.

Шунда капитан каршына бер егет килеп басты.

— Исәнмесез, иптәш капитан! Таныйсызмы?

Ул, сәерсенеп, бер кавым карап торды һәм бары шуннан соң гына:

— Хәтерлим, хәтерлим, әлбәттә,— дип әйтә алды.

— Рәхмәт Сезгә, иптәш капитан. Теге чакта бераз ялгышынган булган. Сезгә ачуланып та йөргән идем. Ә хәзер аңладым. Зур упкынга төшеп китүдән саклап калгансыз икән. Киңәшләрегез өчен тагын бер кат рәхмәт Сезгә!

Әйе, әле күптәнме хулиганлык өчен хөкем ителгән иде бу егет. Ә хәзер әнә... Аның кулын тиран бер канәгатьләнү белән кысты капитан Закиров. Үз эшеңнең уңай нәтиҗәсен күрүдән дә ләззәтлерәк бирәр хис бар микән? Бигрәк тә юрист өчен...

**Мансур Вәлиев**

# УЧАГЫҢ СҮРЕЛМИМЕ?

*...Авылга кереп, Акъәбинең тәрәзәләре кагылган өе янына җиткәч, Миңлебай карт күрше Гарифәдән гел кычкырып сорап уза:*

*— Аккилен кайтмадымы әле?*

*Гарифә ни дип җавап бирергә дә белми,— ул бит инде аңа былтыр ук берничә мәртәбә Акъәбинең калада вафат булуын әйткән иде. «Балалар акылы керә башлаган ахрысы бу картка»,— дип уйлый ул эченнән генә, һәм, аптырагач, ачулана биреп әйтә:*

*— Күй, Миңлебай бабай, үлгән кеше кайтамыни, ничек телең барып сорый.*

*Ләкин карт аның сүзләрен гүя колагына да элми.*

*— Алдама,— ди ул, таягының башын селкеп.— Аккилен үлмәде ул, китте генә... Китте генә... Кайтыр, насыйп булса, кайтыр... Ә син учагын карый тор, учагын... Учагында ут сүнмәсен.*

Әмирхан ага Еникинең «Әйтелмәгән васыять» хикәясендә Миңлебай карт әйткән бу сүзләрне ишетүебезгә инде байтак еллар узды. Әмма ни өчендер һич кенә дә онытылмый, бер дә истән чыкмый ул сүзләр. Күпме генә еллар узса да — гел ишетелә, һаман күңел түрендә алар...

Ә бит һич тә сер түгел: баштарак, әсәр басылып дөньяга чыккан алтмышынчы елларда, Миңлебай картның бу сүзләре турында шактый гына бәхәсләр дә булып алды. Ул чагында кайберәүләребез яше бик тә олыгайган әлеге карт сүзләрендә нииндидер дөрес фикер, иҗтимагый яктан мөһим мәгънә барлыгын шик астына алдылар. Шул уңайдан «Үлгән карчыкның кайтуына ышанып йөргән Миңлебай карт үз акылындамы соң?» — дигән сорау да куелды.

- Аннан бирле менә егерме елдан артык гомер узды... Бу чор эчендә тормышыбызда, көнкүрешебездә үзгәрешләр, күп яңалыклар булып алды. Ул үзгәреш-яңарышларның иң киң колачлысы һәм кешегә иң нык тәэсир итә торганы, мөгаен, шәһәрләшү процессы булгандыр. «Әйтелмәгән васыять» язылган елларда башланып, аннан соң тагын да көчәйгән бу социаль күренеш без элек һич тә уйламаган проблемаларны калкытып чыгарды, игътибар үзәгенә куйды. Яңадан-яңа әхлакый мәсьәләләр, рухи сораулар безнең күңелләрне, акылларны торган саен ныграк били барды.

Һәм биредә безнең өчен шунысы бигрәк әһәмиятле: соңгы еллар тормышы тудырган нәк шул проблемалар хакында ешрак уйланган саен, безгә Миңлебай карт сүзләре һаман ныграк аңлашылды, һаман тирәнрәк төшенелде.

«— Учагын карый тор, учагын... Учагында ут сүнмәсен».

Учак... Әллә соң бөтен хикмәт нәк шул бер сүздәме?

Чыннан да, безнең өчен бик тә ягымлы, бик тә үз һәм кадерле нәрсә бит ул учак! Кешеләрне, халыкларны бик-бик борынгы заманнардан бирле, гомер буена җылытып, яшәтеп, саклап килгән җанлы бер зат, серле бер көч бит ул — учак!

Халыкның туган һәм үскән нигезен, яшәү нигезен гәүдәләндереп торучы якты, матур образ да бит әле ул — учак. Бу сүз безнең күңелләрдә туып үскән нигез, туган авыл, туган төбәк булып һәм, гомумән, зуп-зур, кадерле Ватаныбызның үзеге сыман яши бит...

Әйе, учак безнең өчен инде күптәннән бирле аерылмас юлдашка әверелгән. Бүгенге көндә, кеше искиткеч көчләргә әйләнеп, Җир йөзен куәтле-куәтле машиналар дөбердәткәндә дә, планетабыз әйләнәсендә кеше ясаган гаҗәеп ракеталар очып йөргәндә дә — барыбер, безгә туып-үскән нигезебез — туган учагыбыз кирәк! Ул барыбер безнең өчен кадерле!

Без, куәтле фән белән коралланган егерменче гасыр ахыры кешеләре, космик ракеталарны иярләп салкын галәм киңлекләре буенча кая хәтле генә ерак китә алсак

та, анда, барыбер, кунак кына булып калачакбыз! Каяндыр килгән һәм кире китәргә мәҗбүр затлар булып кына!

Шулай итеп, киң планда, космик масштабта караганда да безнең иң ышанычлы һәм бердәнбер булган нигезебез — Җир. Әмма менә хәзер генә, гасырыбыз ахырында гына, үзебезне тудырган һәм шушы дәрәҗәгә хәтле үстергән планетабызның безнең өчен ни кадәр кадерле булуын без ныклап аңлый башладык сыман. Атом дигән явыз корал килеп чыгу, шуның аркасында безнең гүзәл Җиребезнең, андагы яшәешнең тулаем юкка чыгу мөмкинлеге туу күңел күзебезне ачты ахрысы...

Әле алай гына да түгел!

Җир сүзе үзенең таррак мәгънәсендә дә — бөтен кешелек, тереклек дөньясын туендырып торган туфрак мәгънәсендә дә Кеше өчен бердәнбер нигез булуын һаман ныграк исбатлый бара. Зур-зур шәһәрләрнең кеше өчен, яшәү өчен бик тә җайсыз, уңайсыз булуы хәзер инде махсус белгечләр тарафыннан гына түгел, безнең һәммәбез тарафыннан да нык аңланыла, төшенелә бара. Хәзер һәммәбез шәһәр читендә генә булса да, кечкенә генә булса да, җир-бакча алырга тырыша. Шулай итеп җирдән, туфрактан аерылмаска тели.

Күңелләребездәге мәңгелек учак шәүләсе безне бүген әнә шул рәвешле үзебезнең ышанычлы нигезебезгә дәшә. Авылларыбыздан килгән хатлар булып, ата-бабаларыбыз нигезе булып үзенә чакыра!

Әнә шуңа күрә Миңлебай карт сүзләре бүген безгә:

— Туган нигезеңне, үскән җиреңне онытмагыз! — дигән кыйммәтле киңәш сыман ишетелә.

Әмма халкыбызны мәңгелек юл буйлап озата баручы учак образының мәгънәсе моның белән генә бетә аламы соң?! Әле бит югарыда без карап үткән учакны — кешенең яшәү нигезен гәүдәләндергән учакны гел тере, гел кайнар итеп тотучы икенче бер учак та бар.

Анысы инде — халыкның күңел җимеше, иң кайнар йөрәк хисләре, иң-иң кадерле кичерешләре булып яшәүче әдәбият һәм сәнгать дөньясы. Ул да, көчле бер учак сыман балкып, халыкны мәңгелек юл буйлап озата бара. Аның күңелен җылыта, рухын тере тота. Халыкның авыр чорларда җан авазы булып яңгыраган моңлы аһәңнәре дә, бәхете тулып ташыганда, дөньяны ямьләгән якты хисләре дә — һәммәсе-һәммәсе әнә шул бер учакка өстәлә, шуңа кушыла.

Искә төшерик: әле Бөек Октябрь революциясе якынлашып кына килгәндә, әдәбият-сәнгатьнең халыкны тәрбияләүдәге бөек көчен, миссиясен билгеләп, Галимҗан Ибраһимов болай дип язган иде: «Милләт уйганды, ләкин аңар тамыр җәяргә — туфрак, тын алырга һава кирәк. Ул хәзер сыек маддә шәкелендә. Милләтнең, милли рухның җилгә аумас, суга батмас, утка янмас мәртәбәдә куәт алуы һәм дә мәдәни бер калыпта корычка әйләнүе өчен — ул үзенең сәнаигы нәфисәсенә мохтаҗ... Аны яныбыздан шаулап аккан мәдәният диңгезенә кереп, татар өчен мәңгегә юк булуыннан, мәдәни халыкларга йотылуыннан фәкать аның үз йөрәгендәге эчке тамырларын тибрәтәчәк милли сәнгать кенә алып калыр».

«...Учагыңда ут сүнмәсен». Замандаш язучыбыз таланты белән хасил ителгән учак икән бит ул сүзләр. Юк, сүзләр генә түгел! Әдипнең бөтен иҗаты халкыбыз йөрәген җылытып торучы бер кайнар учакны хәтерләтә. Халык нигезен, туган төбәкне онытмаска кушучы, Ватанны яратырга һәм сакларга өндәүче — укучыларны чын патриотлар итеп тәрбияләүче Учакка әверелгән аның әсәрләре. Әле без сүз алып барган «Әйтелмәгән васыять»тә дә, «Туган туфрак» белән «Саз чәчәге»ндә дә һәм, ниһаять, «Соңгы китап»та да әнә шул ялкын дөрли!

Халкыбыз өчен, аның рухи дөньясы өчен әнә шундый кайнар учак булып яшәүче иҗат дөньялары тагын да бар әле бездә. Бу яктан шөкер, бик тә бай без! Гомәр ага Башировның соңгы берничә елда язылган әсәрләре үзләре генә дә ни тора! «Туган ягым — яшел бишек», «Җидегән чишмә», «Сарут», «И язмыш, язмыш»... — боларда туган ягыбызның, халкыбызның тәрбияви һәм рухи көче, бөек көче нинди гүзәл симфония булып яңгырый!

Ә соң шигърият?! Бүгенге замандашыбыз йөрәге Х. Туфан, С. Хәким, Н. Арслан, Г. Афзал һ. б. шагыйрьләр иҗатыннан башка матур һәм илһамлы яши аламы соң?!

*Халык йөрәгенең тибешләре*
*Кемнән кемгә генә күчмәгән...*
*Тукай булып, Җәлил булып тибә,*
*Өстен калып барлык көчләрдән,—*
*Челтери дә чыга чишмәләр.*

Шагыйрь И. Юзеевның туган як чишмәләре турындагы һәм бер үк вакытта халыкның талантлы уллары хакындагы менә бу шигыре дә «әдәбият» дигән әлеге учакка кушылып, безнең күңелләрдәге ватандарлык утын көчәйтә. Укучы йөрәген туган җирнең яшәү көче бирә торган чыганакларына тоташтыра ул.

Бүгенге кеше өчен матурлык һәм нурлык чыганагы булган шушы эчке хәзинә турында яшьрәк буын шагыйре М. Әгъләмов та рухланып җырлый:

*Юк, түгел бу кошлар җыры гына,*
*Түгел кәккүк авазы гына.*
*Сине җиргә, күккә, тирәлеккә*
*Бәйли торган җепләр сузыла.*

. . . . . . . . . . . . . . . . . . .

*Шулар аша сиңа планетаның,*
*Кешелекнең намусы дәшә.*
*Үз-үзенә кеше кабер казый*
*Әнә шуны аңлый белмәсә.*

Менә шулар шикелле бик күп ялкынлы әсәрләр аша бүгенге әдәбият халкыбызның күңел учагын дөрләтә. Халкыбыз үзе дә гомер-гомергә әдәбият-сәнгать дөньясында күренгән һәр яңа исемгә олы өметләр баглый. Үз күңелендәге, массалар йөрәгендәге яңа җыруны тәү мәртәбә башкаручы дип карый халык талант иясенә.

Әйе, әйе,— нәкъ әнә шулай! Яшәү дәверендә халык күңелендә туган, халык йөрәгенә иңгән һәм дөньяга чыкмыйча түзә алмаган яңа бер көйне башлап җибәрүче, оста итеп башкаручы ул — чын талант иясе! Аның, әлеге талант иясенең, җыруы дөрес булса, халыкныкы булса, халыкча булса һәм ул халык йөрәгенә ятышлы итеп башкарылса — халык үзе дә аңа кушылып китә, аның белән бергәләп җырлап җибәрә, бергә моңлана.

Миңлебай картның «Учагын карый тор, учагын... Учагында ут сүнмәсен...» — дигән гади генә сүзләре бүген безнең күңелләрдә әнә шундый күп катламлы уйлар уята. Ул сүзләр, бер дә күз алдыннан китми торган учак сыман гел безне тынгысызлап яна. Аның яктысында җитди сораулар, ачыклап бетерәсе мәсьәләләр калка. Хәзер шуларның берсенә тукталыйк.

Бүген безнең «әдәби талант» дигән учакларыбызның кайсыберләре ни хәлдә яши икән? Алар бүген тормышта ничегрәк балкыйлар икән? Халкыбыз күңеленә җылыны һәм яктыны җитәрлек дәрәҗәдә бирә алалармы алар? Әгәр бирә алмыйлар икән — эш нәрсәдә, сәбәп нидә? Әйдәгез, әнә шул сорауларга җавапны бергәләп эзлик.

Язучылар союзының поэзия секциясе үзенең чираттагы бер утырышына көн тәртибе итеп шагыйрь Эдуард Мостафин иҗаты турында сөйләшүне куйган иде... Без — шигырь сөючеләр — барыбыз да моңа бик сөендек: чөнки Эдуард Мостафин — чыннан да, сәләтле шагыйрь. Шигъриятттә ап-ачык күренеп торган үз йөзе, башкалар арасында һич тә буталмастай үз тавышы булган шагыйрь. Аның газета-журнал битләрендә соңгы унбиш ел эчендә басылган күп кенә шигырьләре әнә шул фикерне раслый. 1979 елда Татарстан китап нәшрияты тарафыннан чыгарылган «Елның бишенче фасылы» исемле җитди җыентык та шул хакта сөйли.

*— Кайт,— диеп, еракта,*
*Кыр буйлап,*
*Уйнаклап, колыннар йөгерә.*
*— Кайт,— диеп, еракта,*
*Урманда,*
*Сагынып, җиләкләр өлгерә.*
*— Кайт,— диеп, еракта,*
*Күкләрдә*
*Җып-җылы болытлар җыела.*
*— Кайт,— диеп, еракта*
*Күлләрдә,*
*Сагынып, аккошлар коена.*
*— Кайт,— диеп, табында,*
*Бер читтә*
*Бүленгән ашларым суына.*
*— Кайт,— диеп, бер сабый*
*Тын гына*
*Әтисе куенын сагына.*

Үзендәге үзәк өзгеч моңы белән истә калган әнә шундый шигырьләр бар әлеге китапта. Менә бу шигырьне укыгач та, җан сыкрый, әрни. Башта ук әкрен-әкрен сизелә, әзерләнә килеп, шигырь ахырында гына бөтен тулылыгында ачылып киткән гөнаһсыз бер сабый трагедиясе укучы күңелен тәмам тутыра, чайпалдырып җибәрә. Укучы күңеле язгы буа сыман тула, ярларыннан ташый башлый...

Шагыйрьнең беренче китабы көчле тойгылы һәм яшәүнең, дөньяның тирән катламнарыннан — кеше йөрәгенең иң эчкәреге төпкелләреннән бәреп чыккан тәэсирле шигъри авазлары белән кадерле иде. Анда олы дөнья белән чынлап очрашкан һәм үзе өчен күп кенә рухи ачышлар ясаучы яшь егет образы яши иде. Ул егетнең кичерешләре укучыларга онытa алмастай шигъри әсәрләр булып ирешә...

Э. Мостафинның 1986 елда басылып чыккан «Туасы көн» исемле икенче китабыннан без зурны көттек. Үзебезгә беренче китап аша таныш булган яшь егетнең хәзер инде дөнья һәм яшәү катламнарына тагын да тирәнәя төшүен көттек. Әнә шул үзебез эмсенгән, интуитив рәвештә генә сиземләгән яңа һәм тирән катламнардан килгән йөрәк авазы белән шигъри очрашу көттек.

Әмма, кызганыч, «Туасы көн»дә без әллә ни яңа катламнар ача алмыйбыз. Китапның исеме үк без бүгеннән көткәнне һаман киләчәккә күчерә төсле: бүгенге көн, бүгенге кайнар кичерешләр түгел, ә туасы көн, әле билгесез көн, ни икәне, нинди булачагы билгесез көн игътибарга алына төсле...

Яшәеш серләре эченә тагын да тирәнәя алмау өстенә (ә бәлки әле шуның нәтиҗәсе булыптыр?) бу китапта икенче бер сәер сыйфат та баш калкыта. Анда лирик геройның күңел газаплары, йөрәк әрнүләре артык күбәеп китә һәм алар үзмаксатка ук әйләнә башлый. Алар Эдуард Мостафин өчен төп максатка әверелә.

Мин биредә йөрәк хәлләренең зур дөньядан аерым каралуы турында әйтергә телим. Рухи күренешләрнең дөнья һәм реаль чынбарлык белән бәйләнмичә бирелүе турында. Э. Мостафинның икенче китабын укыганда, әнә шул бәйләнеш булмау бик еш күзгә чалына. Ягъни, әсәрдә нинди дә булса бер хис, бер кичереш игътибарга алына, ә аның тормыштагы җирлеге, реаль чыганагы, кичерешнең каян килеп чыгуы, нинди конкрет ситуацияләрдән тууы укучы өчен билгесез кала.

Моңа шактый гына мисаллар китерергә мөмкин. Икенче җыентыкта: «Карны тырнап, ялгыз бүре улый, Боз өстеннән, кайнап, су ага», «Тырнак асларында тычкан елый — Дөнья булгач мәчеләр дә белеп көлсен», «Бер ерткычтай күреп яраладың мине, Үчем сиңа сөю булып арта бары» һ. б. шундый шигъри, көчле чагыштырулар, метафоралар күп. Ләкин шигырьләрдәге менә шул драма-трагедияләрнең реаль җирлеге аңлашылмый кала. Китаптагы байтак шигырьләрне укыганда, укучы күңелен шундый бер сорау борчып тора: «Биредә нәрсә хакында сүз бара соң? Шагыйрь нинди тормыш күренешен сурәтли? Ул безгә нинди мәгънә житкермәкче була?»

Шагыйрь яшәешнең мөһим генә рухи проблемаларына мөрәҗәгать иткәндә дә, шигъри күңелен тулы көченә эшләтмичә, мәсьәләләрне җиңел генә хәл итеп куя. Соңгы китапта моңа да мисаллар күп. «Газаплы төн» шигыре, мәсәлән, иҗат газапларын сурәтләүгә багышланган. Әмма бу газапларның төп мәгънәсе әсәрдәге:

*Су бирми сусата, ач тота,*
*Янында нәрсәдер кыштырдый,*
*Кемнәрдер пышылдый колакка —*
*Тәгаен, акылдан язудыр.—*

диган юлларга гына кайтып кала. Ягъни, автор иҗатның бөтен нигезен, бөтен хикмәтен серле булуда гына күрә. Ә бит һәр чын иҗатның иң беренче нигезе — тормыш, чынбарлык. Шуңа күрә, иҗат процессы хакында сөйләргә алынган очракта, бөтен хикмәтне сергә генә кайтарып калдыру — ул бик җиңел котылу, иҗат хакында яңа сүз әйтә алмау дигән сүз.

Дуслар истәлегенә багышлап язылган һәм «Китә дуслар, китә япь-яшь килеш...» дип башланган шигырь дә бүгенге тормыш күренешенә җиңел караш булу хакында сөйли. Шагыйрь анда:

*Шушы хакта мин әйтергә тиеш:*
*Китә дуслар, китә япь-яшь килеш...—*

тән ары уза алмый. Ә бит укучы шактый еш очраган бу трагедиянең зур икәнен тоя, аның тетрәндергеч тирән икәнен интуитив юл белән үзе дә сизенә. Шагыйрьдән ул эчкәрәк, тирәнгәрәк керүне көткән иде. Әмма аның өмете акланмый кала.

Ә икенче бер шигырендә Э. Мостафин: «Юккамыни безнең күңелләрдә Зилзиләләп куба ярсулар»ның сәбәбен бары тик түбәндәгеләрдә генә күрә:

*Дөнья аша түгел, безнең аша*
*Үтә давыл, агалар сулар.*

Ягъни биредә дә зур күренешнең җирлеген гадиләштереп, җиңел юл белән генә аңлату күрәбез. Икенче төрле итеп әйткәндә, сәләтнең рухи ялкаулыгы.

Мисаллардан күрүебезчә, биредә бик зур нәрсә хакында сүз бара. Чөнки безнең шигърияткә һәм, гомумән, әдәбият-сәнгатьне һәркайчан һәм һәр чорда зур һәм көчле иткән, укучы йөрәгенә якын иткән нәрсә дә әнә шул — яшәү белән, чынбарлык белән бәйләнеш! Барыбыз өчен дә уртак һәм бер бөтен булган әнә шул дөньяви чынбарлык хакында сүз барганга күрә, һәр әсәр аша үзебезнең яшәү мизгелләрен күзаллаганга һәм тойганга күрә, кадерле бит ул безгә поэзия, әдәбият!

Әлеге мөһим сыйфатның Эдуард Мостафин иҗатында соңгы елларда йомшый башлавы безне борчый.

...Алтмышынчы еллар ахырында, җитмешенче еллар башында татар прозасына Азат Ганиев диган сәләтле автор килүе гомуми сөенеч тудырган иде. Аның «Тагын күченәбез» исемле хикәяләр китабы һәм 1972 елда «Казан утлары» журналы битләрен-

дә дөнья күргән «Сүзсез җыр» повесте безгә үзенчәлекле һәм күпне вәгъдә итүче яшь язучы турында сөйләде. Ул елларда М. Мәһдиевнең чын күңелдән куанып журналыбызда «Чишелеш нульгә бетми» дигән кызыклы мәкалә бастыруы да истә калган.

Әсәрне укуга инде менә унбиш елдан артык гомер узуга карамастан, «Сүзсез җыр» повестеның төп герое Габделхак әле һаман да, бүген танышкандай, күз алдында тора. Дөньяның пычрак якларына һәм кешеләрдәге әшәкелеккә каршы ярсып көрәшкә ташланган намуслы яшь рәссам Габделхак үзенең олы һәм якты максаты, яшьлеккә хас сафлыгы, канатлы яшәеше белән безнең күңелләрне били, әсәрләндерә. Габделхак сайлаган юл — иҗтимагый көрәшләр һәм киң масштаблы тормыш бәрелешләре вәгъдә иткән юл иде. Шәхеснең үзенә дә үсү өчен бик перспективалы юл иде ул...

Бу әсәрләрдән соң Азат Ганиев «Габделхак» дигән повесть язды («Казан утлары», 1984 ел, 5 сан).

Әйе, яңа повесть герое безгә таныш — «Сүзсез җыр»да укучы күңелен биләгән Габделхак. Ләкин бу повестьта без Габделхакның иҗтимагый пландагы зур көрәшләрен түгел, ә бераз гына бүтәнрәк нәрсә — гаилә сынавы аша узуын күрәбез. Әсәр башында Габделхакның яратып тормыш корырга уйлаган дусты Хәятнең дөнья куйганлыгы әйтелә. Шуннан соң аны язмыш Дания исемле бер хатын белән очраштыра.

Социаль пландагы зур көрәшләр белән очраштырмаганы өчен баштарак авторга бераз ачуыбыз килсә дә, әсәрне укый-укый, без бүгенге гаилә мөнәсәбәтләренең дә җәмгыять өчен гаять мөһим булуына төшенәбез. Чыннан да, заман тормышы бу өлкәдә дә яңа проблемалар китереп чыгарды. Хәзер байтак кына гаиләләр эчендәге, ир белән хатын арасындагы мөнәсәбәтләр шактый катлауланды. Яшь буынга дөрес тәрбия бирү, гуманлы кешеләр тәрбияләп үстерү максатыннан чыгып караганда, ул проблемаларның мөмкин кадәр тизрәк вакыт эчендә уңай хәл ителүе мөһим.

Габделхак бүгенге тормышта ныклы, тотрыклы гаилә өчен, аның сәламәт нигезе өчен көрәшә. Киңрәк планда алып караганда, бу — бүген зур эшләр белән йөрүче көрәшчеләрнең «тылы» дигән сүз. Габделхакка капма-каршы итеп куелган Дания образы аша без соңгы еллар тормышында шактый еш очрый башлаган хатын-кызларны күрәбез. Үз яшәүләрен җиңел ләззәткә, алдауга һәм акчага табынуга корган хатын-кызларны.

Билгеле, Габделхак белән Даниянең юллары аерыла. Автор укучы алдына зур социаль мәсьәлә китереп куя. Бүгенге гаиләләр нык булмауның бер мөһим сәбәбен ача. Әсәр басылып чыкканнан соң узган еллар автор фикеренең дөреслеген раслап килә. Безнең җәмгыятебезгә, чыннан да, хәзер хатын-кызны яшьтән үк гаилә җылысын, гаилә ныклыгын саклаучы буларак тәрбияләү буенча җитди чаралар күрергә кирәк. Аларга табигать һәм халкыбызның күп гасырлар буена тупланып килгән тәҗрибәсе йөкләгән олы вазифа әле һич тә җиренә җиткереп башкарылмый. А. Ганиевның соңгы әсәре «Габделхак» әнә шул проблеманы үткен итеп китереп куйды.

Хәзер инде «Габделхак» повесте басылып чыкканга да байтак кына гомер узды... Әллә А. Ганиев бөтенләй язмыймы соң? Юк, алай түгел. Ул яза, әмма аның матбугатта басылмаган соңгы берничә хикәясе тормыштан артык ерак булган, артык абстракт уйларга корылган иде. Мәсәлән, аларның берсендә автор җирдә очраклылык юк дигән саф фәлсәфи, чиста фәнни проблеманы хәл итәргә алынган...

Хәер, биредә максатыбыз — дөньяга чыкмаган әлеге хикәяләрне тикшерү түгел. Безне күбрәк язучының иҗат юнәлеше кызыксындыра. Аның иҗатының нинди темалардан кайсы проблемаларга таба үзгәрүе уйландыра.

Азат Ганиев турында беренче сүз башлаганда, күрдек: аның баштагы геройлары яшьлеккә хас саф күңел һәм зур омтылышлар белән канатланып, олы көрәшкә чыктылар. Бу көрәштә җиңделәр дә, җиңелделәр дә. Алар шуның белән кызыклы иде. Аларның тормышы укучыларга шуның белән мәгънәле иде, файдалы иде... Байтак гомер узгач, алда күреп узган «Сөмбел» язылган. Үткән чор әсәре туган... Тагын күпмедер елдан соң гаилә хәлләрен тасвирлаган «Габделхак» повесте туды...

Шулай итеп, без башта бик зур өметләр баглаган прозаигыбызның иҗат юлы социаль көрәшләрдән читләшү, реаль тормышның таррак мәсьәләләре беләнрәк мавыга башлау юнәлешендә бара түгелме соң?! Басылмаган соңгы хикәяләрдәге салкынлык, нindидер тере кешегә хас булмаган җансызлык — гел фикер, гел уй белән генә мавыгу — әнә шул читләшү җимеше түгелме соң?!

Алдарак без шагыйрь Эдуард Мостафин иҗатын карап үткән идек. Менә хәзер аның чордашы булган прозаик Азат Ганиев әсәрләрен күздән кичердек. Ике авторда да безнең бүгенге чынбарлыгыбыздан, аның реаль кайгы-шатлыкларыннан ераклаша бару дигән күңелсез бер тенденция төсмерлибез. Шагыйрь Э. Мостафин, тормыштан ераклашып, үз күңелендә артык нык казына, үзенең хисләрен генә төп максат итә. Прозаик А. Ганиев исә, яза-яза, галәм салкынлыгына чыгып китә. Ул бүгенге чордашыбыз өчен кызык та, кирәк тә булмаган салкын, җансыз идеяләр белән мавыга.

Ә бит бу тенденция, кызганычка каршы, биредә мисал итеп алынган ике яшь авторга гына хас түгел! Без күреп киткән әлеге чир әдәбиятыбыздагы күп кенә

каләм иялəренə дə йогып килə. Яшьлəрдə генə түгел, хəтта урта буын язучыларда да соңгы елларда еш күренə ул чирнең билгелəре.

Шулай булгач, бу социаль һəм рухи күренешнең сəбəплəрен эзлəп, тагын да эчкəрəк керик...

Хикмəт нəрсəдə? Чынлап та, эш нəрсəдə соң?

Ни өчен соңгы елларда безнең яшьлəребезнең байтак өлеше социаль яктан һəм гражданин буларак халыкның, җəмгыятьнең өметен аклап бетерми?

Үзара əңгəмə вакытларында да, матбугат битлəрендə дə хəзер еш кына очрый башлаган бу сорауны биредə иҗат яшьлəренə мөнəсəбəттə карап үтик. Ни өчен М. Шолоховлар, Ш. Усмановлар егерме-утыз яшьлəрендə зур-зур əсəрлəр язганнар да, ə безнең талантлы гына дигəн яшьлəребез бүген бик соң өлгерəлəр? Эш нəрсəдə? Гаеп кемдə? Алар тизрəк өлгерсеннəр өчен, нинди социаль, əхлакый, рухи шартлар кирəк? Бүген бездəн нəрсəлəрне үзгəртү сорала?

Биредə дə уйлануны бер мисалдан башлап җибəрəсе килə.

Сугыштан соңгы елларда, этилəре сугыштан кайта алмау сəбəпле, ятим калган гаилəлəр байтак иде. Андый гаилəлəрнең ир балалары кечкенəдəн үк дөнья көтү, гаилə турында кайгырту җаваплылыгын үз өслəренə, үз җилкəлəренə алдылар. Һəм əнə шул егетлəр этиле гаилəдə үскəн ир балаларга караганда һəр яктан да иртəрəк өлгерə, кеше буларак та тизрəк формалаша иделəр. Аларның кавырсыннары алданрак ката иде. Алар тиз арада чын егет, ир-ат булып җитлегə иделəр.

Ул елларда гаилəне — димəк, үзеңнəн кечкенəрəк һəм көчсезрəк җан иялəрен — ашатырга, киендерергə, җылытырга кирəк булу ир баладагы бик зур эчке көчлəрне эшкə җиккəн, хəрəкəткə китергəн. Үз өстенə əнə шундый олы җаваплылык алган ир бала баш миен дə ныграк һəм житдирəк итеп эшлəткəн, физик эш белəн дə күп шөгыльлəнгəн, əхлакый-рухи яктан да көн саен əллə никадəрле һəм четерекле мəсьəлəлəр чишкəн. Чын егетлəр, ир-атлар əнə шулай, кыенлыклар күрə-күрə, каршылыклар җиңə-җиңə формалаша.

Инде бүгенге көнгə, үзебезнең чорга күчик. Күпчелек яшьлəребезгə карыйк. Аларның күбесе бит хəзер 40 яшькə хəтле этисе җилкəсенə ышыкланып яши! Юк, без аларга кечкенəдəн үк ятимлек телəмибез. Əмма аларның сакал чыккач та үзбаш яши алмаулары, сакаллы сабый булулары — кызганыч.

Бу күренешнең сəбəбе ачык. Соңгы елларда бик күбəйгəн мондый сакаллы сабыйлар кечкенəдəн үк берниндu кайгы-мəшəкать күрми үсə. Шуңа күрə аларның эчлəренə табигать салган күп төрле физик һəм рухи мөмкинлеклəр, импульслар хəрəкəткə килми, кыймылдамый. Димəк, тик торгач — алар үсми, ныгымый дигəн сүз! Менə шуңа күрə бүгенге яшьлəр һəм социаль, һəм физик, һəм рухи яктан акрын формалаша. Алар əкрен хəрəкəт шартларына куелганнар.

Хəзер инде иҗат яшьлəренə, аерым алганда, яшь язучыларга килик. Аларның нилектəн акрын формалашу сəбəплəрен эзлик. Фикеребезне алдарак тукталган ике яшь язучы мисалында дəвам итик.

Күреп үткəнебезчə, аларның баштагы əсəрлəрендə яшь кешенең гомер юлын башлап җибəрүенə бəйле проблемалар булды. Азат Ганиевның да, Эдуард Мостафинның да геройлары нигездə əнə шундый мəсьəлəлəр хəл итəргə тырыша. Укучы сизеп, күреп тора: авторларның үз яшəешлəреннəн алган тəҗрибə җимеше булды бу. Үз тормышларыннан алынган һəм сəнгатьчə итеп тасвирланган күренешлəр, вакыйгалар иде ул əсəрлəр нигездə.

Ə шуннан соң бит инде укучы əсəрлəрдəге тормыш мəсьəлəлəренең тагын да зуррак, катлаулырак булуын көтə. Яшь геройларның җитдирəк геройларга əверелүен, ил һəм халык өчен зуррак əһəмияте булган мəсьəлəлəр хəл итəргə борчылып йөрүлəрен көтə... Лəкин, кызганыч, авторларда һəм əсəрлəрдə андый тенденция сизелми. Əле алай гына да түгел: укучы өчен кызык түгел, мəгънəсе булмаган, ялгыш юнəлешлəргə кереп китү сизелə. Күреп узуыбызча, аларның берсендə күңел кичерешлəре артык нык, кирəкмəгəн дəрəҗəдə күп эксплуатациялəнде, ə икенчесе җансыз һəм салкын идеялəр белəн мавыга башлады.

Хəзер инде безгə бу хəлнең дə килеп чыгу сəбəбе шактый ачык. Чөнки авторларның үзлəренең замана тормышында шəхес буларак өлгерү, шəхес буларак тагын да югарырак күтəрелү, алгарак китү тəҗрибəлəре юк. Ягъни алар реаль яшəешне шəхес буларак үзлəрен үстерергə тиешле олы эшлəр, көрəшлəр белəн конкрет бəйлəнмəгəннəр.

Менə хəзер без, фикер йөртə-йөртə, иҗат яшьлəре арасында инде күптəннəн бирле бəхəсле булып саналган бер кызыклы мəсьəлəгə килеп чыктык. Яшь каләм иясе үзенең иҗатыннан тыш тагын нинди дə булса берəр эштə эшлəргə тиешме, юкмы? — дигəн проблема бу. Əле хəзергə халдə безнең яшь язучыларыбыз барысы да диярлек нинди дə булса бер эштə хезмəт итəлəр, конкрет бер вазифа башкаралар. Лəкин үзара сөйлəшкəн, фикер алышкан чакларда һəркем профессиональ язучы булуны, ягъни бары тик иҗат эше белəн генə шөгыльлəнүне иң зур хыялы итеп саный,

әз генә мөмкинлегем булса (биредә нигездә материаль як күздә тотыла), һич тә уйламый эштән китәр идем, ди. Мондый фикер белдерүче кеше иҗат эшенең үтә авыр һәм күп сорый торган хезмәт булуын әйтә, ниндидер бүтән эштән кайткач кына аңа җитәрлек көч һәм энергия калмавыннан зарлана. Безнең әдәбиятта сыйфат ягы аксауны нигездә әнә шуның белән, әсәрләрнең һәвәскәрлек дәрәҗәсендә эшләнүе белән аңлата.

Әйе, бер караганда, бу сүзләрдә шактый гына дөреслек бар. Әдәби иҗат — чыннан да, гаять зур рухи һәм физик көч сорый. Түземлек, даимилек, үҗәтлеккә кадәр барып җитә торган тырышлык сорый. Болары, һичшиксез, шулай, бәхәс юк.

Әмма, югарыда карап киткән очраклардагы кебек, әле бу хәлдә дә безнең яшь язучыларыбызга тормыш материалы җитмәгәч — ул чагында, тулы «ирек»кә чыккач, алар язарларына азыкны каян, нәрсәдән алырлар соң?

Бүген кайберәүләр бик тә кызыга торган вариант — гаилә мәшәкатьләреннән азат булу, җәмгыятькә файда китерә торган эштән азат булу — бу юл иҗатчы шәхесенең артык иркенлегенә, бер нәрсә өчен дә һәм беркем өчен дә җавап бирмәвенә, ягъни тулы җавапсызлыкка илтә түгелме соң?!

Инде кайберәүләр бик теләгән вариантны, әлеге «ирек»кә тулысынча ирешкән,— гаилә белән дә, балалар үстерү белән дә, җәмгыять өчен нинди дә булса файдалы эш эшләү белән дә үзен бәйләмәгән иҗатчы яшәвен алыйк. Андый яшәү бит инде тоташ янудан, тоташ көрәштән генә торырга тиеш иде! Аларны бит инде бернинди көндәлек дөнья мәшәкате дә тотмый, комачауламый. Ләкин без яшьләребез арасында никтер андый яну, андый көчле көрәш күрмибез.

Соңгы елларда әдәбиятка килгән яшь язучылардан күбесенең эшен, яшәвен, иҗатын янәшә куеп карыйк. Көндәлек эшләрендә алар нинди? Төп-түгәл итеп әйтергә була: гадәти кешеләр кебек! Бүтәннәрдән уздырмаска, калышмаска тырыша алар. Барысы да нормада булсын дип ягъни... Соң шулай булгач — эштә дә, шәхси яшәвендә дә дәрт һәм ялкын булмагач — иҗат өчен, язу өчен дәрт, ялкын каян килергә тиеш икән соң?!

Кызганычка каршы, соңгы елларда әдәбиятка килгән күп кенә яшьләребезнең яшәү, эшләү һәм иҗат итү логикасы әнә шундый. Билгеле бер чикне, норманы, чаманы узмау! Ягъни — әдәбияттагы без ияләнгән сүз белән әйтсәк: урта кул иҗат туу өчен менә дигән нигез, җирлек инде бу!

Көндәлек тормышта артык борчылмыйча — тыныч кына, җайлы гына яшәүнең рухи җимешләре әдәби иҗатта шактый ачык төсмерләнә. Шигъриятебез соңгы елларда үзенең байтак кына укучыларын югалткан икән, биредә иң зур сәбәпләрнең берсе, һичшиксез, әнә шул — шагыйрьләребезнең, бигрәк тә яшь шагыйрьләребезнең күңел учагы сүнә, сүрелә башлау.

Асылы бер булган — рухи көрәшләрдән читләшү булган — әлеге тенденция шигырьләрдә төрле рәвешләрдә гәүдәләнә. Беренчесе һәм мөгаен иң таралганы — укучыны яндырмый да, көйдерми дә торган, салкын һәм битараф, инде күп мәртәбәләр кабатланып, яңа мәгънә эчтәлеге калмаган табигать күренешләре:

*Язлардан соң беләм җәй киләсен,*
*Алышканын аның көз белән.*
*Мин язларга кабат кайткан чакта,*
*Нидер сынган, нидер өзелгән.*

*Н. Әхмәдиев*

Табигать күренешләренең шигырьләрдә зур урын билән, яңа шигъри ачышка китереп җиткермәгән очраклары да бик күп. Мисал өчен, Х. Әюповның «Яшен вакытында язылган шигырь» дип исемләнеп, олы уйлануларга эмсендергән әсәре бары тик менә мондый фикер белән генә тәгалләнә: «Танымыйсыңмыни күк күкрәткән Күңеленне, Кешем!» Шундый зур исем куелган әсәр өчен бик бәләкәй мәгънә бит бу! Бу шагыйрьнең «Биеклек» дигән шигыренең төп фикере исә менә мондый: «Сизеп торам: безнең белән бергә Биегәя бара таулар да». Ике әсәрдән дә күрүебезчә, аларда бүгенге укучының күңелен яңа биеклекләргә алып менә алырдай шигъри канат — көчле образлылык юк.

Табигать күренешләрен сурәтләүгә бәйле бу тенденциянең иң калку чагылышы без сүз алып бара торган учак образының яшь шагыйрьләр иҗатында ничек гәүдәләнүендә күренә. Алдагырак еллар шигърияте аша безгә учак көчле ялкын бирә иде. Ә соңгы елларда ул менә ни рәвештәрәк күзаллана башлады:

*Янды учак. Учак, гүя, алтын тавык.*
*Кемнәр аңа утын-агач әрәм, дисен...*
*Ә астында йомыркалар сыман ятып*
*Пешә иде көтүчеләр бәрәңгесе.*

*Х. Хөснуллин.*

Кайнар романтика символы булган учак шулай итеп хәзер кайберәүләр өчен «алтын тавык салган йомырка»га — бәрәңгегә әверелеп бара. Авторларның төп игътибары да соңгы елларда учакның үзенә, аның ничек януына түгел — ә бүтән нәрсәгә, тамак туйдыра торган нәрсәләргә юнәлә бара.

Төрле матур сүзләр хәйләсенә төренеп, бүгенге шигърияттә, гомумән, учак кирәкме, аны кабызу мөһимме дигән шикелле сораулар да куела башлады:

*Учак ягу, бәлки, кирәк түгел? —*
*Болай да бит янам. Дөрләп янам.*

*Н. Әхмәдиев.*

Алда китерелгән мисаллар аша без бүгенге яшь шагыйрьләрнең күбесенең һәм Н. Әхмәдиевнең үзенең дә ничек «януын» яхшы күрдек, шуңа күрә мондый арзанлы реверанслар һич тә авторлар файдасына сөйләми.

Халык өчен мөһим булган рухи көрәшләрдән ераклыкның икенче төрле чагылышы — яшь авторларның үз-үзләре эчендә артык казынулары, үзләренең иҗат газапларын нык күпертүләре. Хәзер безнең әдәбиятта язу һәм иҗат газаплары хакында шулкадәр күп сөйләнелә — ирексездән ул җирдәге иң авыр, иң газаплы һәм иң мөһим эш икән дигән тәэсир туа.

*Кыяларга менеп, җырлар язам,*
*Җырлар язам җилләр канатына...*

*Я. Игәнәй.*

*Я мин агам, таң мәлендә*
*Тып-тын аккан елга сыман.*
*Я җил булып шуып узам*
*Үлән-яфрак арасыннан.*

*Г. Садә.*

*Мәңгелекнең кай төше бу?*
*Кышмы? Җәйме? Кайсы ай?*
*Мин сагыштан сырхауланып,*
*Саташып ятам бугай.*

*Г. Моратов.*

Әйе, соңгы мисалда ачык итеп әйтелгәнчә — бу күренешнең чын асылы әнә шунда: зур һәм мөһим кичерешләр булмауда, лирик герой диелергә тиешле кешенең ваклануында, бары тик «саташып ятуында». Соңгы елларда безнең яшь шагыйрьләр бу чир белән, чыннан да, бик еш авырыйлар.

Заманның олы мәсьәләләреннән читләшү өченче төр очракларда менә болай чагыла:

*Олимпларны узып җиде кат күккә җитәм,*
*Бөтен рухны бу моң игелеккә җигә.*

*Ә. Гадел.*

*Юеш кояш ярчыклары*
*Җиргә коелып төште.*

*Я. Игәнәй.*

*Ялгыз калган чакларымда*
*Тынгы бирми төсләшем.*

*Ә. Мәхмүдов.*

Ягъни, бирелә анык кына күзаллавы гаять кыен булган нәрсәләр турында сүз барганын күрәбез. Гадәттә, үз күңелендә ачык һәм билгеле әйтер сүзе юк кеше әнә шулай бутап, гаять тә катлаулы итеп сөйли. Безнең шигърияттә дә мондый авыру — «артык акыллылык» чире хәзер еш очрый башлады. Күңел бушлыгын — үзең өчен дә, халкың өчен дә кадерле булган хис-кичерешләр юклыкны әнә шулай итеп капламакчы һәм шул юл белән акыллы шагыйрь шикелле күренмәкче була кайберәүләр... Ләкин сизгер укучы бу очракта да алданмый. Бу — яшьләрнең үзләренең ялгыш юлдан китеп алданулары гына!

Ә проза өлкәсенә күз ташласак, анда хәлләр ничегрәк тора соң? Иҗат учаклары ничек балкый анда?

Әдәбиятның авыр артиллериясе дип йөртелгән бу жанрга талантлар сирәгрәк килә. Чөнки монда табигый сәләттән тыш әле тагын тормыш тәҗрибәсе дә, авторның үзенең акыл утырткан булуы да, язу өстәле янында системалы рәвештә иҗат белән шөгыльләнә алуы да сорала. Ләкин, шулай булса да, бирелә дә иҗади яну иң төп көчне тәшкил итә. Уңышларның да, сүлпәнлекнең дә төп сәбәбе булып тора.

Бездә ел саен байтак кына роман-повестьлар чыга. Ә ни өчен соң укучылар арасында зур җанлану тудырырдайлары бик тә, бик тә сирәк? Укыган кешеләр ихлас сөенмәгәч, димәк, без иң мөһим нәрсәләрне язмаган диган сүз бит бу! Халык көткән иң кадерле уй-кичерешләр чагылмаган диган сүз ич бу! Илебез җәмәгатьчелеге соңгы елларда Ч. Айтматов, В. Распутин, В. Астафьев әсәрләре хакында кызып-кызып бәхәсләшә. Мондый бәхет нигә соң безнең проза әсәрләренә дә эләкми?

Егетлек җитми! Кыюлык җитми! Күп кенә талантлы авторларның әсәрләре ни өчен зур җанлану тудырмавына иң төп һәм иң зур сәбәп менә нәрсә! Югарыда без атап үткән әдипләр — алар, олы талант булу өстенә, егет кешеләр дә, аларга гражданлык кыюлыгы да хас! Әдәби талант белән кушылган әнә шул «егетлек» дигән асыл сыйфат аларга чын биеклек алып килә.

Инде үзебезнең әдәбиятка кайтып, яшьрәк буын язучылар иҗатына күз салыйк. Проза өлкәсендә эшләүче яшьләребезнең фамилияләре барысы да диярлек «Г» хәрефеннән башлана икән: Галиев Марсель, Гаффаров Әхәт, Гыйматдинова Нәбирә, Гыйльметдинов Фәрит. Аларның беренчесенең бүгенге көнгә — 7, икенчесенең — 7, өченчесенең — 3 һәм дүртенчесенең 2 китабы басылып чыккан. Күрүебезчә, болар инде аз түгел. Шактый күләмле иҗат.

Берәм-берәм язган әсәрләрен күз алдыннан үткәрәбез... Болай укыла да алар, кызыклы гына вакыйгалар һәм күренешләр дә бар... Ләкин шундый бер уртак җитешсезлек хас безнең яшь прозаикларыбызның повесть-хикәяләренә: ниндидер бер күнегелгән рәвеш буенча гына, бездә моңа кадәр чыккан әсәрләрдән нык аерылып тормый торган дәрәҗәдә генә «алтын урталыкта» итеп язылганнар алар. Ягъни бүгенге яшәеш хакында өр-яңа сүз әйтү, кыю-кыю фикерләр үткәрү юк аларда! Ничектер, барысы да «китапча гына», «әдәбиятча гына» язылганнар. Тормышның төбендә яткан зур-зур кантарларны кубарып түгел.

Ә бит белүебезчә, югарыда саналган прозаикларга бүген безнең иң зур өметләребез баглана. Димәк, хәзер, укучының мондый өметен аклау өчен, аларга зур бер сикереш ясау кирәк. Алда әйтеп үткәнебезчә, талант янына кыюлыкны, егетлекне китереп кушарга кирәк! Яшәүдә дә, аның җимеше булган әдәби иҗатта да.

Акыл билгеләп куйган ниндидер булса бер чамадан узмый гына, урта дулкында гына барырга омтылган иҗат, ирексездән, ялгыш юлларның берсенә барып керә, шул ялгыш юллар корбаны була. Чөнки аны намуслы йөрәгенең ялкыны, язмабызның башында ук без күреп үткән көчле учак уты түгел, ә башка ниятләр, уйлар йөртә...

Шулай итеп, иҗатта ике юлның берсен сайларга мөмкин булып чыга. Аларның берсе иҗатчыны әйләнә-тирәдә кайнап торган зур тормыш эченә алып керә, андагы конкрет вакыйгалар, төрле тип кешеләрнең үзара бәрелешләре, төрле идеалны яклап көрәшүләре белән тоташтыра... Икенчесе исә күбрәк игътибарны эчкә: үз эченә, сүз эченә, вакыйгаларның эчке ягына юнәлдерә. Чагыштырмача азрак даирә кешеләр ярата торган әсәрләр тууга китерә...

Соңгы ун-унбиш елда матбугатта актив күренгән һәм шактый зур өметләр белән иҗат союзыбызга да кабул ителгән яшь шагыйрьләребез күп безнең. Әмма аларның байтагының, иҗатта беренче баскыч яулаганга байтак ел үтүгә карамастан, икенче сыйфат баскычына атлавы сизелми әле. Ягъни, аларның бүгенге укучы йөрәген тетрәндерердәй, аның күзеннән яшь чыгарырдай, озак вакыт исендә калырдай һәм әдәби җәмәгатьчелектә дә җанлану тудырырдай әсәрләре күренми. Яшь авторлар тормышта үзләренә җайлы ниндидер бер сукмак табып алып, тыныч кына шуннан барырга, шома гына яшәргә һәм замана өчен җайлы шагыйрь булырга уйлыйлар дигән тәэсир туа.

Моннан өч ел элек, яшь шагыйрьләребез Р. Зәйдуллин белән Л. Зөлкарнәевнең беренче китаплары басылып чыккан иде. Ләкин аларның икенче җыентыклары әле һаман юк. Безнең күңелне тагын шикле уйлар бимазалый башлый: «Болар да тегеләр язмышын кабатлар микәнни? Болар да дүрт-биш елга бер китап чыгарып тыныч кына, җайлы гына яши башлар микәнни? Шома шигырь язучылар болай да күп иде бит инде... Бөтен язмышлары белән шагыйрь булган чын шагыйрьләр, давыллы шагыйрьләр бик тә җитми иде бит безгә!»

Әйе, бүген бу ике яшь талант кына түгел, күпләр сынау үтә. Тормыш сынавын уза...

Ә күз алдына шундый бер күренеш килә: язларын шаулап аккан елгалардан уйсу урыннарда су бүленеп кала... Тора торгач, язның җылы, җәйнең эссе көннәрендә ул башта җылына — анда тәннәрне рәхәтләндереп су коенырга була... Ә аннары инде, әкрен-әкрен аның суы бозыла башлый, тынчый башлый... Башта җылы, уңайлы, рәхәт булуы белән эмсендергән су — бозылып, инде күңелне һәм тәнне чиркандыра ук башлый... Аны әллә каян урап, әйләнеп үтәсең!

Ә бит ул кайчандыр шаулый-шаулый ага иде! Ярсып яши иде!

Безнең яшь талантларыбыз да шушы табигать күренешеннән үзләренә гыйбрәт алсыннар иде.

Яшь язучылар белән ихлас әңгәмәләр вакытында кайчак шаяру катыш шундый сорау куела: «безнең чорда ничек итеп бөек булырга?» Юк, очраклы сөйләшү уңаеннан шаяру аша гына килеп чыкса да, җитди мәсьәлә бу! Безнең фикер сөрешебез дә хәзер нәкъ менә шушы проблемага килеп терәлде.

Тормыш агышы китереп чыгарган һәр сорауга җавап бирүдә үткәннәр тәҗрибәсе зур ярдәм итә. Биредә дә шулай эшлик — тарихи мисалларга мөрәҗәгать итик. Безгә иң якын булган бөек шагыйребез Тукайны мисалга алыйк. Аны бөек иткән иң төп сәбәпләр нинди соң?

Әйе, шагыйрьнең яшәү еллары тарихи яктан халыкның милли аңы уяну чорына туры килү аңа бөеклек баскычларына атларга ярдәм иткән. Бишенче елгы революция дулкыны аңа һәм тагын бик күпләргә рухи көч, рухи канат биргән. Галимнәребез язуынча, бусы — бәхәссез хакыйкать.

Әмма Тукайны бөек иткән, шул ук чорда яшәгән һәм талантлы булган башка бик күпләрдән аерып куйган тагын бүтән сәбәпләр дә бар бит әле. Алары ниндиләр соң?

Биредә мин ул сәбәпләрнең икенчесе итеп: Габдулланың шәхси язмышы бик тә авыр булуны, аның йөрәгендә кечкенәдән үк бихисап кайгы-хәсрәт, аһ-зар җыйнала килүне; дөнья зурлыгындагы әнә шул газаплы тойгылар дәрьясының бер кеп-кечкенә кеше күңеленә күпләп тула, йөрәгенең моңнан тулыша баруын әйтер идем.

Әнә шулар инде табигать тарафыннан талант бирелгән Габдуллага чын халык улы булырга — милләтнең иң тирән, иң газиз кичерешләрен нечкә тоярга, аларны халыкчан моңлы итеп җырларга булышкан... Кыскасы, шагыйрьнең йөрәге бик кечкенә яшьтән үк язмыш тарафыннан халык йөрәге белән бер итеп ялгап куелган. Халыкның иң авыр хәсрәтләре, сөзелеп-сөзелеп, әнә шул учакка — шигъри йөрәккә тупланган! Иҗат чоры башлангычтан киң массаларга тәэсир итә алырдай көчле һәм ялкынлы җырлар булып бәреп, ташып чыгар өчен! Бусы — икенче сәбәп шагыйрьнең шәхси язмышы булды.

Ләкин бөеклек өчен әле тагын бер момент зур әһәмияткә ия. Әнә шулай бик күпне кичергән шәхеснең замана тормышында яшәү рәвеше, аның көн итү, гомер итү принциплары нинди булу хакында сүз бара.

Тукайның яшәү рәвеше нинди булган соң? Туры Тукай. Менә шушы ике сүз аның бөтен яшәү рәвешен ача да сала! Тукай үз тормышында гаделлектән, дөресен, турысын әйтүдән башка бүтән бернинди максатны да белми! Аңа бернинди хәйлә, алдын-артын уйлап тору, төрле якны үлчәп, салкын акыл белән исәп-хисап ясау хас түгел! Тормыштагы теге яки бу күренеш аның сизгер һәм керсез йөрәгендә нинди тибрәнеш тапса — шул моң, шул тибрәнеш туп-туры килеш: бары тик бик нык көчәеп, зур тәэсир алып дөньяга чыга. Ата башлаган вулкан сыман булып — туры сүз, туры хис, тугры йөрәк яшәеше бәреп чыга!

Әйе, үз чорының авыр шартларында яшәгән Тукайдан матди яктан өстен кешеләр күп булган. Кечкенәрәк буйлы һәм ярлы Тукай янында алар кәперәеп, үзләрен дөнья хуҗалары санап йөргәннәр! Борынны югары чөеп!

Ә Тукайны нәрсә тоткан соң аларга баш июдән, алар янында ялагайланып, бил бөгеп йөрүдән? Шәхси тәкәбберлек кенәме?

Юк, ул гына түгел! Зур шәхесләрнең бөтен зурлыгы да әнә шунда — ялагайлыкка һәм хәйләгә таянуда түгел, ә үзеңнең намуслы һәм халыкка тугры йөрәгеңә таянуда! Чөнки тугры йөрәк гәүдәне дә туры итә! Тоткан юлыңны да туры итә.

Без бүген бик тә сабак алырдай тагын бер асыл сыйфат бар Тукайда. Әнә шул туры йөрәк җырын, тугры йөрәк хисен кайнар килеш, әз генә дә суынырга ирек бирмичә халыкка, укучыга җиткезә ул! Шунда ук бастырып чыгара, хисләренә киң дөнья күрсәтә.

Искә төшерик: теге яки бу вакыйга уңае белән тәэсирләнеп Тукай кичтән шигырь яза, ә икенче көнне ул әсәр матбугатта басылып чыга. Димәк, әлеге вакыйганың шагыйрь йөрәге аша үтеп тагын да ачыкланган мәгънәсе халыкка шундук барып җитә. Әлеге иҗтимагый күренеш халык күңелендә тагын да ныграк үзләштерелә, яисә инде кире кагыла. Һәрхәлдә, Тукайның туры сүзе укучыны битараф калдырмый!

Әнә шуңа күрә, һәрдаим үзен халык белән, аның көрәше белән бәйләнештә сизеп яшәгәнгә күрә, шул бәйләнеш җебен көчле сизгәнгә күрә, Тукай күп, бик күп яза! Ул инде үзен яшәүнең, тормышның бер поэтик двигателе, моторы сыман тоя башлаган, күрәсең!

Шагыйрьнең кайсы елларда алтышар, җидешәр китап бастырып чыгаруы да юктан түгел. Ул дөнья вакыйгалары белән бер сулышта яшәгәнгә күрә, бүтәнчә эшли алмый, бүтән сүлпәнрәк ритмда яза һәм бастыра алмый! Аңа, Тукайга — Тукай ритмы, Тукай кайнарлыгы һәм Тукай кызулыгы кирәк!

Менә шундый кайнар дулкын — бәләкәй чагыннан алып гомер соңына кадәр дәвам иткән кайнар дулкын — шагыйрьнең бөеклеген билгеләүче факторлардан берсе.

Инде хәзер үзебезнең чорга һәм үзебезнең Тукайдан карт яшь шагыйрьләребезгә кайтыйк (сүз уңаеннан искәртеп үтик: бездә әле 50 яшькә кадәр яшь булып йөрүче «өйрәнчекләр» дә бар!).

Тарихтан мисал алып, бөек шагыйребез Габдулла Тукай тормышы һәм иҗаты аша, без бүгенге яшь шагыйрьләргә якты маяк булырдай көчле учак, көчле үрнәк күрдек. Бүген әнә шул маякка таба — иҗатның шундый көчле Учак сыман балкып торуына таба баруны, хәрәкәт итүне — каян һәм нәрсәдән башларга соң?

Минемчә, безгә биредә эшне тәрбия өлкәсендәге бер ялгыш карашны төзәтүдән башларга кирәк. Без балага бәләкәй вакыттан ук барысын да бирәбез, ә аның үзеннән сорарга онытабыз. Аның үзеннән сорауны кирәк диеп тә санамыйбыз... Без балага ашарга да бирәбез, кием дә бирәбез, үсә төшкәч, белем дә бирәбез — кыскасы, барын да бирәбез! Ә бит ул үзе дә — тере, ул үзе дә безнең кебек үк кеше, җан иясе! Шулай икән, алайса, нигә ,соң без аны һәртөрле актив хәрәкәттән, кеч-

кенә булса да көрәштән читтә калдырабыз? Аны нәрсә өчен дә булса тырышу, көрәшү процессына тартмыйбыз? Баланы пассив хәлдә тоту — минемчә, безнең бүгенге тәрбия процессының шактый зур кимчелеге. Бигрәк тә шәһәр җирендә!..

Әдәбиятта яшь язучыларны дөрес тәрбияләү мәсьәләсенә килгәндә дә нәкъ шулай. Югарыда күреп узуыбызча, хәзергә әле алар үзләрен бер нәрсә өчен дә җаваплы дип санамыйлар. Аларның яшәвендәге һәм иҗатындагы сүлпәнлек, эленке-салынкылык — бары тик менә шул халәт нәтиҗәсе генә. Социаль, мораль һәм рухи җавапсызлык кешене дә, иҗатчы шәхесен дә шулай сүрәнәйтә, акрынайта, әкренләп сүндерә.

Менә шушы зур сәбәпне бик яхшы аңлаганнан соң, безгә яшь язучылар белән эшләүдә киң колачлы практик чаралар комплексына күчәргә кирәктер. Нинди чаралар турында сүз бара соң? Чаралар шундый булсын: иң элек — яшь язучының үзеннән эш таләп ителсен!

— Мәсәлән? — дисезме?

Мәсәлән, менә болай. Соңгы елларда илебез мәктәпләрендә балаларга әдәбият укыту, әдәби әсәрләр аша әхлакый һәм рухи тәрбия, югары гражданлык тәрбиясе бирү проблема булып өлгерде, бик тә актуальләште. Әдәбиятның тормыштагы роле нык үсү, аңа ихтыяҗ нык арту, ә чынбарлыкта ул ихтыяҗның үтәлеп җитмәве проблеманы тагын да үткенәйтә.

Безнең яшь язучыларыбыз үзләренә конкрет эш итеп шушыңа алынсалар — ничек яхшы булыр иде бит! Аларның күбесе республикабыз башкаласы Казанда яши һәм, күрүебезчә, үзендә бернинди дә җаваплылык тоймыйча яши. Ә бит Татарстандагы 39 районга һәм шәһәребездәге 7 районга берәр яисә икешәр яшь язучы беркетелеп, алар балаларга әдәбият укытуда ярдәм итсәләр — һәммә яктан һәм һәркемгә файда булыр иде. Беренчедән, гомерләрендә әле язучы күрмәгән кечкенә балалар әдәбият кешесе белән аралашыр иде, аларга чын әдәбият рухы якынаер иде. Икенчедән, конкрет бер проблеманы уңай хәл итү өчен тырышу, кайбер урыннарда хәтта шуның өчен көрәшү — безнең яшь язучыларыбызны кеше һәм шәхес буларак ничек ныгытыр, үстерер иде! Аларга язу өчен никадәр тормыш материалы булыр иде, яшәешнең тере суты керер иде!

Әле бит мәсьәләнең тагын бер ягы бар: урыннардагы әдәбият түгәрәкләре күп җирдә бик сүлпән эшли, балаларны эстетик һәм әхлакый тәрбияләүдә аларның эшчәнлеге тиешле роль уйнамый. Ә бүген Казанда яшәүче яшь язучы теге яки бу районлагы, авылдагы әдәби түгәрәк өчен җаваплы булса, шуның өчен янып йөрсә,— шулай ук күп яктан файда бит!

Урыннардагы мондый эшчәнлек үз әсәрләребез, үз китапларыбыз таралуга да искиткеч булышыр иде. Югыйсә, алда күреп узган төсле: без әле хәзергә үзара зарланышудан бер адым да уза алмыйбыз. А. П. Чеховның «Алтынчы палата» хикәясендәге сүзен чынга ашыру өчен практик яктан берни дә эшләмәүче мескен интеллигентлар хәлендә әле без!

Партиябезнең XXVII съезды илебездә зур социаль һәм рухи көрәш башлануын, бүген беркем дә аннан читтә калмаска тиешлеген басым ясап әйтте. Ә язучылар, иҗат кешеләре — алар бит гомер-гомергә бөтен көрәшләрнең башында, алгы сафында барганнар... Бу юлы да, югары максатлар өчен көрәшүнең, бу этабында да, һичшиксез, шулай булырга тиеш!

Көрәш сүздә генә түгел, эштә дә барырга тиеш! Чөнки әйләнә-тирәбездә безнең үзебезгә бәйле булган, безнең үзебездән торган бик күп нәрсәләр бар. Шуңа күрә хәзер язучының, иҗат кешесенең әдәбиятта гына түгел, ә конкрет яшәештәге позициясеннән дә бик күп нәрсә бәйле.

Бөек Октябрь социалистик революциясе елларында А. М. Горький әйткән ялкынлы сүзләр тагын искә төшә:

— Культура осталары, сез кем белән?

Чыннан да, бүген — революциянең яңа этабы дәвам иткән көннәрдә — иҗат кешесенең урыны тагы да ачык булырга тиеш. Ул һичшиксез алгы сызыкта булырга тиеш! Югыйсә, алда күреп киткән төсле сүлпәнлек, пассивлык, эленке-салынкы яшәү үзеннән - үзе килеп чыгачак.

*Уйлар яңадан да учак янына алып килә...*

*Бүгенге тормышта халкыбыз алып бара торган зур көрәш учагы... Чын әдәбият һәм сәнгатьтәге көрәш уты... Чын талантларның көчле учак сыман балкый торган иҗатлары...*

*Болар барысы да бүген безнең алда бер һәм бик зур учак булып гәүдәләнә... Яшь язучыларыбыз кабызган учак та, һичшиксез, сүрелмәс дип ышанабыз.*

*Ләкин шулай да, аларның үзләрен бу сорау ешрак бимазаласын иде. Намус ялкыны булып, ул аларны ешрак борчысын иде:*

*— Учагым сүрелмиме?..*

*— Учагың сүрелмиме?!*

# СӨЮНЕҢ СЫНАУЛАРЫ БАР

Кулыма каләм алып, уйланып-дулкынланып, кайчак хисләр давылыннан «ышыкланырга» мәҗбүр була-була, бирелеп-йотылып укыдым мин бу лирик әсәрне — «Болын» повестен.

Без әдәбиятны сүз сәнгате дибез һәм аның беренчел зарур элементы да тел дибез. Фәүзия Бәйрәмованың «Болын» әсәре турындагы фикерләрне дә нәкъ менә шул зарур элементның үзенчәлекләреннән башлап китәсе килә.

Махсус сайлап түгел, балаларча күземне йомдым да бармагымны «Болын» повестенең бер битенә төрттем. Укыйм: «Мин, куркынып, күзләремне йомам, ләкин зиһенем инде уянган, җаным, почмакка поскан кош баласыдай, бу ак халатлы кеше янында куркып дерелди, бәргәләнә иде». Яки менә башка өзек: «Ялкын күпме генә бәргәләнмәсен, ташка ут капмаячак, каралып, бәгырендә эзе калса да, таш стенага ут капмаячак иде! Ялкын гына, үз эссесеннән үзе көеп, хәлсезләнеп, бер-ике сулкылдар да, сүнеп, аның аяк астына егылыр...»

Әсәрдә без Кеше дигән бөек җан иясенең тел һәм сүз ярдәмендә галәмәт катлаулы, үтә нечкә-импульсив физиологик һәм рухи хәрәкәтләрне дә гүзәл тере картинага, фәлсәфи фикер-образларга әверелдерә алуына сокланабыз. «Көйнең, кылдан нечкәреп, җаннарда чыңлаган, өзеләм-өзеләм дип, бәгыремдә бәргәләнгән бер мизгелендә мин түзә алмыйм — салкын пианино клавишаларына капланам да үксеп елап җибәрәм. Бу — үзе бер көй. Бу — үзе бер моң. Бу — үзеңә килгән мәхәббәтне, бәхетне тоеп елау. Бу — сагыну...»

Миңа Фәүзия Бәйрәмова ниндидер бер универсаль музыка коралында бик тә якты, салмак моңлы да, кинәт дәртле, давыллы-өермәле дә, хәсрәтле-сагышлы да, өметле дә лирик-драматик симфоник поэма башкарадыр кебек тоела. Ләкин төсле музыка бу, сурәтле музыка бу! Әлеге могҗизалы универсаль уен коралының исеме — тел!

Яки миңа Бәйрәмова әдәби киергедә бик тә асыл-затлы шәлъяулык чигәдер сыман. Шактый кара-караңгы фонда мин чуар чәчәкле болынны да, кышларда бу болынның «ап-ак күңелен» ачып, «җил малаена дулкын-дулкын, дулкын-дулкын истәлек» көртләр калдырырга «тулы ирек биргәнен» дә, гел «гөжләп торган кебек урманның» куерып үскән абагаларын, пәрәвезләрен, «дуамал агым» белән аккан елганы да һ. б. реаль картиналарның, предмет-детальләрнең җете-ачык сурәтләрен күрәм, исләрен тоям. Һәм иң сөендергәне — бу әдәби шәлъяулыкка Бәйрәмова фәрештәдәй шәфкатьле, акыллы-зирәк, «бала гәүдәле, ап-ак чәчле, ап-ак җанлы» Рәйханә әбинең җемелдәп торган күркәм, җанлы портретын чикте. Көмеш сәйләннәр белән бизи-бизи чикте! Бу шәлъяулыктан авторның авыл көнкүреше, бала тәрбиясе, вакыт-гомерләр агышы турында хак-зирәк сүзләрен, образлы гыйбарәләрен дә укый алдым мин. Бу җете, затлы чигешне бизәр өчен, автор табигый төсләрне, нурлы җеп, чын сәйләннәрне каян алды? Ул тылсымлы, бай йомгакның исеме — тел!

Автор сурәт-бизәкләрне, кичерешләрне, фикерләрне баета, көчәйтә бару өчен пульслы ритмда, сүзләрне, идиомаларны яки бәйлек, теркәгечләрне, хәтта «блок-текст»ларны кабатлау алымы белән яза, образлы рефреннарны еш, кыю куллана. Һәм бу стиль әсәрне бик тә эмоциональ иткән. «Ә мин тотам да... ә мин тотам да «Тәфтиләү»не уйный башлыйм... сизелер-сизелмәс сулкылдап яткан хисләрне ычкындырырга иде бәйдән... Тугарылсыннар иде, җүләрләнсеннәр иде...

Хәзер мин чыгам да...

Юк, башта киенәм. Нык итеп, җылы итеп. Хәзер мин чыгам да...

Анда — минем тиле балачагым, анда — минем кыргый үсмерчагым, анда — минем сөер яшьлегем...»

Күрәсез, автор еш кына кыска җөмләләр белән яза. Ләкин бу кыскалык хикәяләүгә аз гына да хилафлык китерми, киресенчә... «Мин инде кичке уеннарга чыкмый башладым. Капланам да ятам, капланам да ятам. Әби уфылдап йөри, йөри, өйгә бер керә, бер чыга. Дәшми. Сорашмый».

Әсәрдә монолог-диалоглар төрле структив рәвештә, халыкчан бай, табигый, укырга җайлы синтаксик чаралар белән баетылган. Диалоглар кыска, күп очракта самими, ихлас. Мин персонажлар теленнән аларның яшен, настроениесен, кыскасы, кемлеген бик тиз шәйләп-белеп алам.

«— Болынга да барырлык түгелме?

— Ю-ук! Кая ул! Анда бөтенләй котырган буран. Әйтәм бит, үрмәләп диярлек килдем».

Чын-чыннан, повестьның теле соклангыч, укучы хисләрен-уйларын дөрләткән беренчел учагы, җиле дә телдәдер әсәрнең! Безнең әдәбиятка Фәүзия Бәйрәмова дигән талантлы сүз рәссамы килә. Ак юл телик, иҗади еллар телик аңа!

Инде хәзер, әйдәгез, шул сәнгатьле лирик телнең әсәрдә нинди максат-идеягә хезмәт итүен белергә тырышыйк. Повестьның фабуласы гади, сюжеты — бер сукмаклы. Дөрес, башта повестьның әдәби увертюрасы безне ниндидер «шомлы болытлар, ап-ак томаннар эченә ташлап», ниндидер упкын читләрендә йөртеп адаштыра, сагайта. Әдәби «мин»нең хыял, хис, фикерләре шактый буталчык. Гади укучы өчен бигрәк тә. Биредә реаль болын да, «гомер болыны» да, «кочагын җәеп, минем каршыма йөгерер кеше» — өмет, идеалны эзләү дә, чарасызлык, упкын-үлем дә бар сыман. Кыскасы, чамасыз символик өермә...

«Аннан, җүләр, диләр дә китеп баралар. Ә мин бит җүләр түгел, мин бары тик башкаларга охшамаган гына. Ә нигә кеше кешегә охшарга тиеш соң әле?» Бер реаль әзгә төшәбез бугай. Тик, кызганыч, бу җөмләләр, мин теләсәм-теләмәсәм дә, шул мизгелдә үк икенче бер охшашлыкны — хәтеремдә Шәриф Хөсәеновнең «Зөбәйдә — адәм баласы»н калкыталар. «Җүләр дә җүләр» дип, гаиләдә Зөбәйдәнең дә теңкәсенә тияләр ләбаса. Бәлки язмышлары охшаштыр, холкы-табигатьләре? Бер үк буын, бер үк кала вәкилләре бугай әле. Зөбәйдә безгә күптән таныш, ә менә бу Алсу атлы кыз нindирәк? Алсу? Бу исемне әйтүгә Һади Такташның:

Салкын карга басып, Алсу килә.
Үзе көлә,
үзе сөйкемле,
үзе усал,
үзе болай бер дә
усал түгел кебек шикелле...

— дигән, гомерлек булып хәтергә сеңгән шигъри юллары яңгырап куйды да, «җирне, бүгенгене, һәрнәрсәне өзелеп сөюче» Алсуның классик нурлы образы балкып алды. Атаклы шагыйрьнең, мөгаен, шушы гүзәл образын якын иткәнгәдер дә хәзер безнең халыкта Алсу исемле хатын-кызлар галәмәт күп. Фәүзия Бәйрәмова да моны истә тоткандырмы — белмим. Ләкин халык хәтерендә Такташ Алсуының гомер тере портреты саклануын белә торып, икенче бер Алсуның образын гәүдәләндерергә җөрьәт итү — шактый хәтәр җаваплылык, тәвәккәллек бит!

Буласы булган, буявы сеңгән икән инде — Бәйрәмованың Алсуы ниндирәк шәхес соң әле?

... Алсу атлы бу кыз бала шәһәрдә туып үскән. Ләкин һәр җәйне авылга, әбисенә кунакка кайта ул. «Ул кайтуларны мин әкият дөньясы кебек итеп көтеп ала идем»,— ди кызый. «Әгәр җәйләрен авылга кайтмасам, мин акылдан шашар идем. Җәйләрен эссе асфальт урамнарда бәрелеп-сугылып йөргән яшьтәшләремне кызганам. Аларның балачаклары бөтенләй юктыр кебек. Балачакка дип бирелгән еллар бар, ә балачаклары юк...» Әлбәттә, яшүсмер кызыйга автор көчләп әйттергән, авылны шәһәргә бик тә капма-каршы куйган катгый-наив фикерләр генә болар, әдәби фокуста көчәйтелгән максимализм! Ләкин, бигайбә, әлегә яшьлек чикләнгәнлеген, кайнарлыгын гафу итеп, яшүсмернең хаятеннән риясыз матурлыкны, сафлыкны күбрәк эзлик.

Алсу өчен «авыл ул могҗиза иде! Ул әкият иде. Ул моң иде».

Алсу-яшүсмер, «авылга кайтуына, аякларыннан кыйммәтле шәһәр туфлиларын салып ташлый да болынга йөгерә. Беркемнән курыкмыйча, оялмыйча, әдәп-кагыйдәләрнең дөньяда барлыгын да онытып (ай-һай?), тилереп, кыргыйланып, болынга йөгерә». Аның чәчәкле болынны бик яратуы да, хисле кыз, зирәк, күзәтүчән булуы да безне ышандыра. «Кара инде, болында җир җәй көнендә дә салкын була икән бит, куе үлән арасына кояш нуры төшеп җитми микәнни?» Әлегә, беренче карашка, бу яшүсмер кыз самими да, хыялый да. Ул чәчәкләрне өзми, чөнки — «өзгәч, алар шунда ук шиңәләр, ямьсезләнәләр». Әлегә аңа «гел шулай җәй булыр кебек, гел шулай болын булыр, чәчәкләр булыр кебек...»

Ләкин изге, бөек даһи Табигатьнең мәңгелек үз законнары, мәңге тере катгый-камил бокрасы — диалектикасы бар шул. Кеше заты бу мәңгелек хәрәкәтне, матдә-организмнарның тере бокра чылбырларын, дәү дөньяның ихтыяҗларын, кырыкмаса-

кырык мәшәкатьле илнең-көннең таләпләрен күптән белеп яши. Вакыты җиткәч, «кышын малларны ач тотмас өчен, сыерлар күп итеп сөт-каймак бирсен өчен», авыл халкы әлеге чәчәкле болынны печәнгә чаба. Әлбәттә, «кыш буенча мәктәп белән үзе яшәгән йорт арасыннан башка дөнья күрмәгән» Алсу яшүсмер җанында бу «усаллык» — кыңгырау чәчәкләрен печәнгә чабучы, «ак каенкай, мескен каенкайны утынга» кисүче, гомумән, «матурлыкка битараф» булып, «табигатьтәге һәр нәрсәне файдалы-файдасызга бүлеп кенә кабул итүче» авыл кешеләренә карата нәфрәт, протест, рәнҗү, әрнү-өзгәләнү хисләрен дөрләтә, йөгергән сукмакларына яшьләрен койдыра. Яшүсмер шәһәр кызының бу наив-самими рухи драмасына да без елмаю катыш ышанабыз. Әнә бит ул, өченче җәйдә үк үзе дә чәчәкле болынның печәнгә чабылырга тиешлегенә инанып тынычланды ич. Тормыш — илаһи табиб шул. Кызыйның аң-тойгылар эволюциясен автор күрми узмады.

Башта шулай, болын да болын дип, әбисенең «йөрәгенә төшкән» кызый, инде «урман дип саташа» башлый. Бу сәер кызыйның, нигәдер, һаман да урманда адашасы килә. Ләкин «йөри торгач, барыбер урман кырыена килеп чыгасын белә» үзе. «Мондагы урманнар да кечкенә бит. Аларның кеше аягы басмаган урыннары юктыр инде. Әнә бит күпме сукмак, ат, машина, көпчәк эзе. Ә мин аларның берсеннән дә бармыйм. Чәчләремне куаклардан йолкыта-йолкыта, битләремне тырнатып-канатып, кеше йөрмәгән җирләрдән, үҗәтләнеп, үземә юл салам...»

Әнә шулай, «үҗәтләнеп, үзенә юл» салырга, шуның белән үзенең «мин»леген расларга, әлегә үзе дә төгәен белмәгән ниндидер идеал-йолдызын табарга тырышкан кызыйның бу кыланыш-гамәлләре дә безне ышандыра, мавыктыра, еракта калган яшүсмер елларыбызны искә төшереп, сагыну-моң катыш куандыра. Автор бу урында да үз персонажы — яшүсмернең рухи-физик әзләнү процессын тормышчан тасвирлый, психологик логикада хата юк, әдәби текст реаль матур бизәк-буяулар, зирәк күзәтү-фикерләр, символик мәгънәләр белән тулы.

Көннәрдән бер көнне:

«— Әй син!

Кайсы куак шулай эндәште миңа? Мин инде чытырманлыкта басып торам, яшь каплаган күзләрем берни күрми...

— Сиңа әйтәм! Нишләп чәбәләнәсең анда баядан бирле?

Чуалып, күземә төшкән чәчләремне бер селтәнү белән артка алып ташлыйм, атылып, куаклар арасыннан чыгам. Каршымда — бер малай. Авыл малаена охшаган.

— Тропинка салам.

— Нәрсәгә кирәк ул сиңа тропинка? Менә бит сукмак янында гына.

— Булса ни! Ул бит — синең сукмак. Ә минем — үземнеке.

— Урманда һәркем үзенә юл салмый инде. Әллә җүләрме соң син?

— Әйе шул, җүләр, җүләр! Ә сиңа барыбер түгелмени?

— Түгел шул. Син бит анда куакларны сындырасың. Әнә күпме чәчәкне таптагансың инде.

Урманда кинәт бөтен кошлар берьюлы сайрый башлады...»

Җан-хәрәкәт, реаль матурлык, интонацияләрнең табигыйлеге белән балкып торган бу вакыйга-очрашуны минем кат-кат укыйсым килә. Безнең сәер Алсуыбыз «капкара чәчле, кап-кара күзле, сызып куйган кебек матур кара кашлы» үз яшьтәше Алмаз белән беренче тапкыр менә шулай очрашты. Сүзләреннән сизгәнсездер: күрше авыл малае Алмаз, безнең героинябызга караганда, табигатьне мәгънәлерәк ярата, кадерли төшә икән бит! Һәм ул акылы-холкы белән дә Алсудан өстенрәк, ягымлырак.

Шул очрашудан соң, Алсу кызкаебызның күңелендә «әллә нинди сәер тойгы... утлы очкын булып кабынды — гел иртәгә бәйрәм булыр кебек...»

«Утлы очкын» көчәя-дөрли бара. Иртәләр-кичләр, бар әйләнә-тирә яңа төс-нурлар белән балкый башлый, әлегрәк ул аңламаган да, яратмаган да җыр-такмакларга яңа мәгънә, өмет, сагыну-моң иңә... Бар илаһи сөенеч-шатлыклары, татлы-ләззәтле хыяллары, шик-шөбһәләре, газап-михнәтләре белән беренче мәхәббәт килә. Үсмерләрнең беренче мәхәббәте!

«Мең йолдыз! Сез күрдегезме җирдә дә бер йолдыз кабынганны? Аның исеме мәхәббәт икәнен, ул безнең мәхәббәт, безнең өчен бердәнбер булган, кешелек тарафыннан беренче мәхәббәт дигән сагышлы һәм якты исем бирелгән мәхәббәт кабынганын күрдеңме син, мең йолдызлы күк?!»

«Болын» повестенда сурәтләнгән Алсу белән Алмаз мәхәббәте бары тик бу ике шәхескә генә хас сыйфат-төсләр, хис-тойгылар, ачыш-табышлар, ялгышу, югалту, сагышлар белән үзенчәлекле. Фәүзия Бәйрәмованың үз әдәби фокусы, зәвыгы, алым стиле, нәфис буяулары, этюд-картиналары бар.

Әмма кешелек дөньясы сынаган-раслаган, халыклар иҗаты, әдипләр каләме һәрдаим искәртеп-кисәтеп торган мәңгелек бер катгый канун яши җирдә: сөюнең сынаулары бар!

Мәхәббәтнең бардыр сират күперләре,
Һәр бәндәгә насыйп булмас үтүләре...

Шушы хакыйкатьне раслагандай, Алсу белән Алмаз мәхәббәте дә, еллар күперендә сынау үтә алмыйча, сүрелә дә сүнә...

Ике яшь йөрәкнең кушыла алмавына кем гаепле, нинди шартлар, кыенлыклар сәбәп булды?..

Без «Болын» повестендагы Алсуның Ш. Хөсәенов драмасындагы Зөбәйдәгә мәгълүм охшашлыгы, бу ике кызыйның да балалыктан олылыкка күчү чорында, үз шәхесләрен раслар өчен, «аяусыз көрәшүләре», ә өлкәннәрнең, шул табигый зарур булган катлаулы эволюцияне дөрес аңламыйча, аларга һәрдаим, «җүләр дә җүләр» дип, тупас мөһер сугулары хакында әйтеп уздык.

Юк, Зөбәйдә — бер дә җүләр түгел, киресенчә! Ш. Хөсәенов зур осталык белән күренештән-күренешкә Зөбәйдәнең галәмәт тере портретын, рухын ача бара. Зөбәйдә — адәм баласы, ул кешеләрсез сулый да алмый. Йорт-урам шау-шуларына, аяз күккә, якты кояшка аның тәрәзәсе һәрчак ачык, ә күңеле-җаны белән ул бар мохит-даирәгә нур-чаткы чәчрәтеп үсә.

«Мин бу авылда да япа-ялгыз...» Алсу авылның кешеләрен түгел, табигатен генә, анысын да үзенә кирәк дәрәҗәдә генә ярата икән бит. Шәһәрдә, мәктәбендә дә Алсу — ялгызак, аны «беркем яратмый. Кичәләрдә биергә дә чакырмыйлар. Үземә ишетелерлек итеп: «Круглая отличница»,— диләр, артымда: «Круглая дура»,— дип хихылдашалар. Ә миңа барыбер. Миңа шулкадәр барыбер — мин, аларны яратмаган кебек, аларга нәфрәтләнә дә алмыйм. Минем җаным, чабылган чәчәкләрне кызганып еларлык нечкә, үкереп аккан суларга сикерә алырлык көчле җаным — бу салкын дөньядан, бу кешеләрдән мең кат стена артында, мең кат стена артында!»

Дөрес, берара, мәхәббәтнең «бәхетле җүләр» чагында, бу кызый күңелендә кешеләргә мәхәббәт чаткысы елтырап ала. Ләкин бу чаткы тар-йомык күңелдә тиз сүнә, аның җаны һаман тормышка, кешеләргә битарафлык, рәнҗү, сагыш белән тулы.

Бу кызый менә ничегрәк фикер итә: «Мин үземдә, белемем ерта барган саен, хиснең, хыялның, мәхәббәтнең һаман арткарак чигенгәнен тоям...

Миңа уналты яшь. Мин үземдә зирәк аксакаллар акылы сизәм. Ә хис — юк». Нәкъ менә шундый халәтен сизеп-белеп алгач та без, повестьның унбиш-уналты битен укуга, бу кызыйның Алмазны тиң күрмәячәгенә, аларның кушыла алмавына ышанабыз. Чөнки чыннан да алар «икесе — ике дөнья кешеләре». Чөнки эгоист романтик бу кызыйның әлегә дөньяда үз мәнфәгать-ихтыяҗлары гына бар. Хәтта ул мәхәббәттә дә «алласы урынына күреп» үзенә табынучыны эзли. Ә «җир малае» Алмаз исә безнең Алсуыбыз «фанатикларча инану белән идеалга әйләндергән бөек» җан түгел, ул артык гади, гадәти. Шулай итеп, мәхәббәтнең тәмам сүрелеп-сүнүенә сылтау да табылды. Алсу яраткан чәчәкле болынны Алмаз сөреп аткан!

«Болынны сөрү кирәкме, кирәкмиме, дөресме, дөрес түгелме — бу турыда әсәрдә берни дә әйтелми» — дигән фикерләр булды безнең матбугатта. Ә бит повестьта бу мәсьәләгә карата авторның фикерләре ачык. Авыл халкы исеменнән Рәйханә әби теле белән әйттерә ул хөкемен:

«— Үзебезнең авылдан берәү дә риза булмады. Прсидәтелнең аякларына тезләнеп ялвардылар, кагылма болынга дип. Ай-ваена карамады халыкның...» Халык, әнә, карышып та караган, ул болынның печәнен чабарга да төшмәгән икән. «Үзебезнекеләр риза булмагач, Сарылыдан килеп сукаладылар... Алмаз сукалап китте болыныбызны. Су эчәргә дип кергән иде, бирмәдем, суым юк, дидем. Йөзенә күтәрелеп карыйсым килмәде, йөзенә...»

Беренче мәхәббәт «күпере» әнә шулай «дөбердәп җимерелеп ишелеп төшкән»нән соң, күңелебез белән теләмәсәк тә, Алсуның дуамал холкын белгәнгә, безнең уйлар инде, әсәрдәге вакыйгалардан узып, кызның язмышын алдан фараз итә башлый. Бу кызый, сөйми-яратмый гына, кемгәдер, очраклы берәүгә кияүгә чыгар, һәмишә саф мәхәббәтне сагынып, юксынып, ә үзе дәртсез, хиссез платоник мәхәббәттән газапланыр...

Бәй, «Болын» повестенда да шулай булып чыкты. Алсу танышыбыз да, үзе дә интегеп, Гомәр атлы инженер ирен дә интектереп, һәмишә анасын хафалап-бимазалап, җиде ел гомерен исраф итте. Аның аңында ил, җәмгыять мәнфәгатьләре дә, тормыш-гаилә ихтыяҗ-мәшәкатьләре дә, ир кайгысы да, бала хәсрәте дә булмады. Ул бөтен нәрсәгә дә битараф булып, бар мохит-даирәгә нигилистик нәфрәт белән карап, «миллион җанлы шәһәрдә дә» үзенә берәр дус-иш, хәтта якынрак иптәш тә таба алмыйча, тук тормышта да ялгызлык газабы чигеп, үзенең хыялый мизантроп җанында казынып ятты. Тымызык күлне корт басар дигәндәй, нәтиҗәдә, тәмам физик-рухи хәлсезләнеп егылды, психологик авыруга сабышты...

Алсуның бу мизантроплык чире, безнеңчә, аның икенче зур бәласе — иҗтимагый социаль яктан инфантлыгы, җитлекмәгән булуы белән аерылгысыз бәйләнгән.

Укуын тәмамлагач та, иптәшләренең күбесе авылларга укытырга китеп барганда, кайчандыр болын, чәчәкләрне яратам дип йөргән безнең Алсуыбыз ире Гомәр ярдәмендә Казанда, «зур бер оешмага тәрҗемәче булып, җайлы гына урнашып» калды. «Мин моңа уңайсызланмадым, җаным да борчылмады. Мин бу хәлләрнең барысын да шулай тиешле итеп кабул иттем».

Бәлки, ниһаять, үзе эшли башлагач, хезмәтеннән дәва табар, мантып китәр Алсу? Әмма хезмәт аңа ни юаныч, ни максат, ни илһам-сөенеч бирә алмый. Повестьның башындарак Алсу кызый: «Мин кире чигенә алмыйм. Мин бүген шушы упкын каршында куркып артка чигенсәм, гомер юлым гел чигенүләрдән генә торачак! Әйләнгеч юллар эзләүдән торачак! Башкалар салган сукмаклардан шуышып барудан торачак! Нинди мескен киләчәк! Юк, бу киләчәккә риза булганчы, мин, үзем теләп, кайнап торган упкынга сикерәм»,— дип безне куандырган иде. Ә повестьның соңына табарак инде: «Әле утыз яшемә дә җитмәс борын, мин инде арыган идем, минем тормышымның алдыннан түгел, артыннан сөйрәлеп барырга да көчем, теләгем юк иде»,— ди бу ханым. Шулкадәр ап-ачык социаль, рухи деградация нилектән булды? Берниди политик-экономик, социаль сәбәпләр дә юк, тормышның кыен барьерларына, көтелмәгән бәла-казага да очрамады ич ул!

Ниһаять, каты авырудан соң, соклангыч осталык, акыл һәм хис белән тасвирланган бик тирән-катлаулы психологик кичерешләрдән соң, Алсуыбыз чын-чыннан уянып китә! Үз үткәннәренә критик акыл белән бәя бирә алырлык җиңүгә табан атлый. Һәм менә уянгач, котым чыгып карап торам: мин тормышта иң зур байлыктан мәхрүм ителгәнмен — кешеләрсез калганмын! Артык болай яшәргә ярамый иде. Болай яшәү җинаять иде. Чеховка таянып әйтсәк, кешенең үзеннән-үзе канәгать булмавы — бу инде аны үстерә торган батарея. Шөкер, Алсу да, барыбызны да шатландырып, якты, миһербанлы эволюция тантанасына якынлашты.

Без әсәрнең кимчелекләрен сүз җаенда күрсәтә бардык. Әмма тулаем чын-чыннан шунысы бәхәссез: Фәүзия Бәйрәмова үзенчәлекле, моңача әдәбиятыбызда күренмәгән җанлы образ тудыра алган. Әлбәттә, Алсу — авыр холыклы, каршылыклы, аяныч четерекле персонаж. Без аны укучыга уңай герой дип тәкъдим итә алмыйбыз. Ләкин әдәбиятта, безнең реаль чынбарлыктагы кимчелекләребезне күрсәтү өчен, андый Алсулар да яшәргә хаклы бит. Янә кабатлап әйтәбез: г ы й б р ә т өчен!

**Фаяз ДУНАЙ.**

# ЙӨРӘКТӘ НИЛӘР БАР?

Шундый мизгелләр була: күңел еш кына көзге бакча кебек бушап кала. Кәефсез, сырхау кеше сыман үз-үзеңне кая куярга белмичә изаланасың, җәфаланасың. Тәнеңдәге һәр күзәнәкне ялгызлык изә, төшенке хисләр биләп ала. Әгәр дә нәк шул чакта күзеңә нииндидер китап чалынса, үзең дә сизмәстән, кайчандыр югалткан кадерле әйбереңне тапкандай сөенәсең. Җанга шатлыклы-куанычлы хисләр тула.

Китапның тылсымлы кодрәтен сүз белән генә аңлатып булмыйдыр, күрәсең...

Һич арттыру булмас: шагыйрь Фәннур Сафинның «Күкчәчәк» исемле яңа китабы[1] белән танышуым нәк шундый халәт вакытына туры килде.

...Болдырга ук чыгып кунак көткән хуҗа төсле, китапның беренче битендә урын алган «Яшик!» шигыре сине ачык йөз белән каршылый:

*...Йөрәгемне мин сиңа тапшырам,—*
*Ташлама җиргә, югалта күрмә.*
*Ул йөрәктә бит син үзең, үзең!*
*Әйдә үз анда, үз син, үз түргә!*

Ф. Сафин моннан шактый еллар элек язган «Музей ачтым...» шигырендә дә (минемчә, ул шагыйрьнең иң уңышлы әсәрләреннән иде) безне бер мәртәбә үз йөрәгенә дәшкән иде инде:

*...Яңа музей — минем йөрәгемдә,*
*Килегез сез аңа,*
*Кешеләр!..*

Чакырган җиргә килми калу — әдәпсезлек. Килдек. Шагыйрьнең гадәти булмаган музее белән таныштык.

*Мин гаҗәеп музей ачтым.*
*Анда*
*Фатих Кәрим язган каләм бар.*
*Мин өр-яңа музей ачтым.*
*Анда*
*Кутуй кайта дигән хәбәр бар.*
*Минем музеемда Мөҗәйләрдән,*
*Алишлардан яңа хатлар бар.*
*Анда Җәлил ярсып шигырь укый!*
*Ә янында...*
*Аның башын кискән балта бар...*

Һәм, без, әлбәттә, күңелдә тетрәндергеч тәэсирләр уяткан бу йөрәк-музейдан канәгать калдык. Рәхмәтле булып калдык.

Хәзер менә шагыйрь укучыны кабат үз йөрәгенә дәшә.

Түргә узар алдыннан, кыенсынып кына, шагыйрьдән гафу үтенәм: бераз соңгарак калып килдем («Күкчәчәк» китабы 1985 елда басылып чыкты). Безнең татарның гореф-гадәте шундый инде аның: чакырган җиргә бераз көттереп, соңлабрак килергә ярата...

Түргә узам. Кинәт күзгә яз сулышы орынгандай була. Гүя, бүректән арыган, кояш нурларын тансыклаган чәчләрне язгы җилләр тарап-тарап ала, яңа үләннәр арасында үз бәясен белеп кенә югарыга үрләгән табигать хушбуйлары — умырзаялардан һәм ландышлардан бөркелгән ләззәтле исләр борынны кытыклап уза...

Мәгълүм ки, һәр шагыйрьнең яраткан фасылы була. Үзенең бер халәтен чагылдырган «Уйчан көз» дигән шигырендә «Мин — уйчан көз. Кемдер, бәлки, яздыр...» дисә дә, Фәннур Сафинның яраткан фасылы яз булырга тиеш дигән уй туды миндә. Ни өчен дигәндә, яңа китапта урын алган шигырьләрнең күбесе шундый тәэсир калдыра. Сүземне раслау өчен, төрле шигырьләрдәге аерым юлларга гына тукталам:

*Без көткән яз күкрәп килер әле...*
(«Яз килер»)

*Көзләрне дә язга охшатам!..*
(«Көзен чәчәк аткан алмагачтай...»)

*Язлардан соң язлар килеп*
*Гомерләргә ялганса...*
(«Күңел нишләр?»)

*Инде күпме сиңа яз булып та,*
*Таң булып та сөйләп карадым...*
(«Инде күпме сиңа...»)

Күргәнебезчә, шагыйрь язга битараф түгел. Ул аны үзенчә ярата, үз итә — мөнәсәбәтен белдерә. Шагыйрь күңеле язга еш тартыла, чөнки аның өчен яз ул — наз, уяну. Яз — яшеллек, яшьлек. Яз — табыну, сагыну, учак кебек кабыну...

Ф. Сафинның моңарчы дөнья күргән китапларындагы шигырьләрдә яшьлек кайнарлыгы ташып-ургылып торган булса, яңа китапта исә ул бераз сүлпәнләнә төшкән. Бу аңлашыла да: шагыйрь төрле үзгәрешләр кичергән, уй-фикерләү басынкыланган, салмакланган. Дөньяга караш та хәзер бөтенчәрәк — ир уртасы булып өлгергән шагыйрьнеке. Бәхәссез: вакыт үз дигәнен эшли. Табышлар өмет иткәндә, югалтулар бүләк итеп куйгалый. Куәт-дәрманны сыный. Шушы җәһәттән, Ф. Сафинның чордашы шагыйрь Мөдәррис Әгъләмовның:

---

[1] Сафин Фәннур. Күкчәчәк. Казан. Татарстан китап нәшрияты, 1985 ел.

*...Килеп төшә вакыт — янъча генә*
*Бар да була ул дигәнчә генә,—*
дигән сүзләренә кушылмыйча булмый...

Шигърияттә «лирик мин» дигән бер төшенчә бар. Рецензияләрдә, тәнкыйть язмаларында «шагыйрьнең лирик герое болай уйлый», «лирик геройның рухи дөньясы шундый халәттә чагыла», дигән кебегрәк сүзләрне бик еш очратырга мөмкин. Фәннур Сафинның «Тынлык» дигән китабы турында язган рецензиясендә яшь тәнкыйтьче Ә. Сәхәпов «лирик герой»ны үзенчә күзаллап болайрак тасвир кылды: «...ул — искиткеч оптимист табигатьле, тормышны, яшәүне җаны-тәне, бар күңеле белән сөюче ихлас кеше. Ул — табигатьнең моңлы бер баласы! Фәннур Сафинның лирик герое яшьлек романтикасы белән канатланган көчле рухлы, нык үзәкле яшь кеше. Аның мәхәббәте ихлас, сөюе самими, якты. Ул бераз хыялыйрак табигатьле дә...»

Лирик герой турындагы мондый күзаллауны беренинди үзгәрешсез бүтән шагыйрьләр иҗатына карата да әйтеп булыр иде дип уйлыйм. Шуңа күрә, кемгә ничектер, мин «лирик герой»ны аңлый алмыйм, аны кабул итә алмыйм. Шагыйрь үзе булырга тиеш шигырьдә, ә ниндидер лирик герой түгел. Кояш турында язамы шагыйрь, әллә кош исеменнән язамы — аның «мин»ен («лирик мин» түгел!) гади укучы да күрергә тиеш. Бу урында Сергей Есенинның мәгълүм сүзләрен искә төшерү урынлы булыр кебек. «Минем биографиям — шигырьләремдә»,— ди ул. Моны шәрехләп тору кирәк түгелдер, шәт?!

Ышанып әйтергә була: Ф. Сафинның «мин»е шигырьләрендә бар. Бер генә мисал китерәм. Менә «Күзгә сурәт» дигән сигез юллык шигырь:

*Сурәт кебек уйга талган урман,*
*Җил исмәүгә, ахры, аптырап.*
*Күз кысарга куркып кызаргандай*
*Тып-тын калган нәни бер яфрак.*

*Күзгә ачы җилләр килерләр дә*
*Карурманны ярсу итәрләр.*
*Ә яфракны алар үзләренә*
*Юлдаш итеп урлап китәрләр!..*

Карурман, җил, яфрак. Халык, язмыш, шагыйрь. Сигез юллык шигырьгә халык һәм шагыйрь язмышы сыйган. Шигырьдә үткән бар, бүген бар, киләчәк бар. «Мин» дигән сүз юк, әмма «мин» бар!..

Яхшы шигырьгә тылмач кирәкми. Үзе өчен ул үзе сөйли. Аны бары тик күрә белергә, тыңлый белергә кирәк. Һәм, әлбәттә, аңлый-уйлый белергә дә кирәк...

«Күкчәчәк» китабы өч бүлектән тора: «Туган җир», «Йөрәктәге еракка» һәм «Хаклык җиңә!». Исемнәрдән күргәнчә, беренче бүлектә — туган җир, табигать, матурлык турындагы шигырьләр. Тынычлык өчен җан атып язган шигырьләр дә шактый:

*Җан омтыла һаман бу дөньяның*
*Гел кояшлы ягына, ягына...*
*(«Көлен чәчәк аткан алмагачтай...»)*

*Тормыш — Көрәш, әйе, Көрәш!*
*Беләктә көч барында,*
*Кирәк Ирек һәм Мәхәббәт*
*Сарайларын салырга!*
*(«Тормыш — көрәш!»)*

Икенче бүлектә урын алган шигырьләр Фәннур Сафинның да «Мәхәббәтнең Мәҗнүн премиясен» дәгъваларга лаек шагыйрь икәнлеге хакында сөйли.

*Ят күзләрдән сине эзлим,*
*Һәм табалмый интегәм...*
*...Үзем уйлыйм: без дә кавышмасак,*
*Чын мәхәббәт үзе кайда соң?*
*(«Сине эзлим»)*

— дигән шигъри табышларга сокланмый мөмкин түгел.

Ф. Сафин шигырьләренең бер матур сыйфаты бар: ул — гадилек. Мондый сыйфат шагыйрьнең җырларына да хас. «Без барыбер бергә булырбыз» (Р. Яхин музыкасы), «Җырымда юатырмын» (Б. Мулюков музыкасы), «Ялгыз көймә» (Риф Гатауллин музыкасы) җырларының халыкта популяр булуын шуның белән аңлатырга кирәктер.

Өй каршындагы бакчада аллы-гөлле чәчәкләр белән аралашып үскән кыргый үләннәр шикелле, китаптагы уңышлы шигырьләрнең ямен бозыбрак торган кайбер «кыргый шигырьләр» барлыгын да әйтеп булмас. «Курай турында баллада», «Егетлекне сынау өчен», «Яки шул ук...», «Очыш», «Күзгә сурәт» шикелле чәчәкләр янындагы «Ак бәйрәм», «Яңу», «Иске бакчада» кебек «кыргый үләннәрне» шагыйрь үзе яисә китап редакторы башта ук «йолыккан» булса, иллә дә шәп буласы булган...

Соңгы вакытта шагыйрьләрнең байтагы «Моң» авыруы белән авырый башлады. Тиз генә уза торган авыру булмады ул, хәерсез, йогышлы авыру булды: бөтен кыяфәтенә, иҗатына көләчлек, шаянлык чыккан шагыйрьләр дә, мин генә калмыйм дигәндәй, кирәгеннән артык моңлана башлады. Нишләмәк кирәк, моң — матур сүз шул, шайтан алгыры! Бу «авыру» Фәннур Сафин шигърияттен дә читләтеп узмады:

*Нинди моңсу, нинди рәхәт,*
*Елыйсы килә хәтта!..*
*(«Кылганнарың...»)*

*Моң сыярмы күңел ярларына?*
*(«Курай турында баллада»)*

*Ниндидер моң баш миенә*
*Кайнар моң булып тама...*
*(«Бер халәт»)*

*Моң булып күз нурың тарала...*
*(«Без барыбер бергә булырбыз!»)*

Кем белә, балкем, шагыйрь халкына моңлы булу килешәдер. Ә менә шигърият сөючеләргә аларның кирәгеннән артык «моңлы» булулары ошый микән?

Инде китапка исем биргән «Күкчәчәк» поэмасына килик. Ф. Сафин — моңарчы да поэма жанрында көчен сынап караган шагыйрь. Мин «Ак канатлы егет» поэмасын күз алдында тотып әйтәм. Әлеге әсәр белән бу яңа поэма арасында уртаклык бар. Ике әсәрдә дә сугыш чоры тасвирлана. Ике әсәрдә дә — бәхетсез мәхәббәт, язмышы кайгы-сагышка дучар ителгән яшьлек...

Поэманың кыскача эчтәлеге шуннан гыйбарәт: урмандагы яшел сукмак буйлап атлаган Зариф үткәнен, яшьлеген хәтергә төшерә. Ул «күкчәчәкле күлмәк кигән сылу Зәйнәп»кә гашыйк. Әмма Зәйнәп, ни сәбәптәндер, икенче берәүне үз итә, якынрак күрә. Сугыш. Зариф — фронтта. Аяусыз бәрелешләр, югалтулар. Бер бәрелештә Зарифның якын дусты Кәримов һәлак була. Җиңү! Сугыштан күкрәгенә медальләр тагып кайта Зариф. «Йөздән берәү исән калып...» Тик сөйгәне Зәйнәп авыру. Окоп казыганда үпкәсенә салкын тидергән. Зәйнәп үз иткән берәү дигәнебез — Зарифның күршесе — төрле имеш-мимеш тарата. Зарифның аңа җавабы. Сабыр туй. Зәйнәпнең вафат булуы.

*...Ул барыбер озак яшәмәде,*
*Риза түгел иде кебек туйга да...*

Зарифның ялгыз калуы...

Кыскасы, менә шулар хакында шигырь.

Күренгәнчә, әсәр үзәгендә — Зариф язмышы, аның бәхетле дә һәм шул ук вакытта бәхетсез дә язмышы. Шагыйрь әнә шул язмыш хакында сабыр гына сөйли, үткәзеп сөйли. Ул Зариф образын, аның эчке кичерешләрен тулаем бирергә омтыла, тормышка-яшәешкә карата булган мөнәсәбәтен оптимистик рухта тасвир кыла...

Күкчәчәк — символ, мәхәббәт символы. Ул әсәрнең башыннан ахырынача җылы, якты нур булып сирпелә. Бу чыннан да шулай. Күкчәчәктән генә киенгән Зәйнәп. Кәримов һәлак булган күл буендагы кызыл балчык белән буталып, гөлчәчәкләр янында берүзе исән-сау калган күкчәчәк... Күкчәчәкләр тулы хыялый алан Зарифның хәтерәнә еш төшә. Күкчәчәкле урман дөнья кебек шаулап Зарифны каршылый:

*Нигә кайттың кабат, көчле кеше,*
*Нәрсә җитми сиңа, туганым?..*

Поэма, гомумән алганда, күңелдә җылы тәэсир калдыра. Әмма, миңа калса, әсәрдә җитди генә төгәлсезлекләр дә бар. Мәсәлән, мин Зарифның якын дусты Кәримов һәм әлеге күрше егет образы бик үк ачылып җитмәгән дип саныйм. Ни генә әйтсәң дә, поэманың үзенә күрә сюжеты булырга тиешлеген онытмаска кирәк. Аннан соң, Зәйнәпнең ни өчен күрше егетне сайлавы да ахыргача сер булып кала. Күңелне тырнап торган шигъри юллар очравы да поэманың җегәрен киметә. Кәримовның үлемен хәбәр иткәннән соң, шагыйрь:

*Дусның соңгы каны тамган күлдән*
*Су эчәргә ярыймы соң?! —*

диюе белән, шагыйрь Рәшит Әхмәтҗановның «Учак» дигән шигырендәге мондый юлларны хәтергә төшерде:

*Сандугачлар янган утта*
*Җылынырга ярыймы соң?!*

Китап турында нәтиҗә ясап, шуны әйтәсе килә: Фәннур Сафин — барыннан да бигрәк — яшьлек шагыйре. Яшьлек аның кыйбласы. Шагыйрьнең үз кыйбласына һәрчак тугры булып калуына ышанам. Яңа китап — моның шулай буласына янә бер дәлил.

**Ләбиб ЛЕРОН**

# ШАГЫЙРЬ СҮЗЕ БЕР БУЛА

Узган ел әдәби җәмәгатьчелек күренекле шагыйрь Шәехзадә Бабичның 90 еллык юбилей тантанасын билгеләп үтте. Шул уңай белән Уфада шагыйрьнең яңа җыентыгы басылып чыкты[1]. Ш. Бабичның авылдашы һәм аның тормыш юлын, иҗатын өйрәнүче буларак, түбәндә яңа китап уңае белән туган кайбер тәэсирләремне уртаклашам.

Һичшиксез, яңа җыентыкны төзүдә һәм бастырып чыгаруда күп көч куйган Р. Бикбаев — хәзергесе көндә Ш. Бабич иҗатын тулы һәм тирәнтен өйрәнүчеләрнең берсе. Бу хакта китапта бирелгән кереш сүз һәм аңлатмалар бүлеге үк сөйләп тора. Шагыйрьнең тормыш юлы буйлап үзе йөреп чыккан шагыйрь Р. Бикбаев Бабичның инде сирәгәеп барган чордашлары, шәрикътәшләре, каләмдәшләре һәм сеңлесе Фәсәхәт апа белән якыннан таныш, алар белән күп еллар дусларча элемтәдә тора. Бу хәл шагыйрьнең тормыш юлына карата элегрәк әйтелгән фикерләрне һәм кайбер фактларны ачыкларга һәм үстерергә ярдәм иткән. Р. Бикбаев бигрәк тә Бабичлар нәселенең Әсән, Дүртөйле якларында торган урынын һәм ролен күрсәтүче бай фактик материал туплаган.

---

[1] Бабич Шәехзадә. Шигырьләр, поэмалар. (Башкорт телендә.) Уфа, 1985.

Бабич шигъриятен ачуда һәм аңлатуда исә авторга үз шагыйрьлеге ярдәмгә килгән. Ш. Бабичның катлаулы «күк поэзиясен», ашкынучан романтизмын авторниндидер космополитик концепция белән түгел, бәлки «халкына яктылык эзләп җиһанга очты» дип аңлата. Шагыйрь:

*Айга үрләп, нурда уйнап,*
*Күкрәгемне нурладым.*
*— Ит гафу әй, ай, дидем мин,*
*Нурларыңны урладым.*
*— Һич зарар юк, ал, диде ай,*
*Ал да чәч нур халкыңа;*
*Мин дә бит төн хакына*
*Алдым кояшның нурларын,—*

дип язган икән, Р. Бикбаевның сүзләрендә мең хаклык бар. Әйе, нинди генә авыр хәлдә калганда да, Бабич үз романтизмының реаль нигезен, халыкчан асылын югалтмады, туган халкыннан читләшмәде, аңа биргән антына тугры калды. Шулай булмаганда, «туфраклы мохтариять» идеясен үзенә көрәш лозунгысы итеп алып, бу көрәштә шашып адашмас та, соңыннан туры, төз юлга чыга да алмас иде ул. Яңа җыентыкка тупланган әсәрләр шагыйрь үткән шушы авыр һәм катлаулы юлны укучылар күз алдына китереп бастырырга ярдәм итә.

Һаман-һаман бер хакыйкатькә инана киләсең: бөек шагыйрьләр нинди дә булса милли кысалар эченә генә бикләнеп кала алмыйлар. Һәр зур әдип гомумкешелек улы булуга дәгъва итә. Ш. Бавич та — шундый әдипләрнең берсе.

Кереш мәкаләне укый башлау белән, бер нәрсә күзгә ташлана: автор шагыйрьне шыплатып кертеп утырту өчен, ниндидер кысалар эзли кебек. Әлбәттә, аның «башкорт шигъриятенең үсеш тарихында Бабич әсәрләре күренекле урын алып тора», «ул башкорт поэзиясендә беренчеләрдән булып Тукайга багышлап шигырь язды», һисә: «Бабичның тәүге шигырьләрендә башкортча сүзләр, үзенчәлекле грамматик формалар да әледән-әле күзәтелде» дигән юлларда хаклык бар. Бу тезисларның һәрберсен тарихи аңлатып була. Әйтик, Шәехзадә шәкертнең Тукайга багышлап шигырьләр язуы аның иң беренче чиратта татар әдәбияты традицияләрендә тәрбияләнеп үсүеннән килсә, башкорт сүзләре, башкортча формалар куллану шагыйрь туып-үскән, яшәгән Дүртөйле якларындагы татар-типтәр сөйләше закончалыклары белән аңлатыла. Дөрес, Р. Бикбаев язганча, «Бабичның гомер буе башкорт җырларына, кобаерларына, батырлар турындагы төрле легендаларга соклануы» да шик уятмый. Күңел шуңа гына ачына: нигә соң башкорт җырлары гына? Шагыйрьнең авылдашы буларак әйтәм: Эсән якларында саф татарча җырлыйлар, саф татарча хикәят һәм әкиятләр сөйлиләр, татарча бәет укыйлар. Шулай ук Шәехзадәнең берничә ел рәттән, казах далаларына барып, казах акыннары белән шигъри бәйгеләрдә алышып йөрүен, казах халык иҗатының, әдәбиятының йогынтысын кичерүен дә кереш сүзнең авторы онытырга тиеш түгел иде.

Р. Бикбаев алга табан да даимилек саклый. Ул: «Сабантуй һәм милли бәйрәмнәр» (1912) исемле әсәрендә Бабич башкорт халкының гореф-гадәтләрен җентекләп күрсәтте»,— дип яза. Мәгълүм булганча, сабантуй, җыен, карга боткасы кебек бәйрәмнәр татар, башкорт халыкларының уртак бәйрәмнәре; аларда уйналган күп уеннар, җырланган күп җырлар, йола күренешләре дә охшаш һәм хәтта уртак. Өстәвенә, Р. Бикбаев үзе дә элгәрерәк чыгарган бер хезмәтендә Ш. Бабичның беренче иҗат чорын (1912 еллар шул чорга керә) «гомумтөрки характерлы» дип билгеләгән иде (Р. Бикбаев. Ш. Бабич. Тормышы һәм иҗаты.— Уфа, 1981, 61 б.). Инде килеп, ул Бабич поэзиясен бер милли кыса эченә кертеп куярга тели. Бу хәлдән укучыда ялгыш фикер урнашып кына калмый, шагыйрь иҗаты да үзенең хәрәкәт орбитасын тарайта, бөеклеген югалта башлый...

Яңа җыентык,— һичшиксез, шагыйрьнең моңа кадәр дөнья күргән җыентыкларыннан иң тулысы. 1958 елда чыккан «Сайланма әсәрләр»дән аермалы буларак, яңа китапка «Бер тәмсил», «Кадим мулланың сүзе» һәм «Туфрак» кебек әсәрләр өстәлгән. Шагыйрь җыентыклары өчен аларның икенчесе генә яңалык булып тора. «Туфрак» шигыре Бабичның 1918 елгы җыентыгында, ә «Бер тәмсил» әсәре 1958 елда Казанда басылып чыккан татарча «Сайланма әсәрләр»дә дөнья күргән иде.

Сүз дә юк, җыентыкны төзүчеләр әсәрләр сайлауда төп принцип итеп оригиналдан куллануны алганнар. Шуның нәтиҗәсе буларак, «Хәлебездән бер күренеш», «Сугыш» һәм башка кайбер әсәрләрнең строфалары төзәтелеп басылган, «Һатиф вә татар» шигыренең язылу елы да, ниһаять, дөресләнгән һәм 1913 ел белән билгеләнгән

(«Акмулла», 1913, 31 сан). Бәхәсләр тудырып килгән «Язгы җыр» шигыре дә үз елын тапкан (1918).

Әмма, җыентыкны төзүчеләрнең текстлар өстендә җентекләп эшләүләренә дә карамастан, байтак кына хаталар да киткән. Мәсәлән, «Охотник» шигырендәге түбәндәге юлларда хилафлык күзгә бәрелеп тора:

*Әй барабыз, әй барабыз, бер тuктамый тып-тын гына,*
*Җил чыга да безне каплый тик тузан, чүп, ком белән.*

Миңа калса, беренче юлдагы «бер» сүзенең артык икәнлеге, икенче юлдагы соңгы сүзтезмәнең «ком гына» дип бирелергә тиешлеге һәркемгә ачык.

Яки менә «Китабеннас»тан бер эпиграмма:

*Син, Нәҗиб Хәлфин, хәлфәләргә кайда калдырганың?*
*Кузгалак дип чәйнәгән чак бар иде балтырганың!*

Беренче юлдагы «хәлфә» сүзенең урынсыз икәнен һәркем чамалагандыр. Чынлыкта исә бу сүз «хәлфләргә» яки «хәлефләргә» дип язылырга тиеш.

Яңа җыентыктагы «Аңлатмалар» бүлеге дә әлгәреләренә караганда күпкә тулырак, баерак. Кайбер әсәрләрнең чыганагы беренче тапкыр күрсәтелгән, икенчеләренең язылу елы дөресләнгән. Ләкин анда да уйланырга урыннар калган. Ш. Бабичның «Без ник кызылларга кушылдык?» дип аталган әсәрен һәркем белә. Р. Бикбаев әзерләгән җыентыкка бу әсәр беренчел исеме белән, ягъни «Башкорт халкына көйле хитап» дип урнаштырылган.

Билгеле булганча, 1919 елның февралендә буржуаз милләтчеләр кул астындагы башкорт гаскәрләре кызыллар ягына чыга һәм Колчакка каршы бердәм һөҗүм башлый. Шул чорда, әлеге мөһим вакыйгаларның кирәклеген әлегрәк аңлаган Бабич башкорт халкына «хитапнамә» белән мөрәҗәгать итә. Соңрак бу әсәрне брошюра рәвешендә күпләп бастырып, башкорт гаскәрләре урнашкан төбәкләргә дә тараталар. Яңа басылып чыккан җыентыкта әлеге әсәрнең язмышы хакында җитәрлек аңлатма бирелмәгән кебек. Чынлыкта исә 560 юлдан торган бу әсәрнең Г. Ибраһимов 1922 елгы җыентыгында тәкъдим иткән вариантта басылып килүенең үз тарихы бар.

Эш шунда ки, 1918—1919 елгы вакыйгалар эчендә караганда, Ш. Бабичның «хитапнамә»се 1919 ел башында большевиклар алып барган политика белән аваздаш иде. Ә инде Г. Ибраһимовның 1922 елда бу әсәрне кыскартып яңа исем астында басуы вәлидичеләрнең тулысынча фаш ителеп, чит илләргә качулары, шуңа күрә аларга багышланган юлларның да үз көчен югалтуы белән аңлатыла.

Җыентык ахырында бирелгән «Хыялбай» әсәренә карата да берничә сүз әйтү кирәктер. Р. Бикбаев бу әсәр хакында нинди дә булса сүз әйтүне кирәк санамаганмы, «Аңлатмалар» бүлегендә ул телгә алынмаган.

Сәбәп бу әсәрнең авторы ачыкланып җитмәүдә булса кирәк. Хәзерге вакытта «Хыялбай» ике авторга нисбәт ителә. «Сәсән» (1929) журналының 1929 ел 2—3 саннарында басылып чыкканнан соң ул Бабичныкы булып киткән иде. Әсәрне журналга тәкъдим иткән Имай Насыйри аның төгәл чыганагын күрсәтмәсә дә, укучы өчен ул Бабич әсәре булып калды. Әмма шул да мәгълүм булсын, Хатип ага Госманда шагыйрь Тәхфәт Ченәкәйнең бу әсәр уңае белән язылган хаты саклана. 1918—1919 елларда Оренбургта Бабич белән янәшә яшәп иҗат иткән бу шагыйрь «Хыялбай»ны катгый рәвештә үз әсәре дип белдерә, һәм, ул гына да түгел, әлеге шигырь басылып чыккан газетаны да атый. Хат буенча, «Хыялбай» әсәре, 1918 елда язылып, шул елларда Оренбургта чыгып килгән «Оренбур вилаяте мөселман эшләре комиссариаты мөхбире» (редакторы Заһид Шәркый) газетасында «Күрәзә» имзасы белән басыла.

Күрүебезчә, мәсьәлә әлегә ачыкланып җитмәгән. «Аңлатмалар» бүлегендә бу хакта, һичшиксез, искәртеп китәргә кирәк иде.

Ш. Бабич иҗатын тикшерүчеләр урау юлдан йөрделәр. Алар шагыйрь иҗатының төп идея-эстетик принципларын аның лирик шигырьләреннән һәм «Газазил» поэмасыннан эзләү белән чикләнделәр. Үзе бер китап булып оеша алырдай «Китабеннас» исемле эпиграммалар циклы әдәбиятчылар игътибарыннан читтәрәк калып килде. Шушы мөһим әсәрне үзәккә куеп тикшергән Р. Бикбаев алга бик зур адым ясаган. Ике йөздән артык шәхескә бирелгән бәя чынлыкта исә шагыйрьнең үз карашларына, үз иҗатына биргән бәясе, үз идея-эстетик концепциясен ачыклавы иде. Бабичны революцион демократ әдипләр плеядасының бер вәкиле итеп күз алдына бастырган «Китабеннас» киләчәктә тагын да тирәнрәк фәнни анализга мохтаҗ. Хәзергә эш башлангыч этабында гына әле — эпиграммаларда телгә алынган шәхесләрне ачыклау, тарихи фактлар, дәлилләр китерү, Бабичның үзенә мөнәсәбәтен күрсәтү бара.

Башлангыч чорда төгәлсезлекләр, хаталар китүе дә табигый, күрәсең.

Мәсәлән, җыентык ахырында бирелгән «Аңлатмалар»да эпиграммаларда сүз барган кайбер шәхесләрнең дөрес күрсәтелмәве күзгә бәрелеп тора. Татар шагыйре Якуб Аймановны казах шагыйре дип бирү, Сагыйть Сүнчәләй исемен «Сәгиб»,

Фәхри Әхәтовны Әхтәмов дип язу, Хәсни Кәримнең туган төбәген «Бөре өязе» дип кенә җибәрү (Бөре өязе, Тумырҗа авылы) кебек төгәлсезлекләрне хәтсез санарга булыр иде. Ләкин шуны да танырга кирәк: эпиграммаларга бирелгән аңлатмалар, 1958 елгы җыентыкка караганда, шактый тулы, бай. Ул чактагы күп кенә хаталар хәзер төзәтелеп бирелә, күп кенә эпиграммаларга аңлатмалар беренче тапкыр языла.

Соңгы тәэсирем Бабич шигъриятенең аһәңен, ритмын, стилен бозып күрсәткән төгәлсезлекләр хакында. Сүзне «Актык зарым» шигырендәге түбәндәге юллардан башлыйм: «Нишлием соң? Зәкъкумле хәсрәтләр белән күңелем яна?..» Бу очракта Бабич шигыренә «соң» сүзе өстәп язылган һәм, шул сәбәпле, ритмда кытыршылык килеп туган. Икенче бер урында сүзләр төшереп калдырылган. Мәсәлән, «Бар иде торган заманнар җиргә күктән тамып» юлында «күктән» сүзе артыннан «май» сүзе төшеп калган, рифма ук шул сүзне таләп итә. («Яшәсен кыйммәтчелек»). «Әй, Мөхетдин, узам дип, алдыңа карга чыга» дигән юлда «Мөхетдин» сүзеннән соң «мин» сүзе җитешми һ. б. Ачык һәм ябык иҗекләр чиратлашуы кануннарына буйсынмаган мондый мисаллар җыентыкта дистәләгән. Хәтта бер хәрефнең төшеп калуы да бөтен шигъри юл ритмын бозып ташлаган. Мәсәлән:

*Шул вакыт сунгән һавалар алмаша,*
*Мәхшәре — шайтан таша, сөенә, шаша.—*

дигән өзектәге «мәхшәре» сүзе ахырында килгән «е» авазын алып атсак, шигырь шигырь булудан туктый («Газазил»).

Җыентыкта күзәтелгән күпчелек ритмик хаталар татарча текстны башкорт теле закончалыклары нигезендә үзгәртеп бирүдән килә. Дөрес, Р. Бикбаев үзенең «Төзүчедән» дигән искәрмәсендә үк: «Ритмик яңгыраш бозылмасын өчен «җырламыйм» формасы шагыйрь үзе кулланганча калдырылды»,— дип яза. Әмма бу искәрмә җыентыкны ачып җибәргән «Халкым өчен» шигыренә карата гына әйтелгән икән. Ә инде аның артыннан ук урнаштырылган «Бер минут», «Таркау уйлар», «Бай һәм ярлы» һ. б. шигырьләрдә бөтенләй башка юлдан кителгән. Менә «Бай һәм ярлы» әсәреннән берничә юл:

*Син сабыр итсәң, сабыр ит, башкасы сабыр итмәсен.*
*Юк, түзә алмаем, сабыр итә алмаем, акчасы җәбер итмәсен!*

Шул рәвешле, 15 иҗекле Бабич шигыре беренче юлда 16, икенче юлда 21 иҗеккә кадәр үскән һәм, шул сәбәпле, әсәрнең үз аһәңе бөтенләй юкка чыккан. Бабичча ул түбәндәгечә яңгырый:

*Син сабыр итсәң, сабыр ит, башкасы сабритмәсен,*
*Юк, түзалмыйм, сабриталмыйм, акчасы җәбритмәсен!*

Поэтик иҗатта шигырьнең музыкальлеген саклау максатыннан мондый сүз кисешүләр, сүз кыскартулар кулланыла. Шуңа күрә Бабич әсәрләрен башкорт теленә тәрҗемә иткәндә, әлеге кирәкле «төгәлсезлекләргә» юл кую зарури.


Татарча текстны башкорт теленә күчергәндә, еш кына рифмаларга да зәгыйфьлек килә. Мәсәлән, «Кәрәшеп үткәр кыска гомереңне» шигырендәге «айузар» — «агулар», «диуар» — «агыр», «Скрипка» шигырендәге «илай» — «пәрей», «сәсә» — «ыңгыраша» кебек рифма бозылулар яңа җыентыкта шактый очрый.

Ш. Бабич үзенең төп мирасын татар телендә язып, бастырып калдырган. Безгә калса, башкорт телендә басылып чыккан Бабич җыентыгында да әсәрләрне тәрҗемә итү, шул уңайдан килеп туган үзгәрешләр, кыенлыклар хакында искәртү булырга, шулай ук тәрҗемәчесенең исеме дә күрсәтелергә тиеш иде.

«Бабич шигырьнең музыкальлегенә аеруча игътибар итә иде»,— дип язды Хәсән ага Туфан. Киләчәктә Бабич әсәрләренең музыкальлеген мөмкин кадәр төгәл саклаган җыентыклар да дөнья күрер дигән теләктә калабыз.

**Галимҗан ГЫЙЛЬМАНОВ.**

## Оренбургта культурабыз истәлекләре




Муса Җәлил яшәгән йорт
(Ленин урамы)

# ОРЕНБУРГ ҺӘМ ҖӘЛИЛ

Мең тугыз йөз унтугызынчы елның сентябре. Оренбург камалышта. Шәһәргә атаман Дутов гаскәрләре ыргыла. Әнә шундый дәһшәтле көннәрдә Төркстан фронты политидарәсе органы «Кызыл йолдыз» газетасы редакциясенә ике яшүсмер килеп керә... Үткен күзле, тәбәнәк буйлысы, куеныннан кәгазьләр алып, кыяр-кыймас кына редакциядәге олы абыйларына бирә. Күп тә үтми, газетада «Кечкенә Җәлил» имзасы белән акгвардиячеләргә нәфрәт, яшьләрне Кызыл Армиягә өндәгән шигырьләр басыла башлый. Бу — Муса Җәлилнең беренче тапкыр матбугатта чыгыш ясавы була.

Иксез-чиксез Оренбург далаларындагы Мостафа исемле татар авылында дөньяга килгән Мусаның тормыш юлын һәм иҗатын Оренбургтан башка күз алдына да китереп булмый. Герой-шагыйрь исеменә бәйле урыннарның күплеге белән Оренбург Казан яки Мәскәү рәтендә тора.

Язмыш Җәлилне Оренбург белән кайта-кайта очраштыра. Беренче тапкыр бәләкәй Муса шәһәрнең шау-шулы урамнарына 1913 елда аяк баса. Озакламый ул заманына күрә алдынгылардан саналган җәдит мәдрәсәсе «Хөсәения»дә укый башлый. Торулары да ерак түгел: мәдрәсә ишегалдындагы таш йортның гомер кояш нурлары күрмәгән аскы бүлмәсендә. Мәдрәсәдә Муса атаклы Шәриф Камалны күрә, ул чакта иҗаты чәчәк аткан ялкынлы шагыйрь Шәехзадә Бабич чыгышларын тыңлый, әдәбиятка яңа гына аяк баскан Һади Такташ белән очраша.

Әнә «Белек» исемле татар китапханәсе (революциядән соң ул Х. Ямашев исемендә йөртелә башлый). Шәкерт Муса андагы китапларны йотлыгып укый. Тиз тәэсирләнүчән, хыялга бай шәкертнең шигъри күңеленә татар халык әдипләре Г. Тукай һәм М. Гафури әсәрләре бигрәк тә хуш килә.

Дәһшәтле егерме беренче ел Мусаны тагын Оренбургка китерә. «Хөсәения»нең элекке укытучысы Нургали Надиевның эчкерсез ярдәме белән яшь Муса ач үлем тырнагыннан котылып кала. Ул тагын укый башлый. Бу юлы хәрби-партия мәктәбендә. Әле буыннары да ныгып җитмәгән үсмер егет кулына корал тотып өлкән шәриктәшләре белән Оренбург далаларының төрле почмакларында баш күтәргән ак бандаларга каршы көрәшә, ул елларда киң таралган ятимлек, ачлык кебек афәтләрне бетерүгә көченнән килгән кадәр өлеш кертә. Һәм, әлбәттә, ярты төнгәчә сузылган комсомол җыелышлары, кайнап торган әдәби-музыкаль кичәләр дә шат күңелле, ачык чырайлы, үткен, һәркемне мавыктыра белгән Мусадан башка узмаганнар.

Оренбург җанга никадәр якын булмасын, якын дуслар, газиз туганнар никадәр күп булмасын, Җәлил инде Казанга — татар мәдәниятенең үзәге булган дәртле, нурлы, моңлы Казанга ашкына. Редакциядә эшләү, рабфак еллары күз ачып йомганчы узып та китәләр. Кайнап торган Казаннан Җәлил яңадан туган ягына кайта. Озакламый аны Орск шәһәренә комсомолның өяз комитеты инструкторы итеп җибәрәләр. Таныш эш, күңелле эш. Яшьлек энергиясе ташып торган комсомолец Муса бәхәсле җыелышлар эчендә кайный, күңелле кичәләр, ярышып эшли торган өмәләр оештыра. Орскида Муса Җәлилнең тормышында зур вакыйга була: ул Коммунистлар партиясе сафына кабул ителә.

Орскида бер ел чамасы эшләгәч, Муса яңадан Оренбургка кайта, комсомолның өяз комитетында инструктор булып эшли. Җаек ярына елышкан һәм шәһәрнең иң гүзәл почмакларыннан булган Набережная урамындагы 16 нчы йортка беркетелгән мемориаль такта әнә шул хакта сөйли.

1927 елның ямьле язында Җәлил башкалага, комсомолның Бөтенсоюз киңәшмәсенә юл тота. Аннан соң шагыйрьнең язмышы Мәскәү белән бәйләнә: ул Мәскәү университетының әдәбият факультетына укырга керә.

Әнә шулай Оренбург үзенең яшь бөркетен зур тормышка озатып кала, шигъриятебез күгендә мәңге сүнмәс йолдыз булып кабынырга әзерли.

*З. Мөхәммәтҗанова рәсеме,*
*Ж. Миңнуллин тексты.*

# ИГЕЛЕКЛЕ МИРАС



Халкыбызның бай һәм катлаулы тарихын фәнни рәвештә җентекләп өйрәнү эше бары XIX йөзнең икенче яртысыннан гына башланып китте. Аңарчы татар тарихы дигән мәсьәлә объектив һәм субъектив сәбәпләр аркасында төрле әдәбиятта хаклы һәм хаксыз рәвештә каршылыклы карашлар, урынлы-урынсыз бәхәсләр объектына әверелгән иде. Шуңа күрә Урта гасырлардан алып Яңа дәверләргә кадәр «татар тарихы» тирәсендә барлыкка килгән, өсте-өстенә өелеп өлгергән әлеге буталчыклардан — ихлас ялгышулар белән бергә тенденциоз омтылышларның һәммәсеннән югары күтәрелү зарур иде. Ягъни тарихыбызны дөрес яктырту, аның киләчәк үсешен төпле фәнни юнәлешкә салып җибәрү өчен, тирән белемгә ия, чын гражданлык батырлыгына сәләтле фидакарь ир-егетләргә ихтыяҗ туган иде. Эшсәяр халкыбыз, ул яшәгән бай һәм катлаулы мохит әлеге актуаль ихтыяҗны канәгатьләндерү юлында айнык акыллы, какшамас ихтыярлы, мәгәр шул дәрәҗәдә үк тирән каршылыклы Шиһабетдин Мәрҗанине, аның күпсанлы шәкертләрен — тугрылыклы иярченнәрен иҗтимагый мәйданга чыгарды.

Үз элгәргеләренең мирасларын яңа шартларда биек үрләргә күтәрә алган Мәрҗанинең эшчәнлеге гаять күптармаклы һәм нәтиҗәле булды. Остазлары салган шушы олы юлга керүче туры һәм мәгънәви шәкертләр исә аны янә дә баетып, егәрләндереп җибәрделәр. Чөнки алар, кагыйдә буларак, остазлары эшчәнлегенең берәр тармагын сайлап, аны тирәнәйтү, баету юлында армый-талмый көч түктеләр, яңа казанышларга ирештеләр. Шундый кумәк эшчәнлек нәтиҗәсендә милли тарих белемебез фәнгә әверелде, кыска вакыт эчендә күптармаклылык югарылыгына күтәрелә алды.

Иҗтимагый аңыбыз, рухи мәдәниятебез шулай чарланып үсүгә, баюга конкрет өлеш керткән Мәрҗани шәкертләре, аның мәгънәви иярченнәре арасында күренекле археограф һәм педагог Сәид Вахидиның тормыш юлы, эшчәнлеге һәм мирасы махсус игътибарга лаек.

Сәид Габделмәннан улы Вахиди 1887 елның 31 маенда элекке Казан губернасының Спасс өязендә Ташбилге авылында урта хәлле игенче гаиләсендә дөньяга килә. Күзгә күренеп үзгәрә баручы заманада аң-белемнең көчен яхшы тойган Габделмәннан агай, тормышының шактый авыр, зур улының бары гадәти тимерче генә булуына карамастан, сәләтле уртанчы улы Сәиднең, укып, зур белемнәргә ирешүен теләи. Башлангыч белемне кечкенә Сәид туган авылында, аннары Иске Рәҗәптәге мәдрәсәдә ала.

Кызыксынучан үсмер өчен аның туган яклары да үзенә күрә бер гыйбрәтле дөнья — тарихи белем чыганагы иде. Әнә Ташбилге авылы зиратындагы болгар чоры кабер ташлары, әнә авылдан ерак түгелдә генә Сувар каласының урыны; беркадәр арырак китсәң, йәнә дә серлерәк Биләр, Җүкәтау шәһәрлекләре... Ә йорттан-йортка, авылданавылга йөреп, тирә-яклардагы мичләрнең күбесенә якты ут кабызган Габделлатыйф бабай исә болгар чорының кызыклы вакыйгаларын мавыгып сөйли, язу танымаганлыктан, китапка карамыйча, хәтердән генә сөйли... Сәид шәкерттә туган җирнең, үз халкының бай тарихына карата булган ихлас мәхәббәт менә шулай халыкчан нигездә, табигый шартларда формалаша башлый.

1905 елны Казанга килеп, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укый башлагач, Сәиднең тарихи белеме артуга, ул фәнгә карата омтылышы көчәюгә тагын да зуррак мөмкинлекләр ачыла. Казанда ул элек исемен генә ишетеп белгән мәшһүр Шиһаб хәзрәт Мәрҗанинең гыйльми хезмәтләрен уку, үткен фикерле галимнең уй-хыяллары, нәфрәт һәм идеаллары белән танышу бәхетенә ирешә. Мәрҗанинең «Мөстафад-ел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» исемле ике томлык фундаменталь хезмәте, бигрәк тә аның документаль нигезе

дөньяга карашы оешып килә торган егетнең аңында гомер буе җуелмаслык эз калдыра: чын тарих ул иң элек борынгыдан килә торган язма истәлекләрдә саклана икән!..

Кырыс галимнең «үз узганын оныткан халыкның киләчәге юк» дигән ачы фикере егетнең аңына уелып керә, тора-бара, аның үз иманына әверелә. Шул вакытлардан алып С. Вахиди Мәрҗанинең мәгънәви шәкертенә әверелә һәм аның олуг галимгә булган ихлас ихтирамы, мәсләктәге тугрылыгы гомеренең соңгы көннәренә кадәр саклана. Әгәр бүген Вахидиның язмаларын актара башласаң, аның үз остазын телгә алган саен, «галим, хәким, изгелек иясе» мәгънәсендәге фазыйль эпитетын кулланып, гел Фазыйль Мәрҗани дип яза торган булуын күрәсең. Гыйльми мәсләктәге тугрылык исә, Мәрҗани башлаган археографик эшләрнең Вахиди тарафыннан гомер буена дәвам итүендә гәүдәләнә.

Яшь Вахидига Казан чорында рухи һәм гыйльми үсештә көчле тәэсир ясаган икенче бер иҗтимагый факторны да онытмыйк. Ул 1905 елгы Беренче рус революциясенең алдынгы татар яшьләре аңына ясаган көчле тәэсире иде. Чөнки бу революция аң-белем, дөньяви фәннәр өчен барган көрәшнең нигезендә социаль гаделлек, милли тигезлек өчен көрәш интереслары, димәк, аерым шәхесләрнең генә түгел, бәлки киң катлам халык массаларының мәнфәгате ятуын ачып салды.

Казанда яшәгән чакта рус телен өйрәнү, прогрессив рухлы ориенталистларның хезмәтләре белән танышу, демократик юнәлештәге вакытлы татар матбугатын күзәтеп бару егетнең карашын киңәйтеп, фикерен тирәнәйтеп җибәрә. Шуңа күрә 1911 елны, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсен тәмамлап, укытучылык эшенә киткән яшь мөгаллим 1912 елда ук туган авылында рус-татар башлангыч мәктәбен ачтыруга ирешә. Аннары Мамадыш якларында яңа мәктәпләрдә мөгаллимлек итә, ә 1914 елны Вахидины Казандагы 3 нче номерлы мәктәпкә мөгаллим итеп билгелиләр; ул анда татар әдәбияты, төрки-татар һәм рус халыкларының тарихлары буенча дәресләр бирә.

Укытучылык белән бергә параллель рәвештә Сәид Вахиди үзенең гыйльми өлкәдәге эшләрен, археографик эзләнүләрен дә актив дәвам иттерә. Кайда гына булмасын, кемнәр белән очрашмасын, ул иң элек борынгы риваятьләр, эпиграфик истәлекләр, кулъязмалар хакында сораша, җае килгәндә, аларны кулга төшерергә тырыша. 1912 елда Мамадыш ягындагы Мамалай авылында Рәхмәтулла исемле агайда борынгыдан калган бер «хикмәтле язу» барлыгы, ул язуның төрле чирләрдән «ярдәм итүе» хакында ишетә. Әмма үзе язу танымаган Рәхмәтулла агай тиз генә ачылмый: авылдашларына «дәваланыр» өчен биреп тора торган, шуның белән хуҗасына азмы-күпме керем биргән әлеге кәгазен ул Сәид мөгаллимгә бик кыенлык белән күрсәтә, барӊы бер генә кичкә укып карар өчен биреп тора. «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә үк И. Н. Березин, В. В. Радловларның Җучи Улусы (Алтын Урда) һәм Кырым ханнары ярлыкларына багышланган классик хезмәтләре белән таныш Вахиди өчен шәм яктысындагы әлеге караңгы төн зур фәнни ачыш яктылыгын бүләк итә: аның алдында Казан ханлыгы чорыннан калган, моңарчы бер галимгә дә аны күрү насыйп булмаган сирәк документның — 1523 елда бирелгән тарханлык ярлыгының төп нөсхәсе — нәкъ үзе ята иде!..

Истәлекнең кыйммәтен аңлаган С. Вахиди, әлбәттә, документның киләчәге турында кайгырта. Әмма хуҗа сөйләшергә дә теләми. Нәтиҗәдә Вахидиның кулында кыска төндә ашык-пошык эшләнгән күчермә кала...

Әмма һәрвакытта киң күңеллелеге белән аерылып торган илгизәк Вахиди әлеге табыш-ачышның шаукымында масаеп кәперәйми, янсә, ачкүзләнеп, үз кабырчыгында йомылмый, бәлки зур шатлыгын тарихчы Һади Атласи белән уртаклаша. Бу вакытларда галимнең «Казан ханлыгы» исемле күләмле хезмәте язылып яткан була, һәм әлеге ярлыкның беренче күчермәсе, әлбәттә, ачыш авторының ризалыгы буенча, 1914 елда басылып чыккан китапка «кереп утыра». Вахидины исә язмыш Беренче дөнья сугышының алгы сызыгына илтеп ташлый...

1905 елгы революциянең бөек казанышларын татып өлгереп, «кара» халыкны агарту, изелгән милләтне яктылыкка чыгару, социаль гаделлеккә ирешү, империалистик сугышны бетерү өчен нәрсәләр кирәклеген фронт шартларында яхшырак шәйли башлаган С. Вахиди Февраль вакыйгаларын, Октябрь революциясен зур күтәренкелек белән каршылый. Соңрак күренекле тюрколог академик А. Н. Самойловичка күндергән бер хатында ул: «...Октябрь революциясе миңа канат бирде һәм минем алда гыйльми тикшеренү, туган төбәгемнең тарихын өйрәнү өчен зур киңлекләр ачты»,— дип язды.

Революция җиңеп, солдат шинеле иңнән төшүгә үк С. Вахиди, җиңнәрен сызганып, мәктәп-мәгариф эшенә тотына. 1918—1920 елларда ул яңа ачылган күпсанлы совет мәктәпләре өчен тизләтелгән рәвештә укытучылар әзерли торган кыска сроклы педагогик курсларда лектор булып эшли; Спасс, Лаеш, Мамадыш кантоннарында шундый курсларны оештыруга катнаша. 1919 елның октябреннән 1921 елның ахырына кадәр Казан дәүләт университеты каршындагы рабфакта укыта. Моннан соң без Вахидины егерменче елларда Казанда бер-бер артлы оешкан гыйльми оешмаларда, җәмгыятьләрдә, әйтик, Академик үзәктә, Көнчыгышны өйрәнү, Татарстанны гыйльми өйрәнү, Казан университеты каршындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыятьләрендә актив хезмәттәшлек

итүче сыйфатында күрәбез. 1928 елда Татарстанны гыйльми өйрәнү җәмгыяте янында махсус археографик комиссия төзелгәч, С. Вахидига кульязмалар җыю, аларны өйрәнү эше йөкләнә. 1930 елда Татарстан гыйльми-тикшеренү экономик институты төзелгәч, Вахиди шул институтка эшкә керә, 30 елларның икенче яртысында ул Татарстан дәүләт музеенда бүлек җитәкчесе була, шундагы фондларны тәртипкә салуга катнаша. Кыскасы, зур тарихи үзгәрешләрдән, тормыш яңаруыннан канатланган Вахиди актив фәнни иҗат тормышы белән яши. Ләкин, кайда гына эшләмәсен, аның төп юнәлеше кульязмалар җыю, аларны тәртипкә салу, фәнни күзлектән тикшерү һәм өйрәнү булып кала бирә.

Археография өлкәсендә исә Вахиди Октябрьдән соң аерата зур казанышларга ирешә. Хәер, аның иң зур табышы булган Сәхибгәрәй хан ярлыгын чын-чынлап өйрәнү эше дә революциядән соң гына насыйп була. Чөнки кайчандыр бер ялтырап алган, аннары тагын Рәхмәтулла агай янчыгына кереп чумган әлеге «алтын чабак» хакында ул фронт окопларында да онытмый. 1919—1920 елларда, мәктәп-мәгариф эшләре белән актив шөгыльләнеп йөргән чакларында, тагын әлеге Мамалай авылына барып чыга, янә Рәхмәтулланың күңелен аулый, гозерен кабатлый. Ниһаять, (теге агай шартлар үзгәрүен аңлаган бугай...), кыйммәтле документ С. Вахиди милкенә күчә. Шул рәвешчә, Вахидиның дүртбиш ел дәвамында документ өстендә мавыгып эшләү чоры башлана.

Кыйммәтле чыганакның серләре тулырак ачыла башлагач, галим гыйльми аудитория каршында, аннан соң матбугатта чыгышлар ясарга тиеш иде. Гыйльми җәмәгатьчелек исә С. Вахидиның мөһим табышын да, ярлыкны уку һәм аңлауда ул ирешкән казанышларны да хуплап, котлап каршы ала. Мәсәлән, аның махсус публикацияләренә, докладларына карата 1922—1926 еллардагы вакытлы матбугат битләрендә Н. Н. Фирсов, И. Н. Бороздин, Г. С. Гобәйдуллин, М. Г. Худяков, С. Н. Бикбулатов, С. Мортазин, Х. Сафин һәм Галимҗан Ибраһимовның рецензияләре басылуы әлеге теләктәшлекнең, ихлас кызыксынуның нәтиҗәсе булды. 1924 елда чыккан «Казакъ кызы» романының бер нөсхәсе Г. Ибраһимов автографы белән («Сәид Вахидов иптәшкә. Г. И.») бүләк ителүе дә, һичшиксез, шушы игътибарның бер чагылышы иде.

Гыйльми җәмәгатьчелек үз вакытында ук дөрес бәяләгәнчә, С. Вахидиның бу ачышы һәм ул башкарган фәнни эзләнүләр тарихыбызның иң катлаулы чорларыннан берсен тәшкил иткән Казан ханлыгы чорын элеккегә караганда дөресрәк, объективрак аңларга ярдәм итте. Шуны да өстәргә кирәк: беренче нәүбәттә Сәхибгәрәй хан ярлыгын җентекләп өйрәнү нәтиҗәсендә совет галимнәре Казан ханлыгында хөкем сөргән аграр мөнәсәбәтләрне дөрес аңлау мөмкинлегенә ирештеләр. Ниһаять, Казан ханлыгының иҗтимагый-социаль төзелеше хакында Сәхибгәрәй ярлыгы биргән мәгълүматларның дөреслеген Казан хөкемдары Ибраһимның соңрак табылган һәм шулай ук Кырым ханнарының рәсми актлары да тулысынча раслады. Димәк, Сәхибгәрәй ярлыгы турында болай киңнән сөйләү аның хосусый үзенчәлеген күпертү өчен түгел, бәлки ул һәм аның ише материалларның узганны дөрес аңлауда тоткан объектив әһәмиятен күрсәтү җәһәтеннән дә зарур икән.

Ярлыкны җентекләп өйрәнү процессында Вахиди үзе дә, галим буларак, күзгә күренеп үсә. И. Н. Березин, В. В. Радлов, А. Н. Самойлович мәктәпләрен узу аңа тарихи истәлекләрне өйрәнүдә Европа ориенталистлары кулланган алдынгы гыйльми тикшеренү методикасын үзләштерергә ярдәм итә.

Җыеп әйткәндә, шушы бер генә конкрет табышы һәм ике махсус публикациясе[1] белән дә С. Вахиди узганыбызны танып-белү тарихына кереп калырлык хокук яулап алган шәхес иде.

Аның башка хезмәтләре дә хәзергә кадәр әһәмиятләрен югалтмаганнар. Күпсанлы газета публикацияләренә, кульязма килеш архивларда сакланып калган материалларына махсус тукталмыйча, аның Чулман һәм Идел буйларының ерак узганына караган легендалар[2], Ш. Мәрҗани китапханәсенең авыр язмышына багышланган мәкаләсенә[3] игътибарны махсус юнәлдерер идем. Бигрәк тә галимнең икенче хезмәтен мин югары бәялим. Чөнки анда Вахидиның төп сыйфаты шактый тегәл гәүдәләнгән. Әлеге китапханәнең гыйбрәтле язмышы язма мирасыбызны үлемнән коткару юлындагы Вахиди эшчәнлеген фәнни дөрес бәяләргә ярдәм итә.

Вахиди — археограф... Бу теманы яктырта-яктырта, без аның белән бергә дистәләгән районнарга, йөзләгән авылларга барып, меңләгән капкаларны шакыр идек. Ул эзләп таптапкан, шуның белән үлемнән котылган кульязмаларны тышкы яктан гына аерым-аерым тасвирлый башласак, зур күләмле бер китап барлыкка килер иде. Әгәр Вахиди саклап калган истәлекләрнең эченә кереп, аларның узгандагы реаль фәнни дәрәҗәбезне, әдәби фикер һәм халык иҗаты өлкәләрендәге казаныш һәм югалтуларыбызны өйрәнү өчен нәр-

---

[1] Вахидов С.: а) Исследование ярлыка Сахиб-Гирей-хана.— Известия Общества археологии, истории и этнографии при Казанском университете. т. 33, вып. 1, 1925, 61—92 бб.; б) Ярлык хана Сахиб-Гирея.— Вестник научного общества татароведения, 1925, № 1—2, 29—37 бб.
[2] Вахидов С. Татарские легенды о прошлом Камско-Волжского края. Казань, 1925.
[3] Вахиди С. Мәрҗани көтепханәсе һәм аның соңгы язмышы.— «Безнең юл», 1929, 6—7 сан, 14—17 бб.

сәләр бирә алуын барлый башласак та, катлаулы монография хасил булыр иде. Ихтимал, андый күптармаклы тикшеренүне сыйфатлы итеп башкарыр өчен бер кешенең көче дә, гомере дә җитеп бетмәс, ул киләчәк һәм зур коллективларның бурычы.

Югарыда әйтелгәнчә, С. Вахиди 1905 елдан алып, кульъязмаларны эзләү, җыю эше белән актив шөгыльләнә. Егерменче елларның урталарына аның шәхси китапханәсендә сан ягыннан бай, сыйфат җәһәтеннән бик кыйммәтле кульъязмалар коллекциясе барлыкка килә. Мондый истәлекләрнең шәхси кулларда түгел, бәлки фәнни оешмаларда сакланырга, шул рәвешчә халык милкенә әверелергә тиешлеген яхшы аңлаган Вахиди 1925 елның 10 февралендә ике йөздән артык кульъязманы, җөмләдән Сәхибгәрәй ярлыгын да, Академик үзәк аркылы Татарстан АССР Дәүләт музеена бүләк итә. Бу хакта «Красная Татария» (13 февраль), «Кызыл Татарстан» (15 февраль) газеталарында һәм «Безнең юл» журналында (1925, 3 сан) хәбәр ителеп, галимгә рәсми рәхмәтләр белдерелә. Игътибар итик: С. Вахиди әлеге кульъязмалар өчен тәкъдим ителгән акчадан баш тарта!

1930 елда Татарстанны гыйльми өйрәнү җәмгыяте нигезендә Татарстан гыйльми-тикшеренү экономик институты оеша. С. Вахиди, шул яңа институтның фәнни нигезен ныгыту максатыннан чыгып, үз коллекциясеннән тагын 1127 кульъязма китапны, үзе тарафыннан төзелгән исемлек-тасвирламасы белән, әлеге институтка бирә. Әлбәттә, тагын да бушлай, ягъни бүләк итеп...

1934 елны галимнең бүләге сыйфатында биш йөздән артык кульъязманы СССР Фәннәр академиясенең Көнчыгышны өйрәнү институты кабул кыла. Шуны да өстәргә кирәк: нәкъ шушы 1934 елда, югарыда бер искәртелгәнчә, С. Вахиди әлеге институт тарафыннан Вәли Зәбиров җитәкчелегендә оештырылган археографик экспедициягә катнаша. Экспедиция исә көтелгәннән артык нәтиҗәләр бирә: 1200 данә яңа кульъязма, меңнән артык төрле характердагы документлар... Бер сезонда гына моның хәтле кульъязма табылуда тәҗрибәле С. Вахидиның өлеше һәм информациясе зур икәнлеге бәхәссез, әлбәттә.

Шулай итеп, төрле фәнни оешмаларга С. Вахиди коллекциясеннән яки аның катнашы һәм ярдәме белән кергән кульъязмаларны саный башласак, аларның гомумкүләме икеөч меңнән артып китәр иде...

Бер сүз белән әйткәндә, бүген без рухи мәдәниятыбыз тарихы буенча язма чыганаклардан сыйфатлы мәгълүматлар туплый башласак, Вахиди коллекциясендә булган, аерым битләренә «С. Г. Вахиди көтепханәсе. Библиотека С. Г. Вахидова» дигән ике телдәге язулы озынча түгәрәк мөһер-экслибрис сугылган кульъязмаларны актармыйча, мәгънәләренә төшенмичә торып, алга таба бер адым да ясый алмаячакбыз. Бу декларация генә түгел, ә реаль хакыйкать. Чөнки авыр һәм уңайсыз шартларда тынгысыз җан Сәид Вахидиның фидакарь тырышлыгы нәтиҗәсендә табылган, аның ихтыяры белән дәүләт-халык милкенә әверелгән, шул рәвешчә безгә килеп җиткән, меңләгән кульъязмаларда тарихыбыз һәм әдәбиятыбызның төрле өлкәләрен яктыртучы мәгълүматлар тупланган. Әйтик, язма әдәбиятыбызның елга башында торучы Кол Галинең үлемсез «Кыйссаи Йосыф» поэмасын төрле күчермәләр нигезендә җентекләп өйрәнергә теләсәк, С. Вахидиның мөһере сугылган күчермәләргә дә очрыйбыз. «Нәһҗел-фәрадис» әсәрен тикшерергә булсак, тагын С. Вахиди нөсхәләреннән уза алмыйбыз; «Таварихы Болгария», «Дәфтәре Чыңгызнамә» китапларын чыганак буларак өйрәнергә теләсәк, сыйфатлы күчермәләр арасында шул ук Вахиди нөсхәләре; җыр-бәетләр хәзинәсе булган шәкерт дәфтәрләрен актара башласак, янә әлеге озынча түгәрәк мөһергә очрап уйга калабыз... Бездә элек гамәлдә булган юридик нормалар, шәригать законнары, төрле фән-гыйлем тармаклары, риваятьәкиятләр, ышаныч-хорафатлар, нәсел-ыру язулары, шәҗәрәләр, алу-сату, өйләнү-аерылу, мирас бүлү документлары һ. б. Ягъни рухи, мәдәни тарихыбызның кайсы гына тармагына мөрәҗәгать итсәк тә, без С. Вахиди кулы аша узган, аның күз нурларын, күңел җылысын үзләренә «сеңдереп», шуларны характерлы мөһер рәвешендә гәүдәләндергән кульъязмалар — документаль чыганаклар алдында тез йөгенергә, баш иярга мәҗбүр булабыз. Һәммәсе өчен дә кадерле, кыйммәтле истәлекләр — халкыбызның күпгасырлы хәтере алар!..

Кайчандыр Мәрҗани тарафыннан башланган кульъязма мирасыбызны җыю һәм өйрәнү юнәлеше С. Вахиди эшчәнлегендә шулай элегрәк чорларда күрелмәгән нәтиҗәләргә ирешә һәм гомуммәдәни фондыбызның алтын маясына керде.

Кеше буларак та С. Вахиди кызыклы шәхес иде. Эш сөючәнлек, иманданыклык, халык милкенә, милли мираска ихлас мәхәббәт, тарихка мөнәсәбәттә киңлек — һәммәсе дә галим эшчәнлегенең, аның игелекле мирасының аерылгысыз сыйфатын тәшкил итәләр. Әгәр шушы сыйфатларның берәрсен генә сызып ташласаң, С. Вахиди эшчәнлегенең күп җәһәте аңлаешсыз янсә мәгънәсез булып калыр иде.

С. Вахидиның башкалар белән мөнәсәбәттәге хосусый сыйфатлары да игътибарга лаек. Илгәзәк табигатьле, якты чырайлы, хәрәкәтчән чандыр гәүдәле бу кеше чын зур галимнәрнең олы җанлылыгына, юмартлыгына ия иде; аның башка каләмдәшләренә карата эчкерсез ярдәмчел булуы, күңел тарлыгы, көнчелек кебек түбән хисләрдән өстен

торуы бәхәссез фактлар белән раслана. Мәсәлән, Сәхибгәрәй ярлыгын тикшерү буенча ирешкән беренче нәтиҗәләрне, әле үз хезмәте басылып чыкканчы ук, М. Худяковның 1923 елда нәшер ителгән «Казан ханлыгы тарихы буенча очерклар» исемле китабында файдалануга ярдәм итә. «Американ» комедиясендә Кәрим Тинчуринның ярлык табу сюжетын эшкәртүдә С. Вахидиның киңәшләреннән файдалануы ап-ачык...

Дөрес, Вахидиның шушы илгәзәклеге, кешеләр белән мөнәсәбәттә ихласлыгы билгеле бер дәрәҗәдә садәлектән, беркатлылыктан да азат түгел иде. Шуңа күрә ул туры сүзлелектән дә баш тартмый, ирешкән казанышлары белән горурлануын да яшерми. Болар исә бер кеше ирешкән шул хәтле мул табышлар һәм казанышлар өчен болай да тарсынып, көнләшеп йөри торган хәсет җаннарның күңелләре тагын да тарая төшүгә сәбәп булалар. Өстәвенә Вахиди үзе дә кайбер тактик ялгышлар җибәрә. Мәсәлән, егерменче елларда, билгеле объектив сәбәпләр аркасында, хокуклар чикләнеп, үз эчләренә йомылып йөргән руханиларның, авыл картларының китап хәзинәлекләренә юл табуы авырая төшә. Язу алмаштыру ситуациясе исә руханилык эшеннән читтәрәк торучы картларны да кульязмалар җыючыларга шикләнеп карарга мәҗбүр итә: янәсе, болар, «хәрефләрне бетерү» белән канәгатьләнмичә, язма истәлекләрне дә юк итәр өчен йөрмиләр микән?..

Менә шундый шартларда төрле каршылыкларга, аңлаша алмауларга очраган С. Вахиди, наив беркатлылык белән руханилык-муллалык битлеген кия, шул рәвешчә авыл картларының китапханәләренә «ачкыч» таба... Хәзер, айнык акыл белән уйлап карасаң, бу кыланышларда әллә ни зур җинаять булмаган кебек, аларның әхлак җәһәтеннән ярамаган алым, шул ук вакытта мәҗбүрияттән туган садә тәвәккәллек икәнлеген дә аңлавы читен түгел. Әгәр Вахиди, чыннан да шул чордагы кайбер кызу башлар әйткәнчә, «күгәреп беткән милләтче», актив дин пропагандисты булган булса, әзлекле рәвештә язма истәлекләрне җыеп, аларны гыйльми оешмаларга тапшырып торыр идеме соң?! Юк, әлбәттә... Әмма эчләре янып йөргән әлеге хәсетләр өчен бу хәлләр күктән көткәнне җирдән табу белән тиң иде. Утызынчы елларның икенче яртысында Вахиди тирәсендә электән килә торган вак-төяк ыгы-зыгылар, урынсыз гаепләүләр, бигрәк тә аноним әләкләүләрнең куерып китүен, ахыр чиктә башына җитүен менә шулай аңларга кирәк.

Күренекле археограф һәм педагог Сәид Вахиди 1942 елда вакытсыз үлә.

Җыеп әйткәндә, Сәид Вахиди эшчәнлегенә без, бүгенге көн биеклегеннән торып, объектив бәя бирергә тиешбез. Мәсьәләгә шушы җәһәттән якын килгән чакта, галим эшчәнлегенең кыйммәте, аның тарафыннан үлемнән коткарылган меңләгән кульязмалар белән бергә, мәгънәви әһәмияткә дә ия. Мин бу урында С. Вахиди эшчәнлегенең гыйбрәтле мисал һәм яхшы үрнәк булу җәһәтеннән тарихи кыйммәтен күз уңында тотам. Чөнки утыз елга якын дәвам иткән С. Вахиди эшчәнлеге нәтиҗәсендә, өч меңнән артык татар җирлеге кульязмасы җыелудан тыш, татар мохитының кульязмаларга гаҗәп бай икәнлеге дә расланган факт буларак замандашларының һәм варисларының аңнарына сеңеп калды. Ниһаять, кульязма җыяр өчен, халык арасына чыгу идеясе дә, С. Вахиди эшчәнлегендә матди гәүдәләнеш табып, реаль идея, алыштыргысыз чара — юл сыйфатында безгә мирас булып калды. Әгәр соңгы егерме-егерме биш ел дәвамында Казан дәүләт университетында, аннары Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында археографик экспедицияләр эшләп, бүгенге көнгә тулаем ун меңгә якын яңа кульязмалар безнең фондларга кергән, шул рәвешчә халыкның реаль хәзинәсенә әверелгән икән, бу казанышларыбызда да С. Вахиди эшчәнлегенең дәвамын күрү кыен булмаса кирәк!

Игелекле мирасның үзебезгә ясаган шушы тирән тәэсирен без һаман истә тотабыз һәм татар халкының фидакарь улы Сәид Вахидиның якты истәлеге алдында һәрвакыт башларыбызны иябез.

**Миркасыйм ГОСМАНОВ,**
тарих фәннәре докторы, профессор,
СССР Фәннәр академиясенең Археографик
комиссия әгъзасы.

*Миргазиян Юныска 60 яшь*

# ЯШӘҮ МӘГЪНӘСЕ



Заман героен без һаман эзлибез... Ләкин ул, я артык идеал булып, күзләрне камаштыра башлый һәм, реаль җирлектән аерылып, бик югары күтәрелә, я тормыш ваклыклары, интим хисләр белән мавыгып китә дә үз дәрәҗәсен төшерә... Ә тискәре сыйфатлары күп булган геройны күңел шулай ук кабул итми. Үзеңә үрнәк булырдай, халкыңның киләчәге өчен янып яшәүче, югары культуралы, интеллектуаль шәхес күрәсе килә. Өстәвенә, аның хисләре, уйлары, күңел тибрәнешләре синеке белән бер дулкында булсын. Укучы буларак, күпләрнең фикере шулайдыр дип әйтергә җөрьәт итәм.

Бөек әдип Лев Толстой: «Киләчәктә вакыйгалар һәм геройлар турыдан-туры тормышның үзеннән алыныр»,— дигән фикер әйтеп калдырган. Миргазиян Юнысның да «Шәмдәлләрдә генә утлар яна» дигән исем белән татарча чыккан соңгы китабындагы «Юлда уйланулары» чын тормыштан алынып, үз гомеренең бер өлешен, үзе белән бергә эшләгән һәм яшәгән шәхесләрне, чит ил кешеләрен, илләр һәм халыклар арасындагы мөнәсәбәтләрне сурәтләүгә багышланган. Әмма бу сурәтләү — гади юлъязма — фәлсәфи уйланулары, кеше күңеленә үтеп керә белүе, шаян очкыннар чәчеп, күзләреңнән яшь килгәнче көлдерүче үткен юморы белән үзенчәлекле әдәби әсәр дәрәҗәсенә күтәрелгән.

Анда кеше холкының индивидуаль чагылышын сурәтләгән картиналар, лирик чигенешләр белән гомумиләштерү рәвешендәге өземтәләр аралашып бара. Мондый үрелү, ихтимал, образлы һәм фәнни фикерләүнең кушылуыннан киләдер.

Уйлануларның «документаль язмалар» дип тәкъдим ителүе дә укучыга тәэсир көчен арттыра. Юкка гына хәзер тарихилык һәм документальлеккә ихтыяҗ зураймагандыр.

Бүгенге көндә кеше факторы, ягъни адәм баласының рухи сыйфатлары югары һәм саф булсын өчен, кеше дигән бөек исем горур яңгырасын өчен көрәш бара. Бу — материаль байлыклар һәм экономик үсеш өчен көрәшкә караганда күп тапкыр катлаулырак һәм кыенрак. Хәер, илнең экономикасы да кешенең рухи һәм әхлак сыйфатларына бәйле бит.

Әсәрдә автор үзе турында яза — берни яшермичә: кимчелекләрен дә, шикшөбһәләрен дә кертеп, юлында очраган авырлыклар, якты хатирәләр, үзе белән бергә эшләгән кешеләр, җитәкчеләр һәм үз кул астындагы яшьләр турында.

Малай чагыннан ук ул табигатькә гашыйк. Каен урманының чәчәкле аланына чалкан ятып, төпсез зәңгәр күккә карап, кошлар сайравын, яфраклар шавын тыңлап, күктән яуган кояш нурлары аша иксез-чиксез тоташ илаһи зәңгәрлеккә төбәлеп ятарга ярата. Шушы сихри матурлык, чиксез биеклек аны бәхетле итә, хәтта үзенә, югарыга чакыра, өнди! һәм романтик рухлы авыл малае күккә күтәрелә — авиациядә хезмәт итә башлый. Киң илебезнең бер читеннән икенче читенә кадәр күкне гизә. Сахалиннан котыпка очканда, боз өстенә төшеп «утыру»да, җиргә бәрелеп сытылган самолет эчендә канга батып үлем белән көрәшеп яту да аның романтик канатларын сындыра алмый. Врачлар очарга рөхсәт бирмәсәләр дә, дөньяда күк кенә түгел бит әле — диңгез, океан киңлекләре бар, һәм ул диңгезче һөнәрен сайлый.

Башта ул — корабльдә савыт-саба юучы, моряк һәм, ниһаять, чит илләргә сәяхәт итүче гигант теплоходның капитан ярдәмчесе. Матур хыялларга бирелүчән малай, инде сугыш кырыслыкларын да кичергән, тормыш сикәлтәләрен дә узган, җитди авыруларга да дучар булган. Әмма романтик рух исән, ул һаман дөнья киңлекләренә омтыла, күкрәк киереп, давылга каршы бара. Югыйсә, авыру сәбәпле, авыр мәшәкатьле эштән

китеп, башкаланың дәрәҗәле урынын биләп, эшне фәрман белән генә башкарып, персональ машинада гына йөри башлый да бит. Юк, андый тормыш Миргазиян өчен түгел шул! Ул анда да ат турында уйлап, ат сагынып, җирсеп утыра: «Бахбаем, эшкә мин синә атланып килер идем... Рәсәйдә беренче китап баса башлаган Иван Федоровның һәйкәле янына бәйләп, алдыңа солы салып куяр идем. Өйлә җиткәч, Мәскәү елгасына төшереп, су эчереп кайтыр идем...»

Геройның ат турындагы уйлары чит континентларга да ияреп бара. Менә ул, Искәндәрия шәһәренең үзәк урамнарының берсендә, дөньядагы барлык төрдәге машиналар ташкынына карап, сокланып торганда, җиңел кабриолетка җиккән гарәп аты килеп чыга. Шундук «ролле-ройс», «ягуар», «мерседес» һ. б. маркалы машиналарның автор өчен ике тиенлек кызыгы да калмый. Ул аны сөйгәненең сылулыгын сурәтләгәндәй, мавыгып тасвирларга тотына: «Дугаланып торган аккош муен. Сылу гәүдә. Кырып эшләгән орчыкка охшаш озын, матур аяклар. Киң горур күкрәк һәм ут янып торган акыллы күзләр. Сулыш алганда атның танау тишекләре киңәеп китә, тояк астыннан чаткы чәчри...» Авторның нигә шулкадәр ат белән мавыгуын аңлар өчен халкыбызның «Каз канатлары ак була, ир канаты ат була» дигән җырын гына искә төшерү дә җитәдер. Чәчәкле болын, иркен кырлар, бормаланып аккан су буенда ат коендыручы малайлар, яисә атлы, сандугачлы җәйге юка төндә ат көтүче үсмерләр. Менә кайда бит тамырлар! Менә нинди күренешләр сеңеп калган бит язучының балачак хатирәләренә! Ә атны телевизордан гына күргән, яисә пластмасстан ясалган көпчәклесен идәндә тәгәрәтеп йөртүчеләр — бер генә тапкыр да атның ялыннан сыйпамаган, аның йомшак иреннәренә учыннан ризык бирмәгән, акыллы күзләренә карап сокланмаган, иңендә канатлар тоеп, киң кырлар буйлап атка атланып чапмаган малайлар нинди булып үсәр икән? Алар романтиканы яңа төзелешләрдә бульдозерлар белән күпләп акча каеру, квартира, кыйммәтле җиһаз, машинага ирешү дип кенә аңламыйлармы? Менә шушы рухтагы сораулар, уйлар бимазалый авторны.

Миргазиян Юныс, чын хуҗаларча, финансистлар төгәллеге белән, дәүләткүләм әһәмиятле экономик мәсьәләләр күтәрә. Мисаллар бик күп.

Италия портында газ торбалары төйисе корабка Искәндәрия портыннан җиде мең тонна әфлисун төяргә дигән яңа фәрман алалар. Ә әфлисун ящиклары арасына салынырга тиешле такталар юк. Мисыр җирендә такта әфлисуннан кыйммәтрәк. Такта табу мәшәкатьләре белән шактый көннәр бушка уза. Әфлисун нәзберек җимеш, аны озак саклап булмый. Ул арада яңа ел якынлаша, ә Искәндәриядә төялгән йөк иске ел планына керергә тиеш. Менә Мәскәүдән бер-бер артлы радиограмма килә башлый, ашыгырга боералар, план яна, йөкләмә үтәлми кала — макталу, абруй, премия бар да «оча». Докерларны өстәмә түләү белән өч смена эшләтә башлыйлар. Бу хәл дәүләткә керәсе табышны уникс мең долларга киметә. Өстәвенә, соңгы радиограмма йөкнең сигез йөз тоннасын портта калдырып китәргә мәҗбүр итә. Әгәр йөк тулысынча төялеп беткән булса, дәүләткә җитмеш меңгә якын өстәмә табыш керәсе булган. Югары пост биләүләреннән файдаланып, үз мәнфәгатьләрен генә кайгыртучылар, туган илгә килгән зыян бәрәбәренә, премия алачаклар бит әле!

Гомумигътибар үзәгенә алынган проблема — эчүчелек — Миргазиян Юнысны бик күптән борчый. Ул үсмер чагында, авыл комсомол оешмасы секретаре булып эшләгәндә үк, бу йогышлы чирдән котылу юлларын эзләгән, әле һаман шуны дәвам итә.

Менә ул, төнге сәгать өчтә торып, иртән вахтага чыгасы кешеләр белән кызыксына. Чыннан да, ашханәгә барып керсә, «автовыпивка» күренешенә тап була. Чайкалу вакытында, кеше күзеннән качып, шешә кочаклап идәндә шуышып йөрүче «өч борын»: штурман Аксютин, боцман Нагнибеда, электромеханик Соколов. Аларның үзүзләрен тотышлары шулкадәр көлке, әмма бу инде кызык көлү түгел, чарасызлыктан, «менә яшьләр арасында ниндиләр дә бар» дигән әрнү белән аралашкан сарказм. Әгәр шуннан берничә сәгать элек кенә бу кешеләрнең күпме табыш югалтуларын уйласаң, күз яше аша көлү дияргә дә була.

Ә тынычлык өчен көрәш?! Бу мәсьәлә һәрвакыт авторның күңел түрендә, ул һәрвакыт шушы хакта уйлана. Америка империалистларына — үзләрен «бөек халык» санап, башка халыкларны басып алырга, хәтта юк итәргә план коручы, күпләп атом коралы туплаучыларга каршы ачы нәфрәт; табигать могҗизасы Кеше дигән гали затка бәхет, иминлек теләү хисе, гуманизм әсәрнең тукымасында, рухында.

Дөрес, кайбер очракларда автор көчсез. Яшьләрнең ниндидер кыргый хискә бирелеп каты бәгырьлелек күрсәтүләре аны авыр тетрәнүләр кичерергә мәҗбүр итә. Бөтен экипаж бер булып, акуланы вәхшиләрчә җәзалап үтерү күренеше аның «яшәешен канга буягандай» тоела. Башы киселгән акуланың чәбәләнүе күз алдында кызыл шәүлә булып күренеп тора. Кайбер егетләрнең шешә белән дуслыклары, тарихи ядкарьләргә ихтирамсызлык күрсәтү очраклары, ризыкны исраф итүләре, дневальный Иринаның ирләр белән булган мөнәсәбәтендәге тотнаксызлыгы, гомумән, адәм баласындагы һәрбер кимчелек әдипнең җанын талый. Әмма ул, тәрбия эше дөрес куелган очракта, бу кимчелекләрнең бетүенә ышана.

«Тәрбия — ул кешеләрдәге яхшы сыйфатларны үстерү, көчәйтү, начар сыйфатларга каршы көрәш, кешеләрнең рухларын баету, шул байлыкка дөрес юнәлеш бирү дигән сүз...!» Болары анық үз сүзләре.

Әдип безне, үзенә ияртеп, экзотик табигатьле ерак илләргә сәяхәткә алып чыгып китә һәм күргәннәрен бәйнә-бәйнә сөйли. Язучы бертуктаусыз уйлана, һәрбер күренешнең асылына төшәргә тырыша, үз фикерен, уйларын, фәлсәфәсен шәрехләп күрсәтә; тәҗрибәле, акыллы һәм югары культуралы кеше буларак төпле нәтиҗәләргә килә. Әдип, гади күзәтүләрдән чыгып, фәлсәфи гомумиләштерүләр ясый, әдәбиятыбызның интеллектуаль дөньясын баета, укучыны уйланырга өйрәтә.

Әсәрнең үзенә тартып тора торган тылсымлы көче бар — аны ничәмә-ничә кабат дөньяңны онытып укырга була. Ул сиңа эстетик ләззәт, гыйлем бирә, күп кенә томанлы мәсьәләләргә ачык күз белән карарга өйрәтә. Әйтерсең, автор күптән үк илебездә шушындый саф җилләр исәчәген, бөек борылыш чоры — уңышларыбыз белән бергә кимчелекләребез турында да авыз тутырып әйтә алырдай заманнар киләсен белгән! Әйтерсең, ул СССР язучыларының VIII съездында сөйләнәчәк докладларның эчтәлеге белән моннан ун ел элек таныш булган. Язучының алдан күрүчәнлеге, масштаблы фикер йөртә алуы, ил гаме, халык интереслары белән янып яшәве менә шул буладыр инде ул!

Повесть гадилеге, халыкчан тәгъбирләре, һәр җөмләдән саркып торган самимилеге, ихласлылыгы белән сине беренче юлларны укуга ук әсир итеп өлгерә. Әмма анда дидактика, нәсихәт юк, бары да тормыш күренешләреннән, реаль җирлектән алынып ясалган нәтиҗәләр. Масаю, кәперәю дигән нәрсә юк, киресенчә, ул үз кимчелекләреннән көлүдән дә тайчынмый. Үзе турында сөйләгәндә ул юморга бигрәк тә юмартлана.

Менә ул Ла Валетти (Мальта утравы) портында, урам аркылы чыкканда машина астына эләгә, бәхетле очраклылык аркасында гына үлми кала, әмма шактый күңелсезлекләргә дучар була. Аңа, өч ел буе бушлай эшләсә генә түләп бетерерлек, штраф салалар. Авыр хәл... Әмма... көләсең, күзләреңнән яшьләр ага башлаганчы көләсең... Янсә, безнең героебыз кышкы салкында, башына оекбаш киеп, башкала урамы буйлап өенә кайта... Я, волокита аркасында гына самолетка соңга калып, Ростовка илтә торган олы юл читенә чыгып басып, үткән-барган машиналарга «тавыш биреп» торырга мәҗбүр була. Шундый маҗараларга мөнәсәбәттә, көчле рухлы шәхес буларак үзе дә ачыла, юлында очраклы рәвештә генә күзенә юлыккан һәркемне күзәтеп, аңлап, күреп өлгерә: бер-ике генә штрих һәм күз алдында туры бер портрет, характер, җанлы кеше.

Китапта тагын бер повесть бар — «Биектә калу». Бөек Ватан сугышы турында язылган көчле һәм тетрәндергеч әсәр.

Автор унҗиде яшьлек үсмер килеш сугышның соңгы елларында, авиациядә хезмәт иткән, булачак геройлары белән бергә яшәгән. Миргазиян Юныс, гомумән, бары тик үзе күргән, үзе кичергән вакыйгаларны гына әсәрләренә сюжет итеп ала. Ул бик үзенчәлекле, ачык төсмерләнгән характерларны сурәтләргә ярата, хәрәкәт дәвамында ук характерларның яңадан-яңа якларын ача килә.

Үзәк геройларның берсе Сәйрин Сәлахов. Автор исеменнән багышлауда ук аның Бөек Ватан сугышының соңгы көннәрендә һәлак булган реаль шәхес икәнлеге ачыклана.

Сәйрин туган авылыннан башка җирдә булмаган, иген игеп, авыл табигате белән хозурланып, әти-әни, әби-бабайларның гореф-гадәтләрен, көнкүреш ысулларын үзләштереп үскән егет. Үсмер еллары, әле буыннары да ныгымаган килеш, фронт өчен олы ирләр эшен башкарып, яшьлек еллары авиаполкта, дошман объектларын бомбага тотучы очкычларда үтә. Егерме яше туларга дүрт көн кала, сугышчан бурычын тулысынча үтәп, дөнья белән бәхилләшә ул...

Дөрләп янган самолеттан соңгы кеше булып ул сикерә. Әмма ...парашют ачылмый. «Туракланып беткән ак ефәк бәгырьләрне ачыттырып баш өстендә җилферди иде. «Снаряд ярчыгы ерткан...» Өч секунд калды... Сәлахов талпынды, гаиләмне кочып алырлык итеп, кулларын канат итеп җәеп җибәрде. Мәңгегә җитәрлек итеп, комсызлык белән һава йотты. Сулыш — яшәү. Зәңгәр күк, кояш... утка пешкән битнең авыртуы, күкрәктәге кайнар тойгылар — барысы да яшәү. Аста җир. Кешеләр. Тормыш. Җир коточкыч тизлек белән якынлаша. Бер... Ике... Өч...»

Сәйриннең үлем белән йөзгә-йөз очрашуы беренче генә түгел, әмма бусы соңгысы...

Өлкән лейтенант Сәйрин Сәлаховка, бу заданиега кадәр үк, Советлар Союзы Герое исеме бирү турында документлар әзерләп җибәрелгән, ул җитәкчелек иткән экипаж сан ягыннан да, җимерелгән объектларның җитдилеге буенча да полк күләмендә беренче урынга чыккан була.

Алар соңгы заданиега өчәү баралар. Икенчесе штурман Максим Майнагашев. Айхал якуты, кәкре аяклы бер кеше. Йөзе, кыяфәте матур булмаса да, рухи күркәмлеге һәм Җик Мәргәндәй төз атучы булуы белән эскадрилья очучыларын әсир итеп өлгергән. Максим «илле метрдан атып, лейтенант Коненконың фуражкасындагы крабны тишеп чыгара», үзенә генә хас табигый бер эчке тоем белән «дүрт мең метр биеклектән бомбаны кое эченә салып китә» ала. Өстәвенә, Майнагашев гаҗәеп нечкә күңелле, сабыйларча беркатлы, күркәм холыклы кеше. Адашып, ачлыктан үләр хәлгә җиткән

эт баласын яшь баладай тәрбияләү дисеңме, соңгы очышка барганда өй кыегында карлыгач оясы күреп сөенү дисеңме, төшендә әнисен, ерактагы тундрасын, боланнарын күреп күз яшьләре кою дисеңме...

Сәлахов исә үзенең штурманына башы-аягы белән гашыйк, ул аңа карап сокланып та, куанып та бетә алмый.

Экипажның өченче әгъзасы укчы-радист, сержант Марсель Ялчинский. Кара диңгез буендагы ак калада туып үскән тәрбияле, зыялы егет. Әнисе үз республикасының халык артисткасы, әтисе сәнгать белгече, профессор булган. «Ирләр колагына гына ярарлык анекдот сөйләү, кызлар турында шапырынулар аны ифрат рәнҗетә».

Егет сугыш барган чорда әтисен, әнисен, ике сеңлесен югалта, туган төбәгенә килгән һәлакәт аны тирән кичерешләргә дучар итә. «Әмма ул бик түзем һәм нык ихтыярлы егет булып чыга. Эчендәге тойгылар давылын яшерә белә». Бары тик авыз гармунына гына йөрәге әрнүләрен, сагышын, моңын ышанып тапшыра... Марсель үз вазифасын төгәл, оста башкара, «Сәйрин укчы-радисттан да уңа».

Егетләрнең өчесе илнең өч почмагында үссә дә, өчесе өч милләт кешесе булса да, аларны Ватанга бирелгәнлек, үз өстеңә йөкләнгән бурычка җитди караш, туган ил хакына үлемгә барырга да әзер тору хисләре берләштерә. Соңгы очыш, соңгы задание алар өчен һәлакәт белән тәмамлана.

Әсәрдә Сәйриннең сөйгән кызы Разия, аның көчле мәхәббәте, мәхәббәттәге тугрылыгы психологик нечкәлек белән тасвирлана. Сөйгәне кайткач коймак пешерергә дип, ике кило онны саклап тоткан кыз ачлыктан аңын югалту хәленә килә, күзләре күрми башлый. Больницада ятканда да ул сәламәтләнүен булачак эшен уңышлы башкару һәм «Сәйрингә тыныч, рәхәт тормыш шартлары оештыру өчен кирәк» дип саный. «Гаиләдә иминлек, татулык, тынычлык өчен ул җавап бирәчәк». Ләкин кызның матур хыяллары тормышка ашмый кала: аның язмышы да коточкыч фаҗига белән бетә — Сәйринне югалту кайгысыннан ул акылыннан яза...

Шулай итеп, яшәргә тиешле, кешеләргә һәм җәмгыятькә игелек күрсәтергә, бәхетле булырга, нәселләрен сакларга хаклы олы җанлы, чын Кешеләрнең гомерләре киселә.

Сәлахов экипажына задание, дивизия командиры кияве, өлкән лейтенант Орлов агып кайткан белешмәләрдән чыгып бирелә. Гаделлек булганда, үзе күреп кайткан объектны бомбага тотарга Орлов үзе барырга тиеш, моны барысы да аңлыйлар. Әмма... шулкадәр хәтәр операциягә ничек инде шундый кешенең киявен җибәрмәк кирәк?!. Бары тик майор Растопчин гына Орловны җибәрү турында тәкъдим ясый. Тик аның фикерен бер генә кеше дә куәтләми... Киеренке тоташ сюжетның үзенчәлекле характерлар белән кушылуы зур эстетик көчкә ия булган әсәр барлыкка китергән.

«Гөлҗамал» көе повестьның буеннан буена лейтмотив булып бара, әсәргә лирик җылылык, моң өсти. Марсельнең соңгы очышка күтәрелер алдыннан авыз гармунында уйнавы да, мәҗлескә җыелган карчыкларның мөнәҗәтенә кызлар җыры кушылу да, повестьның катлаулы композицион структурасына шигъри детальләр булып өстәлә.

Ике әсәрне дә берләштергән төп проблема — әхлак мәсьәләсе. Автор сөю хисен дә кешенең бөтен табигате, әхлак йөзе белән бәйләнештә карый. Язу предметлары никадәр төрле булса да, повестьлардагы тенденцияләрнең уртаклыгы сизелеп тора. Үз бурычыңны һәм җаваплылыгыңны тою, бөек идеаллар хакына үз-үзеңне корбан итәргә әзер тору, игелеклелек тойгысы, туган иленә һәм кешеләргә мәхәббәт әсәрләрдә шигъри итеп тасвирлана. Кеше бүгенге көн өчен генә түгел, ә киләчәк алдында да бурычлы. Автор, үз геройлары мисалында, әнә шул зур фикергә басым ясый.

Миргазиян Юнысның бу әсәрләре аның, язучы буларак, һаман үсә баруын, тагы да зуррак биеклекләр яулый баруын күрсәтә. Андый әсәрләр безгә, әдәбият сөючеләргә, олы бүләк!

**Ләлә САБИРОВА-ХӘЙДӘРОВА.**

Рафаэль Мостафин

# АБДУЛЛА АЛИШ БЕЛӘН ОЧРАШУ

ГАЗЫЙМ КАДЫЙРОВ ИСТӘЛЕГЕ БУЕНЧА

Польша җирендә Седльце лагере...

Коточкыч олы, бер генә яшел үләне дә калмаган шыксыз мәйдан чәнечкеле тимерчыбык белән уратып алынган. Ара-тирә югарыга такта вышкалар күтәрелгән. Вышкаларда автоматлар, эре калибрлы пулеметлар белән коралланган немец сакчылары. Төннәрен прожекторлар кабына, овчаркалар өргән тавыш ишетелә.

Лагерьга йөз меңгә якын совет әсире тупланган. Хәер, төгәл санны беркем дә белми. Берәүләр ачтан үлә тора, алар урынына көн саен диярлек эшелон-эшелон яңа әсирләрне китереп торалар. Кеше башына көненә илле грамм икмәк телеме (аның да яртысы пычкы онынннан, калганы җыен чүп-чар кушып пешерелгән) һәм консерва банкасыннан ясалган савытка салып баланда бирәләр.

Вышкада немец сакчылары, ач әсирләр күзе алдында, колбаса, сыр, галет ише әйберләр ашап утыралар. Ачлыктан кешелек горурлыгын тәмам җуйган кайберәүләр (кызганычка каршы, әсирләр арасында андыйлар да табыла) вышкаларга якынрак елышып, селәгәйләрен агызып, өскә карап торалар. Немецлар калган сыныкларын ара-тирә ыргыталар да, тешләрен ыржайтып, әсирләрнең, этешә-төртешә, ташландык сынык өчен сугышуларын карап торалар. Арада кәгазьгә төргән ат тизәге, я берәр тутыккан тимер кисәге дә булгалый. Ә инде тоткыннар күбрәк җыйналса, кәгазьгә төреп, «лимон» гранатасы тондыралар. Каты шартлаудан соң тузан басылгач, ун-унбиш мәет ятып калганы күренә...

Эшкә бара алмаган, хәлсез әсирләр, утырган җирдән генә булса да, алюмин кисәгеннән матур итеп бизәкләп, сырлап-шәрехләп портсигар, теш тазарта торган таушалган щетка сапларыннан — төрле төстәге тәмәке мундштугы, җиз акчадан — балдаклар, саламнан — курчаклар, «келәмнәр» һәм башка шулар ише әйберләр ясыйлар. Һәрбер лагерьның үз «базары» була. Базарда шул әйберләрне «сату», дөресрәге — алмашу бара. Иң югары бәяле «валюта» — икмәк. Бер телем икмәккә бер сәгать алмаштырырга мөмкин. Икмәктән кала «акча» урынына черек бәрәңге, пәжегән кишер, чөгендер яфрагы һәм башка ашардай әйберләр йөри. Күпләр сату-алу өчен түгел (бетләрен алучы табылса — сатырлар иде), фәкать карап йөрү, аралашу, якташларын табу өчен генә «базарга» чыгалар. Шуңа күрә, «төшемә» әллә ни булмаса да, «базарда» кеше умарта күче сыман һаман гөжләп тора.

Нәкъ менә шундый «базарда» йөргәндә, Газыйм Кадыйров кечкенәрәк буйлы, йөзен чегәннәрнеке сыман куе кара сакал-мыек баскан бер әсирне күреп ала. Аның өстендә ямаулы иске шинель, башында төсе уңган олырак пилотка, аркасында — яшел төстәге поход капчыгы. Бер аягын сөйрәп, аксабрак йөри. Үзе коточкыч ябык, хәлсез. Калын кара кашлары астыннан эчкә баткан шундый ук кара күзләре генә ялтырап торалар. Татар икәнен абайлап,

Кадыйров аңа сүз куша. Тегесе дә татарча җавап кайтаргач, танышып, сөйләшеп китәләр. Бу кеше үзен: «Мин Абдулла Алишев, Казаннан, балалар язучысы»,— дип таныштыра.

Лагерьда халык төркем-төркем оешып яши. Берәрсе хәлдән таеп егылса, дуслары я су китереп бирә, я берничә кашык баланда таба, һәрхәлдә, ничек тә ярдәм итәргә тырыша. Ялгыз бүре сыман аерым яшәгән кешеләр тиз үләләр... Г. Кадыйровның да биш-алты кешедән оешкан төркеме була. Алишның монда әле яңа кеше булуын, беркемне дә белмәвен ачыклагач, Кадыйров аны үзләре янына алып кайта.

Бу кичне алар учак янына җыйналып, калай савытта су кайнатып, озаклап «чәйләп» утыралар. Алиш күкрәк кесәсеннән соңгы сынык икмәген чыгарып, иптәшләренә тигезләп бүлеп бирә. Кадыйров капчыгында бер шалкан, икенче берәүнең чикләвек зурлыгы гына берничә бәрәңгесе табыла. Барысын уртага салып, ком өстенә утырып, «кичке аш» ашыйлар. Яңа кеше барлыгын күреп, алар янына «кунакка» башка төркемнәрдән дә таныш әсирләр килгәләп китә.

Г. Кадыйров хәтерендә Алишның солдат кашыгы калган. Абдулла аның бер ягын очлап, пәке ясаган. Мондый кашык-пәке барысына да ошый— гаҗәпләнеп, кулдан-кулга йөртеп, карап чыгалар. Шул арада үзләрен кызыксындырган сорауларны да биргәлиләр. А. Алиш 1941 елның октябрь аенда Брянск тирәсендә барган каты сугышлар вакытында әсирлеккә эләккән икән. Ул хезмәт иткән часть чолганышта калган, Алишның аягы яраланган, шуышып-тырмашып, ул әллә ни ерак китә алмаган. Беренче кышны Литваның Алитус шәһәре янындагы лагерьда үткәргән. Ул килгәндә, бу лагерьда 17 мең совет әсире булса, кыш чыкканчы 12–15 меңе кырылып беткән... «Син ничек исән калдың соң?» — дип сорагач, «Мин тартмый идем, шул ярдәм итте»,— дип шаяртып җавап бирә Алиш. Моннан аны Чехословакиягә күчерәләр. Аннан Франция, Голландия, Польша җирләре... Илләре төрле булса да, шартлары барысының да бер чама була.

А. Алиш бер немец алпавыты хуҗалыгында да хезмәт иткән (унарунбишәр кеше, ат арбасына җигелеп, кырларга тирес ташып түккәннәр), заводта шомартучы булып та эшләгән, урман да кискән. Соңгысы никадәр авыр булмасын (зур-зур бүрәнәләрне җилкәгә салып ташыганнар), шулай да җирле халык ярдәмендә ул бераз ныгып кала, шуның аркасында иң авыр вакытларда да бирешми, төшенкелеккә дә бирелми.

А. Алишны барлык әсирләр дә ихтирам итәләр. Ул акыллы, җитди, уйчан. Хәрәкәтләре сабыр. Сөйләшкәндә ашыкмыйча, кабаланмыйча һәр сүзен үлчәп сөйләшә. Аның сүзенә колак салалар. Файдалы киңәшләре күп кешегә ярдәм итә.

Икенче көнне, иртә таңнан торып, комендатура бинасы янына чиратка басалар. Берничә сәгать җил-яңгыр астында басып торганнан соң, немец сакчылары тазаракларын сайлап алып эш командасы төзи. Эшкә чыгу — һәркемгә дә эләкми торган бәхет, чөнки эшкә баручы тамагын ялгап алырга ничек тә берәр җаен таба. Эшкә чыкмаучының исә бернинди өмете юк — бер-бер артлы ачтан кырыла баралар... Аксап-туксап йөргән, тиресендә чыкмаган җаны гына калган Алишны бу юлы да эшкә алмыйлар. Г. Кадыйров тазарак, ныграк була — аны койманың теге ягына чыгарып сафка бастыралар, станциягә эшкә алып китәләр. Таш юлдан агач башмаклар (алар авыр, каты, аякны канга батырганчы кисә, ләкин әсир качмасын өчен «уңайлы») шак-шок итәләр...

Кадыйров баракка агач башмаклары эчендә берәр уч солы, я башка азык-төлек алып кайтырга тырыша. Шуңа башмакларның да зуррагын кия. Немец конвоиры күреп калса, эш харап — күп сөйләшеп тормый, башыңа мылтык түтәсе белән берне генә тондыра. Лагерь капкасы янына җиткәч — тентү. Дөрес, монысын немецлар үзләре түгел — алар тифтан курка — полицайлар ясый. Алар арасында да эт кебек усаллары була, берәр нәрсә тапса, таягы белән җан көченә чәпи... Кич саен диярлек әсирләрне күңелсез хәбәрләр көтә. Ул кайтуга берәр иптәше үлгән, яки тере килеш мәетләр әрдәнәсе янына илтеп ташланган була. Газыйм ага аны эзләп таба, су бирә, авызы-

на пешкән бәрәңге каптырырга маташа. Тегесе исә алмый. Мин барыбер үләсе кеше: үзең аша, имеш...

Шушындый шартларда яшәүләренә карамастан, Алиш поход капчыгында таушалган калын дәфтәр белән каләм йөртә. Немец сакчылары күрә алмаган аулаграк урын таба да, нәрсәдер яза. Иптәшләре, аның шигырь язганын белгәнгә, комачауламаска тырышалар. Кадыйров үзе дә кечкенәдән шигырь, җыр ярата, әкият сөйләргә һәвәс була. Шуңа да ул Алиш язганнарны зур кызыксыну белән тыңлый. Бу шигырьләрдә әсирләр тормышы, алар кичергән хәл тасвирлана. Автордан сорап алып, ул берничә шигырьне үзенә күчереп ала. Алар арасында «Сагынам илемне», «Ул төшне мин кабат күрерменме?», «Акчарлак», «Иркәм хаты» һәм башка шигырьләр була. Бу шигырьләр белән башка татар әсирләре дә бик кызыксына. Кадыйров аларга укый-укый шигырьләрне ятлап чыга. Бервакыт Алишның үзенә дә яттан укып күрсәтә.

— Андый сәләтең булу бик яхшы,— ди аңа Абдулла.— Язмаларны саклау мондый шартларда—икеле. Илгә исән-сау кайта алсаң, Казанга барып тормыш иптәшем Рокыяга, әниемә, туганнарыма барын да сөйләрсең.

— Әй, Алиш абый!— дип юатып карый аны Кадыйров.— Үзең кайтып сөйләрсең әле...

— Юк, энем,— ди Алиш абыйсы бик җитди итеп.— Миңа кайтулар эләкмәс, ахры. Күңелем сизенә — үткән юллар нинди авыр булмасын, үтәселәре тагын да катлаулырак. Үтенечем шул: хәтердә калган шигырьләрне кәгазьгә теркәп Татарстан Язучылар союзына тапшыр.

Г. Кадыйров иптәшенең бу үтенечен үти. Илгә кайту белән истә калган шигырьләрне язып, Татарстан Язучылар союзына тапшыра. Алиш белән очрашулары турында да бәйнә-бәйнә сөйли. Тик ул вакытта аның сүзләренә Рокыя Алишевадан башка, колак салучы гына табылмый. Хәтта куркытып алучылар да табыла: халык дошманы турында күп сөйләнеп йөрмә, янәсе...

Бу шигырьләр әле дә Язучылар союзының архивында саклана. Алар әллә ни күп түгел — нибары җиде-сигез. Кайбер юллары онытылган, сүзләре буталган, шуңа күрә кайвакыт шигырьнең очы очка ялганмый. Шулай да Алишныкы икәнлекләре әллә каян күренеп тора. Моннан тыш, Г. Кадыйров әйтүенә караганда, Алишның проза әсәрләре дә булган. Күрәсең, ул көндәлек дәфтәре алып барган, нәсерләр дә язган (шуларның берсе, «Сандугач» исемлесе, туган ягының табигате турында булган). Алиш әкиятләр дә язган — тик бу юлы балалар өчен түгел, зурлар өчен. Шуларның берсе Г. Кадыйров хәтерендә аеруча уелып калган.

Явыз кара елан керпене әсир итеп, җир астындагы караңгы сасы базда тота. Керпе берни дә эшли алмый — елан аны көн-төн саклый, качып котылырга бернинди әмәл юк. Шуннан керпе әкренләп еланга якынрак елыша, җаен туры китереп, энәләре белән чәнчеп-чәнчеп ала. Еланның тиресе тишекләнеп бетә. Ысылдый-ысылдый да, ахырдан оясын ташлап чыгарга мәҗбүр була. Г. Кадыйров әйтүе буенча, бу әкиятнең мәгънәсен әсирләр яхшы аңлаган, кичләрен учак янына җыелышып утырганда бер-берсенә сөйли торган булганнар.

Әсәрләр белән чикләнмичә, Алиш иптәшләренә турыдан-туры да әйткәләп куя:

— Иң мөһиме — дошман алдында йомшаклык күрсәтмәскә. Нык булырга кирәк. Фашистларның көче көннән-көн азая. Безнең урамда да бәйрәм булыр әле,— ди.

Вакыт үтү белән Алиш ниндидер яңа танышлар таба, кичләрен алар белән нәрсә турындадыр пышылдашып йөри. Лагерьда, кулдан язылган, листовка-өндәмәләр йөри башлый. Русча да, татарча да язылганнары була. Өндәмәләр әсирләрне нәкъ Алиш әйткәнчә Ватанга турылыклы булырга, чын кеше, совет патриоты булып калырга чакыра. Шундый бер листовканы Кадыйров Алиш кулында да күреп кала. Ләкин төпченеп тормый: кирәк дип тапса үзе дә әйтер әле дип уйлый. Абдулла иптәшләренә сугыш хәлләре турында иң соңгы яңалыкларны да хәбәр итеп тора. «Кайдан беләсең?» — дип сорагач, «кайбер иптәшләрем радио аша тыңлыйлар»,— дип кенә җавап

бирә. Әсирләр лагеренда кайдан радио булсын? Моны Г. Кадыйров аңламый кала. Ләкин күрә: Совинформбюро хәбәрләре дә листовкалар формасында кулдан-кулга күчеп йөри...

Әсирләрне Власов армиясенә өндәү башлана. Лагерьга хәрби киемле дә, гражданский киемле дә ниндидер чит-ят кешеләр килә. Алар әсирләрне үзәк мәйданга җыеп, немец яклы агитация алып баралар. Власов армиясенә язылырга чакыралар. Поп, муллалар да килеп чыга. Болары дингә таянып «денсез» большевикларга каршы сугышырга чакыра. Барысы да әсирләрне «җәлләгән» булып кылана, дошман армиясенә язылганнарга алтын таулар— немец солдаты паегы, яңа кием һ. б. вәгъдә итә. Алиш аларның барысын да «кусочниклар» дип атый.

Фашистларның ниятен яхшы аңлаган әсирләр ачтан үлсә үлә, әмма Власов армиясенә язылмый. Күнүчеләр бик сирәк табыла. Моны искә алып булса кирәк, немецлар тактиканы үзгәртә — әсирләрдән сорап-нитеп тормыйча, тазаракларын үзләре сайлап алып, көчләп яза башлыйлар. Моны алар нигездә — татар, башкорт, чуваш һ. б. милләтләр белән шулай эшлиләр. Сайлап алынган әсирләрне «милли легион» дип аталган хәрби частьларга илтеп ташлыйлар. Алиш легионга каршы да агитация алып бара, ләкин мондый шартларда эшләр шактый кыенлаша...

Бервакыт, Алиш белән Кадыйров кухня тәрәзәсендә ташландык бәрәңге кабыклары чүплап йөргәндә, немец сакчылары килеп чыга. Комендатура янына алып барып, аңнарын югалтканчы кыйныйлар. Аңнарына килгәндә караңгы юеш базда икәнлекләрен күрәләр. Тышта инде караңгы төшә башлаган — димәк, алар берничә сәгать аңсыз ятканнар. Башлары-күзләре — тоташ кан. Уйсурак җирдә җыелган су табып, юынып алалар, үзара киңәшәләр. Бәрәңге кабыгы өчен генә фашистлар болай каныкмаслар иде. Димәк, аларны берәр шымчы саткан булырга тиеш. Әйе, лагерьда андыйлар да була — бер буханка икмәк, я бер тартма немец сигареты өчен кеше башын ашыйлар.

Күпмедер вакыт үткәч, ишек ачыла, подвалга кесә фонаре тотып аватүнә немец офицеры төшә. Күкрәгендә чуен тәрене күреп, тоткыннар сагаеп калалар — мондый тәрене фронтта батырлык күрсәтеп яраланган немец солдатларына гына бирәләр. Немец әзрәк «кәефләнеп» алган, борын төбеннән нәрсәдер мыгырдап, җырлаган сыман кылана. Боларның исән икәнлекләрен күргәч, гаҗәпләнеп, үз күзенә үзе ышанмаган сыман карап тора. Аннан яман сүгенеп чыгып китә. Бераздан икенче бер сакчы төшеп, тоткыннарны шул тирәдәге икенче бер бинага алып килә, артларыннан ишекләрен бикли. Бу тәрәзәсез-нисез, таш идәнле тар гына бүлмәдә искиткеч якты була— түшәм турысында прожектор сыман көчле лампа яна. Башта әсирләр моңа әллә ни игътибар итмиләр. Ләкин тора-бара гадәттән тыш яктылык үзенә күрә бер җәза икәнлеге аңлашыла. Баш әйләнә, күзләр шартлап чыгардай була, чытырдап йомсаң да яшьләр ага. Бу төн аларга мәңге бетмәс кебек тоела... Тагын нәрсә булыр дип торганда, допрос-фәлән алып тормыйлар. Иртән шул немец кереп типкәләп-төрткәләп чыгарып җибәрә...

Моннан соң аларны аерым күзәтү астында тоталар. Юк нәрсә өчен дә бәйләнеп торалар. Лагерь территориясеннән беркая да читкә чыгармыйлар. Лагерь эчендә генә бәдрәф чистарту, немец сакчылары торган казармаларны юу кебек төрле эштә файдаланалар.

Бер вакыт Г. Кадыйров үзләре яшәгән баракка кайтып керсә, Алиш көлеп утыра. «Алиш абый, ни булды?» — дип сорагач, Абдулла сөйләп бирә. Бу көнне аңа бер немец офицеры яшәгән бүлмәне җыештырырга кушканнар. Идән юып бетергәндә генә исерек офицер килеп керә дә бар көченә «Сми-р-рна!» — дип акырып җибәрә. Бәйләнергә сәбәп эзләп як-якка карана. Башка сәбәп таба алмагач, «Ник итекләремне тигез итеп куймадың, алар да синең кебек үрә катып торырга тиешләр»,— ди. Алиш алай итеп, болай итеп карый — кунычлар әле теге, әле бу якка ава да китә, ава да китә. Офицер аның саен җикеренә, пистолетын капшый башлый. Шуннан немец күрмәгән арада Алиш итекләргә берәр пүлән утын агачы тыгып куя. Офицер

күзләрен акайтып итекләренә бераз карап тора да, кулын селтәп, Алишка чыгып китәргә рөхсәт итә. Тагын бер-ике бүлмәне җыештырып чыгып барганда, Алиш әлеге офицерның кычкырып сүгенеп җибәргәнен ишетә. Әкрен генә тәрәзә янына килеп караса — тегесе утырып итекләрен кия башлаган икән, аягын утынга бәреп кычкырып җибәргән. Алиш шуңа көлеп утыра икән.

Шулай да аларның хәлләре бер дә уен-көлке булмый. Фашистларның мыскыллауларына түзә алмыйча, Алиш кичләрен барак буйлап читлектәге кош сыман арлы-бирле йөри торган булган. Тешләрен кысып: «Тукта, мәлгунь, килер бер көн, без дә сиңа кем икәнлегебезне күрсәтербез»,— дип әйтә торган булган. «Башка чара калмады — ничек тә качарга кирәк,— дип әйтә ул Г. Кадыйровка.— Бераз хәл генә җыярга да — качарга».

Шулай итеп качарга план корып йөргәндә, Берлиннан бер өер татар эмигрантлары килеп төшә. Алар татар әсирләрен төркем-төркем дә, берәмберәм дә чакыртып, әңгәмәләр үткәрә башлыйлар. Күбрәк укымышлы кешеләр белән кызыксыналар. Алишны да чакырталар. Алиш бу «әңгәмәдән» бик кәефе кырылып кайта. Озак уйланып йөри, иптәшләре белән киңәшә. Ниһаять, бер карарга килә.

— Миңа Берлинга барырга туры килер ахрысы,— дип әйтә ул бер кичне Кадыйровка.

— Анда барып нишлисең? Берлинда да безнең ишегә шул ук баланда булыр әле...

— Эш анда түгел,— ди Алиш, куе баланда артыннан кумаганлыгын белдереп.— Һәр эшнең үз рәте бар, намазның да рәкагате бар, диләр иде борынгылар. Без бит монда балавыздан ясалган аю сыннары сыман бер файдасызга гомер үткәрәбез. Юк, безгә тик ятарга ярамый.

— Тик ятмыйча, нәрсә эшләр идең соң?

— Керпенең елан өендә нәрсә эшләгәнен хәтерләмисеңмени?— дип, читләтеп җавап кайтара Алиш.

Икенче көнне Алишны тагын комендатурага чакыралар. Шул китүдән ул әйләнеп кайтмый.

Алтмышынчы еллар уртасында шагыйрә Флера Гыйззәтуллина (ул чакта ул Бөгелмә районының Карабаш поселогында яши иде) гарәп хәрефләре белән язылган, шактый таушалган, кул яссуы зурлыктагы дәфтәр җибәрде. Дәфтәр Бөек Ватан сугышында катнашкан, әсирлектә булган, утларны-суларны кичкән авылдашы Зәки ага Әһлиуллинныкы икән. Үзе исән чакта ул бу дәфтәрне беркемгә дә, хәтта туганнарына да күрсәтмәгән. Зәки ага үлгәч кенә, дәфтәрне чорма башында яшергән җиреннән табып алганнар, укып караганнар. Анда әсирләрнең ачы язмышларына багышланган шигырьләр булып чыккан. Җәлил шигырьләре түгел микән?— дигән сорау белән Ф. Гыйззәтуллина дәфтәрне миңа җибәргән.

Дәфтәрдәге шигырьләрне мәрхүм Гази ага Кашшаф белән кат-кат укып карадык. Юк, Җәлилнеке дип әйтерлек бер генә юл да таба алмадык. Нигездә биредә халык иҗаты рухында язылган җырлар иде (Бәлки, аларның кайберләрен Зәки ага үзе әсирлектә чакта чыгаргандыр). Ләкин арада профессиональ кул белән язылган әсәрләр дә бар иде. Шулар арасында Абдулла Алишның дәфтәре буенча безгә күптән таныш булган «Очрашу» шигыре дә имзасыз-нисез кучереп язылган иде. Калган шигырьләрнең авторын ул чакта ачыклый алмадык.

Шактый еллар үткәч, К. Ишмури истәлекләрендә шундый бер фактка юлыктым. Ул 1943 елның көзендә Седльце лагеренда Абдулла Алиш белән очрашып сөйләшә. Абдулла аңа лагерьда бик якын дустын, балачактан бергә уйнап үскән авылдашын очратуы турында сөйләгән. Дусты бу вакытта бик ябык, шәүлә генә булып калган, гәүдәсен көчкә сөйрәп, бер валчык икмәккә, бер тамчы суга зар тилмереп йөргән. Бер-берсен танып, кочаклашып үбешкәннәр, шатланып сөйләшкәннәр, елашканнар. Шуннан Алиш кайдадыр (су эзләп булса кирәк) китеп барган. Кайтса — иптәше юк. Соңыннан гына белгән: иптәше җил-яңгырдан ышык эзләп, комны казып, җир астында оя

ясаган булган икән. Шунда чакта ком ишелеп, аны басып үтергән...

Бу турыда Алиш озын бер шигырь яки кечкенәрәк күләмле поэма да язган булган икән. Поэма кулдан-кулга күчеп әсирләр арасында киң таралган булган. Бу вакыйга турында укыгач, Алишның «Очрашу» шигыренә карата язылган искәрмәсе кылт итеп исемә төште:

«Әсирләр лагеренда бер иптәшем белән фаҗигале очрашуга карата язылган бу шигырьне күп әсирләр үзләренең дәфтәрләренә күчереп алганнар иде». Димәк, З. Әһлиуллин дәфтәренә дә бу шигырь очраклы килеп кермәгән! Дәфтәрдәге шигырьләрне тагы кат-кат укып карадым... «Очрашу» шигыре шактый күләмле әсәрдән бер өзек кенә икән! Дөрес, Әһлиуллин дәфтәрендә бу әсәр шактый бозылып күчерелгән, кайбер строфаларның урыннары буталган, ахыры башка, башы ахырга күчкән. Шулай да бер бөтен әсәр икәнлеге әллә каян күренеп тора!

Шушы яңа табылган әсәрне, бераз кыскартып, редакцияләп, укучыларга тәкъдим итәбез (Әсәрнең тулы күләме — 94 юл. Шуларның 6 строфасы, ягъни 26 юлы, безгә Алиш дәфтәре буенча билгеле иде).

## Абдулла Алиш

### Очрашу

Урыныннан купкан агач кебек,
Авар-аумас атлап киләсең,
Кыяфәткәйләрең кызганырлык,
Үзәккәйләремне өзәсең.

Танымаслык булып үзгәргәнсең,
Бу синме соң, әллә шәүләңме?
Кайчан гына батыр егет идең,
Чак йөртәсең хәзер гәүдәңне.

Киемнәрең тәмам теткәләнгән,
Ябык тәнең ярты ялангач.
Сүзең авыр чыга, күренеп тора
Күптән инде синең карының ач.

Ә шулай да өмет чаткысы бар
Янып торган шомырт күзеңдә,
Киләчәккә көчле ышанычың—
Ютәл аша чыккан сүзеңдә.

Без биредә суга зар тилмереп,
Комда үскән чәчкә шикелле,
Кибеп, шиңеп беттек. Явыз язмыш
Шушы хәлгә безне китерде.

Ярдәм итер идем, туган, сиңа,
Минем кулдан килми ул ярдәм,
Син үзең дә аны аңлыйсыңдыр —
Күзләреңнән укып мин күрәм.

Хәтерләдек ерак туган илне,
Семьяларны, якын дусларны,
Хәтерләдек, җырлап исәнлеккә
Күтәрелгән тулы тостларны.

Туган илдә ничек сыйланулар,
Коштай иркен йөргән вакытлар,

Төштәгедәй барысы ерак калды
Илдә үткән татлы минутлар.

Әй, кайда сез, безне тәрбияләп
Үстерүче изге аналар?
Әй, кайда сез, сарылып елый-елый
Озатып калган сабый балалар?

Әй, кайда сез, безнең нечкә билләр?
Эштә чыныгып үскән аталар?
Әй, кайда сез, энекәш, сеңелкәйләр?
Әй, кайда сез, абый, апалар?
Сездән кадер күргән күпме кеше
Тилмерешеп монда яталар.

Хаты-хәбәре юк, үлде ахры диеп,
Ашыкмагыз дога кылырга.
Явыз үлем белән көрәшәбез
Исәп әле тере калырга.

Теләгебез сыерчыклар кебек
Язын туган илгә кайтырга,
Сезнең белән елап күрешергә,
Өебездә рәхәт татырга.

Әнә шундый төрле сүзләр белән
Бераз юанышып утыргач,
Яшь күңелләр безнең нечкәләнеп
Күзләрне яшь белән тутыргач,

Мин салкын су эзләп китеп бардым
Янган йөрәккәйне басарга...
Ә кайтканда син юк идең, туган,
Сине кайдан эзләп табарга?

Сәер базар сыман шаулап торган
Лагерь эчен байтак айкадым.
Туганымны кабат очратмадым,
Күпме эзләсәм дә тапмадым.

Кая киттең, суга төштеңме соң?
Алтын кисәге күк югалдың,
Бергә үстек, бер дә аерылмадык,
Инде хәзер ялгыз мин калдым.

Сөйләделәр миңа тик соңыннан
Өрәк кебек хәлсез кешеләр,
Җилдән качып кергән чокырыңа,
Синең өскә балчык ишелгән.

Бу вакытсыз корбан. Җир куены,
Беләм, аны кабул итәрсең.
Ә син, явыз фашист, әле байтак
Кешеләрнең башына җитәрсең.

Йөрәгем ачу белән телгәләнде,
Нәләт уты гөрләп кабынды.
Безне шушы хәлгә илткән фашист
Ләгънәт белән искә алынды.

**Жанна Иткина**

# РАХЛИН МОГҖИЗАСЫ

## НАТАН РАХЛИН ИҖАТЫНА БЕРНИЧӘ ШТРИХ

Совет дирижерлык мәктәбенә нигез салучыларның берсе, СССРның халык артисты Натан Рахлинның исемен Туган илебездә генә түгел, чит илләрдә дә яхшы беләләр. Классик музыканы да, хәзерге заман музыкасын да үзенә хас фикер сөреше белән баета белүче тиңдәшсез художник илебезнең төрле шәһәрләрендә симфоник оркестрларны оештыручы һәм аларның художество җитәкчесе булды. Киң күңелле, үзенең рухи байлыгын юмарт өләшүче бу кешенең шушы зур эшчәнлеге, кызганычка каршы, үзе исән вакытта тирәнтен өйрәнелмәде.

Безнең республика сәнгать сөючеләре Натан Рахлин исемен аеруча тирән хөрмәт белән искә алалар. Ул Татарстан АССР Дәүләт симфоник оркестрын оештыручы гына түгел, озак еллар дәвамында гомеренең соңгы көннәренә кадәр аның җитәкчесе һәм күп санлы яшь музыкантларның остазы да булды. Күпчелеге Казан дәүләт консерваториясен тәмамлап чыккан яшьләрне Натан Рахлин зур осталыкка ия булган бердәм коллектив итеп туплый алды. Бу осталык дәвамлы репетицияләр, даими тырыш хезмәт нәтиҗәсе иде. Гаять бай концерт репертуары туплаган коллектив соңрак Бөтенроссия һәм Бөтенсоюз конкурслары лауреаты исемен яулап алды, илдә иң танылган оркестрларның берсенә әйләнде.

Казан һәм Татарстан тамашачылары ундүрт ел дәвамында симфоник концертларда төрле чорларның төрле-төрле стильдә язылган дистәләрчә әсәрләрен яңача яңгырашта тыңлау бәхетенә ирештеләр. Профессиональ музыкантларны да, күп санлы музыка сөючеләрне дә әсир итә алырдай шундый яңгырашка ирешүнең, теләсә нинди аудиториягә көчле эмоциональ тәэсир итә алуның сере нәрсәдә? Рахлин иҗатының төп нигезләре кайда?

Иң беренче чиратта алар — Рахлинның илһамлы рухында, талантының һәм музыкаль сиземләвенең көчендә. Болардан тыш, мин Рахлинны музыкада фәлсәфи яңгыраш тапкан дирижер дип тә өстәр идем. Төрле чорларда яшәгән һәм иҗат иткән композиторларның әсәрләрен башкару концепциясендәге идея тирәнлеге, күңел түреннән килүче хисләр белән өретелгән булуы сокландыра. Бетховенның Тугызынчы симфониясе, Шубертның Җиденче симфониясе, Берлиозның «Фантастик симфония»се, Брамсның Өченче симфониясе, Чайковскийның Дүртенче, Бишенче, Алтынчы симфонияләре, «Манфред» симфоник поэмасы, Танеевның до минор симфониясе, Скрябинның Икенче симфониясе, Прокофьевның Җиденче симфониясе кебек күләмле әсәрләрдәге фәлсәфи эчтәлекне калку итеп гәүдәләндерергә омтылу да шуның белән аңлатыла. Шостаковичның байтак симфонияләре Рахлин трактовкасында үзенчәлекле яңгыраш тапты. Еш кына ул аларны беренче яңгыратучы, партитураның телсез тамгаларына юл ачучы да булды.

Рахлин талантының ирексездән баш иярга мәҗбүр иткән мизгелләре әле дә хәтердә. Бу хәл Мәскәү консерваториясенең Зур залында, Шостаковичның Унберенче симфониясе тәүге тапкыр яңгыраган чакта булды. Натан Рахлин тыңлаучыларның игътибарын бер җепкә төйнәп, шундый киеренке ноктага җиткерде ки, музыканың иң драматик кульминациясе — 1905 елда эшчеләр демонстрациясен ату күренеше башланугa, тамашачылар, әйтерсең лә дирижерның ихтыярына буйсынып, барысы бердәй аягүрә торып бастылар!.. Рахлинның исә андый концертлары сирәк булмый иде.

Ә Бетховенның Тугызынчы симфониясе... Бөтен кешелек дөньясы мәшһүр композиторның 200 еллыгын билгеләп үткән көннәрдә әлеге симфония Мәскәүдә Натан Рахлин дирижерлыгында яңгырады. Һәм ул илебезнең музыка тормышындагы вакыйга буларак тарихка кереп калды. Симфониянең һәр кисәге шулкадәр тулы һәм бөтен булып кабул ителә, гүя ки безнең алда граниттан уеп ясалган монумент калка. Ләкин шул ук вакытта Рахлин ул кисәкләрнең аерылмас бербөтенлеген дә истән чыгармый: күз алдында әнә шул дүрт кисәктән торган бердәм организм туа. Музыка үзенең бөтен нечкәлекләре һәм гүзәллеге белән яңгырый башлый, бөек художникның фикер куәте чын тулылыгы белән ачыла.

Кеше һәм язмыш... Бетховен, Чайковский, Шостакович әсәрләрендә төп урынны шушы төшенчәләр, һаман үзгәрештәге шушы көчләр алып тора. Рахлин интерпретациясендә алар гаять дөрес, киң колачлы һәм күтәренке манерада ачыла. Чайковский симфонияләренең геройлары үз чорының социаль күренешен гәүдәләндерүче типик каһарманнар булып күз алдына килеп баса. Алар — гаделлек һәм сафлыкка омтылучы, туктаусыз тормыш мәгънәсен эзләүче тынгысыз кешеләр. Әле шунысы да куанычлы: Рахлин Казанда Чайковскийның барлык симфонияләрен дә яңгыратты.

1969 елның язында Ю. Оснос сценарие буенча Казанда, илебездә беренче тапкыр буларак, «Мәңгелек хакына тормыш» дигән әдәби-музыкаль спектакль куелды. Озын гомерле спектакль булды ул. Чайковский музыкасына куелган шушы постановка белән Казан, Мәскәү, Уфа, Йошкар-Ола, Харьков һәм башка шәһәрләр тамашачылары танышты, ул тыңлаучыларның югары бәясен алды. Ун ел буе спектакльләргә Натан Рахлин дирижерлык итте.

Музыкаль фрагментларның шактый күп булуына карамастан, әсәрләр уңышлы сайлап алынган, чуарлык тумый, спектакль тулаем бер сулышта кабул ителә. Драма артистлары Чайковский музыкасына тиң аһәң таба алдылар һәм спектакльнең бербөтенлегенә ирештеләр. Рахлинның һәм актерларның уңышы сүз белән музыка синтезын тудыра белүдә иде. «Мәңгелек хакына тормыш» спектакле меңнәрчә яңа тыңлаучыларны Чайковский белән кабат кавыштырды, аның иҗатын яңача аңларга ярдәм итте.

Гайдн симфониясе яки Бизеның «Яшьлек симфониясе» булсын, Рихард Штраусның «Тиль Уленшпигеле» яки Стравинскийның «Петрушка»сы булсын — Натан Рахлин аларның һәркайсына үзенчәлекле ачкыч таба белгән дирижер иде. Моны сүз белән генә аңлату мөмкин түгел, бу хисләрне кичерү өчен, оркестрның үзен тыңларга кирәк. Аның төрле группаларындагы киң мөмкинлекләрне Рахлин тыңлаучылар алдында бөтен тулылыгы белән гәүдәләндерә иде.

Еш кына Рахлинны дирижер-импровизатор дип атыйлар иде. Бу «мөһер» — аның репетицияләрдә эшләү алымын, аңа гына хас үзенчәлекләрне аңламау нәтиҗәсе. Чөнки Рахлин аңлы рәвештә репетицияләрдә бер, ә концертларда икенче бурыч куя иде. Беренче карашка, чыннан да, гаҗәбрәк кебек. Концертта илһамлы, якты эмоциональ башкару ишеткән кеше репетицияләрдә бу әсәрнең алай яңгырамавына игътибар итә. Натан Рахлинның үзенчәлеге дә нәкъ менә шунда: ул бер бөтеннең кисәкләрен бар вaклыкларына кадәр бөртекләп уйный, эзерли. Репетицияләрдә музыканы башкаруда, аның темпын билгеләүдә, аерым кисәкләренә төсмер бирүдә ювелирларча төгәллеккә, хәтта академик төгәллеккә ирешкәннән соң гына, аны концертларда шулай башкарып була бит. Ләкин репетицияләр саны һәрвакыт чикле. Бу үзе генә дә дирижер эшен күпмедер дәрәҗәдә «чикли». Менә шуңа күрә дә Рахлин репетициядә, әйтик, симфониянең төрле кисәкләреннән тулаем бербөтен оештыру максатын куймый, ә оркестрның һәм үзенең шартлауга тиң эмоциональ көчен концертка калдыра.

Натан Рахлин Ленинград консерваториясен скрипкачы буларак тәмамлаган иде. Моннан тыш ул кларнет, гобой, торба, валторна, тромбон һәм башка уен коралларында бик яхшы уйный иде. Образлы итеп әйткәндә, үзе дирижер пульты янында чакта да, Рахлин оркестрда, музыкантлар арасында була, алар белән бергә уйный, бергә дәртләнә, бергә моңлана. Шушы кичерешләр уртаклыгы, бәлки, дирижер белән оркестрның органик кушылуын тудыргандыр да.

Озакка сузылган авыр репетициядән соң бервакыт Натан Григорьевич чын дирижерны үз йөрәген кешеләргә биргән, аларны караңгылыктан алып чыгу өчен ялкын итеп кабызган Данко белән тиңләгән иде. Натан Рахлин кебек бөтен барлыгын, җанын һәм йөрәген сәнгатькә биргән кеше турында сөйләгәндә бу сүзләр матур фраза гына түгел. Чөнки һәр дирижер чын мәгънәсендә үз йөрәге белән «юл яктыртканда» гына, оркестр аны таный һәм аңа ияреп ала.

...Репетиция тәмам... Арыган оркестрантлар инде күптән таралышкан. Әле күптәнме генә Бетховенның ярсу симфониясе яңгыраган залда тынлык. Тик дирижер пульты янында гына, башын иеп, берәү утыра. Аның йөзендә, бөтен гәүдәсендә тирән арыганлык чалымнары. Рухы гына түгел — чын мәгънәсендә физик ару, алҗу билгеләре. Әйе, чын сәнгатьнең әнә шундый авыр, ялыктыргыч хезмәт белән җуланганын тамашачы еш кына белми.

Натан Рахлин — музыка сәнгатенә үзенең бөтен темпераментын, юмарт күңелен, йөрәген салган кеше. Казан һәм Татарстан музыка сөючеләре аны аерым бер ихтирам белән яратып искә ала. Гомумән, сирәк башкарыла торган байтак фундаменталь симфоник әсәрләр аның тырышлыгы белән беренче тапкыр нәкъ менә Казанда яңгырады. Татарстан композиторларының күләмле яңа әсәрләрен Рахлин даими рәвештә концерт программаларына кертеп килде, аларга олы тормыш юлы ачты. Моннан тыш чех композиторы И. Паленичекның «Кеше турында поэма» ораториясе, Глиэрның Өченче симфониясе Советлар Союзында беренче тапкыр аның дирижерлыгында башкарылды. Гомумән алганда, үз эшчәнлеге чорында Рахлин совет композиторларының дүрт йөздән артык әсәрен тәүге тапкыр дөньяга чыгарды.

Натан Рахлинның олы сәнгате меңнәрчә музыка сөючеләрнең күңелендә якты истәлек булып саклана.

Тәүфикъ Әйди

# ЗАМАННАРГА КУЕЛГАН ҺӘЙКӘЛ

Сәяхәтчеләрнең байтагы Үзбәкстан башкаласында «Ташкент» кунакханәсенә тукталырга ярата. Аның купшы гөлләре, затлы келәмнәре, уңайлы җиһазлары гына түгел, бинасы да һәм эчке, һәм тышкы яктан күңелгә ятышлы.

«Ташкент» үзәктәге иң күркәм мәйданда — опера һәм балет театры янәшәсендә илленче еллар азагында пәйда була. Кунакханә проекты өчен конкурс театр төзелеп беткәч үк игълан ителә. Яңа бина академик Щусев корган театрны күләгәләмәскә, бердәм ансамбль тәшкил итеп, аны тагын да ачып җибәрергә тиеш була.

Кунакханә театр белән бер үк «күчәрдә» П хәрефе сыман итеп төзелә. Аның үзәк өлеше — биш, канатлары — дүртәр катлы. Беренче катта ресторан, кафе, кибет, кассә урнаштырылган. Калган катларда торак бүлмәләр. Ишегалдында чәчәкләр, куаклар утыртылган ял итү мәйданы, аның астында — хуҗалык хезмәте күрсәтү юллары! Бина, җир тетрәүләргә бирешмәслек нык итеп, кирпечтән салына.

Йортның алгы ягында аркылы һәм буй сызыкларны уңышлы уздыру, ишекләрнең ике ягына биек колонналар бастырып кую, алар артындагы куышларны бизәр өчен ак, зәңгәр, яшькелт төсләрне оста куллану, карнизга милли бизәкләр төшерү архитекторның зур уңышы булып тора. Бина үзе бик тә мәһабәт, ә алтынчы кат тәшкил итеп, баганалар башына «кунган» түбә аңа дача өйләренә хас җиңеллек, нәфислек өсти. Сырланган балкон һәм ишек өсләре, күккә ашкан түбә күзләрне иркәли. Бүлмәләрнең иркенлеге, ванна һәм салкынча һава белән тәэмин ителүе дә арыган, йончыган юлаучыларга рәхәтлек бирә. Кояшлы көньяк шәһәрен бизәп торган шушы күркәм йортны Себер сазлыклары арасында үскән бер егет салгандыр дигән уйны, әлбәттә, кунакларның кайсы да башына китерми.

Архитектор Мидхәт Сәгадәт улы Булатов хәзерге Төмән өлкәсенең Тубыл шәһәреннән биш чакрымда урнашкан Бәргәр авылында 1907 елда туган.

— Авылыбыз зур түгел иде,— дип искә ала архитектор,— йортлары кырыктан артмагандыр. Унтугызынчы гасыр азагына кадәр анда Урта Азия йогынтысы көчле булган. Әмма егерменче йөз башыннан Казан, Оренбург, Уфа, Троицк, Томск кебек үзәкләр аша татар мәдәниятенең тәэсире үскән, «Вакыт» газетасы, «Шура» журналы килә башлаган, Тубыл мәгърифәтчеләре «Берлек» җәмгыяте оештырып җибәргән.

Мидхәтнең бабасы итекче, атасы бер сәүдәгәрдә приказчик була. Күзе ачык, тере Сәгадәт абзый укымышлы кешеләр белән аралашырга омтыла. 1914 елда шәһәргә Фатыйма Мохтарова белән мәшһүр Камил Мотыйгый килгәч, концертка улын да алып бара.

— Бөтен җирне су баскан чак, яз көне иде,— дип искә ала Мидхәт ага,— без Тубылга көймәдә сәфәр чыктык. Сирәк була торган тамашаны күрергә татарлар якынтирәдәге барлык авыллардан җыйналды. Шунда ыспай киемле, мәгърур кыяфәтле Мотыйгыйның залны яңгыратып җырлап җибәрүе әле дә күз алдымда, көе дә колагымда чыңлый.

Авыл кечкенә булса да, яшь буынга белем бирергә теләүчеләр һәр гасырда табылып тора. Үз чираты җиткәч, Сәгадәт абзый да, замандашларының ихтыяҗын үтәп, 1908 елда Бәргәргә яңа мөгаллим алып кайта. 1913 елда исә тайга арасында күмелеп югалгандай тоелган ояга да җәдит укуы килеп керә — ислах таләп иткән өчен «Галия» мәдрәсәсеннән куылган алтмыш биш шәкертнең берсе — Заһит Миравалов Бәргәрдә белем тарата башлый. Зиһенле Мидхәт көтелмәгәндә менә шундый кыю фикерле, укымышлы мөгаллимгә очрап куя. Шуның аркасында малай кадим мәдрәсәдә ун ел баш катырып та сеңдерә алмаслык белемне өч елда үзләштерүгә ирешә.

1915 елда Сәгадәт абзый Тубылга күчеп килә һәм почтага ямчылыкка урнаша. Мидхәтне өч класслы рус мәктәбенә бирәләр. Дин дәресе кергәндә, малай уникe татар иптәше белән бергә поп сабагыннан азат ителә. Әмма бүтән фәннәрне ул бик кызыксынып өйрәнә һәм зирәклеге белән укытучысының игътибарын казана. Өендә үзлегеннән татарча укуын да онытмый — аңа Мәҗит Гафуриның 1915 елда «Шура»да басылган «Юктырсың ла, алла?» шигыре аеруча көчле тәэсир итә. Алдынгы якташларының дини исемнәрдән баш тартып, балаларына күңелләрендәге өмет-теләкләрен чагылдырган «Очкын», «Ялкын» кебек исем кушулары да хәтерендә уелып кала.

1918 елда Мидхәт мәхәллә мәктәбен тәмамлаганда Тубылда әле Совет власте урнашып җитмәгән була. Малай берничә иптәше белән бергә гимназиягә керергә әзерләнә. Әмма революция җилләре чыгу аркасында, гимназия нигезендә биш класслы икенче баскыч мәктәбе оештырыла. Шушы уку йорты каршында әзерлек һәм беренче классларны эченә алган кечкә художество мәктәбе дә пәйда була. Мидхәт бу мәктәпләрнең икесенә берьюлы йөри башлый.

Малай шигырь ярата, еш кына концертларда нәфис сүз сөйли. Художество мәктәбендә өч ел шөгыльләнү дәверендә күмер, карандаш, каләм белән рәсем ясарга, акварель, майлы буяу, натюрморт, интерьер, тере натура, плакат композициясе, сызым, перспектива шикелле төшенчәләрне аерырга өйрәнә. Өстән-өстән булса да, борынгы Мисыр, Греция, итальян Яңарышы сәнгатьләре тарихы белән таныша. Рафаэль, Тициан, Микеланджело, Леонардо да Винчи һ. б. турында кыскача мәгълүмат ала, үз әсәрләрен күргәзмәгә куеп, иптәшләренең фикерен тыңлый. Мәктәп Мидхәтне төрле белем белән коралландыра, зәвыгын үстерә, аңарда үз-үзенә ышаныч уята. Хәтта, төгәл фәннәр — математика, физика, астрономия белән дә кызыксындыра. Сөяктән сыннар кискәндә, Булатов форма, пластикага әһәмият бирергә күнегә. Җыелышларда чыгыш ясау дисеңме, җәмәгать эшләрендә катнашу дисеңме — җитез Мидхәт һәммәсенә дә иркен өлгерә.

Мидхәт Булатовның хезмәт юлы мәктәптә укыганда ук башлана — ул итекче һөнәрен үзләштерә, шәһәр театры сурәтчесенә ярдәм итә, җирле газетага рәсемнәр ясап бирә, В. И. Ленин исемендәге татар клубында «Галия» мәдрәсәсе шәкерте, Тубылның беренче коммунистларыннан исәпләнгән Себер егете Касыйм Салихов оештырган үзешчәннәр түгәрәгенә булыша.

Татар клубы миллионер Мөхәммәтсафа Чембаев йортларының берсендә ачыла. Бүрәнәдән салынган өске каттагы бүлемнәрне сүтеп, сәхнә һәм тамаша залы ясыйлар. Кирпечтән салынган аскы каттагы бүлмәләрдә китапханә урнаша, оркестр, хор, драма түгәрәкләре эшли.

Мидхәт китапханә өчен халыктан китаплар җыюда, шахмат-шашка түгәрәге оештыруда актив катнаша. Дәртле, укымышлы үсмерне клуб идарәсенә секретарь итеп сайлыйлар.

Яшь совет аппаратына бу елларда белемле кадрлар җитми. Тубыл исә укымышлы татар хезмәткәрләренә аеруча кытлык кичерә. Шуңа күрә партия шәһәр комитеты инструкторы Әхмәрев 1925 елда урта мәктәп тәмамлаган Булатовны судка тылмач булып керергә күндерә, бер үк вакытта аның алты айлык юридик курсларга урнашуына сәбәпче була. Эшлекле егет көзен Тубыл шәһәр советы депутаты, 1926 елда исә Татар клубының председателе итеп сайлана. Тынгысыз егетне Тубыл округ адвокатлар коллегиясе бик теләп үз сафына ала.

Күп төрле шөгыльләргә күмелсә дә, Мидхәт, белеменең әллә ни мулдан түгеллеген абайлап, уку ягын кайгырта башлый һәм 1928 елда Казанга, кечкә юридик курсларга китеп бара. Монда ул булачак композитор Җәүдәт Фәйзи белән дуслаша, көндез Татарстан юстиция халык комиссариатында эшли башлый. Әмма ул юрфакка түгел, Ленинградтагы граждалык инженерлары институтының архитектура бүлегенә укырга керә.

Институтны бик яхшы билгеләренә бетергән Мидхәт архитектор эшчәнлеген Мәскәүнең шәһәрләр проектлау институтында башлап җибәрә. Аның башкала мохитендә кайныйсы, тәҗрибәле осталар кулы астында «шомарасы» килә. Шуның өстенә, аны бу оешманың Казан өчен дә проектлар ясавы кызыктыра.

Әмма озакламый ул эшләгән институтны Ленинградка күчерәләр. Булатов исә, башкала мәктәбендә чыныгасы килгәнлектән, Мәскәү проект институтында төпләнеп кала һәм бер үк вакытта Архитектура институтында укыта башлый.

Мәскәүдә профессор Б. А. Коршунов аны Урта Азия калаларын проектлауга җәлеп итә. Бохара ефәк комбинаты өчен торак массивы планлаштыру тапшырылгач, ул берничә мәртәбә Үзбәкстанга килә. Яшеллеккә төренгән үзәнлекләр, күгелҗем томанга уралган тау түбәләре, мәһабәт чинарлар, гүзәл архитектура һәйкәлләре аңарда онытылмаслык тәэсир калдыра. Урамга калын саман коймалары гына чыгып торган традицион үзбәк өйләре, Хива, Сәмәрканд, Бохара, Ташкентның борынгы мәчетләре, мәдрәсәләре, зәңгәр күктә йөзеп барган шикелле тоелган зәбәрҗәт гөмбәзләр, горур манаралар, аларга төшерелгән нәфис бизәкләр чытырманлыгы! Күпме фантазия, матурлык, осталык тупланган бу һәйкәлләрдә. Әйтерсең лә алар чүлмәкче түгәрәгендә генә барлыкка китерелгән дә, ниндидер кодрәт белән өреп, йөзләрчә тапкыр зурайтылган. Буяулары күз явын ала, форма камиллеге, сыгылмалы сызыклар нәфислеге төшеңә кереп йокыңны була!

Мидхәт, килгән саен, Үзбәкстан тормышы, архитектура мирасы белән киңрәк танышырга омтыла. 1937 елда Ташкентка эшкә чакырылгач, баш ватып тормый — берсүзсез риза була.

М. Булатов Үзпланпроектта Сәмәркандның генераль планын эшләүче бригада җитәкчесе итеп билгеләнә. Бурычы гаять җаваплы: шәһәр мәйданын зоналарга бүлү, транспорт юлларын ачыклау, үзәк мәйданны планлаштыру — әзерлекне нульдән башларга туры килә. Мәскәүдә Сокольники районын, Чиләбедә шәһәр төбәкләрен проектлап тәҗрибә җыйган Мидхәт эшкә кыю тотына. Әмма Сәмәрканд — буш җир түгел. Регистан мәйданы, Шаһи Зиндан ансамбле, Биби ханым мәчете кебек кадерле ядкарьләрне саклау, яңа корылмаларны шуларга килештереп бәйләү байтак эзләнүне таләп итә. Шәһәр халкы аларның иҗаты белән якыннан кызыксынып тора. Ниһаять, проектны рәсми органнар да җентекләп тикшерә — республика Министрлар советы аны урта гасыр Төркестан шәһәрләренең йөзек кашы, бүгенге казанышларыбызның көзгесе Сәмәркандка лаек таба һәм тормышка ашырырга карар бирә.

1938 елда Үзпланпроект икегә бүленә: Булатов Планпроектның баш архитекторы итеп билгеләнә. Коллектив та, бурычлар да үсә. Мидхәт җитәкчелегендә Бохара, Фиргանә, Өргәнеч, Каган калаларының генераль планнары әзерләнә. Ул проектлар республикада да, Мәскәүдә дә югары бәя ала.

— Мидхәт абый 1937-38 елларда шәһәр кору эшенә керешкән без — яшьләргә — чын мәгънәсендә канат куючы бердәнбер остаз иде,— ди архитектор Т. Л. Калиновская.— Аңардан алган иҗади чыныгу бүген дә тормышымның иң матур сәхифәләре буларак хәтеремдә калды.

Булатов шул чакта ук инде үз эшенә гашыйк булуы, аны яхшы башкара һәм яклый белүе, коллективны һәвәсләндерә, һәр хезмәткәрнең уңай сыйфатларын ача, аңа таяна алуы белән танылა.

1939 елда Булатов Ташкентның баш архитекторы итеп билгеләнә. Расланган генераль план буенча иске һәм яңа шәһәрне бергә кушу, үзәккә нигездә дүртәр катлы йортлар салу карала. Аны тормышка ашыруда ныклык, иҗади караш, акыл һәм тәҗрибә таләп ителә. Чөнки көн саен, сәгать саен яңа проблемалар калкып чыга. Архитектор аларны үз вакытында тоярга, кирәкле үзгәрешләр ясарга, шәһәрнең күркәмләнүенә ирешергә тиеш. Инженерлык коммуникацияләрен кайгырту, корылмаларның җиренә җиткереп салынуын таләп итү, киңәшмәләрдә чыгыш ясау, нигезләү һәм ышандыру төзелеш мәйданнарына йөрү — Мидхәт башкарган эшләр мәшәкатьле дә, тынгысыз да. Җитмәсә, көньяк шәһәре өчен аеруча актуаль мәсьәләләр дә бар ич әле: яшеллеккә күмү, сугару! Күпмедер парк, бакчалар булса да, алар халыкны канәгатьләндерә алмый. Чөнки Ташкентта яшәүчеләр саны бик тиз арта, М. Булатов яңа бакча, ясалма күлләр булдыру эшенә керешә. 1939 елда аның проекты буенча егерме тугыз гектар җирдә Комсомол парк-күле барлыкка килә һәм ул тиздән күпләрнең ял итү урынына әверелә. Күләгәле аллея, аулак аланнар, яңа комлык, су стадионы, түшәмен дә, диварларын да тере яшеллек тәшкил иткән театр «бинасы», элек кирпеч заводы өчен балчыгы казып алынган җирдә пәйда булган ясалма күл Ташкент микроклиматын яхшыртып, шифаландырып җибәрә. 1942 елда Әдһәм Мөхәммәтшин белән бергә проектлаган Җиңү паркы да шуңа килеп кушыла. Тәҗрибә Мидхәткә Урта Азия табигате шартларында мондый корылмалар барлыкка китерүнең теоретик нигезләрен эшләргә мөмкинлек бирә. Булатов: күп планлы пейзаж, ачык мәйданнар, шуның белән бергә, күләгә төшерерлек агачлар күбрәк утыртылган парк үзен аклыйрак бирә ди. Үләнчәчелгән киң аланнар белән мавыкмаска кирәк, алар кояшта көеп бетә. Шул ук вакытта куакларны чәчәк түтәлләре белән аралаштырырга кирәк. Ясалма күлләр агым суга тоташтырылырга тиеш...

Сугыш архитектор алдына кителмәгән яңа бурычлар куя: эвакуацияләнгән завод-фабрикаларны генераль планны бозмый урнаштыру, шул ук вакытта аларны чимал белән тәэмин итә торган транспорт чараларына уңышлы бәйләү сорала. Ашыгыч рәвештә! Чөнки бу предприятиеләр бик тиз арада хәрби продукция бирә башларга тиеш була.

Яңа биналар салу өчен матди база җитешми, бигрәк тә агачка, металлга кытлык арта. Алардан тыш егерме дүртәр метрлы араларның түбәсен ничек ябасың? Берәүләр өрлек арматурасы өчен камыш тәкъдим итә. Булатов исә гипс конструкцияләрне ныгытуда пыяла җебе (ул корычтан чыдамрак!) куллануны куәтли. Үз фикерен тормышка ашыруда аңа гыйльми исбатлау осталыгы, зур ихтыяр көче ярдәмгә килә.

Генераль план буенча төзелеш сугыш елларында да дәвам итә. Иске шәһәр белән яңасы арасында сузылган Нәваи проспектында борынгы Күкелдаш мәдрәсәсе янәшәсенә яңа биналар салганда, Булатов аеруча күп эзләнә. Ул әле сызым өстәленә ябышып ята, әле оештыру мәшәкатьләренә күмелә. Монда проектлаган һәм корган йортлар Мидхәт аганың киләчәктәге колачлы хезмәтләренә юл сабу, осталыкка ирешүдә бик кирәкле мөһим баскыч була.

Булатовның шәһәр салу таланты чын мәгънәсендә «Пахтакор» стадионын төзегәндә ачыла.

Генераль план буенча шәһәр үзәгендәге Җар-Тегермән казанлыгында ясалма күл барлыкка китерү һәм аның өстеннән эстакада уздыру каралган була. Булатов бу ниятнең максатка ярашлы икәнлегенә шөбһәләнеп, яңа чишелеш эзли башлый. Нәтиҗәдә, бу урында илле мең тамашачыга исәпләнгән стадион төзү фикере бөреләнә. Аның уенча, казанлыктагы күп санлы чокырларны бергә тоташтырып, төбен тигезләсәң, менә дигән киң мәйдан барлыкка киләчәк. Казанлык ярлары исә табигый трибуналарга әйләнәчәк. Булатов стадионны, гадәттә кабул ителгәнчә, шәһәр читендә корудан баш тарта. Ташкент геометрик үзәгендә Җар-Тегермән казанлыгына дүрт яктан да урамнар килеп тоташа — бу меңләгән тамашачыга утыз-кырык минутта өенә кайтып җитү мөмкинлеген бирә. Стадион кору аркасында шул ук вакытта шәһәр уртасындагы зур гына котсыз мәйдан тәртипкә китерелә. Табигый шартларны файдалану исә стадион төзү чыгымнарын киметә.

Стадион 1958 елда төзелеп бетә. Үрдәге урыннар кырдан унбер метр күтәрелеп торганга, уеннар һәр яктан яхшы күренә. Илле биш мең тамашачы кырык сигез секциядә урнаша. Халыкка уңайлык тәэмин итү йөзеннән трибуналар өч аллея белән әйләндереп алына — аларның берсе өстә, икесе аста, тышкы периметрда ясала. Аллеялар күп санлы баскычлар белән үзара тоташтырыла. Көньяктагы өч катлы спорт павильонында гимнастика заллары, ярдәмче бүлмәләр, кунакханә урнаша. Аренага чыгу өчен павильоннан мәйданга тоннель уздырыла.

Кыр кыш көне явым-төшемнән сазлыкка әйләнмәсен, җәен үләне көймәсен өчен махсус чаралар күрелә: стадион дренаж, сугару белән тәэмин ителә.

«Пахтакор» үзенең колачы белән бөтен кала үзәгенә, соңыннан барлыкка киләчәк мәйдан, бульварларга, скверларга рух биреп тора. Киләчәктә аның янәшәсендәге кызыл мәйданда Үзбәкстан башкаласының горурлыгы булган сәнгать сарае, республика компартиясе ҮК бинасы, яшьләр йорты төзелү бер дә очраклы хәл түгел. «Пахтакор» җиңел аяклы булып чыга!

Төзүче-практик. Галим-теоретик. Җәмәгать эшлеклесе. Мидхәт Булатовның эшчәнлеге Үзбәкстанда менә шулай өч тармакка бүленеп дәвам итә.

Архитектор-практикның Сәмәркандта Габдрахман Җәми белән Галишир Нәваига салган һәйкәле, Регистан мәйданында тарих музее бинасы, Ташкентта Авыл хуҗалыгы министрлыгы йорты, «Ташкент» кунакханәсе, Комсомол һәм Җиңү парклары — республиканың йөзек кашлары. Аларга дистәләгән бүтән корылмалар өстәлә. Әгәр Мидхәт аганың бөтен эшчәнлеге шулар белән генә чикләнеп калса да, Үзбәкстан архитектурасы тарихында аның исеме ныклы урын алган булыр иде.

Мидхәт ага егерме өч ел буе Ташкентның баш архитекторы, ун ел дәвамында Үзбәкстан архитекторлар союзының даими җитәкчесе, байтак вакыт СССР архитекторлар союзы идарәсе президиумы әгъзасы булып эшли. Административ һәм җәмәгать эшчәнлеге бергә үрелеп, Үзбәкстанда кала кору үзенчәлеген өйрәнүгә, аннары шул традицияләргә таянып төзелеш алып баруга, бу эшкә күп кенә белгечләрне җәлеп итеп, аларны оештырып, илһамландырып һәм дәртләндереп торуга җитешә.

Мидхәт ага бүген дә Архитекторлар союзының үз кешесе — ул Үзбәкстанның чит илләр белән дуслык җәмгыятендә архитектура һәм шәһәр кору секциясе җитәкчесе, Мәскәү, Лондон, Гаванада уздырылган күп кенә халыкара конгресс, форум, конференцияләр делегаты. Чыгышларында совет сәнгатенең уңышларын бәян итәме, шәрык архитектурасы тарихы белән таныштырамы — бай мәгълүматлы, үз фикере булган иҗатчыны тыңлаучылар шунда ук танып ала.

Урта Азиянең архитектура сәнгате совет чорында зур яңарыш кичерде. М. Булатов шул яңарышка саллы өлеш керткән иң күренекле архитекторларның берсе.

Чит илләргә сәяхәтләр... Андый сәфәрләр вакытында Мидхәт аганы туган иленә, туган җиренә бәйле исем, вакыйгалар аеруча кызыксындыра иде. Мисалга, Мисыр тәхетенә төрки гаскәриләр — мәмлүкләр ия булган 1250—1547 елларда шәһәрләрдә бик күп архитектура һәйкәлләре корылуына ничек игътибар итмисең ди? Заһир Бәйбарыс, Насыйр Мөхәммәт, Заһир Әбүсәет Бәркүк һәм башкалар салдырган гүзәл мәчетләр, мәдрәсәләр, кәрвансарайлар бүген дә замандашларыбызны сокландыра. 1371 елда Насыйр Мөхәммәт корган сусүткәргеч халыкка 531 ел буе хезмәт иткән. Мәмлүкләр салдырган унлап мунча әле бүген дә үз хезмәтен үти ала.

Әмма шәрык илләрендә мәмлүкләргә кадәр дә бөек төзүче сыйфатында тарихка кергән бабаларыбыз бар. Шуларның берсе — Гарәбстанга кол итеп китерелгән төркиләрнең улы Әхмәт ибне Тулун  бик яшьли зирәклеген күрсәтә һәм сарай хезмәтенә алына, 868 елда соңыннан Каһирә дип аталган Фустатның, аннары бөтен Египетның идарәчесе итеп билгеләнә. 879 елда зиннәтле мәчет, сарайлар белән бизәлгән башкаласына ул киләчәктә илнең яңа атамасына әйләнәчәк «Мисыр» (шанлы!) исемен кушкан.

Гарәп патшаларына олтан хезмәте итәргә китерелгән егетләрнең солтанга әверелеп, Каһирәдә даны ерак гасырларга яңгыраячак корылмалар салулары үзе үк аларның канында килгән төзүче идеаллары һәм сыйфатлары хакында сөйли. Мәмлүкләрара-

сыннан шул гүзәл биналарны салган ташчылар, буяучылар, талантлы архитекторлар да аз чыкмагандыр, әмма тарихчылар гасыр арты гасыр патшаларга, гаскәр башлыкларына гына игътибар биреп килгән. Шуның аркасында Бакуда Ширваншаһлар сараен, Казанда Сөембикә манарасын, Сәмаркандта Регистан ансамблен, Бохара, Ташкент һәм башка шәһәрләрдә заманына лаек дистәләрчә бүтән корылмалар барлыкка китергән, архитектура гыйлемен баета торган трактатлар, монографияләр иҗат иткән даһиларыбыз исеме дә онытылган. Әмма иҗат чишмәләре аңа карап кына кипмәгән, халкыбыз дөньяга берсеннән-берсе оста яңа төзүчеләр тудыруын дәвам иткән. Мидхәт ага үзен әнә шуларның эшен дәвам кылырга тиеш бер кеше саный иде...

«Үзбәкстан Верховный Советы бинасы»ның аскы өлеше шахмат тактасы шикелле, җәенке итеп корылачак. Өске ягы шуның уртасыннан күтәрелгән мәһабәт цилиндрны тәшкил итә. Пыяла белән мәрмәрдән төзеләчәк бинаның якты, нәфис булачагы бер караудан ук күзгә бәрелеп тора. Гади, кырыс сызыклар заман рухын, җиргә сыланган аскы катлар белән күккә ашкан үзәк өлеш исә шарыккә хас манаралы корылмаларны искә төшерә. Иорт тирәсендәге гранит баскычлар, байрак әләр өчен утыртылган биек баганалар сафы аңа тантаналы төс биреп тора.

«Гасырлар аша» һәйкәле төрки халыкларның бөек фикер иясе әл-Фарабыйга куелырга тиеш. Галимнең бронза сыны титаннан ясалган дуга сыман биек корылма астына — гранит ташка урнаштырылган. Корылманың бер тераге агым сулы киң арыкка төшеп чумган — бу Фарабый иҗатының үлемсезлегенә, заманнар бәйләнешенә ишарә. Галимнең яланбаш утыруы аның дин белән хисаплашмавын күрсәтә, кулына тоткан баш сөяге — гыйлем иясе, тикшеренүче булуын белдерә. Менә шулай гап-гади, әмма һәрберсе образны ача торган детальләргә бай бу һәйкәл.

Мин сәнгать институтында тамаша иткән һәр ике макет — М. Булатовның яңа иҗат җимешләре. Аның яңа эзләнүләре нәтиҗәсе.

Сәмарканд, Бохара, Хива һәм Урта Азиянең бүтән калаларында гаҗәеп архитектура һәйкәлләре саклана. Алар климат үзенчәлеген искә алып, гасырлар буе үсеп килгән төзелеш тәҗрибәсенә, халыкның милли традицияләренә таянып корылган. Шуңа күрә совет чорында киң җәелгән төзелеш эшләрендә ул казанышларны файдалану үзеннән-үзе аңлашыла торган мәҗбүри бер шарт иде. Тик үткән заман архитектурасы серләре фәнни рәвештә өйрәнелмәгән иде. Ташкентны яңартырга алынган М. Булатов менә шушы эшкә дә үзе тотынырга мәҗбүр була.

Җирле үзенчәлекләрнең берсе — шәһәрне планлаштырганда табигый агышлы сугаруны искә алу иде. Булатов сугару системасын өйрәнеп, киләчәктә ясалма яңгыр ысулы белән дымландыруны да тәкъдим итә. Машина белән сиптерүне дә онытмый. Димәк, арык ерып сугаруны да искә алсак, һәр өч алымны актив куллану хуплана.

Сулыкларны өйрәнү нәтиҗәсендә Булатов агым су белән тоташкан ясалма күлләр булдыруга туктала. Агачлар утыртканда, аларның кайда, ничек күләгә төшерүен, шул ук вакытта җил исүгә комачауламавын күзәтеп эш итә. Чөнки эссе вакытта урамда алтмыш градустан да кызурак була. Булатов фикеренчә, Ташкентта агачларның ябалдашын Идел буендагы кебек өстән түгел, ә өч-биш метр биеклеккә кадәр астан кырку уңышлырак. Шул ук вакытта агачларның чирләми, урамны чүпләми, тамырлары белән тротуарларны җимерми торганнарын сайлап утыртырга киңәш бирә. Урта Азиядә сәүдәнең урамда алып барылуы, өйләрдә бер стенасы ачык бүлмәләр, ишегалдында бакча, арык булуы да яңа шәһәр корганда искә алынырга тиеш. Йортларның өч каттан биек булмаганы эссе климатта уңайлырак, күп катлыларда исә салкынчалыкка һәм бүтән комфортларга ирешү өчен йортны мәгълүм юнәлештә салу, димәк, үтәли җилләтүне күздә тоту шикелле төрле шартларны онытмау таләп ителә.

Мидхәт ага Урта Азиядәге шартларны, тарихи тәҗрибәне җентекләп өйрәнеп, илебезнең көньягында төзелеш нормалары, принципларына җитди төзәтмәләр кертү хаҗәтлеген исбатлады һәм үз фикеренең дөреслеген Ташкентны яңарту барышында практик рәвештә раслады.

Әйе, кирәк икән, архитектор-практик, кирәк икән, тикшеренүче-галим, кирәк икән, танылган җәмәгать эшлеклесе буларак хәтсез казанышларга ирешә Мидхәт атлы Себер егете. Әмма шулай да нигәдер канәгатьләнү сизми ул. Йөз утыз бер мәчет, илле биш мәдрәсә, утыз ике сарай, унтугыз төрбә, унҗиде каралты, өч шифаханә, җиде суүткәргеч, сигез күпер, унҗиде кәрвансарай, утыз өч мунча һәм башка гүзәл биналар, корылмалар иҗат иткән бөек төрек архитекторы Синанны яки замандашы Ле Карбюзьене алып карасаң — тарткалаша аламы соң Мидхәт алар белән? Юк бит әле...

Сүнеп бетсеннәр йолдызлар,
Син дә, кояш, балкыма.
Бет мәңгегә, балкыма син,
Балкымасаң халкыма! —

дигән юлларны кабатларга ярата архитектор. Шушы шигыре өчен ул Әхмәт Ерикәйнең 1945 елда чыгарылган җыентыгын үз кулы белән яңадан төпләде, тагын күпме юлларын ятлап алды. Әмма аңа ни туган ягы Төмән, Тубылда, ни Татарстанда бер генә бина да салырга туры килмәде шул. Бөек итальяннар Растрелли, Росси гомер буе Петербургны бизәгән, Фиораванти исә бөтен СССР тантаналы төстә биш йөз еллыгын билгеләп үткән Мәскәү кремлендәге Успенский соборны салган. Ә Мидхәт менә Ташкентта, Сәмәркандта, Бохараларда иҗат итә. Язмыш шуклыгы. Аның менә шул язмыш шуклыкларына үч итеп дигәндәй, бер егетлек эшлисе килә иде. Игелеге туган халкына да тиярлек, бүтәннәргә дә файдасы булырлыкны. Язган ич әнә Ясәви, Нәваилар: беренчесенең теле татарга, икенчесенең — каракалпакка якынрак сыман, әмма аларны барлык төрки халыклар төшенә, бөтен дөнья үз итә.

Мидхәт җиң сызганып эшләгән өлкәдә дә әнә шулай күпләрдә кызыксыну уятырлык, бер үк вакытта туган халкына да кагыла торган җитди мәсьәлә барлыгын чамалый да шикелле инде. Инглиз, гарәп, фарсы телләрен тирәнрәк үзләштерергә, математика, физика, тарих һәм башка тармаклар буенча әдәбият җыйнарга юкка гына һәвәсләнмәде ләбаса...

Тарихчылар борынгы Шәрыктә архитектура гыйлеме булуын бервакытта да танымый. Элек бу тармакка багышланган һичнинди трактатлар язылмаган, шәрык корылмаларында геометрик алымнар абайланса да, алар архитектураның киемендә генә, ягъни орнаментта гына чагыла; гадәттә исә, профессиональ серләрне ата үзенең баласына гына мирас иткән, дип хөкем йөртелде. Булатов Урта Азиянең архитектура һәйкәлләре белән беренче мәртәбә очрашканда ук аларның искиткеч ятышлы, күркәм булуына, форма сыгылмалылыгына соклана. Бу корылмаларның архитектура өлкәсендәге теоретик белемнәргә таянмыйча төзелүенә шикләнә. Өзлексез шөбһәләр аны архивларда казынуга, гыйльми хезмәтләрне, кульязма китапларны өйрәнүгә, атаклы биналарны җентекләп үлчәүгә, аның нәтиҗәләрен анализлауга этәрә. Ниһаять, ул юлыккан берничә архитектура сызымы һәм рәсеменең кәгазен лабораториядә тикшерү аларның XVI гасырда иҗат ителүен раслый. Ә бу сызымнар исә XVI йөздә Шәрык архитекторларының сызма геометрия, тригонометрия буенча мәгълүматлы, бер яссылыктагы планда бинаның ике киселешен бирә белүләрен күрсәтә. Сызым техникасында исә аларның Европадагы хезмәттәшләреннән остарак та булганлыгы ачыклана. Бинаны төзегәнче аның сызымын сызып, нисбәтләрен чагыштырулары, ә бәлки әле безгә билгесез формулалар кулланып, исәп-хисап та ясаулары ихтималлыгы чамалана.

Булатов барлык буш вакытын — атналык һәм еллык ялларын тикшеренү эшләренә багышлый, макетлар ясый, чагыштыра, шуларга нигезләнеп закончалыклар табарга омтыла. Еллар узу белән эзләнүләр һаман җитдиләнә бара, ышаныч ныгый.

1963 елда ул Хәмзә исемендәге сәнгать институтына эшкә күчә. Озакламый Бохарадагы Саманыйлар төрбәсенә багышланган кандидатлык диссертациясен яклый. IX гасырда корылган бинаны өйрәнеп, Мидхәт ага галимнәр арасында беренче мәртәбә Урта Азиядә бик күптәннән бирле архитектура-төзелеш фәне яшәү мәсьәләсен күтәрә. Габдрахман Җәми, Галишир Нәваилар архитекторга багышланган шигырьләре белән танышу, Даниеле Барбороның сәнгатьтә нисбәтләр әһәмиятен аңлатканда тугызынчы гасыр галиме әл-Киндинең гарәп телендәге хезмәтенә таянуын ачыклау, итальян Яңарышы вәкилләренең унынчы-унберенче йөзләрдә яшәгән Әбугалисинага нигезләнеп, нисбәтне сәнгатьнең анасы һәм патшасы дип игълан итүләрен (Леонардо Ольшки) белү аның ышанычын тәмам ныгыта. Дәвамлы эзләнүләр нәтиҗәсендә ул гарәп һәм фарсы телләрендәге Шәрыктә урта гасырларда ук югары үсешкә ирешкән архитектура-төзелеш гыйлеме яшәгәнлеген раслаучы егермеләп трактатны барлый. Менә шулай Мидхәт ага гасырлар серен ачып, «IX—XV гасырларда Урта Азия архитектурасында геометрик гармонияләштерү» дигән докторлык диссертациясен яза һәм аны уңышлы яклый. Галим монда урта йөзләрдәге Шәрык төзелеш осталары тирәнтен хәл иткән нисбәтләр теориясе, проектлау техникасы математик нигезләрен, ул казанышларның IX—XVйөзләрдә Көнбатыш Европада архитектура теориясе барлыкка килүгә җитди йогынты ясавын ача. Нәтиҗәдә, Көнчыгыш халыклары, шул исәптән, татарлар да җитлеккән төзелеш һөнәрчелегенә, югары үсешкә ирешкән корылыш гыйлеменә ия булмаган дигән йөз еллар хакимлек иткән ялгыш караш кире кагыла. Күренекле галимнәр-архитекторлар, математиклар, тарихчылар, сәнгать белгечләре М. Булатов тикшеренүенең дөнья архитектурасы теориясенә һәм тарихына зур өлеш кертүе беравыздан танырга мәҗбүр була.

Соңгы гасырларда торгынлык кичергән, күп кенә гүзәл корылмалары, бай китапханәләре һәм архивлары рәхимсез дошман яулары тарафыннан пыр туздырылган, колга әйләндерелгән Шәрыкнең казанышларын барлау, абруен кайтару, туган халкының йөзен аклау, шул ук вакытта җир шарының олы бер төбәгендә мәгълүм тармакта кешелек мәдәниятенең үсеш күренешен хакыйкатькә якынайтып, тулыландыры

күз алдына бастыру, димәк ки фәндә чын гыйльмилек, объективлык тантана итүенә саллы өлеш кертү — бу инде теләсә кемнең кулыннан килә торган эш түгел! Бу чиксез мәхәббәт һәм бирелгәнлек, бай белем, иҗади фикерләү, колачлы эзләнүләр, ару-талуны белми торган дәвамлы хезмәт җимеше. Шушы өлкәдә бөтен бер дәвер тәшкил итә торган ачыш!

«Фән капкасына җәһәннәмгә кергәндәге кебек:
Рухыңның нык булсын монда ниргәсе,
Монда сиңа курку киңәш бирмәсен,—

дигән таләп язылып куелырга тиеш»,— ди К. Маркс.

Европаның меңләгән акыл ияләренә каршы чыгып, үз фикереңне раслау өчен, чыннан да, көчле рух, гайрәт, үзеңә нык ышаныч кирәклеге бәхәссез. Мидхәт ага шундый сыйфатларга ия икәнлеген кыю тикшеренүе белән дәлилле рәвештә исбатлый.

Әдәбият, сәнгать, фәннең төрле тармаклары белән даими кызыксыну якташыбызга кайвакыт үзе өчен төп белгечлек саналмаган өлкәләрдә дә нигезле фаразлар ясарга мөмкинлек бирә. Мисалга, 1908 елда Урта Азиядә Олугбәк астрономик обсерваториясе табылу укымышлы дөнья тарафыннан гасыр сенсациясе дип кабул ителә. Бу турыда ерак илләрдә дә мәкаләләр языла, сызымнары тикшерелә. Әмма обсерваториянең җир астында унбер метр тирәнлектәге нигезләре генә табылганлыктан, озакламый шау-шу да басыла.

Шәрык архитектурасы һәм төзелеш гыйлеменә багышланган тарихи-теоретик хезмәтен тәмамлау белән, Мидхәт Булатов шушы обсерваторияне торгызу хыялына бирелә. Обсерваториянең нигез планнары анык һәм бәхәссез. Әмма диварлары нинди биеклектә булуын, бинаның эчке төзелеше, түбәсе ни рәвешле корылганлыкны ничек белергә? Галим башы-аягы белән яңа тикшеренүләргә, математик исәп-хисапларга кереп чума. Тагын борынгы хезмәтләрне актара, астрономия тарихы, физика гыйлемен өйрәнә. Шулай казына торгач, 1419 елда Олугбәкне килеп күргән астроном Гаязетдин Кашинең ата-аналарына язган хатыннан кызыклы хәбәр ала, урта гасырдагы обсерваторияләр белән танышу да, Шәрык архитектурасы традицияләрен тирән белү дә ярап куя. Ниһаять, ул исәп-хисапларына нигезләнеп, сызымнар сызарга, макет ясарга керешә. Эше тәгәлләнгән шикелле күренгәч, Фәннәр Академиясенә бара да, күк йөзен өйрәнүгә кагылышы булган хезмәткәрләргә эшен күрсәтә-күрсәтә, астрономия тарихы буенча лекция укый. Архитекторның чыгышы тәмамлангач, академик-астроном В. П. Щеглов гаҗәпләнеп һәм хуплап:

— Фикерләрегез, тикшеренүләрегез ышандыра. Обсерватория мәсьәләсендә сез безне астрономнарны, узгансыз икән! — дип белдерә.

Үзбәкстанның атказанган төзүчесе, күп кенә орден, медальләр кавалеры М. Булатов бүген дә әнә шундый нәтиҗәле фәнни тикшеренүләр алып бара. Олугбәк обсерваториясен һәм башка проектларын кәгазьдән ташка күчерү, үзен дулкынландырган мәсьәләләр буенча яңа фикер әйтү үе белән яна. Ул бүген дә байтак мәртәбәле советларның әгъзасы, рус, үзбәк, гарәп, инглиз телләрендә басылган күп кенә китап, фәнни хезмәтләрнең авторы, яшьләрнең яраткан һәм юмарт остазы. Үзбәкстаннан еракта да аны инде күптән хыялый практик, реалистик фантазиягә ия архитектор һәм галим, киң карашлы актив җәмәгать эшлеклесе буларак таныганнар.

Халкыбыз аны, гүя үткәнгә хөрмәтен, бүгенгә мәхәббәтен, киләчәккә өметен нисбәтләр музыкасына, хикмәтләр хәзинәсенә әверелдерсен өчен генә тудырган, үстергән шикелле. Мидхәт Булатов исә, гүя, шул теләкне үтәр өчен гомере буе заманнар бәйләнешен өйрәнә, өлкән буыннар тәҗрибәсен, белемен үзләштерә һәм, шуларга таянып, яңага атлый — гыйльми табышлары, төзүче-практик казанышлары белән гасырларга һәйкәл сала. Ул һәйкәл бай эчтәлекле, матур һәм мәһабәт.

# Зәки Нури

## Китап лотереясы

Ярминкәдә уен өч көн барды.
Оталмады күпләр, оттырдылар...
Өч көн рәттән откан бер шагыйрьгә
Үз китабын... күпләп тоттырдылар.

## Төн куна барып

Канатлы ат алды. Бер дустына
Вәгъдә иткән, имеш, колынын да.
Шул атны ул, үзе куна барып,
Ашата ди кеше болынында.

## Аның мәхәббәт баскычлары

— Минем сөю өч баскычлы булды,
Кыска булды минем ярату:
Танышу. Туй. Алименттан качып,
«Үлде» дигән хәбәр тарату.

## Инде төкерә

Бакчасына аткан тәнкыйть ташларын
Җыя барып, корды биек бер стена.
Инде хәзер шуннан торып төкерә
Кем таш атты — шуның барсы өстенә.

## Астыртын тәнкыйть

Бәб-бәләкәй көчекләр дә
Зур этлек эшли ала:
Хәтта артыңнан килгәнен
Сиздерми тешли ала.

## Өй тавыгы

Чыкмый. Йөрми. Тора дачада...
Өстән төшкән дөнья нужасы.
Әйтеп торып шигырь яздыра —
Машинкада суга... Пегасы.

## Тискәре

Сүз әйтсәң дә, җил какса да,
Акланырга сәбәп таба...
Ник икән имән тактага
Һаман юкә кадак кага?

---

ЗӘКИ НУРИ *(1921) — шагыйрь, «Еллар һәм юллар», «Лирика, юмор, сатира», «Күңел яктысы» һ. б. татар һәм рус телләрендә басылган күп санлы шигырь китаплары авторы. РСФСРның атказанган культура хезмәткәре. Казанда яши.*

## ИҖАТ ИНТЕЛЛИГЕНЦИЯСЕ АРЧА РАЙОНЫНДА

27 февральдә КПСС өлкә комитеты каршында республика иҗат интеллигенциясе өчен даими эшләүче семинарның чираттагы занятиесе булды. Ул Арча районы хезмәтчәннәре белән очрашу, хезмәт һәм әдәбият-сәнгать дуслыгын ныгыту мәсьәләләре турында җитди сөйләшү рәвешендә үткәрелде. Анда катнашучылар районның «Авангард» колхозында, милли аяк киемнәре производство берләшмәсендә булдылар.

Район культура йортында язучылар, композиторлар, художниклар, театр һәм кино работниклары, филармония артистларының район хезмәт ияләре вәкилләре белән очрашуы булды. Анда КПСС өлкә комитетының культура бүлеге мөдире Д. Х. Зарипова республикабызның узган ел халык хуҗалыгында һәм культура тормышында ирешкән уңышлары, иҗат интеллигенциясе алдында торган бурычлар турында сөйләде.

Очрашуда КПССның Арча район комитеты беренче секретаре Д. К. Каюмов, «Искра» колхозы председателе Ф. Ә. Галиев, ТАССР Язучылар союзының партия оешмасы секретаре Р. Мостафин, ТАССР Кинематографистлар союзы идарәсенең беренче секретаре Х. Ф. Фәхретдинов, ТАССР Художниклар союзы идарәсе председателе В. М. Маликов, ТАССР Композиторлар союзы идарәсе председателе урынбасары Р. Н. Билалов чыгыш ясадылар. Аннары Татарстан сәнгать осталары һәм Арча районы үзешчәннәре концерты булды.

## ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ПАРТИЯ ОЕШМАСЫНДА

23 мартта Татарстан Язучылар союзының ачык партия җыелышы булып узды. «Татар китапларын пропагандалауда, таратуда партия оешмасының һәм Татарстан Язучылар союзы идарәсенең роле» дигән доклад белән идарә члены, язучы Мәдинә Маликова чыкты. Җыелышта язучылар, нәшрият хезмәткәрләре һәм матур әдәбиятны пропагандалаучы оешмалар җитәкчеләре арасында әлеге мәсьәлә буенча эшлекле сөйләшү, фикер алышу булды.

Фикер алышуларда язучылар Г. Бәширов, С. Баттал, Б. Гыйззәт, В. Нуруллин, Р. Мингалимов, Р. Фәйзуллин, Р. Харис, Р. Хәмид, М. Хуҗин, Р. Вәлиев һ. б. чыгыш ясады.

## БАКЫЙ УРМАНЧЕ ЮБИЛЕЕ

25 февральдә Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрының яңа бинасында Бакый Урманчега 90 яшь тулуга багышланган тантаналы кичә булды.

Юбилей кичәсен ТАССР Министрлар Советы Председателенең беренче урынбасары М. Х. Хәсәнов ачты.

Кичәдә КПСС өлкә комитеты беренче секретаре Г. И. Усманов чыгыш ясады. КПСС өлкә комитеты бюросы, ТАССР Верховный Советы Президиумы һәм Министрлар Советы исеменнән ул Бакый Идрисович Урманчены 90 яше тулу белән котлады һәм СССР Верховный Советы Президиумы исеменнән юбилярга Халыклар Дуслыгы орденын тапшырды.

Б. Урманченың тормыш һәм иҗат юлы турында ТАССР культура министры М. М. Таишев сөйләде.

Юбилярны СССР Художниклар союзы идарәсенең беренче секретаре, СССР Художество академиясенең действительный члены, СССРның халык художнигы Т. Т. Салахов котлады. Ул шулай ук ТАССР Язучылар союзына бөек татар халык шагыйре Габдулла Тукайның танылган рәссам Ә. И. Китаев ясаган зур портретын бүләк итте.

Б. Урманчены иҗат союзлары, республика җәмәгатьчелеге исеменнән Социалистик Хезмәт Герое, СССРның халык артисты Н. Г. Җиһанов, ТАССР Художниклар союзының яшьләр берләшмәсе җитәкчесе Ш. М. Шәйдуллин, Ташкенттан архитектор Н. Абдрахимов һ. б. тәбрикләделәр.

Тантананың икенче өлешендә Татарстан сәнгать осталары катнашында концерт булды.

Республикабыз җәмәгатьчелеге татар сынлы сәнгатенә нигез салучыларның берсе, РСФСРның һәм ТАССРның халык художнигы, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Бакый Идрисович Урманчега 90 яшь тулуны киң билгеләп үтте. Шушы уңайдан СССР Фәннәр академиясе Казан филиалының Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында аның иҗатына багышланган киңәйтелгән утырыш булды. ТАССР Сынлы сәнгать музеенда аның әсәрләреннән оештырылган күргәзмә ачылды. 25 февральдә күргәзмәгә куелган экспонатлар белән КПСС өлкә комитетының беренче секретаре Г. И. Усманов, ТАССР Верховный Советы Президиумы Председателе Ш. Ә. Мустаев, Татарстан АССР Министрлар Советы Председателе М. Ш. Шәймиев, КПСС өлкә комитеты секретаре Р. К. Бе-

ляев, СССР Художниклар союзы идарәсенең беренче секретаре, СССРның халык художнигы Т. Т. Салахов таныштылар.

## ҖӘЛИЛ БӘЙРӘМЕ

Казанда герой-шагыйрьнең истәлегенә багышлап телевизион политик поэзия митингы уздыру күркәм гадәткә әйләнде. Быел да 13 февральдә Казан дәүләт университетының мәрмәр залында шундый митинг булды. Аны шагыйрь Ренат Харис алып барды. Шагыйрьләр Н. Дәүли, Ш. Галиев, И. Юзеев, Роберт Әхмәтҗанов, М. Шабаев, Р. Гатауллин, Зөлфәт h. б. үзләренең яңа шигырьләрен укыдылар. Архангельскидан килгән җәлилче, фронтовик М. Иконников шагыйрьнең үлемсез батырлыгы турында сөйләде.

Бу кичәне зәңгәр экраннан 15 февральдә тамашачылар да карады.

## ӘДИП ЮБИЛЕЕНА БАГЫШЛАП

20 февральдә Казанның Актерлар йортында атаклы язучы, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Ибраhим Газиның тууына 80 ел тулуга багышланган хөрмәтләү кичәсе булып узды. Язучының тормыш hәм иҗат юлы турында тәнкыйтьче Р. Мостафин сөйләде.

Әсәрләре әдәбиятыбызның алтын фондына кергән язучы турында Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе Т. Миңнуллин, язучылар Л. Ихсанова, В, Нурулин, тәнкыйтьче Ф. Миңнуллин истәлекләр, аның иҗатының үлемсезлеге турында сөйләделәр.

## ШАГЫЙРЬ ТУГАН ЯКТА

14 февральдә татар халык шагыйре Сибгат Хәкимнең туган авылы Күлле-Кимедә, шагыйрьнең тууына 75 ел тулуга багышланган әдәби кичәләр булып узды.

Күлле-Киме авылына шагыйрьләр И. Юзеев, Ш. Галиев, Р. Гатауллин, Р. Миңнуллин, Л. Шакирҗанова, җырчы Г. Сафиуллина, композитор Р. Гатауллин, артистка Луара Шакирҗановалар килгән иде Башта — мәктәптә, кичен — авыл клубында hәм авылдагы С. Хәким музеенда уздырылган очрашуларда шагыйрь иҗаты турында җылы аңгәмәләр булды, әсәрләре башкарылды.

## ИҖАТ СЕКЦИЯЛӘРЕНДӘ

16 февральдә проза секциясенең чираттагы утырышы булды. Анда яшь язучы Зиннур Хөснетдиновның кульъязма җыентыгы укып тикшерелде.

Язучылардан М. Мәhдиев, М. Хәсәнов, К. Тимбикова, М. Әгъләмов, М. Галиев, Р. Низамиев, С. Шәмси, Х. Гайнетдинов, Р. Зәйдуллин h. б. авторның хикәяләрен анализладылар, үзләренең киңәш-теләкләрен әйттеләр.

3. Хөснетдиновның беренче китабын, яңа әсәрләр белән тулыландырып, Татарстан китап нәшриятына тәкъдим итәргә дигән карар кабул ителде.

Тәнкыйтьчеләр секциясенең 18 февральдә булган чираттагы утырышында «Яңарыш чоры hәм безнең әдәби тәнкыйть» дигән мәсьәлә тикшерелде. Анда И. Нуруллин, Р. Мостафин, М. Хәбибуллин, Ф. Мусин, Н. Ханзафаров, Мансур Вәлиев, Мөдәррис Вәлиев, Ф. Бәйрәмова, М. Галиев, М. Гайнетдинов, Н. Гыйматдинова, Ф. Зөлкарнәев, Р. Гыйззәтуллин h. б. катнашты.

## БРЕЖНЕВ ЯЗУЧЫЛАР ОЕШМАСЫНДА

23 январьда Брежнев язучылар оешмасында Е. Прохоров, Н. Кандудина hәм Ф. Җамалетдинованың кульъязма китаплары тикшерелде.

Фикер алышуларда Брежнев язучылар оешмасы җаваплы секретаре Я. Игънәй, язучылар Р. Хисмәтуллин, Г. Кашапов, К. Сибгатуллин, Н. Мадъяров, Р. Сәлимҗанов, Н. Алешков, И. Лимонова, Р. Бәшәр, Х. Хөснуллин, «Орфей» hәм «Ләйсән» әдәби берләшмәләре членнары катнашты.

## ШАГЫЙРЬЛӘР КИЧӘСЕ

23 февральдә Казанның Киров исемендәге Культура сараенда Рәдиф Гатауллин hәм Роберт Миңнуллин иҗатына багышланган кичә булды. Кичәнең Р. Гатауллин иҗатына багышланган өлешендә шагыйрьнең төрле елларда язылган шигырьләрен РСФСР халык артисты Р. Тажетдинов, ТАССРның атказанган артистлары Ә. Яhудин, И. Әхмәтҗановлар укыды, шагыйрь сүзләренә җырларны Татарстанның атказанган артисткасы Л. Хәсәнова, К. Хәйретдинова, Ф. Низамовалар башкарды. Р. Миңнуллин шигырьләре исә артистлардан РСФСРның атказанган артисты Р. Шәрәфиев, Татарстанның атказанган артисты Х. Җәләлов, Л. Шакирҗанова, аның сүзләренә җырлар — Татарстанның халык артисткасы Н. Теркулова, Татарстанның атказанган артисты М. Галиев, композитор Р. Абдуллин h. б. башкаруында яңгырады.

## ЯШЬ ТӘНКЫЙТЬЧЕЛӘР ТҮГӘРӘГЕНДӘ

«Казан утлары» редакциясе каршында эшләп килүче яшь тәнкыйтьчеләр түгәрәге hәр атнаның җомга көнендә үзенең утырышларын үткәрә. Январь hәм февраль айларында яшь тәнкыйтьчеләр Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе Т. Миңнуллин белән очраштылар, Рәшит Әхмәтҗановның «Бишташ» поэмасын hәм М. Галиевнең «Сатурн hәм умач» хикәясен тикшерделәр, шулай ук каләмдәшләре Ф. Бәйрәмова, Р. Нуретдинов, Ф. Яхин, Ф. Низамова, С. Зарипова hәм Н. Нуриевларның яңа иҗат ителгән әдәби тәнкыйть әсәрләре хакында фикер алыштылар.

# ХӘСИТӘ

Безнең көннәргә кадәр килеп җиткән борынгы сәнгать җәүһәрләре арасында зәвыклы татар осталары эше — Мәскәү, Ленинград, Казан шәһәрләрендәге коллекцияләрдә саклanучы хәситәләр аеруча игътибарга лаек.

Хәситә — елтырап торган алтын-сары яисә көмеш ука тукыма өстенә нәфис итеп тезелгән таңкәләр, кыйммәтле ташлар, нечкә металл чыбыклардан үреп ясалган үтә күренмәле алтын-көмеш челтәрләр, коеп, яисә үреп эшләнгән түгәрәк бизәкле төймәләр, төрле вак, зиннәтле асылташлар куеп эшләнгән түшьяпма, татар хатын-кызларының гаять оригиналь һәм нәфис бизәнгече. Аның халкыбыз яшәгән төрле төбәкләрнең күзаллавы һәм сөйләше рухында төрле атамалары бар: хәситә, дәвәт, ачкыч-бау, муйтомар, бөти, хәмаил һ. б. Хәситә күлмәк өстеннән күкрәккә — уң җилкәдән түш буйлап сул кул астына таба юнәлтелә, аркада аның ике таррак очы матур каптырма белән, яисә каптырмасыз, беркетеп куела. Хәситәләр борынгы чорларда, мәҗүсилек заманында кешенең җанын, иминлеген саклаучы, төрле бәла-казалардан, авырулардан коткаручы бөти йөртү традициясе белән бәйләнгән булырга тиеш.

Хәмаил-хәситәләрнең, күптәннән мәгълүм булып, татар халкы арасында күп вакытлар буена яшәп килгәнлеген археологик табылдыклар һәм борынгы фольклор ядкарьләре раслыйлар. «Түләк» дастанында, мәсәлән, баһадир һәм озанчы (музыкант) Түләккә гашыйк булган Су пәрие Чачдар ханның кызы Сусылу, егетне үзенә багындыру өчен, аңа куш хәмаил, куш йөзек кебек тылсымлы әйберләр бүләк итмәкче була. Биредә әле борынгы хәмаил-хәситә кешене хорафаттан саклый торган аны илаһи көч белән бәйләүче сихри амулет функциясендә телгә алына.

Соңгы дәверләрдә хәситәләрнең дини эчтәлекләре бетеп, декоратив, эстетик сыйфатлары беренче планга калкып чыга.

Республикабыз сынлы сәнгать музее экспозициясенә куелган хәситә гаять бай һәм искиткеч зиннәтле булуы, нәфислеге, сәнгатьчә камиллеге, ювелир сәнгатенең төрле ысулларын берләштерүе белән бу төр иҗатның югары бер үрнәге булып килеп баса. Чама белән алганда, XIX гасыр башларына караган бу хәситәдә, аерым алганда, тагы да борынгырак, хәтта Алтын Урда һәм Казан ханлыгы чорларында башкарылган фрагментлар, детальләр булу ихтимал (шәҗәрә агачы формасындагы алтын кәгазь белән төреп ясалган сынчыклар, алтын суына манып эшләнгән төймәләр). Төрле тарихи катлам, төрле гасыр, төрле металл, таш һәм техниканы берләштергән хәситә асылда бербөтен нәфис композиция тәшкил итә. Аның концепциясе хәситәнең формасында — ярым-ай, ярым-кояш сурәтен хасил иткән иң затлы, иң төп өлешендә чагылыш таба. Безнең алдыбызда — елкылдап, җемелдәп, нур сибеп торган күк гөмбәзе кисәге; бу — безнең борынгы ата-бабаларыбызның ай-кояшка, күк алласы — тәңрегә табынуыннан туган форма; борынгы кешене күк стихиясе, космос, галәм белән бәйләүче сурәт.

Дулкынсыман салмак бербөтен ритмның астагы «зур телләре» — үтә күренмәле көмеш челтәрләр өстенә утыртып куелган бәллүр сыман, ут уйнатып торган монументаль кашлардан гыйбарәт; нурлары челтәр яссылыкларына кереп, аларның композициясен үзләренә буйсындырып, зур «гөл балкышлары» хасил итәләр. Бу ташларның уңнан-сулга хәрәкәтен нәзакәтле ювелир ысулы — кабарынкы челтәр ысулында сынландырылган зәңгәр лазуритны уртасына алган дүртпочмаклы челтәр тәгәлли.

Урта рәттә — бизәкле челтәр рама эченә алынган дүртпочмаклы һәм түгәрәк шома фирәзә ташлар билгеле бер интервал аша тезелеп киләләр.

Югары, өске өлештә исә хәситәне вак-вак алсу-кызыл, лал (рубин) сыман һәм ак пыяла кашларның ритмик фризы бизи. Бу өч рәт арасына — төрле вак асылташлар, ак ахак, гранат, шәмәхә төстәге аметист, агат, хрусталь төймәләр, йөрәк, орлык, тәлгәш сыман асылмалар эленгән.

XIX гасырның ахырларында, көнкүреш, гореф-гадәтләр, кием-салымнар үзгәрү белән, хәситәләр, кием ансамбленнән чыгып, халык сәнгате традицияләрен туплаган күркәм бер иҗат эшенә әйләнеп калалар.

**Розалина ШАҺИЕВА,**
Татарстан сынлы сәнгать музееның
фәнни хезмәткәре

**Юрий ФИЛИМОНОВ** фотосы

**Тышлыкның дүртенче битендә:** Казанның М. Горький исемендәге культура һәм ял паркы каршында каһарманнар истәлегенә куелган һәйкәл.

**Рөстәм МАНСУРОВ** фотосы

Бәясе 90 тиен.
Цена 90 коп.

Индекс 73210



КАЗАН УТЛАРЫ
(ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ
(на татарском языке)